# МАТТАЙ БӘЯН ИТКӘН ЯХШЫ ХӘБӘР

*Гайсәнең нәсел шәҗәрәсе*

**1** [1] Ибраһим һәм Давыт токымыннан булган Гайсә Мәсихнең
нәсел шәҗәрәсе.
[2] Ибраһим Исхакның, Исхак Ягъкубның, Ягъкуб Яһүднең
һәм аның агай-энеләренең әтисе, [3] Яһүд Тамардан туган Перес
һәм Зерахның әтисе, Перес Хесрунның, Хесрун Рамның, [4] Рам
Амминадабның, Амминадаб Нахшунның, Нахшун Салмунның,
[5] Салмун Рәхәбтән туган Богазның, Богаз Руттан туган Обид-
нең, Обид Ишайның, [6] Ишай Давыт патшаның әтисе иде.

Давыт Уриянең хатыныннан туган Сөләйманның, [7] Сөләй-
ман Рихәбәмнең, Рихәбәм Абиянең, Абия Асаның, [8] Аса Еһо-
шафатның, Еһошафат Яһурамның, Яһурам Уззиянең, [9] Уззия
Йотамның, Йотам Әхәзнең, Әхәз Хизәкыйянең, [10] Хизәкыйя
Менашенең, Менаше Амонның, Амон Йошиянең әтисе иде.
[11] Исраил халкы көчләп Бабылга күчерелү дәверендә Йошиянең
улы Еһоякин һәм аның агай-энеләре туды.

[12] Бабылга көчләп күчерелгәннән соң, Еһоякиннең улы
Шеһалтиел туды. Шеһалтиел Зеруббабелның, [13] Зеруббабел Аби-
һудның, Абиһуд Эльякыймның, Эльякыйм Азурның, [14] Азур
Садыйкның, Садыйк Ахимнең, Ахим Элиудның, [15] Элиуд Элья-
зарның, Эльязар Маттанның, Маттан Ягъкубның, [16] Ягъкуб –
Мәрьямнең ире Йосыфның әтисе иде. Мәрьямнән Мәсих дип
аталган Гайсә туды.

[17] Ибраһимнан Давытка кадәр барлыгы ундүрт буын, Да-
выттан алып Бабылга көчләп күчерелгән вакытка кадәр ундүрт
буын һәм Бабылга күчерелеп, Мәсих туганга кадәр ундүрт буын
булды.

*Гайсәнең тууы*

[18] Гайсә Мәсихнең тууы менә болай булган: анасы Мәрьям
Йосыф белән ярәшелгән булган, әмма алар никахлашканчы,
Мәрьямнең Изге Рухтан балага узганы ачыкланган. [19] Ире
Йосыф исә тәкъва кеше буларак, Мәрьямне оятка калдырмас

өчен, ярәшүне яшертен генә өзәргә ниятләгән. [20] Әмма ул
ниятләгәч, төшендә аның янына Раббы фәрештәсе килде
һәм:
– Давыт нәселеннән булган Йосыф! Мәрьямне хатын итеп
алырга курыкма. Ул карынында йөрткән бала Изге Рухтан
уздырылган. [21] Ул ир бала тудырачак. Син Аңа Гайсә* дип исем
кушарсың, чөнки Ул Үзенең халкын гөнаһлардан коткарачак! –
диде.
[22] Болар барысы да Раббының пәйгамбәр аша:
[23] «Менә, гыйффәтле кыз балага узачак һәм ир бала
тудырачак.
Аңа Иммануил дип исем кушарлар», –
дигән сүзләре гамәлгә ашсын өчен булды. «Иммануил» –
«Аллаһы безнең белән» дигәнне аңлата.
[24] Йосыф йокысыннан уянгач, Раббының фәрештәсе нәрсә
кушкан булса, шуны эшләде: ул Мәрьямгә өйләнде. [25] Әмма
Мәрьям Улын тудырганчы Йосыф аңа якынаймады. Балага ул
Гайсә дип исем кушты.

### *Йолдызчыларның килүе*

**2** [1] Гайсә, Һируд патша идарә иткән вакытта, Яһүдия җирен-
дәге Бәйтлехем шәһәрендә туды. Көнчыгыштан йолдыз-
чылар Иерусалимга килделәр.
[2] – Яңа туган яһүдләр Патшасы кайда? – дип сорадылар
алар. – Без көнчыгыштан Аның йолдызын күрдек һәм Аңа
табыну өчен сәҗдә кылырга дип килдек.
[3] Һируд патша, бу хакта ишеткәч, хафага төште. Һәм аның
белән бергә бөтен Иерусалим хафаланды. [4] Халыкның барлык
баш руханиларын һәм канунчыларын җыеп, ул алардан Мәсих-
нең кайда туарга тиешлеген сорады.
[5] – Яһүдия җирендәге Бәйтлехем шәһәрендә, – диделәр
алар. – Чөнки пәйгамбәр аркылы Аллаһы болай дип әйткән:
[6] «Һәм син, Яһүд җирендәге – Бәйтлехем!
Яһүд җирендәге мөһим шәһәрләрдән
иң түбәне түгелсең.
Чөнки синнән Юлбашчы чыгачак.
Ул Минем Исраил халкымның Көтүчесе булачак».
[7] Шуннан соң Һируд, йолдызчыларны яшертен рәвештә ча-
кыртып алып, алардан йолдызның төгәл калыккан вакытын
белеште [8] һәм, аларны Бәйтлехемгә җибәреп:

---

* 1:21 *Гайсә* – яһүдчә «Йеһошуа»; бу исемнең мәгънәсе: «Раббы кот-
кара». Сүзлекне карагыз.

– Барыгыз, Бала хакында барын да җентекләп белешегез.
Аны тапкач, миңа хәбәр итегез. Мин дә Аңа сәҗдә кылырга
барыр идем, – диде.
9 Патшаны тыңлаганнан соң, йолдызчылар юлга чыктылар,
һәм алар көнчыгышта күргән йолдыз аларның алларыннан
барды. Бала булган урынга килеп җиткәч, ул шул урын өстендә
туктады. 10 Йолдызны күреп, алар шундый шатландылар, шун-
дый сөенделәр! 11 Йолдызчылар, өйгә кергәч, анасы Мәрьям
белән Баланы күрделәр. Бала каршында сәҗдә кылдылар, анна-
ры, хәзинә сандыкларын ачып, Аңа алтын, ладан һәм мирра
дигән хуш исле майлар бүләк иттеләр. 12 Төшләрендә Һируд
янына кире килмәскә дип кисәтү алгач, башка юл белән үз
илләренә кайтып киттеләр.

*Мисырга качу*

13 Алар китү белән, Раббы фәрештәсе Йосыфның төшендә
күренеп:
– Баланы анасы белән алып Мисырга кач. Мин сиңа әйт-
кәнгә кадәр шунда кал. Чөнки Һируд, Баланы табып, үтерергә
ниятли, – диде.
14 Ул, торып, анасы белән Баланы алды һәм төнлә белән
Мисырга китте. 15 Һируд үлгәнгә кадәр ул анда калды. Бу исә
Раббының пәйгамбәр аша: «Мисырдан чакырып алдым Мин
Үземнең Улымны», – дигәннәре гамәлгә ашсын өчен булды.

*Сабыйларны үтереш*

16 Һируд үзенең йолдызчылар тарафыннан алданганын күреп,
бик ярсыды. Ул, Бәйтлехемдә һәм аның тирәсендә яшәүче ике
яшькә кадәр булган, ягъни йолдызчылар аркылы белгән вакыт-
та туган бөтен ир балаларны үтерергә боерып, гаскәриләрен
җибәрде. 17 Иремия пәйгамбәр аша әйтелгәннәр шулай гамәлгә
ашты:
18 «Рама шәһәрендә көчле тавыш,
кычкырып һәм ыңгырашып елау ишетелә.
Бу – балалары өчен Рәхилә елый
Һәм үзенә юатуны теләми,
чөнки алар юк инде».

*Мисырдан әйләнеп кайту*

19 Һируд үлгәннән соң, Мисырда Йосыфның төшендә
Раббының фәрештәсе күренеп:
20 – Тор, Баланы анасы белән алып, Исраил җиренә әйләнеп
кайт. Чөнки Баланы үтерергә теләүчеләр инде үлделәр, – диде.

[21] Йосыф торды да, анасы белән Баланы алып, Исраил җиренә
китте. [22] Әмма Яһүдиядә атасы Һируд урынына Архелай патша
идарә итүен ишетеп, Йосыф анда барырга курыкты. Төшендә
кисәтү алгач, ул Гәлиләя өлкәсенә китте һәм [23] Насара шәһәре-
нә барып урнашты. Раббының пәйгамбәрләр аркылы: «Аны
„Насаралы“ дип атарлар», – дигән сүзләре шулай гамәлгә ашты.

*Чумдыручы Яхъяның вәгазьләве*

**3** [1] Ул көннәрдә Яһүдия чүленә Чумдыручы* Яхъя килде.
[2] Ул:
– Тәүбә итегез, Күкләр Патшалыгы якынлашты! – дип
игълан итте.

[3] Ишагыйя пәйгамбәр:

«Чүлдә кычкыручының тавышы:
„Раббыга юл әзерләгез,
Аңа сукмакларны турайтыгыз“», –

дип Яхъя турында әйткән иде.

[4] Яхъя дөя йонынннан булган киемен күн каеш белән буып
йөрде. Ашаган ризыгы саранча һәм кыр балы иде. [5] Аның яны-
на Иерусалим халкы һәм бөтен Яһүдия белән Үрдүн буе төбә-
гендә яшәүчеләр килә иде. [6] Килүчеләр үзләренең гөнаһларын
икърар иттеләр, һәм аларны Яхъя Үрдүн елгасында чумдырды.

[7] Суга чумдырылырга дип, күп фарисейләрнең һәм саддукей-
ларның** килүен күреп, ул аларга:

– Сез, елан токымы! Аллаһының якынлашып килүче ачуын-
нан кача алырбыз, дип сезгә кем әйтте? [8] Ихлас күңелдән тәүбә
иткәнегезне күрсәтә торган җимеш китерегез. [9] «Безнең ата-
быз – Ибраһим», – дип күңелегездән әйтәсе булмагыз. Сезгә
әйтәм: Аллаһы менә бу ташлардан Ибраһимга балалар булдыра
ала. [10] Балта агачлар төбендә ята, ул инде әзерләп куелган:
яхшы җимеш бирми торган һәр агачны кисеп утка ташлыйлар.
[11] Мин, тәүбә итүегезнең билгесе итеп, сезне суга чумдырам.
Әмма артымнан Килүче миннән кодрәтлерәк. Мин Аның аяк
киемнәрен күтәреп йөреп хезмәт күрсәтергә лаексыз. Ул сезне
Аллаһы Рухына һәм утка чумдырыр. [12] Аның кулында җилгәр-
геч; Ул ашлыкны ындырда җилгәреп, бодаен ашлык бурасына
салыр, ә кибәген сүнмәс утта яндырыр, – дип әйтте.

---

* 3:1 *Суга чумдырылу* – тәүбә итүне һәм үзеңне Аллаһы Тәгаләгә ба-
гышлауны күрсәтә торган йола.

** 3:7 *Фарисейләр* – борынгы яһүдләр арасындагы дини төркем.
*Саддукейлар* – яһүдләрнең йолаларын тотучы дини төркем. Алар
үледән терелүгә ышанмаганнар.

### *Гайсәнең суга чумдырылуы*

[13] Шул вакытта, Үрдүн елгасында Яхъя тарафыннан суга
чумдырылу өчен, Гәлиләядән Гайсә килде. [14] Яхъя исә Аны
туктатырга тырышып:

– Син мине чумдырырга тиеш, ә Син миңа килгәнсең! – диде.

[15] – Хәзер шулай булсын. Аллаһы ихтыярын без шуның белән үтәрбез, – диде аңа Гайсә.

Шуннан соң Яхъя риза булды. [16] Чумдырылу белән үк Гайсә
судан чыкты. Шул вакытта ук күкләр ачылды, һәм Ул Үзенә
Аллаһы Рухының күгәрчен рәвешендә иңүен күрде. [17] Күктән:

– Бу Минем сөекле Улым, Ул Минем куанычым, – дигән тавыш килде.

### *Гайсәнең сыналуы*

**4** [1] Шуннан соң, Рух Гайсәне иблистән сынатыр өчен чүлгә
алып китте. [2] Ризык капмыйча кырык көн һәм кырык төн
үткәреп, Гайсә бик нык ачыкты. [3] Сынаучы иблис, Аның
янына килеп:

– Әгәр Син Аллаһы Улы булсаң, бу ташлар икмәк булсыннар, дип боер, – диде.

[4] Гайсә җавап бирде:

– «Кеше икмәк белән генә түгел, бәлки Аллаһы әйткән һәр сүз белән яшәр», – дип язылган Изге язмада!

[5] Шуннан соң, иблис Аны Иерусалимга – изге шәһәргә алып
килеп, Аллаһы Йорты түбәсенең читенә бастырды [6] һәм әйтте:

– Әгәр Син Аллаһы Улы булсаң, түбәнгә ташлан! Изге язмада әйтелгән бит:

«Аллаһы Үзенең фәрештәләренә Синең турыда
кайгыртырга әмер бирер.
Алар Сине күтәреп алырлар,
аякларың ташка бәрелмәс».

[7] – Анда: «Раббы Аллаһыңны сынама», – дип тә язылган, – дип җавап бирде Гайсә.

[8] Аннары иблис Аны бик биек тауга алып менеп, дөньядагы
барлык патшалыкларны һәм аларның бөтен шөһрәтләрен күрсәтте [9] һәм әйтте:

– Әгәр Син йөзтүбән капланып, миңа табынсаң, боларның һәммәсен Синә бирермен!

[10] – Кит, шайтан! – дип җавап бирде Гайсә. – Язылган: «Раббы Аллаһыңа табын, Аңа гына хезмәт ит».

[11] Шуннан соң иблис Аны калдырып китте, һәм Гайсә янына
фәрештәләр килделәр һәм Аңа хезмәт иттеләр.

*Гайсәнең хезмәт итә башлавы*

[12] Яхъяның төрмәгә утыртылуы хакында белгәннән соң,
Гайсә кире Гәлиләягә кайтты. [13] Насараны калдырып китеп, Ул
Гәлиләя диңгезе* янындагы Зебулун һәм Нафтали җирендәге
Кәпәрнаум шәһәренә барып урнашты. [14] Бу исә, Ишагыйя пәй-
гамбәр аша әйтелгәннәр гамәлгә ашсын өчен булды:

[15] «Зебулун җире, Нафтали җире!
Диңгезгә алып баручы юл,
Үрдүн аръягындагы Гәлиләя – мәҗүсиләр иле!
[16] Караңгылыкта яшәүче халык бөек яктылыкны күрде.
Үлем караңгылыгында яшәүчеләр өчен таң атты».

[17] Шул вакыттан алып Гайсә:
– Тәүбә итегез! Күкләр Патшалыгы якынлашты! – дип игъ-
лан итеп йөрде.

*Гайсәнең беренче шәкертләре*

[18] Гәлиләя диңгезе яныннан үтеп барганда, Гайсә ике бертуган-
ның – Петер дип аталган Шимун һәм аның энесе Әндринең –
диңгезгә ятьмә салуларын күрде. Алар балыкчылар иде.
[19] – Миңа иярегез! Мин сезне кешеләр тотучы** итәрмен! –
диде аларга Гайсә.
[20] Алар шунда ук ятьмәләрен калдырып, Аңа иярделәр. [21] Аннан
киткәч, Гайсә башка ике бертуганны – Зебедәй улы Ягъкубны
һәм аның туганы Яхъяны күреп алды. Алар үзләренең аталары
Зебедәй белән бергә көймәдә ятьмәләрен төзәтәләр иде. Ул
Үзенә иярергә өндәде. [22] Алар шунда ук көймәне һәм аталарын
калдырып, Гайсәгә иярделәр.

*Гайсә өйрәтә, савыктыра*

[23] Гайсә бөтен Гәлиләя җирендә гыйбадәтханәләрдә өйрәтеп,
Патшалык хакында Яхшы хәбәрне игълан итеп, халыкны төрле
авырулардан һәм чирләрдән савыктырып йөрде. [24] Бөтен Сурия
буйлап Аның хакында хәбәр таралды. Аның янына төрле авы-
рулардан һәм интектергеч чирләрдән җәфаланганнарны, җен-
леләрне, өянәк белән авырганнарны һәм паралич сукканнарны
алып килделәр. Гайсә аларны савыктырды. [25] Аның артыннан
Гәлиләядән, Ун каладан, Иерусалимнан, Яһүдиядән һәм Үрдүн
аръягыннан килгән халык төркемнәре йөрде.

---

* **4:13** *Гәлиләя диңгезе* – аны Геннисарет күле дип тә атыйлар.

** **4:19** *Кешеләр тотучы* – Гайсә бу урында кешеләрне Аллаһы юлы-
на алып килүне балык тоту белән чагыштыра.

*Таудагы вәгазь*

**5** [1] Халык төркемнәрен күреп, Гайсә тауга менде. Ул утыргач,
Аның янына шәкертләре килделәр.

*Чын бәхет*

[2] Гайсә аларны өйрәтә башлады һәм әйтте:
3 – Рухи яктан фәкыйрьләр бәхетле,
чөнки Күкләр Патшалыгы аларныкы.
4 Хәсрәт кичерүчеләр бәхетле,
чөнки Аллаһы аларны юатыр.
5 Юашлар бәхетле,
чөнки Аллаһы аларга җир өстеннән хакимлек итәргә
бирер.
6 Тәкъвалыкка ачыккан һәм сусаган кешеләр бәхетле,
чөнки Аллаһы аларның ул теләгән үтәр.
7 Шәфкатьлеләр бәхетле,
чөнки аларга шәфкать күрсәтелер.
8 Саф күңеллеләр бәхетле,
чөнки алар Аллаһыны күрерләр.
9 Татулык урнаштыручылар бәхетле,
чөнки Аллаһы аларны Үзенең балалары дип атар.
10 Тәкъва булганнары өчен эзәрлекләнгәннәр бәхетле,
чөнки Күкләр Патшалыгы аларныкы.

[11] Кешеләр сезне Минем аркада хурлаганда, эзәрлекләгәндә
һәм сезгә каршы төрле явызлык эшләгәндә, сез бәхетле.
[12] Шатланыгыз һәм куаныгыз! Күкләрдә сезнең әҗерегез зур
булачак. Чөнки сезгә кадәр яшәгән пәйгамбәрләрне дә шулай
эзәрлекләделәр.

*Тоз һәм яктылык*

[13] Сез – җир тозы. Әгәр тоз үз тәмен югалтса, аңа ничек тәм
кертерсең? Ул, чыгарып ташланып, кешеләрнең таптавыннан
башка һичнәрсәгә дә яраклы булмас.

[14] Сез – дөнья өчен яктылык. Тау башындагы шәһәр күренми
кала алмас. [15] Шулай ук шәмне яндыргач, аны чүлмәк астына
куймыйлар, бәлки шәмдәлгә утырталар, һәм ул өйдәгеләрнең
барысы өчен дә яктырта. [16] Сезнең яхшы эшләрегезне күреп,
Күктәге Атагызны данласыннар өчен, сезнең яктылыгыгыз да
кешеләр алдында шулай балкысын.

*Канун һәм пәйгамбәрләр*

[17] Минем хакта, Муса канунын яки пәйгамбәрләр язганнарны
юкка чыгарырга килгән, дип уйламагыз. Мин юкка чыгарырга

дип түгел, бәлки башкарырга дип килдем! [18] Сезгә хак сүз әйтәм:
җир һәм күк юкка чыкканчы, канунның бер генә сызыгы да
юкка чыкмаячак: барысы да тормышка ашырылачак! [19] Шулай
итеп, кем дә кем бу иң кечкенә әмерләрнең дә берәрсен бо-
зып, кешеләрне шуңа өйрәтсә, ул кеше Күкләр Патшалыгында
иң түбән кеше дип аталыр. Ә кем аларны үтәп, башкаларны да
үтәргә өйрәтсә, ул кеше Күкләр Патшалыгында бөек булыр.
[20] Чөнки сезгә әйтәм: тәкъвалыгыгыз фарисейләрнекеннән һәм
канунчыларныкыннан өстен булмаса, Күкләр Патшалыгына
кермәячәксез.

*Үтерү һәм ачу тоту турында*

[21] Сезнең ата-бабаларыгызга: «Үтермә! Кеше үтерүче Аллаһы
тарафыннан хөкем ителәчәк», – диелгәнне сез ишеттегез. [22] Ә
Мин сезгә әйтәм: туганына ачу тотучы хөкем ителүгә лаек, ту-
ганына: «Яраксыз», – дип әйтүче исә Югары киңәшмә алдында
җавапка тартылуга, ә инде «Ахмак», – дип әйтүче җәһәннәм
утына лаек. [23] Шуңа күрә, әгәр Аллаһыга бүләк алып барганда,
корбан китерү урынында туганыңның сиңа каршы берәр нәр-
сәсе булуы исеңә төшсә, [24] бүләгеңне корбан китерү урыны ал-
дында калдырып торып, башта туганың белән татулаш, аннан
соң гына кире килеп, бүләгеңне бир. [25] Берәү синең белән дәгъ-
валашып, сине хакимгә алып барса, юлда барганда, әле вакыт
бар чакта, дәгъвалы эшне җайга сал. Югыйсә, гаепләүчең сине
хакимгә китерер, хаким зиндан хезмәтчесенә тапшырыр, һәм
сине зинданга ябарлар. [26] Сиңа хак сүз әйтәм: бурычыңның
актык тиененә кадәр биреп бетермичә, аннан чыкмассың.

*Зина кылу һәм аерылышу турында*

[27] «Зина кылма», – дип ата-бабаларга әйтелгәнне сез ишетте-
гез. [28] Ә Мин сезгә әйтәм: хатын-кызга җенси теләк белән ка-
раучы күңеленнән инде зина кылган була. [29] Әгәр сине уң күзең
гөнаһка төшерсә, аны умырып алып, читкә ташла! Бөтен тәнең
җәһәннәмгә ташлануга караганда, бер әгъзаңны югалтуың
синең өчен яхшырак булыр. [30] Әгәр сине уң кулың гөнаһка тө-
шерсә, аны чабып, читкә ташла! Синең бөтен тәнең җәһәннәм-
гә ташлануга караганда, бер әгъзаңны югалтуың синең өчен
яхшырак булыр.

[31] Ата-бабаларыгызга: «Берәрсе хатынын аерып җибәрә икән,
аңа аерылышу кәгазе бирсен», – дип әйтелгән иде. [32] Ә Мин
сезгә әйтәм: әгәр ир кеше, хатынының зина кылу сәбәбе бул-
мый торып, аның белән аерылышса, ул хатынын зина кылуга
этәрә. Һәм аерылган хатынга өйләнгән кеше дә зина кыла.

### *Ант итү турында*

33 Ата-бабаларга: «Ялган ант итмә! Раббы каршында биргән
антыңны үтә», – дип әйтелгәнне дә сез ишеттегез. 34 Ә Мин
сезгә әйтәм: бөтенләй дә ант итмә! Күк белән дә ант итмә,
чөнки ул – Аллаһының тәхете. 35 Җир белән дә ант итмә, чөнки
ул – Аллаһының аяк басу урыны. Иерусалим белән дә ант ит-
мә, чөнки ул – бөек Патшаның шәһәре. 36 Башың белән дә ант
итмә, чөнки чәчеңнең бер бөртеген генә дә ак яки кара итә
алмыйсың. 37 Сезнең «Әйе» дигән сүзегез – «Әйе» булсын,
«Юк» – «Юк» булсын. Шуннан артык һәммәсе шайтаннан була.

### *Үч алу турында өйрәтү*

38 Ата-бабаларга: «Күзгә – күз» һәм «тешкә – теш» диелгәнне
сез ишеттегез. 39 Ә Мин сезгә әйтәм: үзеңә явызлык кылучыга
каршы килмә. Уң яңагыңа суккан кешегә сул яңагыңны да куй.
40 Берәрсе сине хөкемгә тартып, күлмәгеңне алырга теләсә, аңа
өс киемеңне дә бир. 41 Берәрсе сине бер ара җир үтәргә мәҗбүр
итсә, аның белән ике ара үт. 42 Синнән сораучыга бир һәм бу-
рычка алырга теләүчене буш итмә.

### *Дошманнарыгызны яратыгыз*

43 Ата-бабаларга: «Якыныңны ярат, дошманыңны нәфрәт
ит!» – дип әйтелгәнне сез ишеттегез. 44 Ә Мин сезгә әйтәм:
дошманнарыгызны яратыгыз һәм сезне эзәрлекләүчеләр өчен
дога кылыгыз. 45 Шулай эшләп, сез Күктәге Атагызның балалары
булуыгызны күрсәтерсез. Чөнки Аллаһы кояшын рәхимлеләр
өчен дә, явызлар өчен дә чыгара һәм яңгырын гаделләргә дә, га-
делсезләргә дә яудыра. 46 Әгәр сез үзегезне яратучыларны гына
яратсагыз, ул чакта Аллаһы сезгә ни өчен әҗер бирер? Салым
җыючылар да шулай итәләр түгелме соң? 47 Һәм сез дусларыгыз
белән генә сәламләшсәгез, искитәрлек ни эшләгән буласыз?
Мәҗүсиләр дә шулай эшләмиме соң? 48 Шулай булгач, Күктәге
Атагыз камил булган кебек, сез дә шулай камил булыгыз.

### *Хәер-сәдака*

**6** 1 Кешеләр алдында тәкъва эшләрегезне күрсәтү максаты
белән эшләүдән сакланыгыз. Югыйсә Күктәге Атагыздан
әҗер алмассыз.
2 Шуңа күрә, сәдака биргәндә, ул хакта быргы кычкыртма.
Кешеләр аларга мактау яудырсын дип, монафикълар гыйбадәт-
ханәләрдә һәм урамнарда шулай эшлиләр. Сезгә хак сүз әйтәм:
алар тулысынча әҗерләрен алдылар. 3-4 Ләкин син фәкыйрьгә

ярдәм итәсең икән, ярдәмең яшертен рәвештә эшләнсен өчен, сул кулың уң кулыңның ни эшләгәнен белмәсен. Һәм яшертен эшләнгән һәммә эшләрне күрүче Атаң сиңа әҗереңне бирер.

*Гайсә дога кылырга өйрәтә*

5 Дога кылганда монафикъларча булмагыз. Алар, барысы да
күрсен дип, гыйбадәтханәләрдә һәм юл чатында басып дога кы-
лырга яраталар. Сезгә хак сүз әйтәм: алар тулысынча әҗерләрен
алдылар. 6 Ә син, дога кылганда, бүлмәңә кереп, артыңнан ише-
геңне яп һәм күзгә күренмәгән Атаңа дога кыл. Һәм яшертен
эшләнгән һәммә эшләрне күрүче Атаң сиңа әҗереңне бирер.
7 Дога кылганда, мәҗүсиләр кебек, буш сүзләр әйтмәгез.
Алар, догаларыбызда күп сүзләр әйтсәк, илаһларыбыз безне
ишетер, дип уйлыйлар. 8 Аларга охшамагыз. Сез Атагыздан со-
раганчы ук, нәрсәгә мохтаҗ булуыгызны Ул белә бит. 9 Ә сез
болай дога кылыгыз:

Күктәге Атабыз!
Исемең изге дип икърар ителсен
10 Синең Патшалыгың килсен,
Күктәге кебек, җирдә дә Синең
ихтыярың гамәлгә ашсын.
11 Бу көнгә кирәкле икмәгебезне безгә бүген бир.
12 Башкаларның безгә карата эшләгән явызлыкларын без
кичергән кебек,
безнең дә начар эшләребезне Син кичер.
13 Безне сынауга дучар итмә,
ә явыздан сакла.

14 Чөнки кешеләрнең гаеп эшләрен кичерсәгез, Күктәге Ата-
гыз сезнекен дә кичерер. 15 Ләкин үзегез кичермәсәгез, сезнең
дә яман эшләрегезне Күктәге Атагыз кичермәс.

*Ураза тоту турында*

16 Ураза тотканда, монафикълар кебек караңгы чырайлы бул-
магыз. Үзләренең ураза тотуларын кешеләр күрсен дип, алар
шулай караңгы чырай белән йөриләр. Сезгә хак сүз әйтәм: алар
әҗерләрен тулысынча алдылар. 17 Ә син исә, ураза тотканда,
чәчләреңне майла һәм битеңне ю: 18 синең ураза тотуыңны ке-
шеләр түгел, күзгә күренмәгән Атаң гына күрсен; һәм яшертен
эшләнгән барча эшләрне күрүче Атаң сиңа әҗереңне бирер.

*Чын хәзинә*

19 Үзегезгә байлыкны җирдә җыймагыз. Анда аны көя тапый,
ул тутыга, караклар урлап чыга. 20 Әмма сез хәзинәне күктә

җыегыз: анда аны көя дә тапамый, ул тутыкмый да, караклар
да кереп аны урлап чыкмый. 21 Чөнки хәзинәң кайда булса,
күңелең дә шунда булыр.
22 Тәннең яктырткычы – күзләр. Күзләрең яхшы булса, тә-
нең якты булыр. 23 Ләкин күзләрең начар булса, бөтен тәнең
караңгы булыр. Әгәр синең эчеңдәге яктылык караңгылык бу-
ла икән, ул чакта бу караңгылык нинди тирән була!

*Мәшәкатьләнмәгез*

24 Берәү дә ике хуҗага хезмәт итә алмас: берсен яратмас, ә
икенчесен яратыр; берсенә тугры булыр, ә икенчесен санга
сукмас. Аллаһыга да, байлыкка да берьюлы хезмәт итә ал-
массыз.
25 Шуңа күрә, Мин сезгә әйтәм: тормышыгыз өчен ни белән
тукланырга һәм эчәргә дип, тәнегез өчен нәрсә киярга дип
борчылмагыз. Җан ризыктан, тән киемнән мөһимрәк түгелме
соң? 26 Кошларга карагыз: алар чәчмиләр дә, урмыйлар да, аш-
лыкны амбарларга да салмыйлар, әмма аларны сезнең Күктәге
Атагыз туендыра. Ә сез кошлардан кыйммәтлерәк түгелме соң?
27 Сезнең кайсыгыз, кайгырганга карап, гомерен бер сәгатькә
булса да озайта ала? 28 Һәм кием өчен ник кайгырасыз? Кыр
чәчәкләренә карагыз, алар ничек үсәләр: эшләмиләр дә, эрлә-
миләр дә. 29 Әмма сезгә әйтәм: Сөләйман патша үзенең бөтен
мәһабәтлелегендә дә аларның берсе кебек тә киенмәгән. 30 Бүген
кырда үсеп утырган, ә иртәгә утка ташланачак үләнне Аллаһы
шулай киендерә икән, сезне инде бигрәк тә киендермәсмени,
аз иманлылар? 31 Шулай итеп: «Безгә нәрсә ашарга, безгә нәрсә
эчәргә, безгә нәрсә киярга?» – дип кайгырмагыз. 32 Мәҗүсиләр-
нең төп кайгылары – шул. Ә сезгә боларның һәммәсенең ки-
рәк икәнен Күктәге Атагыз белә. 33 Барыннан да бигрәк, Аның
Патшалыгын һәм Ул кушканнарны ничек тормышка ашырырга
икәнен эзләгез, һәм боларның барысы сезгә бирелер. 34 Иртәгә
булачак көн өчен кайгырмагыз. Иртәгә булачак көн үзе хакын-
да үзе кайгыртыр. Һәр көннең үз мәшәкатьләре җитәрлек.

*Башкаларны хөкем итмәгез*

7 1 Берәүне дә хөкем итмәгез, сезне дә Аллаһы хөкем итмәс.
2 Чөнки нинди хөкем белән хөкем итсәгез, сез дә шундый
хөкем белән хөкем ителерсез; һәм нинди үлчәм белән үл-
чәсәгез, сезгә дә шундый үлчәм белән үлчәп бирелер. 3 Ничек
син туганың күзендәге чүп бөртеген күрәсең, ә үз күзеңдәге
бүрәнәне сизмисең? 4 Үз күзеңдә бүрәнә булганда, син ничек
туганыңа: «Күзеңдәге чүпне алыйм әле», – дип әйтә аласың?

5 Монафикъ! Элек үз күзеңдәге бүрәнәне чыгар, аннары инде
күзләрең ачык күрер һәм туганыңның күзендәге чүпне ала
алырсың.
6 Изге нәрсәне этләргә бирмәгез: алар, сезгә борылып, үзе-
гезне ботарларлар. Энҗеләрегезне дуңгызлар алдына сипмәгез.
Алар ул энҗеләрегезне аяклары белән таптарлар.

*Сорагыз, эзләгез, шакыгыз*

7 Сорагыз – сезгә бирерләр, эзләгез – табарсыз, шакыгыз –
һәм сезгә ачарлар. 8 Чөнки һәр сораучы ала, эзләүче таба һәм
шакучыга ачарлар. 9 Арагыздан кайсыгыз икмәк сораучы улына
таш бирер? 10 Һәм ул балык сораганда, кайсыгыз елан бирер?
11 Әгәр сез, явыз кешеләр булып та, балаларыгызга яхшы
нәрсәләр бирә беләсез икән, сезнең күктәге Атагыз Үзеннән
сораучыларга бигрәк тә бирәчәк. 12 Кешеләрнең сезгә нәрсә
эшләүләрен теләсәгез, үзегез дә аларга шуны эшләгез. Чөнки
Муса канунының һәм пәйгамбәрләр китабында язылган тәгъ-
лиматның мәгънәсе шунда.

*Тар капка*

13 Тар капкадан керегез, чөнки һәлакәткә илтүче юл җиңел,
капкасы да киң, һәм күпләр шул капкадан керәләр. 14 Ә тор-
мышка керә торган капка кысан, юлы тар, һәм аны азлар гы-
на таба.

*Җимешләр*

15 Яныгызга сарык тиресе ябынып килүче ялган пәйгамбәр-
ләрдән сакланыгыз: тире ябынган ерткыч бүреләр алар. 16 Сез
аларны җимешләренә карап таныйрсыз. Күгән куагыннан йөзем,
тигәнәктән инҗир җыяларммыни? 17 Менә шулай, яхшы агач ях-
шы җимеш бирә, ә начар агач начар җимеш бирә. 18 Яхшы агач
начар җимеш бирә алмый, һәм начар агач яхшы җимеш бирә
алмый. 19 Яхшы җимеш бирми торган һәр агачны кисеп, утка
ташлыйлар. 20 Шулай итеп, ялган пәйгамбәрләрне җимешләре-
нә карап таныйрсыз.

*Кисәтү*

21 Күк Патшалыгына Миңа: «Раббым! Раббым!» – дип әйтүче
һәркем түгел, ә Күктәге Атам ихтыярын үтәүче генә керәчәк.
22 Кыямәт көнендә Миңа күпләр: «Раббым, Раббым! Без Синең
исемеңнән пәйгамбәрлек итмәдекмени? Синең исемең белән
җеннәрне куып чыгармадыкмыни? Синең исемең белән башка
күп кодрәтле эшләр эшләмәдекмени?» – дип әйтерләр. 23 Менә

шул вакытта Мин аларга: «Сезне, явызлык кылучыларны, Мин һичкайчан белмәдем, китегез янымнан!» – дип җавап кайтарырмын.

*Ике төзүче*

24 Шулай итеп, Минем сүзләремне ишетеп, аларны үтәүче
һәркем үзенең йортын таш өстенә салган акыллы кешегә охшаган.
25 Яңгыр явып, елгалар ташып, көчле җилләр исеп шул
йортка ябырылган, әмма ул җимерелмәгән. Чөнки йорт таш
нигез өстенә салынган булган.
26 Ә инде ишетеп тә, сүзләремне
үтәмәүче кеше үзенең йортын ком өстенә төзегән акылсыз кешегә охшаган.
27 Яңгыр явып, елгалар ташып, көчле җилләр
исеп шул йортка ябырылган. Ул йорт җимерелеп төшкән, һәм
аның җимерелүе бик каты булган.
28 Гайсә сүзләрен тәмамлагач, Аның өйрәтүенә халык хәйран
калды.
29 Чөнки Ул аларны канунчылар кебек түгел, бәлки хакимлеге булган кеше кебек өйрәтте.

*Гайсә махаулыны савыктыра*

8
1 Гайсә таудан төшкәч, Аның артыннан күп халык иярде.
2 Менә Аның янына бер махаулы* кеше килеп тез чүкте һәм:
– Әфәнде! Әгәр теләсәң, мине тазарта алыр идең! – диде.
3 Гайсә, кулын сузып, аңа кагылды һәм:
– Әйе, телим. Тазарын! – диде. Һәм шунда ук аның махауы
тазарды.
4 Шуннан соң Гайсә аңа әйтте:
– Кара аны, берәүгә дә сөйләмә, ә руханига барып үзеңне күрсәт һәм терелүеңне исбатлау билгесе итеп Муса кануны буенча таләп ителгән бүләкне тәкъдим ит.

*Гайсә йөзбашының хезмәтчесен савыктыра*

5 Гайсә Кәпәрнаумга килгәч, Аннан ярдәм сорап, йөзбашы килде:
6 – Әфәнде! Минем хезмәтчем өйдә параличтан бик нык газапланып ята.
7 – Мин барып, аны савыктырырмын, – диде Гайсә.
8 – Әфәнде! Сине үз йортымда кабул итәргә мин лаеклы түгелмен, – дип җавап бирде Аңа йөзбашы. – Тик сүз генә әйт,
һәм минем хезмәтчем савыгачак.
9 Мин – үзем дә буйсынудагы кеше, һәм минем кул астымда гаскәриләр бар. Аларның берсенә: «Кит», – дисәм, китә, икенчесенә: «Кил», – дисәм, килә, хезмәтчемә: «Моны эшлә», – дисәм, эшли.

---

* 8:2 *Махау чире* – йогышлы тире авыруы.

10 Моны ишетеп, Гайсә хәйран калды һәм артыннан ияреп
баручыларга әйтте:
– Сезгә хак сүз әйтәм: Исраилдә Мин мондый ышануны
һичкемдә күрмәгән идем. 11 Мин сезгә әйтәм: көнчыгыштан
һәм көнбатыштан күпләр килерләр һәм Күк Патшалыгында
Ибраһим, Исхак һәм Ягъкуб белән бергә мәҗлес өстәле артын-
да утырырлар. 12 Ә кемгә Патшалык алдан билгеләнгән иде,
алар тышкы караңгылыкка куылырлар: анда елау һәм тешләр
шыкырдату булыр.
13 Йөзбашына Гайсә:
– Өеңә кайт, һәм сиңа иманың буенча булсын, – диде.
Һәм аның хезмәтчесе шул сәгатьтә үк савыкты.

*Гайсә күпләрне савыктыра*

14 Гайсә Петернең өенә килде һәм аның каенанасының кызы-
шып авырып ятуын күрде. 15 Гайсә бу хатынның кулына кагыл-
гач, кызышуы шунда ук бетте, һәм ул, торып, Гайсә хөрмәтенә
табын әзерли башлады. 16 Ә инде кич җиткәч, Гайсә янына
җенле булган күп кешеләрне китерделәр. Ул Үзенең сүзе белән
явыз рухларны куып чыгарды һәм бөтен авыруларны савык-
тырды. 17 Чөнки Ишагыйя пәйгамбәр аша: «Ул безнең сырхау-
ларыбызны Үзенә алды һәм авыруларыбызны күтәреп алып
китте», – дип әйтелгәннәр тормышка ашырга тиеш иде.

*Гайсәгә иярергә теләүчеләрнең кайберләре*

18 Тирә-ягындагы халык төркемнәрен күреп, Гайсә шәкерт-
ләренә диңгез аръягына кичеп чыгарга кушты. 19 Шуннан соң
Аның янына бер канунчы килеп:
– Остаз, Син кая гына барсаң да, мин Синең артыңнан ба-
рырмын, – диде.
20 – Төлкеләрнең өннәре, кошларның оялары бар, ә Адәм
Улының баш төртер урыны да юк, – дип җавап бирде Гайсә.
21 Икенче берсе – Аның шәкертләреннән берәү – Аңа әйтте:
– Әфәнде! Өемә кайтып, башта атамны күмеп килергә рөх-
сәт ит.
22 Ләкин Гайсә аңа:
– Миңа ияр! Үлеләрне үле кешеләр үзләре күмсен, – диде.

*Гайсә давылны тынычландыра*

23 Гайсә көймәгә керде. Аның артыннан шәкертләре дә керде.
24 Кинәт диңгез өстендә көчле давыл күтәрелде. Дулкыннар
көймәгә бик каты итеп бәрделәр, һәм аңа су керде. Ә Гайсә
йоклап ята иде. 25 Шәкертләре килеп, Аны уяттылар һәм:

– Раббыбыз, коткар! Батабыз! – дип кычкырдылар.

26 – Ни өчен сез шундый куркак, аз иманлылар? – диде Ул аларга.

Гайсә, торып, җилләрне һәм диңгезне тыйды. Һәм тынлык урнашты.

27 – Кем соң Ул? Җилләр дә, диңгез дә буйсына Аңа! – дип кешеләр таң калды.

*Гайсә ике җенле кешене савыктыра*

28 Гайсә аргы як ярдагы Гәдара җиренә килгәч, каберләр* арасыннан Аңа каршы җенле ике кеше килеп чыкты. Алар шундый усал булган ки, хәтта ул юлдан һичкем үтә алмаган.

29 – Аллаһы Улы, Сиңа бездән нәрсә кирәк? Син монда безне вакытыннан элек җәфаларга килдеңме? – дип кычкырдылар алар.

30 Ә ерак түгел зур дуңгыз көтүе утлап йөри иде. 31 Җеннәр:

– Әгәр безне куып чыгарсаң, дуңгыз көтүенә җибәрче! – дип үтенделәр Аннан.

32 – Барыгыз, – дип җавап бирде Гайсә.

Җеннәр чыгып, дуңгызлар эченә керделәр. Шунда ук бөтен көтү текә ярдан диңгезгә атылып, суга батып үлде. 33 Ә көтүчеләр исә торып чаптылар. Алар шәһәргә йөгереп кайтып, барысы хакында сөйләделәр. Җенле кешеләр белән дә ни булганын хәбәр иттеләр. 34 Һәм менә бөтен шәһәр халкы Гайсәнең каршысына килде. Аны күреп, алар Аннан үзләренең җиреннән китүен үтенделәр.

*Гайсә паралич суккан кешене савыктыра*

9 1 Гайсә, көймәгә кереп, диңгезне кичте һәм Үзе яшәгән шәһәргә килде. 2 Берничә кеше паралич суккан авыруны ятагы белән күтәреп, Аңа китерделәр. Гайсә, аларның ышануларын күреп авыруга әйтте:

– Кыю бул, бала! Синең гөнаһларың кичерелде!

3 Шул вакытта канунчылар эчләреннән генә: «Бу кеше көфер сөйли!» – диделәр. 4 Гайсә аларның ни уйлауларын белеп сорады:

– Ни өчен сезнең күңелегездә шундый начар уйлар? 5 Ничек дип әйтергә җиңелрәк: «Синең гөнаһларың кичерелде», – дипме, әллә: «Тор да йөр», – дипме? 6 Ләкин сез хәзер Адәм Улының җирдә гөнаһларны кичерергә хакимлеге барлыгын белерсез!

---

* 8:28 *Кабер* – яһүдләр мәетләрне тауны тишеп ясалган мәгарә-каберләргә куйганнар.

Һәм Гайсә паралич суккан кешегә:
– Тор, үзеңнең ятагыңны алып, өеңә кит! – диде.
7 Тегесе, торып, өенә кайтып китте. 8 Моны күреп торган
халык куркышып калды һәм кешеләргә шундый хакимлек бир-
гән Аллаһыны данлады.

*Гайсә Маттайны чакыра*

9 Шул урыннан китеп барганда, Гайсә салым җыю урынында
утыручы Маттай исемле кешене күрде һәм:
– Минем артымнан бар, – диде.
Маттай, торып, Аның артыннан китте.
10 Гайсә аның өенә ашка килгәч, анда күп кенә салым җыю-
чылар һәм башка гөнаһлылар җыелды. Алар Гайсә һәм Аның
шәкертләре белән бер аш өстәле артында утырдылар. 11 Фари-
сейләр, моны күреп, шәкертләргә әйттеләр:
– Ни өчен сезнең Остазыгыз салым җыючылар һәм башка
гөнаһлылар белән бергә ашый?
12 Гайсә моны ишетеп җавап бирде:
– Табиб сәламәт кешеләргә түгел, ә авыруларга кирәк. 13 Ба-
рыгыз һәм «Мин корбанны түгел, шәфкатьлекне телим» дигән
сүзләрнең мәгънәсен өйрәнегез. Мин бит тәкъва кешеләрне
түгел, бәлки гөнаһлыларны чакырырга дип килдем.

*Ураза тоту хакында сорау*

14 Шуннан соң Аның янына Яхъяның шәкертләре килеп:
– Ни өчен без һәм фарисейләрнең шәкертләре еш ураза то-
табыз, ә Синекеләр ураза тотмыйлар? – дип сорадылар.
15 Гайсә аларга җавап бирде:
– Кияү егете үзләре белән бергә булганда, туйдагы кунаклар
кайгыра алырлармы? Әмма килер бер көн: алар яныннан кияү
алыныр, һәм шул чакта алар ураза тотарлар. 16 Иске киемгә яңа
тукымадан ямаулык салмыйлар, чөнки ул, иске тукыманы ба-
сып төшеп, тишекне тагын да зурайтыр. 17 Һәм яңа шәрабны
иске турсыкка салмыйлар, югыйсә иске турсык тишелер дә,
шәраб та агып бетәр, турсык та әрәм булыр. Юк, яңа шәрабны
яңа турсыкка салалар. Шул вакытта шәраб та, турсык та сакла-
нып калыр.

*Гайсә үлгән кызны һәм авыру хатынны терелтә*

18 Гайсә шулай сөйләп торганда, Аның янына яһүд башлык-
ларының берсе килеп тез чүкте һәм Аңа әйтте:
– Хәзер генә минем кызым үлде. Ә Син аның янына килеп,
өстенә кулларыңны куйчы, һәм ул яшәячәк!

19 Гайсә торды һәм шәкертләре белән аның артыннан китте.
20 Шул вакыт уникe ел буе кан китүдән интеккән хатын, арттан
килеп, Аның киеменең чабуына кагылды. 21 Чөнки ул: «Аның
киеменә генә кагылсам да савыгыр идем», — дип эченнән генә
уйлаган иде. 22 Гайсә борылып карады һәм, аны күреп:

— Кыю бул, кызым! Сине ышануың савыктырды, — диде.

Һәм шул вакытта ук хатын савыктырылды.

23 Башлыкның өенә кергәч, Гайсә анда матәм көйләрен уйнаучыларны һәм елаучылар төркемен күрде һәм:

24 — Китегез моннан! Кыз бала үлмәгән, ул йоклый! — диде.

Аннан көлә башладылар. 25 Ләкин халык өйдән чыгарылгач,
Гайсә, бүлмәгә кереп, кызның кулыннан тотты, һәм кыз торып
басты. 26 Бу хактагы хәбәр шундагы бөтен тирә-як җирләргә
таралды.

*Гайсә тагын күпләрне савыктыра*

27 Гайсә аннан киткәндә, артыннан ике сукыр иярде.

— Давыт Улы, безгә шәфкать күрсәтче! — дип кычкырдылар алар.

28 Ул өйгә кергәч, бу сукырлар Аның янына килделәр. Һәм Гайсә:

— Минем ярдәм итә алуыма сез ышанасызмы? — дип сорады.

— Әйе, Әфәнде, — дип җавап бирделәр алар.

29 Гайсә аларның күзләренә кагылды һәм:

— Ышануыгыз буенча булсын сезгә, — диде.

30 Һәм алар күрә башладылар. Гайсә аларга:

— Карагыз аны, бу хакта беркем дә белмәсен, — дип каты кисәтеп әйтте.

31 Әмма алар, киткәч, Аның хакында шундагы бөтен тирә-як җирләрдә сөйләп йөрделәр.

32 Алар китәм дигәндә, Гайсә янына җенле телсез кешене ки-
терделәр. 33 Гайсә җенне куып чыгаргач, телсез кеше сөйләшә
башлады. Моңа халык хәйран калды һәм әйтте:

— Исраилдә беркайчан да мондый хәлне күргәнебез булмады.

34 Ләкин фарисейләр:

— Ул җеннәрне җеннәр башлыгы көче белән куып чыгара, — дип каршы сөйләделәр.

35 Гайсә гыйбадәтханәләрдә өйрәтеп, бөтен шәһәрләр һәм
авыллар буйлап Патшалык хакындагы Яхшы хәбәрне игълан
итеп, халыкны төрле авырулардан һәм чирләрдән савыктырып
йөрде. 36 Ул халык төркемнәрен күреп кызганды: алар, көтүче-
ләре булмаган сарыклар кебек, борчылган һәм таралган иделәр.
37 Шул чакта Гайсә шәкертләренә әйтте:

– Урасы ашлык күп, ә уракчылар аз. 38 Шуңа күрә ашлык Хуҗасына ялварыгыз: ашлык урырга эшчеләр җибәрсен.

*Унике шәкертне сайлау*

10 1 Гайсә Үзенең янына унике шәкертен чакырып алып, аларга шакшы рухларны куып чыгару һәм төрле авырулардан, төрле чирләрдән савыктыру вәкаләте бирде.
2 Менә ул унике рәсүлнең исеме: беренчесе – Петер дип аталган Шимун һәм аның энесе Әндри, Зебедәй улы Ягъкуб һәм аның энесе Яхъя, 3 Филип һәм Бартулумай, Томас һәм салым җыючы Маттай, Һалфай улы Ягъкуб, Таддай, 4 Көрәшүче Шимун* һәм Гайсәгә хыянәт итәчәк Яһүд Искариот.

*Гайсә унике шәкертен җибәрә*

5 Гайсә менә шушы уникене нәсыйхәт биреп җибәрде:
– Башка халыкларга бармагыз һәм Самареянең бер шәһәренә дә кермәгез. 6 Бигрәк тә Исраил халкының югалган сарыклары янына барыгыз. 7 Барганда исә: «Күкләр Патшалыгы якынлашты!» – дип хәбәр итегез. 8 Авыруларны савыктырыгыз, үлгәннәрне терелтегез, махаулыларны тазартыгыз, җеннәрне куып чыгарыгыз. Бушлай алдыгыз – бушлай бирегез. 9 Путагызга салырга дип, үзегез белән алтын да, көмеш тә, бакыр акча да алмагыз. 10 Биштәр дә, алмаш күлмәк тә, аяк киеме дә, юл таягы да алмагыз – эшче үзенә ризык бирелүгә лаек.
11 Берәр шәһәр яки авылга килгәч, анда кем лаеклы булуын табып, үзегез киткәнгә кадәр аның өендә калыгыз. 12 Өйгә кергәндә, иминлек теләген әйтеп керегез. 13 Әгәр өй лаеклы булса, анда сез теләгән иминлек булсын, ә лаексыз булса, сезнең иминлегегез үзегезгә кире кайтсын. 14 Ә берәр йорт яки шәһәр сезне кабул итмәсә, сүзләрегезне тыңламаса, ул чакта бу йорттан яки бу шәһәрдән киткәндә, аякларыгыздагы тузанны кагып төшерегез. 15 Сезгә хак сүз әйтәм: хөкем көнендә Сәдүм белән Гамура шәһәрләренә бу шәһәргә караганда җиңелрәк булыр.

*Булачак эзәрлекләүләр*

16 Мин сезне бүреләр арасына сарыкларны җибәргән кебек җибәрәм. Шуңа күрә, еланнар кебек сакланучан булыгыз һәм күгәрченнәр кебек эчкерсез булыгыз. 17 Кешеләрдән сакланыгыз. Алар сезне мәхкәмәләргә тапшырырлар, гыйбадәтханәләрендә камчыларлар. 18 Сезне Минем аркада идарәчеләр, патшалар

---

* 10:4 *Көрәшүче Шимун* – Рим хакимлеген көч белән бәреп төшерүне яклап көрәшүче яһүдләр төркеменең әгъзасы.

алдына китерерләр. Бу – сез аларга һәм халыкларга Минем
хакта шаһитлек итсен өчен булыр. 19 Сезне хөкем итәргә китер-
гән чакта, нәрсә һәм ничек сөйләргә дип хафаланмагыз: сезгә
ул сәгатьтә нәрсә сөйләргә кирәклеге белдерелер. 20 Чөнки
әйткән сүзләрегез сезнеке булмас, бәлки сезнең аша Атагыз-
ның Рухы сөйләр.

21 Туган туганын, ата баласын үлемгә тапшырыр, ә балалар
ата-аналарына каршы чыгып, аларны үтертерләр. 22 Минем
өчен барысы да сезне нәфрәт итәр. Ләкин ахырга кадәр чы-
даган кеше котылыр. 23 Бер шәһәрдә эзәрлекли башласалар,
башкасына качыгыз. Сезгә хак сүз әйтәм: сез Исраилнең
барлык шәһәрләрен әйләнеп чыгарга өлгергәнче, Адәм Улы
киләчәк.

24 Шәкерт үзенең остазыннан өстен булмый, һәм хезмәтче дә
үзенең хуҗасыннан өстен булмый. 25 Шәкерт исә остазы кебек
булса, ә хезмәтче хуҗасы кебек булса, шул җитә. Йорт хуҗасын
Белзебул* дип атыйлар икән, өйдәгеләрен инде бигрәк тә шу-
лай дип атарлар.

### *Курыкмагыз*

26 Шуңа күрә, алардан курыкмагыз! Ачылмый калачак бер-
нинди капланган нәрсә һәм беленми калачак бернинди яшерен
нәрсә юк. 27 Мин сезгә караңгылыкта сөйләгәннәрне көн як-
тысында сөйләгез, пышылдап әйткәннәрне өй түбәләреннән
игълан итегез. 28 Тәнне үтереп тә, җанны үтерә алмаучылардан
курыкмагыз. Бәлки күбрәк җәһәннәмдә җанны да, тәнне дә
һәлак итә алучы Аллаһыдан куркыгыз!

29 Ике чыпчык бер бакыр тәңкәгә** сатыла түгелме соң?
Әмма аларның берсе дә Атагызның ихтыярыннан башка җиргә
егылып төшмәс. 30 Ә сезнең хәтта башыгыздагы һәр чәч бөрте-
гегез дә санаулы. 31 Шулай итеп, курыкмагыз: сез күп чыпчык-
ларга караганда кыйммәтлерәк.

### *Мәсих артыннан бару*

32 Шулай итеп, Мине кешеләр алдында икърар иткән кешене
Мин дә Күктәге Атам алдында икърар итәрмен. 33 Ә инде бе-
рәрсе кешеләр каршында Миннән ваз кичсә, Мин дә Күктәге
Атам каршында аннан ваз кичәрмен.

---

* **10:25** *Белзебул* – шайтан өчен кулланылган исем.

** **10:29** *Бер бакыр тәңкә* – грек телендә «бер ассарион». Бер ассари-
он уналтыдан бер динарга тигез. (Бер динар – хезмәтченең бер
көнлек эш хакы.)

34 Мине җиргә тынычлык китерергә килде дип уйламагыз.
Мин тынычлык китерергә дип килмәдем, әмма кылыч алып
килдем. 35 Чөнки Мин улы белән атаны, кызы белән ананы, ки-
лен белән каенананы аерырга дип килдем. 36 Һәм кеше өчен өй-
дәгеләре дошман булыр.

37 Үзенең атасын яки анасын Миңа караганда күбрәк яратучы
кеше Миңа лаек түгел. Үзенең улын яки кызын Миңа кара-
ганда күбрәк яратучы кеше Миңа лаек түгел. 38 Үзенең хачын
алмаган һәм Миңа ияреп бармаган кеше Миңа лаек түгел.
39 Тормышын үзе өчен сакларга тырышучы кеше аны югалтыр.
Ә Минем өчен тормышын югалткан кеше аны табар.

40 Сезне кабул итүче Мине кабул итә. Ә Мине кабул итүче
Мине Җибәрүчене кабул итә. 41 Пәйгамбәрне пәйгамбәр булга-
ны өчен кабул итүче, пәйгамбәрнең әҗерен алыр. Тәкъваны
тәкъва булганы өчен кабул итүче тәкъваның әҗерен алыр.
42 Кем шушы иң түбәннәрнең берсенә Минем шәкертем булга-
ны өчен эчәргә дип бер чынаяк салкын су бирә, хак сүз әйтәм:
әҗереннән мәхрүм калмаячак.

*Гайсәнең Яхъяга җавабы*

**11** 1 Гайсә, Үзенең унике шәкертенә нәсыйхәт биреп бетер-
гәч, башка шәһәрләрдә өйрәтеп һәм вәгазьләп йөрергә
дип, аннан китте.

2-3 Яхъя исә, төрмәдә чакта Мәсихнең кылган гамәлләре ха-
кында ишеткәч: «Килергә тиеш булган Зат Синме, әллә башка
берәүне көтикме?» – дип сорарга үзенең шәкертләрен җибәр-
де. 4 Гайсә аларга җавап бирде:

– Барыгыз, күргәннәрегезне һәм ишеткәннәрегезне Яхъяга
кайтып сөйләгез: 5 Сукырлар янә күрә, аксаклар йөри, махау-
лылар тазарына, чукраклар ишетә, үлгәннәр терелеп тора һәм
фәкыйрьләргә Яхшы хәбәр игълан ителә. 6 Кем Минем хакта
шикләнми, шул бәхетле.

7 Яхъя шәкертләре киткәндә, Гайсә халыкка Яхъя хакында
сөйли башлады:

– Сез чүлгә нәрсә карарга бардыгыз? Җилдә тирбәлгән ка-
мышны карарга дипме? 8 Нәрсә карарга бардыгыз соң? Купшы
кием кигән кешенеме? Ә бит купшы кием кигәннәр сарайларда
яшиләр. 9 Ул чакта нәрсә карарга бардыгыз? Пәйгамбәрнеме? Әйе!
Мин сезгә әйтәм, ул пәйгамбәрдән дә бөегрәк! 10 Изге язмада:

«Мин Синең алдыңнан
хәбәрчемне җибәрәм,
ул Синең алдыңнан Сиңа юл әзерләр», –

дип язылган сүзләр аның турында.

11 Сезгә хак сүз әйтәм: хатын-кыздан туган кешеләр ара-
сында Чумдыручы Яхъядан бөегрәк һичкем булмады. Әмма
Күкләр Патшалыгында иң кечкенәсе дә аннан өстенрәктер.
12 Чумдыручы Яхъя көннәреннән алып бүгенгә хәтле Күкләр
Патшалыгы өчен көрәш бара һәм көч куючылар аны кулга тө-
шерәләр. 13 Чөнки барлык пәйгамбәрләр һәм бөтен канун
Яхъяга кадәр пәйгамбәрлек иттеләр. 14 Һәм әгәр кабул итәргә
телисез икән, белегез: ул – килергә тиешле Ильяс. 15 Колак-
лары булган ишетсен!

16-17 Хәзерге заман кешеләрен нәрсә белән чагыштырырга
икән? Алар:

«Без сезгә күңелле көйләр уйнадык,
  ә сез биемәдегез.
Без кайгылы җырлар җырладык,
  ә сез кайгырып еламадыгыз», –

дип, базар мәйданында бер-берсенә кычкырып утыручы бала-
ларга охшый. 18 Чөнки Яхъя килде, ашамый да, шәраб та эчми,
һәм кешеләр: «Ул җенле», – диләр. 19 Адәм Улы килде, ашый
һәм эчә. Алар: «Күрегез әле, бирән, эчкече, салым җыючы-
ларның һәм гөнаһлыларның дусты!» – диләр. Ә Аллаһының
зирәклеге үзенең эшләре белән хак дип исбат ителде.

*Тәүбәгә килмәгән шәһәрләр*

20 Аннан соң Гайсә могҗизаларының күбесе эшләнгән шә-
һәрләрне тәүбәгә килмәгәннәре өчен шелтәли башлады:

21 – Кайгы сиңа, Хоразин! Кайгы сиңа, Бәйтсайда! Әгәр сез-
дә эшләнгән могҗизалар Тур һәм Сидун шәһәрләрендә күрсә-
телгән булса, алар күптән инде тупас киемнәр киеп һәм көлгә
утырып тәүбә итәрләр иде. 22 Ләкин сезгә әйтәм, хөкем көнен-
дә Тур белән Сидунга сезгә караганда җиңелрәк булыр. 23 Әй,
Кәпәрнаум, әллә сине күккә кадәр күтәрерләр дип уйлый-
сыңмы? Юк, үлем патшалыгына кадәр төшерелерсең. Әгәр
синдә эшләнгән могҗизалар Сәдүмдә эшләнсә, ул хәзерге
көнгә кадәр торган булыр иде. 24 Ләкин сезгә әйтәм: хөкем кө-
нендә Сәдүм җиренә сиңа караганда җиңелрәк булыр.

*Миңа килегез*

25 Шул вакытта Гайсә әйтте:

– Атам, күкнең һәм җирнең Хуҗасы! Зирәкләрдән һәм акыл
ияләреннән яшерелгәнне балаларга ачып бирүең өчен Сиңа
шөкрана итәм! 26 Әйе, Атам, шулай эшләүне Син яхшы дип тап-
тың! 27 Атам бөтенесен дә Миңа тапшырды. Улын Атасыннан
башка һичкем белми. Улыннан башка Атасын һичкем белми,

һәм Улы Аны кемнәргә ачарга тели, шул кешеләрдән башка Атаны һичкем белми.

[28] Авырлыктан җәфа чигүчеләр, һәммәгез дә Миңа килегез.
Мин сезгә тынычлык бирермен. [29] Минем камытымны үзегезгә
киегез һәм Миннән өйрәнегез, чөнки Мин – юаш, басынкы
күңелле; һәм сез тынычлык табарсыз. [30] Чөнки Минем камытым уңайлы һәм йөгем җиңел!

*Шимбә хакында сорау*

## 12

[1] Бервакыт, шимбә көнне, Гайсә иген кырлары аркылы
үтте. Аның шәкертләре, ачыкканлыктан, башаклар өзеп
ашый башладылар. [2] Фарисейләр, моны күреп, Гайсәгә
әйттеләр:

– Кара, Синең шәкертләрең шимбә көн эшләргә ярамаганны эшлиләр!

[3-4] – Давыт һәм аның белән булган кешеләр ачыккач, аның
нәрсә эшләгәне хакында укымадыгызмыни: ул Изге йортка кергән һәм Аллаһыга багышланган икмәкләрне ашаган, ә аларны
исә руханилардан башка һичкемгә дә ашарга рөхсәт ителмәгән,
– диде Гайсә. – [5] Аллаһы Йортында руханиларның шимбә көн
канунын бозуларын, әмма моның аларга гаепкә саналмавын
канун китабыннан укымадыгызмы әллә? [6] Сезгә әйтәм: монда
Аллаһы Йортына караганда бөегрәге бар. [7] Әгәр сез Аллаһының: «Мин корбанны түгел, шәфкатьлекне телим», – дигән
сүзләренең мәгънәсен аңласагыз, гаепсезләрне хөкем итмәс
идегез. [8] Чөнки Адәм Улы – шимбә көненең Хуҗасы.

*Гайсә кулы корышкан кешене савыктыра*

[9] Аннан китеп, Гайсә гыйбадәтханәгә килде. [10] Анда кулы
корышкан кеше бар иде.

– Шимбә көнне савыктыру рөхсәт ителәме? – дип, кайберләре Гайсәдән сорадылар. Чынлыкта исә алар Гайсәне гаепләргә сәбәп эзлиләр иде.

[11] – Сезнең арагыздагы берәүнең бердәнбер сарыгы булып, ул
сарыгы шимбә көнне чокырга егылып төшсә, аны чыгармас
иде микән? – диде Гайсә. – [12] Ә кеше исә сарыктан күпкә
кадерлерәк бит. Шулай булгач, шимбә көнне яхшылык эшләү рөхсәт ителә.

[13] Шуннан соң Ул теге кешегә:

– Кулыңны суз! – диде.

Ул кулын сузды, һәм кулы савыкты; икенчесе кебек үк исән
булды. [14] Фарисейләр исә, гыйбадәтханәдән китеп, Гайсәне
ничек һәлак итү хакында бергәләшеп киңәш кордылар.

*Аллаһының сайланган Хезмәтчесе*

15 Гайсә, бу хакта белеп, аннан китте. Артыннан күп халык
иярде. Ул авыруларның барысын да савыктырды. 16 Әмма Үзе-
нең кем булуы хакында беркемгә дә сөйләмәскә кушты. 17 Бу
вакыйгалар Ишагыйя пәйгамбәр аша әйтелгән сүзләр гамәлгә
ашсын өчен булды:

18 «Менә Мин сайлаган Минем Хезмәтчем,
Минем сөеклем, Минем җанымның шатлыгы.
Мин Аны Үземнең Рухым белән сугарырмын,
һәм Ул Минем хөкемемне халыкларга игълан итәр.
19 Ул бәхәсләшмәс, кычкырмас,
урамнарда Аның тавышын һичкем ишетмәс.
20 Гаделлекне җиңүгә ирештергәнгә кадәр,
чатнаган камышны сындырып төшермәс,
пыскып яткан филтәне сүндермәс.
21 Аның исеменә халыклар өметләрен багларлар».

*Гайсә һәм Белзебул*

22 Аннары Гайсә янына җенле кешене китерделәр; ул сукыр
һәм телсез иде. Гайсә аны савыктырды. Ул сөйләшә һәм күрә
башлады. 23 Кешеләр шаккаттылар һәм:

– Давыт Улы була аламы Ул? – дип, алар бер-береннән со-
радылар.

24 Моны фарисейләр ишетеп:

– Аңа җеннәр башлыгы Белзебул көч биргәнгә күрә генә Ул
җеннәрне куып чыгара, – диделәр.

25 Гайсә, аларның уйларын белеп:

– Әгәр патшалык эчендә бүленү булса, ул җимерелер. Шулай
ук эчендә ызгыш-талаш булган шәһәр яки йорт тора алмас.
26 Әгәр шайтан шайтанны куып чыгара икән, димәк, ул
үзен-үзе тарката. Аның патшалыгы ничек торыр икән? 27 Ә ин-
де Мин җеннәрне Белзебул көче белән куып чыгарам икән,
сезнең иярченнәрегез кемнең көче белән куып чыгара соң?
Шунлыктан, сезнең хаклы булмавыгызны алар үзләре күрсә-
терләр. 28 Ә инде Мин Аллаһы Рухы белән җеннәрне куып
чыгарам икән, димәк, сезгә Аллаһы Патшалыгы инде килеп
җитте, – диде.

29 – Кем дә булса көчле кешенең өенә кереп, башта аны
бәйләп куймыйча, аның малын талый алыр микән? Шулай
эшләгәннән соң гына ул аның өен талап чыгар.

30 Кем Минем белән түгел, ул Миңа каршы. Кем Минем
белән җыймый, ул тарката. 31 Шуңа күрә, Мин сезгә әйтәм:

кешеләрнең бөтен гөнаһлары һәм көферлекләре кичерелер,
әмма Аллаһы Рухына каршы көферләнү кичерелмәс. 32 Адәм
Улына каршы берәр нәрсә әйтүче кичерелер, әмма Аллаһы Ру-
хына каршы берәр нәрсә әйтүче хәзерге заманда да, киләчәктә
дә кичерелмәс.

33 Яхшы җимеш китерер өчен агачның яхшы булуы кирәк.
Әгәр агач начар икән, җимешләре дә начар булыр. Җимешенә
карап, агачы беленә. 34 Елан кавеме! Явыз була торып, сез ни-
чек яхшы сөйләшә аласыз? Кешенең күңеленнән нәрсә ташый,
аның телендә дә шул була. 35 Яхшы кеше үзенең яхшылык хә-
зинәсеннән яхшылык чыгара, ә явыз кеше үзенең явызлык
хәзинәсеннән явызлык чыгара. 36 Сезгә әйтәм: әйтелгән һәр
буш сүз өчен кешеләр кыямәт көнендә җавап бирәчәкләр.
37 Чөнки әйткән сүзләреңә карап сине акларлар, әйткән сүзлә-
реңә карап хөкем итәрләр.

38 Шуннан соң канунчылар һәм фарисейләр арасыннан бер-
ничәсе Аңа әйттеләр:

– Остаз, без Синең илаһи билге күрсәтүеңне телибез.

39 Ләкин Гайсә аларга җавап бирде:

– Явыз һәм Аллаһыга иман итмәүче буын билге таләп итә,
әмма аларга Юныс пәйгамбәр галәмәтеннән башка билге би-
релмәс. 40 Чөнки Юныс пәйгамбәр диңгез җанварының кары-
нында өч көн һәм өч төн үткәргән кебек, Адәм Улы да җир
тирәнлегендә өч көн һәм өч төн үткәрер. 41 Нинәвиләләр хөкем
көнендә бу буын кешеләре белән бергә торып, аларны гаепләя-
чәкләр, чөнки алар Юныс пәйгамбәрнең вәгазен ишетеп тәүбә
иткәннәр. Ә Мондагы – Юныстан бөегрәк. 42 Көньякның пат-
шабикәсе хөкем көнендә, бу буын кешеләре белән бергә то-
рып, аларны гаепләячәк, чөнки ул Сөләйман патшаның зирәк
сүзләрен тыңлау өчен җир читеннән килгән булган. Ә Мондагы
– Сөләйманнан бөегрәк.

43 Шакшы рух, кеше эченнән чыкканнан соң, сусыз урыннарда
үзенә сыенып урын эзләп йөри, әмма таба алмый. 44 Һәм ул:
«Элекке йортыма әйләнеп кайтыйм әле», – ди. Кире кайткач,
ул аны иясез, себерелгән һәм җыештырылган хәлдә таба. 45 Ан-
нары ул үзеннән дә явызрак җиде рухны ияртеп кайта, һәм алар
шунда яши башлыйлар. Һәм ул кешенең бу хәле элеккегә кара-
ганда да начаррак була. Бу явыз буын белән дә шулай булыр.

### *Гайсәнең анасы һәм энеләре*

46 Гайсә халыкка сөйләгән вакытта, Аның анасы һәм энеләре
тышта тордылар: алар Гайсә белән сөйләшергә теләделәр.
47 Ниндидер бер кеше Гайсәгә әйтте:

– Синең әниең белән энеләрең тышта басып торалар. Алар
Синең белән сөйләшергә телиләр.
48 Гайсә исә бу кешегә җавап бирде:
– Кем Минем анам һәм кем туганнарым?
49 Һәм кулы белән шәкертләренә күрсәтеп:
– Менә Минем анам һәм туганнарым! – диде. – 50 Чөнки
Күктәге Атамның ихтыярын үтәүче кеше Миңа ир туганым да,
кыз туганым да, анам да була.

*Чәчүче хакында гыйбрәтле хикәя*

13 1 Гайсә шул көнне өйдән чыкты һәм диңгез ярына барып
утырды. 2 Аның тирәсенә күп халык җыелды. Шунлык-
тан Аңа көймәгә утырырга туры килде, ә бөтен халык
яр буенда басып торды. 3 Һәм Гайсә гыйбрәтле хикәяләр аша
аларга күп нәрсә хакында сөйләде:
– Менә, чәчүче чәчәргә чыккан. 4 Ул чәчкәндә орлыкларның
бер өлеше юл буена төшкән. Кошлар очып килеп, аларны чүп-
ләп бетергән. 5 Икенче бер өлеше туфрагы аз булган ташлы
урынга төшкән. Тирән ятмаганга күрә, алар тиз шытып чыккан-
нар. 6 Ә инде кояш чыгып кыздыргач, тамырлары булмаганлык-
тан, үсентеләр шиңеп төшкәннәр. 7 Орлыкларның башкалары
күгәнлеккә төшкән. Күгән куаклары үсеп, аларны басып кит-
кән. 8 Ә башка орлыклар исә уңдырышлы җиргә төшкән һәм
йөзләтә, алтмышлата, утызлата уңыш биргән. 9 Колаклары бул-
ганнар – ишетсеннәр!
10 Шәкертләре Аның янына килеп, сорадылар:
– Син ни өчен халык белән кинаяле хикәяләр кулланып
сөйләшәсең?
11 – Сезгә Күкләр Патшалыгының серләрен белү бирелгән, ә
аларга бирелмәгән, – диде Ул. – 12 Кемнең бар, шуңа бирелер
һәм аңарда артыгы белән булыр. Ә кемнең юк, аңардан булга-
ны да тартып алыныр. 13 Менә шуңа күрә Мин аларга кинаяле
хикәяләр кулланып сөйлим: алар бит карыйлар, әмма күрми-
ләр, тыңлыйлар, әмма ишетмиләр һәм төшенмиләр. 14 Шулай
Ишагыйяның пәйгамбәрлек сүзләре аларда тормышка ашты:

«Тыңлап-тыңлап та, аңламассыз,
Карап-карап та, күрмәссез.
15 Чөнки бу халыкның йөрәген май баскан.
Көчкә генә ишетә колаклар,
Күзләрен дә алар йомганнар.
Әгәр шулай булмаса,
Күзләре белән күрерләр,
Колаклары белән ишетерләр иде.

Йөрәкләре белән аңларлар,
Миңа таба борылырлар
Һәм Мин аларны савыктырыр идем».
16 Ләкин сезнең күзләрегез бәхетле, чөнки алар күрәләр,
колакларыгыз бәхетле, чөнки алар ишетәләр. 17 Ышаныгыз: сез
күрә торган нәрсәләрне күп пәйгамбәрләр һәм тәкъвалар кү-
рергә теләделәр, әмма күрмәделәр; сез хәзер ишеткән нәрсә-
ләрне ишетергә теләделәр, әмма ишетмәделәр.
18 Шулай итеп, чәчүче хакындагы кинаяле хикәянең нәрсә
аңлатканын тыңлагыз. 19 Патшалык хакындагы сүзне тыңлаучы
һәм аны аңламаучы һәркемнең йөрәгенә чәчелгәнне шайтан
килеп алып китә. Бу – юл буена чәчелгән орлык. 20 Ташлы
урынга чәчелгән орлык исә, сүзне ишетү белән, аны шунда ук
шатланып кабул итүче кеше ул. 21 Әмма аның тамыры булма-
ганлыктан, ул сүзне вакытлыча гына тота. Сүз аркасында кайгы
яки эзәрлекләүләр булса, ул бик тиз чигенә. 22 Күгәнлеккә чә-
челгәне исә – ул сүзне ишетүче кеше, әмма тормыш мәшә-
катьләре һәм байлыкка кызыгу сүзне басып китә һәм ул уңыш
бирми. 23 Уңдырышлы җиргә чәчелгәне – сүзне ишетеп, аны
аңлаучы кеше, ул җимеш бирә һәм уңышы йөзләтә, алтмышла-
та һәм утызлата була.

*Тиле бодай хакында гыйбрәтле хикәя*

24 Гайсә аларга тагын бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:
– Күкләр Патшалыгы нәрсәгә охшаган? Күз алдыгызга ките-
регез: кеше үзенең басуына иң яхшы орлыгын чәчкән. 25 Әмма
төнлә, һәммәсе йоклаган чакта, аның дошманы килеп, иген ара-
сына тиле бодай чәчеп киткән. 26 Үсентеләр күтәрелеп, башак-
лары күренгән вакытта, тиле бодай да күренә башлаган. 27 Йорт
хуҗасының хезмәтчеләре аңа килеп: «Әфәнде, син бит үзеңнең
басуыңа орлыкның иң яхшыларын чәчтең. Тиле бодай каян ки-
леп чыккан соң?» – дип сорадылар. 28 «Бу дошман эше», – дип
җавап бирде хуҗалары. Алар әйттеләр: «Теләсәң, без барып
утыйк аларны!» 29 Ләкин ул әйтте: «Кирәкми, югыйсә утаган ва-
кытта тиле бодай белән бергә игенне дә йолкуыгыз бар. 30 Аны-
сы да, монысы да уңыш урганга кадәр үссеннәр. Ә инде урак
өстендә Мин уручыларга әйтермен: „Иң элек яндыру өчен, тиле
бодай көлтәләрен җыегыз, ә игенне келәткә илтеп салыгыз“».

*Горчица орлыгы һәм чүпрә хакында гыйбрәтле хикәя*

31 Гайсә аларга тагын бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:
– Күкләр Патшалыгы нәрсәгә охшаган? Күз алдыгызга ките-
регез: менә бер кеше үз басуына горчица орлыгын чәчкән. 32 Ул

бөтен орлыклардан да кечкенәрәк, ә инде үсеп җиткәч, бакча-
дагы һәммә үсемлекләрдән дә зуррак, агач кебек була. Һәм
кошлар, очып килеп, аның ботакларында оя ясыйлар.
33 Гайсә аларга тагын бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:
– Күкләр Патшалыгы нәрсәгә охшаган? Күз алдыгызга ките-
регез: менә бер хатын чүпрә белән бер капчык оннан камыр
басып куйган һәм берникадәр вакыттан соң бөтен камыр ка-
барган.
34 Боларның барысын Гайсә халыкка кинаяле хикәя итеп
сөйләде. Ул аларга кинаяле хикәя кулланмыйча бернәрсә дә
сөйләмәде. 35 Бу – пәйгамбәр әйткәннәр гамәлгә ашсын өчен
булды:

«Мин аларга кинаяле хикәяләр аша сөйләрмен,
Дөнья яратылган көннәрдән бирле
билгеле булмаганны сөйләрмен».

*Тиле бодай хакындагы гыйбрәтле хикәянең мәгънәсе*

36 Аннары, халыкны җибәреп, Гайсә өйгә керде. Шәкертләре
Аның янына килеп:
– Басудагы тиле бодай хакындагы гыйбрәтле хикәянең мәгъ-
нәсен безгә аңлатып бирче! – диделәр.
37 – Яхшы орлык чәчүче – ул Адәм Улы, – диде Гайсә. –
38 Басу – дөнья ул, яхшы орлыклар – Патшалык кешеләре, тиле
бодай – шайтан кешеләре, 39 һәм аны чәчүче дошман – иблис.
Урак өсте – дөнья бетү ул, ә уручылар – фәрештәләр. 40 Тиле
бодайны җыеп, утта яндырган кебек, дөнья беткәндә дә шулай
булачак. 41 Адәм Улы Үзенең фәрештәләрен җибәрер, алар
Аның Патшалыгыннан гөнаһка тартучыларның һәм явызлык
эшләүчеләрнең һәммәсен җыеп, 42 янып торган утлы мичкә
ташларлар. Анда елау һәм теш шыкырдату булыр. 43 Ә тәкъва
кешеләр Аталарының Патшалыгында кояштай балкып торыр-
лар. Колаклары булганнар ишетсеннәр!

*Яшерелгән хәзинә һәм энҗе хакында гыйбрәтле хикәя*

44 Күкләр Патшалыгы нәрсәгә охшаган? Күз алдыгызга ките-
регез: берәү кырда күмеп куелган хәзинәне тапкан, ди. Ул аны
яңадан күмеп куйган һәм, шатланып, бөтен булган нәрсәсен
сатып, шул кырны сатып алган.
45 Күкләр Патшалыгы тагын нәрсәгә охшаган? Күз алдыгызга
китерегез: сәүдәгәр яхшы энҗеләр эзли, ди. 46 Менә ул искит-
кеч матур энҗе тапкан. Кайтып, бар булган нәрсәсен саткан
һәм аны сатып алган.

*Ятьмәгә эләккән балыклар хакында гыйбрәтле хикәя*

[47] Күкләр Патшалыгы тагын нәрсәгә охшаган? Күз алдыгызга
китерегез: балыкчылар диңгездә ятьмә салганнар һәм аңа төрле
балыклар эләккән, ди. [48] Ятьмә балык белән тулгач, алар ять-
мәне ярга тартып чыгарганнар да, утырып, балыкларны сайлый
башлаганнар. Яхшыларын кәрзингә салганнар, ә ашарга ярак-
сызларын исә читкә ташлаганнар. [49] Дөнья беткәндә дә шулай
булачак: фәрештәләр килеп, тәкъвалардан яман кешеләрне
аерырлар. [50] Аларны янып торган утлы мичкә ташларлар. Анда
елау һәм теш шыкырдату булыр.
[51] Сез боларның барысын да аңладыгызмы?
— Әйе, — дип җавап бирделәр шәкертләре.
[52] — Менә шуңа күрә, — диде аларга Гайсә, — Күкләр Пат-
шалыгының шәкерте булган һәр канунчы үзенең келәтеннән
иске әйберләрен дә, яңаларын да чыгаручы йорт хуҗасы белән
охшаш.

*Гайсә Насарада инкяр ителә*

[53] Шушы гыйбрәтле хикәяләрне сөйләп бетергәч, Гайсә
аннан китте. [54] Үз шәһәренә кайткач, Ул аларның гыйбадәтха-
нәләрендә өйрәтте. Тыңлаучыларның һәммәсе таң калды.
— Шундый тирән акыл һәм кодрәтле эшләр Аңарда кайдан
икән? — диделәр алар. — [55] Ул балта остасының улы түгелме
соң? Аның анасы — Мәрьям, энеләре — Ягъкуб, Йосыф, Ши-
мун һәм Яһүд түгелме соң? [56] Һәм Аның бөтен сеңелләре мон-
да яшәмимени? Шулай булгач, моның барысы Аңа кайдан
килгән?
[57] Һәм Аны кире кактылар.
— Пәйгамбәр һәр җирдә ихтирам ителә, фәкать үзенең вата-
нында һәм өендә генә хөрмәт күрми, — диде аларга Гайсә.
[58] Аларның ышанмаулары аркасында, Ул анда күп могҗиза-
лар эшләмәде.

*Чумдыручы Яхъяның үleme*

**14** [1] Шушы вакытта идарәче Һируд Гайсә хакында ишетте.
[2] Ул үзенең кешеләренә: «Ул — үледән терелеп торган
Чумдыручы Яхъя. Шуңа күрә, Аның кодрәтле эшләр күр-
сәтергә куәте бар», — диде. [3] Чөнки Һируд, аның абыйсы Фи-
липнең Һирудия исемле хатыны аркасында, Яхъяны богаулап,
төрмәгә япкан иде. [4] Чөнки Яхъя: «Сиңа аның белән яшәргә
ярамый», — дигән иде. [5] Һируд аны үтерер иде, әмма Яхъяны
пәйгамбәр дип исәпләгән халыктан курыкты.

[6] Һирудның туган көнендә Һирудиянең кызы кунаклар ал-
дында биеде һәм Һирудка шулкадәр охшады ки, [7] ул ни генә
сорамасын, барын да бирергә ант итте. [8] Кыз исә, анасы өйрәт-
кәнчә:

– Хәзер үк Чумдыручы Яхъяның башын тәлинкәгә салып
китер, – дип әйтте.

[9] Патша кайгыга төште, әмма кунаклар алдында әйтелгән
ант хакына кызның теләген үтәргә [10] һәм, төрмәдә Яхъяның
башын кистерергә, дип әмер бирде. [11] Башны тәлинкәгә са-
лып китерделәр һәм кызга бирделәр, ә ул анасына илтеп
бирде. [12] Яхъяның шәкертләре килеп, аның гәүдәсен алып
кабергә салдылар, аннары китеп, бу хакта Гайсәгә хәбәр ит-
теләр.

*Биш меңне ашату*

[13] Гайсә исә бу хакта ишеткәч, ялгызы гына көймәгә утырып,
аулак урынга китте. Әмма кешеләр бу турыда ишеткәч, шәһәр-
ләреннән чыгып, Аның артыннан җәяүләп киттеләр. [14] Ярга
чыккач, Гайсә зур халык төркемен күреп алды. Ул аларны кыз-
ганды һәм авыру булганнарын савыктырды. [15] Кич җиткәндә,
Аның янына шәкертләре килделәр һәм:

– Бу кеше йөрми торган урын, ә вакыт соң инде. Халыкны
җибәр; авылларга барып, үзләренә ризык сатып алсыннар, –
диделәр.

[16] – Аларга китеп торасы түгел. Сез аларны үзегез ашаты-
гыз, – диде Гайсә.

[17] – Безнең монда бары тик биш икмәк һәм ике балык кына
бар, – диделәр тегеләр Гайсәгә.

[18] – Аларны Миңа монда китерегез, – диде Гайсә.

[19] Ул кешеләргә чирәмгә утырырга кушып, биш икмәкне
һәм ике балыкны алды да, күккә карап, шөкрана кылды һәм,
икмәкләрне сындыргалап, шәкертләренә бирде, ә алар исә ха-
лыкка өләштеләр. [20] Барысы да ашадылар һәм туйдылар. Шә-
кертләре калган сыныклардан тулы унике кәрзин җыйдылар.
[21] Барлык ашаучыларның саны исә, хатыннарны һәм балаларны
исәпкә алмаганда, биш меңгә якын иде.

*Гайсә су өстеннән атлап килә*

[22] Үзенең халыкны җибәрүен көтмичә, шәкертләренә, хәзер
үк көймәгә утырып, Үзеннән алданрак аргы якка чыгарга куш-
ты. [23] Халыкны җибәргәч, аулакта дога кылырга дип, Гайсә тау-
га менде. Кич җиткәч, Ул анда ялгызы булды. [24] Ә көймә исә
ярдан еракта иде, һәм, җил каршы булганлыктан, аңа көчле

дулкыннар бәрә иде. 25 Иртәнге өч белән алты арасында* Гай-
сә, диңгез өстеннән атлап, алар янына китте. 26 Шәкертләре
Гайсәнең диңгез өстеннән килүен күреп, куркыштылар:
– Бу өрәк! – диделәр. Һәм куркуларыннан кычкырып җи-
бәрделәр.
27 – Кыю булыгыз, бу – Мин! Курыкмагыз! – диде шунда ук
аларга Гайсә.
28 Шуннан соң Петер Аңа эндәште:
– Раббым! Әгәр Син булсаң, яныңа су өстеннән килергә
әмер бирче миңа.
29 – Кил, – диде аңа Гайсә.
Петер, көймәдән чыгып, су өстеннән Гайсәгә таба китте.
30 Әмма җилнең көчле булуын тоеп, куркып китте һәм бата
башлады.
– Коткар мине, Раббым! – дип кычкырып җибәрде ул.
31 Гайсә шунда ук кулын сузып, аны эләктереп алды һәм
әйтте:
– Аз иманлы син, нигә икеләндең?
32 Алар көймәгә кергәч, җил тынды. 33 Көймәдәге шәкертләре
Гайсә каршында йөзтүбән капландылар.
– Син чыннан да Аллаһы Улы! – диделәр алар.
34 Алар, диңгезне кичеп, Геннисарет ярына чыктылар. 35 Җирле
халык, Гайсәне танып, бу хакта шундагы бөтен әйләнә-тирәгә
таратты һәм Аңа барлык авыруларны алып килде. 36 Алар Аның
киеменең чабуына гына булса да кагылырга рөхсәт бирүен
үтенделәр. Һәм кем генә кагылмасын, барысы да савыкты.

*Кешене нәрсә пычрата*

**15** 1 Шуннан соң Иерусалимнан Гайсә янына фарисейләр
һәм канунчылар килделәр.
2 – Ни өчен Синең шәкертләрең ата-бабалардан килгән
йолаларны бозалар: ашар алдыннан кулларын юмыйлар? – дип
сорадылар.
3 – Ә сез ни өчен үзегезнең йолаларыгыз хакына Аллаһы
әмерен бозасыз? – дип каршы төште Гайсә. – 4 Аллаһы:
«Атаңны һәм анаңны хөрмәт ит» һәм «Атасын һәм анасын
хурлаган кеше үтерелергә тиеш», – дип әйткән. 5 Ә сез: «Берәр-
се атасына яки анасына: „Мин сиңа бирергә тиеш булган бү-
ләкне Аллаһыга вәгъдә иттем“, – дип әйтсә, 6 аңа инде атасын

---

* **14:25** *Иртәнге өч белән алты арасында* – грекча сүзгә-сүз «төннең дүртенче сак вакытында». Рим системасы буенча, төн өчәр сәгатьтән торган дүрт сак вакытына бүленгән булган.

хөрмәтләмәсә дә ярый», – дип өйрәтәсез. Моның белән сез
үзегезнең йолагыз хакына Аллаһы сүзен юкка чыгарасыз.
7 Монафикълар! Сезнең хакта Ишагыйя пәйгамбәр алдан күреп
дөрес әйткән:

8 «Бу халык Мине теле белән хөрмәт итә,
ә күңелләре исә Миннәнеракта.
9 Аларның Миңа табынулары бушка:
алар кеше уйлап чыгарган кагыйдәләргә өйрәтәләр».

10 Гайсә халыкны Үзе янына чакырып әйтте:

– Тыңлагыз һәм төшенергә тырышыгыз. 11 Аллаһы алдында
кешене авызына кергән нәрсә түгел, ә авызыннан чыккан
нәрсә пычрата.

12 Шуннан соң, шәкертләре Аның янына килеп:

– Синең сүзләреңне ишетеп, фарисейләрнең рәнҗүләрен
беләсеңме? – диделәр.

13 – Күктәге Атам тарафыннан утыртылмаган һәр үсенте та-
мыры белән йолкыначак, – диде Ул. – 14 Калдырыгыз аларны!
Сукырларны җитәкләп йөрүче сукырлар алар. Сукыр сукырны
җитәкләп бара икән, чокырга икесе дә егылып төшәчәк.

15 – Безгә бу сүзләрне аңлатып бирче, – дип мөрәҗәгать итте
Аңа Петер.

16 – Әллә сез дә һаман аңламыйсызмы? – диде Гайсә. –
17 Авызга кергән нәрсәнең карынга керүе, ә аннан тышка чы-
гарылып ташлануы сезгә аңлашылмыймыни? 18 Кешенең
авызыннан чыкканы йөрәгеннән чыга. Аны шул пычрата.
19 Явыз ниятләр, кеше үтерү, зиначылык, фәхешлек, урлашу,
ялган шаһитлек итү, хурлау кешенең йөрәгеннән чыга. 20 Ке-
шене менә шулар пычрата. Ә юмаган куллар белән ашау кеше-
не пычратмый.

*Мәҗүси хатынның иманы*

21 Гайсә ул урыннан Тур һәм Сидун җирләренә китте. 22 Аның
янына шул җирләрдә яшәүче кәнганлы хатын килде.

– Әфәнде, Давыт Улы! Кызган мине: минем кызым җенле
һәм бик нык газаплана! – дип кычкырды ул.

23 Әмма Гайсә аңа бер сүз белән дә җавап кайтармады. Шә-
кертләре, янына килеп, Аннан үтенә башладылар:

– Җибәр аны. Югыйсә ул кычкырып безнең арттан килә.

24 – Мин Исраил халкының югалган сарыкларына гына җи-
бәрелгән идем, – дип җавап бирде Гайсә.

25 Әмма хатын якын килде һәм Аның каршында йөзтүбән
капланып:

– Әфәнде, миңа ярдәм итче! – диде.

26 – Икмәкне балалардан алып, көчекләргә ташлау яхшы түгел, – диде Гайсә.

27 – Әйе, Әфәнде. Ләкин көчекләр дә хуҗаларының өстәленнән коелган валчыкларны ашый бит, – дип җавап кайтарды хатын.

28 Гайсә аңа:

– Әй, хатын! Синең иманың нык! Сиңа теләгәнеңчә булсын, – диде.

Һәм шул ук вакытта аның кызы савыкты.

*Дүрт меңне ашату*

29 Аннан киткәч, Гайсә Гәлиләя диңгезе яры буйлап барды.
Ул тауга менеп утырды. 30 Аның янына халык төркемнәре аксакларны, сукырларны, гарипләрне, телсезләрне һәм башка күп төрле авыру кешеләрне алып килделәр. Алар авыруларны Аның аяклары янына салдылар, һәм Гайсә аларны савыктырды.
31 Телсезләрнең сөйләшүен, гарипләрнең савыгуын, аксакларның йөрүен һәм сукырларның күрүен күреп, халык таң калды. Һәм алар Исраил Аллаһысын данладылар.

32 Гайсә шәкертләрен чакырып, аларга:

– Кешеләрне кызганам. Алар Минем белән инде өч көн буе, ә ашарларына һичнәрсәләре юк. Минем аларны ач килеш җибәрәсем килми: юлда хәлсезләнерләр, – дип әйтте.

33 – Шундый төркемне туендырырлык икмәкне монда, чүлдә, кайдан алырга? – диделәр Аңа шәкертләре.

34 – Сездә ничә икмәк бар? – дип сорады Гайсә.

– Җиде икмәк һәм берничә кечкенә балык, – дип җавап бирделәр алар.

35 Гайсә халыкка җиргә утырырга кушты һәм, 36 җиде икмәкне һәм балыкларны алып, шөкрана кылды. Аларны сындыргалап, шәкертләренә бирде, ә шәкертләре халыкка өләште.
37 Барысы да ашап туйдылар. Шәкертләре калган сыныкларны җиде кәрзин тутырып җыйдылар. 38 Ә ашаучылар исә, хатыннарны һәм балаларны исәпкә алмаганда, дүрт мең кеше иде.

39 Халыкны җибәргәч, Гайсә көймәгә утырды һәм Мәгедән җирләренә юл тотты.

*Гайсәдән илаһи билге күрсәтүен таләп итәләр*

16 1 Аннан соң, Гайсә янына фарисейләр һәм саддукейлар килделәр. Аны сынарга теләп, Аннан күктән илаһи билге күрсәтүен үтенделәр. 2 Әмма Ул:

– Кич белән сез: «Күк йөзе кызыл, шуңа күрә һава торышы яхшы булыр», – дисез. 3 Ә иртән иртүк: «Бүген давыл булачак,

чөнки күк йөзе кып-кызыл һәм хәвефле», – дисез. Күккә карап, сез һава торышын алдан әйтә аласыз, ә вакытларның билгеләрен аера белмисез. [4] Явыз һәм иман итмәүче буын кешеләре! Сез илаһи билгеләр таләп итәсез, әмма сезгә Юныс галәмәтеннән башка билге бирелмәс, – дип җавап бирде.

Һәм Гайсә аларны калдырып китте.

*Фарисейләр һәм саддукейлар ачыткысы*

[5] Шәкертләре башка ярга килеп җиттеләр. Алар үзләре белән икмәк алырга онытканнар икән.

[6] – Карагыз, фарисейләр һәм саддукейлар ачыткысыннан сак булыгыз! – диде аларга Гайсә.

[7] Алар исә үзара: «Ул, безнең икмәгебез булмаганга, шулай әйтә», – диештеләр.

[8] Гайсә, моны белеп, аларга:

– Аз иманлылар! Сез ни өчен икмәгегез юклыгы турында
сөйләшәсез? [9] Сез берни дә аңламыйсызмыни? Биш мең кеше-
гә өләшкән биш икмәкне оныттыгызмы? Сез ул вакытта ничә
кәрзин җыеп алдыгыз? [10] Ә җиде икмәкне дүрт меңгә өләшү
хакында? Сез ул вакытта ничә кәрзин җыеп алдыгыз? [11] Минем
икмәк хакында әйтмәвем сезгә аңлашылмыймы? Фарисейләр
һәм саддукейлар ачыткысыннан сак булыгыз! – диде.

[12] Шунда алар Гайсәнең икмәк ачыткысыннан түгел, ә фарисейләр һәм саддукейлар тәгълиматыннан сакланырга кушуын аңладылар.

*Кем ул Гайсә?*

[13] Филип Кайсариясе шәһәре янындагы җиргә килгәч, Гайсә Үзенең шәкертләреннән сорады:

– Кешеләр Адәм Улын кем дип белә?

[14] – Берәүләр Аны – Чумдыручы Яхъя, ди, икенчеләре – Ильяс, ә кайберләре исә Иремия яки башка пәйгамбәрләрнең берсе дип исәплиләр, – диделәр.

[15] – Ә сез, сез Мине кем дип беләсез? – дип сорады алардан Гайсә.

[16] – Син – Мәсих, тере Аллаһының Улы, – дип җавап бирде Шимун Петер.

[17] – Яхъя улы Шимун, син бәхетле, чөнки моны сиңа кеше
түгел, ә Минем Күктәге Атам ачып бирде, – диде Гайсә.
[18] – Шуңа күрә Мин сиңа әйтәм: син – Петер* һәм бу кыяда
Мин Үземә иман итүчеләр бердәмлеген төзиячәкмен. Аны үлем

---

* **16:18** *Петер* – грек телендә «кыя» дигән мәгънәне аңлата.

патшалыгы* җиңә алмас. 19 Мин сиңа Күкләр Патшалыгының
ачкычларын бирермен. Син җирдә тыйганны Аллаһы күкләрдә
тыячак, ә җирдә рөхсәт иткәнне Аллаһы күкләрдә рөхсәт итәчәк.
20 Аннан соң, шәкертләренә Үзенең Мәсих булуын һичкемгә
дә әйтмәскә кушты.

*Гайсә Үзенең үлеме хакында әйтә*

21 Шул вакыттан алып, Гайсә шәкертләренә Үзенең Иеру-
салимга барырга һәм анда аксакаллар, баш руханилар һәм
канунчылар тарафыннан күп газапларга дучар ителергә, анда
үтерелергә, әмма өченче көнне терелтеп торгызылырга тиешле-
ге хакында ачык итеп сөйли башлады.
22 Петер исә, Аны читкәрәк чакырып, каршы әйтә башлады:
– Сине Аллаһы сакласын, Раббым! Синең белән мондый хәл
була күрмәсен!
23 Әмма Гайсә, борылып, Петергә әйтте:
– Кит яныннан, шайтан! Син Мине вәсвәсәлисең, синдә
Аллаһы уйлары түгел, ә кешенеке.
24 Аннары Гайсә шәкертләренә әйтте:
– Кем Минем арттан барырга тели, үз-үзеннән баш тартсын,
үзенең хачын алып, Минем арттан барсын. 25 Чөнки кем үзенең
тормышын саклап калырга тели, ул аны югалтыр. Ә кем үзенең
тормышын Минем хакка югалтса, ул аны табар. 26 Бөтен дөнья
милкен үзенә алып, җанын һәлак итсә, кешегә моннан ни
файда? Ул, үзенең җанын кире кайтарып алыр өчен, нәрсә
тәкъдим итә алыр икән соң? 27 Чөнки Адәм Улы Атасының
балкып торган шөһрәте һәм Үзенең фәрештәләре белән килер
һәм һәркемгә аның гамәленә карап бирер. 28 Сезгә хак сүз әй-
тәм: монда басып торучыларның кайберләре Адәм Улының
Патша булып килүен күргәнче үлемне татымаячаклар.

*Гайсәнең тышкы кыяфәте үзгәрә*

**17** 1 Гайсә, алты көннән соң, Петерне, Ягъкубны һәм аның
энесе Яхъяны Үзе белән алып, биек тауга менде. Алар
анда үзләре генә иделәр. 2 Гайсәнең тышкы кыяфәте
аларның күз алдында үзгәреп китте: йөзе кояш кебек балкыды,
ә киемнәре яктылык кебек ап-ак булды. 3 Менә алар каршында
Муса белән Ильяс пәйгамбәрләр пәйда булдылар һәм алар
Гайсә белән сөйләштеләр. 4 Петер Гайсәгә әйтте:
– Раббыбыз! Безнең монда булуыбыз нинди яхшы! Телисеңме,
өч чатыр корам: берсен Сиңа, берсен Мусага, берсен Ильяска?

---

* 16:18 *Үлем патшалыгы* – грек телендә сүзгә-сүз: «үлем капкасы».

[5] Петер сөйләгән вакытта балкып торган болыт төшеп, аларны
каплады. Һәм болыт эченнән: «Бу – Минем сөекле Улым, Ул
Минем куанычым. Аны тыңлагыз!» – дигән сүзләр ишетелде.
[6] Бу тавышны ишетеп, шәкертләр йөзтүбән капландылар һәм
нык куркыштылар. [7] Гайсә, яннарына килеп, аларга кагылды һәм:
– Торыгыз, курыкмагыз! – диде.
[8] Шәкертләр, күтәрелеп карагач, Гайсәдән башка беркемне
дә күрмәделәр.
[9] Таудан төшкәндә Гайсә аларга боерып әйтте:
– Адәм Улы терелтеп торгызылганга кадәр, күргәнегез ха-
кында беркемгә дә сөйләмәгез.
[10] – Ә канунчылар ни өчен, башта Ильяс килергә тиеш, дип
әйтәләр? – дип сорадылар шәкертләре.
[11] – Чыннан да, башта Ильяс килеп, барын да үз урынына
урнаштырачак, – дип җавап бирде Гайсә. – [12] Сезгә әйтәм:
Ильяс килде инде, ләкин кешеләр аны танымадылар һәм аның
белән ни теләсәләр, шуны эшләделәр. Шулай ук Адәм Улы да
алар аркасында күп газаплар кичерәчәк.
[13] Шунда шәкертләре Гайсәнең Чумдыручы Яхъя хакында
сөйләгәнен аңладылар.

### *Гайсә җенле малайны савыктыра*

[14] Алар халык төркеме янына әйләнеп кайткач, Гайсә алдына
бер кеше килде һәм тезләренә егылып:
[15] – Әфәндем, улымны кызганчы! Аңарда өянәк авыруы, ул
бик газаплана. Еш кына әле утка, әле суга ташлана. [16] Мин аны
шәкертләреңә китергән идем, әмма алар аны савыктыра алма-
дылар, – диде.
[17] – Әй, имансыз һәм бозык буын! Миңа күпме сезнең белән
булырга? Сезне күпме түзеп торырга? Малайны Минем янга
китерегез! – диде Гайсә.
[18] Гайсә җенгә чыгарга әмер бирде. Җен чыкты, малай исә
шул ук мизгелдә савыкты.
[19] Шәкертләре Гайсә белән ялгыз гына калгач, Аның янына
килделәр һәм:
– Ни өчен без аны куып чыгара алмадык? – дип сорадылар.
[20] Гайсә җавап бирде:
– Чөнки инануыгыз аз. Сезгә хак сүз әйтәм: сезнең горчица
орлыгы кадәр генә инануыгыз булса һәм менә бу тауга: «Мон-
нан тегендә күчеп кит», – дип әйтсәгез, ул урыныннан күчәр
иде; сезгә мөмкин булмаган һичнәрсә булмас иде. [ [21] ]*

* 17:21 Кайбер кулъязмаларда 21 нче аять тә бар: «Мондый җеннәр төре исә фәкать дога кылу һәм ураза тоту белән куып чыгарыла».

22 Алар Гәлиләядә бергә җыелгач, Гайсә аларга әйтте:
– Адәм Улы кешеләр кулына тотып бирелергә 23 һәм үтерелергә тиеш, әмма өченче көнне Ул терелтеп торгызылачак.
Шәкертләр бик зур хафага төштеләр.

*Аллаһы Йортына бирелә торган сәдака*

24 Алар Кәпәрнаумга килеп җиткәч, Аллаһы Йортына салым* җыючылар Петер янына килделәр.
– Остазыгыз салым түләмиме? – дип сорадылар алар.
25 – Әйе, түли – дип җавап бирде Петер.
Петер өйгә кергәч, беренче булып сүзне Гайсә башлады:
– Петер, син ничек уйлыйсың: җирдәге патшалар салымны һәм ясакны кемнән түләтәләр? Үз халкыннанмы, әллә чит җир кешеләреннәнме?
26 Петер:
– Чит җир кешеләреннән, – дип җавап бирде.
– Алай булгач, үзенекеләре түләүдән ирекле, – диде Гайсә. –
27 Әмма аларны рәнҗетмик. Диңгезгә барып кармак сал. Беренче эләккән балыкны алып, аның авызын ач һәм анда көмеш тәңкә табарсың. Аны алып, Минем өчен дә, үзең өчен дә салым җыючыларга бир.

*Кем иң бөеге?*

18 1 Шуннан соң Гайсә янына шәкертләре килделәр һәм:
– Күкләр Патшалыгында кем иң бөеге? – дип сорадылар.
2 Гайсә бер баланы чакырып алып, алар каршына бастырды
3 һәм:
– Сезгә хак сүз әйтәм: әгәр сез үзгәреп, шушындый балалар кебек булмасагыз, Күкләр Патшалыгына кермәячәксез, – диде.
4 – Кем шушы бала кебек үзен кече итеп тота, шул Күкләр Патшалыгында иң бөеге булыр. 5 Һәм Минем хакка шушындый бер баланы кабул иткән кеше Мине кабул итә. 6 Әмма Миңа иман итүче шушындый кечкенәләрнең берсен юлдан яздыручыны, муенына тегермән ташын асып, тирән диңгез суында батырсалар, аның өчен яхшырак булыр иде.
7 Дөньяга кайгы, чөнки юлдан яздырырдай нәрсәләр күп! Вәсвәсәләрнең килүе котылгысыз, әмма алар кем аркылы килә, шуңа кайгы! 8 Әгәр сине кулың яки аягың вәсвәсәгә төшерсә,

---

* 17:24 *Аллаһы Йортына салым* – төп нөсхәдә: «ике драхма». Һәр яһүд ир-аты елга бер тапкыр Аллаһы Йортына ике динарга тигез булган ике драхма күләмендә салым түләргә тиеш булган.

аны чабып, читкә ташла! Ике кулың һәм ике аягың белән мәңгелек утка ташлануга караганда, тормышка бер кулың белән яки аксак килеш керүең синең өчен яхшырак.
9 Әгәр күзең сине вәсвәсәгә төшерсә, аны суырып алып, читкә ташла! Ике күзең белән җәһәннәм утына ташлануга караганда, тормышка бер күзең белән керүең яхшырак.

*Югалган сарык хакында гыйбрәтле хикәя*

10 Карагыз, бала кебек иман итүчеләрнең берсен дә түбәнсетмәгез. Сезгә әйтәм: аларның фәрештәләре һәрвакыт Күктәге Атамның йөзен күреп торалар. [ 11 ]*

12 Сез ничек уйлыйсыз? Әгәр берәүнең йөз сарыгы булып, аның берсе югалса, ул кеше, туксан тугыз сарыгын тауларда калдырып, югалганын эзләп китмәсме икән соң?
13 Ә инде тапкач, сезгә хак сүз әйтәм: югалмаган туксан тугызга караганда, табылганына күбрәк куаныр.
14 Сезнең Күктәге Атагыз да шулай: кечкенәләрнең берсенең дә һәлак булуын теләми.

*Әгәр имандашың гөнаһ кылса*

15 Әгәр туганың сиңа каршы гөнаһ кылса, барып, гаебен үзенә генә фаш ит. Ул тыңласа, син туганыңны үзеңә кайтарган булырсың.
16 Ләкин тыңламаса, һәр очрак ике яки өч шаһит белән раслансын өчен, үзең белән бер яки ике кешене ал.
17 Әгәр аларны да тыңламаса, иман итүчеләр бердәмлегендә сөйлә, ә инде бердәмлек әгъзаларын да тыңламаса, ул чакта аның белән мөгамәләң мәҗүси, яки салым җыючы белән булган кебек булсын.

18 Сезгә хак сүз әйтәм: җирдә нәрсәне тыйсагыз, шуны күктә Аллаһы тыяр һәм нәрсәне рөхсәт итсәгез, күктә Аллаһы да рөхсәт итәр.

19 Тагын сезгә әйтәм: сезнең икегез җирдә, үзара килешеп, Күктәге Атамнан нәрсә генә сорасагыз да, Ул аны эшләячәк.
20 Чөнки икәү яки өчәү Минем хакка җыелса, Мин дә алар белән булачакмын.

*Мәрхәмәтсез хезмәтче хакында гыйбрәтле хикәя*

21 Шуннан соң Аның янына Петер килде һәм:

– Раббым, туганымны, әгәр ул миңа каршы гөнаһ кылса, ничә тапкыр кичерергә тиешмен? Җидегә кадәрме?

22 – Юк, җидегә кадәр түгел, ә җитмеш тапкыр җидегә кадәр, – диде аңа Гайсә. –
23 Күкләр Патшалыгы менә нәрсәгә охшаулы.

---

* 18:11 Кайбер кулъязмаларда 11 нче аять тә бар: «Чөнки Адәм Улы югалганны коткарырга килде».

Күз алдына китерегез: бер патша үзенең хезмәтчеләреннән хи-
сап эшен таләп иткән. [24] Акча хисабы эше башлангач, аңа ун
мең талант* бурычлы бер кешене китергәннәр. [25] Ул акчаларны
кайтарып бирә алмагач, бурычын түләтер өчен, патша аның
үзен дә, хатынын да, балаларын да, милкен дә сатырга әмер
биргән. [26] Бу хезмәтче патша каршында йөзтүбән капланып
әйткән: «Бурычымны көтче! Мин сиңа барын да кайтарып би-
рәчәкмен!» [27] Хуҗасы, аны кызганып, бурычын бәхилләгән һәм
хезмәтчесен җибәргән.

[28] Ләкин бу хезмәтчесе, киткәч, үзенә бары тик йөз динар**
тиешле хезмәттәшләренең берсен очраткан. Ул аның бугазына
ябышып, буа башлаган. «Миңа бурычыңны түлә!» – дип таләп
иткән. [29] Тегесе, тезләренә егылып, аңа: «Бурычымны көтче,
мин кайтарып бирәчәкмен!» – дигән. [30] Әмма тегесе, риза бул-
мыйча, бурычын түләгәнгә кадәр, аны төрмәгә утырткан.
[31] Патшаның башка хезмәтчеләре, моны күреп, бик кайгырган-
нар һәм бар булган хәлне хуҗаларына сөйләп биргәннәр.
[32] Шуннан соң хуҗасы аны чакырып әйткән: «Яраксыз кол!
Үтенгәч, мин синең бөтен бурычыңны бәхилләдем. [33] Мин рә-
химлек күрсәткән кебек, хезмәттәшеңә син дә рәхимлек күрсә-
тергә тиеш идең бит!» [34] Һәм ачуы чыккан патша, хезмәтчесе
бөтен бурычын түләп бетергәнгә кадәр, аны газаплаучылар
кулына тапшырган.

[35] Әгәр туганыгызны ихлас күңелдән кичермәсәгез, Күктәге
Атам да сезнең белән шулай эшләячәк.

*Гайсә аерылышу хакында өйрәтә*

19 [1] Гайсә Үзенең сүзен тәмамлагач, Гәлиләядән китеп,
Үрдүн аръягындагы Яһүдия җиренә юнәлде. [2] Артыннан
халык төркемнәре барды, һәм Ул алар арасындагы авы-
руларны савыктырды. [3] Гайсә янына фарисейләр килгәч, Аны
сынарга теләп, сорадылар:

– Ир кешегә хатынын һәртөрле сәбәптән аерып җибәрергә
канун рөхсәт итәме?

[4] – Кешеләрне бар иткәндә, Булдыручы баштан ук «аларны ир
һәм хатын итеп бар итте», – дигәнне сез укымадыгызмыни? –
дип сорады Гайсә. – [5] Һәм Аллаһы әйткән: «Шуңа күрә, ир
кеше, атасын һәм анасын калдырып, хатынына кушылыр һәм

---

* 18:24 *Талант* – римлыларның иң зур акча берәмлеге. Ул эшченең унбиш еллык хезмәт хакын тәшкил иткән.

** 18:28 *Динар* – көмеш тәңкә. Эшченең бер көнлек хезмәт хакын тәшкил иткән.

икесе дә бер тән булыр». [6] Шулай итеп, алар инде ике кеше
түгел, ә бер бөтен. Аллаһы кушылдырганны кеше аермасын.

[7] – Ә нигә соң Муса, кеше хатынын аерып җибәргәндә, аңа аерылышу кәгазен бирергә тиеш, дип боерган? – диделәр алар.

[8] – Ул сезгә күңелләрегез каты булганга күрә аерылышырга
рөхсәт биргән. Башта алай түгел иде, – диде Гайсә. – [9] Сезгә
әйтәм: ир кеше, зина кылу сәбәбе булмый торып, хатыны белән аерылыша һәм башкага өйләнә икән, ул зина кыла.

[10] Шәкертләре Аңа:

– Ирнең хатынга карата мөнәсәбәте шундый була икән, ул чакта өйләнмәве яхшырак, – диделәр.

[11] – Мин әйткәннәрне барысы да кабул итә алмыйлар, ә бары тик кемгә бирелгән булса, шул кабул итәр, – дип җавап
бирде Гайсә. – [12] Чөнки кешеләр төрле сәбәпләр аркасында
өйләнми: берәүләр ана карынынннан шундый булып туалар, икенчеләрен кешеләр шундый итәләр, һәм өченчеләре исә Күкләр Патшалыгы хакына үзләре өйләнмиләр. Моны кем кабул итә ала, шул кабул итсен!

*Гайсә балаларга фатиха бирә*

[13] Шуннан соң, кулларын куеп дога кылсын дип, кешеләр
Гайсә янына балаларны алып килделәр. Шәкертләре исә аларны шелтәләделәр. [14] Әмма Гайсә:

– Балаларга ирек бирегез, аларга Минем янга килергә комачауламагыз! Чөнки Күкләр Патшалыгы менә шундыйларныкы, – диде.

[15] Алар өстенә фатихалау өчен кулларын куйгач, Гайсә аннан
китте.

*Гайсә һәм бер бай*

[16] Бервакыт Гайсә янына бер кеше килде:

– Остаз, мәңгелек тормышны алыр өчен мин нинди игелекле эш эшләргә тиеш? – дип сорады ул.

[17] – Син игелек хакында ник Миннән сорыйсың? Берәү генә игелекле. Мәңгелек тормышка керәсең килә икән, Аның әмерләрен үтә, – диде Гайсә.

[18] – Нindиләрен? – дип сорады тегесе. Гайсә җавап бирде:

– Кеше үтермә, зина кылма, урлама, ялган шаһитлек итмә,
[19] атаңны һәм анаңны хөрмәт ит һәм якыныңны үзеңне яраткан кебек ярат.

[20] – Мин боларны үтәп килдем. Миңа тагын нәрсә җитми? – дип сорады егет.

21 – Камил булырга теләсәң, бар да, булган милкеңне сатып,
фәкыйрьләргә өләш. Шулай эшләсәң, күктәге хәзинәгә ия
булырсың. Аннары яныма кил дә Миңа ияр, – диде Гайсә.
22 Егет исә, бу сүзләрне ишетеп, борчуга төште һәм китеп
барды. Чөнки ул бик бай кеше иде. 23 Ә Гайсә шәкертләренә
әйтте:
– Сезгә хак сүз әйтәм: бай кешегә Күкләр Патшалыгына ке-
рүе кыен шул. 24 Тагын сезгә әйтәм: бай кешегә Аллаһы Патша-
лыгына керүгә караганда, дөягә энә күзе аша үтү җиңелрәк.
25 Шәкертләре, моны ишетеп, бик аптырадылар.
– Алай булгач, кем генә котыла алыр соң? – дип сорадылар
алар.
26 Гайсә аларга карап:
– Бу – кешеләргә мөмкин түгел, әмма Аллаһыга барысы да
мөмкин, – диде.
27 Шуннан соң Петер Гайсәгә мөрәҗәгать итте:
– Менә без, бөтен нәрсәбезне калдырып, Сиңа иярдек.
Моның өчен безгә нәрсә була?
28 – Сезгә хак сүз әйтәм: бөтен дөнья яңаргач, Адәм Улы
шөһрәтле тәхетенә утырганнан соң, сез дә, Миңа ияручеләр,
Исраилнең унике кабиләсе өстеннән хакимлек итеп, унике
тәхеткә утырачаксыз. 29 Йортларын яки агай-энеләрен яки
апа-сеңелләрен яки ата-анасын яки балаларын яки басуларын
Минем хакка калдырган һәркем йөз тапкыр күбрәк алачак
һәм аңа мәңгелек тормыш биреләчәк. 30 Әмма беренче бул-
ганнарның күбесе ахыргы булырлар, ә ахыргылары исә беренче
булырлар.

*Йөзем бакчасында эшләүчеләр хакында гыйбрәтле хикәя*

**20** 1 Күкләр Патшалыгы нәрсәгә охшаш? Күз алдыгызга
китерегез: иртән иртүк хуҗа үзенең йөзем бакчасына
эшчеләр ялларга барган. 2 Ялчылар белән көненә бер
динардан килешкәч, ул аларны йөзем бакчасына җибәргән.
3 Иртәнге сәгать тугызда* өеннән чыгып, базар мәйданына кил-
гәч, ул анда эшсез торган башка кешеләрне күреп 4 әйткән:
«Сез дә йөзем бакчасына барыгыз. Мин сезгә тиешенчә түләр-
мен». Алар киткәннәр. 5 Ә хуҗа унике сәгатьтә дә, көндезге
сәгать өчтә дә шулай ук эшләгән. 6 Сәгать бишләр тирәсендә
хуҗа тагын чыгып, басып торган кешеләрне күреп әйткән: «Сез
нигә монда көне буе эшсез торасыз?» – дип. 7 «Безне беркем дә

---

* 20:3 *Иртәнге сәгать тугызда* – вакыт хисабы турында сүзлекне карагыз.

ялламады», – дип җавап кайтарганнар алар. Ул аларга: «Сез дә
йөзем бакчасына барыгыз», – дип әйткән.
8 Кич җиткәч, хуҗа идарәчесенә: «Эшчеләрне чакырып,
аларга түлә. Соңгы ялланганнарыннан башлап, беренчеләре
белән тәмамла», – дигән. 9 Кичке биштә ялланганнар килеп,
һәрберсе бер динар акча алган. 10 Шуңа карап, беренчеләре:
«Күбрәк алырбыз», – дип уйлаганнар. Әмма алар да берәр ди-
нар акча алганнар. 11 Ә алгач, хуҗага зарлана башлаганнар:
12 «Бу соң килгәннәре бары тик бер сәгать эшләделәр, ә син
аларны безнең белән тиңләдең. Без бит бу көннең авырлыгын
һәм эсселеген кичердек».
13 Әмма ул аларның берсенә җавап биргән: «Дустым, мин сиңа
карата гаделсезлек эшләмәдем. Син минем белән бер динарга
килештең түгелме соң? 14 Үзеңә тиешлесен ал да кит. Ә мин бу
соңгысына да сиңа биргән хәтле бирәсем килә. 15 Үземнең ак-
чам белән үзем теләгәнчә эшләргә минем хокукым юкмыни?
Әллә син минем юмартлыгымнан көнләшәсеңме?»
16 Шулай, соңгылар беренче булырлар, ә беренчеләр исә соң-
гы булырлар, – диде Гайсә.

*Гайсә янә Үзенең үлеме хакында әйтә*

17 Иерусалимга таба барганда, Гайсә унике шәкертен читкә
чакырып, аларның үзләренә генә әйтте:
18 – Без Иерусалимга барабыз. Адәм Улы баш руханилар һәм
канунчылар кулына тотып биреләчәк, Аны үлемгә хөкем итә-
чәкләр 19 һәм, мыскыллау, камчылату һәм хачка кадаклату
өчен, мәҗүсиләр кулына тапшырачаклар. Әмма өченче көндә
Ул үледән терелтеп торгызылачак.

*Гайсә һәм Зебедәй уллары*

20 Шуннан соң Зебедәйнең хатыны, уллары белән Гайсә яны-
на килеп, Аның алдында тезләнде. Ул Аннан нәрсәдер сорарга
теләде.
21 – Син нәрсә телисең? – дип сорады Гайсә.
– Минем бу ике улым Синең Патшалыгыңда берсе уң ягыңа,
икенчесе сул ягыңа утырачак, дип вәгъдә итсәң иде, – диде
хатын.
22 – Сез нәрсә сораганыгызны белмисез, – диде Гайсә. –
Мин эчәчәк касәдән эчә алырсызмы?
– Алырбыз, – диделәр алар.
23 – Сез Минем касәмнән эчәрсез, ә уң ягыма яки сул ягыма
утырырга рөхсәт бирү Минем кулда түгел. Анда Атам тарафын-
нан билгеләнгәннәр утырачак.

24 Бу хакта ишеткәч, калган ун шәкертнең бу туганнарына
каршы ачулары чыкты. 25 Ә Гайсә аларны чакырып алып:
– Сез беләсез: халык җитәкчеләре халыклар өстеннән ха-
кимлек итәләр һәм бөекләр халыкларны үз куллары астында
тоталар. 26 Ләкин сездә алай булмасын! Сезнең арагызда бөек
булырга теләүче башкаларга хезмәтче булсын, 27 һәм арагызда
беренче булырга теләүче сезнең өчен кол булсын. 28 Адәм Улы
да бит Үзенә хезмәт итсеннәр өчен дип килмәде, ә Үзе, хезмәт
итеп, күпләрне йолып алу өчен Үзенең тормышын бирергә дип
килде, – диде.

*Гайсә ике сукырны савыктыра*

29 Гайсә шәкертләре белән Әрихә шәһәрен калдырып кит-
кәндә, Аның артыннан зур төркем барды. 30 Юл читендә ике
сукыр утыра иде. Алар Гайсәнең үтеп баруын ишеткәч, кычкы-
рып җибәрделәр:
– Әфәнде, Давыт Улы! Безне кызган!
31 Халык, ачуланып, аларның дәшмәвен таләп итте, әмма
алар тагын да көчлерәк итеп:
– Әфәнде, Давыт Улы! Безне кызган! – дип кычкырдылар.
32 Гайсә, туктап, аларны чакырды һәм:
– Сезнең өчен нәрсә эшләвемне телисез? – дип сорады.
33 – Әфәнде! Безнең күзләребез ачылсын иде! – диделәр алар.
34 Гайсә, аларны кызганып, күзләренә кулын тидерде: алар
шунда ук күрә башладылар һәм Аңа ияреп киттеләр.

*Гайсәнең Иерусалимга тантана белән керүе*

**21** 1 Алар Иерусалимга якынлашканда, Зәйтүн тавындагы
Бәйтфәги авылына килгәч, Гайсә ике шәкертен җибәр-
де 2 һәм:
– Алда күренеп торган авылга барыгыз. Шунда ук бәйдәге
ана ишәк белән яшь ишәкне күрерсез. Аларны бәйдән ычкын-
дырып, Миңа китерегез. 3 Кем дә булса берәр нәрсә әйтсә, аңа:
«Алар Хуҗага кирәк», – дип әйтегез. Һәм ул ишәкләрне шунда
ук җибәрер, – диде.
4 Бу – пәйгамбәр аша әйтелгән сүзләр гамәлгә ашсын өчен
булды:
5 «Сион кызына әйтегез:
„Менә Патшаң сиңа килә.
Ул юаш; ишәккә һәм тайга,
камыт кигезелгән ишәк баласына атланган“».
6 Шәкертләре, барып, барын да Гайсә кушканча эшләделәр.
7 Баласы белән ишәкне алып китерделәр. Өс киемнәрен ишәкләр

өстенә салдылар һәм Гайсә аларга атланды. [8] Зур халык төрке-
ме киемнәрен юл өстенә җәйделәр, башкалары исә агач ботак-
ларын сындырып юлга салдылар. [9] Гайсәнең алдыннан һәм ар-
тыннан килүче зур халык төркемнәре:

– Давыт Улына Һошанна*!
Раббы исеме белән Килүче мөбарәк!
Югарыда Һошанна! –

дип кычкырдылар.
[10] Гайсә Иерусалимга килеп кергәч, бөтен шәһәр кузгалды.
– Кем бу? – дип сораштылар кешеләр.
[11] – Бу – Гайсә, Гәлиләядәге Насарадан пәйгамбәр, – дип
җавап бирде халык.

### *Аллаһы Йорты – дога кылу йорты*

[12] Гайсә, Аллаһы Йортына кереп, барлык сатучыларны һәм
сатып алучыларны куып чыгарды, акча алмаштыручыларның
өстәлләрен һәм күгәрчен сатучыларның утыргычларын аударып
ташлады. [13] Гайсә аларга әйтте:
– Изге язмада: «Минем Йортым дога кылу йорты дип ата-
лыр», – дип язылган, ә сез аны юлбасарлар оясына әйләнде-
рәсез!
[14] Аллаһы Йортында Гайсә янына сукырлар һәм аксаклар
килде һәм Ул аларны савыктырды. [15] Ләкин баш руханиларның
һәм канунчыларның, Ул эшләгән искиткеч эшләрне һәм бала-
ларның Аллаһы Йортында: «Давыт Улына Һошанна!» – дип
кычкыруларын күреп, ачулары чыкты. [16] Алар Аңа әйттеләр:
– Аларның нәрсә әйтүләрен ишетәсеңме?
– Әйе, – дип җавап бирде Гайсә. – Сез: «Балалар һәм на-
расыйлар авызыннан Син Үзеңә мактау чыгарттың», – дип
язылганны әллә укымадыгызмы?
[17] Гайсә, аларны калдырып, шәһәрдән Бәйтәниягә китте һәм
төнне анда үткәрде.

### *Гайсә инҗир агачын каргый*

[18] Иртә белән шәһәргә таба юл тотканда, Гайсәнең карыны
ачты. [19] Юл буендагы инҗир агачын күреп, Ул аның янына
килде, әмма яфрактан башка берни тапмагач, аңа:
– Беркайчан да җимешең булмасын! – диде.
Һәм шунда ук инҗир агачы корып төште.

---

* 21:9 *Һошанна* – яһүд телендә «ярдәм ит» яки «Аллаһыга дан» ди-
гәнне аңлата.

20 Моны күреп, шәкертләренең исләре китте.
– Ничек алай кинәт кенә инҗир агачы корып төште соң? –
дип сорадылар алар.
21 – Сезгә хак сүз әйтәм: ышансагыз һәм икеләнмәсәгез, сез
Мин инҗир агачы белән эшләгәнне генә эшләп калмассыз,
әмма бу тауга: «Күтәрелеп, диңгезгә ташлан!» – дип әйтсәгез
дә шулай булачак. 22 Һәм догагызда ни генә сорасагыз да, әгәр
ышансагыз, алырсыз, – диде Гайсә.

*Гайсәнең вәкаләте кемнән?*

23 Гайсә Аллаһы Йортына кереп, анда өйрәткән вакытта,
янына баш руханилар белән халык аксакаллары килде.
– Син боларны нинди вәкаләт белән эшлисең? Андый хо-
кукны Сиңа кем бирде? – дип сорадылар алар.
24 – Мин дә сезгә бер сорау бирәм, – диде аларга Гайсә. –
Әгәр сез җавап бирсәгез, Мин дә боларны нинди вәкаләт белән
эшләвемне әйтермен. 25 Яхъяның суга чумдыруы кемнән бул-
ды? Күктәнме, әллә кешеләрдәнме?
Алар үзара:
– Әгәр: «Күктән», – дип әйтсәк, Ул: «Ә ни өчен сез аңа
ышанмадыгыз?» – дип сораячак. 26 Ә инде: «Кешеләрдән», – дип
әйтсәк, халык безне нишләтер? Алар бит барысы да Яхъяны
пәйгамбәр дип исәпли, – диештеләр.
27 Шуңа күрә алар Гайсәгә:
– Белмибез, – дип җавап кайтардылар.
– Алай булгач, Мин дә сезгә боларны нинди вәкаләт белән
эшләвемне әйтмим.

*Ике угыл хакында сорау*

28 Ә менә бу хакта сез ни диярсез? Бер кешенең ике улы
булган. Беренчесе янына килеп, ул әйткән: «Улым, бүген йө-
зем бакчасына барып эшлә әле». 29 Тегесе: «Теләмим», – дип
әйткән, әмма бераздан кире уйлап, киткән. 30 Атасы икенче
улы янына килеп, шуны ук әйткән. Анысы исә: «Барам, әфән-
дем», – дип әйткән, әмма бармаган. 31 Аталарының ихтыярын
кайсысы үтәгән?
– Беренчесе, – дип җавап бирделәр тегеләр.
– Ышаныгыз: Аллаһы Патшалыгына салым җыючылар һәм
фахишәләр сездән алда керәчәкләр. 32 Чөнки Яхъя сезгә тәкъ-
валык юлын күрсәтергә дип килгән иде, әмма сез аңа ышанма-
дыгыз. Ә салым җыючылар һәм фахишәләр аңа ышандылар.
Сез, моны күреп тә, барыбер тәүбә итмәдегез һәм аңа ышан-
мадыгыз.

### *Йөзем үстерүче явызлар хакында гыйбрәтле хикәя*

[33] Хәзер икенче гыйбрәтле хикәяне тыңлагыз.
Җир биләүче бер кеше булган. Ул йөзем бакчасы утырткан,
аны койма белән әйләндереп алган, йөзем изү өчен чокыр ка-
зыган, бакчаны саклау өчен манара торгызган һәм бакчаны йө-
зем үстерүчеләргә куллану өчен биреп, үзе чит якларга китеп
барган. [34] Уңыш җыяр вакыт җиткәч, үз өлешен алырга дип,
үзенең хезмәтчеләрен җибәргән. [35] Әмма йөзем үстерүчеләр
хезмәтчеләрен тотып, берсен кыйнаганнар, башкасын үтер-
гәннәр, өченчесен ташлар атып үтергәннәр. [36] Хуҗа тагын да
күбрәк хезмәтчеләрен җибәргән, әмма алар белән дә шулай ук
эшләгәннәр. [37] Ниһаять, «Улыма хөрмәт күрсәтерләр», — дип
уйлап, улын җибәргән. [38] Әмма йөзем үстерүчеләр хуҗаның
улын күреп, бер-беренә: «Бу — варис. Әйдәгез, аны үтерик һәм
аңа каласы мирас безнеке булыр», — диешкәннәр. [39] Алар аны
тотып, йөзем бакчасыннан алып чыгып үтергәннәр.
[40] Шулай итеп, йөзем бакчасының хуҗасы әйләнеп кайткач,
бу йөзем үстерүчеләр белән нәрсә эшләр?
[41] — Ул явыз кешеләрне коточкыч рәвештә үтерер һәм йөзем
бакчасын башка йөзем үстерүчеләргә кулланырга биреп торыр.
Болар хуҗага тиешле өлешне вакытында бирерләр, — дип җавап
бирделәр алар.
[42] — Ә сез Изге язмада:

«Төзүчеләр яраксыз дип кире каккан таш
иң мөһим почмак ташы булды.
Бу Раббы тарафыннан эшләнде
һәм безнең алда гаҗәп нәрсә», —

дигәнне укымадыгызмыни? — диде Гайсә. — [43] Шуңа күрә, Мин
сезгә әйтәм: Аллаһы Патшалыгы сездән алынып, аның җиме-
шен китерүче халыкка биреләчәк. [44] Бу таш өстенә егылган
һәркем челпәрәмә киләчәк, ә ул таш кемнең дә булса өстенә
төшсә, аны сытачак.
[45] Баш руханилар һәм фарисейләр Гайсәнең гыйбрәтле хикә-
яләрен ишетеп, Аның үзләре хакында сөйләвен аңладылар.
[46] Алар Гайсәне кулга алырга теләделәр, ләкин Аны пәйгамбәр
дип исәпләгән халыктан курыктылар.

### *Туй мәҗлесе хакында гыйбрәтле хикәя*

## 22

[1] Гайсә, алар белән сөйләшкәндә, тагын гыйбрәтле хи-
кәяләр сөйләде:
[2] — Күкләр Патшалыгы нәрсәгә охшаган? Күз алды-
гызга китерегез: патша үзенең улы өчен туй мәҗлесе үткәр-
гән. [3] Ул, чакырылган кунакларны мәҗлескә җыярга ниятләп,

хезмәтчеләрен җибәргән, ләкин кунаклар килергә теләмәгәннәр.
4 «Мәҗлесем инде әзер: үгезләрем һәм симертелгән мал суелган,
бөтен нәрсә әзер, кунакка килегез», — дип тагын хезмәтчеләрен
чакырылган кешеләргә әйтергә җибәргән. 5 Әмма, чакыруны
санга сукмыйча, аларның һәрберсе үз эшләре белән таралышканнар: берсе басуына киткән, берсе үзенең сәүдә эшенә киткән,
6 ә калганнары исә хезмәтчеләрне тотып кыйнаганнар һәм үтергәннәр. 7 Патша, ярсып, ул үтерүчеләрне юк итәргә, ә аларның
шәһәрләрен яндырырга әмер биреп, гаскәрен җибәргән. 8 Ә аннан соң патша хезмәтчеләренә әйткән: «Мәҗлес әзер, ә чакырылган кунаклар лаеклы булмадылар. 9 Юл чатларына барыгыз,
кемне генә күрсәгез дә, мәҗлескә чакырыгыз». 10 Хезмәтчеләр,
урамнарга чыгып, очраган бар кешене — яхшысын да, яманын да
алып килгәннәр. Бөтен мәҗлес бүлмәсе кунаклар белән тулган.
11 Ләкин патша, кунакларны карарга чыккач, анда бәйрәм
киеменә киенмәгән бер кешене күреп алган. 12 Патша аңа әйткән: «Дус, син ничек монда бәйрәм киеме кимичә килдең?»
Тегесе эндәшмәгән. 13 Шуннан соң патша хезмәтчеләренә:
«Аның аяк-кулларын бәйләп, караңгылыкка чыгарып ташлагыз. Анда елау һәм теш шыкырдату булыр», — дигән. 14 Чөнки
чакырылганнар күп, ләкин сайланганнар аз.

### *Кайсарга салым түләү хакында сорау*

15 Шуннан соң фарисейләр, китеп, Гайсәне ничек сүздә эләктерергә икән дип киңәшләштеләр. 16 Алар үзләренең шәкертләрен Һируд тарафдарлары белән бергә Гайсә янына җибәрделәр.
— Остаз, — диделәр алар, — Синең дөрес Кеше булуыңны һәм Аллаһы юлына хакыйкать буенча өйрәтүеңне без беләбез. Кешеләрнең Синең хакта нәрсә уйлаганнары Сиңа мөһим түгел, чөнки Син кешене кешедән аермыйсың. 17 Шуңа күрә,
әйтче безгә, Син ничек уйлыйсың: кайсарга салым түләүне
канун рөхсәт итәме, әллә юкмы?
18 Әмма Гайсә аларның явыз ниятләрен белеп, җавап бирде:
— Сез нигә Мине сыныйсыз, монафикълар? 19 Салымны
нинди акча белән түлисез, аны миңа күрсәтегез!

Алар Аңа динар бирделәр.

20 — Монда кемнең сурәте һәм кемнең исеме? — дип сорады
алардан Гайсә.
21 — Кайсарныкы, — дип җавап бирделәр тегеләр.

— Димәк, кайсарныкын кайсарга, ә Аллаһыныкын Аллаһыга бирегез, — диде шуннан соң аларга Гайсә.

22 Бу сүзләрне ишетеп, алар хәйран калдылар. Һәм Аны калдырып киттеләр.

*Үледән терелү турында сорау*

[23] Шул ук көнне Гайсә янына саддукейлар килделәр. Алар
исә үлгән кешеләрнең терелүен инкяр итәләр иде. Алар Гайсә-
гә мондый сорау бирделәр:
[24] – Остаз, Муса канунда әйткән: «Әгәр берәү, бала тудыр-
мыйча, үлеп китсә, аның тол хатынына бертуганы өйләнсен
һәм үлгән бертуганының буынын дәвам иттерсен». [25] Менә
безнең арабызда җиде туган бар иде. Беренчесе өйләнгән; бала
тудырмыйча, хатынын туганына хатынлыкка калдырып, үлеп
киткән. [26] Икенчесе дә, өченчесе дә һәм барлык җидесе белән
дә шулай булган. [27] Ә ахырда хатын үлеп киткән. [28] Шулай бул-
гач, үлеләр терелгән вакытта, ул аларның кайсысының хатыны
булачак? Җидесе дә аның ире булган бит!
[29] – Сез ялгышасыз, чөнки Изге язманы да, Аллаһы кодрәтен
дә белмисез, – дип җавап бирде Гайсә. [30] – Үлгәннәр терелеп
торганда, алар өйләнмәячәкләр дә, кияүгә дә чыкмаячаклар.
Алар күктәге фәрештәләрдәй булачаклар. [31] Ә үлгәннәрнең те-
релеп тору мәсьәләсенә кагылсак, Аллаһының әйткәннәрен сез
укымадыгызмыни? [32] Ул әйткән: «Мин – Ибраһим Аллаһысы,
Исхак Аллаһысы һәм Ягъкуб Аллаһысы». Аллаһы – үлеләр
Аллаһысы түгел, бәлки тереләр Аллаһысы.
[33] Гайсәне тыңлаган халык Аның тәгълиматына таң калды.

*Иң мөһим әмер*

[34] Гайсәнең саддукейларны эндәшмәслек итүен ишеткәч,
фарисейләр бергә җыелдылар. [35] Аларның берсе, канунчы, Аны
сүзендә эләктерү нияте белән сорады:
[36] – Остаз, канунда кайсы әмер иң мөһиме?
[37] – «Раббы Аллаһыңны бөтен йөрәгең, бөтен җаның һәм бө-
тен акылың белән ярат», – диде Гайсә. – [38] Бу – беренче һәм
иң мөһим әмер. [39] Икенчесе дә шундый ук: «Якыныңны үзеңне
яраткан кебек ярат». [40] Бөтен Муса кануны һәм пәйгамбәрләр
шушы ике әмергә нигезләнгәннәр.

*Мәсих – Давыт Улымы?*

[41] Фарисейләр исә бергә җыелгач, Гайсә алардан сорады:
[42] – Сез Мәсих хакында нәрсә уйлыйсыз? Чыгышы буенча,
Ул – кем Улы?
– Давыт Улы, – дип җавап бирделәр алар.
[43] – Ә ни өчен Давыт, Изге Рух белән илһамланып, Мәсихне
Раббы дип атый? Ул бит:
[44] «Раббы Аллаһы минем Раббыма әйтте:

Мин дошманнарыңны салганчы
Синең аякларың астына
Утыр Минем уң ягымда», –
диде.
45 Шулай итеп, Давыт Аны Раббы дип атый икән, ничек инде
Ул аның Улы була ала?
46 Беркем дә Аңа җавап кайтара алмады. Шушы көннән
алып, бер кеше дә Гайсәдән нәрсә дә булса сорарга батырчы-
лык итмәде.

*Гайсә канунчылардан сакланырга куша*

23 1 Шуннан соң Гайсә халыкка һәм Үзенең шәкертләре-
нә мөрәҗәгать итте:
2 – Хокук буенча Муса урынын фарисейләр һәм канун-
чылар алдылар. 3 Шуңа күрә, аларның сезгә кушканнарын тың-
лагыз һәм үтәгез, әмма алар кебек эшләмәгез, чөнки алар үзләре
өйрәткәннәре буенча гамәл кылмыйлар. 4 Алар кешеләр җилкә-
сенә авыр йөкләр салалар, ә үзләре бармаклары белән дә кый-
мылдатырга теләмиләр. 5 Нәрсә генә эшләсәләр дә, аны кешеләр
күрсен дип эшлиләр. Алар маңгайларындагы һәм кулларындагы
догалар салган тартмачыкларын киңәйтәләр, күлмәк чукларын
озынайталар. 6 Мәҗлесләрдә алар иң түрдә, гыйбадәтханәләрдә
иң яхшы урыннарга утырырга яраталар, 7 җыелыш мәйданнарын-
да үзләрен ихтирам итеп сәламләүне һәм кешеләрнең аларны
«остаз» дип атауларын яраталар. 8 Ә сезне «остаз» дип атамасын-
нар, чөнки сезнең тик бер Остазыгыз бар һәм сез бер-берегезгә
туганнар. 9 Җирдә «ата» дип беркемне дә атамагыз – сезнең тик
бер Күктәге Атагыз бар. 10 Сезне «нәсыйхәтче» дип тә атамасын-
нар, чөнки сезнең бердәнбер Нәсыйхәтчегез – Мәсих. 11 Ә ара-
гыздагы иң бөеге сезнең өчен хезмәтче булсын. 12 Үзен-үзе күтә-
рүчене Аллаһы түбәнсетер, ә үзен түбәнсеткәнне Аллаһы күтәрер.
13 Кайгы сезгә, фарисейләр һәм канунчылар! Монафикълар!
Сез кешеләрдән Күкләр Патшалыгын бикләп куясыз, үзегез дә
кермисез, керергә теләүчеләрне дә кертмисез. [ 14 ]*
15 Кайгы сезгә, канунчылар һәм фарисейләр! Монафикълар!
Тик берәүне генә булса да иманыгызга китерер өчен, сез диңгез-
ләр һәм коры җирләр аша үтәсез. Ә инде берәрсен китерсәгез,
аны, үзегезгә караганда да, җәһәннәмгә икеләтә лаеклы итәсез.

---

* 23:14 Кайбер кульязмаларда 14 нче аять тә бар: «Кайгы сезгә, ка-
нунчылар һәм фарисейләр! Сез монафикълар! Тол хатыннарның
йортларын үзегезгә аласыз һәм, кешеләр күрсен дип, озак итеп до-
га кыласыз. Болар өчен тагын да катырак хөкемгә тартылачаксыз».

16 Кайгы сезгә, сукыр юлбашчылар! Сез: «Аллаһы Йорты белән
ант иткәннең анты бернигә дә тормый, ә Аллаһы Йортының
алтыны белән ант итсә, ул аны үтәргә тиеш», – дип өйрәтәсез.
17 Сукыр ахмаклар! Кайсысы мөһимрәк: алтынмы әллә алтын-
ны изге итүче Аллаһы Йортымы? 18 Һәм тагын әйтәсез: «Кор-
бан китерү урыны белән ант иткәннең анты бернигә дә тормый,
ә корбан китерү урынындагы бүләк белән ант итсә, ул аны
үтәргә тиеш». 19 Сукырлар! Кайсысы мөһимрәк: бүләкме, әллә
бүләкне изге итүче корбан китерү урынымы? 20 Шуңа күрә, кор-
бан китерү урыны белән ант итүче кеше аның белән дә, аның
өстендәге бөтен нәрсә белән дә ант иткән була. 21 Һәм Аллаһы
Йорты белән ант итүче кеше аның белән дә, аның эчендә
Яшәүче белән дә ант иткән була. 22 Күк белән ант иткән кеше
Аллаһы тәхете белән һәм анда Утыручы белән ант иткән була.

23 Кайгы сезгә, канунчылар һәм фарисейләр! Монафикълар!
Сез бөтнекнең, укропның, ак әниснең уннан бер өлешен бирә-
сез, ә канундагы иң мөһим нәрсәне: гаделлекне, шәфкатьлекне
һәм тугрылыкны читтә калдыргансыз. Менә боларны үтәргә һәм
канунның калган өлешләрен дә онытмаска кирәк иде. 24 Сукыр
юлбашчылар! Сез черкине сөзеп аласыз, ә дөяне йотасыз!

25 Кайгы сезгә, канунчылар һәм фарисейләр! Монафикълар!
Касәләрнең һәм савытларның тышкы ягын чистартасыз, ә эче
исә урлашу һәм комсызлык белән тулы. 26 Сукыр фарисей! Элек
касәләрнең эчен чистарт, шуннан соң аның тышы да чиста
булыр!

27 Кайгы сезгә, канунчылар һәм фарисейләр! Монафикълар!
Сез агартылган төрбәләр кебек: тыштан алар матур булып кү-
ренәләр, ә эчләре исә мәет сөякләре һәм төрле шакшылык бе-
лән тулы! 28 Сез дә шулай ук: тыштан кешеләргә тәкъва булып
күренәсез, ә эчегез тулы икейөзлелек һәм канунсызлык.

29 Кайгы сезгә, канунчылар һәм фарисейләр! Монафикълар!
Сез пәйгамбәрләр өчен төрбәләр төзисез һәм тәкъваларның
кабер һәйкәлләрен бизисез. 30 Сез: «Ата-бабаларыбыз чорында
яшәгән булсак, алар белән бергә пәйгамбәрләрнең канын түгү-
дә катнашмаган булыр идек», – дисез. 31 Шулай итеп, үзегезгә
каршы үзегез шаһитлек итәсез: сез – пәйгамбәрләрне үтерүче
ата-бабаларыгызның уллары. 32 Шулай ата-бабаларыгыз башла-
ганны тәмамлагыз. 33 Сез – еланнар һәм елан токымы! Сез хө-
кемнән һәм җәһәннәмнән ничек качарга уйлыйсыз? 34 Шуңа
күрә Мин сезгә пәйгамбәрләрне, акыл ияләрен һәм остазларны
җибәрәм. Берәүләрен сез үтерерсез, хачка кадакларсыз, башка-
ларын гыйбадәтханәләрдә камчылатып, шәһәрдән шәһәргә
куарсыз. 35 Шулай итеп, җирдә түгелгән бөтен тәкъваларның

каны сезнең башка төшәчәк: тәкъва Һабил канынннан алып,
корбан китерү урыны белән Изге йорт арасында сез үтергән
Берехия улы Зәкәрия канына кадәр. 36 Сезгә хак сүз әйтәм:
боларның һәммәсе шушы буын кешеләренә төшәчәк!
37 Иерусалим! Пәйгамбәрләрне үтерүче һәм үзеңә җибәрел-
гәннәрне ташлар атып үтерүче Иерусалим! Кош үзенең балала-
рын канаты астына җыйган кебек, Мин дә синең кешеләреңне
ничә тапкыр шулай бергә җыярга теләдем, әмма сез теләмәде-
гез! 38 Инде тыңлагыз: сезнең Изге йортыгыз ташландык хәлдә
калдырылыр. 39 Чөнки сезгә әйтәм: «Раббы исеме белән Килүче
мөбарәк!» – дип сез әйтәчәк вакыт җитми торып, Мине күр-
мәссез!

*Аллаһы Йортының җимерелүе*

**24** 1 Гайсә Аллаһы Йортыннан чыгып киткәндә, Аның
игътибарын Аллаһы Йортының биналарына юнәлтер
өчен, янына шәкертләре килделәр.
2 Ә Гайсә:
– Боларның һәммәсен да күрәсезме? – диде. – Шуны белегез:
монда таш өстендә таш калмаячак, барысы да җимереләчәк!

*Ахыр заман билгеләре*

3 Ул Үзе генә Зәйтүн тавында утырганда, янына шәкертләре
килде.
– Бу кайчан булыр икән, безгә әйтче. Без Синең килүеңне
һәм бу дөньяның бетәчәген нинди билге аша беләчәкбез? –
дип сорадылар алар.
4 Гайсә җавап бирде:
– Сак булыгыз, сезне алдамасыннар! 5 Чөнки күпләр, Минем
исемем белән килеп: «Мин – Мәсих», – дип әйтерләр һәм
күпләрне алдарлар. 6 Сез якындагы сугышлар тавышын һәм ерак-
тагы сугышлар хакында хәбәрләр ишетерсез – карагыз, курык-
магыз! Шулай булырга тиеш. Әмма бу әле ахыры түгел. 7 Халык
халыкка һәм патшалык патшалыкка каршы чыгар, урыны-уры-
ны белән ачлык һәм җир тетрәүләр булыр, 8 әмма боларның
барысы – тулгак тоту газапларының башлануы гына әле.
9 Шушы вакытта сезне газаплауга бирерләр һәм үлемгә тар-
тырлар, бөтен халыклар да Минем өчен сезне нәфрәт итәр.
10 Шул вакытта күпләр иманнан ваз кичәр, бер-беренә хыянәт
итәр һәм бер-берсен нәфрәт итәр. 11 Һәм күп ялган пәйгам-
бәрләр килеп, күпләрне алдар. 12 Явызлык көчәйгәнлектән,
күпләрнең мәхәббәте суыныр. 13 Әмма ахырга тикле чыдаган
кеше котылыр. 14 Барча халыклар да ишетсен өчен, Патшалык

хакындагы бу Яхшы хәбәрне бөтен җиһанда таратырлар. Менә
шуннан соң ахыры килер.
15 Шуңа күрә, сез Данил пәйгамбәр язган «ташландык хәлдә
калдыручы чирканыч нәрсәнең» изге урында торуын күргәч (бу
сүзләрне укыган кеше аңласын), 16 Яһүдия җирендә булганнар
тауларга качсыннар, 17 өй түбәсендә булганнар әйберләрен
алырга дип, өйгә төшеп тормасын, 18 кырда булганнар исә өс
киеме артыннан өенә кайтмасын. 19 Ул көннәрдә йөкле хатын-
нарга һәм бала имезүчеләргә кайгы! 20 Качуыгыз кышка һәм
шимбә көненә туры килмәсен иде дип, дога кылыгыз. 21 Чөнки,
ул вакытта, дөнья яратылганнан бирле бүгенге көнгә кадәр
булмаган һәм булмаячак зур афәт килер. 22 Әгәр ул көннәр
кыскартылмаса, һичкем исән кала алмас иде. Әмма сайланган-
нар хакына ул көннәр кыскартылачак.
23 Әгәр сезгә шул вакытта: «Кара, Мәсих менә монда!» яки
«Ул тегендә!» – дип әйтсәләр, ышанмагыз. 24 Чөнки ялган мә-
сихләр һәм ялган пәйгамбәрләр килерләр, әгәр килеп чыкса,
хәтта сайланганнарны да алдау өчен, искиткеч галәмәтләр һәм
могҗизалар күрсәтерләр. 25 Менә Мин сезгә барысы хакында
алдан әйттем.
26 Шулай итеп, әгәр: «Кара, Ул чүлдә», – дисәләр, анда барма-
гыз яки: «Менә Ул эчке бүлмәләрдә», – дисәләр, ышанмагыз.
27 Чөнки Адәм Улының килүе күкне көнчыгыштан көнбатышка
кадәр яшен ярып үткән кебек булыр. 28 Кайда мәет булса, үләк-
сә кошлары шунда җыелыр.
29 Һәм шунда ук, ул көннәрдәге афәттән соң,
«Кояш каралыр, ай яктыртмас,
Күкләрдән йолдызлар коелыр һәм
Күк кодрәтләре селкетелер».
30 Шуннан соң күктә Адәм Улының билгесе күренер һәм,
Аның күк болытлары өстендә кодрәт һәм балкып торган бөек
дан белән килүен күреп, җирнең бөтен халыклары кычкырып,
бик нык кайгырырлар. 31 Адәм Улы Үзенең фәрештәләрен көч-
ле быргы тавышы белән җибәрер. Һәм алар җирнең дүрт поч-
магыннан, дөньяның бер читеннән алып икенче читенә кадәр,
Аның сайланганнарын җыярлар.
32 Инҗир агачыннан гыйбрәт алыгыз. Аның ботаклары бөре-
ләнеп, яфрак ярган чакта, сез тиздән җәйнең җитәчәген беләсез.
сез. 33 Шулай ук, сез дә боларның һәммәсен күргәндә, шуны
белерсез: ул вакыт якын, инде ишек төбендә. 34 Сезгә хак сүз
әйтәм: бу буын алышынырга өлгермәс, болар һәммәсе дә гамәл-
гә ашыр. 35 Күк һәм җир юкка чыгачак, әмма Минем сүзләрем
һичкайчан юкка чыкмаячак.

*Көне һәм сәгате билгесез*

[36] Ул көннең һәм сәгатьнең кайчан булуы хакында һичкем
белми: күктәге фәрештәләр дә, Угыл да. Бу турыда бары тик
Ата гына белә. [37] Нух көннәрендә ничек булган булса, Адәм
Улы килгән вакытта да шулай булачак. [38] Чөнки ул көннәрдә
кешеләр, туфан килгәнче, ашаганнар, эчкәннәр, өйләнгәннәр
һәм кияүгә чыкканнар. Нух көймәгә кергән көнгә кадәр шулай
булган. [39] Туфан килеп, барын да агызып киткәнгә кадәр, алар
төшенмәгәннәр. Адәм Улы килгән вакытта да нәкъ шулай
булачак. [40] Ул вакытта кырда ике кеше булыр: берсе алыныр,
икенчесе калдырылыр. [41] Бер кул тегермәнендә тартучы ике
хатынның берсе алыныр, икенчесе калдырылыр.

[42] Шуңа күрә, уяу булыгыз! Раббыгыз кайсы көндә киләчәген
сез белмисез бит. [43] Шуны аңлагыз: йорт хуҗасы каракның төн-
лә белән кайсы сәгатьтә киләсен белсә, ул йокламаган булыр
иде һәм аңа үз йортына керергә ирек бирмәгән булыр иде.
[44] Шуңа күрә, сез дә әзер булыгыз: Адәм Улы сез көтмәгән сә-
гатьтә киләчәк.

[45] Шулай итеп, ышанычлы һәм акыллы хезмәтче нинди була
соң? Ризыкны үз вакытында өләшү өчен, аны хуҗасы барлык
хезмәтчеләре өстеннән куйган. [46] Хуҗасы кайткач, аның шулай
эшләвен күрсә, менә шул хезмәтче сәгадәтле. [47] Сезгә хак сүз
әйтәм: хуҗасы аны бөтен милке өстеннән башлык итеп куяр.
[48] Ләкин ул хезмәтче начар булса һәм: «Хуҗам тиз генә кайтмас
әле», – дип уйлап, [49] башка хезмәтчеләрне кыйный башласа, ә
үзе эчкечеләр белән ашап-эчә башласа, [50] хуҗасы ул көтмәгән
көндә һәм уйламаган сәгатьтә кайтып керер дә [51] аны җәзага
тартыр һәм монафикълар белән бер язмышка дучар итәр: анда
елау һәм теш шыкырдату булыр.

*Ун кыз хакында гыйбрәтле хикәя*

**25** [1] Күкләр Патшалыгы ул вакытта менә нәрсәгә охшар.
Күз алдыгызга китерегез: ун кыз, кулларына яктырт-
кычлар алып, кияү каршыларга чыккан. [2] Аларның
бишесе – ахмак, ә бишесе исә акыллы булган. [3] Ахмаклары
яктырткычларын алганнар, ә үзләре белән май алмаганнар.
[4] Акыллылары исә, яктырткычлар белән бергә чүлмәкләрдә май
да алганнар. [5] Кияү тоткарланганлыктан, кызлар йокымсырый
башлаган һәм йоклап киткәннәр.

[6] Төн уртасында: «Кияү килә, аны каршыларга чыгыгыз!» –
дип кычкырган тавыш ишетелгән. [7] Шул вакытта бөтен кызлар
уянып китеп, яктырткычлары яхшырак янсын өчен, аларны

рәтләгәннәр. [8] Ахмаклары акыллыларга: «Безнең яктырткыч-
ларыбыз сүнә, безгә май бирегезче», – дип әйткәннәр. [9] Ә
акыллылары: «Юк, безнең май бөтенебезгә дә җитмәс. Алай
булмасын өчен, сатучыларга барып, май сатып алыгыз», – ди-
гәннәр.
[10] Әмма алар сатып алырга дип киткән арада, кияү килеп
җиткән. Кияүне каршылау өчен барын да әзерләп куйган
кызлар аның белән бергә туй мәҗлесенә киткәннәр, һәм алар
артыннан ишек ябылган.
[11] Аннан соң калган кызлар да килгәннәр. «Әфәнде, безгә
ач!» – дип әйткәннәр алар. [12] Ләкин ул: «Хак сүз сезгә әйтәм:
мин сезне белмим», – дип җавап кайтарган.
[13] Шуңа күрә уяу булыгыз: сез бит көнен дә, сәгатен дә бел-
мисез, – диде Гайсә.

*Хезмәтчеләргә бирелгән акчалар турында гыйбрәтле хикәя*

[14] – Чөнки ул менә моңа охшаш булыр: бер кеше, чит илләр-
гә киткәндә, хезмәтчеләрен чакырып алып, аларга үзенең мил-
кен ышанып калдырган. [15] Һәркайсына сәләтенә карап: берсенә
ул биш талант, икенчесенә ике талант һәм өченчесенә бер та-
лант күләмендә акча калдырган. Ә үзе китеп барган. [16] Биш
талант алганы, шунда ук эшкә керешеп, тагын биш талант ка-
занган. [17] Ике талант алганы да, шулай ук, тагын ике талант
казанган. [18] Ә бер талант алганы исә, китеп, хуҗасының акча-
ларын яшереп җиргә күмеп куйган.
[19] Күп вакыт үткәннән соң, хезмәтчеләрнең хуҗалары әйлә-
неп кайткан һәм алардан хисаплашуларын таләп иткән. [20] Биш
талант алганы тагын бишне китергән. «Хуҗам, – дигән ул, –
син миңа биш талант бирдең. Кара, мин тагын бишне эшләп
таптым». [21] Хуҗасы аңа әйткән: «Яхшы эшләгәнсең, син – яхшы
һәм тугры хезмәтче. Кечкенә эштә син тугры булдың, мин сиңа
зурысын йөкләрмен. Килеп, минем шатлыгымны уртаклаш».
[22] Ике талант алганы да килгән һәм әйткән: «Хуҗам, син
миңа ике талант бирдең. Менә, мин тагын ике талант эшләп
таптым». [23] Хуҗасы аңа әйткән: «Яхшы эшләгәнсең, син – ях-
шы һәм тугры хезмәтче. Кечкенә эштә син тугры булдың,
мин сиңа зурысын йөкләрмен. Килеп, минем шатлыгымны
уртаклаш».
[24] Инде бер талант алганы килгән һәм әйткән: «Хуҗам, мин
синең каты бәгырьле кеше икәнеңне белдем: үзең чәчмәгән
җирдә урасың, утыртмаган җирдә җыясың. [25] Мин синнән ку-
рыктым һәм акчаңны җиргә күмдем. Менә алар, ал үзеңнең ак-
чаларыңны».

[26] Ә хуҗасы җавап кайтарган: «Яраксыз һәм ялкау хезмәтче!
Үзем чәчмәгән җирдә уруымны, утыртмаган җирдә җыюымны
белдең! [27] Шуңа күрә сиңа минем акчаларымны әйләнешкә
кертергә кирәк иде – мин әйләнеп кайткач, үземнекен табышы
белән алган булыр идем. [28] Шулай итеп, аннан бер талантны
алыгыз да ун таланты булганга бирегез. [29] Чөнки кемнең бар,
аңа тагын бирелер, һәм аның артыгы белән булыр, ә кемнең
юк, аның булган нәрсәсе дә тартып алыныр. [30] Ә бу булдыксыз
хезмәтчене тышкы караңгылыкка чыгарып ташлагыз: анда елау
һәм теш шыкырдату булыр».

*Булачак хөкем*

[31] Адәм Улы Үзенең даны белән һәм Үзенең барлык фәрештәләре белән килгәч, шөһрәтле тәхетенә утырачак. [32] Һәм Аның
каршына барча халыклар китереләчәк. Ул, көтүче сарыкларны
кәҗәләрдән аерган кебек, кешеләрне икегә аерачак. [33] Сарыкларны Үзенең уң ягына, ә кәҗәләрне исә сул ягына бастырыр.

[34] Шунда уң ягында торучыларга Патша: «Килегез, Минем
Атамнан фатиха алганнар! Дөнья яратылган көннән бирле сезнең өчен әзерләп куелган патшалыкны мирас итеп алыгыз.
[35] Чөнки ач идем, сез Мине ашаттыгыз; сусаган идем, сез Мине
эчерттегез; Мин – чит илдән килдем, сез Мине өегездә кабул
иттегез; [36] ялангач идем, сез Мине киендердегез; авырган идем,
сез Мине кайгырттыгыз; төрмәдә идем, сез Минем яныма килдегез», – дип әйтер.

[37] Шунда тәкъвалар: «Раббыбыз! Синең ач булуыңны күреп,
без кайчан ашаттык; сусаганыңны күреп, кайчан эчерттек?
[38] Синең чит илдән килгәнеңне күреп, кайчан сыеныр урын
бирдек; ялангач булуыңны күреп, кайчан киендердек? [39] Авырганыңны һәм төрмәдә утырганыңны күреп, кайчан Синең янына бардык?» – дип сорарлар. [40] Һәм Патша аларга җавабында:
«Сезгә хак сүз әйтәм: Минем кечкенә туганнарымның берсенә
нәрсә генә эшләгән булсагыз да, Миңа эшләгән буласыз», –
дип әйтер.

[41] Аннан соң Ул Үзенең сул ягында торучыларга әйтер: «Китегез Минем янымнан, ләгънәт төшкәннәр! Иблискә һәм аның
фәрештәләренә билгеләп куелган мәңгелек утка барыгыз!
[42] Чөнки Мин ач идем, сез ашатмадыгыз; сусаган идем, сез
эчертмәдегез; [43] чит илдән килгән идем, сез Мине өегездә кабул
итмәдегез; ялангач идем, сез Мине киендермәдегез; авыру чагымда һәм төрмәдә утырганда сез яныма килмәдегез».

[44] Шунда тегеләре дә: «Раббыбыз! Кайчан без Синең ач булуыңны, сусавыңны, чит илдән килгәнеңне, ялангач, авыру

булуыңны, төрмәдә утыруыңны күреп, Сиңа ярдәм итмәдек?» —
дип сорарлар. 45 Һәм шул чакта Ул: «Сезгә хак сүз әйтәм: бу
кечкенә туганнарымның берсенә эшләмәгән нәрсәне Миңа да
эшләмәдегез».
46 Һәм алар мәңгелек җәзага, ә тәкъвалар мәңгелек тормышка
барачак.

*Гайсәне үтерү нияте*

26 1 Гайсә бу сүзләрен тәмамлагач, шәкертләренә әйтте:
2 — Ике көннән Коткарылу бәйрәме буласын сез беләсез. Ул көннәрдә Адәм Улын хачка кадакларга тапшырачаклар.
3 Шул вакытта баш руханилар һәм Исраил халкының акса-
каллары Кәяфәс исемле иң баш руханиның сараенда җыелдылар
4 һәм Гайсәне хәйлә белән кулга алып үтерергә сүз куештылар.
5 — Ләкин, халык арасында фетнә килеп чыкмасын өчен,
бәйрәм вакытында булмасын, — диделәр алар.

*Гайсәне Бәйтәниядә майлау*

6 Гайсә Бәйтәниядә махаулы Шимунның өендә иде. 7 Ул анда
ашаган вакытта, Аның янына бик кыйммәтле хуш исле май са-
лынган алебастр* савыт тотып бер хатын килде һәм майны Гай-
сәнең башына койды. 8 Ә моны күргән шәкертләре ачуланып:
— Хуш исле майны нигә алай әрәм итәргә? — диделәр. — 9 Ул
майны зур бәягә сатып, акчасын фәкыйрьләргә өләшергә була
иде бит!
10 Әмма шәкертләренең канәгатьсезлеген белгән Гайсә:
— Ник сез бу хатынга сүз әйтәсез? Минем өчен ул яхшы эш
эшләде. 11 Фәкыйрьләр сезнең белән һәрвакыт булалар, ә Мин
исә сезнең белән һәрвакыт булмам. 12 Ул хатын Минем тәнемә
май коеп, Мине күмәргә әзерләде. 13 Сезгә хак сүз әйтәм: бу
Яхшы хәбәр дөньяның кайсы гына почмагында таратылмасын,
бу хатынны искә алып, аның нәрсә эшләгәне хакында сөйләя-
чәкләр, — диде.

*Яһүднең Гайсәгә хыянәт итүе*

14 Шуннан соң, унике шәкертнең берсе, Яһүд Искариот
исемлесе, баш руханилар янына барып:
15 — Әгәр сезгә Гайсәне тапшырсам, миңа нәрсә бирерсез? —
диде.

---

* 26:7 *Алебастр* — чүлмәкләр ясаганда кулланылган аксыл көрән төстәге йомшак таш.

Алар аңа утыз көмеш тәңкә санап бирделәр. [16] Шушы вакыт-
тан алып, ул Гайсәне аларның кулларына тапшыру өчен уңай
вакыт эзли башлады.

*Коткарылу бәйрәме ашы*

[17] Төче күмәч бәйрәменең беренче көнендә үк шәкертләре
Гайсә янына килеп:

– Коткарылу бәйрәме ашын Синең өчен кайда әзерләвебез-
не телисең? – дип сорадылар.

[18] Гайсә аларга шәһәрдәге бер кешегә барып, аңа: «Безнең
Остазыбыз: „Минем билгеләгән сәгатем якынлашты. Үземнең
шәкертләрем белән Коткарылу бәйрәме ашын синдә ашар-
мын“», – дип әйтергә кушты.

[19] Шәкертләре Гайсә кушканны үтәделәр һәм Коткарылу
бәйрәме ашын әзерләделәр.

[20] Кич җиткәч, Гайсә унике шәкерте белән бергә өстәл арты-
на утырды. [21] Алар ашап утырган чакта Гайсә:

– Мин сезгә хак сүз әйтәм: сезнең берегез Миңа хыянәт итә-
чәк, – диде.

[22] Алар, хафага төшеп, берсе артыннан берсе:

– Раббым, мин түгелдер бит? – дип сорый башладылар.

[23] Ә Ул аларга әйтте:

– Минем белән бергә бер савытта икмәк манучы кеше Миңа
хыянәт итәчәк. [24] Изге язмада язылганча, Адәм Улы китә. Әмма
Адәм Улына хыянәт итүче кешегә кайгы! Ул кеше бөтенләй дә
тумаган булса, Аның өчен яхшырак булыр иде!

[25] Шуннан соң, хыянәт итәчәк Яһүд Аннан:

– Остаз, мин түгелдер бит? – дип сорады.

– Моны син үзең әйттең! – дип җавап бирде Гайсә.

[26] Алар ашаган чакта Гайсә, икмәк алып, шөкрана итте һәм
аны, сындырып, шәкертләренә бирде.

– Алып ашагыз, бу – Минем тәнем, – диде Ул.

[27] Һәм, касәне алып, шөкрана итте һәм аны аларга бирде.

[28] – Шуңардан эчегез. Барыгыз да эчегез. Бу – гөнаһлар киче-
релсен өчен, күпләр өчен түгелә торган Минем каным. Ул – Ал-
лаһы килешүен раслый торган кан. [29] Мин сезгә әйтәм: бүгеннән
алып, Атам Патшалыгында сезнең белән бергә яңа шәраб эчә-
чәк көн җитми торып, Мин йөзем җимеше шәрабын эчмәячәк-
мен, – диде Гайсә.

[30] Мәдхия җырлаганнан соң алар Зәйтүн тавына киттеләр.

*Гайсә Петернең ваз кичәчәген алдан әйтә*

[31] Шунда Гайсә аларга:

– Изге язмада:

«Көтүчене һәлак итәрмен
һәм сарыклар таралышырлар», –
дип язылганча, сез барыгыз да бу төндә Минем аркада ышаны-
чыгызны югалтачаксыз. 32 Әмма, Мине терелтеп торгызылганнан
соң, Мин Гәлиләягә сездән алда барырмын, – дип әйтте.
33 Петер исә:
– Синең аркада барысы да ышанычларын югалтсалар да,
мин һичкайчан югалтмам! – дип каршы төште.
34 Ләкин Гайсә аңа әйтте:
– Сиңа хак сүз әйтәм: бу төнне, әтәч кычкырганчы, син
Миннән өч тапкыр ваз кичәчәксең.
35 – Синең белән үләргә туры килсә дә, мин Синнән һич-
кайчан ваз кичмәячәкмен! – диде Петер. Башка шәкертләре дә
шулай диделәр.

*Гайсә Гетсимәни бакчасында дога кыла*

36 Шуннан соң Гайсә шәкертләре белән Гетсимәни дип атал-
ган урынга китте. Килеп җиткәч, Ул шәкертләренә әйтте:
– Мин анда барып дога кылыйм. Сез монда утырып то-
рыгыз.
37 Ул Үзе белән Петерне һәм Зебедәйнең ике улын алды. Гай-
сәне авыр кичерешләр һәм җан сыкрануы били башлады. 38 Ул
аларга:
– Минем җаным чиктән тыш газап кичерә, монда көтегез
һәм Минем белән бергә уяу булыгыз! – диде.
39 Ул читкәрәк китте һәм җиргә йөзтүбән капланып дога
кылды:
– Атам! Әгәр мөмкин булса, Мине бу газаплар касәсеннән
арындырчы! Хәер, Мин теләгәнчә түгел, ә Син теләгәнчә
булсын.
40 Гайсә шәкертләре янына әйләнеп килгәндә, алар йок-
лый иде.
– Ничек сез Минем белән бергә бер сәгать тә йокламыйча
түзә алмадыгыз? – диде Ул Петергә. – 41 Уяу булыгыз, вәсвәсә-
гә дучар булмас өчен, дога кылыгыз. Рух көчле, ә тән хәлсез!
42 Гайсә тагын, икенче тапкыр читкә китеп, дога кылды:
– Атам, Миңа бу касәне эчмичә үткәрергә мөмкин булмаса,
Синең ихтыярың буенча булсын!
43 Әйләнеп килгәч, аларның тагын йоклауларын күрде:
аларның күзләрен йокы баскан иде. 44 Аларны калдырып, Гайсә
тагын читкәрәк китте һәм өченче тапкыр шул ук сүзләрне
әйтеп дога кылды. 45 Шуннан соң, шәкертләре янына әйләнеп
килеп, аларга:

– Сез һаман йоклыйсызмы, ял итәсезме? Менә Адәм Улы
гөнаһлылар кулына тапшырылачак вакыт җитте. 46 Торыгыз,
киттек! Карагыз, Миңа хыянәт итүче килә, – дип әйтте.

*Гайсәне кулга алу*

47 Гайсә әле әйтеп тә бетермәде, унике шәкертенең берсе –
Яһүд килеп чыкты. Аның белән баш руханилар һәм ак-
сакаллар җибәргән күпсанлы халык төркеме кылычлар һәм
чукмарлар күтәреп килделәр. 48 Хыянәтче: «Мин кемне үпсәм,
шул Гайсә булыр. Аны кулга алыгыз», – дип алар белән алдан
ук сүз куешкан иде.
49 Яһүд шунда ук Гайсә янына килде.
– Исәнме, Остаз! – диде ул һәм Гайсәне үбеп алды.
50 Әмма Гайсә аңа әйтте:
– Син нәрсә өчен килгән булсаң, шуны эшлә, дустым!
Шуннан соң Яһүд белән булган кешеләр алга чыктылар һәм
Гайсәне кулга алып, сак астына куйдылар. 51 Гайсә белән бул-
ганнарның берсе, кулын сузып, кылычын чыгарды һәм, иң баш
рухани хезмәтчесенә селтәнеп, аның колагын чабып өзде.
52 Шунда Гайсә аңа:
– Кылычыңны кынына тыгып куй! Кылыч алучы һәркем
кылычтан һәлак булыр! 53 Әллә Мин Атама мөрәҗәгать итә ал-
мыйм, дип уйлыйсыңмы? Ул шунда ук Миңа унике гаскәрдән*
дә артыграк фәрештәләрен җибәргән булыр иде! 54 Әмма Изге
язмаларда болар булырга тиеш дип язылганнар ничек гамәлгә
ашсын? – дип әйтте.
55 Шуннан соң Гайсә халык төркеменә әйтте:
– Юлбасар тотарга чыккан кебек, сез Мине тотарга кылыч-
лар һәм чукмарлар күтәреп килгәнсез! Мин һәркөнне Аллаһы
Йортында утырып өйрәттем, һәм сез Мине кулга алмадыгыз.
56 Әмма болар һәммәсе пәйгамбәрләрнең язганнары гамәлгә
ашсын өчен булды.
Шуннан соң барлык шәкертләре Аны калдырып, качып кит-
теләр.

*Гайсә Югары киңәшмә каршында*

57 Гайсәне кулга алган кешеләр Аны иң баш рухани Кәяфәс
янына китерделәр. Анда канунчылар һәм аксакаллар җыелган
иде инде. 58 Ә Петер исә, арттарак калып, иң баш руханиның
ишегалдына кадәр Гайсә артыннан барды һәм, эчкә кереп,

---

* 26:53 *Гаскәр* – грекча «легион» – римлыларның 6000 сугышчыдан
торган иң зур хәрби төркеме.

боларның һәммәсенең нәрсә белән бетүен күрергә теләп,
сакчылар белән бергә утырды. 59 Баш руханилар һәм бөтен
Югары киңәшмә, Гайсәне үтертү өчен, Аңа каршы ялган
шаһитлек табарга тырыштылар. 60 Әмма күп ялган шаһитләр
килеп ялганласалар да, бернинди гаеп таба алмадылар. Ниһа-
ять, шаһитлек күрсәтеп, ике кеше чыкты. 61 Алар:

– Бу кеше: «Мин Аллаһы Йортын җимереп, өч көн эчендә яңадан төзи алам», – дип әйтте, – диделәр.

62 Иң баш рухани торып, Гайсәгә:

– Боларның гаепләүләренә берничек тә җавап кайтармый-сыңмы? – дип әйтте.

63 Әмма Гайсә эндәшмәде. Шуннан соң иң баш рухани Аңа:

– Сине тере Аллаһы исеме белән әйтергә өндимен, әйт безгә: Син – Мәсих, Аллаһы Улымы? – диде.

64 Гайсә аңа:

– Моны син үзең әйттең. Хәтта Мин сезгә әйтәм: Адәм Улының Кодрәт Иясенең уң ягында утыруын һәм күк болыт-лары өстендә килүен күрерсез, – дип әйтте.

65 Шунда иң баш рухани, өс киемнәрен ертып:

– Көферләнү бу! Нигә безгә тагын шаһитләр кирәк? Хәзер
генә үзегез көфер сүзләрне ишеттегез! 66 Сез нинди карар чыга-
расыз? – диде.

– Ул гаепле һәм үләргә тиеш, – дип җавап бирделәр кал-ганнар.

67 Шуннан соң алар Гайсәнең битенә төкерделәр һәм кыйна-дылар; башкалар суктылар һәм:

68 – Әй, Мәсих, пәйгамбәрлек итеп әйт безгә: Сиңа кем сукты? – диделәр.

*Петернең Гайсәдән ваз кичүе*

69 Петер исә тышта, ишегалдында утыра иде. Аның янына хезмәтче кыз килде.

– Син дә бит гәлиләяле Гайсә белән булдың, – диде ул.

70 Әмма Петер, аларның барысы алдында ваз кичеп:

– Мин синең нәрсә хакында сөйләвеңне белмим, – диде.

71 Ул капка янына килгәч, аны икенче хезмәтче кыз күреп, анда торучыларга:

– Менә бу кеше дә насаралы Гайсә белән булган, – дип әйтте.

72 Петер тагын, ант итеп, ваз кичте:

– Мин ул Кешене белмим!

73 Бераздан анда торучы кешеләр аның янына килделәр.

– Син чыннан да аларның берсе бит. Чөнки ничек сөйләшү-еңнән беленеп тора, – диделәр алар.

74 Петер ялганламавын тагын ант итеп әйтте:
– Мин ул Кешене белмим! Әгәр сүзләрем дөрес булмаса,
мине каһәр суксын!
Нәкъ шул вакыт әтәч кычкырды. 75 Гайсәнең: «Әтәч кычкыр-
ганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичәчәксең», – дип әйткән
сүзләре Петернең исенә төште. Һәм ул, урам якка чыгып, бик
каты елады.

*Яһүднең үлеме*

27 1 Иртән иртүк, барлык баш руханилар һәм халык акса-
каллары, киңәшләшеп, Гайсәне ничек үтерү турында
сүз куештылар. 2 Аны бәйләп, идарәче Пилатка алып
барып тапшырдылар.
3 Гайсәгә хыянәт иткән Яһүд, Аның үлемгә тартылганын бел-
гәч, эшләгән эшенә үкенеп, баш руханиларга һәм аксакалларга
утыз көмеш тәңкәне кайтарып бирде һәм:
4 – Гөнаһ кылдым мин, гөнаһсызга хыянәт иттем, – диде.
– Безгә ни, ул – синең эшең, – дип җавап бирделәр тегеләр.
5 Һәм ул тәңкәләрне Аллаһы Йортында атып бәрде дә, китеп,
асылынды.
6 Баш руханилар тәңкәләрне алдылар һәм:
– Боларны сәдака сандыгына салу канунсыз: бу – канлы
тәңкәләр, – диделәр.
7 Алар, киңәшләшеп, бу тәңкәләргә, үлгән чит ил кешеләрен
күмәр өчен, чүлмәкче җирен сатып алырга, дигән карар чыгар-
дылар. 8 Шуңа күрә бу җир Кан җире дип атала башлады һәм
хәзерге көнгә кадәр шулай атала. 9 Шул вакытта Иремия пәй-
гамбәр аша әйтелгән сүзләр гамәлгә ашты: «Алар Исраил хал-
кы тарафыннан Аның өчен билгеләнгән бәяне – утыз көмеш
тәңкәне – алдылар, 10 һәм, Раббы миңа кушканча, ул акча бе-
лән чүлмәкче җирен сатып алдылар».

*Гайсә Пилат алдында*

11 Гайсә идарәче каршына бастырылды.
– Син яһүдләр Патшасымы? – дип сорады Аннан Пилат.
– Моны син үзең әйтәсең, – дип җавап бирде Гайсә.
12 Баш руханилар һәм аксакаллар Аны гаепли башлагач, Ул
аларга җавап бирмәде.
13 Шуннан соң Пилат:
– Үзеңә каршы шулкадәр күп гаепләүләрне ишетмисеңме
әллә Син? – дип сорады.
14 Әмма Гайсә җавап итеп бер сүз дә әйтмәде, моның белән
Ул идарәчене бик нык гаҗәпләндерде.

15 Гадәттәгечә, идарәче, бәйрәм уңае белән, халык сораган
бер тоткынны азат итә торган иде. 16 Ул вакытта даны киң та-
ралган Бараб исемле бер тоткын бар иде. 17 Шуңа күрә, халык
җыелгач, Пилат алардан сорады:

– Кемне сезгә азат итүемне телисез: Барабнымы, әллә Мәсих дип аталган Гайсәнеме?

18 Чөнки Пилат яһүд башлыкларының Гайсәне көнләшү ар-
касында тотып биргәннәрен белә иде. 19 Ул хөкем итү урынын-
да утырган чакта, аның хатыны аңа: «Бу тәкъва Кешегә каршы бернәрсә дә эшләмә! Бүген төшемдә Аның аркасында бик нык газапландым», – дип хәбәр иттерде.

20 Ә баш руханилар һәм аксакаллар исә Барабны азат итүен, ә Гайсәне җәзага тартуын таләп итәргә дип халыкны котырт-
тылар. 21 Идарәче халык төркеменнән:

– Сез кемне телисез? Сезгә икенең кайсысын азат итим? – дип сорады.

– Барабны, – дип җавап бирделәр алар.

22 – Ә Мәсих дип аталган Гайсә белән нәрсә эшлим? – дип сорады Пилат.

– Аны хачка кадакларга! – дип җавап бирде аларның барысы да.

23 – Ул нинди начарлык эшләгән соң? – дип сорады ул.

– Аны хачка кадакларга! – дип тагын да көчлерәк тавыш белән кычкырды җыелган халык.

24 Пилат бернәрсә дә эшли алмавын, хәтта чуалыш чыгу мөмкинлеген күреп, су китерергә кушты һәм халык алдында кулларын юды.

– Бу Кешенең үлемендә минем гаебем юк, моңа сез җаваплы! – диде ул.

25 – Аның каны безнең һәм безнең балаларыбыз өстендә булсын! – дип җавап бирде бөтен халык.

26 Шунда Пилат аларга Барабны азат итте. Ә Гайсәне исә камчылаткач хачка кадаклатырга тапшырды.

### *Гаскәриләрнең Гайсәне мәсхәрәләве*

27 Шуннан соң гаскәриләр Гайсәне идарәченең сараена*
алып киттеләр. Аларның бөтен гаскәре Гайсә тирәли җыелды.
28 Алар Гайсәнең киемнәрен салдырып, Аңа җете кызыл төс-
тәге япанча кидерделәр, 29 чәнечкеле ботаклардан таҗ үреп,
Аның башына кидерделәр, уң кулына таяк тоттырдылар һәм Аның каршында тез чүгеп: «Яшәсен яһүдләр Патшасы!» – дип

* 27:27 *Идарәченең сарае* – грек телендә «преториум».

мыскылладылар. 30 Аннары Гайсәгә төкерделәр, таяк алып,
аның белән башына сугып кыйнадылар. 31 Мәсхәрәләүләрен
тәмамлагач, алар Гайсәдән япанчаны салдырып, Аңа Үз киемнәрен кидерделәр һәм хачка кадакларга алып киттеләр.

*Гайсәне хачка кадаклау*

32 Алар, чыгып барганда, Күринидән булган Шимун исемле бер кешене очраттылар. Аны Гайсәнең хачын күтәреп барырга
мәҗбүр иттеләр. 33 Гөлгетә, ягъни «Баш сөяге» дип аталган
урынга килеп җиткәч, 34 алар Гайсәгә үт катыш шәраб бирделәр. Әмма Ул, татып карагач, эчәргә теләмәде. 35 Гайсәне хачка
кадаклагач, алар, жирәбә салышып, Аның киемнәрен бүлештеләр 36 һәм Аны анда утырып сакладылар. 37 Гайсәнең баш өс-
тенә Аның гаебен күрсәтүче «Бу – Гайсә, яһүдләр Патшасы»
дигән язма беркетеп куйдылар. 38 Шул вакытта Аның белән
бергә ике юлбасарны да кадакладылар: берсен Аның уң ягына,
берсен сул ягына. 39 Үтеп баручылар башларын чайкый-чайкый
Аны хурладылар.

40 – Син, Аллаһы Йортын җимерүче һәм аны өч көндә төзүче, Үзеңне коткар! Аллаһы Улы булсаң, төш хачтан! – диделәр алар.

41 Шулай ук, баш руханилар белән бергә, канунчылар һәм аксакаллар да Аны мыскылладылар:

42 – Башкаларны коткарды, ә Үзен коткара алмый! Ә Үзе Исраил Патшасы! Төшсен хачтан – шунда без Аңа ышанырбыз!
43 Ул Аллаһыга ышана һәм Үзен Аллаһы Улы дип атый. Әгәр Ул
Аллаһыга яраклы булса, ул чакта Аны Аллаһы коткарсын!

44 Аның белән бергә кадакланган юлбасарлар да Аны шундый ук сүзләр белән мәсхәрәләделәр.

*Гайсәнең үлеме*

45 Көн уртасында бөтен җир өстен караңгылык каплап алды,
һәм көндезге сәгать өчкә кадәр шулай булды. 46 Ә сәгать өчләр
тирәсендә Гайсә каты тавыш белән:

– Эли, Эли, лема сабахтани? – ягъни: «Әй, Аллаһым, әй, Аллаһым! Нигә Син Мине ташладың?» – дип кычкырды.

47 Анда торучыларның кайберләре, Аны ишетеп:

– Ильясны чакыра, – диделәр.

48 Шунда аларның берсе йөгереп килеп, губка кисәген шәраб
серкәсенә манчып, аны таякка элде һәм Гайсәгә эчәргә бирде.
49 Калган кешеләр аңа:

– Тукта! Әйдә карыйк: Ильяс Аны коткарырга килерме икән? – диделәр.

50 Ә Гайсә, тагын бер тапкыр көчле итеп кычкырып, җан
бирде.
51 Һәм менә, Аллаһы Йортындагы пәрдә өстән аска кадәр
урталай ертылды. Җир тетрәде, таш кыялар ярылдылар, 52 ка-
берләр ачылып китеп, үлгән изгеләр арасыннан күбесе терел-
теп торгызылдылар. 53 Бу изгеләр каберләрдән чыктылар, ә
Гайсә терелгәч, алар изге шәһәргә, Иерусалимга керделәр; һәм
күпләр аларны күрде.
54 Йөзбашы һәм аның белән Гайсәне саклаучы гаскәриләр,
җир тетрәүне һәм башка вакыйгаларны күреп, бик нык курык-
тылар.

– Ул чыннан да Аллаһы Улы булган икән, – диделәр.
55 Анда ерактан карап торучы күп хатыннар да бар иде (алар
Гайсәгә Гәлиләядән ияреп килгән һәм Аңа хезмәт иткән иделәр).
56 Алар арасында Магдалалы Мәрьям, Ягъкуб белән Йосыфның
анасы Мәрьям һәм Зебедәй улларының анасы бар иде.

*Гайсәне кабергә салу*

57 Кич белән, Ариматайдан булган Йосыф исемле бай кеше
килде; ул да Гайсәнең шәкерте иде. 58 Пилат янына килеп, ул
Гайсәнең гәүдәсен алырга рөхсәт сорады. Шунда Пилат Аның
гәүдәсен Йосыфка бирергә кушты. 59 Гәүдәне алып, Йосыф
аны чиста җитен тукымага төрде 60 һәм күптән түгел таш тауны
тишеп ясалган кабергә салды. Зур таш тәгәрәтеп алып килеп,
кабер авызын каплап куйды һәм китеп барды. 61 Ә Магдалалы
Мәрьям белән икенче Мәрьям исә, кабер каршында утыра
иделәр.

*Кабер сакчылары*

62 Икенче көнне – ул шимбә көн иде – Пилат янына баш ру-
ханилар һәм фарисейләр килделәр.
63 – Әфәнде, бу ялганчының исән чагында: «Мин өч көннән
соң терелтелеп торгызылачакмын», – дип әйткәнен хәтерли-
без, – диделәр алар. 64 – Өченче көнгә кадәр каберне сакларга
әмер бир, югыйсә Аның шәкертләре килеп, гәүдәсен урлап
китүләре мөмкин. Ә соңыннан халыкка: «Ул үледән терелтеп
торгызылды», – дип әйтерләр. Һәм бу соңгы ялган беренчесен-
нән дә яманрак булыр.
65 – Сакчыларны алыгыз һәм, барып, белгәнегезчә каберне
саклагыз, – диде Пилат.
66 Алар, китеп, куркынычтан саклар өчен, кабер авызын
каплаган ташка мөһер сугып, каберне сакларга гаскәриләрен
куйдылар.

*Гайсәнең үледән терелеп торуы*

**28** [1]Шимбә көн үтеп, атнаның беренче көненең таңында
Магдалалы Мәрьям белән икенче Мәрьям каберне ка-
рарга бардылар. [2]Кинәт бик каты җир тетрәде, чөнки
Раббы фәрештәсе күктән төште һәм, кабер янына килеп, та-
шын аударып ташлады һәм шул таш өстенә утырды. [3]Аның
килүе яшендәй иде, ә киемнәре кар кебек ак иде. [4]Сакчылар
куркуларыннан калтырадылар һәм үле кебек катып калдылар.
[5]Фәрештә исә хатыннарга әйтте:
– Курыкмагыз! Мин сезнең хачка кадакланган Гайсәне эзлә-
вегезне беләм. [6]Ул монда юк. Ул, әйткәненчә, үледән терелтеп
торгызылды. Килегез монда, Ул монда яткан иде, карагыз.
[7]Тизрәк барып, шәкертләренә: «Гайсә үледән терелтеп торгы-
зылды! Ул сездән алда Гәлиләягә бара. Сез Аны шунда күрер-
сез», – дип әйтегез. Мин сезгә моны әйтер өчен килдем.
[8]Хатыннар ашыгып кабер яныннан киттеләр; куркып һәм
бик нык шатланып, Аның шәкертләренә сөйләргә дип йөгер-
деләр. [9]Кинәт алар алдына Гайсә Үзе килеп чыкты.
– Иминлек сезгә! – диде Ул.
Алар Гайсә янына килеп, Аның аякларын кочаклап, Аның
алдында тезләнделәр. [10]Шунда:
– Курыкмагыз! – диде аларга Гайсә. – Барыгыз, Минем
шәкертләремә Гәлиләягә барырга кушыгыз. Алар Мине шунда
күрерләр.

*Кабер сакчыларын җавапка тарту*

[11]Хатыннар киткәч, кайбер сакчылар, шәһәргә барып, баш
руханиларга булган бөтен хәлне сөйләп бирделәр. [12]Баш рухани-
лар аксакаллар белән җыелышып киңәшләшкәч, гаскәриләргә
күп итеп акча бирделәр [13]һәм аларга:
– «Без йоклаган вакытта Аның шәкертләре, төнлә килеп,
гәүдәсен урлап киткәннәр», – дип әйтегез. [14]Бу хәбәр идарәче-
гә барып җитсә, борчылмагыз, сезнең гаебегез юк, дип без аны
күндерә алырбыз, – диделәр.
[15]Сакчылар акчаларны алып, ничек кушылган булса, шулай
эшләделәр. Бу хәбәр яһүдләр арасында хәзерге көнгә кадәр киң
таралды.

*Гайсә шәкертләре нәрсә эшләргә тиешләр*

[16]Ә Аның унбер шәкерте исә Гәлиләягә, Гайсә барырга куш-
кан тауга китте. [17]Аны күреп, алар Аның каршында тез чүктеләр,
әмма кайберләре шикләнделәр. [18]Гайсә алар янына килеп:

– Күктә дә, җирдә дә бөтен хакимлек Миңа бирелде. 19 Шуңа
күрә, барыгыз һәм бөтен халыклар арасыннан Миңа шәкерт-
ләр булдырыгыз. Аларны Ата, Угыл һәм Изге Рух исеме белән
суга чумдырыгыз 20 һәм Мин сезгә кушканнарның барын да
үтәргә өйрәтегез. Һәм белегез: Мин, дөнья беткәнгә тикле,
һәрвакыт сезнең белән булам, – дип әйтте.

# МАРК БӘЯН ИТКӘН ЯХШЫ ХӘБӘР

*Чумдыручы Яхъяның вәгазьләве*

1 [1] Аллаһы Улы Гайсә Мәсих хакындагы Яхшы хәбәрнең
башы. [2] Ишагыйя пәйгамбәр язганча:
«Мин Синең алдыңнан
хәбәрчемне җибәрәм,
ул Сиңа юл әзерләр.
[3] Чүлдә кычкыручының тавышы:
„Раббыга юл әзерләгез,
Аңа сукмакларны турайтыгыз“».
[4] Шулай итеп, Чумдыручы Яхъя чүлгә килде. Ул:
– Тәүбә итеп, суга чумдырылыгыз*, – дип өндәде. – Һәм
Аллаһы сезнең гөнаһларыгызны кичерер.
[5] Бөтен Яһүдия иле һәм Иерусалим халкы аның янына кил-
деләр. Килүчеләр үзләренең гөнаһларын икърар иттеләр, һәм
Яхъя аларны Үрдүн елгасында чумдырды.
[6] Яхъя исә дөя йоныннан булган киемен күн каеш белән буып
йөрде, ашаган ризыгы саранча һәм кыр балы иде. [7] Ул вәгазен-
дә әйтте:
– Артымнан миннән кодрәтлерәк Берәү килә. Мин, иелеп,
Аның аяк киеменең каешын чишәргә дә лаеклы түгелмен.
[8] Мин сезне суга чумдырам, ә Ул сезне Изге Рухка чумдырыр.

*Гайсәнең суга чумдырылуы һәм сыналуы*

[9] Шул көннәрдә Гәлиләя өлкәсендәге Насара шәһәреннән
Гайсә килде һәм Яхъя Аны Үрдүн елгасында чумдырды. [10] Гайсә,
судан чыгу белән, күкләрнең ачылуын һәм Рухның күгәрчен
рәвешендә Үзенә иңүен күрде. [11] Күктән: «Син – Минем сөекле
Улым. Син Минем куанычым!» – дигән тавыш килде.
[12] Шул вакытта ук Рух Гайсәне чүлгә алып китте. [13] Ул, чүлдә
кырык көн булып, шайтан тарафыннан сыналды һәм кыргый
хайваннар арасында яшәде. Фәрештәләр Аңа хезмәт күрсәттеләр.

---

* 1:4 *Суга чумдырылу* – тәүбә итүне һәм үзеңне Аллаһы Тәгаләгә багышлауны күрсәтә торган йола.

*Гайсәнең беренче шәкертләре*

[14] Яхъя төрмәгә утыртылганнан соң, Гайсә, Аллаһыдан килгән Яхшы хәбәрне сөйләп, Гәлиләягә килде. [15] Ул әйтте:

– Вакыт җитте! Аллаһы Патшалыгы якынлашты! Тәүбә итегез һәм Яхшы хәбәргә иман итегез!

[16-17] Ул, Гәлиләя диңгезе* янынnan үтеп барганда, диңгездә балык тотучы (ә алар балыкчы иделәр) Шимунны һәм аның энесе Әндрине күреп, әйтте:

– Миңа иярегез! Мин сезне кешеләр тотучы** итәрмен.

[18] Алар шунда ук ятьмәләрен калдырып, Аңа иярделәр.

[19] Гайсә, бераз баргач, Зебедәй улы Ягъкубны һәм аның энесе Яхъяны күрде. Алар көймәдә ятьмәләрен төзәтәләр иде, [20] һәм Ул шунда ук аларны чакырды. Алар исә, аталары Зебедәйне ялчылары белән бергә көймәдә калдырып, Аның артыннан киттеләр.

*Гайсә явыз рухны куып чыгара*

[21] Кәпәрнаумга килгәч, шимбә көн туу белән, Гайсә һәм Аның шәкертләре гыйбадәтханәгә бардылар һәм Гайсә өйрәтә башлады. [22] Аның өйрәтүенә барысы да хәйран калдылар, чөнки Ул канунчылар кебек түгел, бәлки хакимлеге булган кеше кебек өйрәтте.

[23] Шушы вакытта гыйбадәтханәгә эчендә шакшы рух булган кеше килеп керде һәм кычкырды:

[24] – Насаралы Гайсә! Сиңа бездән нәрсә кирәк? Син безне һәлак итәргә килдеңме? Мин Синең Кем икәнеңне беләм! Син – Аллаһының Изгесе.

[25] Әмма Гайсә шакшы рухка боерды:

– Эндәшмә, чык аннан!

[26] Шакшы рух, кешене калтыратып, көчле тавыш белән кычкырып, чыкты. [27] Барысы да таң калдылар һәм бер-береннән сораша башладылар:

– Бу нәрсәне аңлата икән? Бу – ниндидер яңа куәтле тәгълимат? Бу Кеше шакшы рухларга боера һәм алар Аңа буйсыналар!

[28] Аның хакындагы хәбәр бик тиз арада бөтен Гәлиләя тирәсендәге җирләргә таралды.

[29] Ягъкуб һәм Яхъя белән бергә гыйбадәтханәдән чыккач ук, алар Шимун белән Әндри йортына юнәлделәр. [30] Шимунның каенанасы кызышып, авырып ята иде, бу хакта Гайсәгә керү

---

* 1:16-17 *Гәлиләя диңгезе* – аны «Геннисарет күле» дип тә атыйлар.

** 1:16-17 Гайсә бу урында кешеләрне Аллаһы юлына алып килүне балык тоту белән чагыштыра.

белән әйттеләр. 31 Гайсә аның янына килде һәм, кулыннан то-
тып, аңа торырга булышты. Аның кызышуы бетте һәм ул табын
әзерли башлады.
32 Ә инде кич җитеп, кояш баегач, Гайсәгә барлык авыру-
ларны, җенле кешеләрне китерделәр. 33 Бөтен шәһәр халкы
Шимун һәм Әндри өенең ишек төбенә җыелды. 34 Гайсә күп
кешеләрне төрле авырулардан савыктырды һәм күп җеннәрне
куып чыгарды. Әмма җеннәр Аның Кем икәнен белгәнгә күрә,
Гайсә аларга сөйләргә рөхсәт итмәде.
35 Иртәгесен, яктырганчы ук, Ул торып аулак урынга китте,
анда дога кылды. 36 Иптәшләре белән Шимун Аны эзләп кит-
теләр һәм, 37 Гайсәне табып:
– Барысы да Сине эзлиләр, – диделәр.
38 – Китик башка урыннарга, күрше авыл-шәһәрләргә, Миңа
анда да Яхшы хәбәрне сөйләргә кирәк. Мин шуның өчен кил-
дем бит, – диде Гайсә.
39 Гайсә шулай җеннәрне куып, гыйбадәтханәләрдә Яхшы
хәбәрне сөйләп, бөтен Гәлиләя җирендә йөрде.

*Гайсә махаулыны савыктыра*

40 Бер көнне, махау чире* белән авыручы бер кеше килде
һәм, Гайсә каршында тезләнеп, үтенеп сорады:
– Әгәр теләсәң, мине тазарта алыр идең!
41 Гайсә, кызганып, кулын сузып, аңа кагылды һәм әйтте:
– Әйе, телим. Тазарын!
42 Аның махауы шунда ук бетте, һәм ул тазарынды. 43-44 Гайсә
каты кисәтеп:
– Кара аны, берәүгә дә берни сөйләмә. Ләкин руханига бар.
Ул үзе сине карасын. Барысына да терелүең билгесе итеп, син
Муса канунында таләп ителгән корбан бүләген китер, – дип,
аны шунда ук җибәрде.
45 Әмма ул, китү белән, булган хәл хакында бөтен җирдә сөй-
ләп йөрде. Шунлыктан Гайсә ачыктан-ачык йөри алмады. Ул
шәһәрләрдән читтә, аулак урыннарда булды, әмма анда да
Аның янына бөтен яктан килделәр.

*Гайсә паралич суккан кешене савыктыра*

2 1 Гайсә берничә көннән Кәпәрнаумга әйләнеп кайткач,
Аның өйдә булуы хакында хәбәр таралды. 2 Халык шулка-
дәр күп җыелды ки, хәтта тышта, ишек алдында да урын
җитмәде. Гайсә аларга Яхшы хәбәр сүзен сөйләде. 3 Аның янына

---

* 1:40 *Махау чире* – йогышлы тире авыруы.

дүрт кеше паралич суккан кешене күтәреп алып килде. [4] Әмма
халык арасыннан үтә алмаганлыктан, алар Гайсә булган урында
түбәне тишеп, паралич суккан кешене ятагы белән бергә шул
тишек аша төшерделәр. [5] Гайсә, аларның ышануларын күреп,
паралич суккан кешегә әйтте:

– Бала, синең гөнаһларың кичерелде!

[6] Анда берничә канунчы утыра иде, алар үзара уйлаштылар:

[7] – Ул нәрсә сөйли? Бу бит көфер сүз! Гөнаһларны Аллаһыдан башка кем кичерә ала?

[8] Гайсә, шунда ук рухы белән аларның уйларын белеп, аларга
әйтте:

– Ни өчен сезнең күңелегездә шундый уйлар? [9] Паралич
суккан кешегә ничек дип әйтергә җиңелрәк: «Синең гөнаһларың кичерелде», – дипме, әллә: «Тор, ятагыңны алып кайтып
кит», – дипме? [10-11] Хәзер сез Адәм Улының җирдә гөнаһларны
кичерергә хакимлеге барлыгын белерсез. Мин сиңа әйтәм, –
Гайсә паралич суккан кешегә мөрәҗәгать итте:

– Тор, ятагыңны ал да өеңә кайт.

[12] Ул торды һәм шунда ук, ятагын алып, барысының күз
алдында чыгып китте. Моңа бөтенесе дә таң калдылар һәм
Аллаһыны данлап әйттеләр:

– Безнең мондый хәлне әле күргәнебез булмады!

*Гайсә Левине чакыра*

[13] Гайсә тагын Гәлиләя диңгезе ярына чыкты. Бөтен халык
Аңа килде һәм Ул аларны өйрәтте. [14] Үтеп барышлый, салым
җыя торган урында утыручы Һалфай улы Левине күреп, аңа
әйтте:

– Минем артымнан бар!

Ул, торып, Аның артыннан китте.

[15] Менә Гайсә Леви өенә ашка килде. Өстәл артында Гайсә
һәм Аның шәкертләре белән бергә күп санлы салым җыючылар һәм башка гөнаһлылар утырды. Шундыйлар Гайсә белән
йөрүчеләр арасында күп иде. [16] Фарисейләр* арасындагы канунчылар Аның гөнаһлылар һәм салым җыючылар белән бергә
ашаганын күреп, Аның шәкертләренә әйттеләр:

– Ничек Ул салым җыючылар һәм гөнаһлылар белән бергә
ашап-эчә?

[17] Гайсә, моны ишетеп, аларга әйтте:

– Табиб сәламәт кешеләргә түгел, ә авыруларга кирәк. Мин
тәкъва кешеләрне түгел, ә гөнаһлыларны чакырырга дип килдем.

---

* 2:16 *Фарисейләр* – борынгы яһүдләр арасындагы дини төркем.

*Ураза тоту һәм шимбә көн хакында сораулар*

[18] Көннәрдән бер көнне Чумдыручы Яхъяның шәкертләре
һәм фарисейләр ураза тотканда, кешеләр Гайсә янына килеп
сорадылар:
– Ни өчен Яхъяның һәм фарисейләрнең шәкертләре ураза
тоталар, ә Синең шәкертләрең ураза тотмыйлар?
[19] Гайсә аларга әйтте:
– Кияү егете туйдагы кунаклар белән булган вакытта аның
дуслары ураза тота алырлармы? Кияү алар белән бергә булган-
да, алар, әлбәттә, ураза тотмыйлар! [20] Әмма килер бер көн: алар
яныннан кияү алыныр һәм шул чакта алар ураза тотарлар.
[21] Иске киемгә яңа тукымадан ямаулык салмыйлар, югыйсә,
ямаулык иске тукыманы басып төшәр һәм тишек тагын да зу-
раер. [22] Шулай ук яңа шәрабны иске турсыкка салмыйлар,
югыйсә шәраб турсыкны тишеп чыгар, һәм шәраб та, турсык
та әрәм булырлар. Яңа шәрабны яңа турсыкка салалар.
[23] Көннәрдән бер көнне, шимбә көнне, Гайсә иген кырлары
аркылы үтеп барганда, шәкертләре башаклар өзә башладылар.
[24] Фарисейләр Аңа әйттеләр:
– Кара, алар ни эшлиләр? Шимбә көнне болай эшләргә
ярамый!
[25] Гайсә аларга әйтте:
– Давыт мохтаҗлыкта калган чакта, ул үзе һәм аның белән
булган кешеләр ачыккач, нәрсә эшләгәнен сез һичкайчан укы-
мадыгызмы әллә? [26] Иң баш рухани булып Эбьятар торганда, ул
Изге йортка кергән һәм Аллаһыга багышланган икмәкләрне
үзе ашаган һәм иптәшләренә дә биргән, ә ул исә руханилардан
башка һичкемгә дә ашарга рөхсәт ителмәгән.
[27] Гайсә әйтте:
– Кеше шимбә көн өчен түгел, ә шимбә көн кеше өчен яра-
тылган. [28] Шуңа күрә Адәм Улы шимбә көненең дә Хуҗасы.

*Гайсә кулы корышкан кешене савыктыра*

**3** [1] Гайсә тагын гыйбадәтханәгә килде. Анда кулы корышкан
кеше бар иде. [2] Әгәр Гайсә шимбә көнне савыктырса, Аны
гаепләргә сәбәп булыр дип, берничә фарисей Аның ар-
тыннан күзәттеләр. [3] Кулы корышкан кешегә Гайсә әйтте:
– Уртага чыгып бас.
[4] Ә тегеләрдән сорады:
– Шимбә көнне нәрсә эшләргә рөхсәт ителгән: яхшылык-
мы, яисә яманлыкмы? Тормышны саклап калыргамы, яисә һә-
лак итәргәме?

Алар эндәшмәделәр. [5] Гайсә аларның каты күңелле булула-
рына ачынып, аларга ачу белән карап алды һәм кешегә әйтте:
– Кулыңны суз!
Ул кулын сузды, аның кулы савыкты. [6] Фарисейләр киттеләр
һәм шунда ук, Һируд патша тарафдарлары белән бергә, Гайсә-
не һәлак итү хакында киңәш кордылар.
[7-8] Гайсә Үзенең шәкертләре белән Гәлиләя диңгезенә таба
юнәлде. Аңа Гәлиләядән һәм Яһүдиядән күп санлы халык иярде.
Аның эшләгән эшләре хакында ишетеп, Иерусалимнан да, Иду-
маядән дә, Үрдүн аръягыннан да, Тур һәм Сидун тирәләреннән
дә күп халык килде. [9] Халык Үзен кысмасын дип, Гайсә шәкерт-
ләренә көймәне әзер тотарга кушты. [10] Күп кешеләрне савык-
тырган булганга, чирдән интеккән кешеләр, Аңа кагылыр өчен,
Аның янына этешеп-төртешеп килә иде. [11] Эчләрендә шакшы
рухлар булганнар да, Аны күрү белән, каршына йөзтүбән егылып:
– Син – Аллаһы Улы! – дип кычкырдылар.
[12] Әмма Гайсә аларны Үзенең кем булуы хакында сөйләүлә-
рен каты итеп тыйды.

*Унике шәкертне сайлау*

[13] Гайсә, тауга менеп, Үзе сайлаганнарны янына чакыртып
китертте. [14-15] Болар – Үзе белән бергә булыр өчен, һәм аларны
Яхшы хәбәр сөйләргә, җеннәрне Аның вәкаләте белән куып
чыгарырга дип кешеләр янына җибәрер өчен сайлаган унике
кеше иде.
[16] Менә ул унике шәкерт: Гайсә Петер дип атаган Шимун, [17] Зе-
бедәй улы Ягъкуб һәм аның энесе Яхъя, – Гайсә аларны «Боа-
ниргес», ягъни «Күк күкрәү уллары» дип атады, [18] Әндри, Филип,
Бартулумай, Маттай, Томас, Һалфай улы Ягъкуб, Таддай, Көрә-
шүче Шимун* [19] һәм Гайсәгә хыянәт итәчәк Яһүд Искариот.

*Гайсә һәм Белзебул*

[20] Гайсә кире өйгә кайтты. Анда тагын шундый күп төркем
җыелды ки, хәтта алар ашап алырга да өлгермәделәр. [21] Туган-
нары бу хакта ишеткәч, акылдан язган икән Бу, дип уйлап,
Аны көчләп алып китәргә килделәр.
[22] Иерусалимнан килгән канунчылар әйттеләр:
– Аның эчендә Белзебул** бар! Ул җеннәрне җеннәр башлы-
гы көче белән куып чыгара.

---

* 3:18 *Көрәшүче Шимун* – Рим хакимлеген көч белән бәреп төшерүне яклап көрәшүче яһүдләр төркеменең әгъзасы.

** 3:22 *Белзебул* – шайтан өчен кулланылган исем.

23 Гайсә аларны Үзе янына чакырып алып, аларга гыйбрәтле
сүзләр сөйләде:
– Ничек итеп шайтан шайтанны куып чыгарсын инде? 24 Әгәр
патшалык эчендә бүленеш булса, бу патшалык тора алмас.
25 Әгәр гаилә эчендә ызгыш-талаш булса, бу гаилә таркалмый
калмас. 26 Ә инде шайтан үзенә-үзе каршы чыгып, бүлгәләнсә,
шайтан патшалыгы калмас, бу аның ахыры булыр. 27 Берәү дә
көчленең өенә кереп, аны бәйләмичә, малын талап чыга алмас.
Бәлки аны бәйләгәч кенә өен талап чыгар. 28 Сезгә хак сүз әй-
түм: кешеләрнең бөтен гөнаһлары һәм, ничек кенә көфер сүз
әйтмәсеннәр, бөтен көферләнүләре кичерелер. 29 Әмма Изге
Рухка карата көфер сүз әйтүче мәңге кичерелмәс, ул мәңгелек
гөнаһта гаепле.
30 Кайберәүләр, Аның эчендә шакшы рух бар, дип әйткәнгә
күрә, Гайсә шулай сөйләде.

*Гайсәнең анасы һәм энеләре*

31 Шул вакытта Гайсәнең анасы белән энеләре килделәр һәм,
тышта торган килеш, Аны чакырттылар. 32 Янында утырган ха-
лык арасыннан берәүләр Аңа әйттеләр:
– Сине тышта әниең һәм энеләрең көтә.
33 – Кем Минем анам һәм туганнарым? – диде Гайсә, аларга
җавап итеп.
34 Һәм Үзе тирәли утырганнарга карап әйтте:
– Менә Минем анам һәм туганнарым. 35 Аллаһы ихтыярын
үтәүчеләр Миңа ир туган да, кыз туган да, ана да булалар.

*Чәчүче хакында гыйбрәтле хикәя*

4 1 Гайсә Гәлиләя диңгезе буенда кешеләрне тагын өйрәтә
башлады. Аның тирәсенә төркем җыелганга күрә, Ул
көймәгә утырды. Көймә исә диңгездә иде, ә халык яр бу-
енда калды. 2 Гайсә аларга күп кинаяле хикәяләр сөйләде һәм
Үзенең өйрәтүендә әйтте:
3 – Тыңлагыз: менә чәчүче чәчәргә чыккан. 4 Ул чәчкәндә,
орлыкларының бер өлеше юл буена төшкән; кошлар очып ки-
леп, аларны чүпләп бетергәннәр. 5 Башка бер өлеше туфрагы аз
булган ташлы урынга төшкән; орлык тирән ятмаганга күрә, тиз
шытып чыккан. 6 Ә инде кояш чыгып кыздыргач, тамыры бул-
маганлыктан, үсентеләр шиңеп төшкән. 7 Орлыкларның башка-
лары күгәнлеккә төшкән; күгән куаклары үсеп, аларны басып
киткәнгә, алар башак бирмәгәннәр. 8 Ә инде башка орлыклар
исә ундырышлы җиргә төшкән; алар үсеп күтәрелгән һәм
утызлата, алтмышлата, йөзләтә уңыш биргән.

9 Гайсә әйтте:
– Ишетергә колаклары булганнар – ишетсеннәр!
10 Үзләре генә калгач, юлдашлары һәм шәкертләре Гайсәдән
кинаяле хикәяләр хакында сорадылар.
11 – Аллаһы Патшалыгының серләре сезгә ачылган, – диде
Гайсә аларга, – ә башкаларга, тышта торганнарга, кинаяле
хикәяләр белән әйтелә.
12 «Аллаһыга борылып кичерелмәсеннәр өчен,
Карап-карап та, күрмәсеннәр,
Тыңлап-тыңлап та, аңламасыннар».
13 Сез бу кинаяле хикәянең мәгънәсен аңламадыгызмы? –
дип сорады алардан Гайсә. – Сез ничек башка кинаяләрне
аңларсыз соң? 14 Чәчүче сүз чәчә. 15 Юл буена төшкән орлык-
лар – чәчкән вакытта ишетүче кешеләр ул, әмма шайтан, ки-
леп, күңелләренә салынган сүзне шунда ук алып китә. 16 Ташлы
урынга чәчелгәне исә – сүзне ишетү белән, шатланып кабул
итүчеләр. 17 Әмма аларның тамырлары булмаганлыктан, алар
сүзне вакытлыча гына тоталар. Сүз аркасында кайгы яки эзәр-
лекләүләр булса, алар бик тиз чигенәләр. 18 Ә башкалары, кү-
гәнлеккә чәчелгән орлык кебек, сүзне ишетәләр. 19 Әмма
тормыш мәшәкатьләре, байлыкка кызыгу һәм башка теләкләр
аларга үтеп кереп, ишетелгән сүзне басып китәләр һәм сүз
уңыш бирми. 20 Ә инде уңдырышлы җиргә чәчелгәннәре исә –
сүзне ишетеп, аны кабул итүчеләр: алар утызлата, алтмышлата,
йөзләтә уңыш бирәләр.

### *Янып торган шәмне шәмдәлгә куялар*

21 Гайсә аларга әйтте:
– Шәмне чүлмәк яки сәке астына куяр өчен алып керәләр-
мени? Юк, аны шәмдәлгә утыртып куялар. 22 Һәр яшерен нәрсә
фаш ителү өчен генә яшерелгән, һәр сер ачылу өчен генә сер
ителгән. 23 Колаклары булганнар – ишетсеннәр!
24 Гайсә аларга әйтте:
– Ишеткән нәрсәләргә дикъкать итегез. Сез нинди үлчәм
белән үлчәсәгез, сезгә дә шундый үлчәм белән үлчәп бирелер
һәм тагын өстәрләр. 25 Кемнең бар, шуңа бирелер, ә кемнең юк,
аның булган нәрсәсе дә алыныр.

### *Орлык хакында гыйбрәтле сүзләр*

26 Гайсә әйтте:
– Аллаһы Патшалыгы нинди ул? Ул болай булыр: кеше җиргә
орлык чәчә. 27 Төнлә йоклап, көндезен тора, ә орлык, шытып
чыгып, өскә үрмәли. Ул кеше моның ничек булуын белми дә.

[28] Җир үзеннән-үзе уңыш бирә: башта сабак үстерә, аннары башагы, аннары башак тулы орлык була. [29] Ә инде ашлык өлгерү белән кеше кулына урак ала, чөнки ашлык уру вакыты җиткән була.

### *Горчица орлыгы хакында гыйбрәтле хикәя*

[30] Гайсә әйтте:
– Аллаһы Патшалыгын безгә нәрсә белән чагыштырырга һәм ничек итеп тасвирларга икән? [31] Ул горчица орлыгы кебек. Җиргә чәчкән вакытта ул җирдәге бөтен орлыклардан да кечкенәрәк. [32] Ә инде чәчелгәч, ул, шытып чыгып, бөтен үсемлекләрдән дә зуррак булып үсәр, аңардан шундый зур ботаклар үсеп чыгар, хәтта аның күләгәсендә кошлар оя кора алырлар.
[33] Халык аңлый алганга кадәр, Гайсә шундый гыйбрәтле сүзләр сөйләде. [34] Башкача Ул берни дә сөйләмәде, ә инде шәкертләре белән үзләре генә калган чакта, аларга барын да аңлатып сөйләде.

### *Гайсә давылны тынычландыра*

[35] Шул көнне кичен Гайсә шәкертләренә әйтте:
– Әйдәгез әле, күлнең аръягына чыгыйк.
[36] Халыкны тараткач, алар Гайсә булган көймәгә утырып, Аның белән юлга кузгалдылар. Анда башка көймәләр дә бар иде. [37] Көчле давыл күтәрелде һәм, дулкыннар көймәгә бәрелүдән, аның эченә су тула башлады. [38] Гайсә исә көймәнең арткы өлешендә башын мендәргә салып йоклый иде. Шәкертләре Аны уятып:
– Остаз, батабыз бит! Бу Сине борчымыймы? – диделәр.
[39] Ул торып, җилне тыйды, ә диңгезгә әйтте:
– Шаулама, тынычлан!
Җил туктады һәм тынлык урнашты.
[40] – Ни өчен сез шундый куркак? Сезнең һаман иманыгыз юкмы? – диде Гайсә аларга.
[41] Аларны курку басты һәм бер-беренә:
– Кем соң Ул? Җил дә, диңгез дә Аңа буйсына ич, – диештеләр.

### *Гайсә җенле кешене савыктыра*

**5** [1] Алар Гәлиләя диңгезе аръягындагы Герәсә җиренә килеп туктадылар. [2-3] Гайсә көймәдән төшкәч үк, каберләр* арасыннан чыккан бер җенле кешене очратты. Ул кеше каберләр арасында яши иде. Аны хәтта чылбырлар белән дә бәйләп куя алмаганнар. [4] Чөнки күп тапкырлар аяк-кулларын чылбырлар

---

* 5:2-3 *Кабер* – яһүдләр мәетләрне тауны тишеп ясалган мәгарә-каберләргә куйганнар.

белән бәйләсәләр дә, ул барыбер чылбырларны өзә һәм богау-
ларны вата торган булган. Берәү дә аны җиңә алмаган. 5 Ул
көне-төне бертуктаусыз каберләр арасында һәм тауларда үзен
ташлар белән бәреп кычкыра торган булган.
6 Ерактан ук Гайсәне күреп, ул Аның янына йөгереп килде
һәм, аякларына егылып, 7 каты тавыш белән кычкырды:

– Аллаһы Тәгаләнең Улы, Гайсә! Миннән Сиңа ни кирәк? Аллаһы хакы өчен Синнән ялварам, газаплама мине.

8 Ул шулай әйтте, чөнки Гайсә аңа: «Шакшы рух, бу кешенең
эченнән чык!» – дигән иде.
9 – Исемең ничек? – дип сорады аннан Гайсә.

– Без бик күбәү, шуңа күрә минем исемем – Гаскәр, – дип
җавап бирде тегесе. 10 Һәм аларны бу җирдән куып җибәрмәвен
үтенеп сорады.
11 Тау битендә зур дуңгыз көтүе утлап йөри иде.
12 – Безне дуңгызларга җибәрче, без аларның эченә керер-
без! – дип ялвардылар шакшы рухлар.
13 Гайсә рөхсәт иткәч, кеше эченнән чыккан шакшы рухлар
дуңгызлар эченә керделәр һәм дуңгыз көтүе текә ярдан диң-
гезгә ташланып батып үлде. Ә дуңгызларның саны ике меңгә
якын иде.
14 Көтүчеләр, качып китеп, бу хакта шәһәрдә һәм аның тирә-
сендәге авылларда сөйләп йөрделәр. Ә анда яшәүчеләр исә,
ни булганын карарга дип, 15 Гайсә янына килделәр, эчендә
җеннәр булган кешенең киенгән һәм акылына килгән хәлдә
утыруын күреп, куркып калдылар. 16 Вакыйганы күргән кеше-
ләр җенле кеше һәм дуңгызлар белән ни булганы хакында
сөйләп бирделәр. 17 Шуннан соң алар Гайсәнең бу урыннан
китүен үтенә башладылар.
18 Гайсә көймәгә утырган чакта, элек җенле булган кеше Гай-
сә белән бергә барырга теләвен әйтте. 19 Әмма Ул рөхсәт итмәде:

– Бар, өеңә кайтып, туганнарыңа Раббының ничек сине кызгануын һәм синең өчен нәрсә эшләгәнен сөйлә, – диде Гайсә.

20 Ул кеше китеп, Гайсәнең аның өчен нәрсә эшләгәне хакын-
да Ун калада сөйләп йөрде һәм барысы да моңа таң калдылар.

*Үлгән кыз һәм авыру хатын*

21 Гайсә көймәдә кире икенче як ярга чыккач, яр буенда
Аның янына тагын күп халык җыелды. 22 Гыйбадәтханә баш-
лыкларыннан берсе, Яһир исемлесе, Аны күрү белән, янына
килеп, Гайсәнең аякларына егылды 23 һәм ялварып сорады:

– Минем кызым үлем хәлендә ята. Килеп, аның өстенә кулларыңны куйчы, ул савыгып һәм яшәр иде!

24 Гайсә аның белән китте.

Аңа, һәр яктан кысрыклап, күп халык ияреп барды. 25 Бер
хатын унике ел буе кан китүдән җәфаланган булган. 26 Бик күп
табибларда дәваланган, бөтен байлыгын сарыф итсә дә, фай-
дасын күрмәгән: хәле тагын да начарайган икән. 27-28 Ул Гайсә
хакында ишетеп: «Аның киеменә генә булса да кагылсам, са-
выгыр идем», – дип уйлаганга, халык арасына кереп, арттан
килеп, Гайсәнең киеменә кагылды. 29 Шунда ук аның кан агуы
туктады һәм ул үзенең тулысынча савыгуын тойды. 30 Гайсә
Үзеннән көч чыкканын тоеп, халыктан сорады:

– Минем киемемә кем кагылды?

31 – Халыкның ничек кысрыклавын күреп торасың бит! Ә Син,
кем кагылды, дип сорыйсың, – диделәр шәкертләре.

32 Әмма Ул моны эшләүчене күзләре белән эзли бирде. 33 Кур-
куыннан калтырап төшкән хатын, үзе белән ни булганын аңлап,
халык арасыннан чыкты һәм, Гайсә алдына егылып, дөресен
сөйләп бирде.

34 – Кызым, ышануың сине савыктырды, имин йөр, исән-сау
бул, – диде аңа Гайсә.

35 Гайсә бу сүзләрне әйткән арада, гыйбадәтханә башлыгы-
ның өеннән килеп әйттеләр:

– Синең кызың үлде. Остазны бүтән борчыма!

36 Әмма Гайсә, аларның сүзләрен ишетеп, башлыкка әйтте:

– Курыкма, тик ышан гына!

37 Гайсә Петердән, Ягъкубтан, Ягъкубның энесе Яхъядан баш-
ка һичкемгә Үзе белән барырга рөхсәт итмәде. 38 Башлыкның
өе янына килгәч, Гайсә анда ыгы-зыгы килеп йөрүчеләрне,
һәм такмаклап-такмаклап үкереп елаучыларны күрде.

39 – Сез нигә ыгы-зыгы килеп йөрисез, нигә елыйсыз? Бала
үлмәгән, тик йоклый гына, – диде аларга Гайсә, өйгә кергәч.

40 Аңардан көлделәр, әмма Ул аларны куып чыгарып, кыз-
ның атасын, анасын, Үзенең юлдашларын алып, кыз яткан
бүлмәгә керде. 41 Баланың кулыннан тотып, аңа әйтте:

– Талита, кум! (Ягъни, «Кызым, сиңа әйтәм, тор!»)

42 Кыз бала шунда ук торды һәм йөри башлады, аңа унике
яшь иде. Барысы да күргәннәреннән хәйран калдылар. 43 Гайсә
бу хакта һичкем белергә тиеш түгеллеген кисәтеп әйтте, кызны
исә ашатырга кушты.

### *Гайсә Насарада инкяр ителә*

6 1 Гайсә шул урыннан китеп, шәкертләре белән бергә Үзе
яшәгән шәһәргә кайтты. 2 Шимбә көнне Гайсә гыйбадәт-
ханәдә өйрәтте. Аны тыңлаган һәммәсе:

– Бу Аңа кайдан килгән икән? Нинди тирән акыл бирелгән?
Аның куллары белән шундый кодрәтле эшләр эшләнә бит! – дип

таң калдылар. [3] – Ул – балта остасы; Мәрьямнең улы, Ягъкуб-
ның, Йосыфның, Яһүднең һәм Шимунның абыйсы түгелме соң?
Аның сеңелләре безнең арабызда түгелме соң? – диделәр.
Алар Аны кире кактылар.
[4] – Пәйгамбәр һәр җирдә дә ихтирам ителә, тик үз ватанында,
үз туганнары һәм гаиләсе тарафыннан гына хөрмәт күрми, –
диде аларга Гайсә.
[5] Шуңа күрә Ул анда бер генә дә кодрәтле эш күрсәтә алмады,
фәкать өсләренә кулларын куеп, берничә авыру кешене савык-
тырды. [6] Аларның ышанмаулары Аны гаҗәпләндерде.

*Гайсә унике шәкертен җибәрә*

Гайсә, авылдан-авылга күчеп, өйрәтеп йөрде. [7] Ул Үзе янына
унике шәкертен чакырып, аларга шакшы рухларны куып чыга-
рырга вәкаләт биреп, икешәрләп-икешәрләп кешеләр янына
җибәрде. [8] Юлга үзләре белән юл таягыннан башка икмәк тә,
биштәр дә, акча да алмаска, [9] аяк киемнәре кияргә кушты һәм:
– Үзегез белән алмаш күлмәк алмагыз, – диде. – [10] Нинди
йортка керсәгез, ул урыннардан киткәнче, шул йортта калы-
гыз, – диде Ул аларга.
[11] – Әгәр берәр җирдә сезне кабул итмичә, тыңлап та торма-
салар, ул чакта, ул урыннан киткәндә, аларга каршы шаһитлек
билгесе итеп, аякларыгыздагы тузанны кагып төшерегез.
[12] Һәм алар китеп, кешеләрне тәүбә итәргә өндәп йөрделәр,
[13] күп җеннәрне куып чыгардылар һәм, зәйтүн мае сөртеп, күп
авыру кешеләрне савыктырдылар.

*Чумдыручы Яхъяның үлеме*

[14] Гайсәнең исеме киң танылгач, ул хакта Һируд патшага да
ишетелде. Кайберәүләрнең сөйләвенчә, Бу – үледән терелеп
торган Чумдыручы Яхъя, шуңа күрә Аның кодрәтле эшләр
күрсәтергә куәте бар, [15] башкалары сөйләвенчә, Ул – Ильяс,
бүтәннәре исә, борынгыда булган пәйгамбәр кебек бер пәйгам-
бәр Ул, дигәннәр.
[16] Әмма Һируд, тыңлап торып, әйтте:
– Ул – Чумдыручы Яхъя! Мин аның башын кистердем, әмма
ул үледән терелеп торды!
[17] Һируд үзенең абыйсы Филипнең хатынына – Һирудиягә
өйләнгәнлектән, Яхъяны кулга алып, төрмәгә утыртырга әмер
биргән иде. [18] Чөнки Яхъя Һирудка: «Синә абыеңның хатыны
белән яшәргә ярамый», – дип әйткән иде. [19] Шуның аркасында
Һирудия аңа нәфрәт итеп, аны үтертергә теләгән, әмма бер-
ни эшли алмаган. [20] Яхъяның тәкъва һәм изге кеше булуын

белгәнгә, Һируд аннан курка һәм яклап килә иде. Аның сүзләре патшаны борчыса да, ул аны рәхәтләнеп тыңлый иде.

[21] Һируд үзенең туган көне уңае белән, зур дәрәҗәле түрәләрне, гаскәр башлыкларын һәм Гәлиләя өлкәннәрен аш мәҗлесенә чакыргач, Һирудиягә җай чыкты. [22] Анда Һирудиянең кызы да килгән иде. Аның биюе Һирудка һәм аның кунакларына бик ошады. Патша аңа:

– Ни теләсәң, барын да миннән сора: барын да бирермен! – диде. [23] Һәм ул, ант итеп, әйтте:

– Хәтта, патшалыгымның яртысын сорасаң да, сиңа бирермен!

[24] Кыз, барып, анасыннан сорады:

– Миңа нәрсә сорарга?

– Яхъя пәйгамбәрнең башын сора, – диде тегесе.

[25] Ул шунда ук патша янына барып:

– Чумдыручы Яхъяның башын хәзер үк тәлинкәгә салып китерүеңне телим! – дип таләп итте.

[26] Патша зур кайгыга төшсә дә, кунаклары алдында ант иткәч, аңа каршы килергә батырчылык итмәде. [27] Ул шунда ук сакчысын, Яхъяның башын китерергә кушып, төрмәгә җибәрде. Ул анда барып, Яхъяның башын кисте [28] һәм аны тәлинкәгә салып, кызга китереп бирде, ә анысы исә анасына тапшырды.
[29] Яхъяның шәкертләре бу хакта ишетеп, аның гәүдәсен килеп алдылар һәм кабергә салдылар.

*Биш меңне ашату*

[30] Рәсүлләр, Гайсә янына әйләнеп кайтып, эшләгән эшләре һәм өйрәтүләре хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. [31] Ул аларга әйтте:

– Ә хәзер, берәр аулак җиргә барып, ялгыз гына бераз ял итеп алыгыз.

Чынлап та, кешеләр берсе артыннан берсе килгәнгә күрә, аларга ашап алырга да вакыт калмый иде.

[32] Алар көймәгә утырып, үзләре генә аулак урынга киттеләр.
[33] Әмма, көймәгә утырган чакта, кешеләрнең күбесе аларны таныдылар, һәм тирә-яктагы барлык шәһәрләрдән килгән кешеләр яр буйлап йөгерә-йөгерә алар барасы урынга алардан алда килеп җиттеләр. [34] Гайсә ярга чыккач, зур халык төркемен күрде һәм аларны кызганды, чөнки алар көтүчеләре булмаган сарыклар кебек иде. Ул аларны күп нәрсәләргә өйрәтә башлады. [35] Вакыт соң иде инде һәм шәкертләре Аның янына килеп әйттеләр:

– Бу кеше йөрми торган урын, вакыт та соң инде. [36] Җибәр аларны, якын-тирәдәге авылларга барып, үзләренә ашарга сатып алсыннар.

37 – Сез аларны үзегез ашатыгыз, – диде Гайсә.
– Әллә үзебезгә барып, алар өчен бер ике йөз динарлык*
икмәк сатып алыргамы? – диделәр алар.
38 – Сездә күпме икмәк бар? Барып карагыз әле, – диде Ул.
Алар карагач, җавап бирделәр:
– Биш икмәк һәм ике балык.
39 Гайсә шәкертләренә, халыкны төркемнәргә бүлеп, яшел
чирәмгә утыртырга кушты. 40 Алар, йөзәр һәм иллешәр кешегә
бүленеп, тезелешеп утырдылар. 41 Гайсә биш икмәкне, ике ба-
лыкны алды да, күккә карап, шөкрана кылды һәм, икмәкне
сындыргалап, халыкка өләшер өчен шәкертләренә бирде. Ул
ике балыкны да һәммәсенә бүлеп бирде. 42 Алар барысы да
ашап туйдылар. 43 Шәкертләр ипидән һәм балыктан калган
сынықларны җыеп, унике кәрзингә тутырдылар. 44 Ашаучылар-
ның саны биш мең ир кеше иде.

*Гайсә су өстеннән атлап килә*

45 Аннары Гайсә шәкертләренә, Аның халыкны җибәргүен
көтмичә, хәзер үк көймәгә утырып, каршы як ярдагы Бәйтсай-
дага Үзеннән алданрак китәргә кушты. 46 Халык белән саубул-
лашкач, Ул дога кылыр өчен тауга менде. 47 Кич җиткәндә көй-
мә диңгез уртасында иде инде, ә Ул яр буенда берүзе калды.
48 Каршы искән җил белән көрәшүләрен, аларның ишүдән хәл-
дән тайганнарын күреп, иртәнге өч белән алты арасында** Ул,
су өстеннән атлап, алар янына китте. Ул аларны узып китәргә
теләде, 49-50 ә шәкертләре Аның су өстеннән килүен күреп, өрәк-
тер дип уйладылар һәм куркышып, кычкырып җибәрделәр.
– Кыю булыгыз, бу – Мин! Курыкмагыз! – диде шунда ук
аларга Гайсә 51 һәм алар янына көймәгә кереп утырды. Шул ва-
кытта ук җил туктады. Һәм бу аларны тагын да ныграк гаҗәп-
ләндерде. 52 Икмәк белән булган хәл нәрсә аңлатканны алар
бит аңламадылар, чөнки аларның йөрәкләре каткан иде.
53 Алар, диңгезне кичеп, Геннисарет ярына килеп туктады-
лар. 54 Көймәдән чыгу белән, кешеләр, Аны танып, 55 бу хәбәр
белән бөтен тирә-якны йөгереп әйләнделәр. Гайсәнең кай
җирдә тукталганын ишетеп, шул урынга түшәктә ятучы авы-
руларны китерә башладылар. 56 Гайсә кайда гына булмасын,
авылллардамы, шәһәрләрдәме, берәр йорттамы, бөтен җирдә

---

* 6:37 *Динар* – көмеш тәңкә. Эшченең бер көнлек хезмәт хакын тәшкил иткән.

** 6:48 *Иртәнге өч белән алты арасында* – грекча сүзгә-сүз «төннең дүртенче сак вакытында». Рим системасы буенча, төн өчәр сәгатьтән торган дүрт сак вакытына бүленгән булган.

авыруларны мәйданнарга китереп салдылар, Аның киеменең
чабуына гына булса да кагылырга рөхсәт бирүен үтенделәр.
Һәм кем генә кагылмасын, барысы да савыктырылды.

*Ата-баба йолалары*

7 [1] Гайсә янына фарисейләр белән бергә Иерусалимнан килгән кайбер канунчылар җыелдылар. [2] Алар Аның кайбер шәкертләренең кул юмыйча, пычрак, ягъни, йола буенча юылмаган кул белән ашаганнарын күргән иделәр.

[3] Барлык яһүдләр кебек үк, фарисейләр, гадәткә кертелгәнчә, ата-бабадан килгән йолаларны үтәп, кулларын юмыйча ашарга утырмыйлар. [4] Базардан кайту белән дә юынмыйча ашарга утырмыйлар. Һәм бик күп башка нәрсәләрне, мәсәлән, касәләрне, чүлмәкләрне, бакырдан эшләнгән савытларны юуга караган күрсәтмәләрне үтиләр.

[5] Фарисейләр һәм канунчылар Гайсәдән сорадылар:

– Ни өчен Синең шәкертләрең ата-бабалардан килгән йолаларны үтәмиләр, ризыкны пычрак куллары белән ашыйлар?

[6] Ә Ул аларга җавап бирде:

– Сез монафикълар! Ишагыйя пәйгамбәр сезнең хакта, алдан күреп, дөрес әйткән. Ул болай дип язган:

«Бу халык Мине теле белән хөрмәт итә,
ә күңелләре исә Миннән еракта.
[7] Аларның Миңа табынулары бушка:
алар кеше уйлап чыгарган кагыйдәләргә өйрәтәләр».

[8] Аллаһы әмерен читтә калдырып, сез кеше урнаштырган йолаларны үтисез.

[9] Үзегезнең йолагызны үтәр өчен, ничек оста итеп Аллаһы әмерен кире кагасыз! – дип дәвам итте Гайсә. – [10] Муса болай дип әйткән: «Атаңны һәм анаңны хөрмәт ит» һәм «Атасын һәм анасын хурлаган кеше үтерелергә тиеш». [11] Ә сез: «Әгәр кеше атасына, яки анасына: „Мин сиңа бирергә тиеш булган әйберне Аллаһыга корбан (ягъни, Аллаһыга тиешле бүләк) итеп вәгъдә иттем“, – дип әйтә икән, [12] ул чакта ул кешегә атасы яки анасы өчен берни эшләмәскә мөмкин», – дип өйрәтәсез. [13] Сез үзегезнең йолагыз белән Аллаһы сүзен юкка чыгарасыз һәм шуңа охшаган төрле эшләр эшлисез.

[14] Ул тагын халыкны чакырып, аларга әйтте:

– Барыгыз да Мине тыңлагыз һәм аңлагыз! [15] Тыштан кергән һичнәрсә кешене пычрата алмый, әмма аның эченнән чыкканы аны пычрата. [ [16] ]*

---

* 7:16 Кайбер кулъязмаларда 16 нчы аять тә бар: «Колаклары булган ишетсен!»

[17] Гайсә халыкны калдырып өйгә кергәч, шәкертләре Аннан
бу сүзләрне аңлатып бирүен сорадылар.
[18] – Әллә сез дә һаман аңламыйсызмы? – диде Ул. – Кеше-
нең эченә тыштан кергән һичнәрсә аны пычрата алмаганын
аңламыйсызмы? [19] Чөнки аның йөрәгенә түгел, ә карынына ке-
рә һәм аннан чыгарылып ташлана! (Моның белән Гайсә бөтен
ризыкның да чиста булуын белдерде.)
[20] Һәм Гайсә дәвам итте:
– Ә кешенең эченнән чыкканы исә аны пычрата. [21] Фәхеш-
леккә, урлашуга, кеше үтерүгә, [22] зиначылыкка китерүче явыз
ниятләр кешенең йөрәгеннән килә; шуннан ук саранлык, кабә-
хәтлек, мәкерлек, әхлаксызлык, көнчелек, хурлау, тәкәбберлек,
акылсызлык килә. [23] Бу барлык яманлык кешенең эченнән чыга,
шул аны пычрата да инде.

*Мәҗүси хатынның иманы*

[24] Аннан Гайсә Тур шәһәре тирәләренә юл тотты. Ул андагы
бер йортта тукталды, һәм бу хакта берәүнең дә белүен теләмә-
гән иде дә, әмма мөмкин булмады. [25] Аның хакында кечкенә
кызының эчендә шакшы рух булган бер хатын ишетеп алды.
Ул шунда ук, килеп, Гайсәнең аякларына егылды. [26] Бу мәҗүси
хатын чыгышы белән Сурия Фойникәсе өлкәсеннән иде. Ул
Гайсәдән кызы эчендәге җенне куып чыгаруын үтенде.
[27] – Башта балалар туенсыннар, – диде аңа Гайсә. – Икмәк-
не балалардан алып, көчекләргә ташлау яхшы түгел.
[28] – Әфәнде, – дип җавап бирде ул, – ләкин көчекләр дә
өстәл астына балалардан коелган валчыкларны ашый бит.
[29] – Шулай дип әйтәсең икән, өеңә кайт: кызыңның эченнән
җен чыкты, – диде Гайсә.
[30] Хатын өенә әйләнеп кайтты һәм кызының исән-сау түшәк-
тә ятуын күрде. Җен аның эченнән чыккан иде инде.

*Гайсә телсез һәм чукрак кешене савыктыра*

[31] Аннан соң, Тур тирәләреннән китеп, Сидун аша һәм Ун ка-
ла тирәләреннән үтеп, Гайсә Гәлиләя диңгезенә чыкты. [32] Аның
янына чукрак һәм начар сөйләшә торган кешене китереп, аның
өстенә кулларын куеп алуын үтенделәр. [33] Гайсә, аны халык
төркеменнән читкәрәк алып китеп, аның колакларына Үзенең
бармакларын тыкканнан соң, төкереп, аның теленә кагылды.
[34] Аннары Гайсә күккә карап һәм тирән сулап әйтте:
– Эффата! (Ягъни, «Ачыл!»)
[35] Шунда ук аның колаклары ишетә башлады һәм теле чи-
шелде, һәм ул ачык итеп сөйләшә башлады. [36] Гайсә кешеләргә

бу хакта берәүгә дә сөйләмәскә кушты. Әмма Ул тыйган саен
алар тагын да күбрәк сөйләп йөрделәр. [37] Аларның гаҗәпләнү-
ләренең чиге булмады.

– Бөтен нәрсәне дә Ул яхшы итеп эшли: чукраклар ишетә-
ләр һәм телсезләр сөйләшәләр! – диделәр алар.

*Дүрт меңне ашату*

8 [1] Ул көннәрдә тагын күп кеше җыелды, ә аларның ашар-
ларына ризыклары юк иде. Шәкертләрен чакырып, Гайсә
әйтте:

[2] – Кешеләрне кызганам. Алар Минем белән инде өч көн
буе, ә ашарларына һич нәрсәләре юк. [3] Әгәр Мин аларны ач
килеш өйләренә кайтарып җибәрсәм, юлда хәлсезләнерләр,
чөнки аларның кайберләре ерактан килгәннәр.

[4] – Барысын да туендырыр өчен чүлдә шулкадәр икмәкне
кайдан алыйк соң? – дип сорадылар шәкертләре.

[5] – Сездә ничә икмәк бар? – дип сорады Гайсә.

– Җиде, – диделәр алар.

[6] Шуннан соң Гайсә халыкка утырырга кушты. Җиде икмәкне
алып, Аллаһыга шөкрана кылгач, икмәкне сындыргалады һәм
халыкка өләшү өчен шәкертләренә бирде. Алар икмәкне өләшеп
чыктылар. [7] Аларның берничә балыклары да бар иде. Гайсә,
шөкрана кылгач, аларны да өләшергә кушты. [8] Кешеләр ашап
туйдылар, һәм шәкертләре, калган сыныкларны җыеп, җиде
кәрзингә салдылар. [9] Ашаучыларның саны дүрт меңгә якын иде.
Гайсә аларны өйләренә кайтарып җибәрде, [10] ә Үзе шунда ук шә-
кертләре белән көймәгә утырып, Далманута җирләренә китте.

[11] Фарисейләр килеп, Гайсә белән бәхәсләшә башладылар.
Аны сынарга теләп, алар күктән илаһи билге күрсәтүен таләп
иттеләр. [12] Гайсә, авыр сулап, аларга әйтте:

– Бу буын кешеләре ни өчен илаһи билге таләп итә икән?
Сезгә хак сүз әйтәм: бу кешеләргә илаһи билге бирелмәячәк.

[13] Ул аларны калдырып, тагын көймәгә утырды һәм икенче
як ярга йөзеп китте.

*Фарисейләр һәм Һируд ачыткысы*

[14] Шәкертләре үзләре белән икмәк алырга оныткан булган-
нар, көймәдә аларның бер икмәкләре генә бар иде. [15] Гайсә
аларга кисәтеп әйтте:

– Карагыз аны, фарисейләр ачыткысыннан һәм Һируд ачыт-
кысыннан сакланыгыз!

[16] Ә шәкертләре үзара: «Ул безнең икмәгебез булмаганга
шулай әйтә», – дип сөйләнделәр.

17 Гайсә, моны белеп, аларга әйтте:
– Сез ни өчен икмәгегез юклыгы турында сөйләшәсез? Сез
берни дә аңламыйсызмыни? Сез һичнәрсә төшенмисезмени?
Йөрәкләрегез катканмы? 18 Күзләрегез бар, сез күрмисезме,
колакларыгыз бар, сез ишетмисезме? Әллә хәтерләмисезме?
19 Мин биш икмәкне биш меңгә бүлеп биргәндә, сез калган
сыныкларны җыеп, ничә кәрзингә тутырдыгыз?
– Унике, – дип җавап бирделәр.
20 – Ә инде җиде икмәкне дүрт меңгә бүлгәндә, калган сы-
нықларны ничә кәрзин тутырып җыйдыгыз?
– Җиде, – дип җавап бирделәр.
21 – Әллә сез һаман төшенмәдегезме? – диде Гайсә.

*Гайсә Бәйтсайдада сукырны савыктыра*

22 Алар Бәйтсайдага килделәр. Кешеләр, Гайсә янына бер
сукырны китереп, өстенә кулларын куеп алуын үтенделәр.
23 Гайсә сукырны җитәкләп авылдан чыгарды. Аның күзләренә
төкереп һәм башына кулларын куеп сорады:
– Берәр нәрсә күрәсеңме?
24 Ул карарга тырышты һәм әйтте:
– Мин кешеләрне күрәм. Алар агачлар булып күренәләр,
ләкин алар йөриләр.
25 Гайсә аның күзләренә тагын кулларын тидергәч, ул текә-
леп карады һәм ачык итеп күрә башлады.
26 – Авылга кире барма, – дип, Гайсә аңа өенә кайтырга
кушты.

*Кем ул Гайсә?*

27 Гайсә Үзенең шәкертләре белән Филип Кайсариясе шәһә-
ре тирәсендә урнашкан авылларга китте. Юлда барганда, Ул
шәкертләреннән сорады:
– Кешеләр Мине кем дип belә?
28 – Берәүләр Сине – Чумдыручы Яхъя, башкалары – Ильяс,
ә кайберләре исә пәйгамбәрләрнең берсе дип исәплиләр, – ди-
деләр алар.
29 – Ә сез, сез Мине кем дип беләсез? – дип сорады Ул алардан.
– Син – Мәсих, – дип җавап бирде Петер.
30 Гайсә аларга Үзе хакында беркемгә дә сөйләмәскә кушты.

*Гайсә Үзенең үлеме хакында әйтә*

31 Гайсә, Адәм Улының күп газаплар чигәргә, аксакаллар,
баш руханилар һәм канунчылар тарафыннан кире кагылырга
һәм үтерелергә, әмма өч көннән соң терелеп торырга тиешлеге

турында шәкертләренә сөйли башлады. [32] Бу хакта Гайсә ачык
итеп сөйләде. Шунда Петер Аны читкәрәк чакырып, Аңа каршы
әйтә башлады. [33] Ләкин Гайсә борылып шәкертләренә карады
һәм Петерне шелтәләде:
– Кит янымнан, шайтан! Синдә Аллаһы уйлары түгел, ә кешенеке.
[34] Үзе янына шәкертләрен һәм халыкны чакырып, Гайсә әйтте:
– Кем Минем арттан барырга тели, үз-үзеннән баш тартсын,
үзенең хачын алып, Миңа иярсен. [35] Үзенең тормышын саклап
калырга теләүче тормышын югалтыр. Ә инде ул тормышын
Минем хакка һәм Яхшы хәбәр хакына югалтса, тормышын саклап калыр. [36] Әгәр берәү бөтен дөнья милкен үзенә алып, җанын
һәлак итсә, моннан аңа ни файда? [37] Кеше нәрсә биреп үзенең
җанын кайтарып ала алыр икән? [38] Кем бу иманы булмаган һәм
гөнаһлы кешеләр арасында Миннән һәм Минем сүзләремнән
гарьләнә, Үзенең изге фәрештәләре белән Атасының балкып
торган шөһрәте белән килгән вакытта, Адәм Улы да ул кешедән гарьләнер.

9 [1] Гайсә әйтте:
– Сезгә хак сүз әйтәм: монда басып торучыларның кайберләре Аллаһы Патшалыгының кодрәт белән килгәнен
күргәнче, үлемне татымаячаклар.

*Гайсәнең тышкы кыяфәте үзгәрә*

[2] Алты көннән соң, Гайсә Петерне, Ягъкубны һәм Яхъяны
Үзе белән алып, биек тауга менде. Алар анда үзләре генә иделәр. Гайсәнең тышкы кыяфәте аларның күз алдында үзгәреп
китте. [3] Аның киемнәре ялтырап, җир йөзендә һичкем агарталмаслык дәрәҗәдә, күз чагылдырырлык ак төскә керде. [4] Шәкертләр алдында Ильяс белән Муса пәйгамбәрләр хасил булды,
һәм алар Гайсә белән сөйләштеләр. [5] Һәм Петер Гайсәгә әйтте:
– Остаз! Безнең монда булуыбыз нинди яхшы! Өч чатыр корыйк: берсен Сиңа, берсен Мусага, берсен Ильяска.
[6] Ул бу сүзләрне нәрсә дип әйтергә дә белмәгәнлектән әйтте,
чөнки шәкертләр шулкадәр куркып калган иде.
[7] Шул вакытта болыт төшеп, аларны каплады һәм болыт
эченнән: «Бу – Минем сөекле Улым, Аны тыңлагыз!» – дигән
сүзләр ишетелде. [8] Шәкертләр тиз-тиз як-якларына каранып
алдылар, әмма яннарында Гайсәдән башка беркемне дә күрмәделәр.
[9] Таудан төшкәндә, Гайсә аларга ни күргәннәрен Адәм Улының үледән терелеп торуына кадәр берәүгә дә сөйләмәскә

кушты. [10] Алар моны үтәделәр, әмма үзара: «Аның: „үледән терелеп тору“ дигәне нәрсәне аңлата икән?» – дип сөйләштеләр.
[11] Гайсәдән сорадылар:

– Канунчылар ни өчен, башта Ильяс килергә тиеш, дип әйтәләр?

[12] – Чыннан да, башта Ильяс килеп, барын да үз урынына урнаштырачак, – дип җавап бирде Гайсә. – Ә ни өчен соң Изге язмада Адәм Улына күп газаплар чигеп кимсетелергә туры киләчәк дип язылган? [13] Ләкин Мин сезгә әйтәм: Ильяс килде
инде һәм, аның турында язылганча, аның белән ни теләсәләр, шуны эшләделәр.

*Гайсә җенле малайны савыктыра*

[14] Алар калган шәкертләр янына әйләнеп кайткач, болар янына күп халык җыелганын һәм канунчыларның болар белән бәхәсләшеп торуларын күрделәр. [15] Гайсәне күреп гаҗәпләнгән
халык төркеме шунда ук Аны сәламләргә йөгерде. [16] Гайсә:

– Алар белән нәрсә хакында бәхәсләшәсез? – дип шәкертләреннән сорады.

[17] Халык арасыннан бер кеше җавап бирде:

– Остаз! Мин Сиңа үземнең улымны китергән идем. Аның эченә шакшы рух кереп, улымны телсез итте. [18] Шакшы рух
аны кайда гына эләктермәсен, аны җиргә атып бәрә. Малайның авызыннан күбекләр ага, ул тешләрен шыкырдата, ә аннан соң бөтен гәүдәсе катып кала. Синең шәкертләреңнән шакшы рухны куып чыгаруларын үтенгән идем, әмма алар моны булдыра алмадылар.

[19] – Әй, имансыз буын! – диде аларга Гайсә. – Миңа сезнең белән күпме булырга? Күпме сезне түзеп торырга? Малайны Минем янга китерегез!

[20] Аны Гайсә янына китерделәр. Гайсәне күрү белән шакшы рух малайны калтыратырга тотынды һәм ул җиргә егылды, авызыннан күбекләр агыза-агыза тәгәрәде.

[21] – Аның белән мондый хәл күптәннән була башладымы? – дип сорады Гайсә малайның атасыннан.

– Балачактан бирле шулай, – дип җавап бирде анысы. –
[22] Аны шакшы рух күп тапкыр һәлак итәргә тырышты: әле утка ташлады, әле суга. Әгәр нәрсәдер эшли алсаң, кызган безне, ярдәм итче!

[23] – Ул ни дигән сүз: «әгәр эшли алсаң»? Ышанган кешегә һәммәсе дә мөмкин.

[24] Һәм малайның атасы кычкырып җибәрде:

– Ышанам! Ышанычым аз булганга күрә, миңа ярдәм ит!

25 Гайсә, халыкның җыелуын күреп, шакшы рухка боерды:
– Телсезлек һәм чукраклык рухы, Мин сиңа боерам: аның эченнән чык һәм башка кермә!
26 Шакшы рух, малайны көчле итеп калтыратып, үкереп чык-
ты. Малай исә, үлгән сыман булды. Шуңа күрә күбесе, үлде,
дип сөйләнделәр. 27 Әмма Гайсә аңа, кулыннан тотып, торырга
ярдәм итте, һәм ул аягына басты.
28 Өйгә кереп, Гайсә белән үзләре генә калгач, шәкертләре Аннан:
– Ә ни өчен аны без куып чыгара алмадык? – дип сорадылар.
29 – Мондый җеннәрне тик дога белән генә куып чыгарып була, – диде Гайсә.
30 Алар аннан китеп, инде Гәлиләя җире аша үттеләр. Гайсә
исә бу турыда һичкемнең дә белүен теләмәде, 31 чөнки Үзенең
шәкертләрен өйрәтә иде. Ул аларга әйтте:
– Адәм Улын кешеләр кулына тотып бирерләр һәм алар Аны үтерәчәкләр, әмма Ул өч көннән соң терелеп торачак.
32 Әйткән сүзләрен шәкертләре аңламадылар, әмма Гайсәдән сорарга курыктылар.

*Кем иң бөеге?*

33 Алар Кәпәрнаумга әйләнеп килделәр. Өйдә Гайсә алардан:
– Юлда барганда сез нәрсә хакында бәхәсләштегез? – дип сорады.
34 Алар исә эндәшмәделәр, чөнки юлда барган чакта, арала-
рында кайсысы иң бөек, дип бәхәсләшкән иделәр. 35 Гайсә,
утырып, унике шәкертен янына чакырды һәм әйтте:
– Кем алдынгы булырга тели, шул иң соңгы булырга тиеш һәм бөтенесе өчен дә хезмәтче булырга тиеш.
36 Гайсә урталарына бер баланы бастырып, кочаклап алды һәм шәкертләренә әйтте:
37 – Шушындый балаларның берсен Минем хакка кабул иткән кеше Мине кабул итә. Ә Мине кабул иткән кеше Мине генә түгел, бәлки Мине Җибәрүчене кабул итә.

*Сезгә каршы булмаган кеше сезнең яклы*

38 – Остаз, – диде Яхъя, – без бер кешенең, Синең исемеңне кулланып, җеннәрне куып чыгаруын күрдек. Безнең белән бер-гә йөрмәгәнгә күрә, без аңа туктарга куштык.
39 Гайсә җавап бирде:
– Аны туктатмагыз. Минем исемемнән кодрәтле эш булдыра
алган кеше Мине начар сүзләр белән тиз генә хурламас. 40 Безгә
каршы булмаган кеше безнең яклы. 41 Сезгә хак сүз әйтәм: кем

дә кем, Мәсихнеке булуыгыз өчен, сезгә эчәргә дип бер чына-
як су бирә, ул әҗереннән мәхрүм калмаячак.
[42] Әмма Миңа иман итүче бу кечкенәләрнең берсен юлдан
яздыручыны, муенына тегермән ташын асып, диңгезгә ташла-
салар, аның өчен яхшырак булыр иде. [43] Әгәр кулың сине вәс-
вәсәгә төшерсә, аны чабып төшер! Җәһәннәмгә, сүнмәс утка
ике кулың белән ташланганчы, тормышка бер кулың белән ке-
рүең синең өчен яхшырак. [ [44] ]* [45] Әгәр аягың сине вәсвәсәгә
төшерсә, аны чабып төшер! Ике аягың белән җәһәннәмгә таш-
лануга караганда, тормышка бер аягың белән керүең синең
өчен яхшырак. [ [46] ]** [47-48] Әгәр күзең сине вәсвәсәгә төшерсә,
аны алып ташла! «Кешеләрне бертуктаусыз кортлар ашап тор-
ган һәм уты сүнмәгән» җәһәннәмгә ике күзең белән ташлануга
караганда, бер күзең белән Аллаһы Патшалыгына керүең синең
өчен яхшырак.
[49] Һәркем ут белән «тозланыр».
[50] Тоз – яхшы нәрсә. Әмма тоз тозсызланса, аны ничек тозлы
итәрсез? Тоз сезнең үзегездә булсын! Һәм бер-берегез белән та-
ту булыгыз.

*Гайсә аерылышу хакында өйрәтә*

**10** [1] Ул урыннан Гайсә Яһүдиягә һәм Үрдүн аръягындагы
җирләргә юнәлде. Тагы күп халык Аңа ияреп китте һәм
Ул, гадәттәгечә, аларны өйрәтте.
[2] Гайсә янына фарисейләр килделәр һәм, Аны сынарга теләп,
сорадылар:
– Ир кешегә хатынын аерып җибәрергә канун рөхсәт итәме?
[3] – Муса сезгә нәрсә эшләргә кушты соң? – диде Гайсә.
[4] – Муса ир кешегә хатынын, аерылышу кәгазе язып, аерып
җибәрергә рөхсәт бирде, – дип җавап бирделәр алар.
[5] – Ул сезгә шундый әмерне күңелләрегез каты булганга кү-
рә язган, – диде Гайсә. [6] – Әмма баштан ук, һәммә нәрсә
яратылганда, Аллаһы «аларны ир һәм хатын итеп бар итте.
[7] Шуңа күрә ир кеше, атасын һәм анасын калдырып, хатыны-
на кушылыр [8] һәм икесе дә бер тән булыр». Димәк, алар инде
ике кеше түгел, ә бер бөтен. [9] Аллаһы кушылдырганны кеше
аермасын.
[10] Өйдә вакытта шәкертләре бу хакта кабат Гайсәдән сора-
дылар.

---

* **9:44** Кайбер кулъязмаларда 44 нче һәм 46 нчы аятьләр дә бар: «Анда кешеләрне бертуктаусыз кортлар ашап тора һәм ут сүнми».
** **9:46** 44 нче аятьнең искәрмәсен карагыз.

[11] – Ир кеше, хатыны белән аерылышып, башкага өйләнә
икән, ул чакта хатынына каршы зина кыла, – диде Гайсә. –
[12] Шулай ук, хатын кеше дә, иреннән аерылып, башкага кияүгә
чыкса, иренә каршы зина кыла.

*Гайсә балаларга фатиха бирә*

[13] Фатихалау өчен кулларын куйсын дип, Гайсә янына кеше-
ләр балаларны алып килделәр, шәкертләре исә аларны шел-
тәләделәр. [14] Моны күреп, Гайсәнең ачуы килде һәм Ул шә-
кертләренә әйтте:

– Балаларга Минем янга килергә ирек бирегез, аларга кома-
чауламагыз, чөнки Аллаһы Патшалыгы менә шундыйларныкы.
[15] Сезгә хак сүз әйтәм, Аллаһы Патшалыгын балалар кебек кабул
итмәгән кеше анда кермәячәк.

[16] Һәм Ул балаларны кочаклап, өсләренә кулларын куеп,
аларны фатихалады.

*Гайсә һәм бер бай*

[17] Гайсә юлга чыккач, янына бер кеше йөгереп килде һәм
Аның каршында тез чүгеп сорады:

– Игелекле Остаз, мәңгелек тормышны мирас итеп алу өчен
миңа нәрсә эшләргә кирәк?

[18] – Ни өчен син Мине игелекле дип атыйсың? – диде Гай-
сә. – Бары тик Аллаһы гына игелекле. [19] Аның әмерләрен син
беләсең: кеше үтермә, зина кылма, урлама, ялган шаһитлек
итмә, ялганлама, атаңны һәм анаңны хөрмәт ит.

[20] – Остаз, мин боларның барысын да яшьтән үк үтәп кил-
дем, – дип җавап бирде тегесе.

[21] Гайсә аңа карады һәм ул Аның күңеленә хуш килде. Ул аңа
әйтте:

– Сиңа тик бер нәрсә җитми. Бар һәм нәрсәң бар, шуны
сатып, фәкыйрьләргә өләш. Шулай эшләсәң, күктәге хәзинәгә
ия булырсың. Аннары яныма кил дә Миңа ияр.

[22] Егет исә, бу сүзләрне ишетеп, борчуга төште һәм китеп
барды. Чөнки ул бик бай кеше иде.

[23] Гайсә исә, як-ягына карап, шәкертләренә әйтте:

– Байлыгы булганнарга Аллаһы Патшалыгына керү ничек
кыен!

[24] Аның бу сүзләре шәкертләрен бик тә гаҗәпләндерде. Әмма
Гайсә кабатлап әйтте:

– Дусларым! Аллаһы Патшалыгына керү ничек кыен! [25] Бай
кешегә Аллаһы Патшалыгына керүгә караганда, дөягә энә күзе
аша үтү җиңелрәк.

26 Алар, гаҗәпләнеп, үзара сөйләштеләр:
– Алай булгач, кем генә котыла алыр соң?
27 Гайсә аларга карап:
– Кешеләргә бу мөмкин түгел, әмма Аллаһыга мөмкин. Аллаһыга һәр нәрсә мөмкин, – дип әйтте.
28 Шуннан соң Петер:
– Менә без, бөтен нәрсәбезне калдырып, Сиңа иярдек, – диде.
29 – Сезгә хак сүз әйтәм: йортын яки агай-энеләрен яки
апа-сеңелләрен яки ата-аналарын яки балаларын яки басула-
рын Минем хакка һәм Яхшы хәбәр хакына калдырган һәркем
30 хәзерге вакытта йөз тапкыр күбрәк йортлар, агай-энеләр,
апа-сеңелләр, аналар, балалар, басулар һәм, әлбәттә, эзәрлек-
ләүләр дә алачак. Ә инде киләчәк дөньяда мәңгелек тормышка
ия булачак. 31 Әмма беренче булганнарның күбесе ахыргы бу-
лырлар, ә ахыргылары исә беренче булырлар.

*Гайсә янә Үзенең үлеме хакында әйтә*

32 Алар Иерусалимга бара торган юлдан баралар иде. Гайсә алда барды, шәкертләре хәйран калган хәлдә, ә артларыннан баручылар куркынган хәлдә иделәр. Гайсә унике шәкертен читкә чакырып, Үзе белән нәрсә буласы хакында сөйли башлады.
33 – Без Иерусалимга барабыз. Адәм Улы баш руханилар һәм
канунчылар кулына тотып биреләчәк. Алар Аны үлемгә хөкем
итеп, Аны мәҗүсиләр кулына тапшырачаклар. 34 Тегеләре, мыс-
кыллап, Аңа төкереп, камчылаячаклар һәм Аны үтерәчәкләр.
Әмма Ул, өч көн үткәч, үледән терелеп торачак.

*Гайсә һәм Зебедәй уллары*

35 Гайсә янына Зебедәй уллары – Ягъкуб белән Яхья килеп:
– Остаз, без сораганны үтәсәң иде, – диделәр.
36 – Сезнең өчен Мин нәрсә эшләргә тиеш соң? – дип сорады Ул.
37 Алар җавап бирделәр:
– Дан патшалыгында безгә Синең белән янәшә утырырга рөхсәт бирсәң иде – беребезгә уң ягында, икенчебезгә исә сул ягында.
38 – Сез нәрсә сораганыгызны белмисез, – диде Гайсә. – Мин эчә торган касәдән эчә алырсызмы, яки Мин чумдырыла торган чумдырылу белән чумдырыла алырсызмы?
39 – Алырбыз, – дип җавап бирделәр алар.
Шуннан соң Гайсә аларга әйтте:

– Сез Мин эчә торган касәдән эчәрсез, Мин чумдырыла
торган чумдырылу белән чумдырылырсыз. 40 Ә инде Минем уң
ягымда яки сул ягымда утырырга рөхсәт бирү Минем кулда
түгел. Анда кемгә билгеләнгән булса, шулар утырырлар.
41 Бу хакта ишеткәч, калган ун шәкертнең ачулары чыкты.
42 Әмма Гайсә аларны чакырып алып әйтте:
– Сез беләсез: халык җитәкчеләре дип исәпләнгәннәр ха-
лыклар өстеннән хакимлек итәләр. Бөекләр халыкларны үз
куллары астында тота. 43 Ләкин сездә алай булмасын: сезнең
арагызда бөек булырга теләүче башкаларга хезмәтче булсын.
44 Һәм арагызда беренче булырга теләүче барыгыз өчен дә кол
булсын. 45 Адәм Улы да бит Үзенә хезмәт итсеннәр өчен дип
килмәде, ә Үзе хезмәт итеп, күпләрне йолып алу өчен Үзенең
тормышын бирергә дип килде.

*Гайсә сукыр Бартимәйне савыктыра*

46 Алар Әрихә шәһәренә килеп җиттеләр. Гайсә Әрихәдән
шәкертләре һәм күп санлы халык белән чыгып барганда, юл
читендә сукыр фәкыйрь Бартимәй (ягъни, Тимәй улы) теләнеп
утыра иде. 47 Насаралы Гайсәнең үтеп баруы хакында ишетеп,
ул кычкырып җибәрде:
– Давыт Улы Гайсә! Кызган мине!
48 Күпләре аның эндәшмәвен таләп иттеләр, әмма сукыр та-
гын да көр тавыш белән кычкырды:
– Давыт Улы, кызган мине!
49 Гайсә баруыннан тукталып әйтте:
– Чакырыгыз аны!
– Курыкма, Ул сине чакыра, – дип сукырны чакырдылар.
50 Бартимәй исә, өс киемен салып ташлап, сикереп торды да
Гайсә янына йөгереп килде.
51 – Синең өчен нәрсә эшләвемне телисең? – дип сорады
аннан Гайсә.
– Остаз, күзләрем күрсен иде! – диде сукыр кеше.
52 – Бар, сине ышануың савыктырды, – диде Гайсә.
Ул шунда ук күрә башлады һәм Гайсәгә ияреп китте.

*Гайсәнең Иерусалимга тантана белән керүе*

**11** 1 Алар Иерусалимга якынлашканда, инде Бәйтфәгидән
һәм Бәйтәниядән ерак түгел, Зәйтүн тавы янында Гайсә
ике шәкертен чакырып, 2 аларга әйтте:
– Алда күренгән авылга барыгыз. Анда керү белән бәйдә-
ге, һичкем атланмаган яшь ишәкне күрерсез. Аны бәйдән ыч-
кындырып, монда алып килегез. 3 Әгәр берәрсе: «Сез нәрсә

эшлисез?» – дип сораса: «Ул Хуҗага кирәк, Ул аны тиздән кайтарып бирер», – дип җавап бирегез.

4 Алар барып, тыкрыкта ишек янына бәйләп куелган яшь ишәкне табып, аны чишә башладылар. 5 Анда булган кешеләр алардан:

– Сез ни эшлисез? Ни өчен ишәкне бәйдән ычкындырасыз? – дип сорадылар.

6 Әмма Гайсә кушканча җавап кайтаргач, аларны җибәрделәр.
7 Ишәкне Гайсә янына китереп, өс киемнәрен ишәк өстенә салдылар һәм Гайсә аңа атланды. 8 Халыкның күбесе өс киемнәрен юл өстенә җәйделәр, ә башкалары исә, кырдагы агачларның ботакларын кисеп түшәделәр. 9 Һәм алда баручылар да, арттагылары да кычкырдылар:

– Һошанна*!
Раббы исеме белән Килүче мөбарәк!
10 Атабыз Давытның киләчәк патшалыгы мөбарәк!
Югарыда Һошанна!

11 Гайсә, Иерусалимга кереп, Аллаһы Йортына юнәлде. Барын да карап чыккач, инде соң булганга, унике шәкерте белән бергә Бәйтфәгигә әйләнеп кайтты.

*Аллаһы Йорты – дога кылу йорты*

12 Икенче көнне алар Бәйтфәгидән чыккач, Гайсәнең карыны ачты. 13 Ерактагы инҗир агачын күреп, Ул, җимеше булмасмы дип, аның янына килде, әмма яфрактан башка берни дә тапмады: инҗир өлгерергә әле иртә иде. 14 Гайсә аңа әйтте:

– Синең җимешеңне һичкайчан берәү дә ашамасын!

Шәкертләре исә моны ишетеп тордылар.

15 Алар Иерусалимга килделәр. Аллаһы Йортына керү белән, андагы сатучыларны һәм сатып алучыларны Гайсә куып чыгара башлады, акча алмаштыручыларның өстәлләрен һәм күгәрчен сатучыларның утыргычларын аударып ташлады. 16 Һәм Аллаһы Йорты аша берәүгә дә һичбер әйбер алып үтмәскә кушты.
17 Гайсә аларны өйрәтеп әйтте:

– Изге язмада әйтелмәгәнмени: «Минем Йортым барча халыклар өчен дога кылу йорты дип аталыр», – дип? Ә сез аны юлбасарлар оясына әйләндергәнсез!

18 Бу хакта баш руханилар һәм канунчылар ишеткәч, алар Гайсәне һәлак итү әмәлен табарга тырыша башладылар. Чөнки

---

* 11:9 *Һошанна* – яһүд телендә «ярдәм ит» яки «Аллаһыга дан» дигәнне аңлата.

бөтен халык Аның өйрәтүен таң калып тыңлаганга күрә, алар
Аннан курыктылар.
[19] Кич җиткәч, Гайсә шәкертләре белән шәһәрдән китте.

*Корып төшкән инҗир агачы*

[20] Икенче көнне иртә белән инҗир агачы яныннан үтеп
барганда, алар аның очыннан алып, тамырына тикле корып
төшкәнен күрделәр. [21] Петер исә, кичәгесен ни булганын исенә
төшереп, Гайсәгә әйтте:
– Остаз! Кара әле, Син каргаган инҗир агачы корып төшкән!
[22] Гайсә аларга җавап бирде:
– Аллаһыга ышаныгыз! [23] Сезгә хак сүз әйтәм: әгәр кем дә
кем бу тауга: «Күтәрелеп, диңгезгә ташлан!» – дип әйтсә, һәм
күңеленнән һич тә шикләнмичә әйткән сүзләренең үтәләчә-
генә ышанса, шулай булачак. [24] Шуңа күрә Мин сезгә әйтәм:
сез Аллаһыдан нәрсә генә үтенеп сорасагыз да, алганыгызга
ышаныгыз, һәм сез алачаксыз да! [25] Һәм дога кылып торган
чакта, берәрсенә карата үпкәгез булса, Күктәге Атагыз сез-
нең гөнаһларыгызны кичерсен өчен, үзегез дә һәммәсен ки-
черегез. [ [26] ]*

*Гайсәнең вәкаләте кемнән?*

[27] Алар тагын Иерусалимга килделәр. Гайсә Аллаһы Йор-
тының ишегалдысы буйлап йөргән чакта, Аның янына баш
руханилар, канунчылар һәм аксакаллар килделәр.
[28] – Синең боларны эшләргә нинди хокукың бар? Боларны
эшләргә Сиңа кем вәкаләт бирде? – дип сорадылар алар.
[29] – Мин сезгә бер сорау бирәм, – диде Гайсә. – Әгәр сез
җавап бирсәгез, Мин дә боларны нинди вәкаләт белән эшлә-
вемне әйтермен. [30] Яхъяның суга чумдыруы күктән идеме яки
кешеләрдәнме? Җавап бирегез!
[31] Алар үзара:
– Әгәр: «Аллаһыдан», – дип әйтсәк, ул чакта Ул: «Ә ни өчен
сез аңа ышанмадыгыз?» – дип әйтер. [32] «Кешеләрдән», – дип
әйтергәме әллә? – диештеләр.
Барча халык төркеме Яхъяны пәйгамбәр дип исәпләгәнгә
күрә, халыктан курыктылар. [33] Шуңа күрә:
– Белмибез, – дип җавап кайтардылар.
– Алай булгач, Мин дә сезгә боларны нинди вәкаләт белән
эшләвемне әйтмим, – дип җавап бирде Гайсә.

---

* **11:26** Кайбер кулъязмаларда 26 нчы аять тә бар: «Ә инде кичермә-
сәгез, Күктәге Атагыз да сезнең гөнаһларыгызны кичермәс».

### *Йөзем үстерүче явызлар хакында гыйбрәтле хикәя*

12 [1] Гайсә аларга гыйбрәтле хикәя сөйли башлады.
– Бер кеше йөзем бакчасы утырткан, аны койма белән әйләндереп алганнан соң, чокыр казып, йөзем изү өчен махсус урын әзерләгән. Бакчаны саклау өчен манара торгызган һәм йөзем үстерүчеләргә бакчасын куллану өчен биреп, үзе чит якларга китеп барган.
[2] Уңыш җыяр вакыт җиткәч, йөзем бакчасыннан үз өлешен алырга дип, үзенең хезмәтчесен җибәргән.
[3] Ә тегеләре исә, аны тотып кыйнаганнар һәм буш кул белән кайтарып җибәргәннәр.
[4] Инде икенче хезмәтчесен җибәргән. Ләкин аның башын яралаганнар, мыскыл иткәннәр.
[5] Тагын берсен җибәргән – аны үтергәннәр. Башкаларын да җибәреп караган: кайсысын кыйнаганнар, кайсысын үтергәннәр.
[6] Аның иң соңгы бер генә кешесе – сөекле улы калган. Һәм: «Минем улымны хөрмәт итәрләр», – дип уйлап, аны җибәргән.
[7] Әмма йөзем үстерүчеләр үзара: «Бу – варис. Әйдәгез, аны үтерик, һәм аңа каласы мирас безнеке булыр», – дип сөйләшкәннәр.
[8] Алар аны тотып үтергәннәр һәм йөзем бакчасыннан чыгарып ташлаганнар.

[9] Инде йөзем бакчасының хуҗасы нәрсә эшләр? Ул, әйләнеп кайткач, йөзем үстерүчеләрне үтерер һәм йөзем бакчасын башкаларга бирер.
[10-11] Изге язмада:

«Төзүчеләр яраксыз дип кире каккан таш
иң мөһим почмак ташы булды.
Бу Раббы тарафыннан эшләнде
һәм безнең алда гаҗәп нәрсә», –

дигәнне әллә сез укымадыгызмы?

[12] Гыйбрәтле хикәянең үзләре турында икәнен аңлап, яһүд башлыклары Гайсәне кулга алырга теләделәр, әмма халыктан курыктылар. Шуңа күрә алар Аны калдырып китеп бардылар.

### *Кайсарга салым түләү хакында сорау*

[13] Аннан соң Гайсә янына, Ул берәр бәйләнерлек сүз әйтмәсме дип, фарисейләрне һәм Һируд тарафдарларын җибәрделәр.
[14] Алар килеп әйттеләр:
– Остаз! Синең дөрес Кеше булуыңны без беләбез. Кешеләрнең Синең хакта нәрсә уйлаганнары Сиңа мөһим түгел. Кешенең иҗтимагый торышына игътибар итмисең, әмма Аллаһы юлына хакыйкать буенча өйрәтәсең. Әйтче, кайсарга* салым

---

* **12:14** *Кайсар* – борынгы Рим императорының рәсми исемнәреннән берсе.

түләүне канун рөхсәт итәме, әллә юкмы? Безгә түләргәме соң, әллә түләмәскәме?

[15] Аларның икейөзлеләнүләрен белеп, Гайсә әйтте:

– Сез нигә Мине сынныйсыз? Миңа динар күрсәтегез әле!

[16] Аңа динар бирделәр һәм Гайсә алардан сорады:

– Монда кемнең сурәте һәм кемнең исеме?

– Кайсарныкы, – дип җавап бирделәр алар.

[17] Һәм Гайсә аларга әйтте:

– Кайсарныкын кайсарга, ә Аллаһыныкын Аллаһыга бирегез.

Аның бу җавабына алар таң калдылар.

*Үледән терелү турында сорау*

[18] Гайсә янына үлеләрнең терелүен инкяр итүче саддукейлар* килде һәм Аннан менә нәрсә хакында сорадылар:

[19] – Остаз! Муса канунында безгә: «Әгәр берәүнең бертуганы бала тудырмаган килеш үлеп китеп, хатыны калса, ул бу тол хатынны үзенә алсын һәм үлгән бертуганның буынын дәвам иттерсен», – дип язган. [20] Җиде бертуган булган. Беренчесе өйләнгән һәм баласы булмыйча үлеп киткән. [21] Аның хатынын икенче туганы үзенә алган, ләкин бала булдырмыйча үлеп киткән. Өченчесе белән дә нәкъ шулай булган. [22] Җиде агай-эне арасында берсе дә токым калдыра алмаган. Барысыннан соң хатын үзе дә үлеп киткән. [23] Үлеләр терелгән вакытта, ул хатын аларның кайсысының хатыны булачак? Җидесе дә аның ире булган бит!

[24] – Сез ничек ялгышасыз! – диде аларга Гайсә. – Беләсезме, ни өчен алай? Чөнки сез Изге язманы да, Аллаһы кодрәтен дә белмисез. [25] Үлгәннәр терелеп торганда, алар өйләнмәячәкләр дә, кияүгә дә чыкмаячаклар. Алар күктәге фәрештәләрдәй булачаклар. [26] Ә инде үлгәннәрнең терелеп тору мәсьәләсенә кагылсак, Муса китабының янып торган күгән агачы хакындагы өлешендә Аллаһының: «Мин – Ибраһим Аллаһысы, Исхак Аллаһысы һәм Ягъкуб Аллаһысы», – дигәнен укымадыгызмыни? [27] Аллаһы – үлеләр Аллаһысы түгел, бәлки тереләр Аллаһысы. Сез бик тә ялгышасыз.

*Иң мөһим әмер*

[28] Аларның бәхәсләшүләрен ишетеп һәм Гайсәнең аларга яхшы итеп җавап бирүен күреп, бер канунчы Аның янына килеп:

– Әмерләрнең кайсысы иң мөһим? – дип сорады.

[29] – Иң мөһим әмер, – дип җавап бирде Гайсә, – «Тыңла, Исраил! Раббы Аллаһыбыз – бердәнбер Раббы! [30] Раббы Аллаһыңны

* 12:18 *Саддукейлар* – яһүдләрнең йолаларын тотучы дини төркем.

бөтен йөрәгең, бөтен җаның, бөтен акылың һәм бөтен көчең
белән ярат». 31 Ә менә икенчесе: «Якыныңны үзеңне яраткан
кебек ярат». Бу әмерләрдән дә бөегрәге юк.

32 – Яхшы әйттен, Остаз, – диде канунчы. – «Аллаһы бердән-
бер һәм Аннан башка илаһ юк», – дип Син дөрес итеп әйттең.
33 «Аны бөтен йөрәгең, бөтен уйларың һәм бөтен көчең белән
ярату» һәм «Якыныңны үзеңне яраткан кебек ярату» бөтен
корбан итеп чалынган хайваннардан да һәм корбан итеп янды-
рылган бүләкләрдән дә мөһимрәк.

34 Аның акыл белән җавап бирүен күреп, Гайсә әйтте:

– Син Аллаһы Патшалыгыннан ерак түгелсең.

Моннан соң бер кеше дә Гайсәдән нәрсә дә булса сорарга батырчылык итмәде.

35 Аллаһы Йортында өйрәткәндә Гайсә әйтте:

– Мәсихне Давыт Улы дип канунчылар ничек әйтә алалар?
36 Изге Рух белән илһамланып, Давыт үзе:

«Раббы Аллаһы минем Раббыма әйтте:
Мин дошманнарыңны салганчы
Синең аякларың астына,
Утыр Минем уң ягымда», –

дип әйткән бит. 37 Давыт үзе Аны «Раббым» дип атый. Шулай
булгач, ничек итеп Ул аның Улы була ала?

Күп халык Аны хозурлык белән тыңлады. 38-39 Халыкка нә-
сыйхәт биреп, Гайсә әйтте:

– Канунчылардан сакланыгыз. Алар озын киемнәр киеп йөрүне, җыелыш мәйданнарында үзләрен ихтирам итеп сәламләүне, гыйбадәтханәләрдә иң яхшы урыннарда утыруны,
мәҗлесләрдә иң түрдә утыруны яраталар. 40 Алар хәйләләп, тол
хатыннарның йортларын үзләренә алалар, кешеләр күрсен дип, озак итеп дога кылалар. Мондыйлар тагын да катырак хөкемгә тартылачаклар.

*Тол хатын бүләге*

41 Гайсә, сәдака сандыгы янына утырган килеш, халык-
ның акча салуын күзәтеп торды. Байларның күбесе күп итеп
салды. 42 Шунда бер фәкыйрь тол хатын килеп, ике вак акча
(бер кодрант*) салды. 43 Гайсә, шәкертләрен чакырып, аларга
әйтте:

– Сезгә хак сүз әйтәм: бу фәкыйрь тол хатын акча салган
кешеләрнең барысына караганда да күбрәк салды. 44 Сәдака

---

* 12:42 *Кодрант* – римлыларның акча берәмлеге. 64 кодрант бер динарга тигез булган.

сандыгына салучыларның барысы да үзләреннән артканын
салдылар, ә ул, фәкыйрь була торып, үзендә булганнарның
барысын, яшәү өчен кирәк булганнарның бөтенесен дә салды.

*Ахыр заман билгеләре*

**13** [1] Гайсә Аллаһы Йортыннан чыгып барганда, шәкертлә-
ренең берсе Аңа әйтте:
– Остаз! Кара әле, нинди зур ташлар, нинди матур
биналар!
[2] – Син бу зур биналарны күреп, таң калдыңмы? – диде
Гайсә. – Монда таш өстендә таш калмаячак, барысы да җиме-
реләчәк!
[3] Гайсә Зәйтүн тавында Аллаһы Йорты каршында утырган
чакта, Петер, Ягъкуб, Яхъя, Әндри Аның белән берүзләре
калгач, сорадылар:
[4] – Безгә әйтче, бу хәлләр кайчан булачак? Боларның тиздән
гамәлгә ашачагын нинди билге аша беләчәкбез?
[5] Гайсә әйтте:
– Сак булыгыз, сезне алдамасыннар! [6] Күпләр, Минем исе-
мем белән килеп: «Мин – Ул», – дип әйтерләр һәм күпләрне
алдарлар. [7] Сез якындагы сугышлар тавышын һәм ерактагы
сугышлар хакында хәбәрләр ишеткәндә, курыкмагыз! Шулай
булырга тиеш тә. Әмма бу әле ахыры түгел. [8] Халык халыкка,
патшалык патшалыкка каршы чыгар, урыны-урыны белән җир
тетрәүләр, ачлык булыр. Болар – тулгак тоту газапларының
башлануы гына.
[9] Сез исә әзер торыгыз: сезне, мәхкәмәләргә тапшырып, хө-
кем итәрләр һәм гыйбадәтханәләрдә кыйнарлар. Сез Минем
аркада, Минем хакта шаһитлек бирү өчен, патшалар һәм ида-
рәчеләр каршына басарсыз. [10] Әмма ахыры килеп җиткәнче,
бөтен халыкларга да Яхшы хәбәр таратылырга тиеш. [11] Сезне
хөкемгә тапшыру өчен алып барганда исә, нәрсә әйтербез, дип
хафаланмагыз: шул сәгатьтә сезгә нәрсә бирелсә, шуны сөйлә-
гез. Сез үзегез түгел, ә Аллаһы Рухы сөйләр. [12] Туган туганны,
ата үзенең баласын үлемгә тапшырыр, ә балалар, ата-аналары-
на каршы чыгып, аларны үтертерләр. [13] Минем өчен барысы да
сезне нәфрәт итәр. Әмма ахырга тикле чыдаган кеше котылыр.
[14] Әмма сез «ташландык хәлдә калдыручы чирканыч нәрсә-
нең» торырга тиеш түгел урында булуын күргәч (бу сүзләрне
укыган кеше аңласын), Яһүдия җирендә булганнар тауга кач-
сыннар. [15] Өй түбәсендә булганнар, әйберләрен алырга дип, өй-
гә төшеп тормасын, [16] кырда булганнар өс киемнәрен алырга
өйләренә кайтмасыннар. [17] Ул көннәрдә йөкле хатыннарга һәм

бала имезүчеләргә кайгы! [18] Болар кышка туры килмәсен иде
дип, дога кылыгыз. [19] Ул көннәрдә иң баштан ук, Аллаһы дөнь-
яны булдырган көннән алып, бүгенге көнгә кадәр булмаган
һәм булмаячак афәт килер. [20] Әгәр Раббы ул көннәрне кыс-
картмаса, һичкем исән кала алмас иде. Әмма Үзе сайлаган ке-
шеләре хакына Раббы ул көннәрне кыскартты.
[21] Әгәр сезгә шул вакытта: «Кара, Мәсих менә монда!» яки «Ул
анда!» – дип әйтсәләр, ышанмагыз! [22] Чөнки ялган мәсихләр һәм
ялган пәйгамбәрләр килерләр, әгәр килеп чыкса, сайланганнар-
ны алдау өчен, галәмәтләр һәм могҗизалар күрсәтерләр. [23] Әмма
сез сак булыгыз – барысы хакында Мин сезгә алдан әйттем.
[24] Ләкин ул көннәрдә, афәттән соң,
«Кояш каралыр,
ай яктыртмас,
[25] Күкләрдән йолдызлар коелыр һәм
күк кодрәтләре селкетелер»,
[26] шунда бөек кодрәт һәм балкып торган дан белән болытларда
килүче Адәм Улын күрерләр. [27] Шул вакыт Ул, фәрештәләрне
җибәреп, җирнең дүрт почмагыннан, җир читеннән алып күккә
кадәр Үзе сайлаганнарны җыяр.
[28] Инҗир агачыннан гыйбрәт алыгыз. Аның ботаклары, бөре-
ләнеп, яфрак ярган чакта, сез тиздән җәйнең җитәчәген белә-
сез. [29] Монда да нәкъ шулай: боларның гамәлгә ашуын күргәндә,
шуны белерсез: ул вакыт якын*, инде ишек төбендә! [30] Сезгә
хак сүз әйтәм: бу буын алышынырга өлгермәс, болар һәммәсе
дә гамәлгә ашыр. [31] Күк һәм җир юкка чыгачак, әмма Минем
сүзләрем һичкайчан юкка чыкмаячак.

*Көне һәм сәгате билгесез*

[32] Ул көннең һәм сәгатьнең кайчан булуы хакында һичкем
белми: күктәге фәрештәләр дә, Угыл да. Бу турыда бары тик
Ата гына белә. [33] Карагыз аны, уяу булыгыз! Вакыты кайчан
җитәчәген сез белмисез. [34] Юлга чыккан кеше үзенең йортын
хезмәтчеләренә калдырып, аларның һәркайсына аерым эш ку-
шып, капка сакчысына уяу торырга боера. [35] Шуңа күрә сез уяу
булыгыз! Йорт хуҗасының кайчан әйләнеп кайтуын белмисез
бит: кич беләнме, төн уртасындамы, тәүге әтәч кычкыргандa-
мы, яисә иртәгесенме. [36] Көтмәгәндә кайтып, ул сезне йокла-
ган килеш тапмасын! [37] Мин сезгә әйткәннәремне кешеләрнең
барысына да әйтәм: уяу булыгыз!

---

* **13:29** *Ул вакыт якын* – грекча сүзгә-сүз: «ул якын». Моны болай да аңлау мөмкинлеге бар: «Ул, димәк, Адәм Улы, озакламый киләчәк».

### *Гайсәне Бәйтәниядә майлау*

**14** [1] Ике көннән соң Коткарылу һәм Төче күмәч бәйрәме
буласы иде. Баш руханилар һәм канунчылар Гайсәне
хәйлә белән кулга алып, үтерү әмәлен эзләделәр. [2] «Ха-
лык арасында фетнә килеп чыкмасын өчен, бәйрәм вакытында
булмасын», – диделәр алар.
[3] Гайсә Бәйтәниядә махаулы Шимунның өендә ашап утыр-
ган чакта, бер хатын алебастр* савытка салынган бик кыйм-
мәтле саф хуш исле нард мае алып килеп, савытын ватып,
майны Аның башына койды. [4] Кайберләре ачуланып, үзара әй-
тештеләр:
– Бу майны нигә алай әрәм итәргә? [5] Аны өч йөздән артык
динарга сатып, акчасын фәкыйрьләргә өләшергә була иде бит!
Һәм алар аны шелтәләделәр.
[6] Әмма Гайсә әйтте:
– Калдырыгыз аны, ник аны борчыйсыз? Ул Минем өчен
яхшы эш эшләде. [7] Фәкыйрьләр һәрвакыт сезнең белән бар һәм
сез аларга теләгән вакытыгызда яхшылык күрсәтә алырсыз, ә
Мин сезнең белән һәрвакыт булмам. [8] Ул хәленнән килгәнен
эшләде: Минем тәнемне алдан майлап, күмәргә әзерләде.
[9] Сезгә хак сүз әйтәм: Яхшы хәбәр дөньяның кайсы гына поч-
магында таратылмасын, бу хатынны искә алып, аның нәрсә
эшләгәне хакында сөйләячәкләр.

### *Яһүднең Гайсәгә хыянәт итүе*

[10] Шунда Яһүд Искариот, унике шәкертнең берсе, Гайсәгә
хыянәт итәргә ниятләп, баш руханилар янына барды. [11] Алар
аны тыңлагач, шатланышып, аңа акча бирергә сүз куештылар.
Һәм ул Гайсәне аларның кулына тапшырырга уңай очрак эзли
башлады.

### *Коткарылу бәйрәме ашы*

[12] Төче күмәч бәйрәменең беренче көнендә, Коткарылу бәрә-
нен чала торган көндә Гайсәдән шәкертләре сорадылар:
– Коткарылу бәйрәме ашын Синең өчен кая барып әзерлә-
вебезне телисең?
[13] Ул, ике шәкертен җибәреп, аларга әйтте:
– Шәһәргә барыгыз. Сезгә су чүлмәге күтәреп кайтучы кеше
очрар. Аның артыннан барыгыз [14] һәм ул кергән өйнең хуҗа-
сына: «Остаз синнән: „Шәкертләрем белән Коткарылу бәйрәме

---

* 14:3 *Алебастр* – савытлар ясау өчен кулланылган йомшак таш.

ашын кайсы бүлмәдә ашыйк?“ – дип сорый», – дип әйтегез.
15 Ул сезгә өске катта бәйрәм өчен җиһазланган әзер бүлмәне
күрсәтер. Шунда безнең өчен ашарга әзерләгез.
16 Шәкертләре, шәһәргә килеп, барын да Гайсә әйткәнчә дип
таптылар һәм бәйрәм ашын әзерләделәр.
17 Кич җиткәч, Гайсә унике шәкерте белән бергә килде.
18 Алар ашап утырганда, Гайсә әйтте:
– Мин сезгә хак сүз әйтәм: сезнең арагыздан берәү – Минем
белән ашап утыручыларның берсе – Миңа хыянәт итәчәк.
19 Шәкертләре хафага төшеп, берсе артыннан берсе сорый
башладылар:
– Мин түгелдер бит?
20 Ул аларга җавап бирде:
– Ул – Минем белән бергә бер савытта икмәк манучы унике
шәкертнең берсе. 21 Әйе, Изге язмада язылганча, Адәм Улы ки-
тә. Әмма Адәм Улына хыянәт итүчегә кайгы! Ул кеше бөтенләй
дә тумаган булса, аның өчен яхшырак булыр иде!
22 Алар ашаган чакта, Гайсә, икмәк алып, Аллаһыга шөкрана
итте һәм аны, сындырып, шәкертләренә бирде.
– Алыгыз, бу – Минем тәнем, – диде Ул.
23 Касәне алып, Ул Аллаһыга шөкрана итте һәм аларга бирде.
Барысы да аннан эчтеләр. 24 Ул аларга әйтте:
– Бу – күпләр өчен түгелә торган Минем каным. Ул – Алла-
һы килешүен раслый торган кан. 25 Сезгә хак сүз әйтәм: Аллаһы
Патшалыгында яңа шәраб эчәчәк көн җитми торып, Мин инде
йөзем җимеше шәрабын эчмәячәкмен.
26 Алар, мәдхия җырлаганнан соң, Зәйтүн тавына киттеләр.
27 Гайсә аларга әйтте:
– Сез барыгыз да, Изге язмада:
«Көтүчене һәлак итәрмен
һәм сарыклар таралышырлар», –
дип язылганча, ышанычыгызны югалтачаксыз. 28 Әмма Мине
үледән терелтеп торгызылганнан соң, сез Гәлиләягә килгәнче,
Мин анда булырмын.
29 – Барысы ышанычларын югалтсалар да, мин югалтмам, –
дип каршы төште Петер.
30 – Сиңа хак сүз әйтәм: бүген төнлә белән әтәч ике тапкыр
кычкырганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичәчәксең, – диде
аңа Гайсә.
31 Петер тагын раслап әйтте:
– Синең белән үләргә туры килсә дә Синнән һичкайчан ваз
кичмәячәкмен!
Башкалары да шулай диделәр.

*Гайсә Гетсимәни бакчасында дога кыла*

[32] Алар Гетсимәни дип аталган урынга килделәр. Гайсә шә-
кертләренә әйтте:
– Мин дога кылган вакытта монда утырып торыгыз.
[33] Ул Үзе белән Петерне, Ягъкубны, Яхъяны алды. Гайсәне
авыр кичереш һәм тойгылар биләп алды. [34] Гайсә аларга әйтте:
– Минем җаным чиктән тыш газап кичерә, монда көтегез
һәм уяу булыгыз!
[35] Ул читкәрәк китте һәм, җиргә егылып, мөмкин булса, га-
заплар сәгате Үзеннән үтеп китсен иде дип, дога кылды.
[36] – Абба*, Әти! Сиңа бар нәрсә мөмкин! Миннән бу газап-
лар касәсен кире алчы! Әмма Мин теләгәнчә түгел, ә Синең
ихтыярың буенча булсын!
[37] Гайсә әйләнеп килгәндә, өч шәкерте йоклый иде.
– Шимун, син йоклап ятасыңмы? Йокламыйча бер сәгать тә
тора алмадыңмы? – диде Ул Петергә. – [38] Вәсвәсәгә дучар бул-
мас өчен, дога кылыгыз. Рух көчле, ә тән хәлсез!
[39] Гайсә тагын читкә китеп һәм шул ук сүзләрне әйтеп дога
кылды. [40] Әйләнеп килгәч, аларның тагын йоклауларын күрде:
аларның күзләрен йокы баскан иде. Алар Гайсәгә нәрсә әйтер-
гә дә белмәделәр.
[41] Өченче тапкыр әйләнеп килеп, Ул әйтте:
– Сез һаман йоклыйсызмы, ял итәсезме? Җиткәндер! Вакыт
җитте: менә Адәм Улы гөнаһлылар кулына тапшырыла. [42] То-
рыгыз, киттек! Карагыз, Миңа хыянәт итүче килә.

*Гайсәне кулга алу*

[43] Ул әле әйтеп тә бетермәде, унике шәкертнең берсе – Яһүд
килеп чыкты. Аның белән бергә баш руханилар, канунчылар
һәм аксакаллар җибәргән халык төркеме кылычлар һәм чук-
марлар күтәреп килде. [44] Хыянәтче: «Мин кемне үпсәм, шул
Гайсә булыр. Аны кулга алып, ышанычлы сак астында алып
китегез», – дип, алар белән алдан ук сүз куешкан иде.
[45] Яһүд шунда ук Гайсә янына килде.
– Остаз! – диде ул һәм Гайсәне үбеп алды.
[46] Гайсәне шунда ук кулга алып, сак астына куйдылар. [47] Янә-
шә торучыларның берсе, кылычын чыгарып, иң баш рухани
хезмәтчесенә селтәнеп, аның колагын чабып өзде. [48] Гайсә әйтте:
– Юлбасар тотарга чыккан кебек, сез Мине тотарга кылычлар
һәм чукмарлар күтәреп килгәнсез! [49] Мин һәр көнне Аллаһы

* 14:36 *Абба* – арамей телендә «Әти» дигән мәгънәне аңлата.

Йортында өйрәткәндә сез дә анда идегез, һәм сез Мине кулга алмадыгыз. Әмма Изге язмаларда язылганнар тормышка ашсын!

50 Шул вакыт барлык шәкертләре Гайсәне калдырып, качып киттеләр.

51 Ниндидер бер егет, шәрә тәненә җитен япма бөркәнгән
килеш, алар артыннан барды. Аны тотып алдылар, 52 әмма ул,
киемен тегеләрнең кулларында калдырып, шәрә килеш качып
китте.

*Гайсә Югары киңәшмә каршында*

53 Гайсәне иң баш рухани янына алып килделәр. Анда барлык
баш руханилар, аксакаллар һәм канунчылар җыелдылар. 54 Петер
исә, алардан арттарак калып, иң баш руханиның ишегалдына
кадәр Гайсә артыннан барды. Ул анда учак янында хезмәтчеләр белән бергә җылынып утырды. 55 Ә баш руханилар һәм
бөтен Югары киңәшмә, Гайсәне үлемгә тапшыру өчен, Аңа
каршы шаһитлек эзләделәр, әмма таба алмадылар. 56 Күпләр
Аңа каршы ялган шаһитлек бирделәр, әмма аларның күрсәтмәләре туры килмәде.

57 Шул вакытта мондый ялган шаһитлек бирүчеләр табылды:

58 – Аның: «Мин кеше кулы белән салынган бу Аллаһы Йортын җимерәчәкмен һәм өч көндә кеше кулы белән эшләнмәгән башкасын төзиячәкмен», – дип әйткәнен без ишеттек.

59 Әмма аларның бу күрсәтмәләре дә расланмады.

60 Шуннан соң иң баш рухани, алга чыгып, Гайсәдән сорады:

– Үзеңә каршы шаһитлеккә Син берничек тә җавап бирмисеңме?

61 Әмма Гайсә эндәшмәде, бернәрсә җавап бирмәде. Иң баш рухани Аннан тагын сорады:

– Син – Мәсихме, мөбарәк Аллаһының Улымы?

62 – Әйе, Мин, – дип җавап кайтарды Гайсә, – һәм сез Адәм Улының Кодрәт Иясенең уң ягында утыруын һәм күк болытлары белән килүен күрерсез.

63 Шунда иң баш рухани киемнәрен ертып әйтте:

– Нигә безгә тагын шаһитләр кирәк? 64 Көфер сүз сөйләвен
сез үзегез ишеттегез! Сез бу хакта ничек уйлыйсыз?

Барысы да, Ул гаепле һәм үләргә тиеш, дигән хөкем карары чыгардылар.

65 Аларның кайберләре Аны төкерә башладылар, битен каплап, Аны кыйнарга тотындылар.

– Пәйгамбәрлек ит! – диделәр алар.

Шулай ук сакчылар да Аны кыйнады.

### *Петернең Гайсәдән ваз кичүе*

66 Бу вакыт Петер аста, ишегалдында иде. Иң баш руханиның
хезмәтче кызларыннан берсе килеп, 67 учак янында җылынып
утырган Петерне күреп алды һәм аңа текәлеп карап:

– Син дә бит бу насаралы Гайсә белән бергә булдың, – диде.

68 Әмма Петер ваз кичеп әйтте:

– Мин бернәрсә дә белмим, синең нәрсә хакында сөйләгәнеңне аңламыйм!

Һәм тышка, алгы ишегалдына чыгып китте. [Шул вакытта әтәч кычкырды.]*

69 Хезмәтче кыз исә, аны анда күреп алды һәм ишегалдында
булган кешеләргә икенче тапкыр әйтте:

– Бу кеше – аларның берсе.

70 Петер тагын ваз кичте. Бераздан ишегалдында торучылар
әйттеләр:

– Ә син чыннан да аларның берсе. Син дә бит Гәлиләядән.

71 Ул:

– Мин Аны, сез әйткән Кешене, белмим! Әгәр сүзләрем дөрес булмаса, мине каһәр суксын! – дип ант итә башлады.

72 Нәкъ шул вакыт әтәч икенче тапкыр кычкырды. Петер исә
Гайсәнең: «Әтәч ике тапкыр кычкырганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичәчәксең», – дигән сүзләрен исенә төшереп, елый башлады.

### *Гайсә Пилат алдында*

15 1 Баш руханилар, аксакаллар, канунчылар һәм бөтен
Югары киңәшмә, иртәдән үк киңәшләшеп, Гайсәне бәйләделәр һәм Пилатка илтеп тапшырдылар.

2 – Син яһүдләр Патшасымы? – дип сорады Пилат.

– Моны син үзең әйтәсең, – дип җавап бирде Гайсә.

3 Баш руханилар Аны күп нәрсәдә гаепләделәр. 4 Пилат Аннан
тагын сорады:

– Син берничек тә җавап бирмисеңме? Күрәсеңме, Сиңа каршы күпме гаепләүләр!

5 Әмма Гайсә җавап бирмәде һәм моның белән Ул Пилатны
бик нык гаҗәпләндерде.

### *Гайсәнең үлемгә хөкем ителүе*

6 Пилат һәр бәйрәм уңае белән халык сораган тоткынны азат
итә торган иде. 7 Ул чакта чуалыш вакытында кеше үтергән

---

* 14:68 Берничә кулъязмаларда җәяләр эчендәге сүзләр юк.

фетнәчеләр зинданга ябылган иде. Алар арасында Бараб атлы
тоткын да бар иде. [8] Халык, Пилат янына килеп, гадәттәгечә,
берәр тоткынны азат итүен сорый башлады. [9] Пилат аларга
әйтте:

– Сезнең өчен яһүдләр Патшасын азат итүемне телисезме?

[10] Баш руханиларның Гайсәне көнләшү аркасында тотып
биргәннәрен ул аңлый иде.

[11] Әмма баш руханилар халыкны, Барабны азат итүен таләп
итегез дип, котыртып куйган иделәр.

[12] – Ә сез яһүдләр Патшасы дип атаган кеше белән миңа ни
эшләргә? – диде яңадан Пилат.

[13] – Аны хачка кадакла! – дип кычкырдылар алар.

[14] – Әмма ни начарлык эшләгән соң Ул? – диде Пилат.

Ләкин алар тагын да көчлерәк тавыш белән:

– Аны хачка кадакла! – дип кычкырдылар.

[15] Пилат, халыкка ярарга тырышып, Барабны азат итте, Гай-
сәне, камчылаткач, хачка кадаклатырга тапшырды.

*Гайсәне гаскәриләрнең мәсхәрәләве*

[16] Гаскәриләр Аны сарай эченә, ягъни преториумга алып ке-
реп, үзләренең бөтен гаскәрен шул урынга чакырдылар. [17] Алар
Гайсәгә куе кызыл төстәге япанча кидерделәр, ә башына чәнеч-
келе ботаклардан үрелгән таҗ куйдылар [18] һәм, Аны сәламли
башлап:

– Яшәсен яһүдләр Патшасы! – диделәр.

[19] Аннары башына таяк белән сугып кыйнадылар. Аңа тө-
керделәр, тезләнеп, Аның алдында баш иделәр. [20] Мәсхәрәлә-
гәннән соң, өстеннән куе кызыл япанчаны салдырып, Үзенең
киемнәрен кидерделәр һәм кадакларга алып чыгып киттеләр.

*Гайсәне хачка кадаклау*

[21] Кырдан кайтып килүче күренеле Шимун атлы бер кешене
– Искәндәр белән Руфусның атасын – Гайсәнең хачын күтә-
реп барырга мәҗбүр иттеләр. [22] Гайсәне Гөлгетә дип аталган
урынга, бу сүз «баш сөяге» дигәнне аңлата, алып килделәр.
[23] Мирра* катыш шәраб тәкъдим иттеләр, әмма Ул аны эчмәде.
[24] Аннары Гайсәне хачка кадакладылар. Һәм, кемгә нәрсә тияр
дип, жирәбә салышып, Аның киемнәрен үзара бүлештеләр.
[25] Алар Аны иртәнге сәгать тугызда хачка кадакладылар.
[26] Гайсәнең гаебен күрсәтүче язуда: «Яһүдләр Патшасы», – дип

---

* **15:23** *Мирра* – яһүдләрнең дини йоласы буенча күмү алдыннан мәеткә сөртә торган кыйммәтле, хуш исле сумала.

язылган иде. [27] Гайсә белән бергә ике юлбасарны – берсен уң
ягында, икенчесен сул ягында – кадакладылар. [ [28] ]*

[29] Үтеп баручылар исә башларын чайкый-чайкый Аны хурладылар.

– Әй, Син, Аллаһы Йортын җимерүче һәм аны өч көндә
төзүче, [30] Үзеңне Үзең коткар, хачтан төш! – диделәр алар.

[31] Шулай ук баш руханилар һәм канунчылар да Гайсәне мыскылладылар.

– Башкаларны коткарды, – диделәр алар, – ә Үзен коткара
алмый. [32] Мәсих, Исраил Патшасы! Хәзер безнең күз алдыбызда хачтан төшсен, шул чакта Аңа без ышанырбыз!

Хәтта Аның белән бергә кадакланганнар да Аны мәсхәрәләделәр.

*Гайсәнең үлеме*

[33] Көн уртасында бөтен җир өстен караңгылык каплап алды,
һәм көндезге сәгать өчкә кадәр шулай булды. [34] Ә сәгать өчтә
Гайсә каты тавыш белән:

– Элои, Элои, лема сабахтани? – дип кычкырды. Бу: «Әй, Аллаһым, әй, Аллаһым! Нигә Син Мине ташладың?» – дигәнне аңлата.

[35] Янында торучыларның кайберләре, Аның сүзләрен ишетеп әйттеләр:

– Ишетәсезме, Ильясны чакыра!

[36] Ә берсе, йөгереп килеп, губка кисәген шәраб серкәсенә манчыды һәм аны, таякка элеп, Аңа эчәргә биреп, әйтте:

– Әйдәгез карыйк: Ильяс Аны хачтан алырга килерме икән?

[37] Гайсә көчле тавыш белән кычкырып җибәрде һәм җан бирде.

[38] Аллаһы Йортындагы пәрдә өстән аска кадәр урталай ертылды.

[39] Хач алдында торучы йөзбашы, Гайсәнең шулай җан биргәнен күреп, әйтте:

– Бу Кеше чыннан да Аллаһы Улы булган икән!

[40] Анда, ерактан карап торучы хатыннар арасында: Магдалалы Мәрьям, шулай ук, кече Ягъкуб белән Йосиснең анасы
Мәрьям һәм Салуми да бар иделәр. [41] Алар Гайсәгә ияреп йөргән иделәр һәм Ул Гәлиләядә булган чакта, Аңа хезмәт иткән иделәр. Һәм анда Аның белән Иерусалимга килгән башка күп хатыннар да бар иде.

---

* **15:28** Кайбер кулъязмаларда 28 нче аять тә бар: «Һәм Изге язмада әйтелгәннәр гамәлгә ашты: „Ул җинаятьчеләр белән тиң саналды“».

*Гайсәне кабергә салу*

42 Кич җитә иде. Бу көн – бәйрәмгә әзерләнә торган көн,
ягъни шимбә алды көн булганга күрә, 43 Югары киңәшмәнең
абруйлы әгъзасы, Ариматайдан булган Йосыф – ул да Аллаһы
Патшалыгын көтә иде – Пилат янына кыю рәвештә килеп,
Гайсәнең гәүдәсен алырга рөхсәт сорады. 44 Аның инде үлгәне-
нә Пилат гаҗәпләнде һәм йөзбашын чакыртып:

– Гайсә үлдемени инде? – дип сорады.

45 Йөзбашы аның шулай булуын раслагач, Пилат Йосыфка
Гайсәнең гәүдәсен алырга рөхсәт бирде. 46 Йосыф, ак җитен
тукыма сатып алып, гәүдәне төреп, таш тауны тишеп ясалган
кабергә салды һәм, таш тәгәрәтеп китереп, кабер авызын кап-
лап куйды. 47 Ә Магдалалы Мәрьям белән Юсиснең анасы
Мәрьям Гайсәнең кайда куелганын күзәтеп тордылар.

*Гайсәнең үледән терелеп торуы*

16 1 Шимбә көн үткәннән соң, Магдалалы Мәрьям, Ягъ-
кубның анасы Мәрьям һәм Салуми Гайсәнең гәүдәсен
барып майлау өчен хуш исле майлар сатып алдылар.
2 Атнаның беренче көнендә, иртән иртүк, кояш чыгу белән
алар кабер янына киттеләр.

3 – Кабер алдындагы ташны безгә кем аударып бирер икән? –
диештеләр бер-беренә алар.

4 Килеп җиткәч, карасалар – таш читкә аударылган! Ә ул
таш бик зур иде. 5 Кабер эченә керү белән, алар уң якта озын
ак кием киеп утыручы бер егетне күреп алдылар һәм куркып
киттеләр.

6 – Курыкмагыз! – диде ул аларга. – Сез хачка кадакланган
насаралы Гайсәне эзлисез. Ул терелтеп торгызылды. Ул монда
юк. Менә Ул яткан урын. 7 Ә сез Аның шәкертләренә һәм
Петергә: «Гайсә сездән алда Гәлиләягә барыр һәм, Ул Үзе әйт-
кәнчә, сез Аны шунда күрерсез», – дип барып әйтегез.

8 Алар, кабердән чыгып, куркуларыннан калтырап йөгерде-
ләр һәм беркемгә дә һичнәрсә әйтмәделәр – алар бик нык
каушаганнар иде.

*Гайсә белән очрашулар*

9 Атнаның беренче көнендә, иртән иртүк, Гайсә, үледән те-
релеп торгач, иң элек Магдалалы Мәрьямгә күренде. Гайсә бу
хатынның эченнән җиде җенне куып чыгарган иде. 10 Мәрьям
Гайсәне күрүе турында элегрәк Гайсә белән бергә йөргәннәргә
хәбәр итте. Алар хәсрәткә төшеп, елап утыралар иде, 11 һәм

алар Гайсәнең исән булуына һәм Мәрьямнең Аны күрүенә
ышанмадылар.
12 Шуннан соң шәһәрдән китеп барган ике шәкертенә Гайсә
башка кыяфәттә күренде. 13 Алар, кире кайтып, калганнарына
хәбәр иттеләр. Әмма аларга да ышанмадылар.
14 Ниһаять, унбер шәкерте ашап утырган чакта, Гайсә аларга
да күренде. Ышанмаганнарына һәм күңелләре каты булуына Ул
аларны шелтәләде, чөнки алар үледән терелеп торган Гайсәне
күрүчеләргә ышанмадылар. 15 Ул аларга әйтте:
– Барыгыз, бөтен җир буйлап барлык кешеләргә Яхшы хәбәр-
не таратыгыз. 16 Иман китереп, суга чумдырылу йоласын үткән
кеше коткарылачак, ә иман итмәүче исә, хөкем ителәчәк.
17 Иман китергәннәр мондый галәмәт билгеләре күрсәтерләр:
алар Минем исемемне әйтеп, җеннәрне куып чыгарырлар, яңа
телләрдә сөйләшерләр, 18 кулларына еланнарны алсалар, яки
агу эчсәләр, аларга зыян килмәс, авыру кешеләрнең өстенә
кулларын куйсалар, алар савыгырлар.
19 Шулай дигәннән соң Раббы Гайсә, күккә алынып, Алла-
һының уң ягына утырды. 20 Ә шәкертләре, китеп, бөтен җир
буйлап Яхшы хәбәрне таратып йөрделәр һәм Раббы аларга яр-
дәм итеп торды, аларның сөйләгәннәрен илаһи билгеләр белән
раслады.*

* 16:9-20 Кайбер кульязмаларда 9-20 нче аятьләр юк.

# ЛҮК БӘЯН ИТКӘН ЯХШЫ ХӘБӘР

1 1-2 Мөхтәрәм Тәүфил!
Күпләр безнең арабызда булып үткән вакыйгалар турында
язарга алындылар. Алар ул вакыйгаларны баштан ук үз күз-
ләре белән күрүче Сүз хезмәтчеләре булган кешеләр безгә хәбәр
иткәнчә яздылар. 3-4 Шулай итеп мин дә, хөрмәтле Тәүфил,
башыннан ук барысын да җентекләп тикшергәннән соң, Сез
үзегезгә өйрәтелгәннәрнең дөреслеген белсен өчен, Сезгә ва-
кыйгаларның барышын эзлекле рәвештә язарга дигән фикергә
килдем.

*Яхъяның туачагы алдан әйтелә*

5 Яһүдиядә* Һируд патша заманында Абия нәселеннән бул-
ган руханилар төркеменнән Зәкәрия атлы бер рухани яшәгән.
Аның хатыны Элисабет тә руханилар нәселеннән булган. 6 Алар
икесе дә, Раббының әмерләрен һәм Ул кушканнарны төгәл
үтәп, Аллаһы алдында тәкъва булганнар. 7 Элисабет балага уза
алмаганлыктан, аларның балалары булмаган. Алар икесе дә ин-
де олы яшьтә булган.
8 Үз төркеменең Аллаһы Йортында хезмәт итү вакыты килеп
җиткәч, Зәкәрия Аллаһы алдында рухани хезмәтен башкарды.
9 Руханилар арасындагы гадәт буенча җирәбә салдылар, һәм
Аллаһы Йортына кереп, хуш исле сумала белән төтәсләү йола-
сын үтәү Зәкәриягә туры килде.
10 Ул Аллаһы Йортында хуш исле сумала белән төтәсләгәндә
тышкы яктагы бар халык дога кылып торды. 11 Шул вакыт Зәкә-
рия алдында, хуш исле сумала яна торган урынның уң ягында,
Раббының фәрештәсе пәйда булды. 12 Фәрештәне күреп, Зә-
кәрия каушап калды һәм бик курыкты. 13 Фәрештә исә аңа:

---

* 1:5 *Яһүдия* – монда бөтен Фалыстын җиренә карый. 4:44, 6:17, 7:17 һәм 23:5 нче аятьләрдә дә бу сүзнең мәгънәсе хәзер күрсәтелгәнчә.

– Курыкма, Зәкәрия, синең догаң ишетелде. Хатының
Элисабет сиңа ир бала тудырачак, син аңа Яхъя дигән исем ку-
шарсың. 14 Ул сиңа сөенеч һәм шатлык китерер, күпләр аның
тууына куанырлар. 15 Чөнки ул Раббы каршында бөек булыр,
шәраб һәм исерткеч эчемлекләр эчмәс һәм анасының кары-
нында вакытта ук Изге Рух белән сугарылыр. 16 Ул Исраил ба-
лаларының күбесен Раббыга, аларның үз Аллаһысына кире
кайтарыр. 17 Ильясныкы кебек рухка һәм кодрәткә ия булып, ул
Раббы алдыннан барыр, аталарны һәм балаларны татулашты-
рыр, Аллаһыга буйсынмаучыларны тәкъва кешеләрнең фикер
йөртү юлына борыр һәм шулай итеп халыкны Раббының ки-
лүенә әзерләр.
18 Зәкәрия фәрештәдән:
– Мин моның шулай буласын ничек белә алам? – дип сора-
ды. – Мин инде карт, хатыным да олы яшьтә.
19 – Мин – Җәбраил, мин Аллаһыга хезмәт итәм. Мин сиңа
менә шушы куанычлы хәбәрне белдерү өчен җибәрелдем.
20 Белеп тор, шушы сүзләр тормышка ашканчы телсез булыр-
сың һәм сөйләшә алмассың, чөнки мин әйткән сүзләргә
ышанмадың. Ә бу сүзләр үз вакытында тормышка ашачак, –
диде аңа фәрештә.
21 Халык Зәкәрияне көтеп торды һәм аның Аллаһы Йортында
тоткарлануына аптырады. 22 Зәкәрия исә, Аллаһы Йортыннан
чыккач, сөйләшә алмады һәм кешеләр аның илаһи күренеш
күргәнлеген аңладылар. Ул алар белән ишарәләр ярдәмендә
аңлашты һәм һаман сөйләшә алмады.
23 Хезмәт итү көннәре тәмамлангач, ул өенә кайтты. 24 Күп-
медер вакыттан соң хатыны Элисабет балага узды һәм биш ай
буена кеше арасына чыкмады.
25 – Минем өчен моны Раббы эшләде, Ул минем хакта кай-
гыртты һәм кешеләр алдындагы хурлыгымны алып ташлады, –
дип уйлады Элисабет.

*Гайсәнең туачагы алдан әйтелә*

26-27 Элисабет балага узып алтынчы ай киткәч, Аллаһы Җәб-
раил фәрештәне Гәлиләя өлкәсендәге Насара шәһәренә,
Мәрьям исемле гыйффәтле кыз янына җибәрде. Мәрьям
Давыт нәселеннән булган Йосыф атлы кешегә ярәшелгән иде.
28 Фәрештә, Мәрьям янына килеп:
– Сәлам сиңа! Аллаһының мәрхәмәтен кабул итүче – син.
Раббы синең белән! – диде.
29 Мәрьям исә кыенсынып калды һәм бу сүзләрнең мәгънә-
сен аңларга тырышты. 30 Фәрештә аңа әйтте:

– Курыкма, Мәрьям! Аллаһы сиңа мәрхәмәт күрсәтте. 31 Син
буйга узарсың һәм Ир Бала табарсың, Аңа Гайсә* дигән исем
кушарсың. 32 Ул бөек булачак, Аллаһы Тәгаләнең Улы дип
аталачак. Раббы Аллаһы Аңа борынгы бабасы Давытның тәхе-
тен бирәчәк, 33 Ул Ягъкуб халкы өстеннән мәңгегә патшалык
итәчәк, Аның патшалыгының ахыры булмаячак.
34 Мәрьям исә фәрештәдән:
– Ничек шулай була ала, минем бит әле ир-ат белән якын-
лык кылганым юк? – дип сорады.
35 – Сиңа Изге Рух иңәчәк, – дип җавап бирде фәрештә, –
һәм синең өстеңә Аллаһы Тәгаләнең кодрәте төшәчәк, шуңа
күрә син тудырачак Бала изге булачак һәм Аллаһы Улы дип
аталачак. 36 Менә, кардәшең Элисабет тә картайган көнендә ба-
лага узды, ул ир бала көтә. Кешеләр аның турында, авырга уза
алмый, дип әйтәләр иде, ә ул инде алтынчы ай авырлы. 37 Чөн-
ки Аллаһы булдыра алмаслык бернәрсә дә юк.
38 Шуннан соң Мәрьям:
– Мин – Раббы колы, минем белән син әйткәнчә булсын, –
диде.
Һәм фәрештә аның яныннан китте.

*Мәрьям Элисабет янында*

39 Озак вакыт үтмәстән, Мәрьям ашыгыч рәвештә Яһүдия
тауларында урнашкан шәһәргә Элисабетләргә китте. 40 Килеп
җиткәч, Зәкәриянең өенә кереп, Элисабет белән исәнләште.
41 Мәрьямнең сәламләү сүзләрен ишетү белән, Элисабетнең ка-
рынындагы баласы хәрәкәтләнеп куйды, һәм Элисабет Изге
Рух белән сугарылды. 42 Ул күтәренке тавыш белән:
– Хатын-кызлар арасында син иң мөбарәк! Туачак Балаң да
фатихалы!
43 Раббымның анасы минем яныма килгән! Ничек миңа
шундый хөрмәт күрсәтелә? 44 Мин синең сәламләвеңне ишетү
белән, карынымдагы балам шатлыгыннан хәрәкәтләнеп куй-
ды. 45 Раббы тарафыннан үзенә әйтелгән сүзләрнең тормышка
ашачагына ышанган хатын бәхетле! – диде.

*Мәрьямнең мәдхиясе*

46 Мәрьям әйтте:
– Күңелем минем Раббыны данлый,
47 Рухым Аллаһы Коткаручымны уйлап шатлана,

---

* 1:31 *Гайсә* – яһүдчә «Йеһошуа»; бу исемнең мәгънәсе: «Раббы коткара».

48 Чөнки Ул Үзенең күндәм колына игътибар итте.
Шушы вакыттан башлап мине барлык буыннар
бәхетле дип атарлар,
49 Чөнки Кодрәт Иясе минем өчен бөек эшләр кылды –
Аның исеме мөкатдәс!
50 Ул Үзен ихтирам итүчеләргә буыннан-буынга шәфкать
күрсәтә.
51 Үз кулы белән куәтле эшләр кылды:
Күңелләреннән тәкәббер уйлаган кешеләрне таратты.
52 Түрәләрне тәхетләреннән төшерде,
ә түбәндәгеләрне күтәрде.
53 Ачларны яхшы нәрсәләр белән туендырды,
ә байларны буш кул белән җибәрде.
54-55 Аталарыбызга биргән вәгъдәсе буенча
хезмәтчесе Исраилгә ярдәм итте,
халкын исендә тотып,
Ибраһимга һәм аның нәселенә
мәңгегә шәфкать күрсәтте.
56 Мәрьям өч айга якын Элисабет янында булганнан соң үз
өенә кайтты.

*Яхъяның тууы*

57 Элисабетнең бала табар вакыты җитте һәм ул ир бала тап-
ты. 58 Күршеләре һәм кардәшләре, Раббының Элисабеткә зур
шәфкать күрсәткәнен ишетеп, аның белән бергә куандылар.
59 Сигезенче көнне алар баланы сөннәткә утыртырга килделәр
һәм аны атасы исеме белән – Зәкәрия дип атарга теләделәр.
60 Ләкин баланың анасы каршы килде:

– Юк, аның исеме Яхъя булырга тиеш.

61 Ә алар аңа:

– Синең кардәшләрең арасында бу исем белән аталган беркем
дә юк бит, – диделәр 62 һәм, ишарәләр белән, баланың атасын-
нан нинди исем кушарга теләвен сорадылар.

63 Зәкәрия язу өчен такта сорап алды һәм: «Аның исеме
Яхъя», – дип язды. Барысы да хәйран калдылар. 64 Шул миз-
гелдә үк аның теле ачылды, һәм ул Аллаһыны данлап сөйли
башлады. 65 Зәкәрия белән Элисабетнең күрше-тирәсендә
яшәүчеләр барысы да куркуга төштеләр, бөтен таулы Яһүдия-
дә шушы вакыйгалар турында сөйлиләр иде. 66 Ишеткән һәр
кеше:

– Бу бала кем булыр икән? – дип уйлады.

Чөнки дөрестән дә Раббының кодрәте аның белән булды.

*Зәкәриянең мәдхиясе*

67 Баланың атасы Зәкәрия, Изге Рух белән сугарылып, Аллаһыдан бирелгән сүзләрне игълан итте:

68 – Раббыны, Исраилнең Аллаһысын, данлыйк,
чөнки Ул ярдәмгә килде һәм Үз халкын азат итте,
69 Үзенең колы Давыт нәселеннән
куәтле Коткаручыны күтәрде,
70 Ул бу турыда күп еллар элек
Үзенең изге пәйгамбәрләре аша әйткән иде.
71 Бу Коткаручы безне дошманнарыбыздан
һәм безгә нәфрәт итүчеләрдән коткарырга дип килде.
72-75 Дошманнарыбыз кулыннан котылгач,
гомеребезнең барлык көннәрендә,
бернәрсәдән курыкмыйча,
Аллаһы алдында изге һәм тәкъва булып,
без Аллаһыга хезмәт итә алсын өчен,
Аллаһы шулай итеп безнең ата-бабаларыбызга
шәфкать күрсәтте,
Үзе төзегән изге килешүне –
атабыз Ибраһимга биргән антын –
исендә тотты.
76 Һәм син, сабый,
Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре дип аталырсың,
чөнки, Раббыга юлны әзерләп,
Аның алдыннан барырсың.
77 Һәм Аның халкына
гөнаһларының кичерелүе аша булган
котылу хакында белдерерсең,
78 Аллаһыбызның шәфкате ташып тора,
һәм шуңа күрә безгә
югарыдан таң кояшы иңәчәк;
79 Караңгыда һәм үлем шәүләсендә утырганнарга яктылык
бирү өчен,
Аякларыбызны тынычлык юлына юнәлтү өчен
киләчәк Ул.

80 Ә бала үсте һәм рухи яктан ныгыды. Исраил халкына күренгәнче, ул чүлдә яшәде.

*Гайсәнең тууы*

**2** 1 Ул көннәрдә Август кайсар тарафыннан бөтен Рим империясендәге бар кешеләрне исемлеккә теркәргә дигән боерык бирелде. 2 Бу теркәү беренче тапкыр уздырылды. Ул вакытта Сурия өлкәсе белән Күрини идарә итә иде. 3 Язылу

өчен һәркем үз нәселе шәһәренә китте. 4 Йосыф та Гәлиләядәге
Насара шәһәреннән Яһүдиягә, Давыт шәһәренә, Бәйтлехемгә
китте, чөнки Йосыф Давыт нәселеннән иде. 5 Йосыф исемлек-
кә теркәлергә үзенә ярәшелгән Мәрьям белән бергә барды.
Мәрьям авырлы иде. 6 Алар Бәйтлехемдә булганда Мәрьямнең
бала табар вакыты җитте. 7 Мәрьям үзенең беренче Баласын –
Ир Баланы тудырды. Ул Аны биләүдә һәм утлыкка салды, чөнки
аларга кунак йортында урын булмады.

*Көтүчеләр һәм фәрештәләр*

8 Ул тирәләрдә шул төнне берничә көтүче кырда сарык көтүе
саклый иде. 9 Алар алдында Раббының бер фәрештәсе пәйда
булды, һәм алар булган урын Раббының данынннан балкып кит-
те. Көтүчеләр бик нык куркып калдылар.

10 Фәрештә исә аларга әйтте:

– Курыкмагыз! Мин сезгә куанычлы хәбәр – бөтен халык
өчен зур шатлык алып килдем: 11 бүген Давыт шәһәрендә сез-
нең өчен Коткаручы туды. Ул – Мәсих*, Рабби! 12 Менә сезгә
билге: сез Баланы табарсыз. Ул биләүгә биләнгән булыр һәм
утлыкта ятар.

13 Кинәт фәрештә янында күп санлы күк фәрештәләре гаскә-
ре күренде, һәм алар:

14 – Күкләрдәге Аллаһыга дан!

Аллаһы илтифат күрсәткән кешеләргә җирдә иминлек! –
дип Аллаһыны данладылар.

15 Фәрештәләр күккә күтәрелгәннән соң, көтүчеләр бер-бер-
сенә:

– Әйдәгез, Бәйтлехемгә барыйк, Рабби әйткән анда булган
хәлне барып күрик, – диештеләр.

16 Алар ашыгып Бәйтлехемгә килделәр һәм анда Мәрьям
белән Йосыфны һәм утлыкта яткан Баланы таптылар. 17 Бала-
ны күргәч, бу Бала хакында үзләренә хәбәр ителгәнне аларга
сөйләп бирделәр. 18 Көтүчеләр сөйләгәнне ишеткән кешеләр
барысы да хәйран калдылар. 19 Мәрьям исә боларның һәммәсен
күңеленә салып куйды һәм шул хакта уйлап йөрде.

20 Ишеткән һәм күргән барлык нәрсәләр өчен Аллаһыны
данлап һәм мактап, көтүчеләр көтүләре янына кайттылар. Ба-
рысы да фәрештә әйткәнчә булды.

21 Сигез көннән соң, Баланы сөннәткә утырту вакыты җит-
кәч, Аңа Гайсә дигән исем куштылар. Анасы Мәрьям балага
узганчы ук фәрештә Аңа шушы исемне кушкан иде.

---

* 2:11 *Мәсих* – «май сөртелгән» дигән мәгънәдә. Сүзлекне карагыз.

[22] Муса кануны буенча пакьләнү йоласын башкару вакыты
җиткәч, Мәрьям белән Йосыф, Раббы алдына китерү өчен, Ба-
ланы Иерусалимга алып бардылар. [23] Чөнки Раббының кану-
нында: «Ана карыныннан беренче булып туган һәр ир бала
Раббыга багышланырга тиеш», – дип язылган. [24] Шулай ук алар,
Раббының кануны буенча, корбан китерү өчен: «ике урман кү-
гәрченен яки ике күгәрчен баласын» бирү өчен дә бардылар.

[25] Ул вакытта Иерусалимда Шимун атлы тәкъва һәм диндар
бер кеше бар иде. Ул Исраилгә юаныч килүен көтеп яши, аңар-
да Изге Рух иде. [26] Изге Рух аңа: «Раббының Мәсихен күрмичә
үлмәячәксең», – дип әйткән булган. [27] Изге Рухның кушуы
буенча, Шимун Аллаһы Йортына килде. Балага карата Муса
кануны кушканны башкару өчен әти-әнисе нарасый Гайсәне
Аллаһы Йортына алып килгәч, [28] Шимун сабый Баланы кулла-
рына алды һәм Аллаһыны данлап әйтте:

[29] – Хәзер инде, Хөкемдар, үтәп вәгъдәңне,
иминлектә җибәрәсең колыңны.
[30-32] Барлык халыклар күреп торганда
Үзең әзерләп куйган котылуны,
Мәҗүсиләрне яктыртачак,
Исраилне, Синең халкыңны
данлыклы итәчәк яктылыкны
күрде күзләрем.

[33] Гайсәнең атасы һәм анасы Шимунның Бала хакында әйт-
кән сүзләрен гаҗәпләнеп тыңлап тордылар. [34] Шимун аларны
фатихалады һәм Баланың анасы Мәрьямгә әйтте:

– Бу Бала Исраилдә күпләрнең егылуына һәм күтәрелүенә
сәбәп булсын өчен һәм билге итеп сайланган. Бу билгене кире
кагарлар. [35] Шуның аркылы күпләрнең күңелләрендәге уйлары
ачылыр. Һәм синең үзеңнең күңелеңә кылыч белән кадаган
кебек булыр.

*Ханна Аллаһыга шөкрана кыла*

[36] Анда Ашер ыруыннан Пенуил кызы Ханна да бар иде.
Ханна – пәйгамбәр һәм бик карт иде. Ул, кияүгә чыккач, ире
белән җиде ел яшәп, [37] тол калган, һәм аңа хәзер сиксән дүрт
яшь иде. Ул, һәрвакыт ураза тотып һәм дога кылып, Аллаһы
Йортында көне-төне Аллаһыга хезмәт итә иде.

[38] Ханна, нәкъ шул вакытта, алар янына килеп, Аллаһыга
шөкрана кылды һәм Иерусалимның азат ителүен көтеп торучы
кешеләрнең барысына да Бала хакында сөйләде.

[39] Раббы кануны буенча башкарырга тиеш булганны үтәп бе-
тергәннән соң, Йосыф белән Мәрьям үзләре яшәгән шәһәргә,

Гәлиләядәге Насарага кайтып киттеләр. [40] Бала исә үсә, ныгый
һәм зирәк акыл белән тула иде. Аллаһының фатихасы Аның
өстендә булды.

*Яшүсмер Гайсә Аллаһы Йортында*

[41] Һәр елны Гайсәнең әти-әнисе Иерусалимга Коткарылу
бәйрәменә баралар иде. [42] Гайсә унике яшьлек вакытта, алар га-
дәттәгечә Иерусалим шәһәренә бәйрәмгә килделәр. [43] Бәйрәм
көннәре үткәч, Йосыф белән Мәрьям кайтыр юлга чыктылар.
Яшүсмер Гайсә исә Иерусалимда калды, ә әти-әнисе бу турыда
белмәделәр. [44] Алар Аны, башка юлчылар белән бергә бара,
дип уйладылар. Бер көнлек юл үткәннән соң, Аны кардәшлә-
ре һәм таныш-белешләре арасыннан эзли башладылар. [45] Һәм,
таба алмагач, Гайсәне эзләп, кире Иерусалимга килделәр.
[46] Өч көннән соң Аны Аллаһы Йортында таптылар. Ул яһүд
укытучылары арасында аларны тыңлап һәм сораулар биреп
утыра иде. [47] Гайсәне ишеткәннәрнең барысы да Аның тирән
акылына, Аның җавапларына хәйран калганнар. [48] Аны күреп,
әтисе-әнисе бик гаҗәпләнде. Әнисе:

– Улым, ни өчен Син безнең белән шулай эшләдең? Без
әтиең белән Сине эзләдек, бик борчылдык, – диде.

[49] Гайсә аларга:

– Сез мине нигә эзләдегез? Атам Йортында булырга тиешле-
гемне белмәдегезме әллә? – дип әйтте.

[50] Ләкин алар Ул әйткән сүзләрне аңламадылар. [51] Гайсә алар
белән бергә Насарага кайтты һәм әти-әнисенә итагатьле булды.
Әнисе Мәрьям бу хәлләрнең барысын да күңелендә саклады.
[52] Гайсә исә үсте, акыл җыйды, Аллаһыга да, кешеләргә дә бик
ошый иде.

*Чумдыручы Яхъяның вәгазьләве*

**3** [1] Тибери кайсар хакимлегенең унбишенче елында, Яһүдиядә
Понти Пилат идарә иткәндә, ә Һируд Гәлиләя башлыгы,
аның ир туганы Филип Итурая һәм Трахунитис өлкәсе
башлыгы, ә Лусани Абилини башлыгы булганда, [2] Һаннас һәм
Кәяфәс иң баш руханилар булган вакытта чүлдә яшәгән Зәкәрия
улы Яхъяга Аллаһыдан сүз булды. [3] Шуннан соң Яхъя Үрдүн ел-
гасы тирәсендәге барлык җирләрдә: «Тәүбә итеп, суга чумды-
рылыгыз, һәм Аллаһы сезнең гөнаһларыгызны кичерер», – дип
өндәп йөрде. [4] Ишагыйя пәйгамбәрнең китабында бу хакта
болай дип язылган:

– «Чүлдә кычкыручының тавышы ишетелә:
„Раббыга юл әзерләгез,

Аңа сукмакларны турайтыгыз.
5 Һәрбер үзән тутырылсын,
Һәр тау һәм калкулык җир белән тигезләнсен,
Бормалы-бормалы юллар турайтылсын,
Сикәлтәлеләре тигезләнеп шомарсын.
6 Һәм барлык кешеләр
Аллаһының коткаруын күрерләр“».

7 Яхъя янына, суга чумдырылырга дип, күп халык килә иде.
Ул кешеләргә:

– Әй, сез, елан токымнары! Аллаһының якынлашып килүче
ачуыннан кача алырсыз дип кем әйтте сезгә? – диде. – 8 Агач-
лар җимеш биргән кебек, тәүбә иткәнегезне эш белән күрсәте-
гез! «Безнең бит атабыз – Ибраһим», – дип уйламагыз да. Мин
сезгә шуны әйтәм: Аллаһы менә шушы ташлардан Ибраһимга
балалар булдыра ала. 9 Балта агачлар төбендә ята, ул инде әзер-
ләп куелган: яхшы җимеш бирми торган һәр агачны кисеп утка
ташлыйлар.

10 Халык аннан:

– Безгә нәрсә эшләргә соң? – дип сорады.

11 Яхъя аларга:

– Ике күлмәге бар кеше берсен бер күлмәге дә булмаганга
бирсен. Кемнең ризыгы бар, ашарына булмаган кеше белән
бүлешсен, – дип җавап бирде.

12 Суга чумдырылырга дип, салым җыючылар да килделәр
һәм Яхъядан:

– Остаз! Ә безгә нәрсә эшләргә? – дип сорадылар.

13 Ул аларга:

– Тиешеннән артыгын таләп итмәгез, – дип җавап бирде.

14 Гаскәриләр дә аннан:

– Ә безгә нәрсә эшләргә? – дип сорадылар.

– Беркемнән дә көчләп, янап әйбер алмагыз. Хезмәт хакы-
гыздан канәгать булыгыз, – диде Яхъя.

15 Халык көтә иде, һәркем күңеленнән Яхъя турында: «Бу
Мәсих түгелме икән?» – дип уйлады. 16 Яхъя исә аларның бары-
сына да болай дип җавап бирде:

– Мин сезне суга чумдырам. Әмма миннән кодрәтлерәк
бер Зат килә, мин Аның аяк киеменең каешын чишәргә дә
лаеклы түгелмен. Ул сезне Изге Рухка һәм утка чумдырыр.
17 Аның кулында җилгәргеч. Ул ындырда ашлыкны җилгәреп,
бодаен аерып, ашлык бурасына салыр, ә кибәген сүнмәс утта
яндырыр.

18 Яхъя Исраил халкына тагын башка төрле үгет-нәсыйхәтләр
биреп, Яхшы хәбәрне вәгазьләп йөрде. 19 Әмма идарәче Һируд,

абыйсының хатыны Һирудия белән булган мөнәсәбәтләре
һәм башка явызлыклары өчен Яхъя аның гаебен күрсәткәнгә,
20 шундый эшләре өстенә тагын берне өстәп, Яхъяны төрмәгә
утыртты.

*Гайсәнең суга чумдырылуы*

21 Халык чумдырылганда Гайсә дә чумдырылды. Ул дога
кылган вакытта күкләр ачылды, 22 һәм Аңа күгәрчен рәвешендә
Изге Рух иңде. Күкләрдән:
– Син – Минем сөекле Улым. Син Минем куанычым! –
дигән сүзләр ишетелде.

*Гайсәнең нәсел шәҗәрәсе*

23 Үзенең хезмәтен башлаганда Гайсәгә утыз яшьләр чамасы
иде. Кешеләр Аны Йосыф улы дип уйладылар. Ә Йосыф –
Эли улы, 24 Эли – Маттат улы, Маттат – Леви улы, Леви –
Мәлки улы, Мәлки – Яннай улы, Яннай – Йосыф улы,
25 Йосыф – Маттати улы, Маттати – Амос улы, Амос – Нахум
улы, Нахум – Һесли улы, Һесли – Нәггәй улы, 26 Нәггәй –
Махат улы, Махат – Маттати улы, Маттати – Шими улы,
Шими – Йосых улы, Йосых – Йода улы, 27 Йода – Йоханан улы,
Йоханан – Риса улы, Риса – Зеруббабел улы, Зеруббабел –
Шеһалтиел улы, Шеһалтиел – Нири улы, 28 Нири – Мәлки
улы, Мәлки – Адди улы, Адди – Көсам улы, Көсам – Элмадам
улы, Элмадам – Эр улы, 29 Эр – Ешуа улы, Ешуа – Элигазәр
улы, Элигазәр – Йорим улы, Йорим – Маттат улы, Маттат –
Леви улы, 30 Леви – Шимун улы, Шимун – Яһүд улы, Яһүд –
Йосыф улы, Йосыф – Йонам улы, Йонам – Эльякыйм улы,
31 Эльякыйм – Мелеа улы, Мелеа – Майнан улы, Майнан –
Маттата улы, Маттата – Натан улы, Натан – Давыт улы,
32 Давыт – Ишай улы, Ишай – Обид улы, Обид – Богаз улы,
Богаз – Салмун улы, Салмун – Нахшун улы, 33 Нахшун – Ам-
минадаб улы, Амминадаб – Админ улы, Админ – Арни улы,
Арни – Хесрун улы, Хесрун – Перес улы, Перес – Яһүд улы,
34 Яһүд – Ягъкуб улы, Ягъкуб – Исхак улы, Исхак – Ибраһим
улы, Ибраһим – Терах улы, Терах – Нахур улы, 35 Нахур – Се-
руг улы, Серуг – Регу улы, Регу – Пелег улы, Пелег – Эбер
улы, Эбер – Шела улы, 36 Шела – Кыйнан улы, Кыйнан –
Әрпәкшәд улы, Әрпәкшәд – Шем улы, Шем – Нух улы, Нух –
Ләмек улы, 37 Ләмек – Мәтушалах улы, Мәтушалах – Ханух
улы, Ханух – Ярид улы, Ярид – Маһалалил улы, Маһалалил –
Кыйнан улы, 38 Кыйнан – Энош улы, Энош – Шет улы, Шет –
Адәм улы, Адәм – Аллаһы улы.

*Гайсәнең сыналуы*

4 [1] Изге Рух белән сугарылган Гайсә Үрдүн елгасы буеннан
чүлгә китте, һәм Рух Аны чүл буйлап йөртте. [2] Гайсә анда
кырык көн буена иблис вәсвәсәсе астында булды, бер-
нәрсә дә ашамады. Соңгы көннәрендә Ул ачыкты. [3] Иблис исә
Аңа әйтте:

– Әгәр син Аллаһы Улы булсаң: «Бу таш ипигә әйләнсен», – дип әйт.

[4] Гайсә аңа болай дип җавап бирде:

– Изге язмада: «Кеше икмәк белән генә яшәми», – дип язылган.

[5] Шуннан соң иблис Гайсәне биеклеккә алып менде һәм Аңа
мизгел эчендә галәмдәге барлык патшалыкларны күрсәтте.

[6] – Шушы патшалыкларның барысы өстеннән хакимлекне
дә, аларның даннарын да сиңа бирермен, – диде Аңа иблис, –
чөнки боларның барысы да миңа бирелгән һәм мин аларны
кемгә теләсәм, шуңа бирә алам. [7] Шулай итеп, миңа табынсаң,
барысы да Синеке булыр.

[8] Моңа каршы Гайсә җавап бирде:

– Изге язмада: «Раббы Аллаһыңа табын, Аңа гына хезмәт ит», – дип язылган.

[9] Шуннан соң иблис Гайсәне Иерусалимга алып китте. Ул
Аны Аллаһы Йортының иң биек урынына бастырды:

– Әгәр дә Син Аллаһы Улы булсаң, шушы урыннан түбәнгә
ташлан. [10] Изге язмада:

«Ул Үзенең фәрештәләренә
Синең хакта кайгыртырга әмер бирер.
[11] Алар Сине күтәреп алырлар,
аякларың ташка бәрелмәс», –
дип язылган бит.

[12] Гайсә аңа:

– Изге язмада: «Раббы Аллаһыңны сынама», – дип язылган, – диде.

[13] Иблис, вәсвәсәсен бетергәч, икенче бер уңайлы вакытка
кадәр Аның яныннан китте.

[14] Рухның кодрәте белән сугарылган Гайсә Гәлиләягә кайтты.
Аның хакындагы хәбәр бөтен тирә-якка таралды. [15] Ул аларның
гыйбадәтханәләрендә өйрәтте, һәм барысы да аны мактады.

*Гайсә Насарада инкяр ителә*

[16] Гайсә Үзе үскән шәһәргә – Насарага килде һәм, гадәттәге-
чә, шимбә көнне гыйбадәтханәгә керде. Изге язманы укырга

дип, урыныннан торгач, 17 Аңа Ишагыйя пәйгамбәрнең язма-
сын бирделәр. Гайсә, кулъязма төргәген ачып, шундый сүзләр
язылган урынны тапты:
18-19 «Раббының Рухы Минем өстемдә,
Чөнки Ул Мине майлап махсус эшкә сайлады.
Ул Мине фәкыйрьләргә Яхшы хәбәрне*
житкерергә,
Әсирләргә – азатлык, сукырларга – күрә башлауны
игълан итәргә,
Җәберләнгәннәрне ирекке чыгарырга,
Раббының шәфкать күрсәтә торган елын хәбәр итәргә
җибәрде».
20 Гайсә, төргәкне җыеп, аны кире хезмәтчегә бирде дә
урынына утырды. Гыйбадәтханәдәге һәммәсенең күзе Аңа
текәлде.
21 Ул аларга:
– Бүген, сез Язманы тыңлаганда, бу сүзләр тормышка аш-
ты, – диде.
22 Барысы да Гайсәне мактадылар һәм, Аның мәрхәмәт тулы
сүзләренә таң калып:
– Бу Йосыф улы түгелме соң? – диештеләр.
23 Гайсә аларга әйтте:
– Әлбәттә, сез Миңа «Табиб! Үзеңне-үзең дәвала» дигән
мәкальне әйтерсез. «Кәпәрнаумда кылган эшләреңне ишеттек.
Монда да, Үз шәһәреңдә дә шуларны эшлә», – диярсез.
24 Ул дәвам итеп әйтте:
– Сезгә хак сүз әйтәм: бер пәйгамбәрне дә үз илендә теләп
кабул итмиләр. 25 Бу чынлап та шулай: Ильяс пәйгамбәр көн-
нәрендә өч ел ярым күкләр ябылып яңгыр яумады һәм бөтен
Исраил илендә зур ачлык булды. Исраилдә тол хатыннар күп
иде, 26 ләкин Ильяс аларның берсе янына да түгел, ә Сидун җи-
рендәге Сарепта шәһәрендә яшәүче бер тол хатын янына гына
җибәрелде. 27 Шулай ук, Элиша пәйгамбәр вакытында Исраил-
дә махау авырулылар күп булды, әмма сурияле Нагаманнан
башка бер махаулы да чистарынмады.
28 Шушы сүзләрне ишетеп, гыйбадәтханәдәге кешеләрнең
барысы да бик нык ачуланып ярсыдылар. 29 Алар, урыннарын-
нан торып, Гайсәне шәһәрдән көчләп алып чыктылар һәм,
кыядан төртеп төшерергә уйлап, шәһәрләре салынган тауның
чыгып торган өлешенә алып менделәр. 30 Әмма Гайсә, халык
арасыннан үтеп, алар яныннан китеп барды.

---

* 4:18-19 *Яхшы хәбәр* – сүзлекне карагыз.

*Гайсә явыз рухны куып чыгара*

[31] Шуннан соң Гайсә Гәлиләянең Кәпәрнаум шәһәренә килде
һәм шимбә көнне халыкны өйрәтте. [32] Аның өйрәтүенә хәйран
калдылар, чөнки Ул хакимнәрчә сөйли иде. [33] Гыйбадәтханәдә
эчендә шакшы рух булган бер кеше көчле тавыш белән:

[34] – И, насаралы Гайсә, Сиңа бездән нәрсә кирәк? Син безне
һәлак итәргә килдеңме? Мин Синең кем икәнеңне беләм.
Син – Аллаһының Изгесе, – дип кычкырды.

[35] Ә Гайсә аңа каты итеп боерды:

– Эндәшмә, аның эченнән чык!

Җен, теге кешене бар халык алдында егып ташлап, аңа һич-
бер зыян китермичә, аның эченнән чыкты. [36] Барысы да таң
калып:

– Нинди сүзләр бу? Ул шакшы рухларга хакимлек һәм код-
рәт белән боерык бирә һәм алар чыгалар, – диделәр.

[37] Аның хакындагы хәбәр бөтен тирә-якка таралды.

*Шимунның каенанасы савыга*

[38] Гайсә гыйбадәтханәдән Шимунның өенә барды. Шимунның
каенанасы бик нык кызышып, авырып ята икән. Гайсәдән аңа
ярдәм итүен сорадылар. [39] Ул хатын янына килде, аңа таба
иелеп, кызышуга чыгарга әмер бирде һәм кызышу аны калдыр-
ды. Шимунның каенанасы шундук торып басты һәм аларга
табын әзерли башлады.

*Гайсә күпләрне савыктыра*

[40] Кояш баеган вакытта төрле авырулардан газап чигүче
якыннары булган бар кешеләр аларны Гайсә янына алып кил-
деләр. Ул, авыру кешеләрнең һәрберсе өстенә кулларын куеп,
аларны савыктырды. [41] Шулай ук күпләрдән: «Син Аллаһы
Улы», – дип кычкыра-кычкыра җеннәр чыкты. Ә Гайсә алар-
ны сөйләүләреннән тыйды, чөнки алар Аның Мәсих икәнле-
ген беләләр иде.

[42] Көн тугач, Гайсә, шәһәрдән чыгып, аулак урынга китте. Ха-
лык төркемнәре Аны эзләделәр, эзләп тапкач, янына килеп, Аны
үзләре яныннан җибәрмәс өчен тотып калырга тырыштылар.

[43] Ләкин Ул аларга:

– Мин башка шәһәрләргә дә Аллаһы Патшалыгы хакындагы
Яхшы хәбәрне җиткерергә тиешмен, чөнки Мин шуның өчен
җибәрелдем, – диде.

[44] Ул яһүдләр җирендәге гыйбадәтханәләрдә Яхшы хәбәрне
сөйләп йөрүен дәвам итте.

*Гайсәнең беренче шәкертләре*

**5** 1 Бервакыт Геннисарет күле* буенда, Аллаһы сүзен тыңларга теләп, халык Аны бар яктан кысрыклаганда, 2 Гайсә яр буенда ике көймә күрде. Балыкчылар, көймәләреннән төшеп, ятьмәләрен юалар иде. 3 Гайсә көймәләрнең берсенә менеп, – ул көймә Шимунныкы иде – ярдан бераз эчкәрәк керергә сорады һәм, көймәдә утырып, халыкны өйрәтте. 4 Сүзен тәмамлагач:

– Шимун, тирәнгәрәк кер дә ятьмәләрегезне салыгыз, – диде.

5 Шимун Аңа:

– Өйрәтүче! Без төн буе тырыштык, ләкин һичнәрсә тота алмадык. Шулай да, Син кушасың икән, ятьмәне салам, – дип җавап бирде.

6 Шулай эшләделәр һәм аларга бик күп балык эләкте, ятьмәләре аздан гына ертылмый калды. 7 Балыкчылар, башка көймәдәге иптәшләренә кул болгап, аларны ярдәмгә чакырдылар. Тегеләре килгәч, бергәләп, ике көймәне дә шыгрым тутырдылар, хәтта көймәләре аздан гына батмый калды. 8 Шимун Петер исә, шушы хәлне күреп, Гайсә алдында тезләренә егылды:

– Раббым, кит минем янымнан, мин гөнаһлы кеше.

9 Ул да, аның белән булганнарның барысы да, тотылган балыкның күплегенә гаҗәпләнеп, куркып калдылар. 10 Шулай ук Шимунның иптәшләре Зебедәй уллары Ягъкуб белән Яхъя да хәйран калды. Гайсә Шимунга:

– Курыкма, шушы вакыттан башлап кешеләр тотучы булырсың, – диде. 11 Көймәләрен ярга тартып чыгаргач, бөтен нәрсәләрен шунда калдырып, алар Гайсәгә ияреп киттеләр.

*Гайсә махаулыны савыктыра*

12 Гайсә бер шәһәрдә булган вакытта, Аның янына бөтен тәне махаулы бер кеше килде һәм, Гайсәне күргәч, йөзтүбән капланып:

– Әфәнде! Әгәр теләсәң, мине тазарта алыр идең, – дип ялварды.

13 Гайсә, кулын сузып, аңа кагылды һәм:

– Әйе, телим. Тазарын! – диде.

Аның махауы шундук бетте. 14 Гайсә аңа бу турыда беркемгә дә сөйләмәскә кушты.

– Бар, руханига күрен һәм, кешеләр өчен терелүеңң билгесе итеп, Муса канунында әмер ителгәнчә, корбан бүләген китер, – диде Ул.

---

* **5:1** *Геннисарет күле* – бу күлне Гәлиләя диңгезе дип тә атаганнар.

[15] Әмма Гайсә хакында сүз таралганнан тарала барды. Күп
халык, Аны тыңлау өчен һәм чирләреннән савыктырылу өчен,
Аның янына агылды. [16] Ә Гайсә вакыт-вакыт аулак урыннарга
китеп дога кыла иде.

*Гайсә паралич суккан кешене савыктыра*

[17] Бер көнне, Гайсә өйрәткән вакытта, Гәлиләянең һәм Яһү-
диянең барлык авылларыннан, Иерусалимнан килгән фарисей-
ләр* һәм канун укытучылары да шунда утыра иделәр. Раббының
кодрәте Аның белән иде, һәм Ул авыруларны савыктырды.

[18] Берничә ир-ат паралич суккан бер кешене ятагы белән
күтәреп алып килделәр һәм аны, Гайсә алдына куяр өчен, өйгә
алып керергә тырыштылар. [19] Ләкин, халык арасыннан үтә ал-
маганга күрә, өй түбәсенә менеп, түбәнең чирәпләрен сүтеп
алдылар һәм авыруны ятагы белән бергә Гайсәнең алдына тө-
шерделәр. [20] Гайсә, аларның ышануларын күреп, теге кешегә:

– Дустым, синең гөнаһларың кичерелде, – диде.

[21] Канунчылар һәм фарисейләр:

– Көфер сүз сөйләүче бу Кеше – Кем ул? Гөнаһларны Алла-
һыдан башка кем кичерә ала? – дип уйладылар.

[22] Гайсә, аларның уйларын белеп, болай диде:

– Ни өчен сез шулай уйлыйсыз? [23] Ничек дип әйтергә җи-
ңелрәк: «Синең гөнаһларың кичерелде», – дипме, әллә: «Тор
һәм йөр», – дипме? [24] Адәм Улының җирдә гөнаһларны киче-
рергә хакимлеге барлыгын белеп торыгыз.

Һәм Гайсә паралич суккан кешегә:

– Сиңа әйтәм: тор, ятагыңны ал да өеңә кайт, – диде.

[25] Ул кеше шундук барысының күз алдында торды һәм, ята-
гын алып, Аллаһыны данлый-данлый, өенә кайтып китте.
[26] Барысы да таң калдылар, Аллаһыны данладылар. Һәммәсе,
куркып калып:

– Без бүген искитәрлек нәрсәләр күрдек, – диделәр.

*Гайсә Левине чакыра*

[27] Шуннан соң Гайсә ул урыннан китте һәм салым җыю
йорты янында утыручы Леви атлы салым җыючыны күрде.

– Минем артымнан бар, – диде Ул аңа.

[28] Леви торып басты һәм, бөтен нәрсәсен калдырып, Гайсә
артыннан китте.

[29] Леви үзенең өендә Гайсә хөрмәтенә зур мәҗлес җыйды.
Кунаклар арасында салым җыючылар һәм башка кешеләр дә

---

* 5:17 *Фарисей* – борынгы яһүдләр арасындагы дини төркем әгъзасы.

күп иде. 30 Фарисейләр һәм аларның төркеменнән булган ка-
нунчылар, ачуланып, Гайсәнең шәкертләренә:

– Ни өчен сез салым җыючылар белән, гөнаһлылар белән бергә ашап-эчеп утырасыз? – диделәр.

31 Гайсә аларга:

– Табиб сәламәт кешеләргә түгел, ә авыруларга кирәк.
32 Мин тәкъваларны түгел, ә гөнаһлыларны тәүбәгә чакырырга
дип килдем, – дип җавап бирде.

*Ураза тоту хакында сорау*

33 Кайбер кешеләр Гайсәгә:

– Яхъяның шәкертләре дә, фарисейләрнекеләр дә еш ураза тоталар һәм дога кылалар, ә Синекеләр ашыйлар, эчәләр, – дип әйттеләр.

34 Ә Ул аларга:

– Кияү егете туйдагы кунаклар янында булган вакытта аның
дусларын ураза тотарга мәҗбүр итеп буламы? 35 Әмма килер бер
көн: алар яныннан кияү алыныр һәм шул көннәрдә ураза тотарлар, – диде.

36 Ул аларга киная белән сөйләде:

– Беркем дә яңа киемнән ямаулык ертып алып иске киемне ямамый, чөнки яңасы да бозыла, иске киемгә дә яңа тукымадан алынган ямаулык бармый.

37 Беркем дә яңа шәрабны иске турсыкка салмый, чөнки
яңа шәраб турсыкны тишә һәм шәраб та агып бетә, турсык
та әрәм була. 38 Киресенчә, яңа шәраб яңа турсыкка салы-
нырга тиеш.

39 Беркем дә иске шәрабны эчкәннән соң яңасын эчәргә теләмәс. «Искесе яхшырак шул», – дияр.

6 1 Бер шимбә көнне Гайсә иген кырлары аша үткәндә, шәкертләре, башаклар өзеп, учларында уып, бодай бөртекләрен ашап бардылар.

2 Кайбер фарисейләр исә аларга:

– Ни өчен сез шимбә көнне эшләргә ярамаганны эшлисез? – диделәр.

3 Гайсә аларга:

– Давыт һәм аның белән булган кешеләр ачыккач, Давыт-
ның нәрсә эшләгәне хакында укымадыгызмы әллә? 4 Ул, Изге
йортка кереп, руханилардан башка беркемгә дә ашарга рөхсәт ителмәгән Аллаһыга багышланган икмәкләрне алып ашаган,
үзе белән булган кешеләргә дә биргән, – дип җавап бирде.
5 Һәм сүзен тәмамлап: – Адәм Улы – шимбә көненең Хуҗа-
сы, – диде.

*Гайсә кулы корышкан кешене савыктыра*

[6] Икенче бер шимбәдә Гайсә гыйбадәтханәгә килде һәм өйрәтте. Анда уң кулы корышкан бер кеше бар иде. [7] Канунчылар һәм фарисейләр исә, Гайсәне гаепләргә сәбәп табу өчен, шимбә көнне авыруларны савыктырмасмы икән дип, Аны күзәтеп тордылар.
[8] Ә Гайсә аларның уйларын белә иде. Ул кулы корыган кешегә:

– Тор да уртага бас, – диде.

Теге кеше уртага килеп басты.

[9] – Мин сезгә шундый сорау бирәм, – диде аларга Гайсә, – шимбә көнне яхшылык эшләргә рөхсәт ителәме, әллә начарлык эшләргәме? Кешенең тормышын коткарыргамы, әллә аны һәлак итәргәме?

[10] Гайсә барысына да әйләнеп карады һәм теге кешегә:

– Кулыңны суз! – диде.

Ул кеше шулай эшләде, һәм аның кулы савыкты. [11] Ә фарисейләрнең һәм канунчыларның ачулары бик нык кабарды һәм алар, Гайсәгә каршы нәрсә эшләргә икән дип, бер-берсе белән сөйләшә башладылар.

*Унике рәсүлне сайлау*

[12] Шул көннәрдә Гайсә дога кылу өчен тауга менде һәм төн буе Аллаһыга дога кылды. [13] Иртәгесен шәкертләрен Үзе янына чакырды да алар арасыннан уникесен сайлап алды һәм аларны рәсүлләр дип атады. [14] Ул Петер дип атаган Шимунны һәм аның энесе Әндрине, Ягъкубны һәм Яхъяны, Филипне һәм Бартулумайны, [15] Маттайны һәм Томасны, Һалфай улы Ягъкубны һәм Көрәшүче кушаматлы Шимунны, [16] Ягъкуб улы Яһүд һәм хыянәт итәчәк Яһүд Искариотны сайлап алды.

*Гайсә күпләрне савыктыра*

[17] Рәсүлләр белән бергә Гайсә таудан төште. Тау итәгендә, тигез җирдә, Аның күп шәкертләре, бөтен Яһүдиядән, Иерусалимнан һәм диңгез буендагы Тур һәм Сидун шәһәрләреннән килгән бик күп халык җыелган иде. [18] Алар Гайсәне тыңларга, авыруларыннан савыгырга дип килгәннәр иде. Шакшы рухлардан газап чигүчеләр дә савыктылар. [19] Һәммәсе Гайсәгә кагылырга тырышты, чөнки Аннан чыккан кодрәт барысын да савыктыра иде.

*Нәрсәдә бәхет, нәрсәдә кайгы*

[20] Гайсә шәкертләренә карап сөйли башлады:

– Фәкыйрьләр, сез бәхетле,
чөнки Аллаһы Патшалыгы сезнеке.

[21] Хәзер карыннары ачлар, сез бәхетле,
чөнки сез туеначаксыз.
Хәзер елаучылар, сез бәхетле,
чөнки көләчәксез.

[22] Кешеләр сезгә Адәм Улы өчен нәфрәт иткәндә, сезне куып
җибәргәндә, хурлаганда, сезне кабул итмәгәндә сез бәхетле.
[23] Шул көнне куаныгыз һәм шатлыктан сикерегез, чөнки күктә
сезгә әҗер зур булачак. Ул кешеләрнең ата-бабалары пәйгам-
бәрләр белән дә шулай ук эшләгәннәр.

[24] Байлар, ә сезгә кайгы!
Сез инде җитәрлек юандыгыз.
[25] Хәзер тук булганнар, сезгә кайгы!
Чөнки сез ачыгырсыз.
Хәзер көлүчеләр, сезгә кайгы!
Чөнки сез хәсрәткә төшәрсез һәм еларсыз.
[26] Сезне бар кешеләр мактый икән,
сезгә кайгы!
Чөнки аларның аталары да
ялган пәйгамбәрләрне шулай мактаганнар.

*Дошманнарыгызны яратыгыз*

[27] – Ә сезгә, мине тыңлаучыларга, әйтәм: дошманнарыгызны
яратыгыз, сезне нәфрәт итүчеләргә яхшылык эшләгез, [28] сезне
каргаучыларны фатихалагыз һәм үзегезне рәнҗетүчеләр өчен
дога кылыгыз. [29] Бер яңагыңа суккан кешегә икенче яңагыңны
да куй, өс киемеңне тартып алучы кешегә күлмәгеңне дә тар-
тып алырга комачаулама. [30] Үзеңнән сораучы һәр кешегә бир,
һәм синекен алган кешедән кире сорама. [31] Кешеләрнең сезгә
нәрсә эшләвен теләсәгез, кешеләргә шуны эшләгез. [32] Үзегезне
яратучыларны гына яратсагыз, нәрсә өчен сезгә рәхмәт әйтер-
гә? Үзләрен яратучыларны гөнаһлылар да яраталар. [33] Үзегезгә
яхшылык кылучыларга гына яхшылык эшләсәгез, нәрсә өчен
сезгә рәхмәт әйтергә? Гөнаһлылар да шулай эшлиләр. [34] Бу-
рычка биргәндә, кире алырмын дип уйлап бирсәгез, нәрсә
өчен сезгә рәхмәт әйтергә? Гөнаһлылар да башка гөнаһлыларга
бурычка биргәндә: «Шулкадәр үк кайтарып алырмын», – дип
уйлап бирәләр. [35] Ә сез, киресенчә, дошманнарыгызны яраты-
гыз, аларга яхшылык эшләгез, кире алырмын дип өметләнми-
чә бурычка бирегез. Шулай эшләсәгез, сезгә әҗер зур булыр
һәм сез Аллаһы Тәгаләнең балалары булырсыз. Чөнки Ул ях-
шылыкның кадерен белмәүчеләргә һәм явызларга да миһер-
банлы. [36] Атагыз шәфкатьле булган кебек, сез дә шәфкатьле
булыгыз.

*Башкаларны хөкем итмәгез*

[37] Хөкем итмәгез, үзегезне дә хөкем итмәсләр. Гаепләмәгез,
үзегезне дә гаепләмәсләр. Кичерегез һәм үзегезне дә кичерерләр.
[38] Бирегез һәм үзегезгә дә бирелер, итәгегезгә күп итеп салып
бирерләр, үлчәү савытын селкетеп, баскалап тыгызларлар, кы-
рыйларыннан түгелә башлаганчы тутырырлар. Нинди үлчәү бе-
лән үлчәп бирсәгез, үзегезгә дә шундый үлчәү белән үлчәрләр.
[39] Гайсә аларга гыйбрәтле сүзләр сөйләде:
– Сукыр сукырны җитәкләп бара аламы? Икесе дә чокырга
егылып төшмәсләрме?
[40] Шәкерт үзенең остазыннан өстен булмый, ә өйрәнеп җит-
кәннән соң һәркем остазы кебек була.
[41] Ничек син туганыңның күзендәге чүп бөртеген күрәсең, ә
үз күзеңдәге бүрәнәне сизмисең? [42] Ничек син, үз күзеңдә бүрә-
нә була торып, туганыңа: «Кая, туган, күзеңдәге чүпне алыйм
әле», – дип әйтә аласың? Монафикъ! Элек үз күзеңдәге бүрә-
нәне чыгар, аннары инде күзләрең ачык күрер һәм туганыңның
күзендәге чүпне ала алырсың.
[43] Бер яхшы агач та начар җимеш бирми, һәм, киресенчә, бер
начар агач та яхшы җимеш китерми. [44] Һәр агачны җимешенә
карап таныйлар! Күгән куагыннан – инҗир, ә чәнечкеле агач-
тан йөзем җыймыйлар. [45] Яхшы кеше үз күңелендәге яхшылык
хәзинәсеннән яхшылык алып чыга, ә явыз кеше күңелендәге
явызлык хәзинәсеннән явызлык алып чыга. Чөнки кешенең
күңеленнән нәрсә ташый, аның телендә дә шул була.

*Ике төзүче*

[46] Ни өчен сез Миңа: «Раббым! Раббым!» – дисез, ә үзегез
Мин әйткәннәрне үтәмисез? [47] Минем яныма килеп, Мине
ишетеп, сүзләремне үтәүчене менә нинди кешегә тиңләп була:
[48] ул, йорт төзегәндә җирне тирән итеп казып, аны таш нигез
өстенә салган кеше кебек. Ташкын вакытында ярларыннан
чыккан сулар йортка килеп бәрелгән, ләкин аны селкетә алма-
ган, чөнки ул нык итеп төзелгән булган. [49] Ә инде ишетеп тә
сүзләремне үтәмәүче кеше – нигез кормыйча гына җир өстенә
йорт салган кеше кебек. Ташкын сулары йортка килеп бәрел-
гән, һәм ул шундук авып төшкән, бик нык җимерелгән.

*Йөзбашының хезмәтчесен савыктыру*

# 7

[1] Халыкка әйтәсе сүзләрен сөйләп бетергәннән соң Гайсә
Кәпәрнаумга килде.
[2] Бер йөзбашының үзе бик ихтирам иткән хезмәтчесе авы-
рып үлем хәлендә ята иде. [3] Йөзбашы, Гайсә турында ишеткәч,

килеп хезмәтчемне коткарсын иде, дигән үтенеч белән яһүдләрнең аксакалларын Гайсә янына җибәрде. 4-5 Алар, Гайсә янына килеп җиткәч:

– Ул йөзбашы Синең ярдәмеңә лаек, чөнки ул безнең халыкны ярата. Гыйбадәтханәне дә безгә ул салдырды, – дип, чын күңелләреннән ялвардылар.

6 Һәм Гайсә алар белән китте. Йөзбашының өенә җитәргә бераз калгач, йөзбашы, Гайсәгә шушы сүзләрне әйтергә дип, дусларын җибәрде:

– Мәшәкатьләнмә, Әфәндем! Сине үз йортымда кабул
итәргә мин лаеклы түгел. 7 Шуңа күрә Синең каршыңа барырга
да үземне лаеклы дип санамадым. Син әйт кенә, һәм минем
хезмәтчем савыгачак. 8 Мин үзем дә башка берәүгә буйсынам,
һәм минем кул астымда гаскәриләр бар. Аларның берсенә: «Кит», – дисәм, китә. Икенчесенә: «Кил», – дисәм, килә. Хезмәтчемә: «Моны эшлә», – дисәм, эшли.

9 Бу сүзләрне ишетеп, Гайсә хәйран калды һәм, борылып, Үзе артыннан ияреп баручы халыкка:

– Мин сезгә шуны әйтәм: хәтта Исраилдә дә мондый ышануны күрмәгән идем, – диде.

10 Җибәрелгән кешеләр, әйләнеп кайткач, авыру хезмәтченең савыккан булуын күрделәр.

### *Тол хатынның үлгән улын терелтү*

11 Озак вакыт үтмәстән Гайсә Наин дип аталган шәһәргә
китте. Шәкертләре һәм күп халык Аңа ияреп барды. 12 Гайсә
шәһәр капкасына якынлашып килгәндә, шәһәрдән мәет күтәреп чыгалар иде. Бер тол хатынның бердәнбер улы үлгән икән. Шәһәрдән хатын белән бергә күп кешеләр чыгып килә иде.
13 Раббы, хатынны күргәч, аны бик кызганды.

– Елама, – диде Ул хатынга.

14 Аннары Гайсә, алар янына килеп, табутка кулын тидерде. Табутны күтәреп баручылар туктадылар, һәм Гайсә:

– Егет, сиңа әйтәм, тор! – диде.

15 Үлгән егет торып утырды һәм сөйләшә башлады. Шулай
итеп Гайсә аны анасына кайтарып бирде. 16 Барысы да куркып
калдылар һәм Аллаһыны данладылар.

– Безнең арадан бөек Пәйгамбәр чыкты. Аллаһы Үз халкына ярдәмгә килде, – диделәр.

17 Гайсә хакындагы мондый хәбәр бөтен яһүдләр иленә һәм аның тирә-ягына таралды.

### *Гайсәнең Яхъяга җавабы*

18-19 Яхъя пәйгамбәрнең шәкертләре бу хәлләрнең барысы хакында остазларына сөйләделәр. Ул: «Килергә тиеш булган Зат Синме, әллә бүтән берәүне көтикме?» – дип сорарга Раббы янына ике шәкертен җибәрде.
20 Гайсә янына килгәч, алар:

– Чумдыручы Яхъя Синнән: «Килергә тиеш булган Зат Синме, әллә бүтән берәүне көтикме», – дип сорарга җибәрде, – диделәр.

21 Ул вакытта Гайсә күпләрне сырхаулардан, көчле авырулардан, явыз рухлардан савыктырган һәм күп сукырларны күзле иткән иде.

22 Гайсә Яхъядан килгәннәргә болай дип җавап бирде:

– Барыгыз, күргәннәрегезне һәм ишеткәннәрегезне Яхъяга кайтып сөйләгез: сукырлар янә күрә, аксаклар йөри, махаулылар тазарына, чукраклар ишетә, үлгәннәр терелтелә, фәкыйрьләргә Яхшы хәбәр игълан ителә.

23 Кем Минем хакта шикләнми, шул бәхетле.

24 Яхъя җибәргән кешеләр киткәч, Гайсә халыкка Яхъя хакында сөйли башлады:

– Сез чүлгә нәрсә карарга бардыгыз? Җилдә тирбәлә торган камышны карарга дипме?
25 Нәрсә карарга бардыгыз соң сез? Купшы киемнәргә киенгән кешенеме? Ә бит кыйммәтле киемнәргә киенүчеләр һәм зиннәттә яшәүчеләр – патша сарайларында.
26 Ул чакта, нәрсә карарга бардыгыз? Пәйгамбәрнеме? Әйе! Мин сезгә әйтәм, ул пәйгамбәрдән дә бөегрәк!
27 Изге язмада:

«Мин Синең алдыңнан
хәбәрчемне җибәрәм,
ул Синең алдыңнан Сиңа юл әзерләр», –
дип язылган сүзләр аның турында.

28 Мин сезгә шуны әйтәм: хатын-кыздан туган кешеләр арасында Яхъя пәйгамбәрдән бөегрәк берәү дә юк. Ә Аллаһы Патшалыгында иң кечесе дә аннан бөегрәк, – дип әйтте Гайсә.

29 Бу сүзләрне ишеткән бөтен халык, хәтта салым җыючылар да, Аллаһының хак икәнен икърар иттеләр, чөнки алар Яхъя тарафыннан суга чумдырылган иделәр.
30 Ә Яхъя тарафыннан чумдырылмаган фарисейләр һәм канун укытучылары Аллаһының үзләренә карата булган ихтыярын кире кактылар.

31 Гайсә дәвам итеп:

– Шулай итеп, бу буын кешеләрен нәрсәгә тиңләп була, алар нәрсәгә охшаган? – диде. –
32 Алар:

«Без сезгә күңелле көйләр уйнадык,
ә сез биемәдегез.

Без кайгылы җырлар җырладык,
  ә сез еламадыгыз», –
дип, базар мәйданында бер-берсенә кычкырып утыручы балаларга охшый. [33] Чумдыручы Яхъя килде, икмәк тә ашамый,
шәраб та эчми. Ә сез: «Ул – җенле», – дисез. [34] Адәм Улы кил-
де. Ашый да, эчә дә, һәм сез: «Күрегез әле, бирән, эчкече,
салым җыючыларның һәм гөнаһлыларның дусты», – дисез.
[35] Ә Аллаһының Зирәклеге барлык балалары тарафыннан хак
дип исбат ителде.

*Гөнаһлы хатын Гайсәнең аякларын майлый*

[36] Фарисейләрнең берсе Гайсәне ашка чакырды. Гайсә, фарисейнең өенә кереп, табын янына утырды. [37] Шул шәһәрдә
яшәүче гөнаһлы бер хатын, Гайсәнең фарисей өендә ашап утыруын белеп, алебастр савытка салынган хуш исле май алып,
шул йортка килде. [38] Ул Гайсәнең артында елап басып торды,
күз яшьләре Аның аякларын чылатты. Гайсәнең аякларына тамган күз яшьләрен үзенең чәчләре белән сөртеп, Аның аякларын үбә-үбә, хуш исле май белән майлады.
[39] Гайсәне ашка чакырган фарисей моны күреп: «Әгәр ул
пәйгамбәр булса, үзенә кагылучы хатынның нинди икәнлеген белер иде. Ул бит гөнаһлы хатын», – дип уйлады.
[40] Гайсә аңа:
– Шимун! Мин сиңа бер нәрсә әйтергә телим, – диде.
– Әйт, Остаз, – диде фарисей.
[41] Гайсә әйтте:
– Ике кешенең әҗәткә биреп торучы берәүгә бурычлары бар икән: берсенең бурычы биш йөз динар*, ә икенчесенең –
илле динар. [42] Ләкин, алар түли алмаганлыктан, ул икесен дә
бәхилләгән. Ничек уйлыйсың, аларның кайсысы аны күбрәк яратыр?
[43] – Бурычы күбрәк булганыдыр, дип фараз кылам, – диде Шимун.
Гайсә аңа:
– Син дөрес уйлыйсың, – диде. [44] Һәм, хатынга таба борылып, Шимунга:
– Бу хатынны күрәсеңме? Мин синең өеңә килдем, ә син аяк юарга су бирмәдең. Ә бу хатын аякларымны күз яшьләре белән
чылатты, чәчләре белән сөртте. [45] Син Мине үпмәдең, ә ул,
Мин монда килгәннән бирле, аякларымны үбүдән туктамый.

---

* **7:41** *Динар* – көмеш тәңкә. Эшченең бер көнлек хезмәт хакын тәшкил иткән.

[46] Син Минем башыма май сөртмәдең, ә ул Минем аякларымны
хуш исле май белән майлады.* [47] Мин әйтермен ни өчен икән-
леген: аның гөнаһлары күп иде, һәм алар кичерелде, шуңа күрә
аның мәхәббәте зур. Ә кемгә аз кичерелә, ул аз ярата.
[48] Һәм Гайсә хатынга:
– Гөнаһларың кичерелде, – диде.
[49] Табын артында утыручылар бер-берсе белән:
– Кем Ул? Ул хәтта гөнаһларны да кичерә! – дип сөйләшә
башладылар.
[50] Гайсә исә хатынга:
– Ышануың сине коткарды, имин йөр, – диде.

8 [1] Шуннан соң Гайсә шәһәрләр һәм авыллар буйлап Алла-
һы Патшалыгы хакындагы Яхшы хәбәрне сөйләп йөрде.
Унике шәкерте Аның белән булды. [2] Гайсә явыз рухлардан
һәм авырулардан савыктырган хатын-кызларның берничәсе:
эченнән Гайсә җиде җенне куып чыгарган Мәрьям, аны Маг-
далалы дип йөрткәннәр, [3] Һируд йортында идарә итүче Хузас
хатыны Йохана, Сусанна һәм башка күп хатыннар да Аның бе-
лән иделәр. Хатын-кызлар Гайсәгә һәм Аның шәкертләренә
үзләре хисабына ярдәм итәләр иде.

*Чәчүче хакында гыйбрәтле хикәя*

[4] Үзе янына төрле шәһәрләрдән күп халык җыелганда Гайсә
гыйбрәтле хикәя сөйләде:
[5] – Бер чәчүче үзенең орлыкларын чәчәргә чыккан. Чәчкән
вакытта орлыкларның кайберләре юл буена төшкән һәм тап-
талган, аларны кошлар чүпләп бетергән. [6] Кайберләре ташлы
туфракка төшкән һәм тишелеп чыксалар да, дым булмаган-
лыктан кипкәннәр. [7] Кайбер орлыклар күгәнлеккә төшкән.
Күгән куаклары, алар белән бергә үсеп, аларны басып киткән.
[8] Ә башка орлыклар яхшы җиргә төшкән һәм, үсеп китеп, бер
орлыктан йөз бөртек уңыш китергән.
Сөйләп бетергәч, Гайсә кычкырып:
– Ишетергә колаклары булганнар – ишетсен! – диде.
[9] Гайсәнең шәкертләре исә Аннан:
– Бу кинаяле хикәянең мәгънәсе нидә? – дип сорадылар.
[10] Ул аларга:

---

* 7:44-46 Яһүдләр кунакларга аяк юарга су тәкъдим итә торган бул-
ганнар, гадәттә кешеләр яланаяк яки ачык аяк киеме киеп йөргәнгә
күрә, аяклары бик тузанлана торган булган. Шулай ук, хуҗа кеше
кунакның битләреннән үпкән һәм аерата хөрмәтле кунакның башы-
на хуш исле май сөрткәннәр.

– Аллаһы Патшалыгының серләрен белү сезгә бирелгән, ә башкаларга, караганда күрмәсеннәр, тыңлаганда төшенмәсен-нәр өчен, кинаяле хикәяләр белән сөйлим.
11 Кинаяле хикәянең исә мәгънәсе менә шундый: орлык –
Аллаһы сүзе. 12 Орлыкларның юл буена төшүе: кешеләр сүзне
ишетәләр, әмма иблис килә һәм, сүзне ишеткән кешеләр ыша-
нып котылмасын өчен, аларның күңелләрендәге сүзне алып
китә. 13 Орлыкларның ташлы туфракка төшүе исә: кешеләр сүз-
не ишетәләр, аны шатланып кабул итәләр, әмма тамырлары
булмаганлыктан, ышанулары кыска вакытлы була, һәм алар
сынау вакытында чигенәләр.
14 Ә орлыкларның күгәнлеккә төшүе: кешеләр сүзне ишетә,
ләкин тормыштагы төрле мәшәкатьләр, байлык һәм ләззәт-
ләр аларны басып китә һәм андый кешеләрнең җимешләре
өлгерми.
15 Ә орлыкларның уңдырышлы җиргә төшүе исә: сүзне ише-
теп, ихластан һәм яхшы күңел белән ул сүзне тотучы кешеләр.
Андыйлар, түземлелек күрсәтеп, җимеш бирәләр.

*Янып торган шәмне шәмдәлгә куялар*

16 Шәмне яндырып җибәргәч, савыт белән капламыйлар,
сәке астына да куймыйлар. Киресенчә, керүчеләр яктылыкны
күрсен өчен, шәмдәлгә утырталар. 17 Чөнки фаш ителмичә ка-
лачак бер яшерен нәрсә дә, беленмичә, ачылмыйча калачак бер
сер дә юк. 18 Шулай итеп, ничек тыңлавыгызга игътибар итегез.
Чөнки кемнең бар, шуңа бирелер; ә кемнең юк, аның, бар дип, уйлаганы да тартып алыныр.

*Гайсәнең анасы һәм энеләре*

19 Анасы белән энеләре Гайсә янына килгәч, халык күп бул-ганлыктан, Аның янына керә алмаганнар.
20 – Әниең белән энеләрең Сине күрергә телиләр, алар тышта торалар, – дип әйттеләр Гайсәгә.
21 Ә Ул аларга:
– Минем анам һәм туганнарым – Аллаһы сүзен тыңлаучылар һәм аны үтәүчеләр, – дип җавап бирде.

*Гайсә давылны тынычландыра*

22 Шулай бер көнне Гайсә шәкертләре белән көймәгә утырды:
– Күлнең аръягына чыгыйк, – диде Ул һәм алар кузгалдылар.
23 Көймәдә барганда Ул йоклап китте. Күл өстендә көчле давыл купты, көймәгә су тула башлады: аларга куркыныч яный иде.

[24] Янына килеп, шәкертләр Гайсәне уяттылар.
– Өйрәтүче! Өйрәтүче! Батабыз! – дип кычкырдылар алар.
Ә Гайсә исә, торып, җилне дә, котырынган дулкыннарны да тыйды. Бар да туктады һәм тынлык урнашты.
[25] Ул аларга:
– Иманыгыз кайда? – диде.
Алар исә курыктылар һәм гаҗәпләнеп бер-берсенә:
– Кем соң Ул? Җилгә дә, суга да әмер бирә, һәм алар Аңа буйсына, – диештеләр.

*Гайсә җенле кешене савыктыра*

[26] Көймәдәгеләр Гәлиләя өлкәсенә каршы күлнең икенче
ягында урнашкан Герәсә җиренә килеп җиттеләр. [27] Гайсә ярга
төшкәч, шундагы шәһәрнең бер кешесе, җенле кеше, Аның
каршына чыкты. Ул кеше инде күптәннән кием кими, йортта
түгел, ә каберләр* арасында яши иде. [28] Гайсәне күргәч, акырып,
Аның алдына егылды һәм каты тавыш белән:
– Аллаһы Тәгаләнең Улы Гайсә, Сиңа миннән ни кирәк? Үтенеп сорыйм, газаплама мине, – диде.
[29] Чөнки Гайсә шакшы рухка ул кешедән чыгарга боерган иде. Шакшы рух аны инде күптәннән газаплаган. Чылбырлар һәм богаулар белән бәйләп саклаганда да ул кеше богауларны өзгән, җен аны чүлләргә куып алып китә торган булган.
[30] Гайсә аннан:
– Исемең ничек? – дип сорады.
Ул:
– Гаскәр**, – диде. Чөнки аның эченә күп җеннәр кергән иде.
[31] Җеннәр Гайсәдән үзләрен төпсез упкынга җибәрмәвен үтенеп сорадылар.
[32] Андагы тауда зур дуңгыз көтүе утлап йөри иде. Җеннәр,
шул дуңгызлар эченә керергә рөхсәт сорап, Гайсәгә ялвардылар.
Ул аларга рөхсәт итте. [33] Теге кешенең эченнән чыгып,
җеннәр дуңгызлар эченә керделәр. Көтү, чабып китеп, текә
ярдан күлгә ташланды һәм батып үлде.
[34] Көтүчеләр исә, булган хәлне күреп, качып киттеләр, шәһәрдә
һәм шәһәр тирәсендәге авылларда барысын сөйләп йөрделәр.
[35] Кешеләр, нәрсә булды икән, дип, шул урынга киттеләр.
Алар Гайсә булган җиргә килеп җиткәндә, эченнән җеннәре

* 8:27 *Кабер* – яһүдләр мәетләрне тауны тишеп ясалган мәгарә-каберләргә куйганнар.
** 8:30 *Гаскәр* – грекча «легион» – римлыларның 6000 сугышчыдан торган иң зур хәрби төркеме.

чыккан кешенең Гайсә янында киенгән һәм акылына килгән хәлдә утыруын күреп, куркып калдылар. 36 Бу хәлне күргән кешеләр аларга җенле булган ирнең савыктырылуы хакында сөйләп бирделәр.

37 Герәсә җире тирәсендә яшәүче бөтен кеше бик нык куркып калды, шуңа күрә Гайсәнең ул җирләрдән китүен сорадылар. Ул, көймәгә утырып, юлга кузгалганда, 38-39 җеннәре куып чыгарылган кеше:

– Синең белән китәргә рөхсәт ит, – дип ялварды.

Әмма Гайсә:

– Өеңә кайт һәм, Аллаһы синең өчен нәрсә эшләде, шул турыда сөйлә, – дип, аны кайтарып җибәрде.

Ул кеше Гайсәнең аның өчен нәрсә эшләгәне хакында бөтен шәһәр буйлап сөйләп йөрде.

*Гайсә үлгән кызны һәм авыру хатынны терелтә*

40 Гайсәнең әйләнеп кайтуын барысы да көтәләр иде, шуңа күрә җыелган халык Аны шатланып каршы алды. 41 Шунда гыйбадәтханә башлыгы Яһир Гайсә янына килде. Ул, Гайсәнең аякларына егылып, ялварып, Аны үзенең өенә чакырды, 42 чөнки аның унике яшьләр тирәсендәге бердәнбер кызы үлем хәлендә ята иде. Яһирнең өенә барганда Гайсәне бар яктан халык төркеме кысрыклады.

43 Шунда унике ел буе кан китүдән газап чиккән бер хатын-кыз бар иде. Ул бөтен байлыгын табибларга сарыф иткән, аны беркем дә савыктыра алмаган. 44 Хатын, арттан Гайсә янына килеп, киеменең чабуына кагылды, һәм аның кан китүе шундук туктады.

45 Гайсә:

– Кем Миңа кагылды? – дип сорады.

Барысы да инкяр иттеләр. Петер:

– Өйрәтүче! Сине урап алганнар. Бар яктан кысрыклыйлар! – диде.

46 Ләкин Гайсә:

– Кемдер Миңа кагылды, Мин Үземнән көч чыкканын сиздем, – диде.

47 Теге хатын исә, яшеренеп кала алмаячагын күреп, калтырана-калтырана Гайсә янына килде. Аның алдына егылып, ни өчен кагылганлыгын һәм ничек итеп шундук савыкканлыгын бөтен халык алдында сөйләп бирде.

48 Гайсә аңа:

– Кызым! Ышануың сине савыктырды! Имин йөр, – диде.

49 Гайсә шул сүзләрне әйткән арада, гыйбадәтханә башлыгының өеннән килгән бер кеше:

– Кызың вафат булды, Остазны бүтән борчыма, – диде.
50 Әмма Гайсә, аның шулай дигәнен ишетеп, Яһиргә:
– Курыкма, ышан гына һәм кызың савыгачак, – диде.
51 Яһирнең өенә килеп житкәч, Петердән, Яхъядан, Ягъкуб-
тан һәм кызның әти-әнисеннән башка берәүгә дә керергә рөх-
сәт итмәде.
52 Барысы да елый, кыз өчен хәсрәтләнә иделәр*. Әмма Гайсә:
– Еламагыз, ул үлмәгән, йоклый гына, – диде.
53 Ә андагы кешеләр исә Аңардан көлделәр, чөнки кызның
үле икәнен беләләр иде.
54 Гайсә, кызның кулыннан тотып:
– Балам, тор, – дип кычкырып әйтте.
55 Кызга җан керде һәм ул шундук урыныннан торды. Гайсә
аны ашатырга кушты.
56 Кызның әти-әнисе хәйран калдылар. Ә Гайсә аларга бу хәл
турында беркемгә дә сөйләмәскә кушты.

*Гайсә унике шәкертен җибәрә*

9 1 Гайсә унике шәкертен чакырып китерде дә, бөтен җеннәр-
не куып чыгарырга, авыруларны дәваларга куәт, вәкаләт
биреп, 2 аларны Аллаһы Патшалыгы хакында вәгазь сөйләр-
гә һәм авыру кешеләрне савыктырырга җибәрде. 3 Ул аларга:
– Юлга бернәрсә дә алмагыз. Юл таягы да, биштәр дә, акча
да, алмаш күлмәк тә алырга кирәк түгел, – диде. – 4 Нинди
йортка керсәгез, ул шәһәрдән киткәнче, шул йортта калыгыз.
5 Әгәр сезне кабул итмәсәләр, ул шәһәрдән киткәндә, аларга
каршы шаһитлек билгесе итеп, аякларыгыздагы тузанны кагып
төшерегез.
6 Шәкертләр юлга чыктылар һәм, бөтен җирдә Яхшы хәбәрне
таратып, авыруларны савыктырып, авылдан-авылга йөрделәр.

*Һируд аптырашта кала*

7 Идарәче Һируд боларның барысы турында ишетеп апты-
рашта кала. Чөнки кайберәүләр: «Бу – үледән терелеп торган
Яхъя», 8 кайсылары: «Ильяс җиргә килгән», башкалары исә:
«Борынгы пәйгамбәрләрнең берсе терелгән», – дип әйтәләр
иде. 9 Ә Һируд:
– Яхъяның башын мин үзем кистердем, ә Монысы кем соң:
миңа Аның турында шундый нәрсәләр ишеттерәләр? – диде.
Һируд Аны күрергә теләде.

---

* 8:52 *Хәсрәтләнә иделәр* – грекча сүзгә-сүз «үзләренең күкрәкләрен кыйный иделәр»; яһүдләр матәм хисләрен шулай күрсәткәннәр.

*Биш меңне ашату*

[10] Әйләнеп кайткач, башкарган эшләре турында рәсүлләр
Гайсәгә сөйләп бирделәр. Үзе белән аларны гына алып, Ул
Бәйтсайда дигән шәһәргә китте. [11] Ләкин, Гайсәнең кая кит-
кәнен белеп, халык Аның артыннан барды. Гайсә аларны теләп
кабул итте, аларга Аллаһы Патшалыгы турында сөйләде һәм
савыгуга мохтаҗларны савыктырды. [12] Көн кичкә авыша башла-
ды. Унике шәкерт Гайсә янына килеп:

– Зинһар өчен, халыкны тарат, якын-тирәдәге авылларга, утарларга барып, үзләренә кунар урын эзләсеннәр. Монда бит кеше йөрми торган урын, – диделәр. [13] Ә Гайсә:

– Сез аларны үзегез ашатыгыз, – диде.

– Безнең биш икмәк белән ике балыктан башка һичнәрсәбез юк. Мондагы кешеләрнең барысына ризыкны без сатып алыйкмы? – диделәр шәкертләр.

[14] Ә анда биш мең чамасы кеше бар иде. Гайсә шәкертләренә:

– Аларны төркемнәргә бүлеп, якынча иллешәр кеше итеп утыртыгыз, – диде.

[15] Шәкертләр шулай эшләделәр, бөтен булган кешене утырт-
тылар. [16] Шуннан соң Гайсә биш икмәкне һәм ике балыкны
кулларына алды да, күккә карап, шөкрана кылды һәм, ризык-
ларны сындыргалап, халыкка өләшер өчен, шәкертләренә бир-
де. [17] Барысы да ашадылар һәм туйдылар, калган сыныкларны
җыеп, унике кәрзингә тутырдылар.

*Кем ул Гайсә?*

[18] Бервакыт Гайсә Үзе генә дога кылганда, шәкертләре Аның янында иделәр, һәм Ул аларга:

– Халык Мине кем дип белә? – дигән сорау бирде.

[19] Алар Аңа:

– Кемдер Чумдыручы Яхъя ди, башкалары исә Ильяс, ә кайберләре, борынгы пәйгамбәрләрнең берсе терелгән дип исәплиләр, – дип җавап бирделәр.

[20] Гайсә алардан сорады:

– Ә сез, сез Мине кем дип беләсез?

Петер Аңа:

– Син Аллаһының Мәсихе, – дип җавап бирде.

[21] Ә Гайсә җитди рәвештә моны беркемгә дә әйтмәскә куш-
ты. [22] Ул:

– Адәм Улы күп газаплар чигәргә, аксакаллар, баш руханилар һәм канунчылар тарафыннан кире кагылырга, үтерелергә әмма өченче көнне терелтеп торгызылырга тиеш, – диде.

*Үз-үзеңнән баш тарт*

23 Гайсә барысына да әйтте:
– Кем Минем арттан барырга тели, үз-үзеннән баш тартсын,
һәр көн үзенең хачын алып Миңа иярсен. 24 Чөнки кем үзенең
тормышын саклап калырга тели, аны югалтыр, ә кем тормышын
Минем хакка югалта, ул аны саклап калыр. 25 Үзен югалта яки
үзен һәлак итә икән, бөтен дөньяны үзенеке итүдән кешегә ни
файда? 26 Кем Миннән һәм Минем сүзләремнән гарьләнә, Адәм
Улы да Үзенең балкып торган шөһрәте белән, Атаның һәм изге
фәрештәләрнең даны белән килгән вакытта ул кешедән гарьлә-
нер. 27 Сезгә хак сүз әйтәм: монда басып торучыларның кайбер-
ләре Аллаһы Патшалыгын күргәнче үлемне татымаячаклар.

*Гайсәнең тышкы кыяфәте үзгәрә*

28 Шушы сүзләрне сөйләгәннән соң сигез көн чамасы үткәч,
Петерне, Яхъяны һәм Ягъкубны Үзе белән алып, Гайсә дога
кылырга дип тауга менде. 29 Гыйбадәт кылган вакытта Аның
йөзе үзгәрде, киеме ялтырап торган ак төскә керде. 30-31 Шул
вакыт ике кеше, балкып торган шөһрәттә пәйда булып, Аның
белән сөйләшә башладылар. Алар, Муса белән Ильяс, Гайсәнең
Иерусалимда гамәлгә ашырырга тиеш булган дөньядан китүе
хакында әйттеләр. 32 Петер һәм аның белән бергә булган шәкерт-
ләрне йокы баскан иде. Уянып китеп, Гайсәнең балкып торган
шөһрәтен һәм Аның янында торган ике кешене күрделәр. 33 Ул
кешеләр Гайсә яныннан киткән вакытта, Петер Гайсәгә:
– Өйрәтүче! Безнең монда булуыбыз нинди яхшы! Без монда
өч чатыр корыйк, берсен Сиңа, берсен Мусага, берсен Ильяс-
ка, – диде.
Ул нәрсә әйткәнен дә белми иде. 34 Петер әйтеп тә бетер-
мәде, бер болыт пәйда булды һәм аларны каплап алды. Алар
болыт эчендә калгач, шәкертләр курыктылар. 35 Болыттан:
– Бу – Минем сайлап алынган Улым. Аны тыңлагыз! – дигән
сүзләр ишетелде.
36 Тавыш әйтеп бетергәч, шәкертләр Гайсәнең бер Үзе генә
калганын күрделәр. Алар бу хәлне сер итеп сакладылар, күргән-
нәре хакында ул көннәрдә беркемгә бернәрсә сөйләмәделәр.

*Гайсә җенле малайны савыктыра*

37 Икенче көнне, алар таудан төшкәч, Гайсәне күп халык кар-
шы алды. 38 Шунда халык арасыннан берәү:
– Остаз! Ялварып сорыйм Синнән, минем улымны килеп ка-
ра, зинһар өчен. Ул минем бердәнбер балам, – дип кычкырды. –

39 Явыз рух аңа һөҗүм итә һәм бала кинәт кычкыра башлый,
тәне тартыша, авызыннан күбекләр чыга. Явыз рух аны бер дә
калдырмый, ул аны харап итә! 40 Шәкертләреңнән аны куып
чыгаруларын үтенгән идем, чыгара алмадылар.

41 – Әй, имансыз һәм бозык буын! Миңа сезнең белән күпме вакыт булырга, сезне күпме түзеп торырга? Улыңны алып кил, – диде аңа Гайсә.

42 Малай Гайсә янына килгән вакытта җен аны җиргә екты һәм ул тартыша башлады. Әмма Гайсә шакшы рухны тыйды һәм баланы савыктырды, аннары үсмерне атасы кулына тапшырды.

43 Аллаһының бөеклеген күреп барысы да таң калдылар.

*Гайсә Үзенең китүе хакында әйтә*

Халык Гайсә кылган эшләргә гаҗәпләнеп торган арада, Ул шәкертләренә:

44 – Бу сүзләрне хәтерегезгә салыгыз: Адәм Улы кешеләр кулына тотып бирелергә тиеш, – диде.

45 Ләкин алар аңламадылар. Бу сүзләрнең мәгънәсе алардан яшерелгән иде, шуңа күрә төшенмәделәр. Ә Гайсәдән сорарга курыктылар.

*Кем иң бөеге?*

46 Шәкертләр үзләре арасыннан кемнең иң бөек булуы турын-
да бәхәсләшә башладылар. 47 Гайсә, аларның уйларын белеп,
бер баланы алды да Үзе янына бастырды:

48 – Бу баланы Минем хакка кабул иткән кеше Мине кабул итә, – диде Ул шәкертләренә. – Ә Мине кабул иткән кеше Мине Җибәрүчене кабул итә. Арагызда иң кечкенәгез чын мәгънәсендә бөек кеше.

*Сезгә каршы булмаган кеше сезнең яклы*

49 Шуннан соң Яхъя әйтте:

– Өйрәтүче! Бер кешенең, Синең исемеңне кулланып, җеннәрне куып чыгаруын күрдек, һәм ул безнең белән Синең артыңнан йөрмәгәнгә күрә, без аңа туктарга куштык.

50 Гайсә аңа:

– Туктатмагыз. Сезгә каршы булмаган кеше сезнең яклы, – диде.

*Гайсәне кабул итмиләр*

51 Күкләргә алыныр вакыты якынлашкач, Гайсә Иерусалимга
барырга булды һәм юлга чыкты. 52 Ул Үзе алдыннан хәбәрчеләр
җибәрде. Алар, Гайсәнең килүенә бөтен нәрсәне әзерләп кую

өчен, Самарея җирендәге бер авылга керделәр. [53] Әмма, Ул
Иерусалимга юл тотканга күрә, Гайсәне анда кабул итмәделәр.
[54] Гайсәнең шәкертләре Ягъкуб белән Яхъя исә, моны күреп:

– Раббыбыз! Күктән ут төшсен һәм аларны юкка чыгарсын, дип боеруыбызны телисеңме? – диделәр.

[55] Ләкин Гайсә, аларга таба борылып, аларны тыйды*. [56] Һәм
алар икенче авылга киттеләр.

*Гайсәгә иярергә теләүчеләрнең кайберләре*

[57] Юлда барганда кемдер Гайсәгә:

– Син кая гына барсаң да, мин Синең артыңнан барырмын, – дип әйтте.

[58] Гайсә аңа:

– Төлкеләрнең өннәре, кошларның ояләры бар, ә Адәм Улының башын терәр урыны да юк, – дип җавап бирде.

[59] Гайсә икенче берәүгә:

– Миңа ияр! – диде.

Ә теге кеше:

– Әфәнде! Өемә кайтып башта атамны күмеп килергә рөхсәт ит, – диде.

[60] Ләкин Гайсә аңа әйтте:

– Үлеләрне үле кешеләр үзләре күмсен. Ә син бар һәм Аллаһы Патшалыгы турындагы Хәбәрне тарат.

[61] Тагын икенчесе:

– Мин Синең артыңнан барырмын, Әфәнде! Ләкин башта өемдәгеләр белән саубуллашып килергә рөхсәт ит, – диде.

[62] Ә Гайсә:

– Сукалый башлагач, артына борылып караган кеше Аллаһы Патшалыгы өчен ышанычлы түгел, – диде.

*Җитмеш ике шәкертне хезмәткә җибәрү*

**10** [1] Раббы, тагын җитмеш ике шәкертен сайлап, Үзе барырга җыенган һәр шәһәргә һәм авылга икешәр-икешәр
итеп Үзе алдыннан җибәрде. [2] Һәм аларга әйтте:
– Урасы ашлык күп, ә уракчылар аз; шуңа күрә ашлыкның
Хуҗасына ялварыгыз, Үзенең ашлыгын урып алу өчен, эшчеләр
җибәрсен. [3] Барыгыз! Мин сезне бүреләр арасына бәрәннәрне
җибәргән кебек җибәрәм. [4] Үзегез белән янчык та, биштәр дә,

---

* 9:55 *Аларны тыйды* – Кайбер кулъязмаларда: «аларны тыйды һәм әйтте: „Сез үзегезнең нинди рухныкы икәнегезне белмисез. Адәм Улы кешеләрне һәлак итү өчен түгел, ә коткару өчен килде“» дигән сүзләр дә бар.

аяк киеме дә алмагыз һәм юлда сәлам бирү өчен туктамагыз.
5 Нинди өйгә керсәгез дә иң элек: «Бу йортка иминлек бул-
сын», – диегез. 6 Анда иминлеккә лаеклы кеше яшәсә, сезнең
иминлегегез аның белән калыр; әгәр юк икән, үзегезгә кире кай-
тыр. 7 Шул өйдә калыгыз, алар нәрсә бирсә, шуны ашагыз һәм
эчегез; чөнки эшче хезмәт хакына лаеклы. Өйдән-өйгә күчеп
йөрмәгез. 8 Кайсы да булса шәһәргә килгәч, анда сезне кабул
итәләр икән, алдыгызга нәрсә куйсалар, шуларны ашагыз. 9 Ан-
дагы авыруларны савыктырыгыз һәм бар кешеләргә: «Сезгә Ал-
лаһы Патшалыгы якынлашты», – диегез. 10 Әмма нинди дә булса
шәһәргә килеп, анда сезне кабул итмәсәләр, аның урамнарына
чыгып, болай дип әйтегез: 11 «Хәтта шәһәрегезнең аякларыбызга
кунган тузанын да үзегезгә кагып калдырабыз; шулай да беле-
гез, Аллаһы Патшалыгы якынлашты». 12 Сезгә әйтәм: кыямәт кө-
нендә ул шәһәргә караганда Сәдүм шәһәренә җиңелрәк булыр.

*Тәүбәгә килмәгән шәһәрләр*

13 – Кайгы сиңа, Хоразин! Кайгы сиңа, Бәйтсайда! Чөнки
сездә эшләнгән могҗизалар Тур һәм Сидун шәһәрләрендә күр-
сәтелгән булса, алар күптән инде тупас киемнәр киеп һәм көлгә
утырып, тәүбә итәрләр иде. 14 Әмма кыямәт көнендә Тур белән
Сидунга сезгә караганда җиңелрәк булыр. 15 Әй, Кәпәрнаум,
әллә сине күккә кадәр күтәрерләр дип уйлыйсыңмы? Юк, үлем
патшалыгына кадәр төшерелерсең. 16 Сезне тыңлаучы Мине
тыңлый, сезне кире кагучы Мине кире кага; Мине кире кагучы
исә Мине Җибәрүчене кире кага.

*Җитмеш ике шәкертнең кайтуы*

17 Җитмеш ике шәкерт, шатлана-шатлана Гайсә янына әйлә-
неп кайттылар һәм Аңа:
– Раббыбыз, без Синең исемеңне кулланганда, безгә хәтта
җеннәр дә буйсына, – диделәр.
18 Ул исә аларга әйтте:
– Мин шайтанның күктән яшен кебек егылып төшүен күр-
дем. 19 Мин сезгә еланнарның, чаяннарның өстенә басу һәм
барлык дошманнарның көчләрен җиңеп чыгу өчен хакимлек
бирдем, сезгә һичнәрсә зыян китерә алмас. 20 Әмма рухларның
сезгә буйсынуына түгел, бәлки исемнәрегезнең күкләрдә языл-
ганлыгына шатланыгыз.

*Ата һәм Улы*

21 Шул вакыт Гайсә, Изге Рух белән шатланып әйтте:
– Әй, Атам, күк һәм җирнең Хуҗасы. Бу эшләрне зирәкләр-
дән һәм акыл ияләреннән яшереп, балаларга ачып бирүең өчен

Сиңа шөкрана итәм. Әйе, Атам, шулай эшләүне Син яхшы дип
таптың! 22 Миңа һәммәсе дә Атам тарафыннан бирелде; Улының
кем икәнен Атасыннан башка беркем дә белми, һәм Атасының
кем икәнен Улыннан һәм Улы белдерәсе килгән кешедән баш-
ка беркем дә белми.

23 Һәм шәкертләренә таба борылып, аларга гына әйтте:

– Сез нәрсә күрсәгез, шуларны күрүче күзләр бәхетле!
24 Сезгә әйтәм: күп пәйгамбәрләр һәм патшалар сез күрә торган
нәрсәләрне күрергә теләделәр, әмма күрмәделәр, һәм сез хәзер
ишеткән нәрсәләрне ишетергә теләделәр, әмма ишетмәделәр.

*Шәфкатьле самареяле*

25 Менә бер канунчы урыныннан торды һәм, Гайсәне сынап
карарга теләп:

– Остаз! Мәңгелек тормыш алу өчен миңа нәрсә эшләргә
кирәк? – дип сорады.

26 Гайсә аңа:

– Канунда нәрсә язылган? Син аннан нәрсә укыйсың? – диде.

27 Канунчы болай җавап бирде:

– Раббы Аллаһыңны бөтен йөрәгең, бөтен җаның, бөтен
көчең вә акылың белән ярат һәм якыныңны үзеңне яраткан
кебек ярат.

28 Гайсә аңа:

– Син дөрес җавап бирдең; шулай эшлә һәм яшәрсең, – диде.

29 Әмма канунчы, үзен акларга теләп, Гайсәдән:

– Ә минем якыным кем соң? – дип сорады.

30 Гайсә моңа болай дип җавап кайтарды:

– Бер кеше Иерусалимнан Әрихәгә барганда юлбасарлар ку-
лына эләккән. Алар аның киемнәрен салдырып алганнар һәм,
кыйнап, үлем хәлендә калдырып киткәннәр. 31 Бер руханига
да шул юлдан барырга туры килгән, әмма ул шунда яткан ке-
шене күргәч, юлның икенче ягына чыгып, үтеп киткән. 32 Шу-
лай ук бер левиле* дә узып барышлый, бу кешене күргән һәм
ул да, юлның икенче ягына чыгып, аның яныннан китеп бар-
ган. 33 Бер самареяле исә, үтеп барганда, бу кешегә тап булган
һәм аны күреп бик кызганган. 34 Янына килеп, яраларын шәраб
белән юган һәм зәйтүн мае сөртеп бәйләгән; аны үзенең ишә-
генә утыртып, кунак йортына алып килгән һәм аның хакында
кайгырткан. 35 Ә икенче көнне юлга чыгарга җыенганда, ике

* 10:32 *Леви* – Ягъкуб улларының берсе. Аллаһы әмере буенча, Леви токымыннан булган кешеләр генә Аллаһы Йортында рухани ярдәмчесе булып хезмәт иткәннәр. Алар левиләр дип аталганнар.

динар чыгарып, кунак йорты хуҗасына биргән һәм: «Аның
хакында кайгыртчы, әгәр күбрәк сарыф итсәң, кире кайткач
түләрмен», – дигән.
36 Гайсә, йомгаклап, шуны әйтте:
– Шушы өч кешенең кайсысы, синеңчә, юлбасарлар кулына
эләккән кешенең якыны була?
37 – Аңа шәфкать күрсәткәне, – дип җавап бирде канунчы.
Шунда Гайсә аңа:
– Бар, син дә шулай эшлә, – диде.

*Гайсә Мәрьям белән Марта янында*

38 Юлын дәвам итеп, Гайсә шәкертләре белән бер авылга
керде; анда Марта исемле бер хатын Аны үз өендә кабул итте.
39 Аның Мәрьям атлы сеңлесе бар икән; ул, Гайсәнең аяк очы-
на утырып, Аның сүзләрен тыңлый иде. 40 Марта исә бик тыры-
шып табын әзерләп йөри иде һәм Гайсә янына килеп:
– Раббым! Сеңлемнең бөтен эшне миңа гына калдыруына бер
дә пошынмыйсыңмы? Әйт әле аңа, миңа булышсын, – диде.
41 Гайсә исә аңа:
– Марта! Марта! Син күп нәрсә хакында кайгыртасың һәм
ыгы-зыгы килеп йөрисең, 42 ә бары бер нәрсә генә кирәк.
Мәрьям исә яхшырак өлешне сайлады, һәм ул аннан алынмас, –
дип җавап кайтарды.

*Гайсә дога кылырга өйрәтә*

11 1 Бервакыт Гайсә бер урында дога кылды. Ул дога кылып
бетергәннән соң, шәкертләренең берсе Аңа:
– Раббым! Яхъя үзенең шәкертләрен өйрәткән кебек,
безне дога кылырга өйрәтче, – диде.
2 Ул аларга:
– Дога кылганда болай дип әйтегез:
«Атабыз!
Исемең, изге дип, икърар ителсен;
Синең Патшалыгың килсен.
3 Көндәлек икмәгебезне безгә көн саен бир.
4 Безнең гөнаһларыбызны кичер,
чөнки без дә үзебезгә явызлык кылучы һәркемне
кичерәбез;
Һәм безне сынауга дучар итмә», –
дип әйтте.
5 Аннары Гайсә шәкертләренә әйтте:
– Әйтик, сезнең берегез төн уртасында дусты янына барып,
аңа: «Әй дустым, бурычка өч ипи биреп торчы, 6 чөнки узып

барышлый миңа бер дустым килеп керде, ә минем аның алдына табынга куярга бернәрсәм дә юк», – дип әйтер. [7] Ә ул өй эченнән: «Борчып йөрмә әле, инде ишекләр бикле, балаларым да минем белән ятакта; урыннан торып, син сораганны бирә алмыйм», – дияр. [8] Мин сезгә шуны әйтәм: ул дуслык хакына гына торып, икмәкне бирмәсә дә, инде тегенең үз дигәнендә нык торуы сәбәпле, аңа нәрсә кирәк булса, шуларның барысын да бирер.

[9] Шулай булгач сезгә әйтәм: сорагыз – сезгә бирерләр; эзләгез – табарсыз; шакыгыз, һәм сезгә ачарлар. [10] Чөнки һәр сораучы ала, эзләүче таба, һәм шакучыга ачарлар. [11] Сезнең арагызда кайсы да булса ата балык сораган улына елан бирерме? [12] Яки күкәй сораса, чаян бирерме? [13] Шулай итеп, сез явыз кеше булып та, балаларыгызга яхшы нәрсәләр бирә беләсез икән, күктәге Ата Үзеннән сораучыларга Изге Рухны бигрәк тә бирәчәк.

*Гайсә һәм Белзебул*

[14] Гайсә бер телсез кешенең эченнән җенне куып чыгарды. Җен чыкканнан соң телсез кеше сөйләшә башлады, халык моңа хәйран калды. [15] Аларның кайберләре исә:

– Ул җеннәрне җеннәр башлыгы Белзебул көче белән куып чыгара, – диделәр.

[16] Ә башкалары, Гайсәне сынарга теләп, Аның күктән бирәр илаһи билге күрсәтүен таләп иттеләр. [17] Әмма Ул, аларның уйларын белеп, халыкка әйтте:

– Үз эчендә бүлгәләнгән һәр патшалык җимерелер; һәм үз эчендә бүлгәләнгән гаилә дә таркалыр. [18] Ә шайтан патшалыгы бер-берсенә каршы өлешләргә таркалса, ул ничек тора алыр? Мин моны шуңа әйтәм, чөнки сез Миңа: «Җеннәрне Белзебул көче белән куып чыгарасың», – дисез. [19] Мин җеннәрне Белзебул көче белән куып чыгарам икән, сезнең иярченнәрегез кемнең көче белән куып чыгара соң? Шунлыктан, сезнең хаклы булмавыгызны алар үзләре күрсәтерләр. [20] Ә инде Мин җеннәрне Аллаһы көче белән куып чыгарам икән, димәк, Аллаһы Патшалыгы сезгә инде килеп җитте. [21] Көчле кеше үз йортын корал белән саклаган вакытта, аның милке иминлектә булыр. [22] Ә инде аннан көчлерәк берәү, аңа һөҗүм итеп, аны җиңсә, аның таянычы булган коралын тартып алыр, һәм аңардан талап алганнарны бүләр. [23] Кем Минем белән түгел, ул Миңа каршы; кем Минем белән җыймый, ул тарката.

*Явыз рухларның кире кайтуы*

[24] – Шакшы рух, кеше эченнән чыкканнан соң, сусыз урыннарда үзенә сыеныр урын эзләп йөри; һәм таба алмагач: «Элекке

йортыма әйләнеп кайтыйм әле», – ди. [25] Кире кайткач, ул аны
себерелгән һәм җыештырылган хәлдә таба. [26] Аннары ул үзен-
нән дә явызрак җиде рухны ияртеп кайта, һәм алар шунда
яши башлыйлар. Һәм ул кешегә элеккегә караганда да начар-
рак була.

*Чын бәхет*

[27] Гайсә моны сөйләгән чакта, халык арасыннан бер хатын,
тавышын күтәрә төшеп, Аңа:

– Сине күтәреп йөргән карын һәм Сине имезгән имчәкләр
бәхет-сәгадәтле! – диде.

[28] Ә Ул әйтте:

– Әмма Аллаһы сүзен тыңлаучылар һәм аны үтәүчеләр сәга-
дәтлерәк!

*Галәмәт эзләүчеләргә кисәтү*

[29] Гайсә тирәсенә кешеләр тагын да күбрәк җыелган вакытта,
Ул сөйли башлады:

– Бу буын кешеләре – явыз; алар илаһи билгеләр таләп итә,
әмма аларга Юныс галәмәтеннән башка билге бирелмәс.
[30] Юныс Нинәви кешеләренә галәмәт булган кебек, Адәм Улы
да бу буын өчен галәмәт булыр. [31] Көньякның патшабикәсе кы-
ямәт көнендә, бу буын кешеләре белән бергә торып, аларны
гаепләячәк, чөнки ул Сөләйман патшаның зирәк сүзләрен
тыңлау өчен җир читеннән килгән; ә Мондагы – Сөләйманнан
бөегрәк. [32] Нинәвилеләр кыямәт көнендә бу буын кешеләре
белән бергә торып, аны гаепләячәкләр, чөнки алар Юныс
пәйгамбәрнең вәгазен ишетеп тәүбә иткәннәр; ә Мондагы –
Юныстан бөегрәк.

*Тәннең яктырткычы*

[33] Беркем дә, шәм яндырып, аны яшерен урынга [яки чүл-
мәк астына]* куймый, бәлки, керүчеләр яктылыкны күрсен
өчен, шәмдәлгә утырта. [34] Тәнеңнең яктырткычы – күзләрең.
Күзләрең яхшы булса, бөтен тәнең дә якты була; ә инде күз-
ләрең начар булса, тәнең дә караңгы була. [35] Шуңа күрә, си-
нең эчеңдәге яктылык караңгылык булмасын. [36] Ә инде синең
бөтен тәнең якты һәм анда бер генә дә караңгы өлеш юк
икән, яктырткыч нурлары сине яктырткан кебек, тәнең дә
шулай якты булыр.

---

* **11:33** Кайбер кульязмаларда «яки чүлмәк астына» дигән сүзләр дә бар.

*Фарисейләргә һәм канунчыларга кисәтү*

37 Гайсә сөйләп бетергәннән соң, бер фарисей Аны өенә ашка чакырды; Гайсә, өйгә кереп, өстәл артына утырды.
38 Фарисей исә, Аның ашар алдыннан юынмавын күреп, гаҗәпкә калды. 39 Әмма Раббы аңа әйтте:
– Әйе, сез, фарисейләр, савыт-сабагызның тышкы ягын чистартасыз, ә үзегезнең эчегез комсызлык һәм явызлык белән тулы. 40 Ахмаклар! Тышкы якны тудырган Аллаһы эчке якны да тудырган түгелме соң? 41 Савыт-сабаларыгызда булганны фәкыйрьләргә өләшегез; шул чакта сезнең өчен һәрнәрсә пакь булыр. 42 Кайгы сезгә, фарисейләр, сез бөтнекнең, рутаның һәм һәртөрле яшелчәнең уннан бер өлешен бирәсез, ә гаделлеккә һәм Аллаһыны яратуга игътибар бирмисез; менә боларны үтәргә һәм канунның калган өлешләрен дә калдырмаска кирәк иде.
43 Кайгы сезгә, фарисейләр, сез гыйбадәтханәләрдә иң яхшы урыннарда утыруны һәм җыелыш мәйданнарында үзегезне ихтирам итеп сәламләүне яратасыз. 44 Кайгы сезгә, чөнки сез – кешеләр белмичә таптап йөри торган билгесез каберләр төсле.
45 Моңа карата канунчыларның берсе:
– Остаз! Бу сүзләрең белән Син безне дә мыскыл итәсең, – диде.
46 Әмма Гайсә әйтте:
– Сезгә дә, канунчылар, кайгы, сез кешеләр өстенә күтәреп йөрергә авыр булган йөкләр саласыз, ә үзегез ул йөкләргә хәтта бер бармагыгыз белән дә кагылмыйсыз. 47 Кайгы сезгә, чөнки сез пәйгамбәрләргә кабер һәйкәлләре куясыз. Ә бит нәкъ менә ул пәйгамбәрләрне сезнең ата-бабаларыгыз үтергән.
48 Моның белән сез ата-бабаларыгыз кылган эшләр белән килешүегезне күрсәтәсез; алар пәйгамбәрләрне үтергәннәр, ә сез аларга кабер һәйкәлләре куясыз. 49 Шуның өчен Аллаһының Зирәклеге әйткән: «Мин аларга пәйгамбәрләр вә рәсүлләр җибәрәм, аларның кайберләрен үтерерләр, ә кайберләрен эзәрлекләрләр». 50 Шуңа күрә дөнья яратылганнан бирле барлык пәйгамбәрләрнең түгелгән каны өчен бу буын кешеләре хөкем ителәчәк, 51 Һабил каныннан башлап, корбан китерү урыны белән Изге йорт арасында үтерелгән Зәкәриянең канына кадәр. Әйе, сезгә әйтәм, бу буын кешеләре хөкем ителәчәк. 52 Кайгы сезгә, канунчылар, чөнки сез белем ачкычын үзегезгә алдыгыз: үзегез дә кермәдегез, керергә теләүчеләргә дә комачауладыгыз.
53 Гайсә фарисей өеннән чыккач, канунчылар һәм фарисейләр, тәнкыйтьләп, Аңа күп санлы сораулар белән һөҗүм итә башладылар. 54 Алар, Гайсәне тозакка эләктерергә теләп, Ул әйткән сүзләрдән гаеп эзләделәр.

*Гайсә икейөзлелек турында кисәтә*

**12** [1] Шул ук вакытта меңнәрчә кешеләр җыелды, һәм алар
бер-берсен кысрыкладылар. Гайсә иң элек Үзенең шә-
кертләренә сөйли башлады:
– Фарисейләр ачыткысыннан, ягъни, икейөзлелектән сак-
ланыгыз. [2] Ачылмый калачак бернинди капланган нәрсә һәм
беленмичә калачак бернинди яшерен нәрсә юк. [3] Шуңа күрә, ка-
раңгыда нәрсә сөйләсәгез, көн яктысында ишетелер; һәм өй
эчендә колакка пышылдап нәрсә сөйләсәгез, өй түбәләреннән
игълан ителер. [4] Сез дусларыма исә әйтәм: тәнне үтереп, шуннан
соң бүтән һичнәрсә эшли алмый торганнардан курыкмагыз.
[5] Әмма сезгә Кемнән куркырга кирәк икәнен әйтәм: гомерегезне
алгач, сезне җәһәннәмгә ташларга хакимлеге булган Аллаһы-
дан куркыгыз; әйе, сезгә әйтәм, менә Аннан куркыгыз! [6] Биш
чыпчык ике бакыр тәңкәгә* сатыла түгелме соң? Алай да Аллаһы
тарафыннан аларның берсе дә онытылмаган. [7] Сезнең хәтта ба-
шыгыздагы һәр чәч бөртегегез дә санаулы. Курыкмагыз, сез күп
чыпчыкларга караганда кыйммәтлерәк. [8] Мин сезгә әйтәм: Ми-
не кешеләр алдында икърар иткән кешене Адәм Улы да Аллаһы
фәрештәләре алдында икърар итәчәк. [9] Ә кем Миннән кешеләр
алдында ваз кичсә, Аллаһы фәрештәләре алдында аннан да ваз
кичәрләр. [10] Адәм Улына каршы сүз әйтүче һәркем кичерелер;
ә инде Изге Рухка карата көфер сүз әйтүче кичерелмәс. [11] Сезне
гыйбадәтханәләргә, башлыклар һәм хакимият кешеләре алды-
на китергән вакытта, үзебезне ничек итеп яклarбыз яки нәрсә
сөйләрбез дип хафаланмагыз, [12] чөнки нәрсә әйтергә кирәклеге
турында Изге Рух сезгә шул сәгатьтә киңәш бирер.

*Акылсыз бай турында гыйбрәтле хикәя*

[13] Халык арасыннан берәү Гайсәгә:
– Остаз! Абыема әйтче, атабыз калдырган мирасны минем
белән бүлешсен иде, – диде.
[14] Ул исә теге кешегә әйтте:
– Дустым, сезне хөкем итәргә яки малыгызны бүләргә Мине
кем билгеләде?
[15] Шуннан соң Ул, һәммәсенә мөрәҗәгать итеп, болай диде:
– Карагыз, һәртөрле комсызлыктан сакланыгыз, чөнки кеше
ничек кенә бай булса да, аның тормышы мал-мөлкәтенә бәйле
түгел.

---

* 12:6 *Ике бакыр тәңкә* – грек телендә «ике ассарион». Бер ассарион
уналтыдан бер динарга тигез.

[16] Һәм Ул аларга шушы гыйбрәтле хикәяне сөйләде:
– Бер байның кырда ашлыгы бик уңган. [17] Бай эченнән генә
болай дип фикер йөрткән: «Инде миңа нәрсә эшләргә? Ашлы-
гымны салыр урыным юк». [18] Һәм ул мондый карарга килгән:
«Менә нәрсә эшлим: амбарларымны сүтим дә, зуррак амбарлар
салыйм һәм бөтен ашлыгымны, бөтен малымны шунда җыяр-
мын. [19] Шуннан соң үземә: „Җаным, синең күп елларга җитәрлек
малың бар; ял ит, аша, эч, тормышның рәхәтен күр“, – дияр-
мен». [20] Әмма Аллаһы аңа әйткән: «Әй, син, акылсыз! Шушы
төндә тормышыңны синнән кире алачаклар. Үзең өчен җыйган-
нарың кемгә калыр соң?» [21] Үзе өчен хәзинә туплаган, әмма Алла-
һы каршында бай булмаган һәркем белән менә шулай була.
[22] Гайсә Үзенең шәкертләренә әйтте:
– Шуның өчен сезгә әйтәм: тормышыгыз өчен ни белән
тукланырга дип, тәнегез өчен нәрсә киярга дип борчылмагыз.
[23] Җан – ризыктан, тән – киемнән мөһимрәк бит. [24] Козгыннар-
га карагыз: алар чәчмиләр дә, урмыйлар да; аларның келәтләре
дә, амбарлары да юк; шулай да Аллаһы аларны туендыра. Ә сез
кошларга караганда никадәр кыйммәтлерәк бит. [25] Сезнең кай-
сыгыз, кайгырганга карап, үз гомерен бер сәгатькә булса да
озайта ала? [26] Шулай булгач, кечкенә нәрсәләрне дә эшли ал-
мыйсыз икән, нигә башка нәрсәләр өчен кайгырырга? [27] Кыр
чәчәкләренә карагыз, алар ничек үсәләр: эшләмиләр дә, эрлә-
миләр дә; ләкин, сезгә әйтәм, Сөләйман патша үзенең мәһа-
бәтлелегендә дә аларның берсе кебек тә киенмәгән. [28] Бүген
кырда үсеп утырган, ә иртәгә утка ташланачак үләнне Аллаһы
шулай киендерә икән, әй сез, аз иманлылар, сезне бигрәк тә
киендерер. [29] Шулай итеп, ни ашарбыз, ни эчәрбез дип кайгыр-
магыз һәм хафаланмагыз. [30] Бу дөнья мәҗүсиләренең төп кайгы-
лары шул; ә сезнең Атагыз сезгә бу нәрсәләрнең кирәк икәнен
белә. [31] Сез, киресенчә, Аллаһы Патшалыгын эзләгез, һәм бо-
лар сезгә бирелер. [32] Әй, кечкенә көтү, курыкма! Чөнки сезгә
Патшалыкны бирүне Атагыз яхшы дип тапты. [33] Милкегезне са-
тыгыз да ярлыларга сәдака өләшегез. Үзегезгә тузмый торган
янчыклар әзерләгез, күктә һич тә кимеми торган хәзинә тупла-
гыз, анда карак та тия алмас, көя дә төшмәс. [34] Чөнки хәзинәгез
кайда булса, күңелегез дә шунда булыр.

*Һәрвакыт әзер торыгыз*

[35-36] Туйдан кайтасы хуҗасын көтеп, ул кайтып шаку белән
үк ишек ачарга әзер торучы хезмәтчеләр кебек, һәрвакыт әзер
торыгыз, билегез пута белән бәйләнгән булсын, яктырткычла-
рыгыз янып торсын. [37] Хуҗа кайткач, аларны уяу хәлдә күрсә,

менә шул хезмәтчеләр сәгадәтле. Сезгә хак сүз әйтәм: хуҗа
билен бәйләр һәм аларны өстәл артына утыртыр да, аларга хез-
мәт күрсәтеп йөрер. 38 Әгәр ул төн уртасында яки тагын да соң-
рак кайткан чагында да хезмәтчеләрен шулай уяу хәлдә күрсә,
менә шул хезмәтчеләр сәгадәтле! 39 Әмма шуны аңлагыз: йорт
хуҗасы каракның кайчан киләсен белсә, аңа үз йортына керер-
гә ирек бирмәгән булыр иде. 40 Сез дә әзер булыгыз: Адәм Улы
сез уйламаган сәгатьтә киләчәк.

*Ышанычлы һәм ышанычсыз хезмәтчеләр*

41 Шунда Петер Гайсәгә әйтте:
– Раббым! Бу гыйбрәтле сүзләрне безнең өчен генә сөйли-
сеңме, әллә һәммә кешеләргәме?
42 Раббы исә әйтте:
– Хезмәтчеләргә тиешле ризыкны үз вакытында өләшү өчен,
хуҗа тарафыннан башка хезмәтчеләргә башлык итеп куелган
ышанычлы һәм акыллы хезмәтче нинди була соң? 43 Хуҗасы,
әйләнеп кайткач, аның шулай эшләвен күрсә, менә шул хезмәт-
че сәгадәтле. 44 Сезгә хак сүз әйтәм: хуҗасы аны бөтен милке
өстеннән башлык итеп куяр. 45 Ә инде шул хезмәтче: «Хуҗам
тиз кайтмас әле», – дип уйлап, хезмәтче ирләрне дә, хатыннар-
ны да кыйный, үзе ашап-эчеп исерә башласа, 46 хуҗасы ул көт-
мәгән көнне, ул уйламаган сәгатьтә кайтып керер дә аны җәзага
тартыр һәм имансызлар белән бер язмышка дучар итәр. 47 Хуҗа-
сының ихтыярын белеп тә, әзер булмаган һәм аның ихтыярынча
эшләмәгән хезмәтче бик каты кыйналыр. 48 Ә инде хуҗасының
ихтыярын белмәүче, җәзалауга лаеклы эш эшләсә дә, азрак кый-
налыр. Кемгә күп бирелсә, аннан күп таләп ителер; һәм кемгә
күп ышанып тапшырылса, аннан тагын да күбрәк соралыр.
49 Мин җиргә ут алып килдем һәм ул утның инде янып китүен
телим! 50 Мин чумдырылу аркылы үтәргә тиешмен; һәм моны
башкарганга кадәр Мин ничаклы интегәм! 51 Сез Мине җиргә
тынычлык китерергә килде дип уйлыйсызмы әллә? Юк, Мин
аерырга дип килдем. 52 Чөнки моннан соң биш кешедән торган
гаилә кешеләре бер-берсенә каршы булыр, өчесе икесенә кар-
шы, ә икесе өчесенә каршы булыр. 53 Ата улына, улы атасына
каршы; ана кызына, кызы анасына каршы; каенана килененә,
килене каенанасына каршы булыр.

*Заман билгеләре*

54 Гайсә халыкка да әйтте:
– Сез көнбатышта болыт күтәрелгәнен күрүгә үк: «Яңгыр
явар», – дисез; һәм шулай була да бит. 55 Көньяктан җил искән

вакытта: «Бик эссе булыр», – дисез; һәм шулай була да бит.
[56] Монафикълар! Җир һәм күк йөзен күзәтеп, һава торышын
билгели аласыз, әмма ничек соң бу заманны аңлата алмый-
сыз? [57] Сез ни өчен нәрсәнең дөрес икәнлеген үзегез хәл ит-
мисез? [58] Дәгъвачың сине хаким янына алып барганда, аның
белән юлда ук килешергә тырыш, юкса ул сине хаким алды-
на ирексезләп алып барыр, ә хаким сине җәзалаучыга тап-
шырыр, җәзалаучы исә төрмәгә ябар. [59] Сиңа шуны әйтәм:
бурычыңның актык тиененә кадәр биреп бетермичә, аннан
чыкмассың.

*Тәүбә итмәсәгез һәлак булырсыз*

**13** [1] Шул вакыт корбан китергән вакытта Пилатның әмере
буенча үтерелгән гәлиләяле кешеләр турында Гайсәгә
килеп сөйләделәр. [2] Гайсә моңа карата болай диде:
– Бу гәлиләялеләр шулай газап чиккәннәр икән, алар калган
бар гәлиләялеләргә караганда гөнаһлырак булганнар дип уйлый-
сызмы әллә? [3] Сезгә әйтәм: юк! Әмма тәүбә итмәсәгез, барыгыз
да алар кебек һәлак булырсыз. [4] Яки сез Шилуахтагы манара
авып басып үтергән шул унсигез кеше Иерусалимда яшәүчеләр-
нең барысыннан да гаеплерәк булган дип уйлыйсызмы әллә?
[5] Сезгә әйтәм: юк! Әмма, тәүбә итмәсәгез, барыгыз да алар ке-
бек һәлак булырсыз.
[6] Ул мондый гыйбрәтле хикәя сөйләде:
– Берәүнең йөзем бакчасында инҗир агачы үскән. Бервакыт
ул бакчага килгән һәм агачтан җимеш эзләргә тотынган, ләкин
таба алмаган. [7] Һәм бакчачыга әйткән: «Менә өч ел инде мин
шушы инҗир агачының җимешен җыярга дип киләм, ләкин
таба алмыйм. Кисеп ташла аны! Ни өчен ул урын алып тора?»
[8] Бакчачы исә аңа болай дип җавап биргән: «Хуҗам, аны та-
гын бер елга калдырып тор, мин аның әйләнә-тирәсен казып,
тирес салырмын, [9] бәлки киләсе елда җимеш бирер? Ә юк икән,
ул чакта кисеп ташларга кушарсың».

*Гайсә шимбә көнне савыктыра*

[10] Гайсә шимбә көнне бер гыйбадәтханәдә өйрәтте. [11] Анда
бер хатын-кыз бар иде. Аның эчендә унсигез ел буена явыз рух
торган. Бу рух аны гарипләндергән, хатын бөкрәеп беткән һәм
бөтенләй турая алмаган. [12] Гайсә, аны күреп, Үзе янына чакы-
рып алды һәм аңа:
– Апа, син чиреңнән азат ителдең, – диде.
[13] Гайсә аның өстенә кулларын куеп алды; хатын шундук ту-
раеп басты һәм Аллаһыны данлый башлады. [14] Бу хәлдән соң,

гыйбадәтханә башлыгы, Гайсәнең шимбә көнне савыктыруына
ачуы килеп, халыкка әйтте:

– Эшләү өчен атнада алты көн бар; чирләрегездән савыгу
өчен шимбә көнне түгел, бәлки шул көннәрнең берсендә ки-
легез.

15 Раббы аңа җавап итеп әйтте:

– Монафикълар, сезнең һәркайсыгыз шимбә көнне, үгезен
яки ишәген утлыктан ычкындырып, су эчертергә алып бар-
мыймыни? 16 Унсигез ел буена шайтан бәйләп тоткан, Ибраһим
нәселеннән булган бу хатынны бу чирдән шимбә көнне азат
итәргә ярамыймыни?

17 Ул бу сүзләрне әйткәч, Аңа каршы килүчеләр барысы да
оялдылар; бөтен халык исә Ул кылган данлы эшләрнең һәммә-
сенә шатланды.

*Аллаһы Патшалыгы*

18 Шуннан соң Гайсә сорады:

– Аллаһы Патшалыгы нәрсәгә охшаш һәм аны нәрсә белән
чагыштырыйм? 19 Ул бер кешенең үз бакчасына утырткан гор-
чица орлыгына охшаган: ул үскән, агач булган, һәм кошлар
аның ботакларына оя корганнар.

20 Ул тагын сорады:

– Аллаһы Патшалыгын нәрсә белән чагыштырып була икән?
21 Ул чүпрә кебек; менә бер хатын чүпрә белән бер капчык он-
нан камыр басып куйган һәм берникадәр вакыттан соң бөтен
камыр кабарган.

22 Гайсә, шәһәрләр, авыллар аша үтеп, өйрәтә-өйрәтә, Иеру-
салимга таба юл тотты. 23 Кемдер Аннан сорады:

– Әфәндем! Котылучыларның саны аз булырмы?

Ул исә андагы кешеләргә әйтте:

24 – Бар көчегезне куеп, тар ишек аша керергә тырышыгыз;
чөнки сезгә әйтәм: күпләр керергә тырышырлар, әмма керә
алмаслар. 25 Йорт Хуҗасы, урыныннан торып, ишекне бикләгәннән соң, сез тышкы якта калып, ишек кага башларсыз
һәм: «Әфәндем! Безгә ишекне ач әле», – диярсез. Ә Ул сезгә:
«Мин сезне белмим, кайдан килгәнегезне дә белмим», – дип
җавап бирер. 26 Шунда сез: «Без Синең белән ашадык, эчтек,
һәм Син урамнарыбызда безне өйрәттең», – дип әйтә башлар-
сыз. 27 Әмма Ул әйтер: «Сезнең кайдан икәнегезне белмим,
барлык явызлык кылучылар, Минем янымнан китегез!» 28 Сез
Ибраһимның, Исхакның, Ягъкубның һәм барлык пәйгамбәр-
ләрнең Аллаһы Патшалыгында икәннәрен, ә үзегезнең аннан
куып чыгарылган булуыгызны күреп, еларсыз һәм тешләрегезне

шыкырдатырсыз. [29] Көнчыгыштан һәм көнбатыштан, төньяктан
һәм көньяктан килерләр һәм Аллаһы Патшалыгындагы мәҗлес-
тә утырырлар. [30] Хәзер ахыргы булган кайберәүләр – беренче,
беренче булган кайберәүләр ахыргы булырлар.
[31] Шул вакытта берничә фарисейләр килеп, Гайсәгә әйт-
теләр:
– Моннан кит, чөнки Һируд Сине үтерергә тели.
[32] Ул аларга болай дип җавап бирде:
– Барыгыз, ул төлкегә әйтегез: «Бүген һәм иртәгә җеннәр-
не куып чыгарам, авыруларны савыктырам һәм берсекөнгә
эшемне тәмамлармын». [33] Алай гына да түгел, Мин бүген дә,
иртәгә дә һәм берсекөнгә дә Үз юлымны дәвам итәргә тиеш-
мен, чөнки пәйгамбәрнең Иерусалимнан читтә үтерелүе мөм-
кин түгел.
[34] Иерусалим! Пәйгамбәрләрне үтерүче, үзеңә җибәрелгән-
нәрне ташлар атып үтерүче Иерусалим! Кош үзенең балаларын
канаты астына җыйган кебек, Мин дә синең кешеләреңне ничә
тапкыр шулай бергә җыярга теләдем, әмма сез теләмәдегез!
[35] Инде тыңлагыз: сезнең Изге йортыгыз ташлап калдырылыр.
Мин сезгә әйтәм: «Раббы исеме белән Килүче мөбарәк!» – дип
сез әйтер вакыт җитми торып, Мине күрмәссез.

*Гайсә фарисей өендә шимбә көнне савыктыра*

**14** [1] Бер шимбә көнне Гайсә фарисей башлыкларыннан
берсенең өенә ашка барды һәм барысы да Аны күзәтте-
ләр. [2] Менә шунда Аның алдына сары су авыруыннан
интегүче бер кеше килеп басты. [3] Шунда Гайсә канунчы һәм
фарисейләргә мөрәҗәгать итеп:
– Канун шимбә көнне савыктырырга рөхсәт итәме? – дип
сорады.
[4] Алар эндәшмәделәр. Ә Ул, авыру кешенең өстенә кулын
куеп, аны савыктырды һәм өенә кайтарып җибәрде. [5] Гайсә
аларга әйтте:
– Берегезнең улы коега төшсә, яки үгезе, шимбә көн булса
да, ул аны шундук коедан чыгармасмы?
[6] Алар Аның бу соравына җавап бирә алмадылар.

*Никах мәҗлесе турында гыйбрәтле хикәя*

[7] Чакырылган кунакларның үзләренә түрдән урын сайлаула-
рын күреп, Гайсә аларга шушы гыйбрәтле хикәяне сөйләде:
[8] – Берәү сине никах мәҗлесенә чакырса, түр башына утыр-
ма, чөнки сиңа караганда хөрмәтлерәк берәүнең чакырылган
булуы мөмкин. [9] Сине һәм аны чакырган хуҗа янына килеп:

«Бу кешегә урын бирче», – дип әйтер; һәм шул чакта син,
оятка калып, ишек катына барып утырырга тиеш булырсың.
10 Киресенчә, мәҗлескә чакырсалар, килгәч ишек катына утыр,
шунда хуҗа янына килеп: «Әй, дустым, түргәрәк утыр», – ди-
яр; шул чакта синең белән бергә мәҗлестә утыручылар ал-
дында сиңа ихтирам булыр. 11 Чөнки үзен башкаларга караганда
өстен куючы һәркем түбәнсетелер; ә үзен-үзе түбәнсетүче кү-
тәрелер.

12 Гайсә Үзен ашка чакырган кешегә дә әйтте:

– Әгәр син төшке яки кичке аш үткәрәсең икән, дусларың-
ны да, туганнарыңны да, кан кардәшләреңне дә һәм бай күр-
шеләреңне дә чакырма, чөнки чакыруыңа каршы кайчан да
булса алар да сине ашка чакыра ала һәм шуның белән исап-хи-
сап беткән булып чыга. 13 Ә инде мәҗлес үткәрәсең икән,
фәкыйрьләрне, гарипләрне, аксакларны, сукырларны чакыр,
14 һәм син бәхетле булырсың, чөнки алар сиңа кайтарып түли
алмыйлар. Ә сиңа тәкъваларның үледән тереләчәк көнендә
түләнер.

*Зур аш мәҗлесе турында гыйбрәтле хикәя*

15 Гайсә белән бергә утыручыларның берсе, моны ишетеп,
Аңа әйтте:

– Аллаһы Патшалыгындагы мәҗлестә ашаячаклар бәхетле!

16 Ул исә аңа болай диде:

– Бер кеше, зур аш мәҗлесе үткәрергә җыенып, күп кунак-
лар чакырган. 17 Мәҗлес башланыр вакыт җиткәч, чакырылган
кешеләргә: «Килегез, инде бөтенесе әзер», – дип әйтергә үзе-
нең хезмәтчесен җибәргән. 18 Барысы да, сүз берләшкән кебек,
гафу үтенә башлаганнар. Беренчесе аңа: «Мин җир сатып ал-
дым, миңа шуны барып карарга кирәк; зинһар өчен, мине гафу
ит», – дигән. 19 Икенчесе исә: «Мин биш пар үгез сатып алдым,
хәзер шуларны сынап карарга барам; зинһар өчен, мине гафу
ит», – дигән. 20 Өченчесе: «Мин хәзер генә өйләндем, шуңа күрә
килә алмыйм», – дигән. 21 Хезмәтче кайтып, бу хакта хуҗасына
хәбәр иткән. Моңа хуҗаның ачуы килгән һәм хезмәтчесенә:
«Бар, бик тиз генә шәһәр мәйданнарыннан һәм тыкрыкларын-
нан фәкыйрьләрне, гарипләрне, сукырларны һәм аксакларны
алып кил», – дигән. 22 Берникадәр вакыт үткәч, хезмәтче аңа:
«Хуҗам, синең әмерең үтәлде, әле тагын да буш урыннар
бар», – дигән. 23 Хуҗа хезмәтчесенә әйткән: «Бар, юлларга,
сукмакларга чык, кешеләрне монда килергә күндер, өем тулы
булсын. 24 Сезгә әйтәм: элек чакырылганнарның берсе дә ми-
нем ашымны татымас».

*Гайсә шәкертләреннән нәрсә таләп итә?*

25 Гайсәгә ияреп зур халык төркеме барды, һәм Ул аларга
мөрәҗәгать итте:
26 – Минем яныма килүче кеше атасын, анасын, хатынын,
балаларын, ир һәм кыз туганнарын һәм шулар өстенә үз тор-
мышын да Мине яратканнан артыграк яратса, ул Минем шә-
кертем була алмый; 27 һәм үзенең хачын күтәреп бармаган һәм
Миңа ияреп йөрмәгән кеше Минем шәкертем була алмый.
28 Әйтик, сезнең арагызда кем дә булса манара төзергә тели ди.
Төзелешне башкарып чыгарга җитәрлек акчасы бармы икәнен
белү өчен, иң башта утырып, аның күпмегә төшәсен хисапла-
масмы әллә? 29-30 Юкса, нигезен салып та, аны төзеп бетерә ал-
маса, моны күргәннәрнең барысы да: «Бу кеше төзи башлады,
әмма тәмамлый алмады», – дип аннан көлә башларлар. 31 Я әй-
тик, бер патша сугышка керергә җыена ди. Егерме мең сугыш-
чыдан торган гаскәр белән килүче башка патшага үзенең ун
мең гаскәре белән каршы торырга көче җиту-җитмәвен башта
утырып киңәшмәсме әллә? 32 Ә көче җитмәсә, ул солых шарт-
ларын сорау өчен, әле еракта булган теге патшага илчеләр
җибәрер.
33 Шулай ук сезнең һәркайсыгыз үзенең бар нәрсәсен кал-
дырмаса, Минем шәкертем була алмый. 34 Тоз – яхшы нәрсә;
әмма тоз үзенең тәмен югалтса, аны яңадан ничек тозлы итәр-
сең? 35 Ул җир өчен дә, тирес өеме өчен дә яраксыз була; аны
чыгарып ташлыйлар. Ишетергә колаклары булган – ишетсен!

**15** 1 Бик күп салым җыючылар, гөнаһлылар Гайсәне тыңлау
өчен Аның янына җыелдылар. 2 Фарисейләр һәм канун-
чылар исә:
– Бу Кеше гөнаһлыларны кабул итә һәм алар белән бергә
ашый, – дип сукрандылар.

*Югалган сарык турында гыйбрәтле хикәя*

3 Гайсә исә аларга шушы гыйбрәтле хикәяне сөйләде:
4 – Әйтик, берегезнең йөз сарыгы булып, шуларның берсен
югалтты ди. Ул туксан тугызын болында калдырып, югалганын
тапканчы эзләмәсме әллә? 5 Ә инде тапкач, шатланып, аны
җилкәсенә салып алып кайтыр; 6 һәм өенә кайткач, дусларын
һәм күршеләрен чакырып: «Минем белән бергә шатланыгыз,
чөнки мин югалган сарыгымны таптым», – дияр. 7 Сезгә шуны
әйтәм: шул рәвешчә, тәүбә итәргә мохтаҗ булмаган туксан
тугыз тәкъва кеше өчен шатлануга караганда, гөнаһлы бер
кешенең тәүбә итүенә күктә күбрәк шатланырлар.

*Югалган көмеш тәңкә турында гыйбрәтле хикәя*

8 – Яки ун көмеш тәңкәсе булган бер хатын, берсен югалтса,
шәм яндырып, идәннәрен себереп, аны тапканчы җентекләп
эзләмәсме әллә? 9 Ә тапкач, үзенең дусларын һәм күршеләрен
чакырып, аларга: «Минем белән бергә шатланыгыз, чөнки мин
югалткан акчамны таптым», – дияр. 10 Сезгә шуны әйтәм:
Аллаһы фәрештәләре дә тәүбә иткән бер гөнаһлы өчен шулай
ук шатланырлар.

*Читкә киткән угыл турында гыйбрәтле хикәя*

11 Ул сөйләвен дәвам итте:
– Бер кешенең ике улы булган. 12 Аларның кечесе атасына:
«Әти, милекнең миңа тиешле өлешен бүлеп бир әле», – дигән.
Атасы милкен улларына бүлеп биргән. 13 Берничә көн үткәч,
кече улы үз өлешен сатып, булган акчаны үзе белән алып, ерак
илгә чыгып киткән һәм анда азгынлыкка бирелеп, байлыгын
туздырып бетергән. 14 Бөтен байлыгын туздырып бетергәч, бу
илдә бик каты ачлык башланган һәм ул мохтаҗлыкта калган.
15 Шунда ул әлеге илнең бер кешесенә ялланган, ә ул аны үзе-
нең басуына дуңгызлар көтәргә җибәргән. 16 Ул шулкадәр ач
булган, хәтта дуңгызлар ашый торган азыкны ашаса да шат бу-
ласы икән, ләкин аңа беркем дә бернәрсә бирмәгән. 17 Аннары
ул, акылына килеп: «Минем атамның ялчылары күп һәм алар-
ның барысының да туйганчы ашарга ризыгы бар, ә мин ачтан
үләм! 18 Хәзер үк атам янына кайтыйм да: „Әти, мин Күктәге
Аллаһы каршында һәм синең алдыңда гөнаһ кылдым, 19 инде
мин синең улың дип аталырга лаек түгел; миңа ялчыларыңның
берсе булырга рөхсәт ит“, – дип әйтим». 20 Һәм ул атасы янына
кайтып киткән. Ул әле еракта вакытта ук, атасы аны күреп ал-
ган һәм бик кызганган, каршына йөгереп барып, аны кочаклап
үпкән. 21 Улы исә аңа әйткән: «Әти, мин Күктәге Аллаһы кар-
шында һәм синең алдыңда гөнаһ кылдым, инде синең улың
дип аталырга лаек түгелмен». 22 Ә атасы үзенең хезмәтчеләренә
әйткән: «Иң яхшы кием алып килеп, аны киендерегез, барма-
гына йөзек бирегез, аякларына башмаклар кидерегез. 23 Аннары
симертелгән бозауны алып чыгып чалыгыз. Ашыйк һәм күңел
ачыйк! 24 Чөнки минем бу улым үлгән иде, ә хәзер терелде,
югалган иде – табылды». Һәм алар бәйрәм итә башлаганнар.

25 Аның өлкән улы исә бу вакытта кырда булган. Ул өенә
кайтып җитәрәк, җыр һәм бию тавышлары ишеткән. 26 Хезмәт-
челәрнең берсен чакырып: «Бу ни хәл?» – дип сораган. 27 Хез-
мәтче аңа: «Синең энең кайтты, аның сау-сәламәт әйләнеп

кайтуына куанып, атаң симертелгән бозауны чалдырды», – ди-
гән. [28] Ә олы угылның моңа ачуы килгән һәм ул өйгә керергә
теләмәгән. Атасы исә чыгып аңардан өйгә керүен үтенгән.
[29] Әмма ул атасына җавап итеп әйткән: «Менә, мин сиңа инде
күпме еллар хезмәт итәм һәм кушканнарыңны һич тә үтәмичә
калганым юк, шуңа да карамастан дусларым белән бергә күңел
ачу өчен синең миңа беркайчан кәҗә бәтие дә биргәнең булма-
ды. [30] Ә инде милкеңне фахишәләр белән туздырып бетергән бу
улың кайткач, аның өчен симертелгән бозауны чалдыргансың!»
[31] Атасы исә аңа әйткән: «Улым, син һәрвакыт минем белән,
бөтен нәрсәм синеке; [32] әмма синең энең үлгән иде, ә хәзер
терелде, югалган иде – табылды, менә шуңа күрә шатланып
күңел ачарга кирәк».

*Ышанычсыз идарәче*

16 [1] Гайсә Үзенең шәкертләренә әйтте:
– Бер байның хуҗалыгы белән идарә итүчесе булган.
Аның хакында байга: «Милкеңне туздырып бетерә», –
дип килеп әйткәннәр. [2] Бай аны чакырып: «Мин синең хакта
нәрсә ишетәм? Үзеңнең идарәң хакында хисап бир, чөнки
моннан ары син минем хуҗалыгым белән идарә итә алмый-
сың», – дигән. [3] Шунда идарә итүче: «Инде нәрсә эшләргә?
Хуҗам мине идарә эшеннән азат итә. Җир казырга көчем юк,
хәер сорашырга оялам. [4] Хуҗалык белән идарә итү эшеннән
чыгарылгач, кешеләр мине үз йортларына кабул итсеннәр
өчен, хәзер нәрсә эшләргә кирәген беләм», – дип уйлаган.
[5] Шуннан ул, хуҗасына бурычлары булган кешеләрне бер-бер
артлы чакырып, беренчесеннән: «Минем хуҗама синең күпме
бурычың бар?» – дип сораган. [6] Теге аңа: «Йөз үлчәү* май ти-
ешмен», – дигән. Идарә итүче аңа: «Бурыч кәгазеңне ал да, тиз
генә утырып, илле үлчәү, дип яз», – дигән. [7] Аннары икенче-
сеннән: «Ә синең күпме бурычың бар?» – дип сораган. Ул аңа:
«Мең үлчәү бодай», – дигән. Идарә итүче: «Бурыч кәгазеңне ал
да, сигез йөз үлчәү, дип яз», – дигән. [8] Ә хуҗа намуссыз идарә-
чене тапкырлыгы өчен мактаган. Чөнки бу дөнья кешеләре үзе
кебекләр белән эш кылганда, яктылык кешеләренә караганда
тапкыррак. [9] Сезгә әйтәм: җирдәге байлык белән үзегезгә дус-
лар булдырыгыз. Шулай эшләсәгез, байлык беткәч, мәңгелек
яшәү урынына кабул ителерсез. [10] Кечкенә нәрсәдә ышанычлы
булган зур нәрсәдә дә ышанычлы булыр, ә кечкенә генә нәр-
сәдә ышанычсыз булган зур нәрсәдә дә ышанычсыз булыр.

---

* **16:6** *Бер үлчәү* – 40 литр чамасы.

11 Шулай итеп, сез җирдәге байлык белән ышанычлы эш йөрт-
мисез икән, чын байлыкны сезгә кем әманәт итәр? 12 Әгәр дә
сез башкалар милке белән ышанычлы эш итмисез икән, үзегез-
некен сезгә кем бирер? 13 Берәү дә ике хуҗага хезмәт итә алмас:
берсен яратмас, ә икенчесен яратыр; берсенә тугры булыр, ә
икенчесен санга сукмас. Аллаһыга да, байлыкка да берьюлы
хезмәт итә алмассыз.

*Фарисейләргә җавап*

14 Фарисейләр боларның барысын да ишеттеләр һәм үзләре
акча яратканлыктан, Гайсәдән мыскыл итеп көлештеләр. 15 Ул
аларга әйтте:
– Сез кешеләр алдында үзегезне яхшы итеп күрсәтәсез, әмма
Аллаһы сезнең күңелегезне белә; кешеләр югары бәя биргән
нәрсә – Аллаһы каршында җирәнгеч. 16 Муса канунының һәм
пәйгамбәрләрнең заманы Яхъя пәйгамбәр килгәнгә кадәр
булды; шуннан бирле Аллаһы Патшалыгы хакында Яхшы хә-
бәр таратыла, һәм һәркем анда бик зур тырышлык куеп керә.
17 Әмма күк һәм җир бетсә дә, канунның бер генә сызыгы да
юкка чыкмаячак.
18 Үз хатынын аерып, башка хатынга өйләнүче һәркем зина
кыла; һәм иреннән аерылган хатынга өйләнүче дә зина кыла.

*Бай һәм Лазар*

19 – Кайчандыр бер бай булган. Ул бик кыйммәтле киемнәр
генә кигән һәм һәр көнне зиннәтле мәҗлесләр үткәргән. 20 Ә
аның капка төбендә бөтен тәне җәрәхәтләр белән капланган
Лазар исемле бер фәкыйрь ята икән. 21 Ул бай табыныннан
төшкән сынык-саныклар белән тукланырга теләгән. Хәтта
янына этләр килеп, аның җәрәхәтләрен ялыйлар икән. 22 Көн-
нәрдән беркөнне фәкыйрь вафат булган һәм фәрештәләр аны
Ибраһим янына илткәннәр; бай да үлгән, аны күмгәннәр. 23 Бай
тәмугта газап чиккән вакытта, башын күтәреп караган һәм
еракта Ибраһимны, аның янында Лазарны күргән. 24 Шунда
кычкырып: «Ибраһим атам, миңа шәфкать күрсәтче, Лазарны
яныма җибәрче, ул бармак башын суга чылатып, минем телемне
суытсын иде, чөнки мин бу ялкында бик каты газап чигәм», –
дигән. 25 Әмма Ибраһим аңа әйткән: «Углым! Исеңә төшер, син
тормышыңда бар рәхәтне татыдың инде, ә Лазар михнәт чикте;
хәзер исә ул монда юаныч күрә, ә син газап чигәсең. 26 Моннан
тыш, безнең белән сезнең арада зур упкын бар, шунлыктан
моннан сезнең якка чыгарга теләүче чыга алмас, сезнең яктан
да бу якка беркем дә чыга алмас». 27 Бай исә әйткән: «Атам,

алайса, зинһар өчен, Лазарны атам йортына җибәрче, 28 чөнки
минем биш туганым бар: ул аларны кисәтсен, алар да бу га-
заплану урынына эләкмәсеннәр иде». 29 Ибраһим аңа әйткән:
«Аларда Муса һәм пәйгамбәрләр бар; шуларны тыңласыннар».
30 Бай исә әйткән: «Юк, Ибраһим атам. Ә менә үлгәннәрдән бе-
рәү терелеп, алар янына барса, тәүбә итәрләр иде». 31 Ә Ибраһим
аңа әйткән: «Алар Мусаны һәм пәйгамбәрләрне тыңламыйлар
икән, хәтта, берәү үледән терелсә дә ышанмаслар».

*Вәсвәсә, кичерү һәм иман*

**17** 1 Гайсә Үзенең шәкертләренә шуны әйтте:
– Кешеләрне гөнаһка этәрүче вәсвәсәләр килүе ко-
тылгысыз; әмма алар кем аркылы килсә, шуңа кайгы:
2 шушы кечкенәләрнең берсен юлдан яздыручыны, муенына
тегермән ташы асып, диңгезгә ташласалар, аның өчен яхшырак
булыр иде. 3 Нәрсә кылуыгызга игътибарлы булыгыз. Туганың
сиңа карата гөнаһ кылса, аны дусларча шелтәлә, ә инде тәүбә
кылса, аны кичер; 4 сиңа карата көнгә җиде тапкыр гөнаһ кы-
лып, гөнаһ кылган саен янына килеп: «Мин гаепле», – дисә,
аны кичер.
5 Рәсүлләр Раббыга:
– Безнең иманыбызны арттырчы, – диделәр.
6 Ул әйтте:
– Сезнең горчица орлыгы кадәр генә иманыгыз булса һәм
менә бу тут агачына: «Тамырың белән кубып, үзеңне диңгезгә
күчереп утырт», – дисәгез, ул сезне тыңлар иде. 7 Сезнең кайсы-
гыз җир сукалап яки көтү көтеп кырдан кайткан хезмәтчесенә:
«Әйдә тизрәк ашарга утыр», – дип әйтер икән? 8 Киресенчә:
«Миңа кичке аш әзерлә дә, билеңне буып, мин ашап-эчкән ва-
кытта миңа хезмәт күрсәт; шуннан соң үзең дә ашап-эчәр-
сең», – дип әйтмәссезме? 9 Кушканнарны эшләгән хезмәтчегезгә
рәхмәт әйтеп тормассыз бит. 10 Шулай итеп, сез дә кушылган-
ның барысын да башкарганнан соң: «Без бары хезмәтчеләр
генә, нәрсә эшләргә тиеш булсак, шуларны гына башкар-
дык», – диегез.

*Махау авырулы ун кешенең савыгуы*

11 Иерусалимга барышлый, Ул Самарея белән Гәлиләя өлкә-
ләрен чикли торган җир буйлап үтте. 12 Һәм бер авылга килеп
кергәндә, Аны махау авырулы ун кеше очратты. Алар еракта
туктап калып, 13 көчле тавыш белән:
– Гайсә, Өйрәтүче, безгә шәфкать күрсәтче! – дип кыч-
кырдылар.

14 Ул аларны күргәч:
– Барыгыз, үзегезне руханиларга күрсәтегез, – диде.
Алар барган чакта ук савыктылар. 15 Аларның берсе исә, үзе-
нең савыкканын күреп, кире кайтты һәм кычкырып Аллаһыны
данлады, 16 һәм Гайсәнең аяклары алдына егылып, Аңа рәхмәт
әйтте. Бу кеше самареяле иде. 17 Шунда Гайсә әйтте:
– Савыктырылганнар унау иде түгелме? Тугызы кайда соң?
18 Ят өлкәдән булган бу кешедән башкалары, Аллаһыга рәхмәт
белдерү өчен, кире кайтмадылармыни?
19 Гайсә аңа:
– Тор, юлыңда бул; ышануың сине савыктырды, – диде.

### *Аллаһы Патшалыгы ничек килер?*

20 Фарисейләр Гайсәдән:
– Аллаһы Патшалыгы кайчан килер? – дип сорадылар.
Ул аларга болай дип җавап кайтарды:
– Аллаһы Патшалыгы күзгә күренеп килмәс. 21 «Менә ул
монда», яки: «Әнә тегендә», – дип беркем дә әйтмәс. Чөнки
Аллаһы Патшалыгы сезнең арада*.
22 Гайсә шәкертләренә мөрәҗәгать итте:
– Адәм Улы көннәренең берсен генә булса да күрәсегез кил-
гән вакыт килер, әмма күрмәссез. 23 Кешеләр сезгә: «Кара, Ул
анда», яки: «Кара, Ул монда», – диярләр; беркая да бармагыз,
алар артыннан чапмагыз. 24 Чөнки яшен яшьнәп, күкнең бер
читеннән икенче читенә чаклы ялтырап киткән кебек, Адәм
Улы Үз көнендә шулай булачак. 25 Әмма башта Ул күп газаплар
чигәргә һәм бу буын тарафыннан кире кагылырга тиеш. 26 Нух
көннәрендә ничек булган булса, Адәм Улы көннәрендә дә
шулай булачак: 27 Нух көймәгә кергән көнгә кадәр кешеләр
ашаганнар, эчкәннәр, өйләнгәннәр, кияүгә чыкканнар. Ул
көймәгә кергәннән соң, туфан килеп барысын да һәлак иткән.
28 Лут көннәрендә ничек булган булса, шулай булачак: ашаган-
нар, эчкәннәр, алыш-биреш иткәннәр, чәчкәннәр, төзегәннәр.
29 Әмма Лут Сәдүм шәһәреннән чыккан көнне, күктән ут белән
күкерт яңгыры яуган һәм аларның барысын һәлак иткән. 30 Адәм
Улы күренгән көнне дә шулай булачак. 31 Ул көнне кем өй тү-
бәсендә булып, ә әйберләре өй эчендә калган булса, аларны
алыр өчен түбәнгә төшмәсен; шулай ук кем кырда булса, өенә
кайтмасын. 32 Лутның хатынын исегездә тотыгыз. 33 Тормышын
саклап калырга тырышучы аны югалтыр; ә инде тормышын

---

* 17:21 *Сезнең арада* – бу сүзләрне грек теленнән «сезнең эчегездә» дигән мәгънәдә дә аңларга мөмкин.

югалткан кеше аны саклап калыр. 34 Сезгә әйтәм: ул төнне ике
кеше бер ятакта булыр: берсе алыныр, ә икенчесе калдырылыр.
35 Ике хатын бергә ашлык тартыр: берсе алыныр, ә икенчесе
калдырылыр. [ 36 ]* 37 Аның бу сүзләренә шәкертләре:

– Раббыбыз, бу кайда булыр? – дип сорадылар.

Ул исә аларга:

– Үләксә кайда булса, үләксә кошлары шунда җыелыр, – дип җавап бирде.

*Тол хатын һәм хаким турында гыйбрәтле хикәя*

18 1 Гайсә Үз шәкертләренә, һәрвакыт күңелне төшермичә
дога кылырга кирәклеген күрсәтү өчен, гыйбрәтле хи-
кәя сөйләде:
2 – Бер шәһәрдә Аллаһыдан курыкмаучы һәм кешеләрне
ихтирам итмәүче бер хаким булган. 3 Шул ук шәһәрдә бер тол
хатын яшәгән һәм ул, хаким янына йөреп: «Мине дошманым-
нан яклачы», – дип әйтә торган булган. 4 Әмма хаким озак
вакыт тол хатынның дәгъвәсен хәл итәргә теләмәгән. Ә ан-
нары болай дип уйлаган: «Мин Аллаһыдан курыкмасам да, ке-
шеләрне ихтирам итмәсәм дә, 5 бу тол хатын миңа тынгылык
бирмәгәнгә күрә, аның дәгъвасын хәл итим, мине башка ялык-
тырып йөрмәсен».
6 Һәм Раббы әйтте:
– Гадел булмаган хакимнең нәрсә әйткәнен ишетәсезме?
7 Көне-төне Үзен ярдәмгә чакыручы Үзе сайлаганнарны Аллаһы
якламасмыни? Ул түзеп тора алырмы? 8 Сезгә әйтәм: Ул тот-
карланмас, яклар. Әмма Адәм Улы килгәч, җирдә иман табар
микән?

*Фарисей һәм салым җыючы*

9 Гайсә үзләрен тәкъва дип хисаплаучы һәм башкаларны тү-
бәнсетүче кайберәүләргә бу гыйбрәтле хикәяне сөйләде:
10 – Ике кеше дога кылу өчен Аллаһы Йортына кергән: берсе
фарисей, ә икенчесе салым җыючы булган. 11 Фарисей, торып,
болай дип дога кылган: «Йа Аллаһы! Мин моның өчен Сиңа рәх-
мәт белдерәм: мин башкалар кебек талаучы да, алдакчы да, зина
кылучы да, яки менә бу салым җыючы кебек тә түгел. 12 Атнага
ике тапкыр ураза тотам, табышымның унынчы өлешен Сиңа би-
рәм». 13 Салым җыючы исә читтәрәк басып торган һәм күзләрен
күтәреп күккә карарга да батырчылык итмәгән; әмма күкрәгенә

---

* 17:36 Кайбер кулъязмаларда 36 нчы аять тә бар: «Ике кеше кырда булыр: берсе алыныр, ә икенчесе калдырылыр».

суга-суга: «Йа Аллаһы! Мин гөнаһлыга мәрхәмәтле бул!» – ди-
гән. 14 Сезгә әйтәм: тегесе түгел, бәлки монысы Аллаһы алдында
акланган хәлдә үз өенә кайтып киткән; чөнки, үзен-үзе күтәрүче
һәркем түбәнсетелер; ә үзен-үзе түбәнсетүче күтәрелер.

*Гайсә балаларга фатиха бирә*

15 Кайбер кешеләр, фатихалау өчен Гайсә кулларын куйсын
дип, Аның янына яшь балаларны да алып килделәр. Шәкертләре
исә, моны күреп, аларны шелтәләделәр. 16 Ә Гайсә балаларны
Үзе янына чакырып әйтте:

– Балаларга Минем янга килергә ирек бирегез, аларга кома-
чауламагыз, чөнки Аллаһы Патшалыгы менә шундыйларныкы.
17 Сезгә хак сүз әйтәм: Аллаһы Патшалыгын балалар кебек ка-
бул итмәгән кеше анда кермәячәк.

*Гайсә һәм бер бай*

18 Башлыкларның берсе Гайсәдән:

– Игелекле Остаз! Мәңгелек тормышны мирас итеп алу өчен
миңа нәрсә эшләргә кирәк? – дип сорады.

19 Гайсә аңа әйтте:

– Нигә син Мине игелекле дип атыйсың? Бер Аллаһыдан
башка һичкем дә игелекле түгел. 20 Аның әмерләрен беләсең:
зина кылма, кеше үтермә, урлама, ялган шаһитлек бирмә,
атаңны һәм анаңны хөрмәт ит.

21 Ә башлык әйтте:

– Мин боларның барысын да яшьтән үк үтәп килдем.

22 Моны ишеткәч, Гайсә аңа әйтте:

– Сиңа әле бер нәрсә җитми: нәрсәң бар, барысын да сат
һәм фәкыйрьләргә өләш, шулай эшләсәң, күктәге хәзинәгә ия
булырсың. Аннары яныма кил дә Миңа ияр.

23 Ул исә, моны ишеткәч, кайгы-хәсрәткә төште, чөнки бик
бай иде.

24 Гайсә, моны күреп, әйтте:

– Байлыгы булганнарга Аллаһы Патшалыгына керү ничек
кыен! 25 Бай кешегә Аллаһы Патшалыгына керүгә караганда,
дөягә энә күзе аша үтү җиңелрәк.

26 Моны ишетүчеләр:

– Алай булгач, кем генә котыла алыр соң? – дип сорадылар.

27 Ул әйтте:

– Кешеләргә мөмкин булмаган Аллаһыга мөмкин.

28 Петер исә әйтте:

– Менә без, булган нәрсәләребезнең бөтенесен калдырып,
Сиңа иярдек.

29 Ул аларга болай диде:
– Сезгә хак сүз әйтәм: Аллаһы Патшалыгы хакына йортын
яки хатынын, агай-энеләрен, ата-анасын яки балаларын калдыр-
ган һәркем, 30 хәзерге вакытта күп тапкырга артыграк, киләчәк
дөньяда исә мәңгелек тормыш алачак.

*Гайсә янә Үзенең үлеме хакында әйтә*

31 Гайсә, унике шәкертен янына чакырып алып, аларга
әйтте:
– Без Иерусалимга менеп барабыз, һәм пәйгамбәрләр тара-
фыннан Адәм Улы хакында язылганнарның барысы да тормыш-
ка ашачак. 32 Аны мәҗүсиләр кулына тапшырачаклар, алар Аны
мыскыллаячаклар, хурлаячаклар һәм Аңа төкерәчәкләр; 33 Аны
камчылаячаклар һәм үтерәчәкләр. Ә өченче көндә Ул үледән
терелеп торачак.
34 Әмма шәкертләр бу сүзләрдән бернәрсә дә аңламадылар;
алар өчен бу сүзләрнең мәгънәсе яшерен иде, һәм алар әйтел-
гәннәргә төшенмәделәр.

*Гайсә сукыр хәерчене савыктыра*

35 Гайсә Әрихәгә якынлашып килгәндә, бер сукыр юл буенда
хәер сорашып утыра иде. 36 Ул, яныннан күп кешеләр үтеп ба-
руын ишетеп:
– Бу ни бу? – дип сорады.
37 Алар аңа:
– Насаралы Гайсә үтеп бара, – диделәр.
38 Шунда ул:
– Давыт Улы Гайсә! Кызган мине! – дип кычкырып җи-
бәрде.
39 Алдан баручылар аңа дәшмәскә куштылар; әмма ул тагын
да катырак итеп:
– Давыт Улы! Кызган мине! – дип кычкырды. 40 Гайсә,
туктап, аны Үз янына китерергә кушты. Сукыр Аның янына
килгәч, Ул аннан:
41 – Син Миннән нәрсә телисең? – дип сорады.
Ул Аңа:
– Әфәнде! Күзләрем күрсен иде, – диде.
42 Гайсә аңа:
– Күзләрең күрсен! Синең ышануың савыктырды, – диде.
43 Ул шундук күрә башлады һәм, Аллаһыны данлап, Гайсәгә
ияреп китте. Андагы кешеләр, моны күреп, Аллаһыны данла-
дылар.

*Зәкәй коткарыла*

19 [1] Гайсә, Әрихәгә кереп, аның аша үтеп бара иде. [2] Анда
салым җыючыларның башлыгы булган Зәкәй атлы бер
бай кеше яши иде. [3] Ул Гайсәнең нинди кеше булуын
күрергә тырышып йөрде, ләкин кыска буйлы булганлыктан,
халык арасыннан Аны күрә алмады, [4] һәм, Гайсәне күрү өчен,
алга йөгереп чыкты да кыргый инҗир агачына менеп утырды,
чөнки Гайсә шул урыннан үтәргә тиеш иде. [5] Гайсә, шул урын-
га җиткәч, югарыга таба карады һәм Зәкәйгә:
– Зәкәй, тизрәк төш әле, чөнки Мин бүген синең өеңдә
кунакта булырга тиеш, – диде.
[6] Ул тиз генә төште дә Аны шатланып кабул итте. [7] Бу хәлне
күргәннәрнең барысы да:
– Ул, гөнаһлы кешенең өенә кереп, аның кунагы булды! –
дип зарлана башладылар.
[8] Зәкәй исә, торып, Раббыга әйтте:
– Әфәнде! Милкемнең яртысын фәкыйрьләргә бирермен,
инде кемне дә булса алдаганмын икән, аңа дүрт тапкыр күбрәк
кайтарып бирермен.
[9] Гайсә исә моңа карата:
– Бүген бу гаиләгә котылу килде, ул да Ибраһим нәселеннән
бит, – диде. [10] – Чөнки Адәм Улы югалганны эзләп табарга һәм
коткарырга килде.

*Хезмәтчеләргә бирелгән акчалар турында гыйбрәтле хикәя*

[11] Кешеләр моны тыңлаганда, Гайсә сүзен дәвам итеп, бер
гыйбрәтле хикәя сөйләде, чөнки Ул озакламый Иерусалимга
килеп җитәчәк иде, һәм алар, тиздән Аллаһы Патшалыгы күре-
нергә тиеш, дип уйладылар. [12] Шуның өчен Ул әйтте:
– Затлы нәселдән булган бер кеше, патшалыкны кабул итү
өчен, ерак илгә киткән. Ул аннан әйләнеп кайтырга тиеш бул-
ган. [13] Ул, юлга чыкканчы, үзенең ун хезмәтчесен чакырып,
аларның һәрберенә берәр алтын тәңкә* биргән һәм: «Мин кайт-
канчы боларны кулланып, табыш казаныгыз», – дигән. [14] Әмма
аның ватандашлары нәфрәтләнеп: «Без аның өстебездән пат-
шалык итүен теләмибез», – дип белдерү өчен, аның артыннан
илчеләр җибәргәннәр. [15] Патшалыкны кабул итеп кайту белән
үк, ул акча бирелгән хезмәтчеләренең күпме табыш алуларын
белү өчен, аларны үз янына чакырырга кушкан. [16] Беренчесе

* **19:13** *Алтын тәңкә* – грекча «мна». Бер мна 100 динарга, димәк, эшченең 100 көнлек хезмәт хакына тигез.

килеп: «Хуҗам, синең бер алтын тәңкәң ун тәңкә китерде», —
дигән. 17 Хуҗасы аңа: «Бик әйбәт, син минем яхшы хезмәтчем.
Кечкенә генә нәрсәдә ышанычлы булганың өчен, ун шәһәр
синең кул астында булсын», — дигән. 18 Икенчесе килеп: «Ху-
җам, синең бер алтын тәңкәң биш алтын тәңкә китерде», — ди-
гән. 19 Хуҗасы аңа да: «Мин сине биш шәһәр өстеннән башлык
итәрмен», — дигән. 20 Ә өченчесе килеп болай дигән: «Хуҗам,
менә син биргән алтын тәңкә, мин аны кульяулыкка төреп,
саклап тоттым; 21 чөнки мин синнән курыктым, син кырыс ке-
ше бит; салмаганыңны аласың, чәчмәгәнеңне урасың». 22 Хуҗа-
сы аңа әйткән: «Әй, яраксыз хезмәтче! Мин сине үз сүзләрең
белән хөкем итәм. Син минем кырыс булуымны, үзем салма-
ганны алуымны, үзем чәчмәгәнне уруымны белгәч, 23 ни өчен
соң мин биргән акчаны әйләнешкә кертмәдең? Шулай эшлә-
гән булсаң, кайткач мин аны табышы белән алган булыр идем».
24 Шуннан соң ул янында торганнарга: «Аннан акчаны алыгыз да
ун алтын тәңкәсе булганга бирегез», — дигән. 25 Алар аңа: «Ху-
җам! Аның ун тәңкәсе бар бит инде», — дип әйткәннәр. 26 Ә ул
аларга болай дип әйткән: «Сезгә әйтәм: кемнең бар, аңа тагын
бирелер, ә кемнең юк, аның булган нәрсәсе дә тартып алыныр.
27 Ә инде үзләре өстеннән патшалык итүемне теләмәгән дош-
маннарымны монда китерегез һәм күз алдымда үтерегез».

*Гайсә тантана белән Иерусалимга керә*

28 Шул сүзләрне әйткәннән соң, Гайсә, башкалар алдыннан
барып, Иерусалимга таба юлын дәвам итте. 29-30 Зәйтүн тавы
дип аталган тау янындагы Бәйтфәги һәм Бәйтәниягә якын-
лашкач, Ул:

— Алда күренгән авылга барыгыз; анда кергәч, моңа кадәр өстенә беркем дә атланмаган, бәйләп куелган яшь ишәкне күрерсез; аны бәйдән ычкындырып, монда алып килегез, —
дип, шәкертләренең икесен Үзеннән алдан җибәрде. 31 — Әгәр
берәрсе сездән: «Нигә аны бәйдән ычкындырасыз?» — дип сораса, аңа: «Ул Хуҗага кирәк», — дип әйтегез.

32 Ике шәкерт китте, һәм һәр нәрсәне Гайсә әйткәнчә тапты-
лар. 33 Алар яшь ишәкне бәйдән ычкындырган вакытта аның
хуҗалары:

— Ни өчен ишәкне бәйдән ычкындырасыз? — дип сорадылар.

34 Алар исә:

— Ул Хуҗага кирәк, — дип җавап бирделәр.

35 Ишәкне Гайсә янына алып килделәр; өс киемнәрен ишәк
өстенә салып, аның өстенә Гайсәне атландырдылар. 36 Ул ат-
ланып барган вакытта, кешеләр өс киемнәрен юл өстенә

җәйделәр. [37-38] Ә Ул Зәйтүн тавыннан төшә торган юлга якынлашкач, күп санлы шәкертләре шатланышып, көчле тавыш белән, үзләре күргән барлык кодрәтле могҗизалар өчен:

– Патша, Раббы исеме белән Килүче мөбарәк!
Күктә – тынычлык, югарыда – данлау! –

дип, Аллаһыны данлый башладылар.

[39] Шунда халык арасыннан кайбер фарисейләр Гайсәгә:

– Остаз! Шәкертләреңне тый! – диделәр.

[40] Әмма Ул аларга җавап биреп:

– Сезгә шуны әйтәм: алар тынып калсалар, ташлар кычкыра башлаячак, – диде.

*Гайсә Иерусалим өчен елый*

[41] Иерусалимга якынлашкач, Гайсә шәһәрне күреп, аның язмышы өчен елый башлады [42] һәм әйтте:

– Әгәр син, ичмасам, шушы көндә генә булса да, синең тынычлыгың өчен нәрсә кирәген белсәң иде! Әмма бу хәзер синең күзләреңнән яшерелгән. [43] Сиңа шундый көннәр килер, дошманнарың, әйләнә-тирәңдә чокырлар казып һәм туфраклар өеп, сине чолгап алырлар һәм һәр тарафтан кысарлар. [44] Сине бөтенләй җимереп бетерерләр, синдә яшәүче кешеләрне кырырлар һәм синдәге бер ташны да үз урынында калдырмаслар, чөнки син Аллаһы янына килеп шәфкать күрсәткән вакытны белмәдең.

*Аллаһы Йорты – дога кылу йорты*

[45] Гайсә, Аллаһы Йортына кереп, андагы сатучыларны куып чыгара башлады. [46] Ул аларга әйтте:

– Изге язмада: «Минем Йортым – дога кылу йорты булачак», – дип язылган; ә сез аны юлбасарлар оясына әйләндердегез.

[47] Ул һәр көн Аллаһы Йортында өйрәтте. Баш руханилар, канунчылар һәм халык аксакаллары исә Аны һәлак итү әмәлен эзләделәр. [48] Әмма Аңа каршы нинди дә булса әмәл таба алмадылар, чөнки бөтен халык һәрвакыт Аның сүзләрен тыңлады.

*Гайсәнең вәкаләте кемнән?*

**20** [1] Көннәрнең берендә Гайсә, Аллаһы Йортында халыкны өйрәтеп, Яхшы хәбәр сөйләгәндә, Аның янына аксакаллар белән баш руханилар һәм канунчылар килде. [2] Алар Аннан:

– Безгә әйт әле, Син боларны нинди вәкаләт белән эшлисең, андый хокукны Сиңа кем бирде? – дип сорадылар.

[3] Ул аларга болай җавап бирде:

– Мин дә сезгә бер сорау бирәм, Миңа әйтегез әле: [4] Яхъяның суга чумдыруы күктән идеме яки кешеләрдәнме?

[5] Алар исә үзара фикер алышып:

– «Күктән», – дисәк, Ул: «Ә ни өчен Яхъяга ышанмадыгыз?» – дияр. [6] Ә инде: «Кешеләрдән», – дисәк, бөтен халык безне ташлар атып үтерер, чөнки халык Яхъяның пәйгамбәр булуына ышана, – диделәр.

[7] Шуңа күрә:

– Без кайдан икәнен белмибез, – дип җавап бирделәр.

[8] Гайсә аларга:

– Алай булгач, Мин дә сезгә боларны нинди вәкаләт белән эшләвемне әйтмим, – диде.

*Йөзем үстерүче явызлар хакында гыйбрәтле хикәя*

[9] Шуннан соң Ул халыкка менә шушы гыйбрәтле хикәяне сөйләде:

– Бер кеше йөзем бакчасы утырткан һәм, аны йөзем үстерүчеләргә куллану өчен биреп, үзе озак вакытка чит якларга китеп барган. [10] Уңыш җыяр вакыт җиткәч, бакчасыннан аның өлешен биреп җибәрсеннәр дип, хезмәтчесен йөзем үстерүчеләр янына җибәргән; ләкин йөзем үстерүчеләр, аны кыйнап, буш кул белән кайтарып җибәргәннәр. [11] Аннары ул икенче хезмәтчесен җибәргән; ләкин алар аны да кыйнап һәм сүгеп, бернәрсәсез кире җибәргәннәр. [12] Ул тагын өченче хезмәтчесен җибәргән; ләкин аны да яралап, куып чыгарганнар. [13] Шуннан соң йөзем бакчасының хуҗасы болай дип уйлаган: «Инде нәрсә эшләргә? Сөекле улымны җибәрим әле, бәлки аны хөрмәт итәрләр». [14] Әмма йөзем үстерүчеләр, аны күргәч, үзара: «Бу – варис. Әйдәгез, аны үтерик һәм аңа каласы мал безнеке булыр», – дип киңәшләшкәннәр. [15] Һәм аны бакчадан алып чыгып үтергәннәр.

Инде йөзем бакчасының хуҗасы алар белән ни эшләр? [16] Ул, әйләнеп кайткач, йөзем үстерүчеләрне үтерер һәм йөзем бакчасын башкаларга бирер.

Моны тыңлаучылар исә:

– Алай була күрмәсен! – диештеләр.

[17] Әмма Ул аларга туры карап әйтте:

– «Төзүчеләр яраксыз дип кире каккан таш
иң мөһим почмак ташы булды», –

дип Изге язмада язылганнар нәрсәне аңлата соң? [18] Бу таш өстенә егылган һәркем челпәрәмә киләчәк; ә ул таш кемнең дә булса өстенә төшсә, аны сытачак.

[19] Шундук баш руханилар һәм канунчылар, Ул сөйләгән гыйбрәтле хикәянең үзләре турында икәнен аңлап, Аны кулга алырга теләделәр, әмма халыктан курыктылар.

*Кайсарга салым түләү хакында сорау*

[20] Алар Гайсә артыннан дикъкать белән күзәтә башладылар һәм янына шымчылар җибәрделәр, ә алар, үзләрен ихлас күңелле итеп күрсәткән булып, идарәче кулына, аның хөкеменә тотып бирү өчен, Аннан бәйләнерлек берәр сүз әйттерергә тырыштылар. [21] Алар:

– Остаз! Без Синең дөреслекне сөйләвеңне һәм өйрәтүеңне, кешене кешедән аермавыңны, Аллаһы юлына хакыйкать буенча өйрәтүеңне беләбез, – диделәр. [22] Һәм Аннан:

– Кайсарга салым түләргә канун безгә рөхсәт итәме, әллә юкмы? – дип сорадылар.

[23] Гайсә исә, аларның мәкерле ниятләрен аңлап, әйтте:

[24] – Миңа бер динарны күрсәтегез әле. Монда кемнең сурәте һәм кемнең исеме?

Алар:

– Кайсарныкы, – дип җавап бирделәр.

[25] Ул аларга:

– Шулай булгач, кайсарныкын кайсарга, Аллаһынекын Аллаһыга бирегез, – диде.

[26] Алар Аның халык алдында сөйләгән сүзләренә бәйләнерлек бер нәрсә дә таба алмадылар һәм, Аның җавабына хәйран калып, тынып калдылар.

*Үледән терелү турында сорау*

[27] Аннары Гайсә янына үлеләрнең терелүен инкяр итүче саддукейлар* арасыннан кайберәүләр килде һәм Аңа болай диделәр:

[28] – Остаз! Муса безгә канунда: «Берәүнең бертуганы, хатыны булып та, балалары булмыйча үлеп китсә, ул тол калган хатынга өйләнеп, бертуганының буынын дәвам иттерсен», – дип язып калдырган. [29] Җиде бертуган булган: шуларның беренчесе, хатын алып, балалары булмыйча үлеп киткән. [30] Ул хатынны икенчесе дә, [31] аннан өченчесе дә, һәм калган башкалары да, шулай ук җиденчесе дә алган, әмма барысы да бала калдырмыйча үлгәннәр. [32] Ахырда хатын да үлгән. [33] Шулай булгач, үлеләр терелгән вакытта ул хатын кайсысының хатыны булачак? Җидесе дә аның ире булган бит!

---

* 20:27 *Саддукейлар* – яһүдләрнең йолаларын тотучы дини төркем. Алар үледән терелүгә ышанмаганнар.

[34] Гайсә аларга болай дип җавап бирде:
– Бу дөнья кешеләре өйләнәләр дә, кияүгә дә чыгалар. [35] Ә
инде киләчәк дөньяда булырга һәм үледән терелергә лаеклы
булганнар, анда өйләнмәсләр дә, кияүгә дә чыкмаслар. [36] Алар
инде үлә дә алмыйлар, чөнки алар фәрештәләрдәй булачаклар
һәм, үледән терелеп торганга күрә, алар Аллаһы балалары бу-
лалар. [37] Ә инде янып торган күгән агачы турында сөйләгәндә
Муса да, Раббыны Ибраһим Аллаһысы дип тә, Исхак Алла-
һысы дип тә, һәм Ягъкуб Аллаһысы дип тә атап, үлеләрнең те-
релүен күрсәткән. [38] Аллаһы – үлеләр Аллаһысы түгел, бәлки
тереләр Аллаһысы, чөнки Аның өчен барысы да тере.
[39] Кайбер канунчылар моңа:
– Остаз! Син яхшы әйттең, – диделәр.
[40] Шуннан соң алар Аннан бернәрсә турында да сорарга ба-
тырчылык итмәделәр.

*Мәсих – Давыт Улымы?*

[41] Ул исә аларга әйтте:
– Ничек кешеләр Мәсихне Давыт Улы дип әйтә алалар?
[42-43] Давыт үзе Зәбур китабында әйтә бит:
«Раббы Аллаһы минем Раббыма әйтте:
Мин дошманнарыңны аяк астыңа
баскыч итеп салганчы,
Утыр Минем уң ягымда».
[44] – Шулай итеп, Давыт Аны Раббы дип атый. Шулай булгач,
ничек инде Ул аның Улы була ала?

*Гайсә канунчылардан сакланырга куша*

[45] Бөтен кешеләр тыңлап торганда, Ул шәкертләренә әйтте:
[46] – Канунчылардан сак булыгыз! Алар озын киемнәр киеп йө-
рүне, җыелыш мәйданнарында үзләрен ихтирам итеп сәламләү-
не, гыйбадәтханәләрдә иң яхшы урыннарда, аш мәҗлесләрендә
иң түрдә утыруны яраталар. [47] Алар, хәйләләп, тол хатыннарның
йортларын үзләренә алалар, кешеләр күрсен дип, озак итеп дога
кылалар; мондыйлар тагын да катырак хөкем ителәчәкләр.

*Тол хатынның бүләге*

**21** [1] Гайсә як-ягына карады һәм байларның сәдака сан-
дыгына сәдака салуын күрде. [2] Шулай ук фәкыйрь тол
хатынның да ике вак акча салуын күрде [3] һәм әйтте:
– Сезгә хак сүз әйтәм: бу фәкыйрь тол хатын башкаларга ка-
раганда күбрәк салды. [4] Чөнки тегеләрнең барысы да үзләрен-
нән артканын Аллаһыга бүләк иттеләр, ә бу хатын, фәкыйрь
була торып, яшәү өчен кирәк булган бар булганын салды.

*Аллаһы Йортының җимерелүе*

[5] Кайберәүләр Аллаһы Йортының затлы ташлар һәм Аллаһыга багышланган бүләкләр белән бизәлгән булуы хакында сөйләгәндә, Гайсә әйтте:

[6] – Килер көннәр, сез монда күргәннәрнең берсеннән дә таш өстендә таш та калмаячак, барысы да җимереләчәк.

*Ахыр заман билгеләре*

[7] Шунда Аннан сорадылар:

– Остаз! Бу кайчан булачак соң? Һәм аларның тиздән булачагын нинди билге аша беләчәкбез?

[8] Гайсә әйтте:

– Сак булыгыз, сезне алдамасыннар; чөнки күпләр Минем исемем белән килерләр һәм: «Мин – Ул», «Ул вакыт инде
якын», – диярләр. Андыйларга иярмәгез. [9] Сугышлар һәм чуалышлар хакында ишеткәндә, куркуга төшмәгез. Бу вакыйгалар алдан булырга тиеш, ләкин әле бу ахыры түгел.

[10] Һәм Ул дәвам итеп әйтте:

– Халык халыкка каршы, патшалык патшалыкка каршы чы-
гар. [11] Урыны-урыны белән көчле җир тетрәүләр, ачлык булыр, үләтләр чыгар, күктә куркыныч күренешләр һәм бөек галәмәт-
ләр күренер. [12] Әмма боларның барыннан да элек Минем хакка сезне кулга алырлар һәм эзәрлекләрләр, сезне хөкем итү өчен гыйбадәтханәләргә алып барырлар һәм төрмәләргә утыртырлар. Сезне патшалар һәм идарәчеләр алдына алып барырлар.
[13] Ул чакта сез Минем турыда шаһитлек бирә алырсыз. [14] Шулай
итеп, күңелегезгә салып куегыз: «Үзебезне ничек итеп якларбыз», – дип, алдан уйламагыз. [15] Чөнки Мин сезгә тиешле сүз-
ләр һәм зирәклек бирермен, сезнең дошманнарыгызның берсе генә дә аларга каршы чыга һәм каршы тора алмаслар. [16] Хәтта
ата-аналарыгыз да, агай-энеләрегез дә, кардәшләрегез дә, дусларыгыз да сезгә хыянәт итәрләр, һәм кайберләрегез үтертелер
дә. [17] Барысы да Минем өчен сезне нәфрәт итәр. [18] Шулай да,
башыгыздагы чәчегезнең бер генә бөртеге дә югалмас. [19] Чы-
дамлыгыгыз белән тормышыгызны коткарырсыз.

*Иерусалимның җимерелүе турында*

[20] Иерусалимның гаскәрләр тарафыннан чолгап алынуын күргән вакытта, белеп торыгыз: аның җимерелү вакыты якын инде.
[21] Шул чакта Яһүдиядә булганнар тауларга качсын; шәһәрдәгеләр аннан чыксын; авыл тирәсендәгеләр анда кермәсен. [22] Чөн-
ки ул көннәр – үч алу көннәре һәм ул көннәрдә Изге язмада
язылганнарның барысы да тормышка ашар. [23] Ул көннәрдә

йөкле һәм бала имезүче хатыннарга кайгы! Чөнки бу илгә зур
афәт һәм бу халыкка нәфрәт киләчәк: 24 берәүләр кылыч белән
үтереләчәк, кайберәүләрне әсир итеп барлык илләргә алып
китәчәкләр; һәм, мәҗүсиләрнең вакыты үткәнче, алар Иерусалимны таптаячак.

*Адәм Улының килүе турында*

25 Кояшта да, айда да, йолдызларда да галәмәтләр булачак,
җирдәге халыклар өметсезлеккә биреләчәк һәм диңгезнең көчле
шаулавына һәм котыруына аптырап калачак. 26 Галәмгә киләчәк
афәтләрне көтеп, кешеләр куркудан аңнарын югалтыр, чөнки
күк кодрәтләре селкетелер. 27 Шул вакыт кодрәт һәм балкып торган бөек дан белән болытта килүче Адәм Улын күрерләр. 28 Болар
гамәлгә аша башлагач, курыкмыйча, тураеп басыгыз, башларыгызны күтәрегез, чөнки сезнең котылуыгыз инде якын.

*Инҗир агачы хакында гыйбрәтле сүзләр*

29 Гайсә аларга бер гыйбрәтле сүз сөйләде:
– Инҗир агачына һәм барлык агачларга карагыз: 30 аларның
яфрак яра башлавын күреп, сез тиздән җәйнең инде җитәчәген
беләсез. 31 Шуның кебек үк, бу хәлләрнең гамәлгә ашуын күргәндә, сез Аллаһы Патшалыгының якын икәнен белерсез.
32 Сезгә хак сүз әйтәм: боларның барысы да тормышка ашмыйча, бу буын кешеләре үлмәячәк. 33 Күк һәм җир юкка чыгачак,
әмма Минем сүзләрем һичкайчан юкка чыкмаячак.

*Уяу булыгыз*

34 Сак булыгыз, артык ашап-эчү, эчеп-исерү һәм тормыш мәшәкатьләре сезнең белән идарә итмәсен, ул көн сезгә, тозак
кебек, көтмәгәндә килмәсен. 35 Чөнки ул көн җир йөзендәге
кешеләрнең барысын да куып җитәр. 36 Шулай итеп, һәрвакыт
уяу булыгыз һәм, булырга тиешле барлык нәрсәләрдән качып
котылырга һәм Адәм Улы каршына килеп басарга көчегез булсын өчен, дога кылыгыз.
37 Көндезләрен Гайсә Аллаһы Йортында өйрәтә, ә кич җиткәч, аннан китеп, төннәрен Зәйтүн тавы дип аталган тауда үткәрә иде. 38 Бөтен халык иртән иртүк Аны тыңлау өчен Аллаһы
Йортына килә иде.

*Гайсәне үтерү нияте*

**22** 1 Коткарылу бәйрәме дип аталган Төче күмәч бәйрәме
якынлаша иде. 2 Баш руханилар һәм канунчылар халыктан курykканга, алардан яшерен рәвештә, Гайсәдән
котылу әмәлен эзләделәр.

[3] Бу вакытта уникe шәкертнең берсе Искариот кушаматлы
Яһүднең эченә шайтан керде. [4] Һәм ул, баш руханилар һәм
Аллаһы Йорты каравылы башлыклары янына барып, Гайсәне
алар кулына тапшыру хакында сөйләште. [5] Алар шатландылар
һәм аңа акча бирергә риза булдылар. [6] Яһүд алар белән риза-
лашты һәм, халык белмәгәндә Гайсәне алар кулына тапшыру
өчен, уңай вакыт эзли башлады.

*Коткарылу бәйрәме ашы*

[7] Коткарылу бәрәне чалынырга тиеш булган, Төче күмәч
бәйрәме көне килеп җитте. [8] Гайсә, Петер белән Яхъяны җи-
бәреп, аларга:
– Барыгыз, безгә Коткарылу бәйрәме ашын әзерләгез, – диде.
[9] Алар Аңа:
– Аны кайда әзерләвебезне телисең? – диделәр.
[10] Ул аларга әйтте:
– Шәһәргә кергәндә сезгә су чүлмәге күтәреп кайтучы бер
кеше очрар. Аның артыннан барыгыз һәм ул кергән өйгә кере-
гез [11] һәм йорт хуҗасына: «Остаз синнән: „Шәкертләрем белән
Коткарылу бәйрәме ашын кайсы бүлмәдә ашыйк?“ – дип со-
рый», – диегез. [12] Ул сезгә өске каттагы җиһазланган зур бүл-
мәне күрсәтер, шунда әзерләгез.
[13] Шәкертләр китте һәм, һәрнәрсәне Гайсә әйткәнчә табып,
Коткарылу бәйрәме ашын әзерләделәр. [14] Аш вакыты җиткәч,
Гайсә рәсүлләр белән бергә табын артына утырды [15] һәм алар-
га әйтте:
– Мин газап чиккәнгә кадәр шушы Коткарылу бәйрәме
ашын сезнең белән бергә ашарга бик теләгән идем. [16] Сезгә
әйтәм: Аллаһы Патшалыгында үзенең тулы мәгънәсен алганга
кадәр Мин аны инде ашамаячакмын.
[17] Ул касәне алды һәм, шөкрана иткәннән соң, болай диде:
– Моны алыгыз да үзара бүлешеп эчегез. [18] Сезгә әйтәм:
Аллаһы Патшалыгы килгәнгә кадәр Мин йөзем шәрабын эчмә-
ячәкмен.
[19] Аннары Гайсә икмәк алды һәм, шөкрана иткәннән соң,
аны сындырды һәм шәкертләренә бирде.
– Бу – Минем сезнең өчен бирелә торган тәнем. Мине искә
алу өчен шулай эшләгез, – диде Ул.
[20] Аштан соң Гайсә шулай ук итеп касәне шәкертләренә
бирде һәм әйтте:
– Менә бу касә – Минем сезнең өчен түгелә торган каным
белән расланган яңа килешү. [21] Әмма Миңа хыянәт итүче Ми-
нем белән бер өстәл артында утыра. [22] Хәер, Адәм Улы, ничек

алдан билгеләнгән булса, шул юл белән бара; ләкин Аңа хыянәт итүчегә кайгы!
[23] Шәкертләр:
– Безнең арадан моны кайсыбыз эшләр икән? – дип, бер-берсеннән сораша башладылар.

*Кем иң бөеге?*

[24] Алар арасында, безнең кайсыбыз иң бөеге булып исәпләнелергә тиеш, дигән мәсьәлә турында бәхәс тә чыкты. [25] Гайсә
исә аларга әйтте:
– Патшалар халыклар өстеннән хакимлек итәләр, һәм алар белән идарә итүчеләр «яхшылык кылучылар» дип аталалар.
[26] Сездә алай булмасын: сезнең арагызда иң олыгыз кече кебек,
башлык булучыгыз хезмәтче кебек булсын. [27] Чөнки, кем олы-
рак: өстәл артында утыручымы, әллә аңа хезмәт итүчеме? Өстәл артында утыручы түгелме соң? Ә Мин сезнең арада хезмәт итүче кебек.
[28] Минем бар сынауларымда сез һаман Минем белән кала бир-
дегез. [29] Һәм, Атам Миңа биргән кебек, Мин дә сезгә патшалык
итү хокукын бирәм. [30] Шулай итеп, сез Минем Патшалыгымдагы
табында ашаячаксыз, эчәчәксез һәм, Исраилнең унике кабиләсе өстеннән хакимлек итеп, тәхетләрдә утырачаксыз.

*Гайсә Петернең ваз кичәчәген алдан әйтә*

[31] Раббы Петергә әйтте:
– Шимун, Шимун! Менә шайтан сезне бодай иләгән кебек
иләргә рөхсәт алды. [32] Әмма син иманыңны югалтмасын дип,
Мин синең өчен дога кылдым; син Миңа кире килгәч, имандашларыңны ныгыт.
[33] Петер Аңа болай диде:
– Раббым! Мин Синең белән төрмәгә дә, үлемгә дә барырга әзермен.
[34] Ә Гайсә әйтте:
– Петер, сиңа әйтәм, бүген әтәч кычкырганчы, Мине белүеңнән өч тапкыр ваз кичәчәксең.
[35] Һәм шәкертләренә әйтте:
– Мин сезне янчыксыз, биштәрсез, башмаксыз җибәргән чакта, сезнең берәр нәрсәгә ихтыяҗыгыз булдымы?
Алар:
– Һичнәрсәгә дә булмады, – дип җавап бирделәр.
[36] Шунда Ул аларга әйтте:
– Әмма хәзер янчыгы булганы аны үзе белән алсын, биштәрен дә алсын; ә янчыгы булмаганы өс киемен сатсын да кылыч

сатып алсын. [37] Чөнки сезгә әйтәм, Изге язманың: «Ул җинаятьчеләр белән тиң саналды», – дип язылган урыны Миңа карата тормышка ашырылырга тиеш. Минем хакта язылганнар тормышка ашырылу алдында.

[38] Шәкертләр Аңа:

– Раббыбыз! Менә монда ике кылыч бар, – диделәр.

Ул аларга:

– Бу турыда җитте! – диде.

*Гайсә Зәйтүн тавында дога кыла*

[39] Гайсә, гадәтенчә, шәһәрдән Зәйтүн тавына китте; Аның белән бергә шәкертләре дә барды. [40] Анда барып җиткәч, Ул аларга:

– Вәсвәсәгә дучар булмас өчен дога кылыгыз, – диде.

[41] Һәм Үзе, алардан таш атымы кадәр читкәрәк китеп, тезләнеп дога кылды [42] һәм әйтте:

– Йа, Ата! Әгәр теләсәң, бу газаплар касәсен Миннән кире алчы. Хәер, Минем ихтыярым түгел, Синең ихтыярың булсын.

[ [43] Шул вакыт, Аның янына күктән бер фәрештә килеп, Аны ныгытты. [44] Күңеле газапланганлыктан, Ул аеруча тырышып дога кылды; Аның тире җиргә тамган кан тамчылары кебек булды.]* [45] Дога кылган урыннан торып, Ул шәкертләре янына килде һәм аларны кайгыдан талчыгып йоклап яткан хәлдә күрде [46] һәм аларга әйтте:

– Нигә йоклап ятасыз? Торыгыз һәм, вәсвәсәгә дучар булмас өчен, дога кылыгыз.

*Гайсәне кулга алу*

[47] Ул әле әйтеп тә бетермәде, бу урынга халык төркеме килеп җитте, ә иң алдан уникe шәкертнең берсе – Яһүд атлысы бара иде. Ул, үбәргә дип, Гайсә янына килде. [48] Гайсә исә аңа:

– Яһүд! Син Адәм Улына үбү белән хыянәт итәсеңмени? – диде.

[49] Гайсә янындагы шәкертләр, хәзер нәрсә булачагын аңлап, Аңа әйттеләр:

– Раббыбыз! Бәлки безгә кылычларыбызны эшкә җигәргәдер?

[50] Аларның берсе, иң баш руханиның хезмәтчесенә селтәнеп, аның уң колагын чабып өзде. [51] Шунда Гайсә:

– Туктагыз! Җитәр! – диде.

Һәм, хезмәтченең колагына кулын тидереп, аны савыктырды. [52] Гайсә Үзен кулга алырга килгән баш руханиларга, Аллаһы Йорты каравылы башлыкларына һәм аксакалларга әйтте:

---

* 22:43-44 Кайбер кулъязмаларда 43-44 нче аятьләр дә бар.

– Юлбасар тотарга чыккан кебек, сез Мине тотарга кылычлар һәм чукмарлар күтәреп килгәнсез! 53 Мин һәр көнне сезнең белән бергә Аллаһы Йортында булдым һәм сез Миңа кул күтәрмәдегез; ә хәзер – сезнең вакыт, караңгылык хакимлек итә.

*Петернең Гайсәдән ваз кичүе*

54 Шуннан соң алар, Гайсәне тотып, иң баш рухани өенә алып
керделәр. Петер исә ерактарак калып алар артыннан барды.
55 Ишегалды уртасына учак ягылган иде. Петер учак тирәсендә
утыручылар арасына барып утырды. 56 Ә бер хезмәтче хатын,
аның учак янында утырганын күреп, аңа текәлеп карады:
– Менә бу да Аның белән иде, – диде.
57 Әмма ул хатынга:
– Мин Аны белмим, – дип, Аннан ваз кичте.
58 Бераздан икенче берәү аны күреп:
– Син дә аларның берсе, – диде.
Ләкин Петер ул кешегә:
– Юк! – диде.
59 Бер сәгатьләп вакыт үткәч, тагын аларның берсе:
– Чынлап та, бу да Аның белән бергә иде, ул да Гәлиләя
кешесе бит, – дип, катгый рәвештә раслады.
60 Әмма Петер ул кешегә:
– Мин синең нәрсә сөйләвеңне белмим, – диде.
Ул нәкъ менә шушы сүзләрне әйткән вакытта әтәч кычкырды.
61 Бу вакытта Раббы борылып Петергә карады; һәм Раббының аңа: «Бүген әтәч кычкырганчы син Миннән өч тапкыр ваз
кичәчәксең», – дигән сүзләре исенә төште. 62 Ул, урам якка
чыгып, бик каты елады.
63 Гайсәне саклап торучылар Аны мыскыл иттеләр һәм кыйнадылар.
64 Гайсәнең күзләрен каплап, Аннан:
– Пәйгамбәрлек итеп әйт: Сиңа кем сукты? – дип сорадылар.
65 Алар болардан башка да Аны хурлый торган күп сүзләр әйттеләр.
66 Таң белән яһүд аксакаллары, баш руханилар һәм канунчылар Югары киңәшмә җыелышына җыелдылар һәм Гайсәне
җыелыш алдына китереп бастырдылар 67 һәм әйттеләр:
– Безгә әйт, Син Мәсихме?
Ул аларга әйтте:
– Әгәр сезгә әйтсәм, сез ышанмассыз. 68 Ә инде сездән
сорасам, Миңа җавап бирмәссез. 69 Бу вакыттан башлап Адәм Улы
Кодрәт Иясенең уң ягында утырыр.
70 Шунда барысы:
– Алайса Син Аллаһы Улы буласың инде? – диделәр.

Ул аларга:
– Сез үзегез Мине Ул дип әйтәсез, – дип җавап бирде.
71 Алар:
– Безгә тагын нинди шаһитлек кирәк? Без инде моны Аның Үз авызыннан ишеттек, – диделәр.

*Гайсә Пилат алдында*

23 1 Киңәшмәдәгеләрнең барысы да, торып, Гайсәне Пилат янына алып килделәр.
2 – Без бу Кешене халкыбызны аздыручы дип таптык. Ул Үзен Мәсих, Патша дип атый һәм кайсарга салым түләүне тыя, – дип гаепли башладылар.
3 Пилат Аннан:
– Син яһүдләр Патшасымы? – дип сорады.
Ул аңа:
– Моны син үзең әйтәсең, – диде.
4 Пилат исә баш руханиларга һәм халык төркеменә:
– Мин бу Кешене гаепләрлек бер сәбәп тә күрмим, – диде.
5 Әмма алар:
– Ул Гәлиләядән башлады, хәзер монда да килде. Бөтен Яһүдиядә өйрәтеп, Ул халыкны котырта, – дип, үз сүзләрендә нык тордылар.

*Гайсә Һируд алдында*

6 Пилат исә Гәлиләя дигәннәрен ишетеп:
– Ул гәлиләялеме? – дип сорады.
7 Гайсәнең Һируд патша идарә иткән өлкәдән икәнен белгәч,
ул Аны Һируд янына җибәрде. Ул көннәрдә Һируд үзе дә
Иерусалимда иде. 8 Һируд исә, Гайсәне күреп, бик шатланды,
чөнки ул Аның хакында ишеткәнлектән, күптәннән Аны күрәсе
килеп йөргән һәм Аңардан нинди дә булса могҗиза күрермен
дип өметләнгән иде. 9 Һируд Аңа күп сораулар бирде; ләкин
Гайсә аңа бер генә җавап та кайтармады. 10 Шунда булган баш
руханилар һәм канунчылар исә Аны бик каты гаепләделәр.
11 Әмма Һируд үзенең гаскәриләре белән Гайсәне мәсхәрәләп
һәм Аңардан көлеп, Аны купшы киемнәргә киендереп, кире
Пилат янына җибәрде. 12 Шул көнне Пилат белән Һируд дуслашып киттеләр. Моңа хәтле алар бер-берсенә дошман иделәр.

*Гайсәнең үлемгә хөкем ителүе*

13 Пилат баш руханиларны, башлыкларны һәм халыкны җыеп,
14 аларга әйтте:
– Сез миңа бу Кешене халыкны котырта дип алып килдегез; менә мин сезнең алда аннан сорау алдым, ләкин бу Кешене

сез әйткән гаепләрнең берсендә дә гаепле дип тапмадым.
[15] Һируд та гаепле дип тапмады; чөнки ул Аны кире безгә җибәрде. Менә шулай, Ул үлем җәзасы бирерлек һичнәрсә дә эшләмәгән. [16] Шулай булгач, мин Аны, җәзалап, иреккә җибәрәм. [ [17] ]*

[18] Әмма барысы бер тавыштан:

– Аңа үлем! Ә безгә Барабны азат ит! – дип кычкыра башладылар.

[19] Бараб шәһәрдә чуалыш китереп чыгаруы һәм кеше үтерүе өчен төрмәгә утыртылган кеше иде. [20] Пилат, Гайсәне иреккә җибәрергә теләп, тагын аларга мөрәҗәгать итте. [21] Әмма алар:

– Аны хачка кадакла, кадакла! – дип кычкыра бирделәр.

[22] Ул өченче мәртәбә аларга әйтте:

– Ул нинди явызлык эшләгән соң? Мин Аңарда үлем җәзасы бирерлек һичнинди гаеп тапмадым; шулай итеп, мин Аны, җәзалап, иреккә җибәрәм.

[23] Ләкин халык төркеме тагын да катырак тавыш белән Аның хачка кадаклануын таләп иттеләр; һәм ахыр чиктә үз дигәннәренә ирештеләр. [24] Пилат, алар теләгәнчә булсын, дигән карар кылды. [25] Чуалыш китереп чыгарган һәм кеше үтергән өчен төрмәгә утыртылганны, алар сораганча, азат итте; ә инде Гайсәне аларның ихтыярына тапшырды.

*Гайсәне хачка кадаклау*

[26] Гаскәриләр Аны алып барганда, кырдан кайтып килүче күриниле Шимун атлы бер кешене туктаттылар да, хачны аның җилкәсенә салып, Гайсә артыннан алып барырга куштылар.
[27] Артыннан күп санлы халык төркеме, шулай ук, Аны кызганып, үкереп елый-елый, хатын-кызлар да барды. [28] Гайсә исә борылып аларга әйтте:

– Әй, Иерусалим хатын-кызлары! Минем өчен еламагыз, бәлки үзегез һәм балаларыгыз өчен елагыз. [29] Чөнки килер көннәр һәм: «Кысыр хатыннар, әле бала тудырмаган карыннар һәм бала имезмәгән имчәкләр бәхетле!» – дип әйтерләр. [30] Шул көннәрдә кешеләр тауларга: «Безнең өскә авыгыз!», калкулыкларга: «Безне каплагыз!» – дип әйтерләр. [31] Чөнки яшелләнеп үсеп утырган агач белән моны эшлиләр икән, корыган агач белән нәрсә булыр соң?

[32] Гайсә белән бергә ике җинаятьчене дә җәзалап үтерергә алып бардылар. [33] Баш сөяге дип аталган урынга җиткәч, Аны

---

* 23:17 Кайбер кульязмаларда 17 нче аять тә бар: «Пилатка бәйрәм уңае белән бер тоткынны азат итәргә кирәк иде».

һәм шул җинаятьчеләрне дә – берсен Аның уң ягына, ә икен-
чесен сул ягына – хачка кадакладылар. [ 34 Гайсә исә әйтте:
– Йа, Ата! Аларны кичер, чөнки алар нәрсә эшләүләрен
белмиләр.]*
Гаскәриләр исә, жирәбә салышып, Аның киемнәрен бүлеш-
теләр. 35 Халык моны карап торды. Башлыклар да Гайсәдән
мыскыллап көлделәр һәм:
– Ул башкаларны коткарды! Әгәр Ул Аллаһы тарафыннан
сайланган Мәсих булса, Үзен-үзе коткарсын! – диделәр.
36 Гаскәриләр дә, Аңа якын килеп һәм шәраб серкәсе тәкъдим
итеп, Аны мыскыл иттеләр 37 һәм:
– Син яһүдләр Патшасы булсаң, Үзеңне-үзең коткар! – ди-
деләр.
38 Аның баш өстенә хачка: «Бу – яһүдләр Патшасы», – дип
язылган язу беркетелгән иде.
39 Хачка асып куелган җинаятьчеләрнең берсе, Аны хурлап:
– Син Мәсих түгелме соң? Шулай булса, Үзеңне дә, безне
дә коткар! – диде.
40 Икенчесе исә:
– Син үзең Аның кебек үк хөкем ителгән, әллә син Аллаһы-
дан да курыкмыйсыңмы? – дип, тегене тыйды. 41 – Безне гадел
хөкем иттеләр, чөнки кылган эшләребезгә карата тиешлесен
алдык; ә Ул һичбер начарлык эшләмәде, – диде. 42 Һәм Гайсәгә:
– Гайсә, Үзеңнең Патшалыгыңа кергәч, мине искә ал, – диде.
43 Гайсә аңа:
– Хак сүз әйтәм: бүген үк син Минем белән бергә җәннәттә
булачаксың.

*Гайсәнең үлеме*

44-45 Инде көн урталары иде. Шул вакыт кояш яктыртмый
башлады, бөтен җир өстен караңгылык каплап алды, һәм көн-
дезге өчкә кадәр шулай булды. Ә Аллаһы Йортындагы пәрдә
урталай ертылды. 46 Гайсә каты тавыш белән:
– Ата! Мин рухымны Синең кулыңа тапшырам, – дип кыч-
кырды һәм шуны әйткәннән соң җан бирде.
47 Бу вакыйганы күреп торган йөзбашы Аллаһыны данлап:
– Чыннан да бу Кеше тәкъва булган икән, – диде.
48 Моны карарга җыелган бөтен кеше, булган вакыйганы күр-
гәннән соң, күкрәкләренә суга-суга, кайгырып өйләренә кайтып
киттеләр. 49 Ә Гайсәнең бар дуслары, шулай ук Аңа ияреп Гәли-
ләядән килгән хатыннар да бу хәлне ерактан карап тордылар.

---

* 23:34 Кайбер кульязмаларда җәяләр эчендәге өлеш тә бар.

*Гайсәне кабергә салу*

[50-51] Югары киңәшмәдә Яһүдия җирендәге Ариматай шәһәреннән Йосыф исемле бер кеше бар иде. Ул, Киңәшмә әгъзасы булса да, анда чыгарылган карарны һәм бу эшне хупламады. Ул игелекле һәм тәкъва булып, Аллаһы Патшалыгы килүен көтә
иде. [52] Йосыф, Пилат янына барып, Гайсәнең гәүдәсен бирүен
сорады. [53] Ул, гәүдәне хачтан алды һәм, җитен тукымага төреп, таш тауны тишеп ясалган бер кабергә салды. Моңа кадәр анда
әле һичкем дә салынмаган була. [54] Бу – бәйрәмгә әзерләнә торган җомга көн иде, инде тиздән шимбә көн башланасы иде.
[55] Гайсә белән Гәлиләядән килгән хатыннар Йосыф артыннан бардылар, каберне һәм Гайсәнең гәүдәсен ничек итеп кабергә
куйганнарын карап тордылар. [56] Шуннан соң алар, өйләренә кайтып, Гайсәнең гәүдәсенә сөртү өчен бәлзәм һәм хуш исле майлар әзерләделәр; һәм Муса канунында кушылганча, шимбә көнне ял иттеләр.

*Гайсәнең терелеп торуы*

**24** [1] Атнаның беренче көнендә хатын-кызлар, алдан әзерләнгән хуш исле майларны алып, иртән-иртүк кабер
янына киттеләр [2] һәм, кабер янына килгәч, ташның
кабер алдыннан читкә аударылганын күрделәр. [3] Ә эчкә кергәч,
Раббы Гайсәнең гәүдәсен тапмадылар. [4] Алар бу хәлгә аптырашып торган вакытта, кинәт алар алдына ялтырап торган киемдә
ике ир кеше пәйда булды. [5] Хатыннар куркып түбән карадылар,
әлеге кешеләр аларга әйттеләр:

– Нигә сез Терене үлеләр арасыннан эзлисез? [6] Ул монда юк:
Ул терелтеп торгызылды. Гәлиләядә чагында Аның сезгә әйткән сүзләрен исегезгә төшерегез: [7] «Адәм Улы гөнаһлылар кулына тотып бирелергә, хачка кадакланырга һәм өченче көндә терелеп торырга тиеш», – дигән иде Ул сезгә.

[8] Шунда Гайсә әйткән сүзләр аларның исләренә төште.
[9] Һәм кабер яныннан китеп, бу хәл хакында алар унбер шәкерткә һәм калганнарга да хәбәр иттеләр. [10] Рәсүлләргә бу хакта Магдалалы Мәрьям, Йохана, Ягъкубның анасы Мәрьям, һәм шулай ук алар белән булган башка хатыннар да сөйләде. [11] Әмма хатын-кызларның бу сүзләре рәсүлләргә буш сүзләр булып тоелды һәм алар ышанмадылар. [12] Ләкин Петер, торып, кабер янына йөгерде һәм иелеп кабер ишеге аша карагач, анда яткан кәфенлекне генә күрде һәм, бу хәлгә таң калып, өенә кайтты.

*Эммаус юлында*

13 Шул ук көнне Гайсәнең ике шәкерте Иерусалимнан унбер
чакрым чамасы ераклыктагы Эммаус дип аталган авылга ба-
рырга чыкты. 14 Алар булып узганнарның барысы хакында да
сөйләшеп бардылар. 15 Алар сөйләшеп, фикер алышып барган
чакта, Гайсә Үзе алар янына килеп, алар белән бергә бара баш-
лады. 16 Әмма шәкертләрнең күзләре каплап торылган кебек
булганга күрә, алар Аны танымадылар. 17 Ул исә алардан болай
дип сорады:

– Сез нәрсә хакында фикер йөртеп барасыз?

Алар кайгыдан туктап калдылар. 18 Шәкертләрнең берсе,
Клеопас атлысы Аңа:

– Иерусалимга килгәннәр арасында бу көннәрдә анда булган
хәлләр турында Син генә белмисеңме әллә? – диде.

19 Ул алардан:

– Нинди хәлләр турында? – дип сорады.

Шәкертләр Аңа әйттеләр:

– Насаралы Гайсә турында; Ул Аллаһы алдында да, бөтен ха-
лык алдында да, эштә дә, сүздә дә кодрәтле Пәйгамбәр иде.
20 Безнең баш руханилар һәм башлыклар Аны үлемгә хөкем итү
өчен тотып бирделәр һәм хачка кадакладылар. 21 Ә без Исраил-
не азат итәргә тиеш Кеше – Ул булыр дип өметләнгән идек,
әмма әле болар гына түгел. Ул вакыйгадан соң инде ике көн
үтте. 22 Шуның өстенә арабыздагы кайбер хатыннар да безне
таң калдырды; алар иртүк кабер янына барганнар, 23 әмма Аның
гәүдәсен тапмаганнар. Шулай ук фәрештәләр пәйда булып,
аларга: «Ул тере», – дип әйткәннәрен алар кайтып сөйләделәр.
24 Аннары арабызда булган кайбер кешеләр кабер янына барды-
лар һәм бар нәрсәнең хатыннар сөйләгәнчә булуын күрделәр;
ләкин Гайсәнең Үзен күрмәделәр.

25 Шунда Гайсә аларга әйтте:

– Әй сез, аңсызлар, пәйгамбәрләрнең әйткән барлык сүзлә-
ренә акрын инанучылар! 26 Мәсих Үзенең шөһрәтенә ирешер
алдыннан шулай газап чигәргә тиеш түгел идемени?

27 Ул Муса язмаларыннан башлап, барлык пәйгамбәрләрнең
язмаларына кадәр бөтен Изге язмадагы Үзе хакында әйтелгән
урыннарны аңлатып бирде. 28 Алар үзләре барасы авылга якын-
лаштылар; ә Гайсә Үз юлын тагын да дәвам итәргә теләгән
кебек итте. 29 Әмма алар:

– Инде кич якынлашып килә, безнең белән кал, – дип Аны
күндерделәр, һәм Ул алар белән өйгә кереп калды. 30 Ул, алар бе-
лән бергә өстәл артына ашарга утыргач, икмәк алып шөкрана

кылганнан соң, аны сындыргалап шәкертләргә бирде. 31 Шул-
чак аларның күзләре ачылып китте һәм шәкертләр Гайсәне
танып алдылар; әмма Ул аларга күренмәс булды. 32 Алар
бер-берсенә:

– Ул безгә юлда сөйләгәндә һәм Изге язманың мәгънәсен аңлатканда, безнең күңелләребез күтәрелеп китте түгелме соң? – диделәр.

33 Һәм шунда ук торып, Иерусалимга кире кайттылар, анда
унбер шәкертне һәм алар белән бергә булган башкаларны җые-
лышып торган хәлдә күрделәр. 34 Аларның барысы да:

– Раббы чыннан да үледән терелеп торды һәм Шимунга күренде, – дип сөйләделәр.

35 Бу кешеләр дә юлда булган вакыйганы һәм икмәк сындырган чакта Гайсәне ничек танып алулары хакында сөйләп бирделәр.

*Гайсә шәкертләренә күренә*

36 Алар бу хакта сөйләгәндә Гайсә Үзе кинәт аларның уртасында пәйда булып:

– Иминлек сезгә, – диде.

37 Алар куркудан катып калдылар, бу өрәк булса кирәк дип
уйладылар. 38 Ләкин Ул аларга әйтте:

– Нигә каушап калдыгыз? Нигә күңелегезгә шундый шик
төшә? 39 Минем кулларыма һәм аякларыма карагыз, бу – Мин
Үзем. Кулларыгызны Миңа тидерегез һәм карагыз; өрәкнең тәне һәм сөяге булмый, ә күргәнегезчә, Миндә бар.

40 Моны әйткәннән соң, Ул аларга кулларын һәм аякларын
күрсәтте. 41 Алар шатлыкларыннан һәм таң калудан һаман да
ышанмый торганда, Ул алардан:

– Сезнең монда ашарга берәр нәрсәгез бармы? – дип сорады.

42 Алар Аңа бер кисәк пешкән балык бирделәр. 43 Ул аны
алып, алар алдында ашады.

44 Аннан соң Гайсә аларга әйтте:

– Мин сезнең белән бергә чакта, нәкъ менә боларны сөйләдем: Муса канунында, пәйгамбәрләрнең китапларында һәм Зәбурда Минем хакта язылганнарның барысы да тормышка ашырылырга тиеш.

45 Аннары Ул аларга Изге язманы аңларга ярдәм итте. 46 Һәм
аларга:

– Изге язмада болай дип язылган: Мәсих газап чигәргә,
өченче көндә үледән терелеп торырга, 47 һәм гөнаһлары кичерелсен өчен тәүбә итү, Иерусалимнан башлап, бар халыкларга

Аның исеме нигезендә игълан ителергә тиеш, – диде. – [48] Сез
моңа шаһитләр. [49] Мин Атам вәгъдә иткәнне сезгә җибәрермен;
сез исә күкләрдән үзегезгә кодрәт бирелгәнгә кадәр Иерусалим
шәһәрендә калыгыз.

*Гайсә күккә аша*

[50] Шуннан соң Гайсә, шәкертләрен шәһәрдән алып чыгып,
Бәйтәниягә чаклы алар белән барды һәм, кулларын күтәреп,
анда аларга фатихасын бирде. [51] Ул аларга фатиха биргәндә,
алардан аерыла барып, күккә алынды. [52] Шәкертләр сәҗдә
кылып, Аңа табындылар һәм зур шатлык белән Иерусалимга
кайттылар. [53] Алар Аллаһыны данлап, һәрвакыт Аллаһы Йорт-
тында булдылар.

# ЯХЪЯ БӘЯН ИТКӘН ЯХШЫ ХӘБӘР

*Сүз Кеше булды*

**1** 1 Иң башта Сүз булган, Сүз Аллаһы белән булган, һәм Сүз
Аллаһы булган. 2 Сүз иң башта ук Аллаһы белән булган.
3 Бар нәрсә Сүз аша яратылган, һәм яратылган һәр нәрсә
Аннан башка яратылмаган. 4 Аңарда тормыш булган, һәм шул
тормыш кешеләргә яктылык биргән. 5 Яктылык караңгылыкта
яктыра, караңгылык исә аны сүндерә алмаган.

6 Аллаһы тарафыннан җибәрелгән Яхъя исемле бер кеше бар
иде. 7 Яхъя шаһитлек бирү өчен килде. Ул, барысы да иман ки-
терсеннәр дип, Яктылык хакында шаһитлек бирергә килде. 8 Ул
үзе Яктылык түгел, ләкин Яктылык хакында шаһитлек бирү
өчен җибәрелгән иде.

9 Дөньяга килүче һәр кешене яктыртучы Яктылык – чын
Яктылык иде. 10 Ул дөньяда булды, ләкин дөнья, Аның аша
яратылган булуга карамастан, Аны танымады. 11 Ул Үз кешелә-
ре янына килде, әмма үзенекеләр Аны кабул итмәде. 12 Ә Аны
кабул итеп, Аңа иман китерүчеләргә Ул Аллаһы балалары бу-
лырга хокук бирде. 13 Алар каннан да, тән нәфесеннән дә, ир
нәфесеннән дә түгел, бәлки Аллаһыдан тудылар.

14 Сүз Кеше булды, мәрхәмәт һәм хакыйкать белән тулы бу-
лып, безнең арабызда яшәде, һәм без Аның данын, Атаның
бердәнбер Улына биргән данын күрдек.

15 Яхъя пәйгамбәр Аның хакында шаһитлек биреп:

– «Миннән соңрак Килүче миннән алга чыкты, чөнки Ул
миннән элек бар иде» дип сөйләгәнем менә Шул инде, – дип
кычкырып әйтте.

16 Аның тулылыгыннан без һәммәбез мәрхәмәт өстенә мәр-
хәмәт алдык, 17 чөнки канун Муса аркылы бирелгән, мәрхә-
мәт һәм хакыйкать исә Гайсә Мәсих аша килде. 18 Аллаһыны
беркем, беркайчан күрмәгән. Аны Ата өчен иң якын булган
бердәнбер Улы ачып бирде.

*Яхъя пәйгамбәрнең шаһитлеге*

19 Иерусалим яһүдләре руханиларны һәм левилеләрне* Яхъя
пәйгамбәрдән: «Син кем?» – дип сорар өчен җибәргәч, 20 ул,
һич тә яшермичә, шаһитлек биреп:

– Мин Мәсих түгел, – дип икърар итте.

21-22 Алар аннан:

– Кем соң син, Ильясмы? – дип сорадылар.

– Юк, – диде ул.

– Вәгъдә ителгән пәйгамбәрме?

– Юк, – дип җавап бирде Яхъя.

– Алайса, кем соң син? Безне монда җибәрүчеләргә җавап бирү өчен үзең хакында безгә нәрсә әйтерсең?

23 Яхъя, Ишагыйя пәйгамбәр әйткән сүзләрне кулланып:

– Мин – «Раббыга юлны турайтыгыз», – дип чүлдә кычкыручының тавышы, – диде.

24 Җибәрелгәннәр фарисейләрдән** иде. 25 Алар Яхъядан:

– Син Мәсих тә, Ильяс та, вәгъдә ителгән пәйгамбәр дә булмагач, ни өчен соң суга чумдыру*** йоласын башкарасың? – дип сорадылар.

26 Яхъя аларга:

– Мин суга чумдырам, әмма арагызда сез белмәгән Берәү
тора. 27 Минем артымнан Килүче нәкъ менә Ул инде, ә мин
Аның аяк киеменең каешын чишәргә дә лаеклы түгелмен, – дип
җавап бирде.

28 Бу вакыйгалар Яхъя пәйгамбәр чумдыра торган урында –
Үрдүн елгасы аръягындагы Бәйтәниядә булды. 29 Икенче көнне
Яхъя пәйгамбәр, каршына килүче Гайсәне күреп, әйтте:

– Менә дөньяның гөнаһын Үз өстенә алучы Аллаһы Бәрәне.
30 «Миннән соңрак килүче бер Зат миннән алга чыкты, чөнки
Ул миннән элек бар иде», – дип сөйләгәнем Ул – Үзе. 31 Мин
Аны белми идем, ләкин, Ул Исраил халкына билгеле булсын
өчен, суга чумдырырга килдем.

32 Яхъя пәйгамбәр шаһитлек биреп, өстәп әйтте:

– Мин Рухның күгәрчен рәвешендә Гайсәгә иңүен һәм
Аның өстендә калуын күрдем. 33 Мин Аны танымас идем, әмма

---

* 1:19 *Леви* – Ягъкуб улларының берсе. Аллаһы әмере буенча, Леви токымыннан булган кешеләр генә Аллаһы Йортында рухани ярдәмчесе булып хезмәт иткәннәр. Алар левилеләр дип аталганнар.

** 1:24 *Фарисейләр* – борынгы яһүдләр арасындагы дини төркем.

*** 1:25 *Суга чумдырылу* – тәүбә итүне һәм үзеңне Аллаһы Тәгаләгә багышлауны күрсәтә торган йола.

мине суга чумдыру өчен Җибәрүче: «Кем өстенә Рух иңүен һәм
Аның өстендә калуын күрсәң, Изге Рухка чумдыручы Шул бу-
лыр», – дигән иде. 34 Мин моны күрдем һәм шаһитлек бирәм:
Ул – Аллаһы Улы.

*Гайсәнең беренче шәкертләре*

35 Икенче көнне Яхъя пәйгамбәр ике шәкерте белән шул ук
урында торганда, 36 узып баручы Гайсәне күреп:
– Менә, карагыз, Аллаһы Бәрәне, – диде.
37 Ике шәкерт, аның бу сүзләрен ишеткәч, Гайсә артыннан
киттеләр. 38 Гайсә исә, артына әйләнеп карап һәм аларның
арттан килүен күреп:
– Сезгә нәрсә кирәк? – диде.
Алар Аннан:
– Рабби, Син кайда яшисең? – дип сорадылар. (Рабби –
Остаз дигән мәгънәдә.)
39 Гайсә аларга:
– Әйдәгез Минем белән, үзегез күрерсез, – диде.
Сәгать дүртләр чамасы* иде. Алар, Гайсә белән барып, Аның
кайда яшәгәнен күрделәр һәм ул көнне Аның янында калдылар.
40 Яхъя пәйгамбәрнең Гайсә турында әйткән сүзләрен ише-
теп, Аның артыннан киткән икенең берсе Шимун Петернең
энесе Әндри иде. 41 Ул, иң элек абыйсы Шимунны табып, аңа:
– Без Мәсихне очраттык, – диде һәм Шимунны Гайсә янына
алып килде. (Мәсих – Май сөртелгән Зат** дигән мәгънәдә.)
42 Гайсә исә, Шимунга карап:
– Син, Яхъя улы Шимун: син Кифас дип аталырсың, – диде.
(Кифас һәм Петер*** дигән исемнәр – кыя дигән мәгънәдә.)
43-44 Икенче көнне Гайсә Гәлиләягә барырга булды. Әндри
белән Петер кебек үк, Бәйтсайда шәһәреннән булган Филипне
очратты һәм аңа:
– Минем артымнан бар, – диде.

---

* 1:39 *Сәгать дүртләр чамасы* – грекча сүзгә-сүз «унынчы сәгать чамасы». Инҗил язылган заманда вакыт хисабы башкача була: көндезге вакыт иртәнге сәгать алтыдан кичке сәгать алтыга кадәр дәвам итә. Шулай итеп, мәсәлән, «беренче сәгать» безнең вакыт буенча иртәнге алтыдан җидегә кадәрге вакытка туры килә.

** 1:41 *Мәсих* – Аллаһы тарафыннан дөньяны коткару өчен сайланып май сөртелгән Зат. Руханилар, Аллаһы кушуы буенча, Исраил патшасын билгеләгәндә сайланган кешенең башына зәйтүн мае сөртә торган булганнар.

*** 1:42 *Кифас һәм Петер* – Арамей телендә «Кифас», грек телендә «Петер» дигән исемнәр – «кыя» дигән мәгънәдә.

45 Филип, Натанаилне табып:
– Без насаралы Йосыф улы Гайсәне очраттык. Аның хакында Муса канунда язган, шулай ук пәйгамбәрләр дә язганнар, – диде.
46 Ләкин Натанаил аңа:
– Насарадан нинди дә булса яхшы нәрсә чыгармы икән? – дип җавап бирде.
– Барыйк, үзең күрерсең, – диде Филип.
47 Гайсә, Үзенә таба якынлашып килүче Натанаилне күреп, аның хакында:
– Менә чын исраилле, аңарда һичнинди мәкер юк, – диде.
48 Натанаил Аннан:
– Син мине каян беләсең? – дип сорады.
– Мин, Филип сине чакырганчы ук, инҗир агачы төбендә күрдем, – дип җавап бирде Гайсә.
49 – Остаз! Син – Аллаһы Улы! Син – Исраил Патшасы! – диде Аңа Натанаил.
50 Гайсә:
– Син Минем: «Мин сине инҗир агачы төбендә күрдем», – дигәнемә күрә генә ышанасыңмы? Моннан да зуррак нәрсәләр
күрерсең әле, – дип җавап бирде һәм, дәвам итеп, – 
51 Сезгә
хак сүз әйтәм: күкләр ачылуын һәм Аллаһы фәрештәләренең Адәм Улы янына күтәрелеп иңүләрен күрерсез, – диде.

*Гайсәнең суны шәрабка әйләндерүе*

2
1 Өченче көнне Гәлиләя өлкәсенең Кәна шәһәрендә туй булды. Туйга Гайсәнең анасы да килде.
2 Гайсә дә Үзенең шәкертләре белән шул туйга чакырылган иде.
3 Шәраб җитмәгәч, Гайсәнең анасы Аңа:
– Аларның шәраблары беткән, – диде.
4 – Син ни өчен моны Миңа әйтәсең? Минем әле вакытым килеп җитмәде, – диде Гайсә аңа.
5 Анасы хезмәтчеләргә:
– Ул сезгә нәрсә әйтсә, шуны эшләгез, – диде.
6 Анда, яһүдләрнең йоласы буенча, пакьләнү өчен куелган ике яки өч үлчәү* су сыйдырышлы алты таш чүлмәк бар иде.
7 Гайсә хезмәтчеләргә:
– Чүлмәкләрне су белән тутырыгыз, – дип әйткәч, алар чүлмәкләрне мөлдерәмә итеп тутырдылар.
8 Шуннан соң Гайсә аларга:
– Инде чумырып алыгыз да туй башлыгына илтеп бирегез, – диде.

---

* 2:6 *Ике яки өч үлчәү* – 80–120 литр чамасы.

Алар илтеп бирделәр. [9] Туй башлыгы шәрабның кайдан
икәнен белми иде. Бу турыда суны чумырып алган хезмәтчеләр
генә белә иде. Туй башлыгы, шәрабка әйләнгән суны татып
карагач, кияүне үз янына чакырып алып:
[10] – Башта һәркем яхшы шәраб бирә, ә инде җитәрлек
эчелгәч, начаррагын китерә; ә син яхшы шәрабны иң соңга
калдыргансың, – диде.
[11] Шулай итеп, Гәлиләянең Кәна шәһәрендә могҗизалы га-
ләмәтләрен башлап җибәреп, Гайсә Үзенең данын күрсәтте,
һәм шәкертләре Аңа иман китерделәр.
[12] Шуннан соң Ул, анасы, энеләре һәм шәкертләре белән
бергә Кәпәрнаум шәһәренә килеп, берничә көнгә анда калды.

*Гайсәнең Аллаһы Йортына мәхәббәте*

[13] Яһүдләрнең Коткарылу бәйрәме* якынлашкач, Гайсә
Иерусалимга килде. [14] Ул андагы Аллаһы Йортында үгез, сарык,
күгәрчен сатучыларны һәм акча алмаштырып утыручыларны
күргәч, [15] баудан чыбыркы үреп, барысын да – сарыкларны да,
үгезләрне дә – Аллаһы Йортыннан куып чыгарды. Акча ал-
маштыручыларның өстәлләрен аударып ташлап, акчаларын
чәчеп җибәрде. [16] Күгәрчен сатучыларга:
– Боларны моннан алып китегез! Минем Атамның йортын
базарга әйләндермәгез! – диде.
[17] Аның шәкертләре: «Мине Синең йортыңа булган мәхәббәт
газаплый», – дип язылган сүзләрне исләренә төшерделәр.
[18] Шуннан, яһүдләр Гайсәдән:
– Болай эшләргә хокукың барлыгын безгә нинди галәмәт
белән исбат итә аласың? – дип сорадылар.
[19] Гайсә аларга:
– Бу Аллаһы Йортын җимереп ташлагыз, Мин аны өч көндә
яңадан торгызачакмын, – диде.
[20] Яһүдләр Аңа әйттеләр:
– Бу Аллаһы Йорты кырык алты ел төзелде, ә Син аны өч
көндә генә торгыза алырсыңмы?
[21] Әмма Гайсә, Аллаһы Йорты дип, Үзенең тәне хакында
әйткән иде. [22] Гайсә үледән терелтелгәч, шәкертләре Аның бу
турыда әйткәнен исләренә төшерделәр һәм, Изге язмага да,
Гайсә әйткән сүзләргә дә ышандылар.
[23] Коткарылу бәйрәме көннәрендә Аның Иерусалимда күр-
сәткән могҗизалы галәмәтләрен күреп, күпләр Гайсәгә иман

* 2:13 *Коткарылу бәйрәме* – Яһүдләрнең бу бәйрәмендә Мисыр коллы-
гыннан котылу искә алына. Грек телендә бу бәйрәм Пасха дип атала.

китерделәр. 24-25 Әмма бөтен кешеләрне Үзе белгәнгә, алар турында кемнең дә булса сөйләп бирүенә Гайсәнең ихтыяҗы юк иде, чөнки кешеләрнең күңелләрендә нәрсә барын Ул белде һәм шуңа күрә аларга ышаныч багламады.

### *Гайсә һәм Никәдим*

3 1 Яһүд башлыкларының фарисейләрдән булган Никәдим атлысы 2 төнлә Гайсә янына килеп:
– Остаз! Синең Аллаһыдан килгән Остаз икәнеңне беләбез; чөнки, Аллаһы аның белән булмаса, Син күрсәткән могҗизалы галәмәтләрне беркем дә эшли алмас иде, – диде.
3 – Сиңа хак сүз әйтәм: беркем дә, яңадан тумаса, Аллаһы Патшалыгын күрә алмас, – диде аңа Гайсә.
4 Никәдим Аннан:
– Кеше картайгач ничек итеп яңадан туа алсын? Ул, анасы карынына кереп, икенче тапкыр туа алыр микән? – дип сорады.
5 Гайсә җавабында аңа әйтте:
– Сиңа хак сүз әйтәм: әгәр кеше судан һәм Рухтан тумаса, ул
Аллаһы Патшалыгына керә алмас. 6 Тәннән туган – тән, Рухтан
туган – рух була. 7 Минем сиңа: «Сез яңадан туарга тиешсез», –
дип әйтүемә гаҗәпләнмә. 8 Җил кайда теләсә, шунда исә, аның тавышын ишетәсең, ләкин кайдан килеп кая китүен белмисең: Рухтан туган һәркем белән нәкъ менә шулай була*.
9 Никәдим Аннан:
– Ничек алай була алсын? – дип сорады.
10 – Син, Исраил мөгаллиме була торып, шуны белмисеңме? –
диде аңа Гайсә. – 11 Сиңа хак сүз әйтәм: без нәрсә белсәк, шуны сөйлибез; нәрсә күрсәк, шуңа шаһитлек бирәбез; ә сез безнең шаһитлегебезне кабул итмисез. 12 Сез җирдәге хәлләр
турында сөйләгәнгә ышанмыйсыз икән, күктәгеләре хакында
сөйләсәм, ничек ышанырсыз? 13 Күктән иңгән Адәм Улыннан
башка берәүнең дә күккә күтәрелгәне юк.
14-15 Адәм Улына иман китерүче һәр кеше мәңгелек тормыш
алсын өчен, Муса чүлдә еланны күтәргән кебек**, Адәм Улы да
күтәрелергә тиеш. 16 Чөнки Аллаһы дөньяны шулкадәр яратты
ки, Улына иман китерүче беркем һәлак булмасын өчен, бәлки
мәңгелек тормыш алсын өчен, Үзенең бердәнбер Улын бирде.

---

* 3:8 Грек телендәге «пнеума» дигән сүз «җил» һәм «Рух» дигән мәгънәләрне аңлата.

** 3:14-15 Бу урында Мусаның чүлдә Аллаһы кушуы буенча бакырдан ясалган еланны, колгага беркетеп куеп, югарыга күтәрүе турында язылa. (Тәүрат, «Саннар» китабы 21:9.)

17 Аллаһы Үзенең Улын дөньяны хөкем итү өчен түгел, бәлки
дөнья Аның аша котылсын өчен, дөньяга җибәрде. 18 Улына
иман китерүче хөкем ителми, ә иман китермәүче инде хөкем
ителде, чөнки ул Аллаһының бердәнбер Улына иман китер-
мәде. 19 Хөкем исә шуннан гыйбарәт: дөньяга яктылык килде,
әмма кешеләр, эшләре яман булганга, яктылык урынына караң-
гылыкны яраттылар. 20 Явызлык эшләүче һәркем яктылыкны
нәфрәт итә һәм, үзенең эшләре ачык күренмәсен дип, якты-
лыкка килми. 21 Ә дөреслек буенча эш итүче, гамәлләренең
Аллаһы аркылы эшләнгәнлеге ачык күренсен өчен, яктылык-
ка килә.

*Яхъя пәйгамбәрнең Гайсә турындагы шаһитлеге*

22 Шуннан соң Гайсә шәкертләре белән Яһүдия җиренә
килде һәм алар белән бергә шунда калып, халыкны суга чум-
дырды. 23 Яхъя да Салим янындагы күп сулы Айнунда шунда
килгән кешеләрне суга чумдыра иде. 24 Ул вакытта әле Яхъя
төрмәгә утыртылмаган була.

25 Яхъя пәйгамбәрнең шәкертләре белән бер яһүд кешесе
арасында пакьләнү йоласы турында бәхәс чыккач, 26 алар, Яхъя
пәйгамбәр янына килеп:

– Остаз! Менә Үрдүннең аръягында синең белән булган һәм
Аның турында син шаһитлек биргән Кеше халыкны суга чум-
дыра, һәм барысы да Аның янына баралар, – диделәр.

27 Яхъя пәйгамбәр җавап итеп әйтте:

– Күктән бирелмәгән булса, кеше үзенә бернәрсә дә кабул
итә алмый.

28 Сез – «Мин Мәсих түгел, әмма Аның алдыннан җибәрел-
дем», – дип әйткәнемне ишетүче шаһитләр. 29 Кияү егетенең
кәләше була, ә кияүнең янында тыңлап торучы дусты, аның
тавышын ишетеп, шатланып куана. Минем куанычым да шу-
лай тулы. 30 Ул үсәргә, мин кечерәергә тиеш.

31 Югарыдан Килүче һәркемнән өстенрәк; ә җирдән булган,
җирнеке булып, җирдәгечә сөйләр. Күктән Килүче һәркемнән
өстендер: 32 Ул Үзе күргәннәре һәм ишеткәннәре турында ша-
һитлек бирә, әмма Аның шаһитлеген берәү дә кабул итми.
33 Аның шаһитлеген кабул итүче, Аллаһының хаклыгына инану-
ын раслап, мөһер суккан була. 34 Аллаһы җибәргән Зат Аллаһы
сүзләрен сөйләр, чөнки Аллаһы Рухны үлчәмичә бирә. 35 Ата
Үзенең Улын ярата һәм бар нәрсәне Аның кулына тапшырган.
36 Улына иман китерүченең мәңгелек тормышы бар, ә Улына
иман китермәүче тормыш күрмәячәк, бәлки аның өстендә Ал-
лаһының ачуы торачак.

*Гайсә һәм Самарея хатыны*

4 [1] Фарисейләр Гайсәнең Яхъя пәйгамбәргә караганда күб-
рәк шәкертләр җыюы һәм аларны суга чумдыруы турында
ишеттеләр, [2] хәлбуки, кешеләрне Гайсә Үзе түгел, бәлки
шәкертләре суга чумдыра иде. [3] Бу турыда белгәннән соң, Гай-
сә, Яһүдияне калдырып, тагын Гәлиләягә китте. [4] Аңа Самарея
өлкәсе аша үтәргә туры килде.
[5] Самареядә, Ягъкуб үзенең улы Йосыфка биргән җир билә-
мәсенә якын урнашкан Сухар дигән шәһәрдә, [6] Ягъкуб коесы
бар иде. Юлда арыган Гайсә шул кое янына килеп утырды. Көн
урталары иде. [7-8] Шәкертләре ризык сатып алу өчен шәһәргә
киткәч, су алырга дип, бер Самарея хатыны килде. Гайсә аңа:
– Миңа эчәргә бирче, – диде.
[9] Хатын исә:
– Ничек итеп Син, яһүд була торып, миннән, Самарея хаты-
ныннан, эчәргә сорыйсың? – диде.
Ул бу сүзләрне яһүдләр самареялеләр белән аралашмаганга
күрә әйтте.
[10] Гайсә аңа болай җавап бирде:
– Аллаһының бүләген белсәң һәм синнән: «Миңа эчәргә
бирче», – дип сораучының кем икәнен белсәң, син үзең Аннан
сорар идең, һәм Ул сиңа тереклек суы бирер иде.
[11] Хатын Аңа әйтте:
– Әфәндем! Синең чумырып алырга бернәрсәң дә юк, ә
кое тирән. Син ул тереклек суын кайдан алырсың икән? [12] Бу
коены безгә Ягъкуб атабыз биргән: үзе дә, балалары да, мал-ту-
арлары да шушы коедан эчкәннәр. Син Ягъкуб атабыздан да
бөегрәкме әллә?
[13] Гайсә аңа җавап биреп әйтте:
– Бу суны эчкән һәркем янә сусар, [14] ә Мин бирәчәк суны
эчкән кеше һичкайчан сусамас. Мин биргән су аңарда мәңге-
лек тормышка ага торган чишмәгә әвереләчәк.
[15] Хатын Аңа:
– Әфәндем! Миңа шул суны бирче, аннан мин сусамас идем
һәм су алыр өчен монда килеп йөрмәс идем, – диде.
[16] – Бар, иреңне чакырып кил, – диде аңа Гайсә.
[17] Хатын исә:
– Минем ирем юк, – дип җавап бирде.
Гайсә аңа:
– Ирем юк, дип син дөресен әйттең, [18] чөнки синең биш
ирең булган, ә инде хәзергесе сиңа ир түгел. Син моны дөрес
әйттең, – диде.

[19] – Әфәндем! Күрәм, Син пәйгамбәрсең. [20] Безнең ата-баба-
ларыбыз Аллаһыга бу тауда табынганнар, ә сез яһүдләр, кешеләр
табына торган урын Иерусалимда булырга тиеш, дип әйтәсез, –
диде Аңа хатын.
[21] Гайсә әйтте:
– Ханым, ышан сүземә, вакыт җитә: Атага табынуыгыз бу
тауда да, Иерусалимда да булмаячак. [22] Сез кемгә табынуыгызны
белмисез, ә без кемгә табынуыбызны беләбез, чөнки котылу
яһүдләрдән килә. [23] Әмма вакыт җитә, һәм килеп тә җитте
инде, ул вакытта чын күңелдән табынучылар Атага рух вә ха-
кыйкать белән табынырлар, чөнки Ата шундый табынучы-
ларны эзли. [24] Аллаһы Ул – Рух, һәм Аңа табынучылар рух вә
хакыйкать белән табынырга тиешләр.
[25] Хатын Аңа:
– Мәсихнең (Май сөртелгән Затның*) киләчәген беләм. Ул,
килгәч, безгә бөтенесен аңлатып бирер, – диде.
[26] Гайсә аңа:
– Синең белән сөйләшүче Мин – ул Үзе, – диде.
[27] Шул вакыт әйләнеп кайткан шәкертләре, Аның хатын
белән сөйләшеп торуын күреп, гаҗәпләнделәр, әмма берсе дә:
«Син аңардан нәрсә сорыйсың?» – яки: «Бу хатын белән нәрсә
турында сөйләшәсең?» – дип сорамады.
[28] Хатын, су чүлмәген калдырып, шәһәргә китте һәм андагы
кешеләргә:
[29] – Барып карагыз әле, кылган эшләремнең бөтенесен әйтеп
биргән Кешене күрерсез; Ул Мәсих түгелме икән? – диде.
[30] Һәм кешеләр, шәһәрдән чыгып, Гайсә янына киттеләр.
[31] Ул арада шәкертләре Аны:
– Остаз! Ашап ал инде, – дип кыстарга керештеләр. [32] Гайсә
аларга:
– Минем сез белми торган ризыгым бар, – диде.
[33] Шәкертләре үзара:
– Әллә Аңа берәрсе ашарга китерде микән? – диештеләр.
[34] Гайсә аларга әйтте:
– Минем ризыгым – Мине Җибәрүченең ихтыярын үтәү
һәм Аның эшен төгәлләү. [35] Сез: «Тагын дүрт айдан урак өсте
җитәчәк», – дисез түгелме? Ә Мин сезгә әйтәм: әйбәтләп кара-
гыз, игеннәр агарып уракка өлгергән инде. [36] Уракчы эш хакы
ала һәм мәңгелек тормыш өчен уңыш җыя. Шуңа күрә, чәчүче
белән уручы бергә куана. [37] Шулай итеп, бу очракка: «Берсе
чәчә, ә икенчесе ура», – дигән әйтем туры килә. [38] Мин сезне

* **4:25** *Май сөртелгән Зат* – Бу хакта 1:41 дән карагыз.

үзегез үстермәгәнне урырга җибәрдем, анда башкалар эшләгән
иде, ә сез аларның хезмәт уңышын җыясыз.
39 «Кылган эшләремнең бөтенесен әйтеп бирде», – дип
шаһитлек иткән хатынның сүзен ишеткәч, әлеге шәһәрдәге
самареялеләрнең күбесе Гайсәгә иман китерде. 40 Шунлыктан,
самареялеләр Аның янына килеп, Аңардан үзләре янында ка-
луын үтенеп сорадылар һәм Ул анда ике көнгә калды. 41 Аның
сүзләрен ишетеп, тагын да күбрәк кеше Аңа иман китерде, 42 ә
теге хатынга исә:

– Без инде синең сүзләреңнән түгел, бәлки Аның сүзләрен үзебез ишетеп һәм Аның чыннан да дөньяны Коткаручы Мәсих икәнен белеп, Аңа ышанабыз, – диделәр.

*Гайсә сарай әһеленең улын савыктыра*

43 Ике көн үткәч, Гайсә бу шәһәрдән Гәлиләягә китте.
44 «Пәйгамбәрне үз илендә ихтирам итмиләр», – дип, Гайсә Үзе
үк шаһитлек биргән иде. 45 Ул Гәлиләягә килгәч, Иерусалимдагы
бәйрәмдә гәлиләялеләр дә катнашканга, бәйрәм көннәрендә
Гайсә эшләгән барлык эшләрне күргәнлектән, Аны бик теләп
кабул иттеләр.
46 Шуннан соң Гайсә яңадан теге чакта суны шәрабка әйлән-
дергән урынга – Гәлиләянең Кәна шәһәренә килде. Кәпәр-
наумда бер сарай әһеле һәм аның авыру улы бар иде. 47 Сарай
әһеле, Гайсәнең Яһүдиядән Гәлиләягә килгәнен ишетеп, Аның
янына китте. Ул Гайсәдән, үзләре йортына барып, үлем түшә-
гендә яткан улын савыктыруын ялварып сорады.
48 – Илаһи билгеләр һәм могҗизалар күрмәсәгез, сез бит
ышанмаячаксыз, – диде аңа Гайсә.
49 Сарай әһеле Аңа:

– Әфәндем! Балам үлгәнче килә күр инде, – диде.

50 Гайсә исә:

– Бар, өеңә кайт, синең улың савыкты, – диде.

Сарай әһеле, Гайсәнең сүзенә ышанып, кайтып китте. 51 Кай-
тышлый хезмәтчеләре очрап:

– Улың савыкты, – диделәр.

52 – Аңа кайсы сәгатьтә хәл керде? – дигән соравына, алар аңа:

– Кичә көндезге сәгать берләрдә бизгәк аннан китте, – дип җавап бирделәр.

53 Гайсәнең «Улың савыкты» дигән сүзләренең нәкъ шул
сәгатьтә әйтелгәнен аңлагач, әти кеше үзе дә, аның йортын-
дагыларның барысы да Гайсәгә иман китерделәр.
54 Бу Гайсәнең Яһүдиядән Гәлиләягә килгәч күрсәткән икен-
че могҗизалы галәмәте иде.

*Буа янында савыктыру*

5 [1] Шуннан соң Гайсә яһүдләрнең Иерусалимда булган бер
бәйрәменә килде. [2] Иерусалимда Сарык капкасы янында
яһүдчә Бәйтхазда* дип аталган буа баганалардан торган,
түбәле биш корылма белән уратып алынган иде. [3] Анда бик
күп авырулар: сукырлар, аксаклар һәм паралич суккан кешеләр
[су кузгалуын көтеп]** яталар иде. [ [4] Чөнки, вакыт-вакыт,
Раббының бер фәрештәсе, буага төшеп, суны болгата, һәм, су
болгану белән, аңа беренче булып кергән кеше теләсә нинди
авырудан да савыга икән.]** [5] Шунда утыз сигез ел буе авырып
ятучы бер кеше бар иде.

[6] Гайсә, ул кешене күреп һәм аның озак вакыт урын өстендә ятуын белеп, аннан:

– Савыгырга телисеңме? – дип сорады.

[7] Авыру Аңа:

– Әйе, Әфәндем. Ләкин су болганган вакытта мине буага төшерер кеше юк, мин анда барып җиткәнче, башка берәү инде төшеп өлгергән була, – дип җавап бирде.

[8] – Тор, ятагыңны ал да йөр, – диде аңа Гайсә.

[9] Кеше шунда ук терелде һәм ятагын алып йөреп китте.
Бу хәл шимбә көнне*** булганга күрә, [10] яһүдләр савыккан
кешегә:

– Бүген шимбә көн, безнең канун буенча, син ятагыңны алып йөрергә тиеш түгел, – диделәр.

[11] Ул аларга:

– Мине савыктырган Кеше миңа: «Ятагыңны ал да йөр», – дип әйтте, – диде.

[12] Аңардан:

– Сиңа: «Ятагыңны ал да йөр», – дип әйткән Кеше кем Ул? – дип сорадылар.

[13] Гайсә җыелган халык арасына кереп югалганга, савыккан кеше Аның кем икәнен белми иде.

[14] Соңрак, Гайсә аны Аллаһы Йортында очратып:

– Менә син савыктың. Сиңа тагын да начаррак булмасын өчен, инде моннан соң гөнаһ кылма, – диде.

[15] Ул кеше, яһүдләр янына барып, үзен савыктыручының Гайсә икәнен әйтте.

---

* 5:2 *Бәйтхазда* – шәфкать йорты дигән мәгънәдә.

** 5:3, 4 Кайбер кульязмаларда җәяләр эчендәге сүзләр дә бар.

*** 5:9 *Шимбә* – Муса кануны буенча, яһүдләрнең ял итү һәм гыйбадәт кылу көне.

### *Атасы нәрсә эшләсә, Улы да шуны эшләр*

16 Шушы эшне шимбә көнне эшләгәне өчен, яһүдләр Гайсәне эзәрлекли башладылар. 17 Гайсә аларга:

– Минем Атам һәрвакыт эшли, Мин дә эшлим, – дип җавап бирде.

18 Яһүдләр Аны шимбә көнен бозуы өчен генә түгел, бәлки, бигрәк тә Аллаһыны Үземнең Атам дип атап, Үзен Аллаһыга тиңләгәне өчен дә үтерергә теләделәр.

19 Гайсә аларның бу теләкләренә:

– Сезгә хак сүз әйтәм: Атасының нәрсә эшләвен күрмичә, Улы Үзе һичнәрсә дә эшли алмас, – диде. – Атасы нәрсә эшләсә, Улы да шуны эшләр. 20 Ата Үзенең Улын ярата һәм Үзе эшләгән һәр эшен Аңа күрсәтә. Ул Аңа сезнең исегез китәрлек моннан да зуррак эшләр күрсәтер әле. 21 Ата үлгәннәрне терелтеп җанландырган кебек, Улы да, кемне теләсә, шуны җанландыра. 22-23 Ата беркемне дә хөкем итми, ә Үзен ихтирам иткән кебек, Улын да һәркем ихтирам итсен өчен, Ул бөтен хөкемне Улына тапшырды. Кем Улын ихтирам итми, шул Аны җибәргән Атаны да ихтирам итми.

24 Сезгә хак сүз әйтәм: Минем сүземне тыңлаучы һәм Мине Җибәрүчегә иман итүче кеше мәңгелек тормышка ия була. Ул кеше хөкемгә дучар булмаячак, чөнки инде үлемнән тормышка күчте. 25 Сезгә хак сүз әйтәм: Аллаһы Улының тавышын ишетеп үлгәннәр тереләчәк вакыт җитә һәм ул вакыт килеп җитте дә инде.

26 Үзендә тормыш булган кебек, Улында да булсын дип, Ата Улына тормыш бирде. 27 Ата Улына хөкем итү хокукын да бирде, чөнки Ул – Адәм Улы. 28-29 Моңа гаҗәпләнмәгез, чөнки кабердәгеләрнең һәммәсе Аллаһы Улының тавышын ишетеп, яхшылык эшләгәннәр – яшәү өчен, ә явызлык эшләгәннәр – хөкем ителү өчен каберләрдән чыгачак вакыт якынлашып килә. 30 Мин Үземнән Үзем бернәрсә эшли алмыйм. Ничек ишетсәм, шулай хөкем итәм, һәм Минем хөкемем гадел, чөнки Мин Үз ихтыярымны түгел, бәлки Мине Җибәрүченең ихтыярын эзлим.

### *Гайсә хакында шаһитлекләр*

31 – Әгәр дә Мин Үзем Үземнең хакта шаһитлек бирәм икән, Минем шаһитлегем бернигә дә тормас иде. 32 Минем хакта шаһитлек бирүче башка Берәү бар, һәм Мин беләм: Аның Минем хакта биргән шаһитлеге хак. 33 Сез Яхъя пәйгамбәр янына кешеләр җибәрдегез, һәм ул хакыйкать хакында шаһитлек бирде.

[34] Ләкин Мин кешеләрнең шаһитлегенә мохтаҗ түгел, ә болар-
ны сез котылсын өчен сөйлим.
[35] Яхъя – янучы һәм нур бирүче яктырткыч иде, ә сез анның
яктылыгы астында бераз вакыт кына куанырга теләдегез. [36] Әмма
Минем шаһитлегем Яхъяныкыннан зуррак: Мин Атаның тө-
гәлләргә дип Миңа биргән эшләрен башкарам. Мин эшләгән
шул эшләр Мине Атам җибәргән булуына шаһитлек бирәләр.
[37] Мине җибәргән Ата Минем хакта Үзе шаһитлек бирде. Сезнең
беркайчан да Аның тавышын ишеткәнегез, йөзен күргәнегез
юк. [38] Аның сүзе сездә тормый, чөнки сез Ул җибәргән Затка
ышанмыйсыз. [39] Мәңгелек тормышка ия булырга теләп, сез Изге
язмада язылганнарны тикшерәсез, ә алар нәкъ Минем хакта
шаһитлек бирәләр. [40] Әмма сез тормыш алу өчен Минем яныма
килергә теләмисез.
[41] Кешеләрнең Мине данлауларына мохтаҗлыгым юк, [42] ә Мин
сезне беләм: сездә Аллаһыны ярату юк. [43] Мин Атам исеменнән
килдем – сез Мине кабул итмисез, ә үз исеменнән килгәнне
кабул итәсез. [44] Сез бер-берегездән дан кабул итәсез, ә бер-
дәнбер Аллаһыдан булган данны эзләмисез. Шулай булгач, сез
ничек итеп ышана алырсыз икән?
[45] Мин сезне Атам алдында гаепләрмен дип уйламагыз. Сезне
гаепләүче – сез өмет баглаган Муса. [46] Сез Мусага ышансагыз,
Миңа да иман китерер идегез, чөнки ул Минем хакта язды.
[47] Ул язганнарга ышанмый торып, Минем сүзләремә ничек
ышанырсыз?

### *Биш меңне ашату*

6 [1] Шуннан соң Гайсә Гәлиләя диңгезенең аръягына китте.
Ул диңгез, шулай ук, Тибериас диңгезе дип тә атала иде.
[2] Авыруларны савыктырган могҗизалы галәмәтләрен кү-
реп, Аның артыннан бик күп халык иярде. [3] Гайсә, тауга менеп,
шәкертләре белән бергә утырды. [4] Яһүдләрнең Коткарылу бәй-
рәме якынлашып килә иде.
[5] Гайсә күзләрен күтәрде һәм Үзенә таба күп халыкның килү-
ен күреп, Филипкә:
– Аларны ашату өчен икмәкне кайдан сатып алырбыз
икән? – диде.
[6] Ул бу сүзләрне Филипне сынау өчен генә әйтте, чөнки нәр-
сә эшләячәген Үзе белә иде. [7] Филип:
– Аларның һәрберсенә аз-аз гына бирү өчен дә ике йөз
динарлык* икмәк җитмәс, – дип җавап бирде.

---

* 6:7 *Динар* – көмеш тәңкә. Эшченең бер көнлек хезмәт хакын бер
динар тәшкил иткән.

[8] Шәкертләренең берсе, Шимун Петернең энесе Әндри:
[9] – Монда бер малайның биш арпа икмәге һәм ике балыгы бар, әмма мондый күп халык өчен ул нәрсә инде? – диде.
[10] – Аларга утырырга кушыгыз, – диде Гайсә.
Ул урында исә чирәм күп иде. Шулай итеп, биш мең чамасы
ир-ат чирәмгә утырды. [11] Гайсә, икмәкне алып, шөкрана итеп,
утыручыларга өләште; балыклар белән дә шулай эшләгәннән
соң, һәркемгә теләгән кадәр бирде. [12] Һәммәсе ашап туйгач,
шәкертләренә:
– Калган сынықларны җыеп алыгыз, бернәрсә дә әрәм булмасын, – диде.
[13] Кешеләр ашаган биш арпа икмәктән калган сыныклар белән унике кәрзинне тутырдылар.
[14] Гайсә эшләгән могҗизалы галәмәтне күреп, кешеләр:
– Дөньяга килергә тиеш булган Пәйгамбәр, чынлап та, Шушыдыр, – диештеләр.
[15] Гайсә исә, аларның Үзен көч белән патша итеп куярга теләүләрен белеп, Үзе генә тагын тауга менеп китте.

*Гайсә су өстеннән атлап килә*

[16] Кич җиткәч, Гайсәнең шәкертләре диңгез буена төштеләр
дә, [17] көймәгә утырып, диңгезнең аръягына, Кәпәрнаумга таба
йөзеп киттеләр. Караңгы төште, ә Гайсә исә һаман күренмәде. [18] Диңгездә каты җил купканлыктан, дулкыннар көчәйде.
[19] Биш-алты чакрым чамасы* киткәннән соң, су өстеннән атлап
көймәгә якынлашып килүче Гайсәне күреп, куркып калдылар.
[20] Әмма Гайсә аларга:
– Бу – Мин! Курыкмагыз! – диде.
[21] Алар Аны көймәгә алырга теләделәр, ләкин нәкъ шул чакта көймә алар бара торган ярга килеп туктады.

*Гайсә – тормыш икмәге*

[22] Икенче көнне дә халык диңгез ярында тора иде әле. Алар
анда бер генә көймә булуын, ул көймәгә шәкертләрнең генә
утырып китүен, ә Гайсәнең анда утырмаганын күргәннәр иде.
[23] Кешеләр Раббы шөкрана итеп биргән икмәкне ашаган урынга Тибериас шәһәреннән башка көймәләр дә килеп туктадылар.
[24] Шулай итеп, Гайсәнең дә, Аның шәкертләренең дә анда юклыгын күргәч, халык, көймәләргә утырып, Кәпәрнаумга Гайсәне эзләргә китте. [25] Аны диңгезнең аръягында эзләп тапкач:

---

* 6:19 *Биш-алты чакрым чамасы* – грек телендә сүзгә-сүз «егерме биш яки утыз стадия».

– Остаз! Син монда кайчан килдең? – дип сорадылар.
[26] Гайсә аларга:
– Сезгә хак сүз әйтәм: сез Мине могҗизалы галәмәтләр күр-
гәнгә түгел, бәлки туйганчы икмәк ашаганга эзлисез. [27] Фани
ризык өчен түгел, бәлки мәңгелек тормыш бирә торган ризык
өчен тырышыгыз. Аны сезгә Адәм Улы бирәчәк, чөнки Аллаһы
Ата, Аны хуплап, Үзенең тамгасын салды, – диде.
[28] Аннан соң алар:
– Аллаһы эшләрен башкару өчен безгә нәрсә эшләргә ки-
рәк? – дип сорадылар.
[29] – Ул Кемне җибәргән булса, сез Шуңа иман итегез, Алла-
һының эше менә шул, – дип җавап бирде Гайсә.
[30] Алар Аңа әйттеләр:
– Сиңа иман китерерлек нинди галәмәт күрсәтерсең? Нәрсә
кылырсың? [31] Безнең ата-бабаларыбыз чүлдә манна* ашаганнар.
Бу турыда Изге язмада: «Ул аларга ашар өчен күктән икмәк
бирде», – дип язылган.
[32] Гайсә аларга:
– Сезгә хак сүз әйтәм: сезгә күктән икмәкне Муса түгел,
бәлки, хак икмәкне күктән Минем Атам бирә. [33] Аллаһы икмәге
Ул – күктән иңеп, дөньяга тормыш Бирүче, – диде.
[34] Алар Гайсәгә:
– Әфәндем! Безне һәрвакыт шундый икмәк белән тәэмин
итеп торчы, – диделәр.
[35] Гайсә исә аларга әйтте:
– Мин – тормыш икмәге: Минем янга килүче һичкайчан
ачыкмас, Миңа иман китерүче һичкайчан сусамас. [36] Ләкин
Мин сезгә: сез Мине күрдегез, әмма Миңа иман китермисез, –
дидем. [37] Атам Миңа юллаган һәркем Миңа киләчәк һәм Миңа
килүчене һичкайчан куып җибәрмәячәкмен, [38] чөнки Мин Үз
ихтыярымны түгел, бәлки Мине җибәргән Атам ихтыярын
башкару өчен күктән идем. [39] Мине җибәргән Атамның ихты-
яры исә шул: Ул биргән беркемне югалтмыйча, соңгы көндә
үледән терелтергә тиешмен. [40] Мине җибәргән Атамның ихты-
яры шул: Улын күрүче һәм Улына иман китерүче һәркемнең
мәңгелек тормышы булсын, Мин аны соңгы көндә терелтеп
торгызачакмын.
[41] Яһүдләр, Аның: «Мин – күктән иңгән икмәк», – дигән
сүзләренә ризасызлык белдереп, үзара:

---

* 6:31 *Манна* – Аллаһы борынгы Исраил халкын Мисыр коллыгын-
нан чыгаргач, чүлдә туйдыру өчен күктән җибәргән ризык.

42 – Бу Йосыф улы Гайсә түгелме соң? Без Аның атасын да,
анасын да беләбез бит. Ничек Ул: «Мин күктән индем», – дип
сөйли ала икән? – диештеләр.
43 Гайсә аларга җавап бирде:
– Үзара сукранышмагыз: 44 Мине җибәргән Ата алып килмә-
сә, Минем яныма беркем дә килә алмый, Мин исә шул кешене
соңгы көндә терелтеп торгызачакмын. 45 Пәйгамбәрләрнең язма-
ларында: «Һәммәсе дә Аллаһы тарафыннан өйрәтеләчәк», – дип
язылган. Атадан ишетеп өйрәнүче һәркем Минем янга килә.
46 Бу әле кем дә булса Атаны күргән дигән сүз түгел; Аллаһыдан
Килүче генә Атаны күрде. 47 Сезгә хак сүз әйтәм: Миңа иман
итүченең мәңгелек тормышы бар. 48 Мин – тормыш икмәге.
49 Сезнең аталарыгыз чүлдә манна ашадылар һәм үлделәр. 50 Күк-
тән иңүче икмәк исә шундый ки, аны ашаучы үлмәс. 51 Мин –
күктән иңгән тере икмәк, бу икмәкне ашаучы мәңге яшәр.
Мин бирәчәк икмәк исә – ул Минем тәнем. Мин аны дөнья
яшәсен өчен бирәчәкмен.
52 Шуннан соң яһүдләр ачуланышып:
– Бу Кеше ничек Үзенең тәнен безгә ашар өчен бирә алыр
икән? – дип үзара бик каты бәхәсләштеләр.
53 Гайсә исә аларга әйтте:
– Сезгә хак сүз әйтәм: Адәм Улының тәнен ашамасагыз һәм
Аның канын эчмәсәгез, үзегездә тормыш булмаячак. 54 Минем
тәнемне ашап, Минем канымны эчүченең мәңгелек тормышы
бар. Мин аны соңгы көндә терелтеп торгызачакмын. 55 Минем
тәнем – чын ризык, Минем каным – чын эчемлек. 56 Минем
тәнемне ашап, Минем канымны эчүче Миндә кала, Мин аңар-
да калам. 57 Мине тере Атам җибәрде һәм Мин Атам аша яшим,
шулай ук Мине ашаучы да Минем аша яшәячәк. 58 Бу – күктән
иңгән икмәк. Ул икмәк сезнең аталарыгыз ашаган манна кебек
түгел: алар үлгәннәр. Ә бу икмәкне ашаучы мәңге яшәячәк.
59 Ул боларны Кәпәрнаумда өйрәткән вакытта гыйбадәтха-
нәдә сөйләде.

*Сез дә китәргә теләмисезме?*

60 Гайсәнең күп шәкертләре, бу сүзләрне ишеткәннән соң:
– Нинди авыр сүзләр! Боларны кем тыңлый алсын? – диделәр.
61 Әмма Гайсә күңеленнән шәкертләренең сукрануларын белеп:
– Сезне шушы рәнҗетәме? 62 Адәм Улының элек булган уры-
нына күтәрелүен күрсәгез нәрсә булыр? 63 Рух Ул – тормыш
бирүче, кешенең көче һичнинди файда китерми; Мин сезгә
сөйләгән сүзләр – рух һәм тормыш. 64 Әмма арагызда иман ит-
мәүчеләр дә бар, – дип әйтте.

Чөнки Гайсә кемнең иман итмәвен һәм кемнең Үзенә хыя-
нәт итәчәген баштан ук белде.
65 Ул сүзен дәвам итеп:
– Менә шуның өчен Мин сезгә, Атам җибәрмәсә, Минем
янга беркемнең дә килә алмаячагын әйттем, – диде.
66 Шул вакыттан башлап Гайсәнең күп кенә шәкертләре Аннан
аерылып киттеләр һәм башка Аның белән бергә йөрмәделәр.
67 Шуннан соң Гайсә унике шәкертеннән:
– Сез дә китәргә теләмисезме? – дип сорады.
68 Шимун Петер Аңа:
– Раббым! Без кем янына барыйк соң? Мәңгелек тормыш
сүзләре Синдә бит. 69 Без Сиңа иман итәбез, Сине Аллаһының
Изге Заты дип таныйбыз, – дип җавап бирде.
70 Гайсә аларга:
– Мин сезне – уникене сайлап алдым түгелме? Әмма сезнең
арада берегез иблис, – диде.
71 Ул бу сүзләрне, Үзенә хыянәт итәчәк, уникенең берсе бул-
ган Шимун улы Яһүд Искариот хакында әйтте.

*Гайсә һәм Аның энеләре*

7 1 Шуннан соң Гайсә, яһүдләрнең Аны үтерергә эзләгәнлек-
ләре сәбәпле, Яһүдиядә йөрергә теләмәде. Шуңа күрә Ул
Гәлиләядә йөрергә булды. 2 Яһүдләрнең Чатыр кору бәй-
рәме якынлаша иде, һәм 3 энеләре:
– Гәлиләядән Яһүдиягә бар, Син эшләгән эшләрне шәкерт-
ләрең дә күрсен. 4 Әгәр кеше үзен танытырга тели икән, эшен
яшерен рәвештә эшләми. Шундый эшләр эшлисең икән, Үзең-
не дөньяга күрсәт, – диделәр.
5 Аңа хәтта энеләре дә иман итмәделәр.
6 Гайсә аларга әйтте:
– Минем вакыт әле килеп җитмәде, ә сезнең өчен һәркайчан
вакыт. 7 Дөнья сезгә нәфрәт белән карамый, ә Миңа нәфрәтен
күрсәтә, чөнки Мин эшләренең явыз булганлыгына һәрвакыт
шаһитлек биреп торам. 8 Сез бәйрәмгә барыгыз, ә Мин бар-
мыйм, чөнки Минем вакыт әле җитмәде.
9 Ул аларга шулай диде һәм Гәлиләядә калды, 10 әмма, энеләре
киткәч, яшерен рәвештә Үзе дә бәйрәмгә барды.

*Гайсә Чатыр кору бәйрәмендә*

11 Яһүдләр исә:
– Ул кайда икән? – дип, Аны бәйрәмдә эзләп йөрделәр.
12 Аның хакында халык арасында күп сүзләр йөрде. Кай-
берләре:

– Ул яхшы Кеше, – диде, башкалары исә:
– Юк, Ул халыкны аздыра, – дип сөйләде.
13 Әмма, яһүдләрдән куркып, Аның хакында беркем дә ачык итеп сөйләмәде.
14 Ә инде бәйрәм уртасында Гайсә Аллаһы Йортына кереп өйрәтә башлады. 15 Яһүдләр:
– Бу Кеше каян белә икән, Ул бит укымаган? – дип гаҗәпләнделәр.
16 Гайсә аларга әйтте:
– Минем өйрәтүем Үземнеке түгел, бәлки Мине Җибәрүченеке. 17 Аның ихтыярын башкарырга теләгән кеше бу өйрәтүнең Аллаһыданмы икәнен яки Үземнән генә сөйлим микәнен
белер. 18 Үз исеменнән сөйләүче үзенә дан эзли, ә Үзен Җибәрүченең данын эзләүче эчкерсез һәм Аңарда ялган юк. 19 Муса
сезгә канун бирде түгелме? Ә сезнең берегез дә аны үтәми. Ни өчен Мине үтерергә йөрисез?
20 Кешеләр:
– Сиңа җен кагылдымы әллә? Кем Сине үтерергә йөри? – диделәр.
21 Гайсә сүзен дәвам итте:
– Мин бер эш эшләдем һәм сез һәммәгез шуңа гаҗәпләнәсез.
22 Муса сезгә сөннәт бирде, – гәрчә ул Мусадан түгел, бәлки аталардан килә, – шуңа күрә шимбә көнне ир баланы сөннәткә
утыртасыз. 23 Муса кануны бозылмасын дип, шимбә көнне ир бала сөннәткә утыртыла икән шимбә көнне бер кешене бөтенләй савыктырганым өчен нигә Миңа ачуыгыз килә? 24 Тышкы
күренешкә генә карап хөкем итмәгез, бәлки дөрес хөкем итегез.

*Гайсә – Мәсихме?*

25 Шунда кайбер иерусалимлылар бер-берсенә:
– Бу әллә яһүдләрнең башлыклары үтерергә теләгән Кешеме?
26 Әнә Ул ачыктан-ачык сөйли, ә алар Аңа бер сүз дә әйтмиләр:
әллә Аны чыннан да Мәсих дип уйлыйлар микән? 27 Әмма,
Мәсих килгәндә, Аның кайдан икәнлеген беркем дә белмәс. Без исә бу Кешенең кайдан икәнен беләбез, – диделәр.
28 Гайсә, Аллаһы Йортында өйрәткәндә, тавышын көчәйтеп, болай диде:
– Сез Мине беләсез һәм кайдан икәнемне дә беләсез. Ләкин Мин Үземнән Үзем килмәдем, һәм Мине Җибәрүче хак. Сез
Аны белмисез, 29 ә Мин Аны беләм, чөнки Мин Аннан килдем, Мине Ул җибәрде.
30 Алар Гайсәне тотып алырга теләделәр, ләкин берсе дә Аңа кул тидермәде, чөнки Аның вакыты килеп җитмәгән иде

әле. 31 Халык арасында исә, күп кешеләр Аңа иман китерделәр һәм:

– Мәсих килгәч, бу Зат күрсәткәннән дә күбрәк илаһи билгеләр күрсәтер микән? – диештеләр.

32 Фарисейләр халыкның Гайсә хакында шундый сүз йөрткәннәрен ишеттеләр, һәм баш руханилар белән фарисейләр, Аны тотып алу өчен, тәртип саклаучыларны җибәрделәр.
33 Гайсә:

– Мин сезнең арада озак булмам, тиздән Үземне Җибәрүче янына кире кайтачакмын. 34 Мине эзләрсез, әмма тапмассыз. Мин булачак урынга сез килә алмассыз, – дип әйтте.

35 Шунда яһүдләр үзара:

– Без таба алмаслык нинди урынга китмәкче була икән? Әллә греклар арасына таралып яшәүче безнекеләр янына китеп, грекларны өйрәтергә тели микән? 36 Аның: «Мине эзләрсез, әмма тапмассыз. Мин булачак урынга сез килә алмассыз», – дигән сүзләре нәрсәне аңлата икән? – диештеләр.

37 Бәйрәмнең соңгы, бөек көнендә Гайсә торып басты һәм көчле тавыш белән әйтте:

– Сусаган кеше Минем янга килсен һәм эчсен. 38 Миңа иман итүченең, Изге язмада әйтелгәнчә: «күңел түреннән елгалар булып тереклек суы агачак».

39 Ул моны Үзенә иман китергәннәр алачак Рух хакында әйтте; әле Гайсә данланмаганга, аларга Изге Рух бирелмәгән иде.

40 Аның бу сүзләрен тыңлап торган халык арасында кайберләре:

– Ул – чынлап та вәгъдә ителгән Пәйгамбәр, – диделәр.

41 Берләре:

– Бу – Мәсих.

Ә башкалары:

– Мәсих Гәлиләядән килер микән? 42 Изге язмада, Мәсих Давыт нәселеннән булачак һәм Давыт шәһәреннән – Бәйтлехемнән киләчәк, дип язылган түгелме? – диделәр.

43 Шулай итеп, халык арасында Гайсә хакында бәхәс чыкты.
44 Кайберләре Аны тотып алырга теләделәр, ләкин берсе дә Аңа кул тидермәде.

45 Тәртип саклаучылар баш руханилар белән фарисейләр янына кайткач, алардан:

– Ни өчен Аны тотып китермәдегез? – дип сорадылар.

Тегеләр:

46 – Берәүнең дә һичкайчан ул Кеше сөйләгән кебек сөйләгәне юк, – дип җавап бирделәр.

[47] Фарисейләр аларга:
– Әллә сез дә алдандыгызмы? [48] Башлыкларның яки фари-
сейләрнең берәрсе Аңа иман китердеме? [49] Ә канунны белмәүче
бу халык ләгънәт ителгән.
[50] Шунда фарисейләрнең берсе, Никәдим атлысы, ул элегрәк
Гайсә янына килеп киткән иде:
[51] – Башта кешене тыңламыйча һәм аның нәрсә эшләгәнен
белмичә безнең канун аны хөкем итәме? – диде.
[52] – Әллә син дә Гәлиләядәнме? Тикшереп кара һәм күрер-
сең: Гәлиләядән һич тә пәйгамбәр чыкмас, – дип җавап бир-
деләр аңа.

*Уйнашлыкта тотылган хатын*

[ [53] Барысы да өйләренә таралгач,
**8** [1] Гайсә Зәйтүн тавына китте.
[2] Иртә белән Ул яңадан Аллаһы Йортына килде һәм Аның
янына күп халык җыелды. Ул, утырып, аларны өйрәтә
башлады. [3] Шулчак канунчылар һәм фарисейләр, уйнашлыкта
тотылган бер хатынны алып килеп, уртага бастырып куйдылар
[4] һәм Гайсәгә:
– Остаз! Бу хатын зина кылганда тотылды. [5] Канунда Муса
мондыйларны ташлар атып үтерергә әмер бирә, ә Син нәрсә
әйтерсең? – диделәр.
[6] Алар моны, Гайсәне сынау өчен, Аны гаепләргә берәр сыл-
тау табарбыз, дигән уй белән әйттеләр. Әмма Гайсә, чүгәләп,
бармагы белән җиргә яза башлады. [7] Ләкин алар сорауларын
кабат биргәнгә, Ул торып басты һәм аларга:
– Сезнең кайсыгыз гөнаһсыз, шул башлап аңа таш атсын, –
диде. [8] Һәм, тагын чүгәләп, җиргә язуын дәвам итте.
[9] Алар исә, моны ишеткәч, өлкәннәреннән башлап бер-бер
артлы чыгып киттеләр. Гайсә уртада басып торган хатын белән
генә калды.
[10] Гайсә торып басып:
– Сеңлем! Кайда алар? Сине беркем дә хөкем итмәдеме? –
дип сорады.
[11] Хатын исә:
– Беркем дә, Әфәндем! – диде.
Гайсә аңа:
– Мин дә сине хөкем итмим: бар, башка гөнаһ кылма, –
диде.]*

---

* 7:53-8:11 Кайбер кульязмаларда җәяләр эчендәге сүзләр дә бар.

*Гайсә – дөньяга яктылык*

12 Гайсә тагын халыкка сөйләде. Ул:
– Мин – дөньяга яктылык. Минем артымнан баручы караңгылыкта йөрмәячәк, бәлки аның тормыш бирүче яктылыгы булачак, – дип әйтте.
13 Шуннан соң фарисейләр Аңа:
– Син Үзең хакында Үзең шаһитлек бирәсең, Синең шаһитлегең хак түгел, – диделәр.
14 Гайсә исә аларга:
– Мин Үзем хакында Үзем шаһитлек бирсәм дә, Минем шаһитлегем хак, чөнки кайдан килеп кая баруымны беләм, ә сез
Минем кайдан килеп кая баруымны белмисез. 15 Сез кешеләр
үлчәме буенча хөкем итәсез, ә Мин беркемне дә хөкем итмим.
16 Мин хөкем итсәм дә, Минем хөкемем хак, чөнки Мин Үзем
генә түгел, Мине җибәрүче Ата белән бергә Мин. 17 Сезнең ка-
нуныгызда да: «Ике кешенең шаһитлеге хак», – дип язылган.
18 Мин Үзем хакында Үзем шаһитлек бирәм һәм Минем хакта
Мине җибәргән Ата шаһитлек бирә, – дип җавап бирде.
19 Шуннан соң Гайсәдән:
– Кайда Синең атаң? – дип сорадылар.
Гайсә:
– Сез Мине дә, Атамны да белмисез. Әгәр Мине белсәгез, Атамны да белер идегез, – диде.
20 Гайсә бу сүзләрне Аллаһы Йортында өйрәткәндә сәдака сандыгы янында әйтте. Берсе дә Аңа кул тидермәде, чөнки Аның вакыты әле килеп җитмәгән иде.

*Мин китәчәк урынга сез килә алмассыз*

21 Гайсә аларга янә:
– Мин китәм. Сез Мине эзләрсез. Сез үз гөнаһыгыз белән үләрсез. Мин китәчәк урынга сез килә алмассыз, – дип әйтте.
22 Яһүдләр:
– Ул Үзен Үзе үтерәчәк микәнни? Чөнки: «Мин китәчәк урынга сез килә алмассыз», – ди бит, – диештеләр.
23 Ул аларга:
– Сез түбәннән, Мин югарыдан. Сез бу дөньяныкы, Мин бу
дөньяныкы түгел, – диде. 24 – Сез Минем мәңге бар* икәнемә
ышанмасагыз, үз гөнаһларыгыз белән үләрсез. Шуңа күрә Мин сезгә: «Сез гөнаһларыгыз белән үләрсез», – дидем.

---

* **8:24** *Мин мәңге бар* – Бу сүзләр Аллаһының «Мин – бар» дигән исеменә туры килә. (Тәүрат, «Чыгыш» китабы 3:14.)

[25] Шуннан соң Гайсәдән:
– Кем соң Син? – дип сорадылар.
– Мин сезгә Үземнең кемлегемне инде күптән әйтәм, – диде
аларга Гайсә. – [26] Сезнең хакта күп сөйләп, сезне хөкем итә
алыр идем. Әмма Мине Җибәрүче хак, һәм Аннан нәрсә ишет-
сәм, Мин дөньяга шуны сөйлим.
[27] Алар Гайсәнең Ата хакында сөйләвен аңламадылар. [28] Гайсә
аларга әйтте:
– Сез Адәм Улын күтәргәч, Минем мәңге бар* икәнемне
һәм Үзлегемнән һичнәрсә эшләмәвемне, бәлки, Атам ничек
өйрәткән булса, шулай сөйләвемне белерсез. [29] Мине Җибәрүче
Минем белән. Атам Мине ялгыз калдырмады, чөнки Мин һәр-
вакыт Ул теләгән эшләрне генә эшлим.
[30] Ул шушы сүзләрне сөйләгән чакта күпләр Аңа иман ки-
терделәр.

*Ибраһимның балалары*

[31] Гайсә Үзенә иман китергән яһүдләргә:
– Минем сүзләремне тотсагыз, чыннан да Минем шәкерт-
ләрем булырсыз. [32] Хакыйкатьне белерсез һәм хакыйкать сезне
ирекле итәр, – дип әйтте.
[33] – Без Ибраһим нәселеннән, – диделәр алар Аңа, – һәм
беркайчан да һичкемнең дә колы булмадык. Ничек соң Син:
«Ирекле булырсыз», – дисең?
[34] – Сезгә хак сүз әйтәм: гөнаһ кылучы һәркем – гөнаһ колы.
[35] Кол өйдә мәңге тормый, ә атаның улы анда мәңге тора.
[36] Шулай итеп, Улы сезне ирекле итсә, сез чын мәгънәсендә
ирекле булачаксыз. [37] Мин сезнең Ибраһим нәселеннән булуы-
гызны беләм, әмма, Минем сүзләремә сездә урын булмаганга
күрә, сез Мине үтерергә йөрисез. [38] Мин Атам янында күргән-
нәрем хакында сөйлим, ә сез үз атагыз янында ишеткәннәрне
эшлисез, – диде аларга Гайсә.
[39] Алар, җавап биреп:
– Безнең атабыз – Ибраһим, – диделәр.
Гайсә аларга әйтте:
– Сез Ибраһим балалары булсагыз, Ибраһим эшләрен эшләр
идегез. [40] Ә хәзер Мине, Аллаһыдан ишеткән хакыйкатьне сөй-
ләгән Бәндәне, үтерергә йөрисез. Ибраһим алай эшләмәде.
[41] Сез үз атагызның эшләрен эшлисез.
Алар Аңа:

---

* **8:28** *Мин мәңге бар* – 8:24 тәге искәрмәне карагыз.

– Без уйнаштан тумаган, безнең Атабыз бер генә: Ул – Алла-
һы, – диделәр.
42 Гайсә аларга әйтте:
– Атагыз Аллаһы булса, сез Мине яратыр идегез, чөнки Мин
Аллаһыдан килдем. Мин Үзлегемнән килмәдем, Мине Ул җи-
бәрде. 43 Ни өчен сез Мин сөйләгәннәрне аңламыйсыз? Чөнки
сез Минем сүземне тыңлый алмыйсыз. 44 Сезнең атагыз – иб-
лис, һәм сез атагызның теләкләрен үтәргә телисез. Ул баштан
ук кеше үтерүче булып, хакыйкатьне тотмады һәм хәзер дә тот-
мый, чөнки аңарда хакыйкать юк. Ул, ялган сөйләгән вакытта,
үзенекен сөйли, чөнки ул – ялганчы һәм ялганның атасы.
45 Ә сез, Мин хакыйкатьне сөйләгәнгә күрә, Минем сүзләремә
ышанмыйсыз. 46 Минем гөнаһта гаепле булуымны кайсыгыз ис-
бат итә алыр? Әгәр хакыйкатьне сөйлим икән, ни өчен Минем
сүзләремә ышанмыйсыз? 47 Кем Аллаһыдан булса, ул Аллаһы
сүзләрен тыңлар; ә сез, Аллаһыдан булмаганга күрә, тыңла-
мыйсыз.

### *Гайсә һәм Ибраһим*

48 Моңа яһүдләр:
– Син самареяле, Синең эчеңдә җен бар, – әллә бу дөрес
түгелме? – диделәр.
49 Гайсә җавап бирде:
– Миндә җен юк. Мин Атамны хөрмәт итәм, ә сез Мине хур
итәсез. 50 Хәер, Мин Үземә дан эзләмим, ә эзләүче башка Бе-
рәү бар һәм Ул хөкем итә. 51 Сезгә хак сүз әйтәм: кем Минем
сүземне тота, ул һичкайчан үлем күрмәячәк.
52 Яһүдләр Аңа:
– Менә хәзер Синдә җен барлыгына һич шигебез калмады:
Ибраһим да, пәйгамбәрләр дә үлгәннәр, ә Син: «Кем Минем
сүземне тота, ул беркайчан да вафат булмас», – дисең. 53 Син
атабыз Ибраһимнан да бөегрәкме? Ул үлгән, пәйгамбәрләр дә
үлгәннәр. Син Үзеңне кем дип саныйсың?
54 Гайсә җавап бирде:
– Үземне Үзем данлыйм икән, Минем даным буш булыр. Сез
«Аллаһыбыз» дип атаган Атам Мине данлый. 55 Сез Аны бел-
мисез, ә Мин Аны беләм. Аны белмим дисәм, сезнең кебек
ялганчы булыр идем; әмма Мин Аны беләм һәм Аның сүзен
тотам. 56 Сезнең атагыз Ибраһим Минем көнемне күрәчәгенә
шатланды. Ул аны күреп куанды.
57 Яһүдләр Аның бу сүзләренә:
– Сиңа әле илле яшь тә юк, ә Син Ибраһимны күрдеңме? –
диделәр.

58 Гайсә аларга әйтте:
– Сезгә хак сүз әйтәм: Ибраһим булганга кадәр Мин бар*.
59 Шул чакта алар, Аңа ыргыту өчен, кулларына ташлар алды-
лар, әмма Гайсә, яшеренеп, Аллаһы Йортыннан чыгып китте.

*Тумыштан сукыр кешенең күрә башлавы*

9 1 Үтеп барышлый, Гайсә тумыштан ук сукыр бер кешене
күрде. 2 Шәкертләре Аннан:
– Остаз! Бу кешенең сукыр булып тууы кемнең гөнаһын-
нан: бу кеше үзе гөнаһ кылганмы, әллә ата-анасымы? – дип со-
радылар.
3 Гайсә җавап бирде:
– Бу кеше үзенең гөнаһы өчен дә, ата-анасының кылган гө-
наһы өчен дә сукыр түгел. Ул, аның авыруы аша Аллаһы эшлә-
ре күренсен өчен, сукыр булып туды. 4 Көн үткәнче без Мине
Җибәрүченең эшләрен башкарырга тиешбез. Төн җитә, ул чакта
һичкем берни эшли алмас. 5 Мин дөньяда вакытта, Мин –
дөньяга яктылык.
6 Шулай дип, Ул җиргә төкерде, төкереге белән лай ясады,
шул лайны сукырның күзләренә сөртте дә 7 аңа:
– Шилуах буасына барып юын, – диде. (Шилуах – «Җибә-
релгән» дигән мәгънәдә.)
Ул барып юынды һәм күзләре күрә торган булып кайтты.
8 Аның күршеләре һәм элек хәер сорашып утыруын күргән ке-
шеләр:
– Бу соң, теге, хәер сорашып утырган кеше түгелме? – диделәр.
9 Кайберләре: «Бу – шул», ә кайберләре: «Шуңа охшаган», –
диделәр.
Сукыр үзе исә:
– Мин шул кеше, – дип әйтә иде.
10 Аннан:
– Күзләрең ничек ачылды соң? – дип сорадылар.
11 Ул җавап биреп:
– Гайсә атлы Кеше лай ясап күзләремә сөртте, аннан: «Ши-
луах буасына барып юын», – диде. Мин барып юындым һәм
күзләрем ачылды, – диде ул.
12 Аннан: «Ул Кеше кайда?» – дип сорагач:
– Мин белмим, – дип җавап бирде.
13 Элек сукыр булган бу кешене фарисейләр янына алып
бардылар. 14 Ә Гайсә лай ясап сукырның күзләрен ачкан көн –

---

* 8:58 *Мин бар* – Бу сүзләр Аллаһының исеменә туры килә. 8:24 нең искәрмәсен карагыз.

шимбә көн иде. 15 Фарисейләр дә аннан ничек күрә башлавы
хакында сораштылар. Ул аларга:

— Ул минем күзләремә лай сылады, мин юындым да күрә башладым, — диде.

16 Кайбер фарисейләр исә:

— Бу Кеше шимбә көнне тотмый, шуңа күрә Ул Аллаһыдан түгел, — дип әйттеләр.

Ә башкалары:

— Гөнаһлы кеше мондый могҗизалы галәмәтләрне ничек
эшли алсын? — диделәр. Һәм алар арасында бәхәс чыкты.
17 Әлеге сукырга: — Син Аның турында нәрсә әйтерсең, Ул бит
синең күзләреңне ачты, — диделәр.

— Ул — Пәйгамбәр, — дип җавап бирде сукыр.

18 Әмма яһүдләр, күзләре ачылган кешенең ата-анасын чакырганчы, аның сукыр булганына һәм күрә башлавына ышанмадылар.

19 — Тумыштан сукыр дигән улыгыз шушымы? Әмма хәзер ул ничек күрә ала? — дип сорадылар алар.

20 Ата-анасы аларга:

— Без аның улыбыз икәнен һәм сукыр булып туганын беләбез.
21 Ә аның ничек күрә башлавын да, күзләрен кем ачканын
да белмибез. Ул инде балигъ булган, үзеннән сорагыз, үзе хакында үзе сөйләсен, — дип җавап бирделәр.

22 Сукырның ата-анасы, яһүдләрдән курыкканга күрә, шулай
диде. Чөнки яһүдләр, Гайсәнең Мәсих икәнен икърар итүче
һәркемне гыйбадәтханәдән аерырга, дип сүз куешкан иделәр.
23 Шунлыктан аның ата-анасы: «Ул инде балигъ булган, үзеннән сорагыз», — диделәр.

24 Шулай итеп, яһүдләр элек сукыр булган кешене икенче тапкыр чакырып, аңа:

— Аллаһыны ихтирам ит! Без ул Кешенең гөнаһлы икәнен беләбез, — диделәр.

25 Ул аларга:

— Ул гөнаһлымы, түгелме, анысын белмим. Шуны гына беләм: мин сукыр идем, ә хәзер күрәм, — дип җавап бирде.

26 Алар аннан:

— Ул нәрсә эшләде? Синең күзләреңне ничек ачты? — дип тагын сорадылар.

27 Ул аларга:

— Мин инде сезгә сөйләдем, ә сез тыңламадыгыз. Ни өчен тагын ишетергә телисез? Әллә сез дә Аның шәкертләре булырга җыенасызмы? — дип җавап бирде.

28 Алар аңа бик ачуланып:

– Син – Аның шәкерте, ә без – Муса шәкертләре. 29 Без
Аллаһының Мусага сөйләгәнен беләбез, әмма Моның кайдан
икәнен белмибез, – диделәр.
30 Күрә башлаган кеше, аларга җавап биреп, болай диде:
– Шунысы гаҗәп тә: сез Аның кайдан икәнен белмисез, ә Ул
минем күзләремне ачты! 31 Без Аллаһының гөнаһлыларны тың-
ламавын беләбез, әмма Аллаһыга табынучыны һәм Аның ихты-
ярын башкаручыны Ул тыңлый. 32 Кемнең дә булса тумыштан
сукыр кешенең күзләрен ачуы турында гомердә дә ишетелгәне
юк. 33 Ул Кеше Аллаһыдан булмаса, һичнәрсә булдыра алмас иде.
34 – Башыңнан аягыңа тикле гөнаһта тугансың, нигә безне
өйрәтәсең? – дип, аны куып чыгардылар.

*Рухи сукырлык*

35 Гайсә, аны куып чыгарганнарын ишеткәч, аны табып:
– Син Адәм Улына ышанасыңмы? – дип сорады.
36 Ул исә:
– Әфәндем, мин Аңа ышансын өчен Аның кем икәнен әйт
сәнә, – дип җавап бирде.
37 Гайсә әйтте:
– Син Аны күрдең. Хәзер синең белән Ул сөйләшә.
38 Ул исә:
– Раббым, мин ышанам! – дип Аның алдына тезләнеп, Аңа
табынды.
39 Гайсә:
– Мин бу дөньяга, күрми торганнар – күрсен, ә күрә торган-
нар – сукырайсын дип, хөкем итү өчен килдем, – дип әйтте.
40 Аның янында булган кайбер фарисейләр, моны ишеткәч:
– Әллә без дә сукырмы? – диделәр.
41 – Сез сукыр булсагыз, гөнаһыгыз өчен гаепле булмас иде-
гез; ә сез, күрәбез, дигәнлектән гөнаһыгыз үзегездә кала, – дип
әйтте Гайсә.

*Гайсә – яхшы Көтүче*

10 1 – Сезгә хак сүз әйтәм: кем сарык утарына капкадан
түгел, бәлки башка юл белән керә, ул – карак һәм юл-
басар. 2 Ә капкадан керүче сарыкларга көтүче була: 3 аңа
сакчы капка ача, сарыклар аның тавышын ишетәләр һәм ул са-
рыкларын исемнәре белән чакырып, аларны алып чыга. 4 Үзе-
нең бар сарыкларын алып чыкканнан соң, ул алар алдыннан
бара; ә сарыклар аның артыннан баралар, чөнки аның тавы-
шын таныйлар. 5 Алар чит кеше артыннан бармыйлар, ә аннан
качып китәләр, чөнки аның тавышын танымыйлар.

[6] Гайсә аларга бу гыйбрәтле хикәяне сөйләде, ләкин кешеләр
Аның нәрсә хакында сөйләгәнен аңламадылар.
[7] Шулай итеп, Гайсә аларга янә:
– Сезгә хак сүз әйтәм: Мин – сарыкларга капка. [8] Миннән
алда килгәннәрнең барысы да карак һәм юлбасар иделәр, ләкин сарыклар аларны тыңламадылар. [9] Мин – капка. Минем
аша керүче котылачак, кереп-чыгып йөриячәк һәм көтүлек
табачак. [10] Карак ул урлау, үтерү һәм һәлак итү өчен генә килә.
Мин исә аларның тормышы булсын, тормышы мул булсын
дип килдем.
[11] Мин – яхшы Көтүче; яхшы көтүче сарыклары өчен гомерен дә кызганмый. [12-13] Ә яллanган көтүче – чын көтүче түгел
ул. Сарыклар үзенеке булмаганга, ул алар турында кайгыртмый:
бүренең килгәнен күреп, сарыкларны ташлап, качып китә, бүре, сарыкларга һөҗүм итеп, аларны таратып бетерә.
[14-15] Мин – яхшы Көтүче. Ата Мине, Мин Атаны таныган кебек, Мин үземнекеләрне таныйм, алар Мине таныйлар. Мин
сарыкларым өчен тормышымны да кызганмыйм. [16] Минем бу
утардан булмаган башка сарыкларым да бар. Мин аларны да
алып килергә тиеш. Алар Минем тавышымны ишетәчәкләр.
Бер көтү һәм бер көтүче булачак. [17] Ата Мине шуның өчен ярата: Мин Үз тормышымны аны яңадан кабул итү өчен бирәм.
[18] Аны Миннән беркем дә алмый, Мин аны Үз ихтыярым белән
бирәм: аны бирергә дә, кире алырга да хокукым бар. Болай эшләргә Миңа Атам боерык бирде.
[19] Бу сүзләр нәтиҗәсендә яһүдләр арасында янә бәхәс чыкты.
[20] Аларның күбесе:
– Аңарда җен бар, Ул акылсыз. Сез ни өчен Аны тыңлыйсыз? – диделәр.
[21] Башкалары исә:
– Бу җенле кеше сүзләре түгел, җен сукырның күзләрен ача
аламы соң? – диделәр.

*Яһүдләр Гайсәне кабул итмиләр*

[22] Кыш җиткәч, Иерусалимда Яңару бәйрәме* вакытында,
[23] Гайсә Аллаһы Йортында Сөләйман әйванында** йөргән чакта, [24] яһүдләр, Аның тирәсенә җыелып:
– Син безне газаплы билгесезлектә озак тотарсыңмы? Син
Мәсих булсаң, безгә ачык итеп әйт, – диделәр.

---

* 10:22 *Яңару бәйрәме* – Мәсих туганга кадәр 165 нче елда Иерусалимдагы Аллаһы Йортының яңадан ачылуын искә алу бәйрәме.
** 10:23 *Әйван* – баганалардан торган өсте каплаулы зал.

25 Гайсә аларга болай дип җавап бирде:
– Мин сезгә әйттем, ә сез ышанмыйсыз. Атам исеменнән
кылган гамәлләрем Минем хакта шаһитлек бирәләр. 26 Әмма
сез ышанмыйсыз, чөнки сез Минем сарыкларымнан түгел.
27 Минем сарыкларым тавышымны ишетәләр, Мин дә аларны
таныйм, һәм алар Минем арттан баралар. 28 Мин аларга мәңге-
лек тормыш бирәм. Алар һичкайчан да һәлак булмаячаклар,
һәм аларны беркем дә Минем кулдан тартып ала алмаячак.
29 Аларны Миңа биргән Атам һәммәсеннән дә бөек. Атамның
кулыннан аларны тартып алырга беркемнең дә көче җитмәячәк.
30 Мин һәм Ата – бер.

31 Шуннан соң яһүдләр, Аны үтерергә теләп, тагын куллары-
на ташлар алдылар.

32 Гайсә исә аларга:
– Мин сезгә Атам исеменнән күп яхшы эшләр күрсәттем,
шуларның кайсысы өчен Мине ташлар атып үтерергә телисез? –
дип әйтте.

33 Яһүдләр Аңа:
– Без Сине яхшы эшләрең өчен түгел, бәлки, Аллаһыны хөр-
мәт итмичә, Аңа каршы көфер сүз сөйләвең, Үзең кеше була
торып, Үзеңне Аллаһы дип әйтүең өчен үтерергә телибез, – дип
җавап бирделәр.

34 Гайсә аларга:
– Аллаһының: «„Сез – илаһлар“, – дидем Мин», – дип әйт-
кән сүзләре сезнең кануныгызда язылган түгелме? 35 Аллаһы
Үзенең сүзе бирелгән кешеләрне илаһлар дип атады, ә Изге
язма юкка чыгарыла алмый. 36 Ничек соң сез Миңа, Ата изге
эшкә аерып дөньяга җибәргән Затка, Мин: «Мин – Аллаһы
Улы», – дип әйткәндә: «Көфер сөйлисең», – дисез? 37 Мин
Атамның эшләрен башкармыйм икән, Миңа ышанмагыз. 38 Ә
инде башкарам икән, Минем Үземә ышанмасагыз да, Атамның
Миндә, Минем Аңарда икәнлекне белү һәм аңлау өчен, эшлә-
ремә ышаныгыз, – дип әйтте.

39 Шунда Аны тагын кулга алырга тырыштылар, әмма Ул
алардан качып китте.

40 Шуннан соң Гайсә тагын Үрдүннең аръягына, элек Яхъя
чумдырган урынга китте һәм шунда калды. 41 Күпләр Аның
янына килделәр һәм бер-берсенә:
– Яхъя һичбер могҗизалы галәмәт күрсәтмәде, әмма Яхъя-
ның бу Кеше турында әйткәннәре һәммәсе дә дөрес булды, –
диделәр.

42 Һәм анда күпләр Аңа иман китерде.

*Гайсәнең Лазарны үледән терелтеп торгызуы*

11 [1] Мәрьям һәм аның апасы Марта яшәгән Бәйтәния авылында Лазар исемле бер кеше авырый иде. [2] Мәрьям – авырып ятучы Лазарның сеңлесе, Раббының аякларын хуш исле май белән майлап, чәче белән сөрткән кыз. [3] Кыз туганнар Гайсәгә:

– Раббым! Якын дустың Лазар авырый, – дип хәбәр җибәрделәр.

[4] Гайсә бу турыда ишеткәч:

– Бу авыру – үлемгә дигән чир түгел, бәлки Аллаһының данлануы өчен, һәм бу авыру аша Аллаһы Улы данлансын өчен, – диде.

[5] Гайсә Мартаны, аның сеңлесен һәм Лазарны ярата иде, [6] әмма, Лазарның авыру икәнен ишеткәч тә, булган урынында Ул тагын ике көнгә тоткарланды. [7] Шуннан соң шәкертләренә:

– Яңадан Яһүдиягә барыйк, – диде.

[8] Шәкертләре Аңа:

– Остаз! Әле күптән түгел генә яһүдләр Сине ташлар атып үтерергә йөргәннәр иде, Син тагын шунда барасыңмы? – диделәр.

[9] Гайсә җавап бирде:

– Көн яктылыгы унике сәгать түгелме соң? Көндез йөрүче абынмый, чөнки бу дөньяның яктысын күрә. [10] Ә төнлә йөрүче абына, чөнки аңарда яктылык юк.

[11] Шуннан соң Гайсә сүзен дәвам итте:

– Дустыбыз Лазар йоклап киткән, Мин аны уятырга барам.

[12] Аның шәкертләре:

– Раббыбыз! Йоклап киткән булса, савыгыр, – диделәр.

[13] Гайсә аның үлгәнлеге хакында әйткән иде, алар исә, гадәттәге йокы турында сөйли, дип уйладылар. [14] Шуңа күрә Гайсә аларга ачык итеп:

– Лазар үлде. [15] Сез ышансын дип, анда булмаганыма сезнең өчен шатланам. Әйдәгез, аның янына барыйк, – диде.

[16] Игезәк кушаматлы Томас шәкертләргә:

– Әйдәгез, киттек, Аның белән бергә без дә үлик, – диде.

[17] Бәйтәниягә килеп җиткәч, Гайсә Лазарның инде дүрт көн буена кабердә ятуын ишетте. [18] Бәйтәния исә Иерусалимга өч чакрым* чамасы гына иде. [19] Абыйлары өчен кайгыручы Марта белән Мәрьямне юатырга байтак яһүдләр килгән иде. [20] Марта, Гайсәнең килүе хакында ишеткәч, Аны каршы алырга чыкты. Мәрьям исә өйдә калды.

---

* **11:18** *Өч чакрым* – грекча сүзгә-сүз: «унбиш стадия».

21 Марта Гайсәгә әйтте:
– Раббым! Син монда булсаң, абыем үлмәгән булыр иде.
22 Әмма хәзер дә беләм: Син Аллаһыдан нәрсә генә сорасаң да,
Ул Сиңа бирәчәк.
23 Гайсә аңа:
– Абыең үледән терелячәк, – диде.
24 – Соңгы көндә – үледән терелү вакытында – аның терелә-
чәген беләм, – диде Марта.
25 Гайсә исә:
– Мин – терелү һәм тормыш. Миңа иман итүче, үлсә дә,
яшәячәк. 26 Яшәүче һәм Миңа иман китерүче һәркем һичкай-
чан үлмәс. Син моңа ышанасыңмы? – диде.
27 Марта Аңа:
– Әйе, Раббым! Синең дөньяга килергә тиеш булган Мәсих,
Аллаһы Улы икәненә ышанам, – диде.
28 Моны әйткәч, Марта китеп барды, һәм, сиздермичә генә
сеңлесе Мәрьямне чакырып:
– Остаз монда, Ул сине чакыра, – диде.
29 Мәрьям, моны ишеткәч тә, тиз генә урыныннан торып,
Гайсә янына китте. 30 Ул вакытта Гайсә әле авылга кермичә,
Марта белән очрашкан урында тора иде. 31 Мәрьям белән бергә
булган юатучы яһүдләр аның җәһәт кенә торып чыгып киткәнен
күрделәр һәм, елау өчен кабер янына китте, дип уйлап, аның
артыннан киттеләр.
32 Мәрьям исә, Гайсә торган урынга килеп җиткәч, Аны күреп:
– Раббым! Син монда булсаң, абыем үлмәгән булыр иде, –
дип, Аның аякларына егылды.
33 Мәрьямнең һәм аның белән килгән яһүдләрнең елауларын
күреп, Гайсә Үзе дә борчылды һәм көенеп:
34 – Сез аны кайда күмдегез? – дип сорады.
Алар Аңа:
– Әйдә, барыйк, Раббым! Үзең күрерсең, – диделәр.
35 Гайсә елады.
36 Моны күреп яһүдләр:
– Карагыз әле, Ул Лазарны ничек яраткан икән! – диештеләр.
37 Ә кайберләре:
– Ул сукырның күзләрен ачкан икән, ник соң Лазарны да
үлемнән алып калу өчен берәр нәрсә эшли алмаган? – диделәр.
38 Гайсә тагын да ныграк көенгән хәлдә кабер янына килде.
Кабер мәгарә булып, аңа керү юлы таш белән бастырып куел-
ган иде.
39 Гайсә:
– Ташны читкә алып куегыз, – диде.

Мәрхүмнең сеңлесе Марта Аңа:

– Раббым! Ул инде исләнгән, чөнки ул үлгәннән соң дүрт көн үтте, – диде.

40 Гайсә аңа:

– «Әгәр иман итсәң, Аллаһының данын күрәчәксең», – дип әйтмәдемме сиңа? – диде.

41 Мәгарә авызыннан ташны алып куйдылар. Гайсә исә, югарыга карап:

– Атам! Мине ишеткәнең өчен Сиңа рәхмәт белдерәм. 42 Мине һәрвакыт ишетүеңне беләм, ләкин бу сүзләремне монда басып торучы кешеләр өчен, Мине Син җибәргәнгә ышансыннар өчен әйтәм, – диде.

43 Шулай дигәннән соң Ул көчле тавыш белән:

– Лазар! Чык! – диде.

44 Шул вакыт үлгән кеше килеп чыкты. Аның куллары һәм аяклары кәфен белән уралган, йөзе яулык белән капланган иде. Гайсә:

– Чишегез аны, йөрсен, – диде.

### *Фарисейләр Гайсәне үтерергә ниятлиләр*

45 Мәрьям янына килгән яһүдләрнең күбесе, Гайсә кылган эшләрне күреп, Аңа иман китерделәр. 46 Ә кайберләре фарисейләр янына барып, аларга Гайсә кылган эшләр турында сөйләделәр. 47 Шунда баш руханилар һәм фарисейләр киңәшмә җыйдылар.

– Безгә нәрсә эшләргә? – диделәр алар. – Бу Кеше күп галәмәтләр күрсәтә. 48 Аны шул көе калдырсак, һәммәсе Аңа иман китерәчәк, һәм римлылар килеп, җиребезне дә, халкыбызны да басып алачак.

49 Аларның берсе – ул елны иң баш рухани булган Кәяфәс аларга:

– Сез бернәрсә дә белмисез! 50 Бөтен халык һәлак булуга караганда, халык өчен бер кешенең үлүе – сезнең өчен хәерлерәк. Сез шуны аңламыйсызмы? – диде.

51-52 Ул моны үзеннән сөйләмәде, бәлки, ул елның иң баш рухание буларак, Гайсәнең яһүд халкы өчен, бу халык өчен генә дә түгел, бәлки, таралып яшәгән Аллаһы балаларын бергә җыю өчен дә үләчәген алдан әйтеп бирде.

53 Шул көннән соң алар Аны үтерергә ниятләделәр. 54 Шуңа күрә Гайсә инде яһүдләр арасында ачыктан-ачык йөрмәде. Ул аннан чүл янындагы бер өлкәгә, Эфраим дигән шәһәргә китте һәм Үзенең шәкертләре белән шунда калды.

[55] Яһүдләрнең Коткарылу бәйрәме якынлашканда, бәйрәм
алдыннан пакьләнергә дип, Иерусалимга илнең төрле поч-
макларыннан күп халык килде. [56] Халык Гайсәне эзләде. Алар
Аллаһы Йортында бер-берсенә:
– Сез ничек уйлыйсыз? Ул бәйрәмгә килер микән? – диеш-
теләр.
[57] Баш руханилар һәм фарисейләр исә, Гайсәне тотып алу
өчен, Аның кайда булуын белгән кешеләр безгә килеп әйтергә
тиеш, дигән әмер бирделәр.

*Гайсәне Бәйтәниядә майлау*

12 [1] Коткарылу бәйрәменә алты көн кала, Гайсә Бәйтә-
ния авылына килде. Ул авылда Гайсә үледән терелткән
Лазар яши иде. [2] Анда Гайсә хөрмәтенә аш мәҗлесе
җыйдылар, Марта хезмәт күрсәтеп йөрде, ә Лазар Гайсә бе-
лән бергә табын артында утыра иде. [3] Мәрьям, нард үсемле-
геннән* ясалган бер кадак бик кыйммәтле хуш исле саф май
алып, Гайсәнең аякларын майлады да үзенең чәче белән
сөртте. Өй эче ислемайның хуш исе белән тулды. [4] Шунда
Гайсәнең шәкертләреннән берсе – Аңа хыянәт итәчәк Яһүд
Искариот:
[5] – Ни өчен бу хуш исле майны, өч йөз динарга сатып, фә-
кыйрьләргә өләшеп бирмәскә иде? – диде.
[6] Ул моны һич тә фәкыйрьләр хакында кайгыртып түгел, бәл-
ки карак булганы өчен әйтте. Уртак акча янчыгын йөртү аның
вазифасы иде. Ул аннан үзенә акча ала торган иде.
[7] Гайсә моңа җавап бирде:
– Калдыр Мәрьямне, ул бу эшне Мине күмү көненә сакла-
ды, [8] фәкыйрьләр һәрвакыт сезнең белән бит, ә Мин сезнең бе-
лән һәрвакыт бергә булмам.
[9] Шул вакытта күп яһүдләр, Гайсәнең Бәйтәниядә икәнлеген
белеп, шунда җыелдылар. Алар Гайсә өчен генә түгел, Ул үле-
дән терелткән Лазарны күрү өчен дә килделәр. [10] Шунлыктан
баш руханилар Лазарны да үтерергә карар чыгардылар, [11] чөнки
аның аркасында күп яһүдләр Гайсә янына килә һәм Аңа иман
китерә иде.

*Гайсә тантана белән Иерусалимга керә*

[12] Икенче көнне бәйрәмгә килгән халык арасында «Гайсә
Иерусалимга килә икән» дигән хәбәр таралды. [13] Халык, хөрмә
ботаклары тотып, Гайсәне каршыларга чыкты һәм:

---

* **12:3** *Нард үсемлеге* – Һиндстанда үсә торган үсемлек.

– Һошанна*!
Раббы исеме белән Килүче
Һәм Исраил Патшасы мөбарәк! –
дип кычкырдылар.
14 Гайсә исә, бер ишәк табып, аңа атланды һәм һәммәсе Изге
язмада язылганча булды:
15 «Сион кызы**, курыкма!
Менә, яшь ишәккә атланып,
Синең Патшаң килә».
16 Аның шәкертләре ул вакытта моны аңламадылар, ә инде
Гайсә данланганнан соң, Аның хакында шулай язылган булуын
һәм Аңа нәкъ шулай эшләүләрен хәтерләренә төшерделәр.
17 Элек Гайсә белән бергә булган кешеләр Аның Лазарны
кабердән чакырып чыгарып, үледән терелтүе турында сөйләп
бирделәр. 18 Аның шундый могҗизалы галәмәт кылганын ишет-
кәнгә, халык Аны каршыларга чыкты.
19 Фарисейләр исә үзара:
– Күрәсезме, безгә бернәрсә дә ярдәм итми. Бөтен дөнья
Аның артыннан бара, – диделәр.

*Гайсә Үзенең үләчәген әйтә*

20 Бәйрәмдә Аллаһыга табыну өчен килүчеләр арасында бер-
ничә грек та бар иде. 21 Алар Гәлиләядәге Бәйтсайдадан булган
Филип янына килеп, аннан:
– Әфәндем! Без Гайсәне күрергә телибез, – дип үтенделәр.
22 Филип бу турыда Әндригә әйтте, аннары алар икәүләп бу
үтенечне Гайсәгә сөйләделәр. 23 Гайсә аларга җавабында:
– Адәм Улының данлану вакыты җитте, – диде. 24 – Сезгә
хак сүз әйтәм: җиргә төшкән бодай бөртеге үлмәсә, шул ки-
леш калыр, ә үлсә, зур уңыш китерер. 25 Үзенең тормышын
яратучы аны һәлак итәчәк, ә бу дөньяда үз тормышын нәф-
рәт итүче аны мәңгелек тормыш өчен саклаячак. 26 Кем Миңа
хезмәт итә, ул Миңа иярсен. Мин кайда булсам, Минем хез-
мәтчем дә шунда булыр. Миңа хезмәт итүчегә Атам ихтирам
күрсәтер.
27 Күңелем Минем хәзер борчулы. Нәрсә әйтим? «Атам! Ми-
не бу сәгатьтән коткар!» – дипме? Ләкин бу сәгатькә Мин нәкъ
шуның өчен килдем дә. 28 Атам! Исемеңне данла.
Шул вакыт күктән:

---

* 12:13 *Һошанна* – яһүд телендә «ярдәм ит» яки «Аллаһыга дан» ди-
гәнне аңлата.
** 12:15 *Сион кызы* – Иерусалим халкы.

– Мин данладым һәм данлаячакмын, – дигән тавыш ишетелде.
[29] Шунда торган һәм моны ишеткән халык:
– Күк күкрәде, – диде.
Кайберләре исә:
– Аңа фәрештә сөйләде, – диделәр.
[30] Моңа каршы Гайсә:
– Бу тавыш Минем өчен түгел, бәлки сезнең өчен килде.
[31] Бу дөнья хәзер хөкем ителә, хәзер бу дөньяның мирзасы*
куып чыгарылачак. [32] Мин җирдән күтәрелгәннән соң барлык
кешеләрне Үземә тартачакмын, – диде.
[33] Ул моны Үзенең нинди үлем белән үләчәген белдереп
әйтте. [34] Халык Аңа җавап бирде:
– Без кануннан Мәсихнең мәңге яшәячәген белдек, ә Син, Адәм Улы күтәрелергә тиеш, дип ничек әйтәсең? Кем Ул – Адәм Улы?
[35] Шунда Гайсә аларга:
– Яктылык сезнең белән бераз вакыт булыр әле. Үзегезне караңгылык басмасын өчен, яктылык бар чагында йөреп калыгыз, чөнки караңгыда йөрүче кая барганын белми. [36] Яктылык
сезнең белән булган чакта яктылыкка иман китерегез, шул чакта сез яктылык балалары булачаксыз, – диде.
Шушы сүзләрне әйткәннән соң Гайсә, китеп, халык күзеннән яшеренде.

*Халыкның Гайсәгә иман китермәве*

[37] Гайсә халык алдында шулкадәр күп могҗизалы галәмәтләр күрсәтсә дә, ул Аңа иман китермәде. [38] Ишагыйя пәйгам-
бәрнең:

«Йа Раббым! Без сөйләгән хәбәргә кем ышанды?
Раббының кодрәте кемгә ачылды?» –

дигән сүзләре тормышка ашты.
[39] Алар иман китерә алмадылар, чөнки Ишагыйя әйткәнчә:
[40] «Ул аларның күзләрен күрмәс итте,
йөрәкләрен таш кебек катырды;
Югыйсә алар күзләре белән күрерләр,
йөрәкләре белән аңларлар,
Миңа таба борылырлар
һәм Мин аларны савыктырыр идем».
[41] Ишагыйя бу сүзләрне Гайсәнең данын күргәнгә әйткән, ул шулай дип Аның турында сөйләгән.

---

* 12:31 *Бу дөньяның мирзасы* – иблис дигән мәгънәгә ия.

42 Хәер, башлыкларның да күбесе Аңа иман китерде, ләкин
алар, фарисейләр гыйбадәтханәдән аерыр дип куркып, икърар
итмәделәр, 43 чөнки Аллаһы данына караганда кешеләр данын
күбрәк яраттылар.
44 Гайсә исә көчле тавыш белән:
– Миңа иман итүче Минем Үземә түгел, бәлки Мине Җибә-
рүчегә иман итә, – диде. 45 – Мине күрүче Мине Җибәрүчене
күрә. 46 Миңа иман итүче караңгылыкта калмасын дип, Мин
дөньяга яктылык булып килдем. 47 Кем дә булса Минем сүзлә-
ремне ишетеп тә үтәми икән, аны хөкем итмим, чөнки Мин
дөньяны хөкем итү өчен түгел, бәлки коткару өчен килдем.
48 Мине кире кагып, сүзләремне кабул итмәүченең үз хөкем
итүчесе бар: аны соңгы көндә Мин әйткән сүз хөкем итәчәк.
49 Мин Үземнән сөйләмәдем, нәрсә сөйләргә, нәрсә әйтергә ки-
рәклеге хакында Мине җибәргән Ата Миңа әмер бирде. 50 Мин
Аның әмеренең мәңгелек тормыш икәнен беләм. Шулай итеп,
Мин нәрсә сөйлим – һәр сүзне Атам кушканча сөйлим.

*Гайсә шәкертләренең аякларын юа*

**13** 1 Коткарылу бәйрәме алдыннан Гайсә, Үзенең бу дөнья-
дан Ата хозурына китү сәгате җиткәнен белеп, дөньяда
булган үзенекеләрен ничек яраткан булса, аларны соң-
гы чиккә кадәр шулай яратуын эш белән күрсәтте.
2 Иблис Шимун Искариот улы Яһүднең күңеленә Гайсәгә
хыянәт итү фикерен салганнан соң, шәкертләре белән кичке
аш ашаган вакытта, 3 Гайсә Атаның һәрнәрсәне Аның кулына
биргәнен һәм Үзенең Аллаһыдан килеп Аллаһы янына китүен
белгәнгә, 4 урыныннан торды да, өс киемен салып, биленә сөл-
ге урады. 5 Һәм ләгәнгә су салып, шәкертләренең аякларын юа
башлады, юган берсен билендәге сөлге белән сөртә барды.
6 Нәүбәт Шимун Петер янына җиткәч, Петер Аңа:
– Раббым! Синме минем аякларымны юасың? – диде.
7 – Син әле хәзер Минем нәрсә эшләвемне аңламыйсың, –
дип җавап бирде Гайсә, – әмма соңыннан аңларсың.
8 – Син минем аякларымны һичкайчан юарга тиеш түгел-
сең, – диде Петер.
– Синең аякларыңны юмасам, Миндә синең өлешең бул-
мас, – дип җавап бирде Гайсә.
9 – Раббым! – диде Шимун Петер. – Аякларымны гына түгел,
кулларымны да, башымны да юа күр.
10 – Юынган кешенең бөтен тәне чиста була. Шуңа күрә аяк-
ларыннан башка аның бүтән җирен юу кирәк түгел, – диде
Гайсә. – Сез чиста, әмма барыгыз да түгел.

[11] Үзенә кемнең хыянәт итәчәген белгәнгә, Ул: «Сезнең барыгыз да чиста түгел», – диде.

[12] Шәкертләренең аякларын юып бетергәч, киемен киеп, Ул
яңадан урынына барып утырды һәм аларга:
– Минем нәрсә эшләгәнемне аңлыйсызмы? [13] Сез Мине
Остаз һәм Раббы дип атыйсыз. Сез хаклы: Мин нәкъ Шулмын.
[14] Шулай итеп, Мин – сезнең Раббыгыз һәм Остазыгыз, сезнең
аякларыгызны юганмын икән, сез дә бер-берегезнең аякларын
юарга тиеш. [15] Сез дә Мин сезгә эшләгән кебек эшләсен дип,
сезгә үрнәк күрсәттем. [16] Сезгә хак сүз әйтәм: хезмәтче үзенең
хуҗасыннан бөегрәк түгел, җибәрелгән дә үзен җибәрүчедән
бөек түгел. [17] Сез хәзер моны беләсез. Белгәнегезне үтисез
икән, сез – бәхетле.

[18] Мин барыгыз турында да әйтмим. Кемнәрне сайлап алга-
нымны беләм, ләкин Изге язмада: «Минем белән бергә икмәк
ашаучы Миңа каршы үкчәсен күтәрде», – дип язылган сүзләр
тормышка ашырга тиеш. [19] Алар тормышка ашкан вакытта сез
Минем мәңге бар* булуыма ышансын өчен, Мин сезгә бу сүз-
ләр тормышка ашканчы ук сөйлим. [20] Сезгә хак сүз әйтәм: Мин
җибәргән кешене кабул итүче Мине кабул итә; Мине кабул
итүче исә Мине Җибәрүчене кабул итә.

*Гайсә хыянәтче Яһүдне фаш итә*

[21] Моны әйткәннән соң Гайсә борчылды һәм шәкертләренә шаһитлек биреп:

– Сезгә хак сүз әйтәм: сезнең берегез Миңа хыянәт итәчәк, – диде.

[22] Шәкертләре исә, Аның кем хакында сөйләвен һич аңла-
мыйча, бер-берсенә караштылар. [23] Аларның берсе – Гайсә-
нең яраткан шәкерте – Аның күкрәгенә терәлеп диярлек уты-
ра иде.

[24] Гайсәнең кем хакында сөйләвен сорарга кушып, Шимун
Петер шул шәкерткә ишарә итте. [25] Теге шәкерт, Гайсәгә тагын
да якынрак килеп, Аннан:
– Раббым, ул кем? – дип сорады.

[26] Гайсә, җавап биреп:
– Мин бер сынык икмәкне кемгә манып бирсәм, ул – шул, –
диде һәм, бер сынык икмәкне манып, Шимун Искариот улы
Яһүдкә бирде. [27] Шул сыныкны кулына алуга ук аның эченә
шайтан керде. Шунда Гайсә Яһүдкә:
– Эшлисе эшеңне тизрәк эшлә, – диде.

---

* **13:19** *Мин мәңге бар* – 8:24 тәге искәрмәне карагыз.

[28] Әмма Гайсәнең аңа ни өчен шулай дип әйтүен анда уты-
ручыларның берсе дә аңламады. [29] Акча янчыгы Яһүдтә бул-
ганлыктан, кайберәүләр: Гайсә аңа бәйрәм өчен безгә кирәк
булган әйберләрне сатып алырга, яки фәкыйрьләргә нәрсә дә
булса бирергә кушкандыр, дип уйладылар. [30] Сыныкны алу бе-
лән Яһүд чыгып китте. Төн иде.

*Яңа әмер бирәм: бер-берегезне яратыгыз*

[31] Яһүд чыгып киткәч, Гайсә әйтте:

– Хәзер Адәм Улы данланды һәм Аның аша Аллаһы дан-
ланды. [32] [Аллаһы Аның аша данлана икән]* Ул да Адәм Улын
Үзендә данлаячак, һәм шунда ук данлаячак.

[33] Балаларым! Мин сезнең белән инде озак булмам. Сез
Мине эзләрсез. Яһүдләргә әйткән сүзләремне сезгә дә әйтәм:
Сез Мин китәчәк урынга килә алмассыз.

[34] Сезгә яңа әмер бирәм: бер-берегезне яратыгыз. Мин сезне
яраткан кебек, сез дә бер-берегезне яратыгыз. [35] Бер-берегезне
яратуыгыздан барысы да сезнең Минем шәкертләрем булуы-
гызны белерләр.

[36] Шимун Петер Гайсәдән:

– Раббым! Син кая китәсең? – дип сорады.

Гайсә аңа:

– Мин китәчәк урынга Син хәзер ияреп бара алмыйсың,
әмма соңыннан киләчәксең, – дип җавап бирде.

[37] – Раббым! Ни өчен Синең артыңнан хәзер бара алмыйм?
Синең өчен җанымны да бирергә әзер, – диде Аңа Петер.

[38] Гайсә аңа:

– Син Минем өчен җаныңны да бирергә әзерме? Сиңа хак
сүз әйтәм: әтәч кычкырганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичә-
чәксең, – диде.

*Мин – юл, хакыйкать һәм тормыш*

**14** [1] – Борчылмагыз! Аллаһыга ышаныгыз һәм Миңа ыша-
ныгыз. [2] Минем Атам йортында торыр урын күп. Әгәр
дә алай булмаса, Мин сезгә әйткән булыр идем. Мин
сезгә урын әзерләргә барам. [3] Барып урын әзерләгәч, сез дә
Мин булган урында булсын өчен, янә килеп, сезне Үз яныма
алачакмын. [4] Мин бара торган урынга сез юлны беләсез.

[5] Томас Гайсәгә:

– Раббым! Кая баруыңны белмибез, шулай булгач, анда бару
юлын каян белик инде? – диде.

---

* 13:32 Кайбер кульязмаларда җәяләр эчендәге сүзләр дә бар.

6 Гайсә аңа:
– Мин – юл, хакыйкать һәм тормыш. Минем аркылы үтмичә,
Атам янына беркем дә килә алмаячак. 7 Мине беләсез икән,
Минем Атамны да белерсез. Шушы вакыттан башлап, сез Аны
беләсез һәм Аны күрдегез, – дип әйтте.
8 – Раббым! Безгә Атаны күрсәт һәм без канәгать булырбыз, –
диде Аңа Филип.
9 – Филип, Мин никадәр вакыт сезнең белән бергә булып та
син Мине белмисеңме? – диде Гайсә. – Мине күргән кеше
Атаны да күргән була. Ничек инде син: «Безгә Атаны күрсәт», –
дисең? 10 Минем Атада, Атаның Миндә икәнлегенә ышанмый-
сыңмы? Сезгә сөйләгән сүзләрне Мин Үземнән сөйләмим, ә
Миндәге Ата Үзенең эшләрен башкара. 11 «Мин Атада һәм Ата
Миндә», – дигән сүзләремә ышаныгыз. Мин әйткән сүзләр-
гә ышанмыйсыз икән, эшләгән эшләрем хакына ышаныгыз.
12 Сезгә хак сүз әйтәм: Миңа иман итүче Мин башкарган эшләр-
не һәм аларга караганда да бөегрәк эшләрне башкарыр, чөнки
Мин Атам янына барам. 13 Ата Улында данлансын өчен, Минем
исемем белән нәрсә генә сорасагыз да, эшләрмен. 14 Минем исе-
мем белән Миннән нәрсә сорасагыз да, Мин аны эшләрмен.

*Гайсә вәгъдә иткән Изге Рух*

15 – Мине яратсагыз, Минем әмерләремне үтәрсез. 16 Мин
Атадан сораячакмын, һәм Ул сезгә бүтән Яклаучы-Юатучы
бирәчәк, Ул Яклаучы мәңге сезнең белән булачак. 17 Ул Як-
лаучы-Юатучы – хакыйкать Рухы. Дөнья Аны күрмәгәнгә һәм
белмәгәнгә кабул итә алмый, ә сез Аны беләсез, чөнки Ул сез-
нең белән калачак һәм сездә булачак.
18 Сезне ятим калдырмаячакмын, Мин сезнең янга киләчәк-
мен. 19 Бераздан дөнья Мине күрмәячәк, ә сез күрәчәксез. Мин
яшәгәнгә, сез дә яшәячәксез. 20 Сез ул көнне, Мин – Атамда,
сез – Миндә һәм Мин сездә икәнлекне беләчәксез. 21 Минем
әмерләремне кабул итеп, аларны үтәгән кеше Мине ярата.
Мине яраткан кешене Атам да яратыр, Мин дә яратырмын һәм
аңа Үземне күрсәтермен.
22 Яһүд (Яһүд Искариот түгел) Аннан:
– Раббым! Ни өчен Син Үзеңне дөньяга түгел, ә безгә күрсә-
тергә телисең? – дип сорады.
23 Гайсә аңа җавабында:
– Мине яратучы Минем сүзләремне тотар. Атам аны яратыр
һәм Без, аның янына килеп, аның белән бергә яшәрбез. 24 Ми-
не яратмаучы Минем сүзләремне тотмый, ә сез ишетә торган
сүз Миннән түгел, бәлки Мине җибәргән Атадан, – дип әйтте
һәм, дәвам итеп:

[25] – Мин сезгә боларны сезнең белән бергә булганда ук әйт-
тем. [26] Ә Минем исемемнән Ата җибәрәчәк Яклаучы-Юатучы –
Изге Рух – сезне һәрнәрсәгә өйрәтәчәк һәм Мин сезгә сөйлә-
гәннәрнең һәммәсен дә хәтерегезгә төшерәчәк, – диде.
[27] Сезгә тынычлык калдырам, Үземнең тынычлыгымны сезгә
бирәм, әмма сезгә биргәнем дөнья биргән кебек түгел. Күңеле-
гез борчылмасын һәм курыкмасын. [28] «Сездән китәм һәм сезгә
киләчәкмен», – дигәнемне ишеттегез. Мине яратсагыз, Атам
янына баруыма куаныр идегез, чөнки Атам Миннән бөегрәк.
[29] Мин сезгә бу сүзләрне ул хәл тормышка ашканда сез ышан-
сын өчен хәзер сөйләдем. [30] Сезнең белән күп сөйләшмәм инде,
чөнки бу дөньяның мирзасы килә. Аның Миндә һичнәрсәсе
юк. [31] Әмма дөнья белсен: Мин Атаны яратам һәм, Ата Миңа
нинди әмер биргән булса, Мин шуны башкарам.
– Торыгыз, моннан китик, – диде.

*Гайсә – чын йөзем агачы*

15 [1] – Мин – чын йөзем агачы, ә Минем Атам – Йөзем үс-
терүче. [2] Ул Миндәге җимеш бирми торган һәр ботакны
кисеп ташлый һәм, күбрәк җимеш бирсен өчен, җимеш
бирә торган һәр ботакны чистарта. [3] Сезгә сөйләгән сүзем аша
сез инде чистартылдыгыз. [4] Миндә торыгыз, һәм Мин сездә то-
рырмын. Йөзем агачында булмаган ботак үзеннән үзе җимеш
бирә алмаган кебек, Миндә тормасагыз, сез дә җимеш бирә ал-
массыз.
[5] Мин – йөзем агачы, ә сез – ботаклар. Кем Миндә торса
һәм Мин аңарда торсам – ул күп җимеш бирер, чөнки Миннән
башка бернәрсә дә эшли алмассыз. [6] Кем Миндә тормаса, аны,
ботак кебек кисеп, читкә ташларлар һәм ул корып бетәр, ә ан-
дый ботакларны җыялар да утка ташлыйлар һәм яндыралар.
[7] Сез Миндә торсагыз һәм Минем сүзләрем сездә торса, ул чак-
та теләгән нәрсәгезне сорагыз, һәм ул сезгә бирелер. [8] Күп җи-
меш китереп, сез Минем шәкертләрем булырсыз, һәм моның
белән Минем Атам данланыр.
[9] Атам Мине яраткан кебек, Мин дә сезне яратам. Минем
мәхәббәтемдә торыгыз. [10] Мин, Атамның әмерләрен үтәп,
Аның мәхәббәтендә торам, һәм сез дә, Минем әмерләремне
үтәсәгез, Минем мәхәббәтемдә калырсыз. [11] Куанычым сездә
булсын һәм сезнең куанычыгыз тулы булсын дип, Мин болар-
ны сезгә сөйләдем.
[12] Минем әмерем шушы: Мин сезне яраткан кебек, сез дә
бер-берегезне яратыгыз. [13] Дуслары өчен җанын биргән ке-
шенең яратуыннан да бөек ярату юк. [14] Әмерләремне үтәсәгез,

сез – Минем дусларым. 15 Инде сезне хезмәтчеләрем дип ата-
мыйм, чөнки хезмәтче хуҗасының нәрсә эшләвен белми, ә
сезне дусларым дип атадым, чөнки Атамнан ишеткәннәрнең
һәммәсен сезгә белдердем. 16 Мине сез сайламадыгыз, бәлки
Мин сезне сайладым: сез барып җимеш бирсен һәм җимешегез
даими булсын дип, сезне билгеләп куйдым. Шулай итеп, Минем
исемем белән Атадан нәрсә генә сорасагыз да, Ул аны сезгә
бирәчәк. 17 Сезгә әмерем шул: бер-берегезне яратыгыз.

*Дөньяның нәфрәте*

18 – Дөнья сезне нәфрәт итә икән, исегездә тотыгыз: сездән
элек ул Мине нәфрәт итте. 19 Сез дөньяныкы булсагыз, дөнья
сезне үзенекеләре итеп яратыр иде. Ләкин сез дөньядан түгел,
бәлки Мин сезне дөньядан сайлап алдым, дөнья сезне шуңа
нәфрәт итә. 20 «Хезмәтче үзенең хуҗасыннан өстен түгел», –
дигән сүзләремне хәтерләгез. Мине эзәрлекләгәннәр икән,
сезне дә эзәрлекләрләр. Минем сүземне тотканнар икән, сез-
некен дә тотарлар. 21 Алар боларның барысын да сез Минеке
булганлыктан эшләрләр, чөнки Мине Җибәрүчене белмиләр.
22 Мин килеп аларга сөйләмәгән булсам, аларның гөнаһта гаеп-
ләре булмас иде, ә хәзер гөнаһларын акларлык чаралары юк.
23 Мине нәфрәт итүче Атамны да нәфрәт итә. 24 Башка беркем
дә эшләмәгән эшләрне алар арасында күрсәтмәгән булсам,
аларның гөнаһта гаепләре булмас иде; ә хәзер күрделәр һәм
Миңа да, Атама да нәфрәтләнделәр. 25 Әмма аларның канунын-
да: «Алар Миңа бер сәбәпсезгә нәфрәтләнделәр», – дип язылган
сүзләр тормышка ашсын өчен бу шулай булды.

26 Мин Атадан сезгә Яклаучы-Юатучы җибәрәчәкмен. Ул –
Атадан чыккан хакыйкать Рухы – килгәч, Минем хакта
шаһитлек бирәчәк. 27 Сез дә шаһитлек бирерсез, чөнки сез
баштан ук Минем белән булдыгыз.

16 1 – Мин боларны сез вәсвәсәгә бирелмәсен өчен сөй-
ләдем. 2 Сезне гыйбадәтханәләрдән аерырлар. Хәтта
шундый вакыт килер: ул вакытта сезне үтерүче һәркем
Аллаһыга шуның белән хезмәт итәм дип уйлар. 3 Һәм шулай
эшләрләр, чөнки алар Атаны да, Мине дә якыннан белмәде-
ләр. 4 Моны сезгә шуның өчен әйттем: ул вакыт җиткәч, сез ул
хакта сөйләгәнемне исегезгә төшерерсез. Мин боларны сезгә
башта ук сөйләмәдем, чөнки сезнең белән бергә булдым.

*Яклаучының килүе*

5 Ә хәзер Мин Үземне Җибәрүче янына барам, һәм сезнең
берегез дә Миннән: «Кая барасың?» – дип сорамый. 6 Мин сезгә

боларны сөйләгәнгә күрә, сезнең күңелегез кайгы белән тулды.
[7] Әмма Мин хак сүз әйтәм: Минем китүем сезнең өчен хәерле-
рәк. Чөнки Мин китмәсәм, сезгә Яклаучы-Юатучы килмәячәк,
ә китсәм, Мин Аны сезгә җибәрәчәкмен. [8] Ул килгәч, дөньяны
гөнаһка, хаклыкка һәм хөкемгә карата фаш итәчәк: [9] гөнаһка
карата, чөнки кешеләр Миңа иман итмиләр; [10] хаклыкка карата,
чөнки Мин Атам янына барам һәм сез инде Мине бүтән күр-
мәссез; [11] хөкемкә карата, чөнки инде бу дөньяның мирзасы
хөкем ителде.

[12] Сезгә сөйлисе сүзләрем бик күп, әмма сез аларны хәзер ка-
бул итә алмассыз. [13] Ул – хакыйкать Рухы – килгәч, сезгә тулы
хакыйкатькә юл күрсәтеп торачак. Ул сезгә Үзеннән түгел, бәл-
ки ишеткәнен сөйләячәк һәм булачак хәлләрне белдерәчәк.
[14] Ул, Миннән кабул иткән сүзләрне сезгә сөйләп, Мине данла-
ячак. [15] Атаныкы булган барлык нәрсәләр – Минеке; Мин
шуңа күрә: «Миннән кабул иткән сүзләрне Изге Рух сезгә бел-
дерәчәк», – дидем.

*Шәкертләрнең кайгысы шатлыкка әйләнер*

[16] – Сез Мине бераздан инде күрмәячәксез, һәм янә бераздан
Мине күрәчәксез.

[17] Шуннан соң Аның кайбер шәкертләре бер-берсенә:

– «Бераздан сез Мине күрмәячәксез, һәм янә бераздан Мине
күрәчәксез», һәм: «Мин Атам янына барам», – дип әйтүе нәр-
сәне аңлата икән? [18] «Бераздан» дигәне нәрсә икән? Аның
нәрсә сөйләгәнен аңламыйбыз! – диештеләр.

[19] Үзеннән нәрсә турында сорарга теләгәннәрен белеп, Гайсә
аларга:

– Сез Минем: «Мине бераздан күрмәячәксез, һәм янә бе-
раздан Мине күрәчәксез», – дигән сүзләрем хакында бер-бе-
регездән сорашасызмы? [20] Сезгә хак сүз әйтәм: сез еларсыз,
үкереп еларсыз, ә дөнья шатланыр; сез кайгырырсыз, әмма
кайгыгыз шатлыкка әйләнер. [21] Вакыты җиткәч, бала тудыру-
чы хатын җәфа чигә, әмма сабыен тудыргач, баланың дөнья-
га килүенә шатланып, газаплануын оныта. [22] Шуның кебек
сез дә хәзер кайгырасыз; әмма Мин сезне тагын күрәчәкмен,
һәм сезнең күңелегез куаначак, һәм куанычыгызны сездән
беркем дә ала алмаячак. [23] Ул көнне сез Миннән бернәрсә
турында да сорамаячаксыз. Сезгә хак сүз әйтәм: Минем исе-
мем белән Атадан нәрсә генә сорасагыз да, Ул сезгә бирә-
чәк. [24] Моңарчы сез Минем исемем белән бернәрсә дә сора-
мадыгыз. Сорагыз һәм алырсыз, һәм сезнең куанычыгыз ту-
лы булыр.

*Кыю булыгыз: Мин дөньяны җиңдем*

[25] Моңарчы Мин сезгә кинаяләр белән сөйләдем; ләкин
вакыт җитәр, Мин сезгә инде кинаяләр белән сөйләмәм, бәл-
ки Ата хакында ачык итеп әйтермен. [26] Ул көнне сез Минем
исемем белән сорарсыз. «Сезнең өчен Атадан үтенермен», –
димим, [27] чөнки сез Мине ятканга һәм Минем Аллаһыдан
килгән булуыма ышанганга, Ата Үзе сезне ярата. [28] Мин дөнья-
га Атадан килдем; һәм менә яңадан, дөньяны калдырып, Ата
янына китәм.
[29] Шәкертләре Аңа:
– Менә хәзер Син кинаяләр белән түгел, ә ачык итеп сөйли-
сең. [30] Хәзер без Синең һәрнәрсәне белүеңне һәм, хәтта, Сиңа
сорауны сүзләр белән әйтергә дә кирәк түгеллеген күрәбез.
Менә шуңа күрә без Синең Аллаһыдан килгән булуыңа ышана-
быз, – диделәр.
[31] Гайсә аларга җавап бирде:
– Сез хәзер ышанасызмы? [32] Менә вакыт җитә һәм җитте дә
инде: сез таралып, һәрберегез үз өйләренә китәчәк. Сез Мине
ялгыз калдырачаксыз. Ләкин Мин ялгыз түгел, чөнки Ата
Минем белән.
[33] Мин моны тынычлыгыгыз Миндә булсын дип сөйләдем.
Дөньяда кайгыларыгыз булыр, ләкин кыю булыгыз: Мин дөнь-
яны җиңдем.

*Гайсәнең догасы*

**17** [1] Гайсә бу сүзләрдән соң күккә күтәрелеп карап:
– Атам! Вакыт җитте, – диде. – Улың Сине данласын
өчен Улыңны данла. [2] Син Аңа биргән кешеләрнең
барысына да Ул мәңгелек тормыш бирсен өчен, Аңа бөтен ке-
шеләр өстеннән хакимлек бирдең. [3] Сине, бердәнбер хак Алла-
һыны, һәм Син җибәргән Гайсә Мәсихне танып белү – шул
мәңгелек тормыштыр.
[4] Син тапшырган эшләрне башкарып чыгып, Мин Сине җирдә
данладым. [5] Хәзер Син, Атам, дөнья ятылганга кадәр Минем
Синең белән булгандагы даным белән Үз яныңда Мине данла.
[6] Син дөньядан Миңа биргән кешеләргә Синең исемеңне
ачып бирдем. Алар Синеке иде, Син исә аларны Миңа бирдең.
Алар Синең сүзеңне тоттылар һәм [7] хәзер Син Миңа биргән
бар нәрсәнең Синнән икәнлеген беләләр. [8] Чөнки Миңа әйт-
кән сүзләреңне аларга җиткердем, алар кабул иттеләр. Һәм
Минем чынлап та Синнән килүемне танып, Мине Син җибәр-
гәнгә ышандылар.

[9] Мин алар өчен үтенәм. Бөтен дөнья өчен түгел, бәлки Син
Миңа биргәннәр өчен үтенәм, чөнки алар – Синеке. [10] Минем
бөтен нәрсәм Синеке, ә Синекеләр – Минеке. Мин алар аркы-
лы данландым.
[11] Мин инде дөньяда түгел, ә алар әле дөньяда. Мин Синең
янына барам. Изге Атам! Без бер булган кебек, алар да бер бул-
сын өчен, аларны Үз исемең белән, Син Миңа биргән исемең
белән саклап тор. [12] Алар белән бергә дөньяда булганда, Мин
аларны Синең исемең белән – Син Миңа биргән исем белән –
саклап тоттым. Мин аларны сакладым, һәм Изге язмада язылган
сүзләр тормышка ашсын өчен, һәлак булырга тиешлесеннән
башка берсе дә югалмады.
[13] Хәзер исә Мин Синең янына барам. Мин бу сүзләрне,
аларда куанычым тулы булсын өчен, дөньяда чакта сөйлим.
[14] Мин аларга Синең сүзеңне җиткердем. Дөнья аларга нәф-
рәтләнде, чөнки Мин дөньядан булмаган кебек, алар да
дөньядан түгел. [15] Аларны дөньядан алуыңны түгел, бәлки
явызлыктан саклавыңны үтенәм. [16] Мин дөньядан булмаган
кебек, алар да дөньядан түгел. [17] Аларны Үз хакыйкатеңдә
изге ит*. Синең сүзең – хакыйкать. [18] Син Мине дөньяга
җибәргән кебек, Мин дә аларны дөньяга җибәрдем. [19] Алар
да хакыйкатьтә изге ителсеннәр* дип, Үземне алар хакына
изге итәм*.
[20] Мин алар өчен генә түгел, бәлки аларның сүзе аркылы
Миңа иман китерүчеләр өчен дә үтенәм: [21] бөтенесе бер бул-
сын. Атам, Син Миндә һәм Мин Синдә булган кебек, Мине
Син җибәргәнгә дөнья ышансын өчен, алар да Бездә булсын-
нар. [22] Син Миңа биргән данны аларга җиткердем: Без бер бул-
ган кебек, алар да бер булсыннар. [23] Мин – аларда, Син –
Миндә. Мине җибәргән булуыңны һәм Мине яраткан кебек
аларны да яратуыңны дөнья танысын өчен, алар бөтен килеш
бер булсыннар.
[24] Атам! Син Миңа биргән кешеләрнең Мин булачак урын-
да Минем белән бергә булуларын телим. Син Мине дөнья
яратылганга кадәр үк сөйгәнгә күрә, алар Син Миңа биргән
данны күрсеннәр иде. [25] Гадел Атам! Дөнья Сине белми, ә
Мин беләм, һәм алар да Мине Син җибәргәнне беләләр.
[26] Миңа булган мәхәббәтең аларда да булсын һәм Үзем дә алар-
да булыйм дип, Синең исемеңне аларга белдердем һәм белде-
рәчәкмен.

---

* [17:17, 19] Грек телендә «һагиазо» дигән сүз «изге итү» һәм «багышлау, изге эшкә аеру» дигән мәгънәләргә ия.

### *Гайсәне кулга алу*

**18** 1 Бу сүзләрне әйткәннән соң, Гайсә, шәкертләре белән
Кыдрун инешенең аръягына чыгып, шундагы бакчага
керде. 2 Гайсә шәкертләре белән еш кына шунда җыел-
ганлыктан, ул урынны Аңа хыянәт итәчәк Яһүд тә белә иде.
3 Яһүд гаскәри төркем һәм дә баш руханилар вә фарисейләр
җибәргән тәртип саклаучылар белән бергә шунда килде. Алар үз-
ләре белән факеллар, яктырткычлар һәм кораллар алганнар иде.
4 Гайсә исә, Үзе белән булачак һәр нәрсәне белеп, алгарак
чыкты һәм алардан:
– Кемне эзлисез? – дип сорады.
5 Алар Аңа:
– Насаралы Гайсәне, – дип җавап бирделәр.
Гайсә аларга:
– Ул – Мин, – диде.
Хыянәтче Яһүд тә алар белән шунда тора иде. 6 Гайсә: «Ул –
Мин», – дигәч, алар артка чигенеп, җиргә егылдылар.
7 Ул янә:
– Кемне эзлисез? – дип сорады.
Алар:
– Насаралы Гайсәне, – диделәр.
8 Гайсә җавап бирде:
– Мин инде сезгә: «Ул – Мин», – дип әйттем бит. Сез Мине
эзлисез икән, минем белән булган кешеләрне чыгарып җи-
бәрегез.
9 Ул: «Син Миңа биргәннәрнең берсен дә югалтмадым», –
дигән сүзләр тормышка ашсын өчен шулай дип әйтте.
10 Шимун Петернең кылычы бар иде. Ул аны тартып чыгарды
һәм иң баш руханиның хезмәтчесенә селтәнеп, аның уң кола-
гын чабып өзде. Ул хезмәтченең исеме Мәлик иде. 11 Әмма
Гайсә Петергә:
– Кылычыңны кынына тыгып куй. Атам биргән касәне Мин
эчмәм дип уйлыйсыңмы әллә? – диде.
12 Гаскәриләр, аларның башлыгы һәм яһүдләрнең тәртип сак-
лаучылары Гайсәне тотып бәйләделәр. 13 Башта Аны шул елның
иң баш рухание булган Кәяфәснең каенатасы Һаннас янына
алып бардылар. 14 Яһүдләргә: «Халык өчен бер кешенең үлүе хә-
ерлерәк», – дип киңәш биргән кеше шул Кәяфәс иде.
15 Шимун Петер һәм тагын бер шәкерт Гайсә артыннан бар-
дылар. Бу шәкерт исә иң баш рухани белән яхшы мөнәсәбәттә
булганга күрә, Гайсә белән иң баш руханиның ишегалдына ке-
рә алды. 16 Ә Петер тышкы якта ишек артында басып калды.

Аннары иң баш рухани белән яхшы мөнәсәбәттә булган теге
шәкерт чыкты да, ишек саклаучы хезмәтче кызга әйтеп, Петер-
не эчкә алып керде. 17 Шунда ишек саклаучы хезмәтче кыз
Петердән:

– Син дә бу Кешенең шәкертеме әллә? – дип сорагач, ул:

– Юк, – дип җавап бирде.

18 Салкын булганлыктан хезмәтчеләр һәм тәртип саклаучылар
учак ягып җылынып торалар иде. Петер дә алар белән бергә
җылынып торды.

19 Иң баш рухани исә Гайсәдән Аның шәкертләре хакында
һәм нәрсәләргә өйрәтүе турында сорашты. 20 Гайсә аңа:

– Мин дөньяга ачык сөйләдем. Һәрвакыт яһүдләр җыела
торган гыйбадәтханәдә һәм Аллаһы Йортында өйрәттем һәм
яшеренеп һичнәрсә сөйләмәдем. 21 Нигә Миннән сорыйсың?
Мин сөйләгәннәрне ишеткән кешеләрдән сора. Мин нәрсә
сөйләгәнне алар беләләр, – дип җавап бирде.

22 Гайсә шулай дигәч, Аның янында торган тәртип саклаучы-
ларның берсе, Аның яңагына сугып:

– Иң баш руханига Син шулай җавап бирәсеңме? – диде.

23 Гайсә аңа:

– Мин ялган сөйләгән булсам, ялган икәнен исбат ит, ә дөре-
сен сөйләгәнмен икән, нигә Миңа сугасың? – дип җавап бирде.

24 Һаннас Аны, бәйләнгән хәлдә, иң баш рухани Кәяфәс
янына җибәрде.

25 Җылынып торганда Шимун Петердән:

– Син дә Аның шәкертләренең берсе түгелме? – дип сора-
дылар.

Ул:

– Юк, – дип ваз кичте.

26 Иң баш рухани хезмәтчеләренең берсе, Петер колагын ча-
бып өзгән кешенең туганы, аңа:

– Мин сине Аның белән бергә бакчада күрдем түгелме соң? –
диде.

27 Петер тагын ваз кичте. Нәкъ шул вакыт әтәч кычкырды.
28 Гайсәне Кәяфәс яныннан идарәче Пилат сараена алып кил-
деләр. Бу хәл иртә белән булды. Коткарылу бәйрәменең ашын
ашарга мөмкин булсын өчен, пакьләнүләре бозылмасын дип,
яһүд башлыклары идарәче сараена кермәделәр. 29 Идарәче
Пилат, алар янына чыгып:

– Сез бу Кешене нәрсәдә гаеплисез? – дип сорады.

30 Алар аңа:

– Ул җинаятьче булмаса, Аны сиңа тотып китермәгән булыр
идек, – дип җавап бирделәр.

31 Пилат аларга:
– Аны кануныгыз буенча үзегез хөкем итегез, – диде.
Яһүдләр аңа:
– Безгә беркемне дә үлемгә дучар итү хокукы бирелмәгән, – диделәр.
32 Бу Гайсәнең Үзенең нинди үлем белән үләчәгенә ишарә итеп әйткән сүзе тормышка ашсын өчен әйтелде.
33 Шунда Пилат яңадан сараена керде һәм, Гайсәне чакыртып, Аннан:
– Син яһүдләр Патшасымы? – дип сорады.
34 Гайсә аңа:
– Син моны үзеңнән генә әйтәсеңме, яки Минем хакта сиңа башкалар сөйләдеме? – диде.
35 Пилат әйтте:
– Әллә мин яһүдме? Сине миңа Синең халкың һәм баш руханилар тапшырды. Син нәрсә эшләдең?
36 – Минем Патшалыгым бу дөньяныкы түгел. Әгәр Патшалыгым бу дөньяныкы булса, хезмәтчеләрем яһүдләр кулына тапшырылмавым өчен көрәшкән булырлар иде, әмма Минем Патшалыгым бу дөньяныкы түгел, – дип җавап бирде Гайсә.
37 Пилат Аңа:
– Димәк, Син – Патша? – диде.
Гайсә җавап биреп:
– Син Мине Патша дип әйтәсең. Мин хакыйкать хакында шаһитлек бирү өчен тудым, Мин шуның өчен дөньяга килдем дә. Хакыйкатьтән булган һәркем Мине тыңлый, – диде.
38 Пилат Аннан:
– Нәрсә ул – хакыйкать? – дип сорады.
Шуннан соң ул яңадан яһүдләр янына чыгып:
– Мин Аны гаепләрлек бер сәбәп тә күрмим, – диде. –
39 Сезнең гореф-гадәтегез буенча, Коткарылу бәйрәмендә мин сезгә бер тоткынны азат итәргә тиешмен. Яһүдләр Патшасын азат итүемне телисезме?
40 Шунда барысы да:
– Аны түгел, Барабны чыгар! – дип кычкырдылар.
Бараб исә юлбасар иде.

*Гайсәнең үлемгә хөкем ителүе*

**19** 1 Шуннан соң Пилат Гайсәне камчы белән суктырырга
кушты. 2 Гаскәриләр Аның башына күгән агачы чы-
быкларыннан таҗ үреп куйдылар, өстенә куе кызыл
төстәге япанча кидерделәр, 3 һәм берсе артыннан берсе Аның
янына килеп:

– Яшәсен яһүдләр Патшасы! – дип яңакларына суктылар.
[4] Пилат, янә чыгып, халыкка әйтте:
– Карагыз, Аңарда бернинди гаеп тапмавымны белдерү өчен Аны сезнең янга чыгарам.
[5] Башына чәнечкеле таж, өстенә япанча кигән Гайсә чыкты. Пилат аларга:
– Менә – Кеше! – диде.
[6] Баш руханилар һәм тәртип саклаучылар Аны күргәч:
– Хачка* кадакла, кадакла Аны! – дип кычкырдылар.
Пилат аларга:
– Аны үзегез кадаклагыз, чөнки мин Аңарда бернинди гаеп тапмыйм, – диде.
[7] Яһүдләр аңа:
– Безнең кануныбыз бар, канун буенча Ул үләргә тиеш, чөнки Ул Үзен Аллаһы Улы дип атый, – дип җавап бирделәр.
[8] Бу сүзләрне ишеткәннән соң Пилат бигрәк тә куркуга
төште, [9] һәм, янә сарайга кереп, Гайсәдән:
– Син кайдан? – дип сорады.
Әмма Гайсә аңа җавап бирмәде.
[10] Пилат Аңа:
– Миңа җавап бирәсең килмиме? Сине хачка кадаклатырга да, азат итәргә дә хокукым барлыгын белмисеңме әллә? – диде.
[11] Гайсә җавап биреп:
– Синә югарыдан бирелмәгән булса, Минем өстән һичбер хакимлегең булмас иде, шуңа күрә Мине сиңа тапшырган кешенең гөнаһы синекеннән зуррак, – диде.
[12] Шуннан соң Пилат Аны азат итәргә теләде. Яһүдләр исә:
– Аны җибәрсәң, ул чакта син кайсарның** дусты түгелсең; үзен-үзе патша итүче һәркем – кайсарның дошманы, – дип кычкырдылар.
[13] Бу сүзләрне ишеткәч, Пилат, Гайсәне чыгарып, «Таш басма» (яһүдчә Габбата) дип аталган җирдәге хөкем итү урынына барып утырды.
[14] Бу көн Коткарылу бәйрәменә әзерләнә торган җомга көн, көндезге сәгать уникеләр тирәсе иде. Пилат яһүдләргә:
– Менә сезнең Патшагыз! – диде.
[15] Ә алар:

---

* **19:6** *Хач* – Ул чорда кешеләрне җәзалап үтерү өчен кулланыла торган, бер-берсенә туры почмаклап кагып куелган ике бүрәнә. Ул җайланманы «тәре» дип тә атыйлар.
** **19:12** *Кайсар* – борынгы Рим императорының рәсми исемнәреннән берсе.

– Алып кит Аны, олаксын! Хачка кадакла! – дип кычкырдылар.
– Патшагызны кадаклыйммыни? – диде Пилат.
Баш руханилар:
– Безнең кайсардан башка патшабыз юк, – дип җавап бирделәр.
16 Ниһаять, кадакларга дип, Пилат Аны аларга тапшырды. Алар Гайсәне алып киттеләр.

*Гайсәне хачка кадаклау*

17 Үзенең хачын күтәреп, Гайсә, «Баш сөяге», ягъни яһүдчә
Гөлгетә дип аталган урынга килеп җитте. 18 Аны һәм Аның бе-
лән бергә тагын ике кешене, берсен Гайсәнең бер ягына, икен-
чесен икенче ягына, хачка кадакладылар. 19 Пилат кушканча язу
язып, хач өстенә кактылар. Ул язуда: «Насаралы Гайсә – яһүд-
ләр Патшасы», дип язылган иде. 20 Ул язуны күп яһүдләр укыды,
чөнки Гайсә хачка кадакланган урын шәһәргә якын иде, һәм
ул язу яһүдчә, грекча һәм латинча язылган иде. 21 Яһүдләрнең
баш руханилары Пилатка әйттеләр:
– «Яһүдләр Патшасы», – дип түгел, бәлки, «Ул Үзен: „Мин – яһүдләр Патшасы“, – диде», – дип яз.
22 Пилат:
– Мин нәрсә яздым, шул язылды инде, – дип җавап бирде.
23 Гаскәриләр исә, Гайсәне хачка кадаклагач, Аның киемнә-
рен алып һәр гаскәригә бер өлеш итеп дүрткә бүлделәр һәм ча-
панын да алдылар; чапан исә тегелмәгән, ә бербөтен тукыма-
дан иде. 24 Шулай итеп, алар бер-берсенә:
– Моны ертмыйк, ә жирәбә салыйк, кемгә чыгар, – диделәр.
Бу Изге язмадагы: «Алар киемнәремне бүлештеләр, күлмәгем өчен жирәбә салыштылар», – дип язылган сүзләр тормышка ашсын өчен булды. Гаскәриләр нәкъ шулай эшләделәр.
25 Гайсә кадакланган хач янында Аның анасы, анасының сең-
лесе, Клопас хатыны Мәрьям һәм Магдалалы Мәрьям басып
торалар иде. 26 Гайсә, анасын һәм шунда торган сөекле шәкер-
тен күреп, анасына:
– Ханым! Менә бу – синең улың, – диде.
27 Аннары шәкерткә:
– Менә бу – синең анаң! – дип әйтте.
Шәкерт шуннан соң аны үз өенә алды.

*Гайсәнең үлеме*

28 Шуннан соң Гайсә, һәрнәрсәнең чынга ашканын белеп,
һәм Изге язмада язылганнар тормышка ашсын дип:

– Сусадым, – диде.
[29] Шунда шәраб серкәсе салынган савыт тора иде. Гаскәриләр, губка кисәген серкәгә манчып, аны һүссөп* ботагына элеп, Аның авызына китерделәр.
[30] Гайсә серкәне татыгач:
– Чынга ашты! – диде һәм, башын иеп, җан бирде.
[31] Бу көн бәйрәм алдындагы җомга көн булганлыктан, яһүдләр гәүдәләрне шимбә көнгә хачта калдырмас өчен, – чөнки ул шимбә бөек көн иде, – аларның аякларын сындырып, аларны хачтан төшерергә Пилаттан рөхсәт сорадылар.
[32] Шуннан гаскәриләр килеп, Гайсә белән бергә кадакланганнарның башта берсенең, аннан икенчесенең аякларын сындырдылар.
[33] Әмма Гайсә янына килгәч, Аның инде үлгән булуын күрделәр һәм шуңа күрә аякларын сындырмадылар,
[34] ә бер гаскәри Аның кабыргасына сөңге белән чәнчеде. Аннан кан белән су агып чыкты.
[35] Бу хәлләрне күргән кеше, сез иман итсен дип, шул хакта шаһитлек бирде. Аның шаһитлеге хак һәм ул хакыйкатьне сөйләвен белә.
[36] Чөнки бу хәл Изге язмада: «Аның һичбер сөяге сынмас», – дип язылган сүзләр тормышка ашсын өчен булды.
[37] Изге язманың башка бер урынында: «Алар үзләре чәнчегән Затка карарлар», – дип тә язылган.

*Гайсәне кабергә салу*

[38] Шуннан соң, яһүдләрдән курыкканга күрә, Гайсәнең шәкерте булуын яшереп йөргән ариматайлы Йосыф Пилаттан Гайсәнең гәүдәсен алырга рөхсәт сорады; Пилат рөхсәт бирде. Йосыф Гайсәнең гәүдәсен хачтан барып алды.
[39] Элегрәк төнлә Гайсә янында булган Никәдим дә килде һәм үзе белән йөз кадакка якын мирра** белән алоэ кушып ясалган хушбуй китерде.
[40] Шулай итеп, алар, Гайсәнең гәүдәсен алып, яһүдләрнең күмү йоласы буенча, Аны хушбуй сөртелгән кәфенгә урадылар.
[41] Гайсә хачка кадакланган җирдә бер бакча, ә бакчада әле һичкем салынмаган яңа кабер бар иде.
[42] Яһүдләрнең бәйрәмгә әзерләнә торган җомга көне булганлыктан, Гайсәне шунда салдылар, чөнки кабер якын иде.

---

* **19:29** *Һүссөп* – яһүдләрнең дини йолаларында кулланыла торган үсемлек.

** **19:39** *Мирра* – яһүдләрнең дини йоласы буенча күмү алдыннан мәетнең гәүдәсенә сөртә торган кыйммәтле хуш исле сумала.

*Гайсәнең терелеп торуы*

20 [1] Атнаның беренче көнендә иртән иртүк, әле караңгы
вакытта ук, Магдалалы Мәрьям кабер куышы янына
килде һәм кабер алдыннан ташның читкә алып таш-
ланганын күрде. [2] Ул шунда ук Шимун Петер һәм Гайсәнең
теге сөекле шәкерте янына йөгереп барып, аларга:

– Раббыны кабердән алып киткәннәр. Кая куйганнарын бел-
мибез, – диде.

[3] Петер белән әлеге шәкерт шундук кабер янына киттеләр.
[4] Алар икесе дә йөгерделәр, әмма теге шәкерт, Петергә кара-
ганда җәһәтрәк йөгергәнгә, кабер янына алданрак барып җит-
те. [5] Иелеп карагач, анда яткан кәфенне күрде, ләкин кабер
эченә кермәде. [6] Аның артыннан ук Шимун Петер килеп җитте.
Ул, кабер эченә кереп, анда яткан кәфенне [7] һәм Аның башына
чорналган яулыкны күрде, әмма яулык кәфен белән бергә тү-
гел, бәлки, чорнап куелганча, үз урынында ята иде. [8] Шуннан
соң, кабер янына алданрак килеп җиткән әлеге шәкерт тә эчкә
керде, һәм, күреп, ышанды. [9] Алар Изге язмада Гайсәнең үле-
дән терелеп торачагы турында язылганны әле аңламыйлар иде.
[10] Шуннан соң шәкертләр тагын өйләренә кайтып киттеләр.

[11] Мәрьям исә кабер янында елап басып калды. Елый-елый
иелеп кабер эченә карады һәм [12] анда актан киенгән ике фә-
рештәне күрде. Аларның берсе Гайсә гәүдәсе яткан урынның
баш очында, икенчесе аяк очында утыра иде. [13] Алар Мәрь-
ямнән:

– Хатын! Нигә елыйсың? – дип сорадылар.

– Минем Раббымны алып киткәннәр. Аны кая куйганнарын
белмим, – диде ул.

[14] Шулай дигәннән соң артына борылып карады һәм анда
басып торган Гайсәне күрде, әмма Аның Гайсә икәнен таны-
мады. [15] Гайсә аңа:

– Сеңлем! Нигә елыйсың? Кемне эзлисең? – дип әйтте.

Мәрьям, Аны бакчачы дип уйлап:

– Әфәндем! Син Аны чыгарып куйган булсаң, кая куйга-
ныңны әйт, мин Аны алып китәрмен, – диде.

[16] Гайсә аңа:

– Мәрьям! – диде.

Ә ул әйләнеп карап, яһүдчә:

– Раббуни! – дип әйтте. (Раббуни – Остаз дигәнне аңлата.)

[17] Гайсә аңа:

– Миңа кагылма, чөнки Мин әле Атам янына күтәрелмәдем.
Туганнарым янына кайтып әйт: «Мин Үземнең Атам һәм сезнең

Атагыз янына, Үземнең Аллаһым һәм сезнең Аллаһыгыз янына
күтәреләм», – диде.
18 Магдалалы Мәрьям шәкертләр янына килеп:
– Мин Раббыны күрдем, – диде һәм аларга Гайсә әйткән
сүзләрне сөйләп бирде.
19 Шәкертләре шул ук көнне кич белән, яһүдләрдән куркып,
йорт ишекләрен бикләп җыелып утырганда, Гайсә килеп керде
һәм, уртага басып, аларга:
– Сезгә иминлек булсын! – диде.
20 Шулай дигәннән соң, Ул аларга кулларын һәм кабыргала-
рын күрсәтте. Шәкертләр Раббыны күргәнгә бик куандылар.
21 Гайсә аларга тагын:
– Сезгә иминлек булсын! Атам Мине җибәргән кебек, Мин
дә сезне җибәрәм, – дип әйтте.
22 Моны әйткәч, Ул сулышын аларга өреп:
– Изге Рухны кабул итегез. 23 Кемнең гөнаһларын кичерсәгез,
шуныкы кичерелер; кемнекен кичермәсәгез, аныкы кичерел-
мәс, – диде.

*Күрмичә ышанучылар бәхетле!*

24 Гайсә килгәндә уникенең берсе, Игезәк кушаматлы Томас,
алар белән түгел иде. 25 Башка шәкертләр аңа:
– Без Раббыны күрдек! – диделәр.
Ә ул аларга:
– Аның кулларындагы кадак яраларын күрмичә, кадак яра-
ларына бармагымны, кабыргаларына кулымны тидереп кара-
мыйча, ышанмам, – дип әйтте.
26 Бер атнадан соң Аның шәкертләре бер йортта тагын җые-
лып утырганда, Томас та алар белән бергә иде. Гайсә ишекләр
бикле килеш килеп керде һәм аларның уртасына басып:
– Сезгә иминлек булсын! – диде.
27 Аннары Томаска:
– Бармагыңны монда куй һәм кулларыма кара; кулыңны суз
да кабыргаларыма тидер; шикләнеп торма, ышан, – дип әйтте.
28 Шунда Томас Аңа җавап биреп:
– Минем Раббым һәм Аллаһым! – диде.
29 Гайсә:
– Син Мине күргәнгә ышандың. Күрмичә ышанучылар бә-
хетле! – дип әйтте.
30 Гайсә Үзенең шәкертләре алдында бу китапта язылмаган
башка бик күп могҗизалы галәмәтләр дә күрсәтте. 31 Болар исә
сез Гайсәнең Аллаһы Улы, Мәсих булуына иман итсен өчен
һәм, иман итеп, Аның исеме аркылы сезгә тормыш булсын
өчен язылды.

*Гайсәнең шәкертләре белән очрашуы*

**21** [1] Шушы хәлләрдән соң Тибериас диңгезе буенда Гайсә
шәкертләренә янә күренде. Аның күренүе болай булды:
[2] Шимун Петер, Игезәк кушаматлы Томас, Гәлиләядәге
Кәна шәһәреннән Натанаил, Зебедәй уллары һәм Гайсәнең
тагын ике шәкерте бергә иделәр. [3] Шимун Петер:

– Балык тотарга барам, – дигәч, калган шәкертләр аңа:

– Без дә синең белән барабыз, – диделәр.

Алар көймәгә утырып, йөзеп киттеләр, әмма ул төнне һичнәрсә тота алмадылар.

[4] Таң атканда яр буенда Гайсә басып тора иде, әмма шәкерт-
ләре Аның Гайсә икәнен танымадылар. [5] Гайсә аларга:

– Егетләр! Сезнең ашарга бирәр нәрсәгез бармы? – диде.

Алар Аңа:

– Юк, – дип җавап бирделәр.

[6] Ул аларга:

– Ятьмәне көймәнең уң ягына салыгыз, тотарсыз, – диде.

Алар шулай иттеләр һәм эләккән балыкның күплегеннән
ятьмәне тартып чыгара алмадылар. [7] Шунда Гайсәнең яраткан
шәкерте Петергә:

– Бу – Раббы, – диде.

«Бу – Раббы», – дигәнне ишеткәч, Шимун Петер, өс киемен
киеп (ул чишенгән иде), суга сикерде. [8] Ярдан йөз кырык ар-
шын чамасы гына ераклыкта булган башка шәкертләр, көймә
белән килеп, балык белән тулган ятьмәне сөйрәп ярга алып
чыктылар. [9] Ярга чыккач, алар икмәкне һәм учакта яткан ба-
лыкны күрделәр. [10] Гайсә аларга:

– Тоткан балыкларыгызның беразын монда алып килегез, – диде.

[11] Шимун Петер зур балыклар белән тулган ятьмәне өстерәп
җиргә чыгарды. Анда йөз илле өч балык бар иде. Балыкның
шундый күп булуына да карамастан ятьмә ертылмады.

[12] Гайсә аларга:

– Ашарга килегез, – диде.

Шәкертләрнең берсе дә: «Син кем?» – дип сорарга батырчы-
лык итмәде, чөнки алар Аның Раббы икәнен белделәр. [13] Гайсә
якынрак килеп икмәкне алды һәм аларга өләште, шулай ук ба-
лыкны да алып аларга бирде.

[14] Бу инде Гайсәнең, үледән терелтелгәннән соң, шәкертлә-
ренә өченче тапкыр күренүе иде.

[15] Ашаганнан соң Гайсә Шимун Петердән:

– Яхъя улы Шимун! Син Мине башка шәкертләремә карарганда күбрәк яратасыңмы? – дип сорады.

Петер Аңа:

– Әйе, Раббым! Син минем яратуымны беләсең, – дип җавап бирде.

Гайсә аңа:

– Минем бәрәннәремне көт, – диде.

16 Гайсә икенче мәртәбә:

– Яхъя улы Шимун! Син Мине яратасыңмы? – дип сорады.

Петер Аңа:

– Әйе, Раббым! Син минем яратуымны беләсең, – дип җавап бирде.

– Минем сарыкларыма көтүче бул, – диде.

17 Өченче мәртәбә Ул аннан:

– Яхъя улы Шимун! Син Мине яратасыңмы? – дип сорады.

Петер, Аның: «Син Мине яратасыңмы?» – дип, өченче мәртәбә соравына көенеп, Аңа:

– Раббым! Син бөтенесен беләсең. Син яратуымны да беләсең, – дип җавап бирде.

Гайсә аңа:

– Минем сарыкларымны көт, – диде. –
18 Сиңа хак сүз әйтәм: син яшь чакта үзеңне-үзең билбаулап, теләгән җиреңә бара идең. Ә картайгач, кулларыңны сузарсың, һәм башка берәү, сине билбаулап, теләмәгән җиреңә алып барыр.

19 Ул бу сүзләрне Петернең нинди үлем белән Аллаһыны данлаячагын белдереп әйтте. Шуннан соң Гайсә аңа:

– Минем артымнан бар, – диде.

20 Шул вакыт Петер, артына әйләнеп карагач, артларыннан Гайсәнең яраткан шәкерте килүен күрде. Бу – кичке аш вакытында Гайсәнең күкрәгенә терәлеп диярлек утырган, «Раббым! Сиңа кем хыянәт итәчәк?» – дип сораган шәкерт иде.
21 Петер, аны күргәч, Гайсәдән:

– Раббым! Аның белән нәрсә булачак? – дип сорады.

22 Гайсә аңа:

– Мин килгәнгә кадәр аның яшәвен теләсәм дә, анда синең ни эшең бар? Син Минем артымнан бар, – диде.

23 Шуңа күрә кардәшләр арасында: «Ул шәкерт үлмәячәк», – дигән сүз таралды. Әмма Гайсә: «Үлмәячәк», – димәде, ә: «Мин килгәнгә кадәр аның яшәвен теләсәм дә, анда синең ни эшең бар?» – диде.

24 Бу вакыйгаларга шаһитлек биреп, бу сүзләрне язган шәкерт – шул шәкерт була. Без аның шаһитлегенең хак икәнен беләбез.

25 Гайсә болардан башка да күп эшләр башкарды. Аларның һәммәсе турында да язылса, язылган китаплар дөньяга сыймас иде дип уйлыйм.

# РӘСҮЛЛӘРНЕҢ ЭШЛӘРЕ

1 1-2 Мин сиңа, Тәүфил, беренче китабымда Гайсәнең хезмәт
итә башлаган көннәреннән алып, Үзе сайлап алган рәсүл-
ләргә* Изге Рух аркылы боерыклар биреп күккә алынган
көненә кадәр, барлык эшләгән эшләре һәм өйрәткәннәре ту-
рында язган идем. 3 Газап чиккәннән соң, күп санлы хак дә-
лилләр белән Ул Үзенең тере икәнен исбат итте, кырык көн
буена рәсүлләргә күренде һәм Аллаһы Патшалыгы хакында
сөйләде.

*Гайсә күккә аша*

4 Рәсүлләр белән ашап утырганда, Гайсә аларга шундый боe-
рык бирде:
– Иерусалимнан китмәгез, Ата вәгъдә иткән бүләкне көте-
гез. Мин сезгә ул турыда сөйләгән идем. 5 Яхъя суга чумдырды**,
ә сез, берничә көн үткәч, Изге Рухка чумдырылырсыз.
6 Бергә җыелгач, рәсүлләр Гайсәдән:
– Раббыбыз! Син Исраил патшалыгын шушы вакытта яңа-
дан торгызачаксыңмы? – дип сорадылар.
7 Ул исә аларга:
– Ата Үз хакимлеге белән билгеләгән вакытларны яки миз-
гелләрне белү сезнең эшегез түгел, – диде. – 8 Әмма сез үзегез-
гә Изге Рух иңгәннән соң кодрәт алачаксыз һәм Иерусалимда,
бөтен Яһүдиядә, Самареядә һәм, хәтта дөньяның читенә кадәр
барып җитеп, һәркайда Миңа шаһит булачаксыз.
9 Шушы сүзләрне әйткәч, рәсүлләрнең күз алдында Гайсә
күккә күтәрелде һәм болыт Аны аларның алдыннан алып китте.

---

* 1:1-2 *Рәсүл* (грек сүзе «апостолос») – җибәрелгән кеше. Бу сүзнең Инҗилдәге мәгънәсе: Аллаһы тарафыннан сайланып алып җибәрелгән илче. Аның Гайсә Мәсихтән бирелгән вәкаләте бар.
** 1:5 *Суга чумдыру* – суга чумып чыгу йоласы – гөнаһлардан тәүбә итүне, үзеңне Аллаһы Тәгаләгә багышлауны күрсәтә торган йола.

[10] Гайсәнең күтәрелүен күзәтеп, күккә текәлеп карап торганда,
кинәт рәсүлләр янында актан киенгән ике ир заты пәйда булды.
[11] – Гәлиләя ирләре! Ник сез күккә текәлеп карап торасыз?
Сезнең яныгыздан күккә ашкан бу Гайсә күз алдыгызда ничек күтәрелгән булса, яңадан шул ук рәвешле киләчәк, – диделәр алар.

*Яһүд урынына рәсүл сайлау*

[12] Шуннан соң рәсүлләр Зәйтүн тавы дип аталган бу таудан
Иерусалимга кайттылар. Зәйтүн тавы Иерусалимнан бер шимбә
көнлек юл* ераклыгында иде. [13] Кайтып җиткәч, үзләре тукталган өске каттагы бүлмәгә керделәр. Анда Петер, Ягъкуб, Яхъя, Әндри, Филип, Томас, Бартулумай, Маттай, Һалфай улы Ягъкуб, Шимун көрәшүче** һәм Ягъкуб улы Яһүд бар иде. [14] Алар
һәрвакыт бердәм рәвештә дога кылуда булдылар. Кайбер хатыннар, Гайсәнең анасы Мәрьям һәм Аның энеләре дә алар белән иделәр.
[15] Шул көннәрнең берсендә иман итүчеләр арасыннан Петер торып басты. Анда йөз егермегә якын кеше бар иде.
[16] – Туганнар, – дип сүз башлады ул. – Гайсәне кулга алган кешеләрне Аның янына алып килгән Яһүд хакында Изге Рух Давыт аркылы әйткән сүзләр бар. Язмадагы ул сүзләр тормышка ашарга тиеш иде. [17] Яһүд безнең арабызда саналды, ул шул
хезмәттә катнашу өчен сайланган иде, – диде Петер.
[18] Яһүд хәрәм акчага җир сатып алды, шул җирдә егылып, аның эче ярылды һәм барлык эчке әгъзалары тышка агып
чыкты. [19] Бу хәл бөтен Иерусалим халкына билгеле булды, шуңа күрә дә ул җир аларның телендә «Акелдама», ягъни «Канлы җир» дип атала башлады.
[20] – Зәбурда*** исә:

«Аның йорты буш булсын,
эчендә яшәүче булмасын»,

һәм:

«Аның хезмәтен башка берәү алсын», –

дип язылган.

---

* 1:12 *Бер шимбә көнлек юл* – бер чакрым чамасы. Муса кануны буенча шимбә – яһүдләрнең ял итү һәм гыйбадәт кылу көне. Бу көнне бер чакрымнан да ары йөрергә ярамаган.

** 1:13 *Шимун көрәшүче* – Рим хакимлеген көч белән бәреп төшерүне яклап көрәшүче яһүдләр төркеменең әгъзасы.

*** 1:20 *Зәбур* – Изге Китапның бер язмасы «Зәбур» дип атала (русча – Псалтирь).

[21-22] Шуңа күрә, Яхъя Гайсәне чумдырган көннән алып Гайсә
бездән алынган көнгә кадәр, Раббы Гайсә безнең арабызда
булганда һәрвакыт безнең белән бергә булганнарның берсе
безгә кушылырга һәм Аның үледән терелгәнлеге хакында без-
нең белән бергә шаһитлек итәргә тиеш, – диде Петер.
[23] Ике кешене: Барсаб дип аталучы Йосыфны (аны тагын
Юсты дип тә атыйлар) һәм Маттиасны тәкъдим иттеләр.
[24-25] – Раббыбыз! Син бар кешеләрнең йөрәкләрен беләсең.
Яһүд үзенә тиеш булган урынга китте. Ул калдырган бу хезмәт
урынын һәм рәсүллекне кабул итү өчен Син шушы икәүнең
кайсысын сайладың – шуны күрсәт, – дип дога кылдылар.
[26] Аннары алар жирәбә салдылар. Жирәбә Маттиаска чыкты
һәм ул, калган унбер кебек, рәсүлләр исәбенә кертелде.

*Изге Рухның иңүе*

**2** [1] Илленче көн бәйрәме* җиткәндә иман итүчеләр барысы
бергә бер урында иделәр. [2] Күктән кинәт көчле җил ис-
кән кебек тавыш ишетелде һәм шул тавыш алар булган
йортны тутырды. [3] Иман итүчеләр арасында ялкын телләре
кебек телләр күренде һәм ул телләр аларның һәрберсенә бе-
рәрләп кунды. [4] Барысы да Изге Рух белән сугарылдылар һәм
Изге Рух биргән сүзләр белән башка телләрдә сөйли башла-
дылар. [5] Иерусалимда исә җир йөзендәге һәр халыктан килгән
диндар яһүдләр яши иде. [6] Бу тавышны ишетеп җыелган ха-
лык аптырады, чөнки һәркем кайсы да булса иман итүченең
үз телендә сөйләвен ишетте. [7] Алар хәйран калдылар һәм,
шаккатып:
– Бу сөйләүчеләр барысы да гәлиләялеләр түгелме соң? –
диделәр. – [8] Ничек инде һәрберебез аларның һәркайсыбызның
туган телендә сөйләүләрен ишетә? [9] Без пәртиялеләр, мадай-
лылар, эламлылар, Месупотамиядә, Яһүдиядә, Кәппәдүкиядә,
Понтта, Асия өлкәсендә**, [10] Фругиядә, Памфулиядә, Мисыр-
да һәм Ливиянең Күринигә якын өлешләрендә яшәүчеләр,
[11] Римнан килгән яһүдләр һәм мәҗүсилектән яһүд диненә күч-
кән кешеләр, критлылар һәм гарәбстанлылар, – Аллаһының
бөек эшләре хакында аларның безнең телләрдә сөйләүләрен
ишетәбез!

---

* 2:1 *Илленче көн бәйрәме* – Коткарылу бәйрәменнән соң илленче көнне яһүдләр бөртекләрнең уңышын җыеп алуны бәйрәм иткәннәр.

** 2:9 *Асия өлкәсе* – Рим империясенә караган Асия өлкәсе бүгенге Төркия җиренең көньяк-көнбатыш өлешендә булган.

12 Барысы да хәйран калдылар һәм, аптырашып, бер-берсенә:
– Бу нәрсәне аңлата икән? – диештеләр.
13 Ә кайберләре:
– Алар шәраб эчеп исергәннәр, – дип көлделәр.

*Петернең Илленче көн бәйрәмендә сөйләгән вәгазе*

14 Петер исә, унбер рәсүл белән бергә торып басты һәм кычкырып сөйли башлады:
– Яһүд ирләре һәм Иерусалимда яшәүче барлык кешеләр! Мин сезгә моның нәрсә икәнен аңлатырмын. Минем сүзләремне игътибар белән тыңлагыз, – диде ул халыкка. – 15 Алар, сез уйлаганча, исерек түгел, чөнки хәзер сәгать иртәнге тугызынчы*
гына әле. 16 Бу турыда Йоил пәйгамбәр аркылы алдан әйтелгән:
17 «Аллаһы әйтә: „Ахыр көннәрдә
Үз Рухымны коярмын
Бар кешеләргә.
Улларыгыз, кызларыгыз
Мин әйткән сүзләрне
Игълан итәрләр.
Яшьләрегез илаһи күренешләр,
Картларыгыз төшләр күрерләр.
18 Үз Рухымны коярмын
Ир-ат колларыма да, хатын-кыз колларыма да.
Һәм Мин әйткән сүзләрне
Игълан итәрләр алар да.
19 Күрсәтермен югарыда – күктә могҗизалар,
Ә түбәндә – җирдә галәмәтләр.
Кан һәм ут, һәм куе төтен булыр:
20 Кояш сүнәр, ә ай исә канга әйләнер.
Һәм дә килер Раббының көне –
Бөек һәм шөһрәтле көн.
21 Һәм ялварып Раббыга мөрәҗәгать иткән һәркем
котылыр“».
22 Исраил ирләре! Бу сүзләрне тыңлагыз: белгәнегезчә, Аллаһы сезнең арагызда Гайсә аркылы кодрәтле эшләр, могҗизалар, галәмәтләр кылды һәм шул эшләре белән насаралы Гайсәнең сезнең өчен билгеләнгән Зат икәнен исбат итте. 23 Аллаһының
алдан билгеләнгән максаты һәм алдан белеп торуы белән сезнең

---

* 2:15 *Иртәнге тугызынчы* – Аларның вакыт хисабы буенча көндезге өченче сәгатькә туры килә. Вакыт хисабы безнекеннән аермалы буларак, көндезге вакыт иртәнге алтыдан башланып кичке алтыга тикле, төнге вакыт кичке алтыдан иртәнге алтыга тикле дәвам иткән.

карамакка бирелгән шушы Кешене канунсызлар кулы белән
хачка кадаклап үтердегез. [24] Әмма Аллаһы, үлем богауларын
өзеп, Гайсәне үледән терелтте, чөнки үлем Аны тотып кала
алмады. [25] Давыт Аның хакында болай диде:

«Мин Раббыны һәрвакыт
үз алдымда күрдем.
Ул минем уң ягымда,
икеләнмим шуңа күрә.
[26-27] Җанымны үлеләр дөньясында
калдырмассың Син,
Үз Изгеңә черергә
ирек бирмәссең Син.
Шуңа күрә куанды минем күңелем,
шатланды минем телем,
Өмет баглап яшәр хәтта
минем тәнем.
[28] Тормыш юлын ачып бирдең
Син миңа.
Миңа шатлык индерерсең
Үз каршыңда».

[29] – Туганнар! Ыруыбыз башлыгы Давыт хакында кыюлык бе-
лән сезгә шуны әйтә алам: ул үлде һәм күмелде. Билгеле бул-
ганча, аның кабере бүгенге көнгә кадәр сакланган. [30] Аллаһы
Давытка аның токымыннан булган берәүне аның тәхетенә утыр-
тачагы турында ант иткән. Давыт бу ант турында белеп һәм
пәйгамбәр буларак, [31] Мәсихнең үледән терeләчәге, Аның үлеләр
дөньясында калдырылмаячагы һәм тәненең черемәячәге хакын-
да алдан белеп әйтте. [32] Аллаһы шушы Гайсәне үледән терелтте,
һәм без һәммәбез – моның шаһитләре. [33] Шулай итеп, Аллаһы
Аны Үзенең уң ягына* күтәргәч, Ул, Атасыннан вәгъдә ителгән
Изге Рухны кабул итеп, безнең өскә сез хәзер күреп һәм ишетеп
торган бүләкне койды. [34-35] Давыт үзе күккә күтәрелмәде, әмма ул:

«Раббы Аллаһы әйтте минем Раббыма:
Мин дошманнарыңны аяк астыңа
баскыч итеп салганчы,
утыр Минем уң ягымда», –

диде. [36] Шулай итеп, бөтен Исраил халкы яхшы белсен: Аллаһы
сез хачка кадаклаган бу Гайсәне Раббы һәм Мәсих итте, – диде
Петер.

[37] Тыңлаучылар ишеткән бу сүзләр йөрәкләренә барып ка-
далды:

---

* **2:33** *Уң як* – аеруча мөһим, хөрмәтле урын.

– Туганнар, безгә нәрсә эшләргә соң инде? – диделәр алар Петергә һәм башка рәсүлләргә.

38 – Һәркайсыгыз, гөнаһларыгыз кичерелсен өчен, тәүбә итеп, Гайсә Мәсих исемендә чумдырылу йоласын үтегез, һәм сез Аллаһының бүләген – Изге Рухны кабул итәрсез. 39 Аллаһының вәгъдәсе Аллаһыбыз Раббы Үзенә чакырган һәркемгә – сезгә, сезнең балаларыгызга һәм еракта яшәүче барлык кешеләргә дә, – дип җавап бирде Петер.

40 Ул тагын да күбрәк сүзләр белән аларны кисәтте:

– Бу бозык буыннан котылыгыз, – дип өндәде Петер.

41 Аның сүзләрен кабул итүчеләр чумдырылдылар, һәм ул көнне иман итүчеләргә өч меңгә якын кеше кушылды.

*Иман итүчеләрнең бердәм тормышы*

42 Иман итүчеләр һәрвакыт рәсүлләрнең өйрәтүләрен кабул итеп, бер-берсе белән аралашып яшәделәр, бергә икмәк сындырдылар һәм бергәләп дога кылдылар. 43 Рәсүлләр аркылы күп могҗизалар һәм галәмәтләр күрсәтелде, һәм бу һәркемнең күңелендә курку хисе уятты. 44 Барлык иман итүчеләр бергә булдылар һәм һәрнәрсә уртак иде. 45 Хуҗалыкларын һәм милекләрен сатып, һәркемнең хаҗәтенә карап, үзара бүлештеләр.
46-47 Алар һәр көн даими рәвештә бердәм күңел белән Аллаһы Йортында булдылар, өйләрендә Аллаһыны мактап, шат һәм күндәм күңелдән икмәк сындырып, ризыкны бергәләп ашадылар. Бар халык аларны яратты, Раббы исә коткарылучыларның санын һәр көн саен арттырып торды.

*Аяклары гарип кеше йөри башлый*

3 1 Шулай бер көнне көндезге өчләр тирәсендә, дога кылу вакытында, Петер белән Яхъя Аллаһы Йортына килделәр.
2 Тумыштан ук аяклары гарип булган бер кешене, Аллаһы Йортының Матур дип аталган капкасы янына алып килеп, керүчеләрдән хәер сорау өчен, һәр көн утыртып калдыралар иде.
3 Шул кеше, Петер белән Яхъяның Аллаһы Йортына керүләрен күреп, алардан хәер сорады. 4 Алар аңа игътибар белән карадылар һәм Петер:

– Безгә кара, – диде.

5 Теге кеше, нәрсә булса да алырга өметләнеп, аларга текәлеп карады. 6 Әмма Петер:

– Минем алтын-көмешләрем юк, ә нәрсәм бар, шуны сиңа бирәм. Насаралы Гайсә Мәсих вәкаләте белән боерам: тор һәм йөр! – диде 7 һәм аны уң кулыннан тартып торгызды.

Шундук гарип кешенең аяклары һәм тез буыннары ныгыды.
8 Ул сикереп торды һәм йөри башлады, Аллаһыны мактый-мактый, сикерә-сикерә, алар белән бергә Аллаһы Йортына керде.
9 Бар халык бу кешенең йөргүен һәм Аллаһыны мактавын күрде.
10 Кешеләр аның Матур капка янында хәер сорашып утырган адәм икәнен таныдылар, аның белән булган хәлгә хәйран калып, бик гаҗәпләнделәр.

*Петернең Сөләйман әйванында сөйләгән вәгазе*

11 Әлеге савыккан кеше Петер белән Яхъяны җибәрмичә тотып торган вакытта, бик нык гаҗәпләнгән халык, Сөләйман әйваны* дип аталган залга йөгереп кереп, алар янына җыелды.
12 Петер, моны күреп, халыкка:
– Исраил ирләре! Нигә моңа гаҗәпләнәсез? – диде. – Ник безгә текәлеп карап торасыз? Әллә без үзебезнең кодрәтебез яки диндарлыгыбыз белән аны савыктырган дип уйлыйсызмы?
13 Ибраһимның, Исхакның һәм Ягъкубның Аллаһысы, безнең аталарыбызның Аллаһысы Үзенең Хезмәтчесе Гайсәне шөһрәтле итте, ә сез Аны тотып бирдегез һәм, Пилат Аны азат итәргә
уйлаганда, Пилат алдында Аңардан баш тарттыгыз. 14 Сез Изге
һәм Хак Заттан ваз кичтегез һәм кеше үтерүчене иреккә чыгарырга сорадыгыз. 15 Сез тормышны Бар итүчене үтердегез, әмма
Аллаһы Аны үледән терелтте. Без – моның шаһитләре.
16 Һәммәгез күргәнчә, Аның исеменә ышану аркылы Аның исеменең көче сез күреп белгән бу кешене куәтләндерде, аны Гайсә аркылы килгән иман савыктырды, – диде Петер. – 17 Хәер,
туганнар, мин беләм: сез моны, башлыкларыгыз кебек үк, белмичә эшләдегез. 18 Аллаһы Үз Мәсихенең газап чигәчәге турында барлык пәйгамбәрләр аша алдан әйткән хәбәрен шулай тормышка ашырды.
19 Ә сез гөнаһларыгыз кичерелсен өчен тәүбә итегез һәм
Аллаһыга таба борылыгыз. 20 Шулай эшләсәгез, Раббыдан
юанычлы заманнар килер, Ул сезгә алдан билгеләнгән Мәсихне – Гайсәне җибәрер. 21 Аллаһы Үзенең изге пәйгамбәрләре
аша борынгыдан сөйләгән барлык сүзләр гамәлгә ашканчы Гайсә күктә калырга тиеш.
22 Муса әйткән: «Раббы Аллаһыгыз туганнарыгыз арасыннан сезгә минем кебек Пәйгамбәр күтәрәчәк. Ул сезгә нәрсә генә сөйләсә дә, сез һәммәсен тыңларга тиешсез; 23 бу Пәйгамбәрнең сүзен тыңламаган һәр кеше Аллаһы халкы арасыннан юк ителәчәк».

---

* 3:11 *Әйван* – баганалардан торган өсте каплаулы зал.

24 Шамуилдән башлап барлык пәйгамбәрләр бу көннәр хакында алдан хәбәр иттеләр. 25 Сез – пәйгамбәрләрнең варислары. Аллаһы Ибраһимга: «Җир өстендә барлык кабиләләр синең нәселең аша фатиха алачак», – дип әйтеп, аталарыгызга васыять кылды. Сез – шушы васыятьнең мирасын кабул итүчеләр.
26 Аллаһы сезнең һәркайсыгызны яман эшләрегездән кире кайтарырга һәм фатиха бирергә тели. Шуның өчен Ул Үзенең Хезмәтчесен күтәрде һәм Аны иң элек сезгә җибәрде.

*Петер белән Яхъя Югары киңәшмә алдында*

4 1-2 Петер белән Яхъяның халыкны өйрәтүләренә, Гайсәнең үледән терелүен мисал итеп, үлеләрнең терeләчәге турында вәгазь сөйләүләренә ачулары килгән руханилар, саддукейлар* һәм Аллаһы Йортында тәртип саклаучылар башлыгы, рәсүлләр халыкка сөйләп торган вакытта килеп, 3 аларны кулга алдылар. Инде кич булганлыктан, иртәгесе көнгә кадәр аларны сак астына тапшырдылар. 4 Рәсүлләр сөйләгән вәгазьне тыңлаучыларның күбесе иман китерде. Иман китерүче ирләрнең саны биш мең чамасы иде.

5 Икенче көнне Иерусалимда яһүдләрнең башлыклары, аксакаллар һәм канунчылар җыелды. 6 Иң баш рухани Һаннас, Кәяфәс, Яхъя, Искәндәр һәм иң баш руханиның гаиләсеннән булган башкалар да шунда иделәр.

7 Петер белән Яхъяны уртага бастырып, алардан:

– Сез бу савыктыруны нинди кодрәт белән яки нинди исем белән эшләдегез? – дип сорадылар.

8 Шул вакыт Петер, Изге Рух белән сугарылып, аларга:

– Халык башлыклары, аксакаллар! – диде. – 9 Авыру кешегә күрсәтелгән яхшылык турында һәм аның ничек савыктырылуы хакында бүген бездән җавап таләп итәләр икән, 10 сезнең һәммәгезгә һәм бөтен Исраил халкына мәгълүм булсын: сезнең каршыгызда басып торган адәм Гайсә Мәсих исеме белән – сез хачка кадаклаткан, Аллаһы тарафыннан үледән терелтелгән насаралы Гайсә Мәсих исеме белән савыктырылды. 11 Изге язмада әйтелгәнчә, Гайсә ул – «сез, төзүчеләр, кире каккан, ләкин иң мөһим булып чыккан нигез ташы».

12 Башка беркемдә дә котылу юлы юк. Җир йөзендә кешеләргә бирелгән исемнәр арасында без коткарыла алырдай башка исем юк, – диде Петер.

---

* 4:1 *Саддукейлар* – нигездә руханилардан һәм байлардан торган, яһүд халкының йолаларын тотучы төркем. Алар үледән терелүгә ышанмаганнар.

[13] Белемнәре дә булмаган бу гап-гади кешеләрнең – Петер
белән Яхъяның кыюлыгын күреп, Киңәшмәдә* утыручылар
бик гаҗәпләнделәр. Аларның Гайсә белән бергә йөргән кеше-
ләр икәнен хәзер генә аңладылар. [14] Савыккан кешенең дә алар
белән торуын күргәч, каршы сүз әйтә алмадылар һәм [15] аларга
Киңәшмәдән чыгып торырга әмер бирделәр.
[16] – Бу кешеләр белән нәрсә эшләргә? Алар кылган бу могҗи-
залы галәмәт Иерусалимда яшәүчеләрнең һәммәсенә билгеле,
һәм без аның тәгаенлеген инкяр итә алмыйбыз. [17] Әмма бу хак-
та халык арасында артык сүз таралмасын өчен, аларны катгый
рәвештә кисәтик: бу исем турында беркайчан да кешеләргә
сөйләмәсеннәр, – дип үзара киңәшләштеләр.
[18] Аларны чакырып керттеләр һәм Гайсә хакында һичнәрсә
сөйләмәскә һәм өйрәтмәскә әмер бирделәр. [19] Әмма Петер бе-
лән Яхъя:
– Үзегез уйлап карагыз, Аллаһының сүзен тыңлауга караган-
да сезнең сүзне күбрәк тыңлау Аллаһы каршында дөрес булыр-
мы икән? [20] Без күргәннәребез һәм ишеткәннәребез турында
сөйләми булдыра алмыйбыз, – дип җавап бирделәр.
[21] Тегеләр исә, җәза бирерлек сәбәп таба алмыйча, тагын
бер тапкыр янап, Петер белән Яхъяны чыгарып җибәрделәр.
Чөнки булган хәл өчен һәммәсе Аллаһыны данлый иде. [22] Са-
выгу могҗизасын татыган теге кеше кырык яшьтән узган иде
инде.

*Иман итүчеләрнең догасы*

[23] Азат ителгәннән соң Петер белән Яхъя, иптәшләре янына
килеп, баш руханилар һәм аксакаллар әйткән сүзләрне сөйләп
бирделәр. [24] Иман итүчеләр исә, моны ишеткәч, бердәм рә-
вештә көр тавыш белән Аллаһыга дога кылдылар:
– Хөкемдарыбыз! Син – күкне, җирне, диңгезне һәм алар-
дагы барлык нәрсәләрне барлыкка китерүче! [25] Син Үзеңнең
хезмәтчең һәм безнең атабыз Давыт аркылы Изге Рух аша
әйттең:

«Ни өчен милләтләр котырына,
Халыклар ният итә юкка гына?
[26] Җирдәге патшалар каршы чыктылар,
Башлыклар бергә җыелып,
Раббыга һәм Аның Мәсихенә каршы кузгалдылар».

---

* 4:13 *Киңәшмә (Югары киңәшмә)* – яһүдләрнең иң югары хөкем шу-
расы. Бу Киңәшмәдә күбрәк дини мәсьәләләр каралган (грекча –
«сунедрион»).

[27-28] Чынлап та, Һируд һәм Понти Пилат, мәҗүсиләр һәм
Исраил халкы белән бергә, Син май сөрткән* Изге Хезмәтчең
Гайсәгә каршы, Синең кодрәтең һәм ихтыярың белән булачагы
алдан билгеләнгән эшләрне гамәлгә кую өчен бу шәһәргә
җыелдылар. [29] Хәзер, Раббыбыз, аларның янауларын ишет һәм
колларыңа Синең сүзеңне зур кыюлык белән сөйләргә көч бир.
[30] Кулыңны суз һәм Изге Хезмәтчең Гайсә исеме белән савыктыр, галәмәтләр һәм могҗизалар күрсәт.

[31] Дога кылганнан соң алар булган урын селкенеп китте һәм
барысы да Изге Рух белән сугарылдылар.

Шушы хәлдән соң иман итүчеләр Аллаһы сүзен кыюлык белән сөйли башладылар.

*Һәрнәрсә уртак*

[32] Барлык иман итүчеләр йөрәкләре һәм күңелләре белән
бердәй булдылар. Берсе дә үз милкен минеке дип әйтмәде,
һәрнәрсә уртак иде. [33] Рәсүлләр исә бөек көч белән Гайсә
Раббының яңадан терелеп торуына шаһитлек кылдылар, һәм
Аллаһы аларның һәммәсенә Үзенең мәрхәмәтен мул итеп
биреп торды. [34] Иман итүчеләр арасында беркем дә мохтаҗ булмады, чөнки җирләре яки йортлары булганнар, аларны сатып,
акчасын [35] рәсүлләр карамагына тапшыралар иде. Һәркемгә
хаҗәтенә карап бирелә иде. [36] Мәсәлән, рәсүлләр Барнаб дип
йөрткән (ягъни «Юаныч улы»), Кипрда туган Йосыф исемле
бер левиленең** [37] үз җире бар иде. Ул, җирен сатып, акчасын
рәсүлләргә китереп бирде.

*Һанани белән Сапфира*

**5** [1] Һанани атлы берәү, үзенең хатыны Сапфира белән бергә, милкен сатып, [2] сатудан чыккан акчаның бер өлешен,
хатыны белән сөйләшеп, яшереп калдырды, ә калганын
рәсүлләргә китереп бирде. [3] Әмма Петер:

– Һанани! Ни өчен син шайтанга йөрәгең белән идарә итәргә ирек бирдең? Хәтта, акчаның бер өлешен яшереп калдырып,
Изге Рухка ялганларга уйлагансың, – диде. – [4] Сатмаган хәлдә
ул милек синеке булып калачак иде түгелме соң? Сатканнан соң
акчасы синең карамагыңда түгел идеме? Ни өчен син шундый

---

* 4:27-28 *Май сөртү* – Сүзлектән карагыз.

** 4:36 *Леви* – Ягъкуб улларының берсе. Аллаһы әмере буенча, Леви токымыннан булган кешеләр генә Аллаһы Йортында рухани ярдәмчесе булып хезмәт иткәннәр. Алар левиләр дип аталганнар.

ниятне йөрәгеңә керттең? Син кешеләргә түгел, ә Аллаһыга ялганладың.

[5] Шушы сүзләрдән соң Һанани җан биреп идәнгә ауды. Бу
хәл турында ишеткән кешеләр куркып калдылар. [6] Һананиның
үле гәүдәсен егетләр кәфенгә төреп алып чыгып киттеләр һәм
күмделәр.

[7] Өч сәгать чамасы үткәннән соң аның хатыны да килде. Ул
булган хәлне белми иде әле. [8] Петер исә аңардан:

– Әйт әле миңа, җирегезне шушы бәягә саттыгызмы? – дип сорады.

Хатын аңа:

– Әйе, шушы бәягә, – дип җавап бирде.

[9] Әмма Петер:

– Димәк сез Раббының Рухын сынап карарга сүз беркеттегез? Менә ireңне күмгән кешеләр ишектән кереп киләләр. Алар сине дә алып чыгачаклар, – диде.

[10] Хатын шундук җан биреп идәнгә егылды. Егетләр, кергәч,
аның үлгән булуын күрделәр һәм, алып чыгып, ире янына күмеп
куйдылар.

[11] Иман итүчеләрне һәм бу хәбәрне ишетүчеләрнең барысын
көчле курку биләп алды.

*Галәмәтләр һәм могҗизалар*

[12] Рәсүлләр кулы белән халык арасында күп галәмәтләр һәм
могҗизалар кылынды. Иман итүчеләр бердәм рәвештә Сөләйман әйванында очрашып тордылар. [13] Халык аларны хөрмәт
итте, ләкин беркем, үзе килеп, иман итүчеләргә кушылырга
базмады. [14] Шулай да бик күп ир-атлар һәм хатын-кызлар Раббыга иман китерделәр һәм аларның саны арта барды. [15] Петер
үтеп барганда, һич булмаса аның күләгәсе генә булса да төшсен иде, дигән теләк белән, авыруларны урамнарга чыгарып,
ятакларга һәм түшәкләргә салдылар. [16] Иерусалимга якын-тирәдәге шәһәрләрдән бик күп халык килә иде. Алар алып килгән сырхаулар һәм шакшы рухлардан газап чигүчеләрнең барысы да савыкты.

*Кулга алынган рәсүлләрне фәрештә ireккә чыгара*

[17] Иң баш рухани һәм аның барлык тарафдарлары, ягъни садукейлар төркемендәгеләр, көнләшеп, [18] рәсүлләрне кулга алдылар һәм халык зинданына ябып куйдылар. [19] Әмма төнлә
белән Раббының бер фәрештәсе зиндан ишекләрен ачты:

[20] – Барыгыз, бу яңа тормыш турында барысын да Аллаһы
Йортында халыкка сөйләгез, – дип, аларны чыгарып җибәрде.

21 Рәсүлләр, тыңлаучанлык күрсәтеп, иртә таңнан Аллаһы
Йортына килделәр һәм өйрәтә башладылар.
Ә иң баш рухани һәм аның ярдәмчеләре, Исраил халкының
аксакалларын чакырып, Югары киңәшмә җыйдылар. Рәсүл-
ләрне алып килү өчен, тәртип саклаучыларны зинданга җибәр-
деләр, 22 әмма хезмәтчеләр, зинданда аларны тапмыйча, кире
кайттылар.
23 – Без килгәндә зиндан ышанычлы бикләнгән, ишекләр
янында сакчылар басып тора иде. Әмма, ишекләрне ачып эчкә
кергәч, беркемне дә тапмадык, – диделәр алар.
24 Аллаһы Йортында тәртип саклаучылар башлыгы һәм баш
руханилар, моны ишеткәч:
– Тагын нәрсә булыр икән инде? – дип аптырашта калдылар.
25 Шул арада берәү килеп:
– Әнә, карагыз, сез зинданга утырткан кешеләр Аллаһы
Йортында халыкны өйрәтә, – дип әйтте.

*Рәсүлләр Югары киңәшмә алдында*

26 Шуннан соң тәртип саклаучылар белән аларның башлык-
лары, шунда барып, халык таш ата башлар дип курыкканга кү-
рә, көч кулланмыйча гына, рәсүлләрне алып килделәр. 27 Ки-
леп җиткәч, аларны Киңәшмә алдына бастырдылар һәм иң
баш рухани:
28 – Без сезгә бу исем турында өйрәтмәскә дип, катгый рә-
вештә әйткән идек түгелме? Ә сез үзегезнең тәгълиматыгызны
бөтен Иерусалимга тараттыгыз һәм ул Кешенең түгелгән ка-
нында безне гаепләргә теләп ашкынасыз, – диде.
29 Петер һәм башка рәсүлләр исә:
– Без кешеләргә караганда күбрәк Аллаһыга итагатьле булыр-
га тиешбез. 30 Аталарыбызның Аллаһысы сез агачка кадаклатып
үтергән Гайсәне үледән терелтте. 31 Исраилгә тәүбә итү һәм гө-
наһлары кичерелү мөмкинлеген бирү өчен, Аллаһы Аны Хаким
һәм Коткаручы итеп Үзенең уң ягына күтәрде. 32 Без – бу эшләр-
нең шаһитләре. Һәм шулай ук Аллаһы Үзенә итагать итүчеләргә
биргән Изге Рух та бу эшләргә шаһит, – дип җавап бирделәр.
33 Моны ишеткәч, Киңәшмә әгъзалары бик ярсыдылар һәм
рәсүлләрне үтерергә теләделәр. 34 Шул вакыт бөтен халык тара-
фыннан мөхтәрәм канунчы, Гәмәлиил атлы бер фарисей* торып

* **5:34** *Фарисей* – борынгы яһүдләр арасындагы дини төркем әгъза-
сы. Фарисейләр Муса канунын һәм кешеләр тарафыннан гасырлар
буена канунга өстәлеп килгән кагыйдәләрне төгәл үтәүне алга сө-
реп яшәгәннәр.

басты һәм рәсүлләрне аз гына вакытка чыгарып торырга әмер
бирде. [35] Рәсүлләр чыгып киткәч:

– Исраил ирләре! – дип сүз башлады Гәмәлиил. – Бу ке-
шеләр белән нәрсә эшләячәгегезне яхшырак итеп уйлагыз.
[36] Моннан элегрәк үзен бик бөек итеп күрсәтергә тырышучы
Тәүдәс дигән кеше пәйда булды, аңа дүрт йөзгә якын кеше
иярде. Әмма ул үтерелү белән, аңа иярүчеләр төркеме юкка
чыкты. [37] Шуннан соң сан алу көннәрендә гәлиләяле Яһүд пәй-
да булды һәм күпмедер халыкны фетнәгә котыртты. Әмма ул
һәлак булганнан соң аңа ияргән халык та таралды. [38] Шуңа күрә
хәзер сезгә әйтәм: бу кешеләргә тимәгез! Аларны җибәрегез!
Чөнки бу ният һәм бу эш кешеләрдән булса, ул юкка чыгачак.
[39] Ә инде Аллаһыдан булса, сез аны юкка чыгара алмаячаксыз.
Аллаһыга каршы көрәшүчеләр була күрмәгез, – диде ул.

[40] Аксакаллар аның сүзенә колак салдылар. Рәсүлләрне чакы-
рып керттеләр һәм кыйнаганнан соң, Гайсә исеме хакында өй-
рәтмәскә боерып, аларны иреккә җибәрделәр. [41] Рәсүлләр исә,
Гайсә исеме өчен кимсетелүгә лаек булганнарына шатланып,
Киңәшмәдән чыгып киттеләр. [42] Һәр көн Аллаһы Йортында
һәм өйләрдә Яхшы хәбәрне – Гайсәнең Мәсих икәнлеге ха-
кында сөйләүләрен һәм өйрәтүләрен дәвам иттеләр.

*Ярдәмчеләр сайлау*

6 [1] Шәкертләрнең саны арта барган шул көннәрдә, грек
яһүдләре, көндәлек ризыкны бүлгән вакытта үзләренең
тол хатыннарын исәпкә алмыйлар дип, җирле яһүдләрдән
ризасызлык белдерделәр. [2] Шуңа күрә унике рәсүл, барлык
шәкертләрне җыеп:

– Без, ризык бүлү белән шөгыльләнеп, Аллаһы сүзенә игъ-
тибарны киметергә тиеш түгелбез, – диделәр. [3] – Шулай бул-
гач, туганнар, үз арагыздан Рух һәм зирәклек белән тулы
булган җиде кешене сайлап алыгыз. Без аларны шушы эшкә
куярбыз. [4] Ә безнең төп эшебез дога кылу һәм сүз белән хез-
мәт итү булыр.

[5] Бу тәкъдим барсына да ошады. Иман һәм Изге Рух белән
тулы булган Эстефәнне, шулай ук Филипне, Прохырны, Никә-
нүрне, Тимунны, Парменне һәм яһүд диненә мәҗүсилектән
кабул ителгән антиухеяле Никүләйне сайладылар. [6] Аларны
рәсүлләр алдына бастырдылар. Рәсүлләр аларның башларына
кулларын куеп дога кылдылар.

[7] Шулай итеп, Аллаһы сүзе киң таралды, Иерусалимда шәкерт-
ләр саны күпкә артты, руханиларның да бик күбесе итагатьлек
белән иман итте.

*Эстефәннең кулга алынуы*

[8] Ә мәрхәмәт һәм кодрәт белән тулы булган Эстефән исә
халык арасында бөек могҗизалар һәм галәмәтләр кылды. [9] Шу-
лай бервакыт «Азат ителгәннәр гыйбадәтханәсе» дип аталган
гыйбадәтханәнең Күринидән һәм Искәндәриядән, шулай ук
Киликия һәм Асия өлкәләреннән булган кайбер әгъзалары
Эстефән белән бәхәскә керделәр, [10] әмма аның сүзләрендәге
зирәклеккә һәм Рухка каршы тора алмадылар. [11] Шуннан соң
алар кайберәүләргә:

— Без аның Мусага һәм Аллаһыга каршы көфер сөйләгәнен ишеттек, — дип коткы салдылар.

[12] Халыкны, аксакалларны һәм канунчыларны Эстефәнгә
каршы котыртып, һөҗүм итеп аны тоттылар һәм Югары ки-
ңәшмәгә алып киттеләр. [13] Алар Киңәшмәдә ялган шаһитләр-
гә сүз бирделәр. Ә тегеләре исә:

— Бу кеше шушы изге урынга һәм канунга каршы көфер сөй-
ләүдән туктамый, — диделәр. — [14] Без аның: «Насаралы Гайсә бу
урынны җимерәчәк һәм Муса безгә биргән йолаларны үзгәртә-
чәк», — дигәнен ишеттек.

[15] Киңәшмәдә утыручы барлык кешеләр Эстефәнгә карады-
лар. Аның йөзе фәрештәнеке кебек иде.

*Эстефән Югары киңәшмә алдында*

**7** [1] Иң баш рухани Эстефәннән:
— Бу гаепләүләр дөресме? — дип сорады.
[2] — Туганнар һәм аксакаллар! — дип сүзен башлады Эсте-
фән. — Тыңлагыз. Атабыз Ибраһим Харан шәһәренә күчеп кил-
гәнче, Месупотамиядә аңа шөһрәтле Аллаһы күренгән [3] һәм:
«Үзең яши торган җирне һәм туганнарыңны калдыр һәм Мин
күрсәтәчәк җиргә кит», — дигән. [4] Шуннан соң Ибраһим, хал-
дайлыларның биләмәләреннән чыгып, Харанга күчеп килгән.
Атасы вафат булганнан соң Аллаһы аны хәзер сез яши торган
менә шушы якларга күчергән. [5] Монда аның үзенә аз гына да
биләмә бирмәгән, ләкин аңа һәм аның киләчәк буыннарына бу
җирне бирергә вәгъдә иткән. Ул вакытта әле Ибраһимның ба-
ласы да булмаган. [6] Аллаһы аңа: «Синең киләчәк буыннарың
чит җирдә килмешәк булачаклар, дүрт йөз ел буена коллыкта
изелеп яшәячәкләр. [7] Әмма Мин аларны коллыкта тотачак ха-
лыкны хөкем итәчәкмен. Шуннан соң алар ул илдән чыгачак-
лар һәм шушы җирдә Миңа хезмәт итәчәкләр», — дигән.
[8] Аллаһы Ибраһим атабыз белән килешү төзегән һәм, шул
килешүнең билгесе итеп, сөннәткә утырту йоласын биргән.

Шулай итеп, Исхак туганнан соң сигезенче көнне атасы Ибра-
һим аны сөннәткә утырткан. Шулай ук итеп Исхак Ягъкубны,
ә Ягъкуб булачак унике ыруг башлыгын сөннәтләгән. 9 Ыруг
башлыклары, көнләшеп, Йосыфны Мисырга сатып җибәргән-
нәр. Әмма Аллаһы аның белән булган, 10 аны барлык хәсрәт-
ләрдән коткарган. Йосыфны зирәк акыллы итеп, Аллаһы аңа
Мисыр патшасы булган фиргавеннең яхшы мөнәсәбәтен яуларга
мөмкинлек биргән. Фиргавен исә аны Мисырга һәм үзенең са-
раена идарәче итеп билгеләгән.
11 Бөтен Мисыр һәм Кәнган җиренә зур михнәт – ачлык кил-
гән, һәм безнең аталарыбыз ризык таба алмаганнар. 12 Ягъ-
куб, Мисырда ашлык барлыгын ишеткәч, ул илгә безнең атала-
рыбызны беренче тапкыр җибәргән. 13 Ә алар икенче тапкыр
килгәч, Йосыф ир-туганнарына үзенең кем икәнлеген ачкан,
һәм фиргавен Йосыфның нәселе турында шул вакытта белгән.
14 Йосыф, хәбәр җибәреп, үзенең атасы Ягъкубны һәм бөтен
гаиләсен, җитмеш биш җанны, үзе янына чакырып китергән.
15 Ягъкуб Мисырга күчеп килгән һәм үзе дә, безнең аталарыбыз
да үлгәнче шунда яшәгәннәр. 16 Үлгәч, аларны Шәхәм шәһәре-
нә алып килеп, анда яшәүче Хамур улларыннан көмеш түләп
Ибраһим сатып алган кабергә күмгәннәр.
17 Ибраһимга Аллаһы биргән вәгъдәнең гамәлгә ашу вакыты
якынлашкан саен Мисырда безнең халык саны арта барган.
18 Йосыфны белмәгән башка бер патша хакимлек итә башла-
ган. 19 Ул патша безнең нәселгә карата бик мәкерле булган, хал-
кыбызны юк итәргә теләгән: бер генә яңа туган нарасый да
исән калмасын өчен, аталарыбызны балаларын ташларга мәҗ-
бүр иткән.
20 Шул вакытта Муса туган. Ул бик күркәм бала булган, аны
өч ай буе үз атасы өендә тәрбияли алганнар. 21 Ә чыгарып таш-
ланганнан соң Мусаны фиргавен кызы тапкан һәм үз улыдай
күреп тәрбияләгән. 22 Муса мисырлыларның барлык гыйлемнә-
рен өйрәнгән, сүздә дә, эштә дә куәтле булган.
23 Кырык яшь тулгач, аның күңелендә үз туганнары – исра-
иллеләр янына барып килү теләге туган. 24 Алар янында булган
чакта бер мисырлының исраиллене рәнҗетүен күргән һәм,
мисырлыны үтереп, кыйналган кеше өчен үч алган. 25 «Аллаһы
минем аркылы аларга котылу бирәчәген туганнарым аңлар-
лар», – дип уйлаган Муса. Ләкин алар аңламаганнар. 26 Икенче
көнне, ике исраилленең сугышканын күреп, ул алар янына
килгән. Аларны татулаштырырга теләп: «Сез туганнар бит,
нигә бер-берегезне кыйныйсыз?» – дигән. 27 Әмма үзенең ип-
тәшен рәнҗетүче, Мусаны этеп җибәреп: «Сине безнең өстән

башлык һәм хөкем кылучы итеп кем билгеләде? 28 Кичә мисыр-
лыны үтергән кебек, әллә мине дә үтерергә телисеңме?» – ди-
гән. 29 Муса, бу сүзләрне ишеткәннән соң, качып киткән һәм
Мидьян җирендә килмешәк булып яши башлаган. Анда аның
ике улы туган.

30 Кырык ел үткәч, Синай тавы чүлендә янып торучы күгән
куагының ялкынында аңа бер фәрештә күренгән. 31 Муса, моны
күреп, бик гаҗәпләнгән. Ә инде карарга дип якынрак килгәч,
Раббының: 32 «Мин – синең аталарың табынган Аллаһы. Мин –
Ибраһим, Исхак һәм Ягъкуб Аллаһысы», – дигән авазын
ишеткән. Муса, куркуыннан калтыранып, күтәрелеп карарга
да батырчылык итә алмаган. 33 Раббы аңа: «Аяк киемеңне сал,
чөнки син басып торган җир – изге урын. 34 Мин халкымның
Мисырда җәберләнүен күрдем. Әйе, Мин моны күрдем, хал-
кымның сыкрануын ишеттем һәм аны азат итү өчен индем.
Юлга чык, Мин сине Мисырга җибәрәм», – дигән.

35 «Сине безгә башлык һәм хөкем кылучы итеп кем билге-
ләде?» – дип исраиллеләр кире каккан шул Мусаны, Аллаһы
күгән куагында күренгән фәрештә аркылы, башлык һәм азат
итүче итеп җибәргән. 36 Мисыр җирләрендә, Кызыл диңгездә
һәм кырык ел буена чүлләрдә могҗизалар, галәмәтләр күрсә-
теп, аларны Мисырдан ул алып чыккан. 37 Исраил халкына:
«Аллаһы сезгә туганнарыгыз арасыннан минем кебек Пәйгам-
бәр күтәрәчәк», – дип әйтүче дә шул Муса. 38 Синай тавында
фәрештә әйткән сүзләрне чүлдә җыелган халыкка нәкъ менә
ул җиткергән. Безгә тапшыру өчен тере сүзләрне кабул итеп ул
алган.

39 Безнең аталарыбыз, Муса әйткәнне тыңламыйча, кабат
Мисырга китәргә теләгәннәр. 40 Һарунга: «Юлыбызда безне
алып барачак илаһлар яса. Чөнки безне Мисырдан алып чык-
кан Муса белән нәрсә булганын да белмибез», – дигәннәр.
41 Шул көннәрдә, бозау кыяфәтле пот ясап, шул потка корбан
китергәннәр һәм үз куллары белән ясаган әйбергә карап күңел
ачканнар. 42 Аллаһы исә алардан читкә борылган һәм аларны
күктәге йолдызларга хезмәт итәргә калдырган. Пәйгамбәрләр-
нең язмаларында исә болай дип язылган:

«Әй, Исраил халкы! Кырык ел буе чүлдә
Хайваннар суеп Миңа корбан китердегезме?
43 Молых илаһның чатырын,
Райфан илаһыгыз йолдызын –
Табыну өчен үзегез
Ясаган шул потларны –
Сез күтәреп йөрдегез.

Шуңа күрә Мин сезне
Бабылдан да арырак
Сөргенгә җибәрәчәкмен».

44 Ата-бабаларыбызның чүлдә шаһитлек чатыры* булган. Ул
чатыр, Аллаһы Мусага боерганча, аңа күрсәтелгән үрнәктә ясал-
ган булган. 45 Безнең ата-бабаларыбыз ул чатырны үзләренең
аталарыннан кабул итеп алганнар. Алар, Ешуа җитәкчелегендә,
халыкларын Аллаһы куып чыгарган җирне яулап алганнар һәм
чатырны шунда куйганнар. Чатыр Давыт патша көннәренә кадәр
шул җирдә калган. 46 Давыт Аллаһыга бик ошаган. Ул Ягъкубның
Аллаһысына яшәү өчен урын табып бирергә рөхсәт сораган.
47 Ә йортны Аллаһыга Сөләйман салган. 48 Әмма Аллаһы Тәгалә
кул белән ясалган корылмаларда яшәми. Пәйгамбәр әйткәнчә:

49 «Күк – Минем тәхетем,
Ә җир – Минем аяк астым, – ди Раббы. –
Нинди йорт сала аласыз сез Миңа?
Нинди Минем яши торган урыным?
50 Һәммәсен дә боларның
Булдырмадымы әллә Минем шушы кулларым?»

51 Үҗәт халык! Йөрәкләрегез белән дә, колакларыгыз белән
дә сөннәтсез адәмнәр! Сез, аталарыгыз кебек үк, Изге Рухка
һәрвакыт каршы киләсез. 52 Сезнең ата-бабаларыгыз эзәрлеклә-
мәгән берәр пәйгамбәр калдымы икән? Алар Хак Затның ки-
ләчәген алдан хәбәр итүчеләрне үтергәннәр, ә хәзер сез Аның
Үзенә хыянәт иттегез һәм Аны үтердегез. 53 Сез фәрештәләр ар-
кылы Аллаһыдан бирелгән канунны кабул итеп алдыгыз, ләкин
аны үтәмәдегез.

*Эстефәннең үтерелүе*

54 Шушы сүзләрне ишеткәч, Киңәшмәдә утыручылар ачула-
рыннан тешләрен шыкырдаттылар. 55 Изге Рух белән тулы бул-
ган Эстефән исә, күккә карап, Аллаһының шөһрәтен һәм Ал-
лаһының уң ягында торган Гайсәне күрде.

56 – Мин ачылган күкләрне һәм Аллаһының уң ягында басып
торучы Адәм Улын** күрәм, – диде ул.

57 Ә тегеләр, колакларын томалап, акыра-акыра, барысы
бергә Эстефәнгә ташландылар. 58 Шәһәрдән алып чыгып, аңа

---

* 7:44 *Шаһитлек чатыры* – исраиллеләр Аллаһы Йортын төзегәнче шушы чатырда Аллаһыга табынганнар. (Тәүрат, «Чыгыш» китабы, 25:8, 22.)

** 7:56 *Адәм Улы* – Эстефән монда шушы исем белән Гайсә Мәсихне атый. (Сүзлекне карагыз.)

ташлар ата башладылар. Шаһитләр исә үзләренең киемнәрен
Шаул исемле бер яшь егет янына куеп тордылар. [59] Алар ташлар
аткан вакытта Эстефән, дога кылып:

– Раббым Гайсә, минем рухымны кабул ит, – дип, [60] тезлә-
ренә егылып, көчле тавыш белән: – Раббым! Бу эшне аларга
гөнаһ дип санама, – диде һәм җан бирде.

8 [1] Шаул исә бу үтерүне хуплады.

*Бердәмлекнең таралуы*

Шул көннәрдә Иерусалимдагы мәсихчеләрне нык эзәрлекли
башладылар һәм рәсүлләрдән башкалар барысы да Яһүдиянең
һәм Самареянең төрле урыннарына таралдылар.

[2] Аллаһыга бирелгән кешеләр Эстефәнне күмеп куйдылар
һәм аның өчен бик нык кайгырып еладылар. [3] Ә Шаул мәсих-
челәр бердәмлеген газаплый башлады. Өйдән-өйгә йөрде,
ир-атларны һәм хатын-кызларны сөйрәп алып чыгып, зин-
данга япты.

*Филип Самареядә*

[4] Таралышкан мәсихчеләр, кайда гына булсалар да, вәгазь
сөйләп йөрделәр. [5] Филип, Самарея шәһәренә барып, шәһәр
халкына Мәсих турында сөйләде. [6] Филип кылган галәмәтләр
турында ишеткәнгә һәм ул галәмәтләрне үз күзләре белән күр-
гәнгә күрә, күп халык ул сөйләгән сүзләрне бергәләп дикъкать
белән тыңлады. [7] Күп кешеләрдән шакшы рухлар көчле тавыш
белән акырып чыктылар. Параличланган һәм аксак булган күп
кешеләр савыкты. [8] Шәһәр халкы бу эшләргә бик куанды.

[9] Ул шәһәрдә, күпмедер вакыт сихерчелек итеп, Самарея хал-
кын хәйран калдырган, үзен бөек дип саный торган Шимун
исемле бер кеше бар иде. [10] Кечесе дә, олысы да – барчасы аңа
дикъкать итә иде. «Бу кеше – бөек дип аталган илаһи кодрәт», –
дип әйтәләр иде аның хакында. [11] Ул аларны шактый вакыт
үзенең сихерләре белән шаккатырып торганлыктан, кешеләр
аны тыңлыйлар иде. [12] Әмма Аллаһы Патшалыгы һәм Гайсә
исеме хакында Филип сөйләгән Яхшы хәбәргә ышангач, ирләр
дә, хатыннар да суга чумдырылу йоласын үттеләр. [13] Шимун
үзе дә иман китерде һәм суга чумдырылды. Ул Филип яныннан
бер адымга да китмәде. Аның зур галәмәтләр һәм кодрәтле
эшләр кылуын күреп, чиксез хәйран калды.

[14] Иерусалимда булган рәсүлләр, самареялеләрнең Аллаһы сү-
зен кабул итүләрен ишетеп, Петер белән Яхъяны алар янына җи-
бәрделәр. [15] Петер белән Яхъя, Самареягә килгәч, андагылар Изге
Рухны кабул итсеннәр өчен дога кылдылар. [16] Чөнки алар инде

Раббы Гайсә исеменә суга чумдырылган, ләкин берсенә дә әле
Изге Рух иңмәгән була. [17] Шуннан соң Петер белән Яхъя сама-
реялеләрнең башларына кулларын куйдылар һәм тегеләр Изге
Рухны кабул иттеләр. [18] Шимун исә, Рухның рәсүлләр кулларын
куйганнан соң бирелгәнен күреп, аларга акча тәкъдим итте.

[19] – Мин кулымны башына куйган һәр кеше Изге Рухны ала
алсын өчен миңа да шундый вәкаләт бирегезче, – диде ул.

[20] Әмма Петер аңа:

– Әгәр Аллаһы бүләген акчага сатып алырга мөмкин дип
уйлыйсың икән, акчаларың белән бергә һәлак булырсың, –
диде. – [21] Син бу эштә катнаша алмыйсың, чөнки Аллаһы кар-
шында синең күңелең чиста түгел. [22] Шуңа күрә, үзеңнең бу
явызлыгыңнан тәүбә ит һәм Раббыга дога кыл. Бәлки йөрәгең-
дәге уең кичерелер. [23] Чөнки синең ачы көнчелек белән тулган-
лыгыңны һәм гөнаһ богауларында икәнлегеңне күрәм.

[24] – Сез әйткәннәрнең берсе дә минем белән була күрмәсен
өчен Раббыга дога кылыгыз, – дип җавап бирде Шимун.

[25] Петер белән Яхъя, Раббы сүзен аңлатып вәгазь иткәннән
соң, кире Иерусалимга киттеләр. Юл уңаеннан Самареянең күп
кенә авылларында Яхшы хәбәрне игълан иттеләр.

*Филип һәм хәбәш кешесе*

[26] Раббының бер фәрештәсе Филипкә:

– Тор да көньякка таба, Иерусалимнан Газага илтә торган
юлга бар, – диде.

Ул юл чүл аша уза иде.

[27] Филип шул юлга чыкты һәм Аллаһыга табыну өчен Иеру-
салимга килгән хәбәш кешесенең иленә кайтып баруын күрде.
Ул кеше сарай хезмәтчесе*, Хәбәшстан патшасы кәндәки** ха-
тынның бөтен хәзинәсен саклаучы югары дәрәҗәле түрә иде.
[28] Хәбәш үзенең арбасында Ишагыйя пәйгамбәр китабын укып
утыра иде. [29] Рух Филипкә:

– Арбага якынрак кил, – диде.

[30] Филип арба янына йөгерде һәм хәбәшнең Ишагыйя пәй-
гамбәр язган китапны укуын ишетте.

– Укыганыңны аңлыйсыңмы? – дип сорады ул аннан.

[31] – Берәр кеше төшендермәсә, ничек аңлый алыйм? – диде
ул һәм Филипкә үзе янына утырырга тәкъдим итте.

---

* 8:27 *Сарай хезмәтчесе* – бу сүзнең төп нөсхә грек телендә беренче мәгънәсе евнух, печелгән кеше. Ул вакытларда сарай хезмәтчеләре булып күпчелек печелгән кешеләр хезмәт иткәннәр.

** 8:27 *Кәндәки* – Хәбәшстандагы хатын-кыз патшаларның титулы.

[32] Хәбәш Изге язманың шушы урынын укый иде:
«Ул, сарык кебек, суярга китерелде.
Йонын кыркучы алдында
Тавышсыз торган бәрән кебек,
Авызын да ачмады.
[33] Ул кимсетелде,
Гадел хөкемнән мәхрүм булды.
Аның нәселе турында кем әйтә алыр?
Аның тормышы җирдән алынды бит».
[34] Түрә исә Филиптән:
– Зинһар өчен, әйтче миңа. Монда пәйгамбәр кем хакында сөйли? Үзе хакындамы, әллә башка берәү турындамы? – дип сорады.
[35] Филип аңа Гайсә хакындагы Яхшы хәбәрне шул урыннан
башлап сөйләп бирде. [36] Шулай бара торгач, алар су янына
килеп җиттеләр.
– Менә бит, монда су бар, чумдырылырга миңа нәрсә комачаулый? – диде хәбәш.
[ [37] – Чын күңелеңнән иман итсәң, мөмкин, – диде Филип.
– Гайсә Мәсихнең Аллаһы Улы икәнлегенә иман китерәм, – диде хәбәш.]*
[38] Ул арбаны туктатырга кушты, алар Филип белән суга керде-
ләр һәм Филип аны суга чумдырып алды. [39] Алар судан чыккач,
хәбәшкә Изге Рух инде. Филипне Раббының бер фәрештәсе
алып китте һәм түрә аны бүтән күрмәде. Хәбәш, шатланып,
юлын дәвам итте. [40] Ә Филип Азут шәһәрендә пәйда булды.
Ул, Кайсариягә килеп җиткәнче, шәһәрләрдә Яхшы хәбәрне
вәгазьләп йөрде.

*Шаулның Аллаһыга таба борылуы*

9 [1] Шаул исә һаман да, Раббының шәкертләрен үтерергә
теләп, аларга яный иде. Ул иң баш руханидан [2] Гайсә
юлыннан баручы ир-атларны да, хатын-кызларны да кулга
алу һәм Иерусалимга алып килү вәкаләтен бирә торган хат сорап алды. Хат Дәмәшекъ гыйбадәтханәләре өчен иде.
[3] Юлда барганда, инде Дәмәшекъкә якынлашып килгән ва-
кытта, кинәт Шаулның тирә ягы күктән төшкән яктылыктан
балкып китте. [4] Ул җиргә егылды һәм:
– Шаул, Шаул! Нигә син Мине эзәрлеклисең? – дигән тавыш ишетте.
[5] – Син кем, Әфәнде? – дип сорады Шаул.

---

* 8:37 Иң элекке кулъязмаларда бу аять юк.

– Мин – син эзәрлекли торган Гайсә, – дип җавап бирде
тавыш. 6 – Тор да шәһәргә бар. Нәрсә эшләргә кирәклеге ха-
кында анда сиңа әйтелер.
7 Шаул белән бергә булган кешеләр тавыш-тынсыз басып
торалар иде. Чөнки алар әлеге тавышны ишеттеләр, әмма
һичкемне күрмәделәр.
8 Шаул җирдән торды, күзләрен ачты, ләкин беркемне дә
күрә алмады. Шуңа күрә Дәмәшекъкә аны җитәкләп алып
килделәр. 9 Өч көн буе аның күзләре күрмәде, һәм ул ашамады
да, эчмәде дә.
10 Дәмәшекътә Һанани исемле бер шәкерт бар иде. Илаһи
күренештә Раббы аңа:
– Һанани! – дип эндәште.
– Әйе, Раббым, – диде ул.
11 – Туры урам дип аталган урамга бар. Яһүд яши торган
йортка кереп Шаул исемле тарслыны сора. Ул хәзер дога кыла.
12 Ул илаһи күренештә Һанани исемле берәүнең үзе янына ки-
лүен һәм, күзләре янә күрә башласын өчен, Һананиның аның
өстенә кулларын куюын күрде, – диде аңа Раббы.
13 – Раббым! Мин күп кешеләрдән ул адәмнең Иерусалим-
да Синең изгеләреңә күрсәткән күпме явызлыклары турында
ишеттем. 14 Сиңа табынучыларның барысын монда да кулга
алырга аның баш руханилардан вәкаләте бар, – диде Һанани.
15 Әмма Раббы аңа:
– Кузгал, чөнки Мин аны чит халыкларга һәм патшаларга,
шулай ук Исраил халкына, Минем турыда шаһитлек бирү өчен,
Үземнең корал итеп сайладым. 16 Үземнең исемем хакына аның
күпме газап чигәргә тиешлеген Мин аңа күрсәтермен, – диде.
17 Һәм Һанани, шул йортка килеп, Шаул өстенә кулларын
куйды.
– Шаул туган! Күзләрең күрә башласын өчен һәм сине Изге
Рух белән сугарырга дип Раббы – сиңа юлда күренгән Гайсә –
мине синең яныңа җибәрде, – диде Һанани.
18 Шундук, күзләрен каплап торган тәңкәләр коелып төш-
кәндәй, Шаул тагын күрә башлады. Ул урыныннан торды һәм
суга чумдырылу йоласын үтте. 19 Ашап алганнан соң, аңа янә
көч керде.
Шаул берничә көн шәкертләр белән бергә Дәмәшекътә
булды. 20 Ул шундук: «Гайсә – Аллаһы Улы», – дип, гыйбадәт-
ханәләрдә вәгазь сөйләп йөри башлады.
21 Аның сөйләгәнен ишеткән бар кеше, хәйран калып:
– Иерусалимда шул Кешегә табынучыларны юкка чыгарыр-
га тырышкан кеше түгелме соң бу? Монда да ул аларны, кулга

алып, баш руханиларга тапшыру өчен килмәдеме икән? – ди-
деләр.
22 Ә Шаул кодрәтләнгәннән кодрәтләнде. Гайсәнең Мәсих
икәнлеген исбат итеп йөреп, Дәмәшекъта яшәүче яһүдләрне
аптырашка төшерде.
23 Шактый күп вакыт үткәч, яһүдләр аны үтерергә сүз куеш-
тылар. 24 Алар аны үтерү өчен көне-төне шәһәр капкаларын
күзәтеп тордылар. Әмма Шаул аларның бу ниятен белеп алды.
25 Шәкертләр аны төнлә белән, кәрзингә утыртып, шәһәр дива-
ры аркылы төшерделәр.

### *Шаул Иерусалимда*

26 Иерусалимга килгәч, Шаул шәкертләр белән бергә булырга
тырышты, әмма барысы да аннан курыктылар, аның Гайсә шә-
керте булуына ышанмадылар. 27 Барнаб исә Шаулны рәсүлләр
янына алып килде һәм аның юлда Раббыны күрүен, Раббының
аңа нәрсәләр әйтүен, аның Дәмәшекъта Гайсә исеме хакында
кыюлык белән вәгазь әйткәнен аларга сөйләп бирде.
28 Шаул шәкертләр белән калды һәм Иерусалимда Раббы
исеме хакында кыю рәвештә вәгазьләп йөрде. 29 Шулай ук ул
грек яһүдләре белән күп тапкырлар очрашып сөйләште, бәхәс-
ләште. Ә алар аны үтерергә тырыштылар. 30 Имандашлар, бу
хакта белеп алгач, аны Кайсариягә озаттылар, ә аннан Тарска
җибәрделәр.
31 Бөтен Яһүдиядә, Гәлиләядә һәм Самареядә иман итүчеләр
бердәмлеге өчен тыныч заманнар килде. Бердәмлек ныгыды,
Раббыга карата тирән хөрмәт белән йөрде. Изге Рухның дәрт-
ләндерүе астында иман итүчеләрнең саны арта барды.

### *Петер Луддә һәм Яфу шәһәрләрендә*

32 Петер исә, бик күп җирләрдә булганнан соң, Аллаһының
Луддәдә яшәүче изге кешеләре янына килде. 33 Анда ул, сигез
ел буе авырып ятучы, паралич суккан Айнеас исемле бер ке-
шене күрде.
34 – Айнеас! Сине Гайсә Мәсих савыктыра. Ятагыңнан тор, –
диде аңа Петер.
Ул кеше шундук торды. 35 Луддәдә һәм Шарунда яшәүче бар
халык, савыккан кешене күреп, Раббыга иман китерделәр.
36 Яфу шәһәрендә Табита (грек телендә «Доркәс»*) исемле
иман итүче бер хатын бар иде. Ул һәрвакыт яхшы эшләр кыла,

---

* 9:36 *Доркәс* – Арамей телендә «Табита», грек телендә «Доркәс» дигән исемнәр «кыр кәҗәсе» дигән мәгънәне аңлата.

фәкыйрьләргә ярдәм итә иде. 37 Шул көннәрдә ул хатын авырып вафат булды. Аны юып, югары каттагы бер бүлмәгә урнаштырдылар. 38 Лүддә Яфуга якын булганлыктан, шәкертләр Петернең анда икәнен ишеттеләр һәм, аның үзләре янына тизрәк килүен үтенеп, Петер янына ике кешене җибәрделәр. 39 Петер алар белән бергә Яфуга килде, һәм аны югары каттагы бүлмәгә алып керделәр. Барлык тол хатыннар, Петер янына килеп, елый-елый, Доркәс теккән күлмәкләрне, киемнәрне күрсәттеләр. 40 Бүлмәдән бөтен кешеләрне чыгарып җибәргәч, Петер тезләнеп дога кылды һәм, мәеткә таба борылып:

– Табита, тор! – диде.

Хатын күзләрен ачты һәм, Петерне күргәч, торып утырды. 41 Петер, кулын биреп, аны торгызды һәм иман итүчеләрне, тол хатыннарны чакырып, Табитаны алар каршына тере килеш бастырып куйды.

42 Бу хәл бөтен Яфу халкына билгеле булды, һәм күпләр Раббыга иман китерделәр. 43 Петер Яфуда Шимун исемле күнче йортында шактый вакыт яшәде.

*Петер һәм Көрнили*

**10** 1 Кайсариядә Италия полкы дип аталган гаскәрдә йөзбашы булып хезмәт итүче Көрнили исемле бер кеше бар иде. 2 Ул үзе һәм аның бөтен гаиләсе диндар, тирән хөрмәт белән Аллаһыдан куркучан иде. Ул халыкка күп хәер-сәдака бирә һәм һәрвакыт Аллаһыга гыйбадәт кыла иде.

3 Бер көнне, көндезге өчләр тирәсендә, Аллаһының бер фәрештәсе ап-ачык итеп Көрнилигә күренде. Фәрештә аның янына килеп:

– Көрнили! – дип эндәште.

4 Көрнили куркып калды, аңа күзләрен текәп:

– Нәрсә, әфәнде? – диде.

– Синең догаларыңны һәм хәерләреңне Аллаһы корбан итеп хәтерендә калдырды. Ул сине искә алды, – дип җавап бирде аңа фәрештә. 5 – Петер исемле Шимунны алып килергә Яфуга кешеләр җибәр. 6 Ул хәзер күнче Шимун янында кунакта, аның йорты диңгез буена урнашкан.

7 Фәрештә киткәч, Көрнили хезмәтчеләренең икесен һәм үз гаскәриләреннән диндар булган берсен чакырып алды. 8 Һәммәсен аңлатып, аларны Яфуга җибәрде.

9 Икенче көнне җибәрелгән кешеләр шәһәргә якынлашып килгәндә, көндезге уникеләр тирәсендә, Петер гыйбадәт кылу өчен яссы түбәле өйнең түбәсенә менде. 10 Аның карыны ач иде, ул ашарга теләде. Ашарга әзерләнгән арада Петер гадәти

булмаган гыйбадәт кылу халәтенә килде. [11] Ул күкнең ачылуын
һәм зур тукымага охшаган бер әйбернең дүрт почмагыннан
тотып җиргә төшерелүен күрде. [12] Аның эчендә җирдә яшәүче
һәртөрле дүрт аяклы җәнлекләр, сөйрәлүчеләр һәм киек кош-
лар бар иде. [13] Ул:

– Тор, Петер, суй һәм аша, – дигән тавыш ишетте.

[14] Әмма Петер:

– Юк, Раббым, минем беркайчан да шакшы яки хәрәм нәр-
сә ашаганым булмады, – диде.

[15] Шулвакыт ул янә:

– Аллаһы чиста дип игълан иткәнне шакшы дип исәпләмә, –
дигән тавыш ишетте.

[16] Өч тапкыр шулай кабатланды, һәм шунда ук әйбер күккә
күтәрелде. [17] Петер үзе күргән бу илаһи күренешнең нәрсәне
аңлатуын уйлап, аптырап торган арада, Көрнили тарафыннан
җибәрелгән кешеләр, Шимун өен эзләп табып, капка янына
килеп бастылар.

[18] – Петер исемле Шимун мондамы? – дип кычкырдылар.

[19] Күргән илаһи күренеш турында уйланып торганда, Рух
Петергә:

– Сине өч кеше эзли. [20] Төш һәм, һич шикләнмичә, алар
белән бар. Чөнки аларны Мин җибәрдем, – диде.

[21] Петер Көрнили җибәргән кешеләр янына төште:

– Сез эзләгән кеше – мин. Нинди эш белән килдегез? –
диде ул аларга.

[22] – Безне бөтен яһүд халкы алдында мөхтәрәм, тәкъва һәм
тирән хөрмәт белән Аллаһыдан куркучы йөзбашы Көрнили
җибәрде. Ул изге фәрештәдән син сөйләячәк сүзләрне тыңлау
өчен сине үз йортына чакырырга дигән боерык алды, – диде-
ләр алар.

[23] Шуннан соң Петер аларны өенә алып керде һәм кунак
итте, ә иртәгесен алар белән китте. Яфудан булган кайбер ту-
ганнар дә аларга ияр деләр. [24] Кайсариягә алар икенче көнне
барып җиттеләр. Көрнили исә, үзенең туганнарын һәм якын
дусларын җыеп, аларны көтеп тора иде. [25] Петер йортка кергән-
дә Көрнили аның каршысына чыкты һәм Петернең аяклары
алдына тезләнеп сәҗдә кылды.

[26] – Тор, мин дә кеше бит, – диде Петер һәм аны торгызды.

[27] Алар сөйләшә-сөйләшә өйгә керделәр. Петер анда күп ха-
лык җыелганлыгын күрде [28] һәм аларга:

– Сез, әлбәттә, беләсез: безнең дини канун буенча яһүдигә
башка халык кешеләре белән аралашырга, алар янына кунак-
ка йөрергә рөхсәт ителми. Әмма Аллаһы миңа бер кешене дә

шакшы яки хәрәм дип исәпләмәскә кирәклеген күрсәтте.
[29] Шуңа күрә, сез мине чакыру белән, мин һичсүзсез сезнең янга
килдем. Инде әйтегез: мине ни өчен чакырттыгыз? – диде.

[30] – Өч көн элек шушы вакытта, сәгать өчтә үз өемдә дога
кыла идем, – диде Көрнили. – Кинәт минем алда аксыл ялты-
равык кием кигән бер кеше пәйда булды [31] һәм миңа: «Көрни-
ли, Аллаһы синең догаңны ишетте һәм синең хәерләреңне
хәтергә алды. [32] Яфудан Петер исемле Шимунны алып килергә
кешеләр җибәр. Ул хәзер диңгез буенда яшәүче күнче Шимун
өендә кунакта», – диде. [33] Мин шундук сиңа кеше җибәрдем,
һәм син килеп яхшы эшләдең. Хәзер без һәммәбез, Раббы сиңа
сөйләргә кушкан бар сүзләрне тыңлау өчен, Аллаһы алдында
торабыз.

*Петер Көрнили өендә вәгазь сөйли*

[34] – Аллаһының кешеләрне аермавын мин хәзер чынлап та
аңлыйм, – дип сүзен башлады Петер. – [35] Һәр халык арасында
Аннан куркучылар һәм тәкъвалык кылучылар Аңа мәгъкуль.
[36] Аллаһы, Гайсә Мәсих аша килүче тынычлык хакындагы
Яхшы хәбәрне сөйләп, Исраил улларына Үзенең сүзен җи-
бәрде. Гайсә – һәммәбезнең Раббысы. [37] Яхъя, чумдырылу
йоласын үтегез, дип игълан иткәннән соң, Гәлиләядән алып
бөтен Яһүдиядә булган хәлләрне – [38] Аллаһының насаралы
Гайсәне Изге Рух һәм кодрәт белән майлаганын, Аллаһы Гайсә
белән булганга күрә, Аның, яхшы эшләр кылып, иблис кулын-
дагыларны савыктырып йөргәнен сез беләсез. [39] Ул яһүдләр
илендә һәм Иерусалимда кылган барлык эшләргә без шаһит-
без. Аны хачка асып үтерделәр. [40] Ә өченче көнне Аллаһы Аны
терелтеп торгызды. [41] Аллаһы, Үз ихтыяры буенча, Гайсәне
бөтен халыкка түгел, ә Үзе тарафыннан алдан ук сайланган
шаһитләргә күрсәтте. Ул шаһитләр – без, Ул үледән терелеп
торганнан соң Аның белән бергә ашаган һәм эчкән кешеләр.
[42] Гайсә – терeләргә һәм үлеләргә Аллаһы тарафыннан бил-
геләп куелган хөкем итүче Хаким. Гайсә безгә шушы хакта
халыкка вәгазьләргә һәм шаһитлек итәргә боерык бирде.
[43] Барлык пәйгамбәрләр, Аңа иман итүче һәркем Аның исеме
аркылы гөнаһларының кичерелүен алыр дип, Аның хакында
сөйләделәр, – диде Петер.

*Яһүд булмаганнар Изге Рухны кабул итә*

[44] Петер бу нотыгын сөйләгән вакытта ук тыңлаучыларның
барысына да Изге Рух инде. [45] Петер белән бергә килгән иман
итүче яһүдләр Изге Рухның яһүд булмаганнарга да бирелүенә

бик нык гаҗәпләнделәр. 46 Чөнки алар тегеләрнең таныш булма-
ган телләрдә сөйләүләрен һәм Аллаһыны олылап мактауларын
ишеттеләр. Шул вакыт Петер:
47 – Бу кешеләр безнең кебек үк Изге Рухны кабул итеп ал-
дылар. Шуңа күрә аларны суга чумдырылудан кем тыя алыр? –
диде.
48 Ул аларны Гайсә Мәсих исеменә суга чумдырырга әмер
бирде. Аннары алар Петердән үзләре янында берничә көнгә
калуын үтенделәр.

*Аллаһы тазартканны шакшы дип исәпләмә*

11 1 Рәсүлләр һәм бөтен Яһүдиянең буеннан-буена яшәгән
иман итүче туганнар яһүд булмаган кешеләрнең дә Ал-
лаһы сүзен кабул итүләре хакында ишеттеләр. 2-3 Петер
Иерусалимга килгәч, яһүдләр:
– Син сөннәтсез кешеләр янына кереп алар белән ашаган-
сың, – дип, аны тиргәделәр.
4 Һәм Петер аларга җентекләп сөйләп бирде:
5 – Мин Яфу шәһәрендә дога кыла идем һәм, гадәти булма-
ган гыйбадәт кылу халәтенә килеп, бер илаһи күренеш күрдем:
зур тукымага охшаган бер әйбер дүрт почмагыннан тотып күк-
тән минем яныма төшерелде. 6 Мин аның эченә күз ташладым
һәм җирдә яшәүче дүрт аяклы хайваннарны, җәнлекләрне,
сөйрәлүчеләрне һәм киек кошларны күрдем. 7 Шуннан соң:
«Тор, Петер, боларны суй һәм аша», – дигән тавыш ишеттем.
8 «Юк, Раббым, беркайчан да минем авызыма шакшы яки хә-
рәм нәрсәнең кергәне юк», – дидем мин. 9 Күктән аваз миңа
икенче тапкыр: «Аллаһы чиста дип игълан иткәнне шакшы дип
исәпләмә», – диде. 10 Бу өч тапкыр кабатланды һәм бөтенесе
тагын күккә тартып алынды.
11 Нәкъ шул вакыт мин булган йорт алдына Кайсариядән ми-
нем янга җибәрелгән өч кеше килеп басты. 12 Рух миңа: «Һич тә
шикләнмичә алар белән бар», – диде. Хәзер минем янымда
торучы бу алты туган да минем белән бергә барды. Без ул ке-
шенең өенә килеп җиттек. 13 Ул безгә ничек итеп үз өендә
фәрештәне күрүе хакында сөйләде. Фәрештә аңа: «Петер исем-
ле Шимунны чакыру өчен Яфуга кешеләр җибәр. 14 Ул сиңа
сөйләячәк сүзләр аша син үзең һәм бөтен йортың котыла-
чак», – дип әйткән.
15 Мин сөйли башлагач, башта безгә иңгән кебек, аларга да
Изге Рух иңде. 16 Шулвакыт мин Раббының: «Яхъя суга чум-
дырды, ә сез Изге Рухка чумдырылырсыз», – дигән сүзләрен
хәтергә төшердем. 17 Шулай итеп, без Раббы Гайсә Мәсихкә

иман китергәч, безгә биргән бүләкне Аллаһы аларга да биргән икән, Аллаһыга каршы торырга кем мин? – диде Петер.

[18] Моны ишеткәч, иман итүче туганнар тынычландылар һәм Аллаһыны данлап:

– Димәк, тормыш бирә торган тәүбә итү юлын Аллаһы яһүд булмаган халыкларга да ачкан, – диделәр.

*Антиухея шәһәрендә Гайсә Мәсихкә иман итүчеләр бердәмлеге*

[19] Эстефән белән булган вакыйгалар аркасында килеп чыккан
эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә таралышкан иман итүчеләр, яһүд-
ләргә генә вәгазьләп, Фойникә өлкәсенә, Кипрга һәм Антиу-
хея шәһәренә кадәр барып җиттеләр. [20] Әмма алар арасында-
гы кайсыбер кипрлылар һәм күринилеләр, Антиухеягә килгәч,
яһүд булмаганнарга да Раббы Гайсә хакындагы Яхшы хәбәрне
сөйләделәр. [21] Раббының көче алар белән булды, һәм бик күп-
ләр, инанып, Раббыга таба борылдылар. [22] Бу хактагы хәбәр
Иерусалимдагы иман итүчеләр бердәмлегенә барып җитте, һәм
Барнабны Антиухеягә җибәрделәр.

[23] Антиухеягә килгәч, ул Аллаһы мәрхәмәтенең җимешләрен
күреп шатланды һәм андагы кешеләрне Раббыга чын күңелдән
тугры булып калырга өндәде. [24] Барнаб Изге Рух һәм иман бе-
лән тулы яхшы кеше иде, һәм иман итүчеләр санына күп халык
кушылды.

[25] Шуннан соң Барнаб Шаулны эзләргә дип Тарска китте
һәм, аны табып, Антиухеягә алып килде. [26] Алар бер ел буе
иман итүчеләр бердәмлеге белән очраштылар, күп кешеләрне
өйрәттеләр. Иң беренче тапкыр шәкертләрне «мәсихчеләр»
дип Антиухея шәһәрендә атый башладылар.

[27] Шул көннәрдә Антиухеягә Иерусалимнан пәйгамбәрләр
килде. [28] Аларның берсе, Һагәб исемлесе, торып басты һәм
бөтен җирдә зур ачлык булачагы хакында Рух аркылы алдан
күреп әйтте. (Ул ачлык Кләүди кайсар* заманында булды.)

[29] Шуннан соң шәкертләр, һәрберсенең хәленнән килгәнчә,
Яһүдиядә яшәүче туганнарга ярдәм җибәрергә булдылар. [30] Һәм
шулай эшләделәр дә: җыелган бүләкләрне Барнаб белән Шаул
аша Гайсә Мәсихкә иман итүчеләр бердәмлегенең өлкәннә-
ренә** җибәрделәр.

---

* 11:28 *Кайсар* – борынгы Рим императорының рәсми исемнәреннән берсе.

** 11:30 *Өлкәннәр* – Гайсә Мәсихкә иман итүчеләр бердәмлегендә баш кешеләр.

*Петернең кулга алынуы*

**12** [1] Шул вакытларда Һируд патша*, явызлык эшләү нияте
белән, иман итүчеләр бердәмлегендәге кайбер кешеләрне
эзәрлекли башлады. [2] Яхъяның туганы Ягъкубны кылыч
белән чабып үтертте. [3] Бу эшнең яһүдләргә ошавын күреп, Петерне дә кулга алды – ул вакытта Төче күмәч бәйрәме көннәре
иде – [4] аны зинданга утыртты һәм, Коткарылу бәйрәменнән
соң халык алдына чыгарырга уйлап, дүртәр гаскәридән торган
дүрт төркемгә аны сакларга әмер бирде. [5] Петер зинданда сак
астында булган вакытта иман итүчеләр бердәмлегендә аның
өчен Аллаһыга бик тырышып дога кылдылар.

*Петернең азат ителүе*

[6] Һируд Петерне халык алдына чыгарырга теләгән көнгә каршы төндә Петер, ике богау белән богауланган хәлдә, ике гаскәри уртасында йоклап ята иде. Ә ишек янында каравылчылар
сакта торды. [7] Кинәт Раббының бер фәрештәсе пәйда булды
һәм бүлмә эче яктырып китте. Фәрештә Петерне төртеп уятты.

– Тизрәк тор! – диде ул аңа.

Шул вакыт Петернең кулларыннан богаулары шуып төште.

[8] – Билеңне бу һәм аягыңа ки, – диде фәрештә.

Ул шулай эшләде.

– Өс киемеңне ки дә минем арттан бар, – диде аннары.

[9] Петер, фәрештә кылган бу эшләрнең чынбарлыкта икәнен
дә аңламыйча, аның артыннан китте. Ул, илаһи күренеш күрәмдер, дип уйлады. [10] Беренче һәм икенче сакчыны үтеп, шәһәргә чыга торган тимер капка янына килеп җиттеләр. Капка
үзеннән-үзе ачылды, алар урамга чыктылар һәм, бер урамны
үткәннән соң, кинәт фәрештә аның берүзен калдырды.

[11] Шул вакыт Петер аңына килде:

– Хәзер мин чынлап та беләм: Раббы Үзенең фәрештәсен җибәргән. Ул мине Һируд кулыннан һәм яһүд халкы минем белән булыр дип көткән һәрнәрсәдән коткарды, – дип уйлады ул.

[12] Барын да аңлагач, Марк исемле Яхъяның анасы Мәрьям
йортына килде. Анда җыелган халык дога кыла иде. [13] Петер
ишек шакыды, ишек ачарга дип Роди исемле хезмәтче кыз
чыкты. [14] Петернең тавышын таныгач, ул, шатлыгыннан, ишекне ачарга да онытып, йөгереп кереп китте һәм йорттагыларга
Петернең ишек янында торуы турында әйтте.

---

* **12:1** *Һируд патша* – Яһүдия һәм Самареянең патшасы Һируд Әгрип беренче, Бөек Һирудның оныгы.

[15] – Син үз акылыңдамы? – дигеләр аңа.
Әмма кыз үз сүзендә торды. Ә тегеләр:
– Ул аның фәрештәседер, – диделәр.
[16] Петер исә һаман шакыды. Ишекне ачтылар һәм аны күреп
хәйран калдылар. [17] Ул, кулы белән ишарә ясап, тавышланмас-
ка кушты һәм Раббының аны ничек итеп зинданнан чыгаруы
турында аларга сөйләп бирде.
– Бу хакта Ягъкубка да, туганнарга да әйтегез, – диде ул.
Шуннан соң Петер башка урынга китте.
[18] Көн тугач, Петер белән нәрсә булды икән дип, гаскәриләр
борчыла башладылар. [19] Һируд исә, аны эзләтеп тә таптыра алма-
гач, сакчылардан сорау алды һәм аларны үтерергә әмер бирде.

*Һирудның үлеме*

Шуннан соң Һируд Яһүдиядән Кайсариягә китте һәм шунда
калды. [20] Ул Тур һәм Сидун шәһәрләрендә яшәүчеләргә бик
ачулы иде. Алар исә, үзара сүз беркетеп, аның янына килделәр
һәм, патшаның сарай идарәчесе Бластыны үз якларына ауда-
рып, солых сорадылар, чөнки аларның өлкәсе патша өлкәсен-
нән туена иде. [21] Билгеләнгән көнне Һируд, патша киемнәренә
киенеп, хөкем итү урынына утырды һәм алар алдында чыгыш
ясады. [22] Ә халык:
– Бу тавыш – кеше тавышы түгел, бу – илаһ тавышы, – дип
кычкырды.
[23] Шушы шөһрәтне Аллаһыга бирмәгән өчен Раббының бер
фәрештәсе кинәт Һирудны орды. Ул кортлап үлде.
[24] Аллаһы сүзе исә киң таралды һәм аны кабул итүчеләрнең
саны үсә барды. [25] Ә Барнаб белән Шаул, тапшырылган эшне
башкарганнан соң, Марк исемле Яхъяны алып, Иерусалимга
кайттылар.

*Барнаб белән Шаулга изге хезмәт йөкләнә*

**13** [1] Антиухеядәге иман итүчеләр бердәмлегендә Барнаб,
Шимун (аны тагын Нигер дип тә атыйлар), күриниле
Луки, өлкә идарәчесе Һируд белән бергә тәрбияләнгән
гән Манаин һәм Шаул исемле пәйгамбәрләр, мөгаллимнәр
бар иде. [2] Алар ураза тоткан вакытта, Раббыга хезмәт иткәндә
Изге Рух:
– Минем эшемне башкару өчен сайланган Барнабны һәм
Шаулны Миңа аерыгыз, – диде.
[3] Догалар кылып ураза тотканнан соң пәйгамбәрләр һәм мө-
галлимнәр, Барнаб белән Шаулның башларына кулларын куеп,
аларны хезмәт итү өчен җибәрделәр.

### *Рәсүлләр Кипрда*

[4] Изге Рух тарафыннан җибәрелгән Барнаб белән Шаул Се-
ләүкия шәһәренә килделәр, аннан су юлы белән Кипр утравына
киттеләр. [5] Утраудагы Саламис шәһәренә килгәч, яһүдләрнең
гыйбадәтханәләрендә Аллаһы сүзен вәгазьләделәр. Аларга Яхъя
да ярдәм итте. [6] Бөтен утрауны үтеп Паф шәһәренә килделәр.
Анда алар сихерче һәм ялган пәйгамбәр булган Барьешуа исем-
ле бер яһүд кешесенә тап булдылар. [7] Ул өлкә башлыгы Серги
Паул янында иде. Серги Паул – акыллы кеше – Аллаһы сүзен
тыңларга теләп, Барнаб белән Шаулны сараена чакырды. [8] Ә
сихерче Элум (Барьешуаның грекча исеме) өлкә башлыгын
иманга китерттермәскә тырышып, аларга каршы торды. [9] Изге
Рух белән сугарылган Шаул, аны тагын Паул дип тә атыйлар,
Элумга туп-туры карап:
[10] – Син һәртөрле ялган һәм мәкерлелек белән тулгансың.
Син, иблис улы, һәртөрле дөреслекнең дошманы! Раббының
хакыйкатен ялганга әйләндерүдән туктыйсыңмы син, юкмы? –
диде. – [11] Хәзер менә Раббының кулы синең өстеңдә: син
сукыраячаксың һәм билгеле бер вакытка кадәр кояшны күр-
мәячәксең.

Кинәт аны томан һәм караңгылык каплап алды, һәм ул,
берәрсе җитәкләп юл күрсәтмәсме икән дип, әле бер якка, әле
икенче якка таба атлады.
[12] Өлкә башлыгы, бу хәлне күреп, Раббы турындагы тәгъли-
матның кодрәтенә таң калды һәм Раббыга иман китерде.

### *Паул һәм Барнаб Антиухея шәһәрендә*

[13] Паул һәм аның белән бергә булганнар, Пафтан китеп, су
юлы белән Памфулия өлкәсендәге Перги шәһәренә килделәр.
Яхъя, алардан аерылып, Иерусалимга кайтты, [14] ә калганнар
Пергидән Писидия өлкәсендәге Антиухеягә килделәр.

Шимбә көнне алар гыйбадәтханәгә кереп утырдылар. [15] Муса
канунынннан һәм пәйгамбәрләр язган китаплардан өзекләр укы-
ганнан соң, гыйбадәтханә башлыклары, кешеләр аша, аларга:

– Туганнар! Халыкка әйтергә теләгән нәсыйхәт сүзегез бул-
са, әйтегез, – диделәр.
[16] Паул, кулы белән ишарә итеп, тынычланырга чакырды:
– Исраил ирләре һәм Аллаһыга табынучы башкалар, тыңла-
гыз! [17] Исраил халкының Аллаһысы безнең ата-бабаларыбыз-
ны сайлап алган һәм Мисыр җирендә булган чагында бу ха-
лыкны бөек иткән, Үзенең кодрәтле кулы белән аларны Мисыр
җиреннән чыгарган. [18] Алар чүлдә вакытта, Ул аларга карата

кырык ел чамасы сабыр булган. [19] Кәнган җирендә җиде халыкны юк иттергәннән соң, шул җирне аларга мирас итеп биргән. [20] Бу вакыйгалар чама белән дүрт йөз илле ел барышында булган. Моннан соң Шамуил пәйгамбәр яшәгән чорга кадәр аларга хакимнәр биргән. [21] Аннары алар патша сораганнар, һәм Аллаһы аларга Биньямин нәселеннән булган Кыйш улы Шаулны биргән. Ул кырык ел чамасы идарә иткән. [22] Аны тәхеттән төшергәннән соң патша итеп Давытны куйган һәм аның хакында: «Мин күңелемә ошаган бер ирне, Ишай улы Давытны таптым. Ул Мин теләгән һәр эшне башкарачак», – дигән.

[23] Үзенең анты буенча, Аллаһы Давыт нәселеннән Исраилгә Коткаручы Гайсәне бирде. [24] Коткаручы килер алдыннан Яхъя, тәүбә итәргә һәм чумдырылу йоласын үтәргә өндәп, бөтен Исраил халкына вәгазь сөйләде. [25] Үз хезмәтенең ахырында Яхъя: «Сез мине кем дип уйлыйсыз? Мин Ул түгел. Минем артымнан Бер Зат килә, мин Аның аякларындагы башмак бауларын чишәргә дә лаеклы түгелмен», – диде.

[26] Туганнар! Ибраһим нәселенең балалары һәм Аллаһыга табынучы башка кешеләр! Коткарылу хакындагы бу хәбәр безгә җибәрелде. [27] Иерусалимда яшәүчеләр һәм аларның башлыклары Мәсихне танымадылар, Аны хөкем итеп, пәйгамбәрләрнең һәр шимбә укыла торган сүзләрен гамәлгә ашырдылар. [28] Аңарда үлемгә лаеклы һичбер гаеп тапмасалар да, Пилаттан, катгый рәвештә, Аның үтертелүен сорадылар. [29] Аның хакында язылганнарның бөтенесен тормышка ашыргач, Аны, агачтан төшереп, кабергә салдылар. [30] Әмма Аллаһы Аны үледән терелтеп торгызды. [31] Ул Үзе белән Гәлиләядән Иерусалимга килгән кешеләргә күп көннәр буе күренде, хәзер ул кешеләр халык алдында Аның шаһитләре.

[32-33] Без сезгә Яхшы хәбәр алып килдек: Аллаһы, Гайсәне терелтеп торгызуы белән, аталарыбызга биргән вәгъдәне безнең өчен – аларның балалары өчен гамәлгә ашырды. Бу икенче мәдхиядә язылганча булды:

> «Син – Минем Улым,
> Бүген Мин Сине тудырдым*».

[34] Аның гәүдәсен черетмичә, Аны үледән терелтеп торгызу турында исә болай дигән:

> «Давытка бирелгән изге һәм ышанычлы вәгъдәне
> Сезнең өчен тормышка ашырачакмын».

---

* 13:32-33 Патша итеп сайланып май сөртелгән кешене, Аллаһы, ата кеше үз улын яраткандай, якын күрә. Шундый мөнәсәбәт бу өлештә Гайсәгә карый. («Зәбур» китабы, 2 нче мәдхия.)

[35] Һәм башка бер урында:
«Үз Изгеңнең гәүдәсен
Һичкайчан черетмәссең», –
дип язылган.
[36] Үз дәверендә Аллаһы ихтыяры буенча хезмәт иткәннән
соң Давыт вафат булды һәм үзенең аталары янына күмелде.
Аның гәүдәсе череде. [37] Ә Аллаһы терелтеп торгызган Зат че-
ремәде.
[38-39] Шулай итеп, туганнар, сезгә мәгълүм булсын: Гайсә аркы-
лы сезгә гөнаһларыгызның кичерелүе игълан ителә. Сез Муса
кануны аша аклана алмаган барлык гөнаһлардан иман итүче
һәркем Аның аркылы Аллаһы тарафыннан акланыр. [40] Сак бу-
лыгыз, пәйгамбәрләр әйткән сүзләр сезгә карата булмасын.
Пәйгамбәрләр әйткәннәр:
[41] «Тәкәбберләр, карагыз!
Таң калыгыз һәм юк булыгыз.
Бер эш башкарачакмын Мин
Сез яшәгән көннәрдә.
Сез ышанмас идегез,
Әгәр ул эш турында
Сезгә сөйләсәләр дә».
[42] Паул белән Барнаб гыйбадәтханәдән чыкканда, кайбер ке-
шеләр:
– Киләсе шимбәдә дә бу хакта сөйләгез әле, – диделәр.
[43] Җыелыш таралганнан соң күп яһүдләр һәм мәҗүсилектән
яһүд диненә күчкән, Аллаһыны хөрмәт итә торган диндар ке-
шеләр Паул белән Барнаб артыннан бардылар, һәм рәсүлләр,
алар белән әңгәмә корып, аларны Аллаһы мәрхәмәтендә то-
рырга үгетләделәр.
[44] Икенче шимбәдә бөтен шәһәр диярлек Раббы сүзен тыңлар-
га җыелды. [45] Ә яһүдләр, халыкның күплеген күреп, көнләштеләр
һәм Паулның сүзләренә каршы яман телләнделәр. [46] Ә Паул һәм
Барнаб исә кыюлык белән:
– Аллаһы сүзе иң элек сезгә игълан ителергә тиеш иде, –
диделәр. – Әмма сез аны кире кагасыз һәм шуның белән үзе-
гезне мәңгелек тормышка лаек түгел итәсез. Шуңа күрә без
башка халыкларга таба борылабыз. [47] Чөнки Раббы безгә:
«Синең аша котылу
Җирнең читләренә кадәр
Барып җитсен дип,
Мин Сине башка халыкларга
Яктылык итеп куйдым», –
дигән әмер бирде.

48 Яһүд булмаган кешеләр Паул белән Барнаб әйткән сүз-
ләрне ишетеп куандылар һәм Раббыны сүзе өчен данладылар.
Мәңгелек тормыш өчен сайлап алынганнарның барысы да
иман китерделәр. 49 Раббы сүзе шул тирәдәге бар җирләргә
таралды.
50 Әмма яһүдләр, атаклы гаиләләрдән булган хатыннарны
һәм шәһәрдәге җитәкче кешеләрне Паул белән Барнабка кар-
шы котыртып, аларны эзәрлекләделәр һәм үз җирләреннән
кудырттылар. 51 Паул белән Барнаб исә, аларга каршы шаһит-
лек билгесе итеп, аякларындагы тузанны кактылар һәм Икүниун
шәһәренә киттеләр.
52 Ә шәкертләр куаныч һәм Изге Рух белән тулы булдылар.

*Паул белән Барнаб Икүниун шәһәрендә*

**14** 1 Икүниунда Паул белән Барнаб, гадәттәгечә, яһүдләр
гыйбадәтханәсенә керделәр. Аларның тәэсирле итеп
сөйләүләреннән бик күп яһүдләр һәм башка халык ке-
шеләре Раббыга иман китерделәр. 2 Ә иман китермәгән яһүд-
ләр яһүд булмаганнарны иман китергән туганнарына каршы
котырттылар. 3 Паул белән Барнаб анда шактый озак вакыт
булдылар, Раббы турында тәвәккәллек белән вәгазьләделәр. Ә
Раббы, Үзенең мәрхәмәте хакындагы хәбәрне раслап, аларның
кулы белән галәмәтләр һәм могҗизалар кылды. 4 Шәһәрдәге
халык икегә бүленде: бер өлеше яһүдләр ягында, икенчеләре
рәсүлләр ягында булды. 5 Яһүд булмаганнар һәм яһүдләр, үзлә-
ренең башлыклары белән берлектә, аларга һөҗүм итеп, ташлар
атып үтерергә ниятләделәр. 6 Рәсүлләр бу хакта ишеткәч, Лукәү-
ниягә качып киттеләр. Андагы Лустра, Дерби шәһәрләрендә
һәм шул тирәдәге җирләрдә 7 халыкка Яхшы хәбәрне сөйләүлә-
рен дәвам иттеләр.

*Лустра шәһәрендә булган хәлләр*

8 Лустра шәһәрендә аяклары йөрми торган бер кеше бар иде.
Ул кеше, тумыштан ук гарип булып, беркайчан да йөри алма-
ган. 9 Ул да Паул сөйләгән сүзләрне тыңлап утырды. Паул аңа
туп-туры карады һәм, шифа алачагына гарипнең ышанычы
булганын күреп:
10 – Аякларыңа туры итеп бас, – дип кычкырып әйтте.
Ул шундук сикереп торды һәм йөри башлады. 11 Халык исә,
Паулның нәрсә эшләгәнен күреп, лукәүния телендә:
– Безнең яныбызга кеше кыяфәтендә илаһлар инде, – дип
кычкыра башладылар.

[12] Барнабны грекларның илаһы Зевс дип, ә Паулны Гермес*
дип атадылар, чөнки ул күбрәк сөйли иде. [13] Шәһәр читенә
урнашкан Зевс гыйбадәтханәсенең каһине** исә, халык белән
бергә, капка алдына үгезләр һәм чәчәк бәйләмнәре алып килеп,
корбан китерергә теләде.
[14] Рәсүлләр, бу хакта ишеткәч, өсләрендәге киемнәрен ер-
тып төшереп, халык арасына йөгереп керделәр һәм бар тавыш-
ларына:
[15] – Сез нәрсә эшлисез? – дип кычкырдылар. – Без дә сез-
нең кебек үк кешеләр. Сезне бу файдасыз әйберләрдән арын-
дыру, күкне, җирне, диңгезне һәм алардагы барлык нәрсәләрне
яраткан тере Аллаһыга таба бору өчен без сезгә Яхшы хәбәр
турында сөйлибез. [16] Элегрәк Ул барлык халыкларга үз юллары
белән барырга ирек бирде. [17] Әмма, яхшылыклар кылып, Үзен
күрсәтеп торды: вакытында күкләрдән яңгыр яудырып һәм мул
уңыш биреп, безне ризык белән тәэмин итте һәм йөрәкләре-
безне куаныч белән тутырып торды. [18] Шулай дип әйтеп тә,
алар көчкә-көчкә генә халыкны үзләренә корбан китермәскә
күндерә алдылар.
[19] Антиухейдән һәм Икүниун шәһәреннән килгән кайбер
яһүдләр халыкны рәсүлләргә каршы котыртып, Паулны ташлар
атып кыйнадылар һәм, үлде дип уйлап, аны шәһәр читенә чы-
гарып ташладылар. [20] Аның янына шәкертләр җыелгач, ул тор-
ды һәм шәһәргә китте.
Икенче көнне Паул белән Барнаб Дерби шәһәренә юл тот-
тылар. [21] Ул шәһәрдә Яхшы хәбәрне вәгазьләп, шактый күпләр-
не шәкерт иткәннән соң, тагын Лустра, Икүниун һәм Антиухея
шәһәрләре аша уздылар. [22] Шәкертләрнең күңелләрен дәртлән-
дереп, иманда нык торырга өндәделәр.

– Аллаһы Патшалыгына керү күп михнәтләр аша булачак, –
диделәр.

[23] Һәр бердәмлектә баш кешеләрне билгеләделәр һәм, ураза
тотып дога кылганнан соң, аларны үзләре дә иман китергән
Раббының кулларына тапшырдылар.

*Сурияләге Антиухейгә әйләнеп кайту*

[24] Шуннан соң алар, Писидия аша үтеп, Памфулия өлкәсенә
килделәр. [25] Пергидә Аллаһы сүзен вәгазь иткәннән соң Атталея
шәһәренә юнәлделәр. [26] Атталеядән, корабка утырып, Антиухейгә

* 14:12 *Зевс, Гермес* – Греклар мифологиясендә Зевс – иң бөек илаһ, ә Гермес – тел остасы дип саналган.

** 14:13 *Каһин* – мәҗүсиләрдә дин башлыгы.

киттеләр. Паул белән Барнаб, үзләре әле генә төгәлләгән эшне
башкару өчен, Аллаһының мәрхәмәтенә шушы шәһәрдә тапшы-
рылган иделәр. 27 Алар Антиухеягә кайтып җиткәч, бердәмлекне
җыеп, үзләре аша Аллаһының нәрсәләр эшләгәнен, Аның яһүд
булмаган халыкларга иман ишеген ачканын – барысын да бәй-
нә-бәйнә сөйләп бирделәр. 28 Паул белән Барнаб шәкертләр
янында шактый озак вакытка калдылар.

*Сөннәтле булу мәҗбүриме*

15 1 Яһүдиядән Антиухеягә килгән ниндидер кешеләр иман
итүче туганнарны:
– Муса кануны кушканча сөннәткә утыртылмасагыз,
котыла алмыйсыз, – дип өйрәтә башладылар.
2 Паул һәм Барнаб теге кешеләр белән риза булмадылар һәм
алар арасында зур бәхәс туды. Шуңа күрә Паул белән Барнаб-
ны һәм тагын берничә кешене бу мәсьәлә буенча Иерусалимга
рәсүлләр һәм өлкәннәр янына җибәрергә булдылар.
3 Шулай итеп, бердәмлек аларны юлга озатты. Фойникә һәм
Самарея өлкәләрен үткәндә, алар, яһүд булмаган халыкларның
Аллаһыга таба борылулары турында сөйләп, барлык туганнар
арасында зур куаныч уяттылар. 4 Иерусалимга килеп җиткәч,
аларны бердәмлек тә, рәсүлләр дә, өлкәннәр дә ачык йөз белән
кабул иттеләр. Паул белән Барнаб аларга үзләре аша Аллаһы-
ның нинди эшләр башкаруы турында сөйләп бирделәр. 5 Шун-
нан соң фарисейләр арасыннан иман китергән кайберәүләр,
урыннарыннан торып:
– Яһүд булмаганнарны сөннәткә утыртырга һәм алардан Му-
са канунын тотуны таләп итәргә кирәк, – диделәр.
6 Бу мәсьәләне тикшерү өчен рәсүлләр һәм өлкәннәр бергә
җыелдылар. 7 Озак бәхәсләрдән соң Петер, урыныннан торып:
– Туганнар! – дип сүз башлады. – Сез беләсез, минем аша
Яхшы хәбәрне ишетеп яһүд булмаган халыклар иман китерсен-
нәр өчен, Аллаһы мине сезнең арагыздан инде күптән сайлаган
иде. 8 Кеше күңелен белеп торучы Аллаһы, безгә биргән кебек,
яһүд булмаганнарга да Изге Рухны биреп, аларны кабул итүен
күрсәтте. 9 Алар белән безнең арада бернинди аерма калдыр-
мыйча, йөрәкләрен иман аша сафландырды. 10 Шулай булгач,
безнең аталарыбыз да, без үзебез дә күтәрә алмаган йөкне
шәкертләр җилкәсенә салып, сез хәзер ни өчен Аллаһыны
сыныйсыз? 11 Ә бит без дә, алар кебек үк, Гайсә Раббының
мәрхәмәте аркылы котылганыбызга инанабыз.
12 Бөтен җыелыш тынып калды. Барнаб белән Паул үзләре
аша Аллаһының башка халыклар арасында кылган галәмәтләре

һәм могҗизалары турында сөйләделәр, халык аларны тыңлады.
[13] Алар сүзләрен тәмамлагач, Ягъкуб сөйли башлады:
– Туганнар, мине тыңлагыз! [14] Шимун Аллаһының, яһүд булмаган халыклар турында кайгыртучанлык күрсәтә башлап, алар арасыннан Үзенә Үз халкын алуы хакында сөйләде. [15] Пәйгамбәрләрнең Изге язмада язган сүзләре дә моңа туры килә:
[16-17] «Шуннан соң, – дигән Раббы, –
Үз яныма чакырып,
Мин Үземнеке иткән
Барлык калган халыклар
Мине – Раббыны эзләсеннәр дип,
Мин кире кайтачакмын.
Давытның җимерелгән йортын
Яңадан торгызачакмын,
Җимерекләрдән торгызып,
Аны яңартачакмын.
Шулай дип әйтә Раббы!
[18] Борынгыдан билгеле булган
Бу эшләрне Ул кыла».
[19] Шуңа күрә башка халыклар арасыннан Аллаһыга таба борылучыларга кыенлык тудырмаска, [20] ә аларга, потлар алдына китерелеп, хәрәм ризыклардан, җенси азгынлыктан, буып үтерелгән хайван итеннән һәм каннан тыелыгыз, дип язарга кирәк, минемчә. [21] Чөнки элек-электән Муса кануны һәр шәһәрдә вәгазь ителеп килде, һәр шимбә гыйбадәтханәләрдә укыла.

*Мәҗүсилектән күчкән иман итүче туганнарга җавап*

[22] Шуннан соң рәсүлләр һәм өлкәннәр бөтен бердәмлек белән бергә үзләре арасыннан берничә кешене сайлап, Паул белән Барнабка ияртеп, Антиухеягә җибәрергә карар кылдылар. Туганнар арасында җитәкчелек итә торган Барсаб дип аталучы Яһүдне һәм Силасны сайладылар [23] һәм алар белән шундый хат җибәрделәр:

«Рәсүлләрдән һәм өлкәннәрдән – сезнең туганнарыгыздан – Антиухеядәге, Сүриядәге һәм Киликиядәге, мәҗүсилектән күчкән иман итүче туганнарга сәлам.

[24] Бездән килгән кешеләр, без аларга шундый эшне тапшырмаган булсак та, сезне борчыганнар һәм күңелегезне тынычсызлаганнар дип ишеттек. [25-26] Шуңа күрә без, барыбызның ризалыгы буенча, берничә кешене сайларга һәм аларны сезнең янга җибәрергә дигән фикергә килдек. Алар сезнең янга үзләренең гомерләрен Раббыбыз Гайсә Мәсихкә багышлаган яраткан туганнарыбыз Барнаб һәм Паул белән

бергә барырлар. 27 Без Яһүдне һәм Силасны җибәрәбез, алар
сезгә бу хатта язылганнарны телдән аңлатып бирерләр.
28 Изге Рух һәм без шундый карарга килдек: хәзер язылачак таләпләрдән башка сезнең өскә һичнинди йөк салырга
кирәк түгел. 29 Потларга корбан итеп китерелгән ризыктан,
каннан, буып үтерелгән хайван итеннән һәм җенси азгынлыктан тыелыгыз. Үзегезне шушы эшләрдән сакласагыз,
бик яхшы булыр.

Сәламәт булыгыз!»

30 Шулай итеп, җибәрелгән туганнар Антиухеягә килделәр
һәм, бердәмлекне җыеп, хатны тапшырдылар. 31 Хатны укыгач,
барысы да бу юанычлы хәбәргә куандылар. 32 Яһүд һәм Силас,
үзләре пәйгамбәр буларак, бик күп сүзләр әйтеп, туганнарны
рухландырдылар һәм ныгыттылар. 33 Яһүд белән Силас Антиухеядә күпмедер вакыт булганнан соң, туганнар, иминлек теләп,
аларны Иерусалимга, үзләрен җибәргән кешеләр янына озаттылар. [ 34 Әмма Силас Антиухеядә калырга булды.]* 35 Паул белән
Барнаб исә, Антиухеядә калдылар. Алар күп кешеләр белән бергә, Раббы турындагы хәбәрне өйрәттеләр һәм вәгазьләделәр.

*Паул белән Барнабның юллары аерыла*

36 Берникадәр вакыт үткәннән соң Паул Барнабка үзләре
Раббы сүзен вәгазьләп йөргән барлык шәһәрләрдәге туганнар
янына барып, аларның хәлләрен белергә тәкъдим итте. 37 Барнаб Марк исемле Яхъяны да үзләре белән алырга теләде. 38 Әмма
Яхъя, тапшырылган эшне төгәлләмичә, Памфулиядә үзләреннән
аерылып калганга күрә, Паул аны алырга теләмәде. 39 Паул белән
Барнаб арасында җитди каршылык туды һәм алар икесе ике якка
китәргә булдылар: Барнаб, Маркны алып, су юлы белән Кипрга
китте. 40 Ә Паул үзенә Силасны сайлап алды һәм, туганнар аны
Раббы мәрхәмәтенә тапшырганнан соң, ул юлга чыкты, 41 бердәмлекләрне ныгытып, Сурия һәм Киликия өлкәләре аша үтте.

*Тимуте Паулны озатып бара*

16 1 Шуннан соң Паул Дербигә, ә аннары Лустрага килде.
Анда Тимуте атлы бер шәкерт бар иде. Аның анасы
яһүд, ул да улы кебек үк Гайсәгә иман итүче, ә атасы
грек иде. 2 Лустрадагы һәм Икүниундагы туганнар Тимуте турында яхшы сүзләр генә сөйләделәр. 3 Паул аның үзе белән юлга чыгуын теләде һәм шуңа күрә аны сөннәткә утыртты. Ул бу
эшне шунда яшәүче яһүдләр хакына эшләде, чөнки барысы да
атасының грек икәнен беләләр иде. 4 Шәһәрләр аша үткәндә

---

* 15:34 Берничә кульязмада бу җөмлә юк.

алар иман итүчеләргә Иерусалимдагы рәсүлләр һәм өлкәннәр тарафыннан чыгарылган карарларны тапшырдылар һәм аларны үтәргә үгетләделәр.
5 Бердәмлекләр иманда ныгыды һәм көннән-көн иман итүчеләрнең саны арта барды.

*Паул Македуния өлкәсенә чакырыла*

6 Паул һәм аның белән булган кешеләр Фругия һәм Гәләтия аша киттеләр, чөнки Изге Рух аларга Асия өлкәсендә вәгазь
сөйләтмәде. 7 Мусия төбәгенә килгәч, алар Битуния төбәгенә
барырга булдылар, әмма Гайсәнең Рухы аларны җибәрмәде,
8 һәм алар Мусиядән Троас шәһәренә килделәр.
9 Төнлә Паул шундый бер илаһи күренеш күрде: македунияле
берәү, Паулның Македуниягә килүе һәм аларга ярдәм итүе турында ялварып, аның каршында басып тора. 10 Шушы илаһи
күренештән соң, Аллаһы безне анда Яхшы хәбәрне сөйләргә чакыра, дигән нәтиҗәгә килеп, шундук Македуниягә китәргә булдык.

*Лудиянең Аллаһыга иман китерүе*

11 Троастан су юлы белән китеп, без туп-туры Самутрәки утравына, ә икенче көнне Неяполис шәһәренә килдек. 12 Аннары Македуниянең беренче өлешендәге Рим хакимлеге астында булган Филиппуй шәһәренә* юл тоттык. Без бу шәһәрдә бернично көн булдык.
13 Шимбә көнне, шәһәрдән чыгып, елга буена киттек, чөнки дога кылу урынын шунда дип уйладык. Елга буенда без җыелган хатын-кызлар белән сөйләшеп утырдык.
14 Анда Түәтәйрә шәһәрендә куе кызыл төстәге кыйммәтле тукымалар сатучы, Аллаһыны хөрмәт итә торган Лудия исемле бер хатын бар иде. Паул сөйләгән сүзләргә Раббы аның йөрәген
ачты. 15 Үзе һәм өендәгеләре чумдырылганнан соң, ул безгә:
– Мине Раббыга иман итүче дип санасагыз, өемә керегез һәм кунак булыгыз, – диде.
Ул безне күндерде.

*Филиппуйда тоткынлыкта*

16 Бер көнне гыйбадәтханәгә барганда безгә күрәзәче рухлы бер хезмәтче кыз очрады. Ул, күрәзәлек итеп, үзенең хуҗаларына

---

* **16:12** *Рим хакимлеге астында булган шәһәр* – грек телендә «Рим колониясе» дигән сүзләр белән бирелгән. Филиппуй шәһәренең Рим императорыннан кабул итеп алынган үзидарә хокуклары булган, шәһәр Рим кануннары буенча яшәгән. Шундый колониягә күп римлылар күчеп килә торган булганнар.

күп табыш китерә икән. 17 Кыз, Паул артыннан һәм безнең
арттан:
– Бу кешеләр – Аллаһы Тәгалә коллары, алар сезгә котылу
юлын күрсәтәләр, – дип кычкырып барды.
18 Ул берничә көн шулай эшләде. Паулның ачуы килде һәм
ул, борылып, рухка:
– Гайсә Мәсих вәкаләте белән сиңа аның эченнән чыгарга
боерам, – диде.
Һәм рух шундук чыкты. 19 Кызның хуҗалары, табыш алуга
өметнең юкка чыгуын күреп, Паул белән Силасны тотып алды-
лар һәм мәйданга – шәһәр башлыклары янына өстерәп алып
киттеләр. 20-21 Аларны идарәчеләр янына китерделәр һәм:
– Бу кешеләр – яһүдләр. Алар безгә, римлыларга, кабул
итәргә дә, башкарырга да ярамаган йолаларны вәгазьләп, шә-
һәрдә тынычсызлык тудыралар, – диделәр.
22 Халык та аларга каршы чыккан кешеләргә кушылды. Шә-
һәр идарәчеләре, аларның киемнәрен йолкып салдырдылар
һәм таяк белән кыйнарга боердылар. 23 Нык кына кыйнаганнан
соң, аларны зинданга ташладылар һәм зиндан каравылчысына
тоткыннарны бик нык итеп сакларга боердылар. 24 Шундый
әмер алгач, каравылчы аларны зинданның эчке бүлмәсенә яп-
ты һәм аякларын агач богауларга беркетеп куйды.
25 Төн уртасындарак Паул белән Силас дога кылдылар, Алла-
һыны мактап мәдхияләр җырладылар, ә тоткыннар аларны
тыңлап утырдылар. 26 Кинәт бик нык итеп җир тетрәде, хәтта
зинданның нигезе селкенеп куйды. Шундук барлык ишекләр
ачылды, барысының да аякларыннан богаулары төшеп китте.
27 Зиндан каравылчысы йокысыннан уянды һәм ишекләрнең
ачык булуын күреп, тоткыннар качкандыр, дип уйлады һәм,
кылычын чыгарып, үзен-үзе үтерергә теләде. 28 Әмма Паул:
– Үзеңә һичбер явызлык эшләмә, чөнки без барыбыз да
монда, – дип кычкырды.
29 Каравылчы ут сорап алды да бүлмә эченә йөгереп керде
һәм, калтыранып, Паул белән Силас алдына егылды. 30 Ул алар-
ны тышкы якка алып чыкты.
– Әфәнделәрем! Котылу өчен миңа нәрсә эшләргә кирәк? –
дип сорады ул алардан.
31 – Раббы Гайсә Мәсихкә иман китер. Шулай эшләсәң үзең
дә котылырсың, бөтен өең дә котылыр.
32 Аңа һәм өендә булганнарның барысына Раббы хакындагы
сүзне вәгазьләделәр. 33 Ул шул ук сәгатьтә, төнлә белән, алар-
ның җәрәхәтләрен юды. Шундук ул үзе һәм өендәгеләр бары-
сы да чумдырылу йоласын үттеләр. 34 Үзенең өенә алып килеп,

аларга табын тәкъдим итте һәм Аллаһыга иман китергәне өчен бөтен йорты белән куанды.

35 Көн тугач, шәһәр идарәчеләре, ярдәмчеләр артыннан, аларны азат итәргә, дигән хәбәр җибәрделәр. 36 Зиндан каравылчысы бу турыда Паулга әйтте:

– Шәһәр идарәчеләре сезне азат итәргә дигән хәбәр җибәргәннәр. Барыгыз, иминлек сезгә, – диде.

37 Әмма Паул:

– Безне, Рим гражданнарын, халык алдында хөкемсез кыйнадылар һәм зинданга яптылар, ә хәзер яшерен рәвештә чыгарырга телиләрме? Юк! Килсеннәр дә үзләре безне чыгарсыннар, – диде.

38 Ярдәмчеләр бу сүзләрне шәһәр идарәчеләренә җиткерделәр, ә идарәчеләр, аларның Рим гражданнары икәнен ишеткәч, куркып калдылар. 39 Яннарына килеп гафу үтенделәр, аларны иреккә чыгардылар һәм шәһәрдән китүләрен сорадылар.

40 Алар исә, зинданнан чыккач, Лудиянең йортына килделәр. Анда иман итүче туганнарны очратып, аларга үгет-нәсыйхәт бирделәр һәм юлга чыктылар.

*Тессалуникә шәһәрендә фетнә*

**17** 1 Рәсүлләр, Амфиполис һәм Апуллуния шәһәрләре аша үтеп, Тессалуникә шәһәренә килделәр. Анда яһүдләр гыйбадәтханәсе бар иде. 2 Паул, гадәттәгечә, гыйбадәтханәгә барды һәм өч шимбә рәттән яһүдләр белән Изге язмаларда язылганнар турында әңгәмә корды. 3 Аларга Мәсихнең газап чигәргә һәм үледән терелергә тиеш булганлыгын аңлатты һәм исбат итте.

– Мин сезгә Гайсә хакында вәгазь итәм һәм шушы Гайсә – Мәсих, – диде Паул.

4 Яһүдләрнең кайберләре, шулай ук Аллаһыны хөрмәт итә торган бик күп греклар һәм күп кенә күренекле хатын-кызлар иман китерделәр һәм Паул белән Силаска кушылдылар. 5 Ләкин башка яһүдләр көнләштеләр һәм, мәйдандагы юньсез кешеләрне җыеп, шәһәрдә чуалыш чыгардылар. Паул белән Силасны халык алдына алып чыгу өчен, Ясун йортына килеп, аларны эзләделәр. 6 Рәсүлләрне тапмагач, Ясунны һәм кайбер башка иман итүче туганнарны шәһәр башлыклары янына сөйрәп алып килделәр.

– Бөтен җирдә чуалыш чыгарып тынычлыкны бозып йөрүчеләр монда да килгәннәр, 7 ә Ясун аларны үз йортына кабул иткән. Алар барысы да, кайсарның әмерләренә каршы чыгып, башка берәүне – Гайсәне патша дип исәплиләр, – дип кычкырдылар.

[8] Бу сүзләр халыкны һәм шәһәр башлыкларын борчуга салды.
[9] Ә Ясунны һәм башкаларны, иреккә чыгу өчен билгеләнгән күләмдә акча түләттергәннән соң, кайтарып җибәрделәр.

*Рәсүлләр Беруя шәһәрендә*

[10] Шул ук төнне туганнар Паул белән Силасны Беруя шәһәренә озаттылар. Беруягә килеп җиткәч, Паул белән Силас яһүдләр гыйбадәтханәсенә киттеләр.
[11] Мондагы кешеләр, тессалуникәлеләргә караганда киңрәк карашлы иделәр. Алар сүзне бик теләп кабул иттеләр һәм һәр көн, Паул сөйләгән сүзләрнең дөреслеген тикшерү өчен, Изге язманы өйрәнделәр.
[12] Күп кенә яһүдләр иман китерде, шулай ук мөхтәрәм грек хатыннары һәм ирләре арасында да иман китерүчеләр аз булмады.

[13] Әмма Паулның Беруядә дә Аллаһы сүзен вәгазьләве турында белеп алгач, Тессалуникәдә яшәүче яһүдләр монда да килделәр һәм, коткы салып, халыкны котырттылар.
[14] Тиз арада туганнар Паулны диңгез буена җибәрделәр, ә Силас белән Тимуте Беруядә калдылар.
[15] Паулны озата баручылар аның белән Афинага чаклы килделәр һәм кире кайтып киттеләр. Паул, алар артыннан, Силаска һәм Тимутегә мөмкин кадәр тиз арада килеп җитәргә кушты.

*Паул Афинада*

[16] Силас белән Тимутене көткәндә, бу шәһәрдә потларның күп булуын күреп, Паулның күңеле әрнеде.
[17] Ул гыйбадәтханәдә яһүдләр белән, Аллаһыны хөрмәт итүче башка кешеләр белән әңгәмә корып утырды, шулай ук һәр көн базар мәйданында очраган кешеләр белән сөйләште.

[18] Шулай бер көнне кайбер фәлсәфәчеләр – эпикүрчеләр һәм стоачылар – Паул белән бәхәскә керделәр. Ул аларга Гайсә хакында һәм үледән терелү турындагы Яхшы хәбәрне сөйләгәнгә күрә, фәлсәфәчеләрнең кайберләре:

– Бу тел бистәсе нәрсә әйтергә тели? – диделәр, ә икенчеләре:

– Ул чит илаһлар турында вәгазь итә булса кирәк, – диделәр.

[19] Алар, Паулны тотып, Арейпәгкә* алып килделәр.

– Син вәгазьли торган бу яңа тәгълимат турында күбрәк белергә телибез.
[20] Үзең безгә сөйләгән сәер сүзләрнең мәгънәсенә төшендер, – диделәр алар.

---

* **17:19** *Арейпәг* – Афина шәһәре урнашкан калкулыкларның берсендә – Арейпәг калкулыгында җыела торган хөкем итү шурасын шулай дип атаганнар.

21 Нинди дә булса яңа фикерләр турында сөйләү яки тыңлау – афиналыларның һәм анда яшәүче чит ил кешеләренең иң яраткан шөгыльләре иде.

22 Паул Арейпәг киңәшмәсе алдына басты.

– Афиналылар! Сезнең бөтен яклап аеруча диндар икәнегезне күреп торам, – диде ул. –
23 Чөнки сезнең изге әйберләрегезне карап йөргәндә мин «Билгесез илаһка» дип язылган корбан китерү урынын да күрдем. Мин сезгә үзегез табына торган шул билгесез Аллаһы турында вәгазь итәм.

24 Дөньяны һәм аның эчендәге һәммә нәрсәне бар иткән Аллаһы – Ул күкләрнең һәм җирнең Раббысы. Ул кеше кулы белән төзелгән изге йортларда яшәми
25 һәм Ул кешеләрнең Аңа хезмәт итүләренә мохтаҗ түгел. Ул Үзе һәркемгә тормыш, сулыш һәм барлык нәрсәне бирә.
26 Бөтен җир йөзендә яшәсеннәр дип, Ул бер кешедән барлык халыкларны бар итте, вакытларны һәм яшәү урыннарының чикләрен билгеләде.
27 Ул моны кешеләр Аллаһыны эзләсеннәр өчен, Аны капшанып эзләп тапмасlармы икән, дип эшләде. Ул бит безнең һәрберебездән ерак түгел.
28 Сезнең кайбер шагыйрьләрегез: «Без дә Аның нәселеннән», – дип әйткән кебек «без Аңарда яшибез, хәрәкәт итәбез һәм көн күрәбез».
29 Шуңа күрә без, Аллаһы нәселеннән буларак, илаһилык ул кеше кулларының осталыгы һәм хыялы белән сурәт рәвеше алган алтынга, көмешкә яки ташка охшаш, дип уйларга тиеш түгелбез.
30 Шулай итеп, хакыйкатьне белмичә яшәгән заманнарны Аллаһы гаеп итмәде, ләкин хәзер Ул бөтен җирдәге барлык кешеләргә тәүбә итәргә әмер бирә.
31 Чөнки Аллаһы галәмне гадел хөкем итү көнен билгеләде. Ул Үзе билгеләгән Зат аша хөкем итәр. Ул Затны үледән терелтеп, Аллаһы моны һәркемгә исбат итте.

32 Үлеләрнең терелүе хакында ишеткәч, кайберәүләр көлделәр, ә икенчеләре:

– Бу хакта сине башка бер вакытта тыңларбыз, – диделәр.

33 Шуннан соң Паул Арейпәгтән чыкты.
34 Кайбер кешеләр, ул сөйләгәннәргә ышанып, иман китерделәр. Алар арасында Арейпәг әгъзасы Диунуси, Дамар атлы бер хатын һәм тагын башкалар да бар иде.

*Паул Көринт шәһәрендә*

**18** 1 Шуннан соң Паул Афинадан китте һәм Көринт шәһәренә килде.
2 Ул анда Әкүл атлы бер яһүдне һәм аның Прискиллә исемле хатынын очратты. Кләүди кайсар барлык яһүдләргә Римнан китәргә әмер биргәнгә күрә чыгышы белән Понт шәһәреннән булган Әкүл күптән түгел хатыны

белән Италиядән килгән иде. Паул алар янына барды. [3] Һөнәр-
ләре бер үк булганлыктан Паул алар янында калды һәм алар бе-
лән бергә эшләде. Аларның кәсебе чатыр кору иде. [4] Һәр шимбә
көнне ул гыйбадәтханәдә, яһүдләрне һәм грекларны инанды-
рырга тырышып, алар белән сөйләшеп утырды. [5] Силас белән
Тимуте Македуниядән килгәч, Паул бөтен вакытын, Гайсәнең
Мәсих икәнлеге хакында шаһитлек биреп, яһүдләргә вәгазь
сөйләүгә багышлады. [6] Әмма яһүдләр аңа каршы чыгып, яман
телләнә башлагач, ул, киемендәге тузанны кагып, аларга:

– Үз каныгызга үзегез гаепле булырсыз. Минем өстән җавап-
лылык алына. Мин башка халыклар янына вәгазь сөйләргә
китәм, – диде.

[7] Ул, гыйбадәтханәдән чыгып, якында гына яшәүче, Аллаһы-
ны хөрмәт итә торган Тити Юсты атлы кешенең йортына кер-
де. [8] Гыйбадәтханә башлыгы Криспи исә үзенең бөтен гаиләсе
белән Раббыга иман китерде. Паулның сөйләгәнен ишеткән
күп кенә көринтлеләр иман китерделәр һәм суга чумдырылу
йоласын үттеләр.

[9] Бервакыт төнлә белән Паул илаһи күренеш күрде. Күре-
нештә Раббы аңа:

– Курыкма! Сөйләвеңне дәвам ит һәм туктама. [10] Чөнки Мин
синең белән, һәм беркем дә һөҗүм итеп сиңа зыян китермәячәк.
Бу шәһәрдә Минем күпсанлы халкым бар, – диде.

[11] Паул, иман итүчеләрне Аллаһы сүзенә өйрәтеп, Көринттә
ел ярым яшәде.

[12] Ахаядә Гәллиун өлкә башлыгы булган вакытта яһүдләр,
берләшеп, Паулга һөҗүм иттеләр һәм аны, тотып, хөкем урыны
алдына алып килделәр.

[13] – Ул кешеләрне канунга каршы рәвештә Аллаһыга табы-
нырга өйрәтә, – диделәр.

[14] Паул сүзен башларга гына теләгән иде, Гәллиун яһүдләргә:

– Яһүдләр! Әгәр нинди дә булса явыз эш яки җинаять кылын-
ган булса, сезне тыңлау өчен сәбәп булыр иде. [15] Әмма сүзләр,
исемнәр һәм сезнең кануныгыз хакында сүз барганга күрә, бу
мәсьәләне үзегез хәл итегез. Мин мондый эшләрне хөкем итәргә
теләмим, – диде [16] һәм аларны хөкем урыныннан куып чыгарды.

[17] Хөкем урыны каршында анда булган кешеләр гыйбадәтха-
нә башлыгы Состенисне тотып кыйнадылар. Ә Гәллиунның
моңа исе дә китмәде.

*Паулның Антиухеяга кайтуы*

[18] Паул, тагын шактый гына көннәр Көринттә булганнан
соң, туганнар белән хушлашып, су юлы белән Сүриягә китте.

Прискиллә һәм Әкүл дә аның белән киттеләр. Юлга чыгар алдыннан, нәзер биргәнгә күрә, Паул Кенхерәйдә чәчен алдырды.
[19] Эфескә килеп җиткәч, юлдашларыннан аерылып, Паул гыйбадәтханәгә китте һәм яһүдләр белән сөйләшеп утырды.
[20] Алар аңардан үзләре янында күбрәк вакытка калуын сорадылар, ләкин ул риза булмады. [21] Туганнар белән саубуллашып:

– Аллаһы теләсә, тагын килермен, – диде Паул.

Шуннан соң ул су юлы белән Эфестән китте. [22] Кайсариягә
килеп җиткәч, корабтан төшеп Иерусалимга килде, андагы бердәмлекне сәламләде һәм Антиухеягә китте. [23] Анда бераз вакыт
торганнан соң, Паул юлга чыкты. Барлык шәкертләрне иманда ныгытып, Гәләтия һәм Фругия аша үтте.

*Апуллус Эфестә вәгазь сөйли*

[24] Эфескә чыгышы белән Искәндәриядән булган Апуллус атлы бер яһүд килде. Ул телгә оста, Язманы белә [25] һәм Раббы
юлына өйрәтелгән иде. Яхъя кылдырган чумдыру йоласы турында гына белсә дә, зур рухлану белән Раббы хакында дөрес итеп сөйләде һәм өйрәтте. [26] Ул гыйбадәтханәдә бик кыю сөй-
ләде. Прискиллә белән Әкүл, Апуллусның сөйләгәннәрен ишетеп, аны үзләре янына чакырып алдылар һәм Аллаһы юлы турында тулырак аңлаттылар. [27] Ул Ахаягә китәргә ният белдер-
гәч, туганнар аны дәртләндерделәр һәм андагы шәкертләргә Апуллусны кабул итүләрен сорап хат яздылар. Апуллус анда килгәч, Аллаһы мәрхәмәте аркылы иман итүчеләргә күп ярдәм күрсәтте. [28] Чөнки ул, Изге язмада язылганнар белән, Гайсә-
нең Мәсих икәнлеген исбатлап, бөтен халык алдында яһүдләр сөйләгән сүзләрнең дөрес түгеллеген ышандырырлык итеп күрсәтеп бирде.

*Паул Эфестә*

19 [1] Апуллус Көринттә вакытта, илнең югарыдагы өлешләре аша үтеп, Паул Эфескә килде. Анда берничә шәкертне очратты.

[2] – Сез иман китергәндә Изге Рухны кабул иттегезме? – дип сорады ул алардан.

– Изге Рух хакында безнең ишеткәнебез дә юк, – диделәр аңа.

[3] – Сез нинди чумдырылу үттегез соң?

– Яхъя кылган чумдырылуны, – дип җавап бирделәр шәкерт-
ләр. [4] – Яхъя кылган чумдырылу гөнаһларыннан тәүбә итүче кешеләр өчен булды. Яхъя кешеләрне үзеннән соң Килүчегә, ягъни Гайсәгә иман китерергә өндәде, – диде аларга Паул.

[5] Моны ишеткәч, алар Гайсә Раббы исеменә суга чумдырыл-
дылар. [6] Паул алар өстенә кулларын куйгач, шәкертләргә Изге
Рух иңде һәм алар таныш булмаган телләрдә сөйли һәм Аллаһы
әйткән сүзләрне игълан итә башладылар. [7] Анда уникеләп шә-
керт бар иде.

[8] Паул өч ай буе гыйбадәтханәгә йөреп, тәвәккәллек белән
вәгазьләде, әңгәмәләр корып, кешеләрне Аллаһы Патшалыгы
турындагы хакыйкатькә инандырырга тырышты. [9] Әмма кай-
берәүләр, усалланып һәм иман китерергә теләмичә, җыелган
халык алдында Раббының юлын яманладылар. Шуңа күрә Паул
алардан китте. Шәкертләрне аерып алып, Туран атлы берәү-
нең дәресләр уза торган бер зур бүлмәсендә һәр көн әңгәмә-
ләр корып утырды.

[10] Ике ел буе шулай дәвам итте. Шунлыктан Асия өлкәсендә
яшәүчеләрнең һәммәсе – яһүдләр дә, яһүд булмаганнар да –
Раббы турындагы хәбәрне ишеттеләр.

*Ә сез кем?*

[11] Аллаһы исә Паулның куллары белән искитәрлек кодрәтле
эшләр кылды. [12] Паул тиеп алган кульяулыкларны, билбауларны
алып китеп авырулар өстенә салдылар һәм шуннан соң авыру-
лар савыкты, алардан явыз рухлар чыкты. [13] Кайбер ырымчы
илгизәр яһүдләр дә, җенлеләрдән явыз рухларны куып чыга-
рырга теләп:

– Мин сезгә Паул вәгазь иткән Гайсә вәкаләте белән боерык
бирәм, – дип, Гайсә Раббы исемен кулланырга тырыштылар.

[14] Яһүд кешесе Эскевә атлы бер баш руханиның җиде улы да
шулай эшләде. [15] Әмма явыз рух:

– Гайсәне беләм, Паул да миңа таныш, ә сез кемнәр? – дип
җавап бирде.

[16] Явыз рухлы кеше аларга ташланды һәм аларны шундый
итеп кыйнады, тегеләр ул йорттан киемнәре ертылган һәм яра-
ланган хәлдә чыгып качтылар. [17] Бу вакыйга Эфестә яшәүче
барлык яһүдләргә һәм башка халык кешеләренә мәгълүм бул-
ды. Бар кешеләр куркуга төште, һәм Гайсә Раббының исеме
тагын да күбрәк ихтирам ителә башлады. [18] Күп кенә иман ки-
тергән кешеләр үзләре кылган начар эшләрне икърар итте.
[19] Ә сихерчелек белән шөгыльләнүчеләрнең күбесе бар кеше
алдында үзләренең китапларын җыеп яндырды. Яндырылган
китапларның бәясен санадылар: бөтенесе илле мең көмеш
тәңкә чыкты.

[20] Раббы турындагы хәбәр менә шундый көч белән таралды
һәм ныгыды.

*Эфестә чуалыш*

21 Шушы вакыйгалардан соң Паул Македуния һәм Ахая жир-
ләре аша Иерусалимга барырга булды.
– Иерусалимнан соң мин Римда булырга тиешмен, – диде
Паул.
22 Ярдәмчеләренең икесен, Тимуте белән Эрастыны, Маке-
дуниягә җибәреп, үзе бераз вакытка Асия өлкәсендә калды.
23 Шул көннәрдә Раббы юлына каршы зур фетнә булды. 24 Грек-
лар алиһәсе Артемида гыйбадәтханәсенең көмештән сурәтен
ясаучы, шушы эш белән һөнәрчеләргә шактый күп табыш
алырга ярдәм итүче Димитер атлы көмешче 25 көмешчеләрне
һәм башка шундый һөнәрчеләрне җыйды.
– Дуслар! Сез беләсез, безнең мул тормышыбыз шушы кә-
сепкә бәйләнгән, – диде ул. – 26 Хәлбуки, сез күрәсез һәм ише-
тәсез, шушы Паул, кеше кулы белән ясалган нәрсәләр илаһлар
түгел, дип сөйләп, Эфестә генә түгел, ә бөтен Асия өлкәсендә
диярлек күп кешеләрне инандырды һәм юлдан яздырды. 27 Мо-
ның куркынычы безнең кәсепнең яманаты чыгу белән генә
тәмамланмый. Бөек алиһә Артемида гыйбадәтханәсенең дә
әһәмияте бетәр, бөтен Асия өлкәсе һәм бөтен дөнья табына
торган алиһә үзенең бөеклегеннән мәхрүм ителер.
28 Шушы сүзләрне ишеткәннән соң һөнәрчеләрнең ачуы ка-
барды:
– Эфеслеләрнең Артемидасы бөек! – дип кычкыра башла-
дылар алар.
29 Бөтен шәһәрдә буталыш башланды. Паулның юлдашла-
рын – македунияле Гәйне һәм Аристархны тотып алып, ба-
рысы бергә тамаша урынына омтылдылар. 30 Паул халыкка мө-
рәҗәгать итәргә теләде, ләкин шәкертләр аны җибәрмәделәр.
31 Шулай ук Паулның дуслары булган Асия өлкәсенең кайбер
башлыклары да, кешеләр артыннан хәбәр җибәреп, аның тама-
ша урынында күренмәвен үтенделәр.
32 Халык җыелган урында берәүләр бер нәрсә, икенчеләр
башка нәрсә кычкырды. Җыелышта тәртипсезлек хөкем сөрде,
андагыларның күбесе ни өчен җыелганнарын да белмиләр иде.
33 Кайберәүләр Искәндәр исемле бер кешене гаепле дип уйла-
дылар, чөнки яһүдләр аны халык алдына чыгарга мәҗбүр ит-
теләр. Искәндәр, халыкка сөйләргә теләп, кулы белән ишарә
ясады. 34 Аның яһүд икәнлеген белеп алгач, һәммәсе бер та-
выштан:
– Эфеслеләрнең Артемидасы бөек! – дип кычкыра башла-
дылар.

Алар шулай дип ике сәгать буе диярлек кычкырдылар. 35 Ни-
һаять, шәһәр сәркатибе, халыкны тынычландырып:
– Эфеслеләр! Эфес шәһәренең бөек алиһә Артемиданы һәм
күктән төшкән изге ташны саклаучы шәһәр икәнен кем генә
белми? – диде. 36 – Моның шулай икәнлеге бәхәссез икән, ул
чакта сез тыныч булырга һәм уйламыйча эш итмәскә тиешсез.
37 Сез тотып китергән бу кешеләр Артемида гыйбадәтханәсен
дә таламаган, сезнең алиһәгезне дә хурламаган. 38 Димитернең
һәм аның белән булган башка һөнәрчеләрнең кемгә дә булса
дәгъвасы бар икән, моның өчен мәхкәмәләр һәм өлкә баш-
лыклары бар. Шунда барып, бер-берсенә шикаять* итсеннәр.
39 Әгәр тагын сорауларыгыз бар икән, сез аларны халык җыелы-
шында күтәрә аласыз. 40 Без хәзер бүгенге вакыйга өчен фетнә
куптаруда гаепләнү куркынычы астында торабыз. Ә бит мон-
дый җыенны акларлык һичбер дәлилебез юк.
Шундый сүзләр әйтеп шәһәр сәркатибе җыелышны таратты.

*Паулның Македуниягә һәм Грециягә сәфәре*

**20** 1 Фетнә тукталганнан соң Паул шәкертләрне үзе яны-
на чакырып алды, аларның күңелләрен күтәрде һәм,
алар белән саубуллашып, Македуния өлкәсенә китте.
2 Авыллар, шәһәрләр аша үткәндә, иман итүчеләрне дәртлән-
дереп, күп нәсыйхәт бирде. Паул Грециядә тукталды. 3 Ул анда
өч ай булды. Су юлы белән Сириягә китәргә дип торганда,
яһүдләр аңа һөҗүм итәргә сүз куештылар. Шуңа күрә ул, Ма-
кедуния аша кайтырга, дигән фикергә килде. 4 Аны Пур улы
беруяле Сопатыр, тессалуникәлеләрдән Аристарх һәм Сикүн-
ди, дербиле Гәй, шулай ук Тимуте һәм асиялеләр Тухик бе-
лән Трофим озата бардылар. 5 Алар, алдан китеп, безне Троас
шәһәрендә көтеп тордылар. 6 Ә без Төче күмәч бәйрәменнән
соң Филиппуйдан су юлы белән киттек һәм, биш көн дигән-
дә, алар янына Троаска килеп җиттек. Без анда җиде көн
булдык.

*Паул үлгән егетне терелтә*

7 Атнаның беренче көнендә икмәк сындырып ашау өчен бер-
гә җыелдык. Паул иман итүчеләр белән әңгәмә корып утырды
һәм, икенче көнне китәргә ниятләгәнгә күрә, әңгәмәне төн
уртасына кадәр дәвам итте. 8 Без җыелган өске каттагы бүлмәдә
күп яктырткычлар яна иде. 9 Паул сөйләгән вакытта, тәрәзә тө-
бендә утырган Әүтух исемле бер яшь егетне йокы басты һәм ул,

---

* 19:38 *Шикаять* – кешенең гаебен күрсәткән сүз яки әләк.

йоклап китеп, өченче каттан егылып төште. Аны күтәрделәр, ул үле иде.

10 Паул урамга чыкты, егетнең өстенә иелеп аны кочаклады һәм:

– Борчылмагыз, ул исән, – диде.

11 Паул янә бүлмәгә менеп, икмәк сындырып ашады, аннары тагын бик озак, таң атканга кадәр, шәкертләр белән сөйләшеп утырды һәм иртә таңнан юлга чыкты.

12 Теге яшь егетне өенә алып киткәндә ул тере иде. Бу хәлгә бар кешеләр бик куанды.

*Троастан Милиткә*

13 Без корабка утырып Ассус шәһәренә таба юл алдык. Паул
коры җирдән барырга һәм шул шәһәрдә безгә кушылырга
булды. 14 Ассус шәһәрендә очрашканнан соң, Паулны алып,
Митулини шәһәренә килдек. 15 Митулинидән киткәннең икен-
че көнендә Хиос утравы каршында тукталдык, ә иртәгесен Сам
утравында идек һәм тагын бер көннән Милит шәһәренә килеп
җиттек. 16 Паул, Асия өлкәсендә тоткарланмас өчен, Эфесне
читләтеп үтәргә булды. Чөнки ул, мөмкинлек булса, Илленче
көн бәйрәме җиткәнче Иерусалимда булырга ашыга иде. 17 Ул,
Милиттән Эфескә кешеләр җибәреп, бердәмлектәге өлкәннәр-
не чакыртты. 18 Алар килеп җиткәч:
– Асия өлкәсендә сезнең белән беренче көннән үк ничек
яшәгәнемне үзегез беләсез, – диде ул аларга. 19 – Зур күндәмлек
һәм күп күз яшьләре белән, яһүдләрнең явыз ниятләре арка-
сында килгән сынаулар эчендә Раббыга хезмәт иттем. 20 Сезгә
файдалы булырлык бернәрсәне дә бәян итмичә калдырмадым,
сезне халык алдында да, өйдән-өйгә йөреп тә өйрәттем. 21 Тәү-
бә итеп Аллаһыга таба борылуның һәм Раббыбыз Гайсәгә иман
китерүнең кирәклеге турында яһүдләргә дә, яһүд булмаганнарга
да җитди рәвештә игълан иттем.
22 Ә хәзер, Рухның ихтыярына буйсынып, Иерусалимга ба-
рам. Мине анда нәрсә көтә? Мин белмим. 23 Мин фәкать шуны
беләм: барлык шәһәрләрдә мине богаулар һәм хәсрәт көтә. Из-
ге Рух шулай ди. 24 Ләкин минем өчен үз тормышымның кадере
юк, тик хезмәтемне һәм Гайсә Раббыдан кабул итеп алган эш-
не – Аллаһының мәрхәмәте турындагы Яхшы хәбәрне вәгазь
итү вазифасын тәгәлләргә телим. 25 Хәзер Мин беләм: минем,
сезнең арагызда йөреп, Аллаһы Патшалыгын вәгазьләвемне
ишеткән һәммәгез мине бүтән күрмәячәксез. 26 Шуңа күрә мин
бүген сезгә әйтәм: әгәр берәрегез һәлак булса, сезнең каныгыз-
да минем гаеп юк. 27 Чөнки мин сезгә Аллаһының ихтыярын
тулысы белән бәян иттем.

[28] Шулай итеп, үзегез турында һәм Изге Рух сезне көтүчеләр
итеп куйган көтү турында кайгыртыгыз. Үз Улының каны аша
Аллаһы Үзенеке иткән бердәмлеккә көтүчеләр булыгыз. [29] Мин
киткәннән соң, сезнең яныгызга рәхимсез, көтүгә карата аяусыз
бүреләрнең киләчәген мин беләм. [30] Иман итүчеләрне үзләренә
ияртү өчен сезнең арагыздан да ялган сөйләүчеләр чыгачак.
[31] Шуңа күрә сак булыгыз, өч ел буе сезнең һәрберегезгә күз
яшьләре белән көне-төне нәсыйхәт бирүемне хәтерегездән чыгармагыз. [32] Хәзер сезне Аллаһы кулына һәм Аның мәрхәмәте
турындагы сүзгә тапшырам. Ул сүз сезне тагын да ныгытырга
һәм барлык изге ителгәннәр арасында сезгә мирас бирергә
сәләтле.

[33] Мин һичкемнең алтын-көмешен дә, киемен дә теләмәдем.
[34] Үзегез беләсез, минем ихтыяҗларымны һәм минем белән
булганнарның хаҗәтләрен менә шушы кулларым канәгатьләндерде. [35] Раббы Гайсәнең: «Алуга караганда бирүдә бәхет
күбрәк», – дигән сүзләрен истә тотып, тырышлык куеп, хәлсезләргә ярдәм итәргә кирәк. Шулай эшләргә кирәклекне мин
һәр эштә күрсәттем.

[36] Сөйләп бетергәч, Паул, тезләнеп, алар белән бергә дога
кылды. [37] Һәммәсе елады, Паулны кочаклап үптеләр. [38] Бигрәк
тә «Мине бүтән күрмәячәксез инде» дигән сүзләренә кайгырдылар. Аннары аны корабка чаклы озата бардылар.

*Паул Иерусалимда*

**21** [1] Без, алар белән саубуллашып, юлга чыктык һәм
туп-туры Кос утравындагы шәһәргә килдек, икенче
көнне Родоста, аннары Патара утравында булдык.
[2] Анда, Фойникә өлкәсенә китүче кораб табып, аңа утырдык
һәм кузгалып киттек. [3] Кипр утравын көньягыннан урап үтеп,
Сурия өлкәсенә таба йөздек. Турда тукталыш ясадык, чөнки
анда корабтан йөк бушатылырга тиеш иде.

[4] Шәкертләрне эзләп таптык һәм алар янында җиде көн
булдык. Алар, Рухның күрсәтүеннән чыгып, Паулны Иерусалимга бармаска кисәттеләр. [5] Китер вакыт җиткәч юлга чыктык. Барлык иман итүчеләр, хатыннары һәм балалары белән,
безне шәһәр читенә кадәр озата бардылар, ә яр буена килеп
җиткәч, бөтенебез бергә тезләнеп дога кылдык. [6] Саубуллашканнан соң, без корабка утырдык, ә алар өйләренә кайтып
киттеләр.

[7] Без исә, юлыбызны дәвам итеп, Пытулемаис шәһәренә
килеп төштек. Анда туганнар янына барып, алар белән бер көн
булдык. [8] Ә икенче көнне Паул һәм без Кайсариягә килдек һәм

Иерусалимда сайланган җиде ярдәмченең* берсе булган, Яхшы
хәбәрне таратучы Филипнең өендә тукталдык. 9 Аның Аллаһы
әйткән сүзләрне игълан итә торган пәйгамбәр кызлары – кияүгә чыкмаган дүрт кызы бар иде.

10 Без килеп берничә көн үткәч, Яһүдиядән Һагәб атлы бер
пәйгамбәр килде. 11 Ул, безнең янга килеп, Паулның билбавын
алды һәм үзенең кул-аякларын бәйләде.

– Изге Рух әйтә: Иерусалимдагы яһүдләр бу билбауның иясен менә шулай бәйләячәкләр һәм мәҗүсиләр кулына тапшырачаклар, – диде Һагәб.

12 Моны ишеткәч, без һәм анда булган башка кешеләр аның
Иерусалимга бармавын үтендек. 13 Әмма Паул:

– Сез нәрсә эшлисез? Ник елыйсыз һәм минем йөрәгемне телгәлисез? Мин Раббы Гайсә исеме хакына Иерусалимда тоткын булырга гына түгел, үләргә дә әзермен, – дип җавап бирде.

14 Без исә, аны күндерә алмагач, тынычландык һәм:

– Раббының ихтыяры булсын! – дидек.

15 Кайсариядә бераз вакыт булганнан соң, җыенып, Иерусалимга киттек.
16 Безнең белән бергә Кайсариядән берничә шәкерт тә барды. Алар безне кипрлы Мынасун атлы, күптән иман итүче бер шәкерт янына, без тукталачак йортка алып килделәр.

*Паул Ягъкуб янында*

17 Иерусалимдагы туганнар безне шатланып кабул иттеләр.
18 Икенче көнне Паул Ягъкуб янына килде. Без дә аңа ияреп
бардык. Анда барлык өлкәннәр җыелган иде. 19 Аларны сәламләгәннән соң, үз хезмәте аркылы Аллаһының башка халыклар арасында нәрсәләр эшләгәнлеге турында Паул җентекләп
сөйләп бирде. 20 Паулны тыңлагач, андагылар Аллаһыны данладылар.

– Беләсеңме, туган, – диделәр аңа, – яһүдләр арасында инде ничә мең иман китергән кеше бар. Алар барысы да Муса канунын бик тырышып яклаучылар.
21 Синең хакта аларга, ул башка
халыклар арасында яшәүче барлык яһүдләрне улларын сөннәткә утыртмаска һәм яһүд халкының йолаларын тотмаска өндәп, Муса кануныннан баш тартырга өйрәтә икән, дип әйткәннәр.
22 Нәрсә эшләргә инде? Әлбәттә, халык синең килүең турында
ишетер. 23 Шуңа күрә безнең сиңа киңәш шундый: бездә нәзер
кылган дүрт кеше бар. 24 Алар белән бергә тазарыну йоласын
үтә. Чәчләрен алдыра алсыннар өчен аларның чыгымнарын үз

* 21:8 Бу турыда алтынчы бүлекнең беренчедән алтынчыга кадәрле аятьләрен укыгыз.

өстеңә ал. Барысы да синең хакта ишеткәннәренең дөрес түгел-
леген һәм үзеңнең дә канунга буйсынып яшәвеңне күрерләр.
25 Ә инде Гайсә Мәсихкә иман китергән башка халык кеше-
ләренә килгәндә, без аларга үзебезнең карарны әйтеп хат яз-
дык. «Потларга корбан итеп китерелгән ризыкны, канны, буып
үтерелгән хайван итен ашаудан һәм җенси азгынлыктан тыелы-
гыз», – дидек без аларга.
26 Шулай итеп, икенче көнне теге кешеләрне үзе белән алып,
Паул алар белән тазарыну йоласын үтте. Шуннан соң Аллаһы
Йортына керде. Анда ул тазарыну көннәренең кайчан тәмам
булачагы һәм кайчан аларның һәрберсе өчен корбан китерелә-
чәге хакында игълан итте.

*Паул Аллаһы Йортында кулга алына*

27 Җиде тазарыну көне үтте дигәндә, Асия өлкәсеннән кил-
гән берничә яһүд, Паулны Аллаһы Йортында күреп, аңа каршы
бөтен халыкны котырттылар һәм аны тотып алдылар:
28 – Исраил ирләре, ярдәм итегез! Бөтен җирдә безнең ха-
лыкка, канунга һәм бу урынга каршы өйрәтә торган кеше
шушы. Шуның өстенә, яһүд булмаганнарны Аллаһы Йорты-
на алып кереп, бу изге урынны мәсхәрә итте, – дип кычкыр-
дылар.
29 Алар аны элегрәк шәһәрдә эфесле Трофим белән бергә
күргәнгә күрә: «Паул аны Аллаһы Йортына да алып кергән», –
дип уйлыйлар иде.
30 Бөтен шәһәрдә ыгы-зыгы купты, төрле яктан халык җый-
налды. Паулны Аллаһы Йортыннан сөйрәп алып чыктылар һәм
шундук капкаларны бикләп куйдылар. 31 Алар аны үтерергә ты-
рышкан вакытта, гаскәриләр башлыгына бөтен Иерусалимда
башланган буталыш турында хәбәр иттеләр. 32 Ул шундук, гас-
кәриләр һәм йөзбашлары белән бергә, халык җыелган урынга
йөгерде. Кешеләр, башлык кешене һәм гаскәриләрне күреп,
Паулны кыйнаудан туктадылар. 33 Гаскәриләр башлыгы якын-
рак килде һәм Паулны кулга алырга, аны ике чылбыр белән
богауларга әмер бирде.
– Бу кеше кем һәм ул нәрсә эшләде? – дип сорады ул.
34 Халык арасында берәүләр бер нәрсә, икенчеләре башка
нәрсә кычкыра башлады. Гаскәриләр башлыгы, шундый шау-шу
булганга күрә эшнең нәрсәдә икәнен белә алмады һәм шунлык-
тан Паулны ныгытмага* алып барырга кушты. 35 Алар баскычка

---

* 21:34 *Ныгытма* – Тарихтан билгеле булганча, монда Антони ны-гытмасы турында сүз бара.

килеп җиткәндә, халык кысрыклаганлыктан, гаскәриләргә
Паулны күтәреп барырга туры килде. [36] Халык төркеме:

— Аңа үлем! — дип кычкыра-кычкыра ияреп барды.

[37] Ныгытма ишекләренә якынлашкач, Паул гаскәриләр башлыгына:

— Сиңа бер нәрсә әйтергә мөмкинме? — диде.

— Син грекча беләсеңмени? — дип гаҗәпләнде теге. — [38] Димәк
элегрәк фетнә күтәреп дүрт мең юлбасарны чүлгә алып
чыккан мисырлы син түгел?

[39] — Мин — яһүд, Киликия өлкәсендәге шактый гына танылган
Тарс шәһәреннән. Синнән үтенәм, халыкка сөйләргә
рөхсәт итче, — диде аңа Паул.

[40] Гаскәриләр башлыгы рөхсәт бирде. Паул, баскычта басып
торган килеш, халыкка ишарә ясады. Тирән тынлык урнашты
һәм Паул яһүд телендә сөйли башлады.

*Паул үзен яклый*

**22** [1] — Туганнар һәм аталар! Үземне яклап берничә сүз әйтергә рөхсәт итегез, — диде Паул.

[2] Аның үзләре белән яһүд телендә сөйләшүен ишетеп,
халык тагын да ныграк тынып калды.

[3] — Мин — яһүд кешесе, — диде ул. — Киликиянең Тарс шәһәрендә
тудым, Иерусалимда тәрбияләндем. Гәмәлиилнең шәкерте
булып, аталар канунына җентекләп өйрәтелдем. Мин дә,
сезнең һәммәгез кебек үк, Аллаһыга бик нык бирелгән кеше.

[4] Мин Раббының юлыннан баручыларны үтергәнчегә тикле
эзәрлекләдем, ир-атларны да, хатын-кызларны да богаулап
зинданнарга ташлаттым. [5] Моның шулай икәнен баш рухани
һәм аксакаллар киңәшмәсе раслый ала. Мин алардан Дәмәшекътә
яшәүче яһүд туганнарга хат алып, шул юлдан баручы
дәмәшекълеләрне җәзалау өчен, аларны богаулап Иерусалимга
алып килергә дип, Дәмәшекъкә бара идем.

*Паул үзенең Раббыга таба борылуы хакында сөйли*

[6] Дәмәшекъкә якынлашып килгәндә, көн уртасындарак,
кинәт күктән көчле яктылык төште һәм минем тирә-ягымны
яктыртты. [7] Мин җиргә егылдым һәм: «Шаул, Шаул! Нигә син
Мине эзәрлеклисең?» — дигән тавыш ишеттем. [8] Мин: «Син
кем, Әфәнде?» — дип җавап бирдем. «Мин — син эзәрлекли
торган насаралы Гайсә», — диде Ул миңа. [9] Минем белән бергә
булган кешеләр яктылыкны күрделәр, әмма миңа Сөйләүченең
тавышын ишетмәделәр. [10] Мин Аннан: «Раббы, миңа нәрсә эшләргә?»
— дип сорадым. «Тор да Дәмәшекъкә бар, анда сиңа

дип билгеләп куелган барлык эшләр турында әйтерләр», – диде миңа Раббы.

[11] Көчле яктылыктан сукырайганга күрә, минем белән булган кешеләр мине Дәмәшекъкә җитәкләп алып килделәр. [12] Дәмәшекътә яшәүче, барлык яһүдләр арасында мөхтәрәм, диндар һәм канунга турылыклы Һанани исемле берәү [13] минем яныма килде һәм миңа: «Шаул туган! Күзләрең ачылсын», – диде. Шундук минем күзләрем ачылды һәм мин аны күрдем. [14] «Ата-ларыбызның Аллаһысы Аның ихтыярын белергә, Хак Затны күрергә һәм Раббының тавышын ишетергә сине алдан билгеләде, – диде миңа Һанани. – [15] Чөнки син барлык кешеләргә күргәннәреңне һәм ишеткәннәреңне сөйләп, Аңа шаһит булырсың. [16] Шулай итеп, тагын нәрсә көтәргә? Тор һәм суга чумдырылу йоласын үт, Раббыга мөрәҗәгать итеп, гөнаһларыңны юып төшер», – диде ул миңа.

[17] Иерусалимга кайткач, Аллаһы Йортында гыйбадәт кылган вакытта, гадәти булмаган гыйбадәт кылу халәтенә килеп, [18] Раббыны күрдем. Ул миңа: «Ашык һәм тиз арада Иерусалимнан кит, чөнки монда Минем хактагы шаһитлегеңне кабул итмәячәкләр», – диде. [19] «Раббым! – дидем мин. – Гыйбадәтханәдән гыйбадәтханәгә йөреп, Сиңа иман итүчеләрне тотып зинданнарга утыртуым һәм кыйнавым хакында алар беләләр. [20] Синең хакта шаһитлек итүче Эстефәннең каны коелган вакытта мин анда идем. Мин аны үтерүне хупладым, үтерүчеләрнең киемнәрен саклап тордым», – дип җавап бирдем. [21] Раббы миңа: «Бар, Мин сине еракка, башка халыклар янына җибәрәм», – диде.

*Паул – Рим гражданы*

[22] Шушы сүзләрне әйткәнче Паулны тыңладылар, ә аннары:

– Бу кешене җир йөзеннән юк итәргә! Мондый кеше яшәргә тиеш түгел, – дип кычкыра башладылар.

[23] Алар, акыра-акыра, киемнәрен өскә күтәреп болгадылар, һавада тузан туздырдылар*. [24] Гаскәриләр башлыгы Паулны ныгытмага алып керергә әмер бирде. Аңа каршы шул чаклы акыруларының сәбәбен белү өчен, аны камчылап сорау алырга боерды. [25] Ләкин аны каешлар белән бәйләгән вакытта Паул үзе янында торган йөзбашына:

– Рим гражданын камчыларга, җитмәсә, хөкем итмичә торып, сезгә рөхсәт ителәмени? – диде.

---

* **22:23** *Һавага тузан туздыру* – яһүдләрдә каты ачулануны белдерү өчен кулланылган хәрәкәт: җирдән учлап тузан алганнар һәм һавага чәчкәннәр, киемнәрен өскә күтәреп болгаганнар.

26 Йөзбашы, моны ишеткәч, гаскәриләр башлыгына барып
әйтте.
– Сез нәрсә эшлисез? Бу кеше – Рим гражданы, – диде
ул аңа.
27 Шуннан соң гаскәриләр башлыгы, Паул янына килеп:
– Әйт әле миңа, син Рим гражданымы? – диде.
– Әйе, – диде Паул.
28 – Мин бу гражданлыкны күп акча түләп алдым, – дип җа-
вап бирде гаскәриләр башлыгы.
– Ә мин шул гражданлыкта тудым, – диде Паул.
29 Аннан сорау алырга теләүчеләр шундук аның яныннан чит-
кәрәк киттеләр, ә гаскәриләр башлыгы, Паулның Рим гражданы
икәнлеген белгәч, аны бәйләгәне өчен куркуга төште.
30 Икенче көнне, яһүдләрнең Паулны нәрсә өчен гаепләүләрен
төгәл белергә теләп, гаскәриләр башлыгы баш руханиларга,
Югары киңәшмә әгъзаларының барысына җыелырга әмер бир-
де һәм, богауларын салдырып, Паулны алар алдына бастырды.

*Паул Югары киңәшмә алдында*

23 1 Паул, Югары киңәшмә әгъзаларына карап:
– Туганнар! – диде. – Бүгенге көнгә кадәр Аллаһы
каршында саф вөҗдан белән яшәдем.
2 Иң баш рухани Һанани Паул янында торучыларга аның
авызына сугарга кушты. 3 Ә Паул аңа:
– Әй, агартылган дивар, сиңа Аллаһы сугачак! Син канун бу-
енча хөкем итү өчен утырасың, ә үзең, канунга каршы килеп,
миңа сугарга әмер бирәсең, – диде.
4 – Син Аллаһының иң баш руханиен мыскыл итәсеңме? –
диделәр аның янында торучылар.
5 – Мин, туганнар, аның иң баш рухани икәнлеген белмәдем.
Изге язмада: «Үз халкың белән идарә итүче турында начар сөй-
ләмә», – дип язылган, – диде Паул.
6 Андагыларның бер өлеше саддукейлар, икенче өлеше фари-
сейләр икәнлеген белеп алгач, Паул, кычкырып:
– Туганнар! Минем ата-бабаларым фарисей булганнар, үзем
дә мин фарисей. Мине үлеләрнең терелүе турындагы өметем
өчен хөкем итәләр, – диде.
7 Ул шулай дигәннән соң фарисейләр белән саддукейлар ара-
сында каты бәхәс башланды, һәм җыелыш икегә бүленде.
8 Чөнки саддукейлар, үледән терелү дә, фәрештәләр дә, рухлар
да юк, диләр, ә фарисейләр боларның барысын да икърар итә-
ләр. 9 Зур гауга купты, фарисейләрдән булган канунчылар бик
нык бәхәсләштеләр.

– Без бу кешедә һичбер начарлык тапмыйбыз. Бәлки аңа рух яки фәрештә нәрсәдер әйткәндер, – диделәр алар.

10 Ызгыш көчәйгәнлектән, гаскәриләр башлыгы, Паулны өзгәләп ташлауларыннан курыкканга күрә, гаскәриләргә, аска төшеп, аны ул кешеләр арасыннан алырга һәм ныгытмага илтергә әмер бирде.

11 Икенче төнне Паул янына Раббы килде.

– Нык бул! Иерусалимда Минем турыда ничек шаһитлек биргән булсаң, Римда да шулай шаһитлек бирергә тиешсең, – диде аңа Раббы.

*Яһүдләр Паулны үтерергә теләп сүз куешалар*

12 Көн тугач, кайбер яһүдләр бергә җыелып явыз ният кордылар һәм Паулны үтергәнчегә тикле ашамаска, эчмәскә ант иттеләр.
13 Ант итүчеләрнең саны кырыктан артык иде.
14 Алар, баш руханилар һәм аксакаллар янына килеп:

– Без Паулны үтермичә торып һичнәрсә ашамаска җитди рәвештә ант иттек.
15 Ә сез хәзер, Югары киңәшмә белән берлектә, аның хакындагы эшне төгәлрәк тикшерергә телибез, дигән булып, гаскәриләр башлыгыннан аны сезнең янга чыгаруын сорагыз. Без әзер торырбыз һәм ул юлда чагында аны үтерербез, – диделәр.

16 Паулның сеңлесенең улы, аларның явыз нияте турында ишетеп, ныгытмага килде һәм бу турыда Паулга әйтте.

17 Паул исә, йөзбашларының берсен чакырып:

– Бу егетне гаскәриләр башлыгы янына алып бар, чөнки аның аңа әйтәсе сүзе бар, – диде.

18 Йөзбашы егетне гаскәриләр башлыгы янына алып килде.

– Тоткын Паул бу егетне сезнең яныгызга алып килүемне сорады. Ул сезгә нәрсәдер әйтергә тели.

19 Гаскәриләр башлыгы, егетнең кулыннан тотып, аны читкәрәк алып китте.

– Син миңа нәрсә әйтергә телисең? – дип сорады ул аннан.

20 – Яһүдләр, Паул хакындагы эшне төгәлрәк тикшерү өчен дигән булып, иртәгә сездән Паулны Югары киңәшмә алдына китерүегезне сорарга сүз куештылар, – дип җавап бирде егет. –
21 Ләкин сез аларны тыңламагыз, чөнки Паулны үтергәнчегә тикле ашамаска һәм эчмәскә дип ант иткән кырыктан артык кеше аны сагалап торалар. Алар инде Паулны үтерергә әзер, алар сезнең сүзегезне генә көтәләр.

22 Шуннан соң гаскәриләр башлыгы егеткә:

– Моны миңа сөйләвең турында беркемгә дә әйтмә, – дип, аны кайтарып җибәрде.

*Паул идарәче Филикескә җибәрелә*

23 Шуннан соң гаскәриләр башлыгы ике йөзбашын чакырып алды.

– Ике йөз җәяүле, җитмеш атлы һәм ике йөз укчы гаскәр
әзерләгез. Алар кичке сәгать тугызда Кайсариягә китсеннәр.
24 Паулны утыртып алып барырга да атлар әзер булсын. Аны
идарәче Филикес янына хәвеф-хәтәрсез алып барып җиткерегез, – диде ул аларга.

25 Һәм шундый эчтәлекле хат язды:

26 «Кләүди Лусидән мөхтәрәм идарәче Филикескә сәлам!

27 Яһүдләр бу кешене тотып алганнар һәм үтерергә җыеналар иде. Мин, аның Рим гражданы икәнен белгәч, гаскәриләр белән барып, аны коткарып калдым.

28 Аннары, аны ни өчен гаепләүләрен белергә теләп, бу
кешене яһүдләрнең Югары киңәшмәсенә алып килдем
29 һәм гаепләүләрнең яһүдләр канунына кагылышлы икәнлеген белдем, аны үлемгә яки богаулауга дучар итәрлек гаепләүләр булмады.

30 Бу кешегә каршы явыз ният турында ишеткәч, мин аны тиз арада Сезнең яныгызга җибәрдем, аны гаепләүчеләргә аңа каршы Сезнең алда сөйләргә әмер бирдем».

31 Шулай итеп, гаскәриләр, үзләренә бирелгән әмерне үтәп,
төнлә белән Паулны Антипатырга алып киттеләр. 32 Ә икенче
көнне, Паулны атлы гаскәриләргә тапшырып, җәяүле гаскәриләр кире ныгытмага кайттылар. 33 Кайсариягә килеп җиткәч,
гаскәриләр, идарәчегә хатны биреп, Паулны аның карамагына
тапшырдылар. 34 Идарәче хатны укып чыкты һәм Паулның кайсы өлкәдән булуын сорады. Киликиядән икәнен белгәч, 35 бу
эшне гаепләүчеләр килгәч кенә тыңлаячагын әйтте. Ә Паулны Һируд сараенда сак астында тотарга әмер бирде.

*Паулга гаеп ташлау*

**24** 1 Биш көннән баш рухани Һанани аксакаллар белән һәм канун буенча белгеч булган Тертул атлы бер кеше белән Кайсариягә килде. Алар идарәче янына Паулга
гаеп ташлау өчен килделәр. 2 Паулны чакыртып китергәч, Тертул гаепләү сүзләрен башлады:

3 – Мөхтәрәм Филикес! Сезнең җитәкчелек астында озак вакыт тынычлыкта яшәвебезне һәм сез кайгыртканга күрә бу халыкның хәле яхшы якка үзгәрүен һәрвакыт һәм һәр җирдә күп рәхмәтләр белән икърар итәбез, – диде ул. – 4 Сезне озак
мәшәкатьләмәс өчен, без әйтергә теләгән берничә сүзне ачык күңел белән тыңлавыгызны үтенәм.

[5] Бөтен дөньяда яшәүче яһүдләр арасында фетнә салучы һәм
Насара мәзһәбенең* башлыгы булган бу кешене бердәмлекнең
чире дип таптык. [6] Ул хәтта Аллаһы Йортын нәҗесләргә ты-
рышты. Без аны кулга алдык [һәм үз канунибыз буенча хөкем
итәргә теләдек. [7] Әмма гаскәриләр башлыгы Луси аны безнең
кулдан көч белән йолып алды. [8] Аны гаепләүчеләргә сезнең
яныгызга килергә кушты.]** Безнең аны нәрсәдә гаепләвебезне
сез үзегез аннан сорап белә алырсыз, – диде Тертул.
[9] Яһүдләр:
– Әйе, шулай, – дип, аның сүзләрен раслап тордылар.

*Паул Филикес алдында*

[10] Идарәче, сөйләргә мөмкин дип, Паулга ишарә ясады.
– Сезнең бу халыкны күп еллар буе хөкем итүегезне бел-
гәнгә, мин үземне шатланып яклаячакмын, – диде Паул. –
[11] Аллаһыга табыну өчен Иерусалимга килгәнемә унике көннән
дә артык булмаганлыгын белә аласыз. [12] Аллаһы Йортында да,
гыйбадәтханәләрдә дә, шәһәрдә дә алар минем бер кеше белән
дә бәхәсләшүемне яки халык арасында фетнә салуымны күр-
мәделәр. [13] Үзләре миңа хәзер ташлаган гаепләүләрен дә исбат
итә алмыйлар. [14] Әмма сезнең алда шуны икърар итәм: мин,
алар мәзһәб дип атаган юлдан барып, аталарым Аллаһысына
хезмәт итәм, Муса канунына һәм пәйгамбәрләр тарафыннан
язылганнарның барысына ышанам. [15] Тәкъва кешеләр дә, тәкъ-
ва булмаганнар да үледән тереләчәк, дип, алар кебек үк, мин
дә Аллаһыга өмет баглыйм. [16] Шуңа күрә мин һәрвакыт Аллаһы
алдында һәм кешеләр каршында саф вөҗдан белән яшәргә
тырышам.
[17] Күп еллар үткәннән соң үз халкыма хәер-сәдака бирү өчен
һәм корбан китерергә дип Иерусалимга кайттым. [18] Аллаһы
Йортында тазарыну йоласын үтеп, мин шушы эшләрне баш-
карган вакытта алар миңа тап булдылар. Минем яныма халык
та җыелмаган иде, беркемне дә борчымадым да. [19] Алар Асия
өлкәсендә яшәүче берничә яһүд иде. Мине гаепләрлек берәр
нәрсәләре булса, алар сезнең каршыгызга килеп басарга һәм
мине гаепләргә тиешләр иде. [20] Яки, бу кешеләр мин Югары
киңәшмә алдында торганда миндә нинди явызлык табулары
хакында әйтсеннәр. [21] Мин анда булганда: «Мине хәзер үлеләр-
нең терелүенә ышануым өчен хөкем итәләр», – дип кычкырып
әйттем, башка һичнәрсә эшләмәдем, – диде Паул.

---

* 24:5 *Мәзһәб* – дини төркем (русча – секта).
** 24:6-8 Кайбер кулъязмаларда җәяләр эчендәге өлеш тә бар.

[22] Раббының юлы хакында яхшы белгән Филикес:
– Сезнең эш турында гаскәриләр башлыгы Луси килгәч ка-
рар кылырмын, – дип, тикшерү эшен кичектерде.
[23] Ә йөзбашына, Паулны сак астында тотарга, ләкин аның
дусларына аңа хезмәт күрсәтүдә комачауламаска, дигән әмер
бирде.

*Паул сак астында*

[24] Берничә көннән соң Филикес үзенең яһүд хатыны Друсилла
белән килде һәм Паулны чакыртып алды. Ул Паулның Гайсә
Мәсихкә иман итү турында сөйләгәнен тыңлады.
[25] Паул тәкъвалык, нәфесне тыю һәм булачак хөкем хакында
сөйләгәндә Филикес куркуга төште.
– Хәзергә җитте, вакыт тапкач сине чакыртырмын, – диде
ул. [26] Шул ук вакытта ул Паул аңа акча бирер дип өмет итте.
Шуңа күрә аны еш кына чакыртып, Паул белән әңгәмә корып
утырды. [27] Әмма ике елдан Филикес урынына Порки Фисте
килде. Филикес, яһүдләргә ярарга тырышып, Паулны тоткын-
лыкта калдырды.

*Паул кайсар хөкемен таләп итә*

**25** [1] Өлкәгә килеп өч көн торганнан соң Фисте Кайсария-
дән Иерусалимга китте. [2] Баш руханилар һәм яһүдләр-
нең башлыклары, аның янына килеп, Паулга гаеп
ташладылар. [3] Үзләренә мәрхәмәт күрсәтүне сорап, Паулны
Иерусалимга чакыртуын үтенделәр. Ә үзләре аны юлда үте-
рергә сүз куештылар. [4] Әмма Фисте Паулның Кайсариядә сак
астында калачагын һәм тиздән үзенең шул шәһәргә барача-
гын әйтте.
[5] – Шулай итеп, – диде ул, – җитәкчеләрегез минем белән
барсын һәм, ул кешенең гаебе булса, аның гаебен әйтсен.
[6] Иерусалимда атна – ун көн булганнан соң, Фисте Кайсари-
ягә кайтты. Икенче көнне ул хөкем итү урынына утырды һәм
Паулны алып керергә әмер бирде. [7] Паул кергәч, Иерусалимнан
килгән яһүдләр аны урап алдылар һәм аңа каршы күп санлы
авыр гаепләүләр ташладылар, ләкин ул гаепләүләрне исбат итә
алмадылар.
[8] – Мин яһүдләр канунына да, Аллаһы Йортына да, кайсар-
га каршы да һичнинди начарлык кылмадым, – диде Паул үзен
яклап.
[9] Фисте, яһүдләргә ярарга теләп, Паулдан:
– Иерусалимга барырга һәм анда, бу гаепләүләрне тикшерү
өчен, минем хөкем алдына басарга син ризамы? – дип сорады.

[10] – Мин кайсарның хөкеме урыны алдында торам һәм мин шундый урында хөкем ителергә тиешмен. Сез үзегез дә яхшы беләсез, мин яһүдләрне бер нәрсә белән дә рәнҗетмәдем.
[11] Әгәр дә мин нәрсәнедер дөрес эшләмичә үлемгә хөкем ителерлек эш кылганмын икән, үлемнән баш тартмыйм. Ә инде алар миңа ташлаган гаепләүләр дөрес булмаса, беркем дә мине аларның кулына тотып бирә алмый. Кайсарга мөрәҗәгать итәргә* телим, – диде Паул.
[12] Фисте, ярдәмчеләре белән киңәшләшкәннән соң:
– Син кайсарга мөрәҗәгать итәргә теләдең һәм кайсар янына китәчәксең, – диде.

*Паул Әгрип патша алдына китерелә*

[13] Берничә көннән, Фистене тәбрик итү өчен, Әгрип патша белән Берники Кайсариягә килделәр. [14] Алар анда күп көннәр
булганлыктан, Фисте Паулның эшен патшага тыңларга тәкъдим итте:
– Монда Филикес тоткынлыкта калдырган бер кеше бар.
[15] Мин Иерусалимда булганда яһүдләрнең баш руханилары һәм аксакаллары, аны хөкем итүне таләп итеп, шикаять белән килделәр. [16] Мин аларга римлыларда, гаепләнүченең йөзенә карап гаепләүчеләре һәм гаепләүгә каршы үзен яклау мөмкинлеге булмыйча торып, кешене җәзага тарту гадәте юклыгын әйтеп
җавап бирдем. [17] Алар монда килгәч, мин һич кичектермичә, икенче көнне үк, хөкем итү урынына утырдым һәм ул кешене алып килергә әмер бирдем. [18] Гаепләүчеләр аңа гаеп ташларга дип сүз алдылар, ләкин мин көткән гаепләүләрнең берсен дә китермәделәр.
[19] Алар үзләренең диннәренә кагылышлы мәсьәләләр турында, Паул тере дип раслаган ниндидер үлгән Гайсә хакында бәхәстә иделәр. [20] Бу мәсьәләне хәл итәргә кыенсынып, мин аңа: «Иерусалимга барырга һәм бу эш буенча шунда хөкем ителергә телисеңме?» – дидем. [21] Әмма ул галиҗәнап карарын сорады һәм сак астында калырга теләде. Шуңа күрә мин аны, кайсар янына җибәрелгәнче, сак астында тотарга куштым, – диде Фисте.
[22] Әгрип Фистегә:
– Ул кешене мин дә тыңларга телә идем, – диде.
– Иртәгә сез аны тыңларсыз, – дип җавап бирде Фисте.

---

* **25:11** *Кайсарга мөрәҗәгать итү* – Хөкемгә тартылган Рим гражданы куллана алган иң югары мөмкинлек – кайсарга мөрәҗәгать итү булган.

[23] Икенче көнне Әгрип һәм Берники, хәрби җитәкчеләр һәм
иң күренекле гражданнар белән бергә, бик купшыланып зур
бүлмәгә кергәч, Фисте әмере буенча Паулны алып килделәр.
[24] – Әгрип патша һәм биредә утыручылар! – диде Фисте. –
Иерусалимда да, монда да күп яһүдләр менә шушы кешедән
зарландылар. Алар: «Ул бүтән яшәргә тиеш түгел», – дип кыч-
кырдылар. [25] Әмма мин, ул үлемгә хөкем ителерлек бернинди
эш эшләмәгән, дип таптым һәм, ул үзе галиҗәнапка мөрәҗә-
гать итәргә теләгәнлектән, мин аны кайсар янына җибәрергә
булдым. [26] Ләкин аның хакында кайсарга нәрсә язарга да бел-
мим. Шуңа күрә, тикшергәннән соң язарлык берәр нәрсә
булсын иде дип, мин аны сезнең алдыгызга, бигрәк тә, Әгрип
патша, сезнең каршыгызга китердем. [27] Чөнки тоткынның
нинди эштә гаепләнүен күрсәтмичә аны кайсар янына җибәрү,
минемчә, уйламыйча эшләнгән эш булачак.

*Паул Әгрип патша алдында*

**26** [1] Әгрип Паулга:
– Сиңа үзеңне яклап сөйләргә рөхсәт ителә, – диде.
Шуннан соң Паул кулын күтәрде һәм үзен яклап сөйли
башлады:
[2] – Әгрип патша! Бүген сезнең алда яһүдләрнең барлык гаеп-
ләүләреннән үземне яклый алуыма мин бәхетле. [3] Сез яһүд-
ләрнең барлык йолаларын һәм бәхәсле фикерләрен бик яхшы
белгәнгә күрә мине түземлелек белән тыңлавыгызны үтенәм.
[4] Яшьтән үк минем ничек гомер иткәнлегемне барлык яһүд-
ләр белә. Үз халкым арасында яшәгәнлегемне һәм Иеруса-
лимдагы тормышымны алар баштан ук беләләр. [5] Алар мине
күптәннән белә һәм, теләсәләр, минем фарисейләр төркемен-
дә булганлыгым – динебезнең иң таләпчән тәгълиматын тот-
канлыгым хакында шаһитлек бирә алалар. [6] Һәм хәзер мин
Аллаһы тарафыннан аталарыбызга бирелгән вәгъдәнең үтәлүен
өмет итүем өчен хөкем алдында торам. [7] Безнең унике кабилә,
ул вәгъдәнең тормышка ашуына өмет баглап, көне-төне тыры-
шып Аллаһыга хезмәт итә. Әгрип патша, яһүдләр мине шушы
өмет өчен гаеплиләр. [8] Кешеләр, ни өчен сез Аллаһының үле-
ләрне терелтүен ышанмаслык эш дип саныйсыз?
[9] Дөрес, мин дә, Насаралы Гайсә исеменә каршы мөмкин
булган бөтен нәрсәләрне эшләргә кирәк, дип уйладым. [10] Һәм
Иерусалимда мин шулай эшләдем дә: баш руханилардан вәка-
ләт алып, Аллаһының күп изгеләрен зинданнарга ташлаттым,
башкалар аларны үтергәндә мин ризалыгымны белдерә идем.
[11] Гыйбадәтханәдән гыйбадәтханәгә йөреп, күп тапкырлар мин

аларны җәзаладым һәм Гайсәгә булган иманнарын инкяр иттерергә тырыштым. Аларга карата ачуым бик көчле булганлыктан, андыйларны хәтта чит шәһәрләрдә дә эзәрлекләдем.

*Паул үзенең Раббыга таба борылуы хакында сөйли*

**12** Тагын шундый максат куеп, баш руханилар тапшырган эш
буенча һәм аларның вәкаләте белән Дәмәшекъкә барганда,
**13** көн уртасындарак, әй, патша, күктән төшкән бик көчле якты-
лык күрдем. Кояштан да яктырак ул ут минем һәм юлдашларым-
ның тирә ягын яктыртты. **14** Без барыбыз да җиргә егылдык,
һәм мин тавыш ишеттем. Ул тавыш миңа яһүд телендә: «Шаул,
Шаул! Ни өчен син Мине эзәрлеклисең? Үгез үз хуҗасының
таягына тибенгән кебек, үзеңә зыян китерәсең», – диде.
**15** «Син кем, Әфәнде?» – дип сорадым мин. Ул миңа әйтте:
«Мин – син эзәрлекли торган Гайсә. **16** Тор, аякларыңа бас!
Мин сине хезмәтче итеп куяр өчен, хәзер күргәннәреңә һәм
Минем тарафтан сиңа киләчәктә күрсәтеләчәк әйберләргә
сине шаһит итәр өчен сиңа күрендем. **17** Сине яһүд халкыннан
да, башка халыклар кулыннан да коткарырмын. Мин сине алар
янына җибәрәм. **18** Гөнаһлары кичерелсен өчен, Миңа булган
иман аркылы изге ителгәннәр арасында урын алсыннар өчен
син аларның күзләрен ачарга, аларны караңгылыктан якты-
лыкка, шайтан хакимиятеннән Аллаһыга таба борырга тиеш-
сең», – диде миңа Раббы.
**19** Шуңа күрә, Әгрип патша, күктән килгән илаһи күренешкә
мин буйсындым **20** һәм башта Дәмәшекъ һәм Иерусалим кеше-
ләренә, аннары бөтен Яһүдия җирендә яшәүчеләргә һәм яһүд
булмаган башка халыкларга вәгазьләдем. Мин аларны тәүбә
итәргә һәм Аллаһыга таба борылырга, тәүбә итүләрен күрсәтә
торган лаеклы эшләр кылырга чакырдым. **21** Аллаһы Йортында
яһүдләр мине менә шуның өчен тотып алдылар һәм үтерергә
тырыштылар. **22** Ләкин, Аллаһының ярдәме белән, мин бүгенге
көнгә кадәр олысына да, кечесенә дә шаһитлек бирәм. Мин
бары тик пәйгамбәрләр һәм Муса, киләчәктә булачак, дип
әйткән хәлләр турында гына сөйлим. **23** Алар Мәсихнең газап
чигәргә тиешлеген һәм беренче булып үледән терелачәген,
яһүд халкына һәм башка халыкларга яктылык турындагы хәбәр
игълан итәчәген әйткәннәр иде, – диде Паул.
**24** Ул шулай дип үзен яклаганда, Фисте аңа:
– Син, Паул, акылыңнан шашкансың! Зур гыйлемлек сине
акылдан яздыра, – диде.
**25** – Юк, мөхтәрәм Фисте, – диде Паул. – Мин акылдан
шашмадым, мин аек акыл белән хакыйкать сүзләре сөйлим.

26 Патша болар турында белә, һәм мин аның алдында кыюлык
белән сөйли алам. Бу эшләр патшаның игътибарыннан читтә
калмаганлыгына шигем юк, чөнки аларның берсе дә яшерен
эшләнмәде.
27 Әгрип патша, пәйгамбәрләргә ышанасызмы? Беләм, ыша-
насыз, – диде Паул.
28 Әгрип Паулга:
– Син мине шулай тиз генә мәсихче итәргә мөмкин дип уй-
лыйсыңмы? – диде.
29 – Тиз генәме, юкмы, – диде Паул, – сезнең генә түгел, ә
бүген мине тыңлаучыларның барысының да минем кебек булу-
ларын Аллаһыдан үтенеп сорыйм. Әлбәттә, богаулардан тыш.
30 Шуннан соң патша һәм идарәче, Берники һәм алар бе-
лән утыручылар урыннарыннан тордылар
31 һәм, читкәрәк
китеп:
– Бу кеше үлемгә яки тоткынлыкка хөкем ителерлек һичнәр-
сә эшләмәгән, – дип сөйләштеләр.
32 Әгрип Фистегә:
– Кайсарга мөрәҗәгать итәргә теләмәгән булса, бу кешене
азат итәргә мөмкин булган булыр иде, – диде.

*Паулны Римга җибәрәләр*

**27**
1 Безнең Италиягә баруыбыз турында карар кылынгач,
Паулны һәм тагын берничә тоткынны югары патша
полкының Юли атлы йөзбашына тапшырдылар.
2 Без
Асия өлкәсенә бара торган Адрамут шәһәреннән булган ко-
рабка утырдык һәм йөзеп киттек. Безнең белән Тессалуникә
шәһәрендә яшәүче македунияле Аристарх барды.
3 Икенче
көнне Сидун шәһәренә килеп җиттек. Юли, кешелеклелек
күрсәтеп, Паулга дуслары янына барырга һәм аларның кайгыр-
туларыннан файдаланырга рөхсәт итте.
4 Сидуннан без тагын
диңгезгә чыктык һәм, җил каршы булганлыктан, Кипрның
җилдән ышык ягына таба йөзеп киттек.
5 Киликия һәм Пам-
фулия ярлары буйлап диңгезне кичтек һәм Лукия өлкәсендәге
Мура шәһәренә килеп җиттек.
6 Мурада йөзбашы, Искәндәрия
шәһәреннән булган Италиягә китәчәк корабны табып, безне
шул корабка утыртты.
7 Без күп көннәр акрын йөздек һәм
бик авырлык белән Книд шәһәре турысына килеп җиттек.
Көчле җил аркасында бу юнәлештә бару мөмкин булмаганга
күрә, Салмуни борынын узып, Критның җилдән ышык ягына
юнәлдек.
8 Авырлык белән яр буйлап йөзеп, Яхшы гаваньнар
дигән урынга килдек. Ул урыннан ерак түгел Ласея шәһәре
урнашкан иде.

*Паул киңәш бирә*

9 Шактый күп вакыт үтте. Ураза вакыты да үтеп китте һәм, диңгез буенча юлны дәвам итү куркыныч булганлыктан, Паул киңәш бирде:
10 – Әфәнделәр! Хәзер диңгездә булу йөк һәм кораб өчен генә түгел, ә үзебез өчен дә куркыныч булачагын һәм күп зыян китерәчәген күрәм, – диде ул.
11 Ләкин йөзбашы, Паулның сүзләренә караганда койрык тотучының һәм кораб хуҗасының сүзләренә күбрәк колак салды.
12 Гавань кыш үткәрергә яраклы булмаганлыктан, диңгезчеләрнең күбесе аннан китәргә һәм, мөмкин булса, Критның көньяк-көнбатыш һәм төньяк-көнбатышка караган ягында урнашкан Фойникес гаванена барырга һәм шунда кышларга карар кылдылар.

*Кораб давылга эләгә*

13 Көньяк җиле исә башлагач, алар, инде теләгебезгә ирештек, дип уйлап, якорь күтәрделәр, һәм без Крит яры буйлап йөзеп киттек.
14 Әмма, күп тә үтмәде, «төньяк-көнбатыш җиле» дип аталган бик көчле җил купты.
15 Җил безнең корабны эләктереп алды һәм агызып алып китте. Кораб җилгә каршы тора алмады.
16 Кәүдә дип аталган кечкенә генә утрауның җилдән ышык ягына килеп чыгып, авырлык белән генә коткару көймәсен урнаштырып куя алдык.
17 Аны палубага күтәргәннән соң, арканнарны кораб астыннан үткәреп, корабны бәйләп куйдылар. Сиртис дип аталган сай җиргә утырудан куркып, җилкәнне төшердек һәм шул хәлдә диңгез буйлап йөзеп йөрдек.
18 Һаман көчле давыл булганлыктан, икенче көнне йөкләрне диңгезгә ташлый башладылар.
19 Ә өченче көнне, үз куллары белән, диңгезгә кораб җиһазларын ыргыттылар.
20 Күп көннәр кояш та, йолдызлар да күренмәгәч һәм көчле давыл дәвам иткәнлектән, котылуга булган бөтен өмет югалды.

*Берегез дә һәлак булмассыз*

21 Корабтагы кешеләр күп көннәр буе бернәрсә ашамадылар. Паул аларга:
– Әфәнделәр! Минем сүзне тыңларга һәм Криттан кузгалмаска кирәк иде. Шулай иткән булсак, бу кыенлыклар да, югалтулар да булмаган булыр иде.
22 Ә хәзер минем сезгә киңәшем шундый: күңелегезне төшермәгез, чөнки сезнең берегез дә һәлак булмаячак, корабны гына югалтачаксыз, – диде. –
23 Мин Аллаһы кешесе һәм Аңа хезмәт итәм. Үткән төнне

Аллаһының бер фәрештәсе миңа күренде. [24] Ул миңа: «Курыкма, Паул! Син кайсар алдында булырга тиешсең. Аллаһы Ул – мәрхәмәтле. Ул синең белән булган кешеләрнең барысына да тормыш бүләк итә», – диде. [25] Менә шуңа күрә, әфәнделәр, күңелегезне төшермәгез, мин Аллаһыга инанам, Ул миңа әйткәнчә булачак. [26] Без ниндидер утрауга килеп чыгачакбыз, – диде Паул.

[27] Әдрән диңгезендә йөзеп йөргәндә, ундүртенче төннең урталары җиткәч, диңгезчеләр коры җиргә якынлашуыбызны сизә башладылар. [28] Алар тирәнлекне үлчәделәр – утыз җиде метр чамасы* булды. Күпмедер вакыт үткәч тагын үлчәделәр – егерме җиде метр чамасы иде. [29] Ташлы урынга барып эләгүдән куркып, корабның койрык ягыннан дүрт якорь төшерделәр һәм көн тууын теләп дога кылдылар.

[30] Диңгезчеләр, корабтан качарга теләп, борын яктан якорьлар төшерергә телибез, дигән сылтау белән диңгезгә көймә төшергәч, [31] Паул йөзбашына һәм гаскәриләргә:

– Алар корабта калмасалар, сез котыла алмаячаксыз, – диде.

[32] Шуннан соң гаскәриләр көймә бауларын чабып өзделәр, һәм көймә суга төшеп китте.

[33] Көн туар алдыннан, Паул һәммәсен ризык ашарга кыстады.

– Сез инде ундүртенче көн көтәсез һәм һичнәрсә ашамыйсыз. [34] Шуңа күрә ашавыгызны үтенәм: бу сезнең гомерегезне саклап калу өчен зарур. Сезнең берегезнең дә башыннан бер генә бөртек чәче дә төшмәс, – диде ул.

[35] Шулай дигәч, Паул, икмәкне кулларына алып, Аллаһыга шөкрана кылды һәм сындырып ашый башлады. [36] Шул вакыт барысының да күңелләре күтәрелде һәм алар да ашарга утырдылар. [37] Без корабта бөтенесе ике йөз җитмеш алты җан идек. [38] Ашап туйгач, диңгезчеләр корабны җиңеләйтү өчен диңгезгә булган бодайны ташладылар.

### *Көймә җимерелә, кешеләр исән кала*

[39] Көн тугач, диңгезчеләр бу җирне танымадылар, ләкин алар анда сөзәк ярлы ниндидер култык күрделәр һәм, булдырып булса, кораб белән шул яр буена килеп туктарга булдылар. [40] Якорьларны чабып өзделәр, корабның койрыгында урнашкан ишкәкләрне ычкындырдылар һәм алгы җилкәнне җил уңаена көйләделәр. Кораб ярга таба юл алды, [41] ләкин комга килеп

---

* 27:28 *Утыз җиде метр чамасы* – грек телендә егерме оргуя дип бирелгән. 1 оргуя – 1,8 метр чамасы. Егерме җиде метр чамасы – унбиш оргуя дип бирелгән.

утырды. Корабның борыны кузгатмаслык булып эләгеп калды, ә койрык өлеше дулкын көче белән җимерелә башлады.

[42] Гаскәриләр, тоткыннарның берәрсе йөзеп китеп качмасын дип, аларны үтерергә ният иттеләр. [43] Әмма йөзбашы, Паулны коткарып калу теләге белән, аларны туктатты һәм башта йөзә белүчеләргә суга сикерергә һәм ярга чыгарга кушты.

[44] – Калганнарыгыз я такталарга, я корабтагы берәр нәрсәгә тотынып йөзегез, – диде ул.

Шулай итеп барыбыз да котылып җиргә чыктык.

*Паул Мальта утравында*

**28** [1] Исән-имин ярга чыгып җиткәч, утрауның Мальта дип аталуын белдек. [2] Утрау кешеләре безгә гадәттән тыш кунакчыл булдылар. Яңгыр ява башлаганга һәм салкын булганга күрә учак яктылар һәм безнең барыбызны да учак янына чакырдылар. [3] Паул үзе җыеп алып килгән бер кочак чыбык-чабыкны учакка салгач, уттан атылып чыккан бер зәһәрле елан аның кулына ябышып калды. [4] Утрау кешеләре, аның кулында асылынып торган еланны күреп, бер-берсенә:

– Бу адәм – кеше үтерүче. Диңгездән котылса да, гаделлек алиһәсе аны исән калдырмады, – диештеләр.

[5] Әмма Паул еланны утка селкеп төшерде һәм аз гына да җәрәхәтләнмәде. [6] Кешеләр, ул шешенер, яки кинәт егылып үләр, дип көттеләр. Әмма озак көткәннән соң, аңа һичнинди зарар булмаганлыгын күреп, фикерләрен үзгәрттеләр:

– Ул – илаһ, – диделәр алар.

[7] Шул урыннан ерак түгел утрау башлыгы Поплиның хуҗалыгы урнашкан иде. Ул безне үз йортына чакырды һәм өч көн буе дусларча кунак итте. [8] Поплиның атасы бизгәк һәм корсак авыруы белән җәфаланып ята иде. Паул, аның янына кереп, дога кылды һәм, аның өстенә кулларын куеп, аны савыктырды. [9] Бу вакыйгадан соң утраудагы башка авырулар да Паул янына килделәр һәм савыктылар. [10] Утрауда яшәүче кешеләр безгә күп хөрмәт күрсәттеләр, ә китәргә җыенгач, кирәкле әйберләр белән тәэмин иттеләр.

*Паул Римга килә*

[11] Мальта утравында өч ай торганнан соң, шул утрауда кышлаган, күк игезәкләре* сурәте төшерелгән, Искәндәрия шәһәреннән булган бер корабка утырып, юлга чыктык. [12] Сиракүсай

---

* **28:11** *Күк игезәкләре* – греклар мифологиясендә диңгезчеләрне саклый торган ике илаһ бар дип уйлаганнар.

шәһәренә килеп җиткәч, анда өч көн булдык. [13] Аннан Ригиун шәһәренә килдек. Икенче көнне, көньяк җиле исә башлагач, Ригиуннан киттек һәм ике көндә Потиулуй шәһәренә килеп җиттек. [14] Ул шәһәрдә туганнарны очраттык, һәм алар бер атнага үзләре янында калуыбызны үтенделәр.

Шулай итеп без Римга килеп җиттек. [15] Андагы туганнар, безнең хакта ишетеп, Аппи мәйданы һәм Өч кунакханә шәһәрләре янына тикле җитеп, безне каршы алырга килгәннәр. Аларны күргәч, Паул Аллаһыга шөкрана кылды, аның күңеле күтәрелде. [16] Рим шәһәрендә Паулга сак астында аерым яшәргә рөхсәт ителде.

*Күренекле яһүдләр белән очрашу*

[17] Римга килеп өч көн торганнан соң Паул яһүдләрнең башлыкларын җыйды.

– Туганнар! Үз халкыбызга яки аталарыбызның йолаларына каршы һичбер нәрсә эшләмәсәм дә, мин Иерусалимда тоткын булдым һәм римлылар кулына тапшырылдым, – диде ул аларга. – [18] Алар миннән сорау алганнан соң, үлемгә хөкем итәрлек һичнинди гаебем булмаганга күрә азат итәргә теләгәннәр иде. [19] Әмма, яһүдләр моңа каршы килгәнлектән, мин кайсарга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдым, ләкин үз халкымны нәрсәдә дә булса гаепләү максаты белән түгел. [20] Шуңа күрә мин сезне очрашып сөйләшергә чакырдым. Чөнки минем шушы богауларым Исраил баглаган өмет өчен, – диде Паул.

[21] Ә алар аңа:

– Без Яһүдиядән синең хакта хатлар да алмадык, Яһүдиядән килгән туганнардан да беркем синең хакта бернәрсә хәбәр итмәде һәм начар сүзләр сөйләмәде. [22] Хәер, без синең фикерләреңне үзеңнән ишетергә теләр идек. Чөнки безгә билгеле булганча, һәркайда бу мәзһәбкә каршы сөйлиләр, – диделәр.

[23] Билгеләнгән көнне Паул яшәгән йортка элек килгәннән дә күбрәк кешеләр килде. Ул иртәдән кичкә тикле Аллаһы Патшалыгы хакында аңлатты, Гайсә турында Муса кануныннан һәм пәйгамбәрләр язмаларыннан дәлилләр китереп, аларны инандырырга тырышты. [24] Кайберләре аның сүзләренә инандылар, кайберләре исә ышанмадылар [25] һәм бер-берсе белән килешә алмыйча таралыштылар. Алар киткәнче Паул болай диде:

– Изге Рух сезнең аталарыгызга Ишагыйя пәйгамбәр аркылы менә нинди яхшы сүзләр әйткән:

[26] «Бу халык янына бар да әйт:
Тыңлап-тыңлап та, аңламассыз,
Карап-карап та, күрмәссез.

27 Чөнки бу халыкның йөрәген май баскан.
Көчкә генә ишетә колаклар,
Күзләрен дә алар йомганнар.
Әгәр шулай булмаса,
Күзләре белән күрерләр,
Колаклары белән ишетерләр иде.
Йөрәкләре белән аңларлар,
Миңа таба борылырлар
Һәм Мин аларны савыктырыр идем».
28 Шуңа күрә сезгә мәгълүм булсын: яһүд булмаган халыклар-
га Аллаһының коткаруы турындагы хәбәр җибәрелгән һәм аны
алар тыңларлар, – диде Паул.
[ 29 Ул шулай дигәннән соң, яһүдләр бик нык бәхәсләшә-бә-
хәсләшә таралыштылар.]*
30 Ә Паул үзе түләп торган йортта ике ел буе яшәде һәм яны-
на килүчеләрнең барысын да кабул итте. 31 Ул кыюлык белән
һәм каршылыкларга очрамыйча Аллаһы Патшалыгы турында
сөйләде һәм Раббы Гайсә Мәсих хакында өйрәтте.

* 28:29 Бу аять иң иске кулъязмаларда юк.

# ПАУЛДАН РИМЛЫЛАРГА ХАТ

*Паулның сәламе*

1 [1] Аллаһының Яхшы хәбәрен игълан итү өчен сайлап куел-
ган, Мәсих Гайсәнең рәсүл булырга чакырылган колы
Паулдан сәлам!
[2] Аллаһы Яхшы хәбәрне алдан, Үзенең пәйгамбәрләре аркы-
лы, Изге язмаларда вәгъдә иткән. [3-4] Бу Яхшы хәбәрдә Аның
Улы турында сөйләнелә. Ул чыгышы ягыннан Давыт нәселен-
нән булган, ә изгелек Рухы буенча, үледән терелтелү сәбәпле,
кодрәт белән Аллаһы Улы дип билгеләнгән. Ул – Раббыбыз
Гайсә Мәсих. [5] Аның аркылы һәм Аның исеме хакына без,
бар халыклар арасындагы кешеләрне Аллаһыга итагатькә
һәм иманга китерү өчен, мәрхәмәт һәм рәсүллек алдык. [6] Гай-
сә Мәсихнеке булырга чакырылган бу кешеләр арасында сез
дә бар.
[7] Аллаһының Рим шәһәрендә яшәүче барлык сөеклеләренә,
изгеләр булырга чакырылганнарга: Атабыз Аллаһыдан вә Раббы
Гайсә Мәсихтән мәрхәмәт һәм иминлек булсын.

*Паул Римга барырга тели*

[8] Иң элек Гайсә Мәсих аркылы һәммәгез өчен Аллаһыма
рәхмәтләр укыйм, чөнки иманыгыз хакында бөтен дөньяда
сөйләнелә. [9] Сезне бертуктаусыз искә алуыма Аллаһы шаһит,
Аның Улы хакындагы Яхшы хәбәрне белдереп, Аңа бөтен ру-
хым белән хезмәт итәм. [10] Аллаһы Үз ихтыяры белән, ниһаять,
яныгызга килергә мөмкинлек бирсен иде дип, догаларымда
һәрвакыт ялварам. [11-12] Чөнки сез ныгысын дип, сезгә нинди
дә булса рухи бүләк бирү өчен, ягъни уртак иманыбыз ниге-
зендә бер-беребезне дәртләндерү өчен сезне бик күрәсем килә.
[13] Имандашлар, сезнең белми калуыгызны теләмим: мин күп
тапкырлар яныгызга килергә ният иттем, ләкин әлегәчә тоткар-
лыкларга очрадым. Яһүд булмаган башка халыклар арасындагы
кебек, сездә дә уңыш җыя алуымны телим. [14] Мин греклар һәм
вәхшиләр, зирәкләр һәм наданнар алдында да бурычлымын.

[15] Шуңа күрә, мин сезгә, Римда яшәүчеләргә дә, Яхшы хәбәрне
белдерергә атлыгып торам.
[16] Чөнки Яхшы хәбәрдән оялмыйм, ул – һәр иман итүчегә,
башта яһүдкә, аннары яһүд булмаганга да, котылу өчен Алла-
һының кодрәте бит. [17] Чөнки Яхшы хәбәр Аллаһының кеше-
ләрне иман аша һәм бары тик иман аша гына хак* санавын**
ача. Изге язмада язылганча: «Аллаһы тарафыннан иман аша ак-
ланган кеше яшәячәк».

*Кешеләрнең гаеплелеге*

[18] Яманлык кылып хакыйкатьне танырга комачаулаучы кеше-
ләрнең һәртөрле имансызлыгына һәм яманлыгына күктән Ал-
лаһының ярсуы ачыла бара. [19] Чөнки Аллаһы хакында белергә
мөмкин булган һәрнәрсә алар өчен ачык, аларга аны Аллаһы
ачып бирде бит. [20] Галәм барлыкка китерелгәннән бирле Аның
күренмәгән сыйфатлары, ягъни Аның мәңгелек кодрәте һәм
илаһилыгы Ул булдырган нәрсәләр аша ачык күренә һәм аңла-
шыла. Шулай итеп, ул кешеләрнең акланырга дәлилләре юк.
[21] Алар, Аллаһыны белсәләр дә, Аллаһы итеп Аны тиешенчә
данламадылар һәм Аңа шөкер итмәделәр. Киресенчә, алар буш
уйларга бирелделәр, һәм аларның аңларга теләмәгән йөрәк-
ләрен караңгылык каплады. [22] Алар, үзләрен зирәккә санап,
тинтәкләнделәр [23] һәм үлемсез Аллаһының данын фани кеше-
ләргә, кошларга, дүрт аяклыларга һәм сөйрәлүчеләргә охшаган
сурәтләргә алыштырдылар.
[24] Шуның өчен Аллаһы аларны үзләренең азгын теләкләренә
һәм бозыклыклары карамагына тапшырды, алар үз тәннәрен
бер-берсе белән мәсхәрә итә башладылар. [25] Алар Аллаһы ха-
кыйкатен ялган белән алыштырдылар һәм Тудыручыга түгел,
бәлки тудырылганга табындылар һәм хезмәт иттеләр. Тудыру-
чыга исә мәңгегә дан булсын. Амин.
[26] Шул сәбәптән Аллаһы аларны хурлыклы нәфесләргә дучар
итте: аларның хатыннары табигый якынлык кылуны табигый
булмаган якынлык кылуга алыштырды. [27] Алар кебек үк, ир-
ләр дә, хатын-кыз белән табигый якынлык кылуны ташлап,
бер-берсенә карата хайвани теләк белән яндылар вә бер-берсе
белән рисвайлык кылдылар һәм үзләренең азгынлыклары өчен
тиешле җәза алдылар.
[28] Шулай итеп, Аллаһы турында белүне истә тотуны мөһим
дип исәпләмәгән өчен, Аллаһы аларны, эшләнергә тиешле

---

* 1:17 *Хак* – Аллаһы алдында дөрес, Аңа карата дөрес мөнәсәбәттә.
** 1:17 *Хак санавын* – ягъни «аклавын».

булмаган эшләрен кыла бирсеннәр өчен, бозык акылга дучар
итте. 29 Аларның күңелләре һәртөрле яманлык, мәкерлек, ком-
сызлык, явызлык белән тулган. Алар көнчелек, кеше үтерү,
ызгыш-талаш, алдау, яман ниятләр белән тулы. Алар – гайбәт-
челәр, 30 яла ягучылар, Аллаһыны нәфрәт итүчеләр, оятсызлар,
тәкәбберләр, мактанчыклар, явызлык тудыручылар, ата-анага
итагатьсезләр, 31 акылсызлар, үз сүзендә тормаучылар һәм
шәфкатьсезләр, мәрхәмәтсезләр. 32 Алар мондый нәрсәләрне
эшләүчеләрнең Аллаһының гадел хөкеме буенча үлемгә лаек
булулары турында беләләр; әмма мондый эшләрне эшләп кенә
калмыйлар, бәлки андый эшләр кылучыларны хуплыйлар да.

*Аллаһының гадел хөкеме*

**2** 1 Әй, син, башкаларны хөкем итүче адәм, үзеңне аклап
һичнәрсә әйтә алмыйсың; чөнки башкаларның эшләрен
хөкем итүең белән үзеңне дә хөкем итәсең, син үзең дә
шул ук эшләрне эшлисең бит. 2 Без исә беләбез: андый эш эш-
ләүчеләр өчен Аллаһының хөкеме гадел. 3 Әй, син, адәм, андый
гамәл кылучыларны хөкем итәсең, ә үзең шул ук эшләрне эш-
лисең! Әллә син Аллаһы хөкеменнән качып котылырмын дип
уйлыйсыңмы? 4 Яки, Аллаһының игелеге сине тәүбәгә китерә-
чәген аңламыйча, Аның зур игелеген, сабырлыгын һәм түземле-
ген санга сукмыйсыңмы? 5 Ләкин кирелегең һәм тәүбә итәргә
теләмәгән йөрәгең аркасында син Аллаһының гадел хөкеме
ачылачак ачу көненә җәзаңны арттырасың. 6 Аллаһы һәркемгә
аның эшләренә карап түләр: 7 сабырлык белән игелекле эшләр
кылып данга, хөрмәткә һәм үлемсезлеккә омтылучыларга Ул
мәңгелек тормыш бирә. 8 Ә инде үзен генә яратып, хакыйкать-
кә буйсынмыйча, явызлык артыннан баручылар өстенә Аллаһы
Үз ачуын һәм ярсуын төшерәчәк. 9 Явызлык кылучы һәркемгә –
башта яһүдкә, аннары яһүд булмаганга – михнәт һәм газап бу-
лачак. 10 Ә игелек кылучы һәркемгә – башта яһүдкә, аннары
яһүд булмаганга – дан, хөрмәт һәм иминлек булачак. 11 Чөнки
Аллаһы һәркемгә бертигез карый.

12 Кануны булмаган хәлдә гөнаһ кылганнар шул хәлдә һәлак
булачаклар да; ә инде канунны белә торып гөнаһ кылганнар ка-
нун буенча хөкем ителәчәкләр. 13 Чөнки канунны ишетүчеләр
түгел, бәлки канунны үтәүчеләр Аллаһы каршында акланган
дип игълан ителәчәк. 14 Мәҗүсиләрнең кануны юк, ләкин
алар, табигый тойгылары белән канун буенча эшләгән вакытта,
кануннары булмаса да, үзләренә үзләре канун. 15 Бу исә алар-
ның йөрәкләренә канун таләпләре язылганлыгын күрсәтә;
моны аларның вөҗданы да раслый, чөнки аларның уй-фикере

кайвакыт аларны гаепли, ә кайвакыт хәтта яклый да. [16] Мин
сөйләгән Яхшы хәбәр буенча, кешеләрнең серләрен Гайсә Мә-
сих аркылы Аллаһы хөкем итәчәк көндә әнә шулай булачак.

*Яһүдләр һәм Аллаһы кануны*

[17] Менә син үзеңне яһүд дип атыйсың, Муса канунына тая-
насың һәм Аллаһы белән мактанасың, [18] канунннан өйрәнеп,
Аллаһының ихтыярын һәм яманнан яхшыны аера беләсең.
[19] Сукырларның юл күрсәтүчесе, караңгылыктагылар өчен як-
тылык, [20] наданнарның остазы, тәҗрибәсезләрнең укытучысы
син үзең булуына ышанасың һәм, канун белем вә хакыйкатьне
гәүдәләндерә, дип саныйсың. [21] Шулай булгач, ничек соң син,
башкаларны өйрәтеп тә, үзеңне-үзең өйрәтмисең? Урламаска
үгетлисең, ә үзең урлыйсыңмы? [22] «Зина кылма» дисең, ә үзең
зина кыласыңмы? Потлардан җирәнәсең, ә үзең аларның табы-
ну урынын талыйсыңмы? [23] Аллаһы кануны белән мактанасың,
ә үзең, аны бозып, Аллаһыны мәсхәрәлисеңме? [24] Изге язмада
язылганча, «мәҗүсиләр Аллаһы исемен сезнең аркада мәсхә-
рәлиләр».

[25] Канунны үтәсәң, сөннәтле булуың файдалы; ә инде син
аны бозасың икән, ул чакта сөннәткә утыртылмаган кебек бу-
ласың. [26] Шулай булгач, сөннәтсез кеше канун кагыйдәләрен
үтәсә, ул сөннәткә утыртылган булып саналмасмы? [27] Тышкы
яктан сөннәтсез булган, әмма канунны үтәүче кеше, син языл-
ган канунга һәм сөннәтлелеккә ия булсаң да, сине канунны
бозганың өчен хөкем итәр. [28] Чөнки тышкы яктан гына яһүд
булган – чын яһүд түгел, һәм тәндә генә булган сөннәтләнү
чын сөннәт түгел. [29] Әмма эчке яктан яһүд булган гына чын
яһүдтер; һәм язылган канун түгел, бәлки, Рух китергән, йөрәк
түрендә булган сөннәт кенә чын сөннәттер. Мондый кешегә
мактау кешеләрдән түгел, бәлки Аллаһыдан килә.

**3** [1] Шулай итеп, яһүд булуның өстенлеге яки сөннәтле бу-
луның файдасы бармы? [2] Һәрьяктан зур өстенлек бар! Ал-
лаһы сүзе иң элек нәкъ аларга әманәт ителгән. [3] Шулай
булгач, кайберәүләр Аллаһыга тугрылыклы булмаган икән, ни
булыр? Аларның тугры булмаулары Аллаһының тугрылыклы-
гын юкка чыгарырмы? [4] Һич тә алай түгел! Һәр кеше ялганчы
булса да, Аллаһы хак, Үз сүзенә турылыклы. Шуңа күрә, Аның
турында Изге язмада язылганча:

«Синең сүзләрең хак дип танылыр,
һәм хөкем ителгәндә җиңәрсең».

[5] Әгәр безнең гаделсезлегебез Аллаһының хаклыгын ачыграк
күрсәтә икән, Аллаһы өстебезгә ачуын яудырып дөрес эшләмәде,

дип әйтә алабызмы? (Мин биредә кешеләрчә фикер йөртәм).
[6] Һич тә! Юкса Аллаһы дөньяны ничек хөкем итә алыр иде?
[7] Әмма минем ялганым аркылы Аллаһының хакыйкате ачыграк
күренгәнгә Аның даны һаман арта икән, ни өчен соң әле мин
гөнаһлы дип хөкем ителәм? [8] Ни өчен соң: «Әйдәгез, яхшылык
килсен дип, яманлык кылыйк!» — дип әйтмәскә? Кайберәүләр,
безне яманлап, имеш, без шулай әйтәбез, дип сөйлиләр. Алар
үзләренә тиешле хөкемне алырлар.

*Бер тәкъва кеше дә юк*

[9] Шулай итеп нәрсә? Безнең хәлебез яһүд булмаганныкылар-
дан яхшыракмы? Һич тә юк; чөнки без инде ачык күрсәттек:
яһүдләр дә, яһүд булмаганнар да — барысы да гөнаһ хакимлеге
астында. [10] Изге язмада язылганча:

«Бер тәкъва кеше дә юк, бер генә дә.
[11] Акылга ия булучы беркем дә юк, Аллаһыны эзләми беркем дә.
[12] Барысы да Аллаһыдан читләштеләр һәм Аңа яраксыз булдылар;
яхшылык эшләүче юк, берәү дә юк.
[13] Аларның бугазлары — ачык кабер,
иреннәрендә елан агуы, телләре белән алдыйлар,
[14] аларның авызы ләгънәт һәм әрнү белән тулы.
[15] Аларның аяклары кан түгү өчен җитез,
[16] алар булып узган җирдә бары җимерек һәм һәлакәт кенә кала.
[17] Алар иминлек юлын белмиләр.
[18] Аллаһыны хөрмәт итү турында уйлап та карамыйлар».

[19] Ә без беләбез: үзен акларга дип авызын да ачмасын өчен
һәм бар дөнья Аллаһы каршында гаепле булсын өчен, канун
нәрсә дә булса сөйли икән, ул канун хакимлеге астында бул-
ганнарга сөйли, [20] канун таләпләрен үтәү белән Аның кар-
шында беркем дә акланган булмас бит. Дөресрәге, без канун
аркылы гөнаһның нәрсә икәненә төшенәбез.

*Иман аша аклану*

[21] Әмма хәзер Аллаһының кешене Муса кануныннан бәйсез
рәвештә хак санавы* күренде. Бу турыда канун һәм пәйгамбәр-
ләр шаһитлек итә. [22] Аллаһы Гайсә Мәсихкә иман итү аша бар-
лык ышанучыларны хак саный. Кеше белән кеше арасында
аерма юк, [23] чөнки барысы да гөнаһ кылдылар һәм Аллаһының

---

* 3:21 *Хак санавы* — ягъни «аклавы».

данынnан мәхрүм калдылар. 24 Ә алар Аның мәрхәмәте белән,
үзләрен йолып алучы Мәсих Гайсә аша, Аллаһы тарафыннан
түләүсез акланалар. 25 Аллаһы Гайсәне, Аның үлеме аша Гайсә-
гә иман итүчеләрнең гөнаһлары кичерелсен өчен, Аллаһы бе-
лән татулаштыручы, кичерү алып килүче корбан итеп билгеләп
куйды. Шулай эшләп, элек кылынган гөнаһлар өчен җәза бир-
мичә, Ул, зур сабырлык күрсәтеп, Үзенең хаклыгын раслады.
26 Ул шулай итеп хаклыгын хәзер дә күрсәтә: Ул Үзе хак һәм
Гайсәгә иман итүчеләрне аклый.

27 Без хәзер нәрсә белән мактана алабыз? Бер нәрсә белән дә
мактана алмыйбыз. Нинди кагыйдә белән? Канун таләпләрен
үтәү беләнме? Юк, иманыбыз булу белән. 28 Чөнки без раслый-
быз: кеше, канун таләпләрен үтәүдән тыш, иман белән Аллаһы
тарафыннан аклана. 29 Аллаһы – яһүдләр Аллаһысы гынамы,
башка халыклар Аллаһысы да түгелмени? Әлбәттә, башка ха-
лыклар Аллаһысы да, 30 чөнки Аллаһы бер, Ул яһүдләрне иман
белән һәм яһүд булмаганнарны иман аша аклый. 31 Шулай итеп,
без иман итү белән канунны юкка чыгарабызмы? Һич тә алай
түгел, киресенчә, без аны раслыйбыз.

*Ибраһим үрнәге*

4 1 Халкыбызның нәсел башлыгы Ибраһим хакында нәрсә
әйтә алабыз? Ул нәрсәгә ия булды соң? 2 Әгәр Ибраһим
үз гамәлләре белән акланган дип саналган икән, аның
мактанырга хакы булган, әмма Аллаһы каршында түгел. 3 Чөн-
ки Изге язмада нәрсә диелгән? «Ибраһим Аллаһыга ышанды,
һәм моның белән хак саналды».

4 Эшчегә түләнгән хезмәт хакы бүләк дип түгел, бәлки бире-
лергә тиешле нәрсә булып санала. 5 Әгәр кеше үзенең эш-га-
мәлләренә таянмыйча, гаеплеләрне аклаучы Аллаһыга ышана
икән, ышануы белән ул хак санала. 6 Шулай ук Давыт та, Алла-
һы, эш-гамәлләренә карамастан, хак исәпләгән кешенең сәга-
дәтлеге турында сөйләгәндә, болай ди:

7 «Явыз эшләре кичерелгән, гөнаһлары бетерелгән
кешеләр сәгадәтле.
8 Раббы тарафыннан гөнаһлары исәпкә алынмаган кеше
сәгадәтле».

9 Бу сәгадәтлелек сөннәтлеләргә генәме, әллә сөннәтсезләр-
гә дә кагыламы? Без: «Ибраһим үзенең ышануы белән хак са-
налды», – дип әйттек. 10 Кайчан саналды? Сөннәтле булгачмы,
әллә сөннәтле булганчымы? Сөннәтле булгач түгел, бәлки сөн-
нәтле булганга кадәр. 11 Әле сөннәтсез чакта, ышануы белән ул
хак саналды. Аның сөннәткә утыртылуы моны раслаучы билге

булды. Шулай итеп, Ибраһим, сөннәтләнмәгән булсалар да,
барлык иман итүче, хак саналучы кешеләрнең рухи атасы бул-
ды. 12 Ибраһим – шулай ук сөннәтлеләрнең дә атасы, ягъни,
сөннәткә утыртылып кына калмыйча, атабыз Ибраһимның әле
сөннәтләнмәгән чакта йөргән иман сукмакларыннан йөрүче-
ләрнең атасы.

*Аллаһының вәгъдәсе һәм иман*

13 Аллаһының, дөнья синеке булыр, дигән вәгъдәсе Ибра-
һимга һәм аның токымына канун таләпләрен үтәгән өчен тү-
гел, бәлки иман итеп, хак исәпләнгәнгә күрә бирелде. 14 Чөн-
ки, канунны тотуга таянучылар Аллаһы вәгъдә иткәнне алалар
икән, ул чакта иманның мәгънәсе юк, вәгъдә дә юкка чыгары-
ла. 15 Канун Аллаһының ачуын китерә, әмма канун булмаса,
канун бозу да булмый.
16-17 Аллаһының вәгъдәсе, мәрхәмәт буенча гына булсын өчен,
иманга нигезләнгән. Шулай итеп, вәгъдә Ибраһим токымының
һәммәсе өчен дә: канунны тотучылар өчен генә түгел, бәлки
аның кебек иман итүчеләр өчен дә ышанычлы. Чөнки, Изге яз-
мада «Мин сине күп халыкларның атасы итеп куйдым» дип
язылганча, Ибраһим – безнең һәммәбезгә ата. Үлеләрне терел-
түче, булмаган нәрсәләрне барлыкка китерүче Аллаһыга ышан-
ган Ибраһим – Аның каршында безнең барыбыз өчен дә ата.
18 Ул бернинди өмете булмаган вакытта да өмет белән ышанды
һәм, «Синең токымың шулкадәр күп санлы булачак», – дип әй-
телгән сүзләр буенча, күп халыкларның атасы булды. 19 Ул, йөз
яшьтә диярлек булса да, тәненең инде үлеп барган булуы һәм
Сара карынының бала тудырырга сәләтсез булуы хакында уй-
ланганда, иманда зәгыйфьләнмәде. 20 Аллаһы вәгъдә иткәнгә
ышанмыйча, аңа шикләнеп карамады, бәлки, иманда ныгып,
Аллаһыны данлады. 21 Аллаһының вәгъдә иткәнен үти алачагына
инанып, 22 Ибраһим үзенең ышануы белән «хак саналды». 23 Хә-
ер, «ул хак саналды» дигән сүз бер аның өчен генә түгел, 24 бәлки
безнең өчен дә язылды. Раббыбыз Гайсәне үледән терелткән
Аллаһыга иман итүчеләр булган безне дә Аллаһы хак санар.
25 Гайсә безнең гөнаһларыбыз өчен үлемгә тапшырылды һәм,
без Аллаһы тарафыннан аклану алсын өчен, үледән терелтелде.

*Аклауның нәтиҗәсе*

5 1 Шуңа күрә, без иман белән акланган, дип игълан ителеп,
Раббыбыз Гайсә Мәсих аша Аллаһы белән безнең арада та-
тулык мөнәсәбәте урнаша. 2 Мәсих безгә мәрхәмәткә ире-
шергә мөмкинлек бирде. Иманыбыз аша бу мәрхәмәттә торабыз.

Шуның өчен, үзебез Аллаһы данын уртаклашырбыз, дигән өмет
белән куанабыз. [3] Моңа гына түгел, бәлки михнәт чигүгә дә
шатланабыз. Чөнки беләбез: михнәт түземлек тудыра, [4] түзем-
лектән тотрыклылык, тотрыклылыктан өмет хасил була. [5] Ә өмет
алдамый, чөнки Аллаһы Үзенең мәхәббәтен безгә бирелгән Из-
ге Рух аша йөрәкләребезгә мул итеп яудырган.

[6] Без әле ярдәмгә мохтаҗ вакытта, Аллаһы билгеләгән бер
заманда, Мәсих имансызлар өчен үлде. [7] Кем дә булса тәкъва
кеше өчен үләргә теләр микән? Хәер, игелек күрсәтүче кеше
өчен, бәлки, кемнең дә булса үләргә җөрьәт итүе дә мөмкин.
[8] Әмма Аллаһы безгә булган мәхәббәтен шуның белән исбат
итә: Мәсих без әле гөнаһлылар булган чакта ук безнең өчен үл-
де. [9] Шуңа күрә, хәзер, Аның түгелгән каны белән акланган дип
игълан ителгәнгә, Аның аркылы Аллаһының ачуыннан без та-
гын да ныграк котылачакбыз. [10] Чөнки без Аллаһыга дошман
булган вакытта, Улының үлеме аркылы Аллаһы белән татулан-
ганбыз икән, бигрәк тә хәзер, татулангач, Аның тормышы бе-
лән котылачакбыз. [11] Һәм әле бу гына да түгел, бәлки Раббыбыз
Гайсә Мәсих аркылы Аллаһы өчен шатланабыз, Аның белән
безне Мәсих дуслаштырды бит.

*Кеше һәм Мәсих*

[12] Бер кеше аркылы гөнаһ һәм гөнаһ белән бергә үлем дөнья-
га үтеп керде. Шулай итеп, үлем барлык кешеләргә таралды,
чөнки барлык кешеләр гөнаһ кылдылар. [13] Инде канунга кадәр
дә дөньяда гөнаһ бар иде; әмма канун булмаганда берәүнең дә
гөнаһы исәпкә алынмый. [14] Әмма ләкин Адәмнән алып Муса
пәйгамбәргә кадәр, барысы өстеннән, Адәмнең гөнаһы кебек
гөнаһ кылмаганнар өстеннән дә, үлем хакимлек иткән. Адәм
исә, кайсыдыр ягы белән, киләчәк Зат кебек булган.

[15] Әмма Аллаһының мәрхәмәт бүләген гөнаһ белән чагышты-
рып булмый. Чөнки берәүнең гөнаһы күпләрне үлемгә дучар
итә икән, Аллаһының мәрхәмәте дә, бер Кешенең – Гайсә
Мәсихнең мәрхәмәте белән бирелгән бүләк тә күпләр өчен
чагыштыргысыз дәрәҗәдә зур була. [16] Аллаһының бүләген бер
кешенең гөнаһы белән чагыштырып булмый; бер гөнаһ нәти-
җәсендә гаепле дигән хөкем карары чыгарылды, ә күп гөнаһ-
лардан соң Аллаһы кешеләргә, «сез гаепсез» дип, Үзенең
мәрхәмәтен күрсәтә. [17] Чөнки бер кешенең гөнаһы аркасында
шул кеше аркылы үлем хакимлек итә икән, Аллаһының мул
мәрхәмәтен һәм Аның алдында хак булу бүләген кабул иткән-
нәр исә бер Зат – Гайсә Мәсих аркылы тормышта бигрәк тә
хакимлек итәчәк.

[18] Шулай булгач, бер гөнаһ барлык кешеләргә хөкем китер-
гән кебек, бер хак эш барлык кешеләргә аклану һәм тормыш
китерә. [19] Чөнки, бер кешенең итагатьсезлеге аркасында күп-
ләр гөнаһлы ителгән кебек, бер Кешенең итагать итүе арка-
сында күпләр акландырылачак. [20] Җинаятьнең авырлыгын
көчәйтү өчен Муса кануны кертелгән булган. Гөнаһ күбәйгән
җирдә Аллаһының мәрхәмәте тагын да арткан. [21] Шулай итеп,
кешеләрне үлемгә китереп, алар өстеннән гөнаһ хакимлек
иткән кебек, Аллаһының мәрхәмәте дә хаклык белән хаким-
лек итәр һәм Раббыбыз Гайсә Мәсих аркылы мәңгелек тор-
мышка илтер.

*Без гөнаһка карата үле*

6 [1] Нәрсә әйтик соң? Аллаһының мәрхәмәте артсын дип,
гөнаһ кылуны дәвам итәргәме? [2] Һичбер вакытта да! Без
гөнаһка карата үле: шулай булгач, ничек гөнаһ кылуны дә-
вам итә алабыз? [3] Суга чумдырылу йоласын үтәп, Мәсих Гайсә-
гә чумдырылган һәммәбезнең дә Аның үлеменә чумдырылуы
турында беләсездер. [4] Шулай итеп, Атаның бөек кодрәте белән
Мәсих үледән терелтелгән кебек, яңа тормыш белән яшәү өчен,
чумдырылу йоласы аша без Аның үлемен уртаклаштык һәм
Аның белән бергә күмелдек. [5] Мәсих белән бертөрле үлемдә
берләшкәнбез икән, үледән терелүдә дә Аның белән берләш-
кән булачакбыз.

[6] Без беләбез: без гөнаһ коллары булудан туктасын дип,
гөнаһлы асылыбызның хакимлеге юкка чыгарылсын өчен,
элекке кеше Аның белән бергә хачка кадакланды. [7] Үлгән ке-
ше инде гөнаһ хакимлегеннән азат ителде. [8] Мәсих белән бер-
гә үлгәнбез икән, Аның белән бергә яшәрбез дә, дип ышана-
быз. [9] Чөнки беләбез: үледән терелтелгәч, Мәсих кабат үлми;
инде үлем Аның өстеннән хакимлек итми. [10] Ул бер тапкыр
үлде, һәм гөнаһка карата бөтенләйгә үлде. Ә Аның гомер ки-
черүе – Аллаһы өчен яшәү. [11] Шулай ук сез дә үзегезне гөнаһ-
ка карата үле, әмма Мәсих Гайсә аша Аллаһы өчен тере дип
исәпләгез.

[12] Шуңа күрә, фани тәнегез өстеннән гөнаһ хакимлек ит-
мәсен, шул вакытта сез тәнегез нәфесләренә буйсынмассыз.
[13] Тәнегездәге кайсы да булса өлешнең явызлык коралы булып,
гөнаһка хезмәт итүенә юл куймагыз, киресенчә, үлемнән тор-
мышка күчерелгәннәр буларак, үзегезне Аллаһыга һәм әгъза-
ларыгызны тәкъвалык коралы итеп Аңа тапшырыгыз. [14] Гөнаһ
сезнең өстән хакимлек итми, чөнки сез канун астында түгел,
бәлки Аллаһының мәрхәмәте астында яшисез.

### *Гөнаһтан азат булу*

15 Инде нишлик? Канун астында түгел, бәлки Аллаһының
мәрхәмәте астында булганга күрә, безгә гөнаһ кылыргамы? Бер
вакытта да! 16 Сез моны беләсездер: үзегезне итагатьле кол итеп
кемгә тапшырсагыз, шуның коллары булырсыз: гөнаһ коллары
булсагыз, бу сезне үлемгә китерер; Аллаһыны тыңлаучанлык-
ның коллары булсагыз, бу сезне Аллаһы алдында хак саналуга
алып килер. 17 Аллаһыга шөкер, элек гөнаһ коллары булсагыз
да, хәзер үзегез кабул иткән тәгълимат төренә чын күңелдән
итагать иттегез. 18 Гөнаһтан азат ителгәч, тәкъвалык коллары
булдыгыз. 19 (Сезнең табигый көчсезлегегез сәбәпле, кешеләр
фикер йөрткәнчә сөйлим.) Элек тәннәрегезне явыз эшләргә
китерүче бозыклыкка һәм явызлыкка кол итеп тапшырганыгыз
кебек, хәзер аларны, изге тормыш итү өчен, тәкъвалыкка кол
итеп тапшырыгыз.
20 Сез, гөнаһ коллары булган вакытта, тәкъвалык гамәлләренә карата азат идегез. 21 Элек кылган яман эшләрегездән
сез нинди файда алдыгыз? Ул чакта алган нәрсәләрдән хәзер
сез оялясыз, чөнки аларның ахыры – үлем. 22 Ләкин хәзер,
гөнаһтан азат ителгәнлектән, Аллаһының коллары булгач,
изгелеккә илтүче уңышка ия буласыз, нәтиҗәдә мәңгелек тормыш алырсыз. 23 Чөнки гөнаһ өчен әҗер – үлем, ә инде Аллаһының мәрхәмәт бүләге – Раббыбыз Мәсих Гайсәдә мәңгелек
тормыш.

### *Кануннан азат булу*

7 1 Имандашлар, сез канунны белгәнлектән, хәзер әйтәсе
сүзләремне сез белергә тиеш: кеше исән вакытта гына
аның өстеннән канун хакимлек итә. 2 Мәсәлән, кияүдәге
хатын ире исән чакта канун буенча ире белән бәйләнгән; ә ире
үлсә, хатын үзен иренә бәйләп торучы кануннан азат ителә.
3 Шуңа күрә, ире исән чакта, башка ир-атныкы булса, зина кылучы дип аталачак; ә инде ире үлсә, хатын бу кануннан азат
ителә һәм башка берәүгә кияүгә чыкса да зина кылучы булмый.
4 Менә шулай сез дә, имандашларым, Аллаһыга хезмәт итүдә
файдалы булыйк дип, башка Берәүнеке, ягъни үледән терелтелгән Мәсихнеке булу өчен, Аның тәне аркылы Муса канунына карата үлдегез. 5 Чөнки кешелек табигатебез йогынтысы
астында булган чакта, канун уяткан гөнаһлы нәфесләр безнең
әгъзаларыбызда эш иттеләр, һәм без кылган һәммә нәрсәнең
нәтиҗәсе үлем булды. 6 Әмма хәзер, элек безне бәйләп торган

канунга карата үлгәч, бу кануннан азат булдык һәм хәзер Аллаһыга искечә – язылган канун буенча түгел, бәлки яңача – Рух буенча хезмәт итәбез.

*Аллаһы кануны һәм гөнаһ*

7 Инде нәрсә әйтик? Әллә канун гөнаһмы? Һич тә юк! Әмма
мин гөнаһны канун аркылы гына белдем. Әгәр канун: «Башка
кешенекенә нәфесеңне сузма», – димәсә, мин нәфесләнүнең
нәрсә икәнен аңламаган булыр идем. 8 Әмма гөнаһ, бу әмердән
файдаланып, миндә һәртөрле нәфес теләкләре уятты. Кануннан
башка, гөнаһ үле. 9 Кайчандыр мин кануннан башка яши идем;
әмма Аллаһы тарафыннан әмер бирелгәч, гөнаһ терелде, 10 һәм
мин үлдем. Шулай итеп, яшәү китерергә тиешле әмер чынлык-
та исә үлем китерде. 11 Чөнки, әмерне сылтау итеп, гөнаһ мине
алдады һәм шуның белән әмер ярдәмендә мине үтерде. 12 Шу-
лай булгач, канун – изге; әмер дә изге, гадел һәм яхшы.
13 Шулай итеп, яхшы нәрсә миңа үлем китердемени? Һич тә
алай түгел! Әмма гөнаһ, гөнаһ булып танылсын өчен, яхшы
нәрсә аркылы миңа үлем китерде. Һәм гөнаһ әмер аркылы чик-
тән тыш гөнаһлы булды.

*Гөнаһ белән көрәшү*

14 Без беләбез, канун – рухи; ә мин – дөньяви, гөнаһка кол
итеп сатылганмын. 15 Хәтта нәрсә эшләвемне дә аңламыйм;
чөнки теләгәнемне түгел, бәлки нәфрәт иткәнемне эшлим. 16 Ә
инде үзем теләмәгәнне эшлим икән, канун яхшы дип, аның бе-
лән килешәм. 17 Шулай булгач, инде моны үзем түгел, бәлки
миндә яши торган гөнаһ эшли. 18 Чөнки беләм: миндә, ягъни
кешелек табигатемдә, һичнинди яхшы нәрсә юк; хәер, миндә
яхшылык кылу теләге бар, әмма аны тормышка ашыра ал-
мыйм. 19 Эшләргә теләгән яхшылыкны түгел, бәлки теләмәгән
явызлыкны эшлим мин. 20 Теләмәгән нәрсәне эшлим икән, ин-
де аны мин түгел, бәлки миндә яшәүче гөнаһ эшли.
21 Шулай итеп, моннан шундый кагыйдә табам: мин яхшы-
лык эшләргә телим, ләкин яманлыктан арына алмыйм. 22 Эчем-
нән Аллаһы канунына шатланам, 23 әмма үз тәнемдә башка бер
канунның эш итүен күрәм. Бу канун акылым хуплаган канунга
каршы көрәшә һәм мине үземдә эш итүче гөнаһ канунына буй-
сындыра. 24 Мескен кеше мин! Үлем китерүче бу тәннән мине
кем коткарыр? 25 Мине Раббыбыз Гайсә Мәсих аркылы котка-
ручы Аллаһыга шөкер! Менә мин акылым белән Аллаһы кану-
нына, ә кешелек табигатем белән гөнаһ канунына хезмәт итәм.

*Рух буенча яшәү*

8 [1] Шулай итеп, Мәсих Гайсәдә яшәүчеләргә хәзер һичнин-
ди хөкем юк, [2] чөнки тормыш бирүче Рухның кануны
Мәсих Гайсә аркылы сине* гөнаһ вә үлем канунынннан
азат итте. [3] Кешелек табигате көчсез булганга, канун башкара
алмаганны Аллаһы Үзе башкарды. Гөнаһлы кешегә охшашлы
рәвештә, Ул Үзенең Улын гөнаһ өчен корбан итәргә җибәреп,
кешедә гөнаһны хөкем итте. [4] Аллаһы моны канунның гадел
таләпләре бездә, кешелек табигатебез буенча түгел, бәлки Рух
буенча яшәүчеләрдә, гамәлгә ашсын өчен эшләде.
[5] Чөнки кешелек табигате буенча яшәүчеләр шул табигать
теләге буенча гына фикер йөртәләр, ә Рух буенча яшәүчеләр –
Изге Рух теләгәнчә фикер йөртәләр. [6] Кешелек табигате буенча
уйлау – үлемгә, ә Рух буенча уйлау – тормышка һәм иминлек-
кә китерә. [7] Чөнки кешелек табигате буенча фикер йөрткән
кеше – Аллаһыга дошман; ул Аллаһы канунына буйсынмый
һәм буйсына да алмый. [8] Кешелек табигате буенча яшәүчеләр
Аллаһыга ярый алмыйлар.
[9] Әмма ләкин сездә Аллаһы Рухы яши икән, сез кешелек таби-
гате буенча түгел, бәлки Рух буенча яши торган буласыз. Инде
берәүдә Мәсих Рухы юк икән, димәк, ул Аныкы түгел. [10] Ә инде
Мәсих сездә икән, сезнең тәнегез гөнаһ аркасында үле, әмма,
Аллаһы сезне хак санаганга күрә, Изге Рух сезнең өчен тормыш
була. [11] Әгәр Гайсәне үледән терелткән Аллаһының Рухы сездә
яши икән, ул чакта Мәсихне үледән терелткән Аллаһы, сездә
яшәүче Рухы белән, фани тәнегезгә дә тормыш бирәчәк.
[12] Шулай булгач, имандашлар, без бурычлы, ләкин без ке-
шелек табигатенә, аның буенча яшәү өчен бурычлы түгел.
[13] Кешелек табигате буенча яшәсәгез, сез үләчәксез; ә инде гө-
наһлы эшләрегезне Изге Рух көче белән үтерәсез икән, сез
яшәячәксез. [14] Аллаһы Рухы йөрткән кешеләрнең һәммәсе дә –
Аллаһы балалары. [15] Чөнки сез, коллыкка төшереп, сезне кабат
куркынып яшәүгә китерүче рухны түгел, бәлки үзегезне Ал-
лаһы балалары итүче Рухны кабул иттегез. Һәм Аның белән:
«Абба, Әти», – дип Аллаһыга мөрәҗәгать итәбез. [16] Изге Рух
Үзе, рухыбыз белән бергә, безнең Аллаһы балалары булуы-
бызны раслый. [17] Әгәр Аның балалары икәнбез, варислары да –
без, димәк, Мәсих белән бергә Аллаһы вәгъдә иткәннәргә ия
булабыз. Чөнки без Мәсих белән бергә михнәт чигәбез икән,
Аның данын да уртаклашырбыз.

---

* 8:2 *Сине* – кайбер борынгы кулъязмаларда «мине».

### *Булачак дан*

[18] Мин болай уйлыйм: хәзерге вакытлы газаплар, безнең өчен
килеп, ачык күренәчәк дан белән чагыштырганда, бернәрсәгә
тормыйлар. [19] Аллаһы тарафыннан барлыкка китерелгәннәрнең
барысы да Аңардан Үз балаларын ачыктан-ачык күрсәтүне
түземсезлек белән өметләнеп көтә, [20] чөнки Аллаһы бар иткән-
нәрнең һәммәсе ыгы-зыгыга буйсындырылды. Бу аларның их-
тыяры буенча түгел, бәлки Буйсындыручының ихтыяры буенча
эшләнде. [21] Аллаһы тарафыннан яратылганнарның бөтенесе
фанилыкка илтүче коллыктан азат ителеп, Аллаһы балалары-
ның данлы азатлыгын уртаклашачак дигән өмет булганга бу
шулай эшләнде.

[22] Чөнки без беләбез: Аллаһы тарафыннан яратылганнарның
һәммәсе хәзергә кадәр сыкрана һәм бала тудыргандагы газап-
ларны кичерә. [23] Һәм алар гына түгел, Аллаһы бүләкләренең
беренчесе булган Изге Рухка ия булып, Аллаһының безне Үз
балалары итүен, тәнебезнең азат ителүен көтеп, без дә эчебез-
дән сыкранабыз. [24] Чөнки без бу өмет белән котылдык. Әмма
өмет иткән нәрсәне күрсәк, ул инде өмет түгел; чөнки үзе
күргән нәрсәне кем өмет итә соң? [25] Ә инде үзебез күрмәгән
нәрсәгә өметләнәбез икән, ул чакта моны сабырлык белән
көтәбез.

[26] Шулай ук Рух та зәгыйфьлегебездә безгә ярдәм күрсәтә;
чөнки без ничек дога кылырга кирәк икәнен белмибез, әмма
Рух Үзе сүз белән әйтеп булмаслык көрсенүләр белән безнең
өчен Аллаһыга ялвара. [27] Йөрәкләрне карап белүче Аллаһы исә
Рухның фикерен белә, чөнки Изге Рух, Аллаһы ихтыяры буен-
ча, изгеләр өчен Аңа ялвара.

[28] Белгәнебезчә, Аллаһыны сөючеләргә, Аның нияте буенча
чакырылганнарга яхшылык булсын өчен һәрнәрсә ярдәм итә.*
[29] Чөнки, Аллаһы Улы күп санлы туганнары арасында беренче
туган Угыл булсын өчен, Аллаһы алдан кемнәрне сайлаган бул-
са, шуларны ук Үз Улына охшаш булырга алдан билгеләде дә.
[30] Ә кемнәрне алдан билгеләгән булса, Ул шуларны чакырды;
кемнәрне чакырган булса, шуларны aклады; һәм кемнәрне
аклаган булса, шуларга Үзенең бөеклеген уртаклашырга мөм-
кинлек бирде.

---

* 8:28 Бу аятьне грек теленнән болай да аңларга мөмкин: «Белгә-
небезчә, Аллаһы Үзен яратучыларга, Аның нияте буенча чакы-
рылганнарга яхшылык булсын өчен, һәрнәрсәдә алар белән бергә
эш итә».

*Аллаһының Мәсих Гайсә аша күрсәткән мәхәббәте*

[31] Моңа нәрсә әйтергә соң? Аллаһы безнең яклы икән, кем
безгә каршы була ала соң? [32] Үзенең Улын кызганмыйча, Аны
безнең һәммәбез өчен биргән Аллаһы, Аның белән бергә
һәрнәрсәне безгә бүләк итеп бирмәс микәнни? [33] Аллаһы сай-
лаганнарны кем гаепли алыр? Һичкем гаепли алмас! Аллаһы
аларны гаепсез дип игълан итә. [34] Кем аларны хөкем итә алыр?
Мәсих Гайсә үлде, әмма алай гына да түгел – үледән терелтел-
де; Ул Аллаһының уң ягында тора һәм безнең өчен Аллаһыга
ялвара. [35] Мәсих мәхәббәтеннән безне нәрсә аера алсын: мих-
нәтме яки газапмы, эзәрлекләүме, ачлыкмы яки ялангачлык-
мы, хәвефме яки кылычмы?
[36] Изге язмада болай дип язылган:
«Синең өчен безне һәрвакыт үтерерләр,
Безне суеласы сарыкларга санныйлар».
[37] Әмма без боларның һәммәсен дә безне Яратучы ярдәмендә
тулысынча җиңеп чыгабыз. [38] Чөнки мин инанам: үлем һәм
тереклек тә, фәрештәләр, күктәге башлыклар һәм көчләр дә,
хәзерге вә киләчәктәге нәрсәләр дә, [39] биеклек һәм тирәнлек
тә, барлыкка китерелгән һичбер нәрсә дә Аллаһының Раббы-
быз Мәсих Гайсә аша күрсәткән мәхәббәтеннән безне аера
алмаячак.

*Аллаһы һәм Исраил халкы*

9 [1] Мәсихнеке булганга хакыйкать сөйлим, алдамыйм, вөҗ-
даным Изге Рух аркылы алдамавымны раслый: [2] йөрәгем
үз халкым өчен зур кайгы һәм өзлексез газап белән тулы.
[3] Бу үз милләтемә, кан кардәшләремә ярдәм итә алса, үземнең
каһәрләнгән һәм Мәсихтән аерылган булуымны теләр идем.
[4] Алар – исраиллеләр, Аллаһы аларны Үз балалары итте, аларга
Үзенең данын күрсәтте, алар белән килешүләр төзеде, аларга
канун, гыйбадәт кылу тәртибе, вәгъдәләр бирде. [5] Алар – без-
нең олы аталарыбызның токымы, Мәсих чыгышы белән алар
арасыннан. Ул – һәрнәрсәдән өстен Аллаһы; Ул мәңге
данлансын*. Амин.
[6] Әмма, Аллаһының сүзе гамәлгә ашмады, дип әйтергә мөм-
кин түгел. Чөнки Исраил халкының һәммәсе дә чын исраилле
түгел. [7] Ибраһим нәселеннән булганнарның һәммәсе дә аның
чын балалары түгел; Изге язмада: «Синең нәселең Исхак аркылы

---

* 9:5 Икенче җөмләне грек теленнән болай да аңларга мөмкин: «Һәрнәрсәдән өстен Аллаһы мәңге данлансын».

булыр», – диелгән бит. [8] Ягъни табигый рәвештә туган балалар
Аллаһы балалары дигән сүз түгел; бәлки, Аллаһының вәгъдәсе
нәтиҗәсендә туган балалар Аллаһы балалары булып санала.
[9] Ә вәгъдә сүзе болай иде: «Билгеләнгән вакытта әйләнеп ки-
лермен, һәм Сараның улы булыр».

[10] Әле бу гына да түгел; Рабига Исхак атабыздан игезәк угыл-
ларга узган. [11-12] Игезәкләр әле туганчы һәм бернинди яхшылык
та, яманлык та эшләргә өлгергәнче үк Аллаһы Рабигага: «Зуры-
сы кечесенә хезмәт итәчәк», – дигән. Ул моның белән Үзенең
сайлап алу турындагы ниятенең хәерле эшләргә түгел, бәлки
чакыручы Аллаһыга бәйле булуын күрсәткән. [13] Бу турыда Изге
язмада болай язылган бит: «Мин Ягъкубны яраттым, ә Эсауга
нәфрәтләндем».

[14] Моннан нәрсә килеп чыга соң? Әллә Аллаһы гадел түгел-
ме? Һич тә алай түгел! [15] Чөнки Ул Мусага әйтте:

«Кемгә телим, шуңа шәфкать күрсәтермен;
Кемне кызганырга телим, шуны кызганырмын».

[16] Димәк, һәммәсе кемнеңдер теләгенә яки тырышлыгына тү-
гел, бәлки шәфкать күрсәтүче Аллаһыга бәйле. [17] Изге язмада
Аллаһы фиргавенгә болай дигән: «Синең аша Үземнең кодрә-
темне күрсәтү өчен, һәм бөтен җир йөзендә Минем исемем
игълан ителсен дип, Мин сине патша итеп куйдым». [18] Шулай
итеп, Аллаһы Үзе теләгән кешегә шәфкать күрсәтә һәм Үзе те-
ләгән кешене үҗәт итә.

*Аллаһының ачуы һәм шәфкате*

[19] Берәрегез миннән: «Аллаһы безне ни өчен гаепли соң?
Аның ихтыярына кем каршы килә ала?» – дип сорар. [20] Әй
адәм, Аллаһы белән бәхәсләшергә син кем соң? Чүлмәк чүл-
мәкчегә: «Ни өчен мине болай итеп ясадың?» – диярме?
[21] Чүлмәкченең бер үк балчык кисәгеннән бер савытны махсус
куллану өчен, ә икенчесен гадәти куллану өчен ясарга хокукы
юкмыни?

[22-23] Аллаһы да шулай ук эшләде түгелме соң? Ул, Үзенең ачу-
ын күрсәтергә һәм кодрәтен белдерергә теләп, Үзенең ачуы
юнәлгән, һәлакәткә дучар ителгән чүлмәкләргә зур сабырлык
белән түзде. Ул моны Үзенең даны өчен Үзе әзерләгән, шәф-
кать күрсәткән чүлмәкләргә Үзенең бай данын белдерү өчен
эшләде. [24] Яһүдләрдән генә түгел, бәлки башка халыклардан
да – Ул чакырган шундый чүлмәкләр без. [25] Һошея китабында
Аллаһы болай ди:

«Минем халкым булмаганны Үз халкым дип,
сөекле булмаганны сөеклем дип атармын.

26 Һәм аларга: „Сез Минем халкым түгел“, – дип әйтелгән урында
алар тере Аллаһының уллары дип аталырлар».
27 Ә Ишагыйя Исраил хакында шуны игълан итә:
«Исраил улларының саны диңгез ярындагы ком бөртекләре кадәр булса да,
бик азлар гына котылачак.
28 Чөнки Раббы җир йөзендә кешеләр өстеннән
эшен тиз тормышка ашырачак».
29 Ишагыйя алдан әйткәнчә:
«Чиксез Кодрәтле Раббы безгә нәсел калдырмаган булса,
без Сәдүм кебек һәм Гамурага охшашлы булыр идек».

*Исраил халкы һәм Яхшы хәбәр*

30 Инде нәрсә әйтик? Аллаһының аклавын эзләмәгән чит ха-
лыклар Аллаһы тарафыннан аклау алдылар. Бу аклау иман аша
булды. 31 Ә инде Аллаһының аклавын бирүче канунны эзләгән
Исраил халкы ул канунга ирешә алмады. 32 Ни өчен? Чөнки
аны, иман белән түгел, бәлки, эш-гамәлләр белән ирешергә
мөмкин дип, канун гамәлләре аша эзләде. Алар ташка абынды-
лар. 33 Ә Изге язмада бу таш турында болай язылган:
«Менә, Сионда кешеләрне абындырачак бер таш,
алар абынып егылачак бер кыя куям;
әмма Аңа иман итүче һичкем оятка калмас».

10 1 Имандашлар! Мин чын күңелдән Исраил халкының
котылуын телим һәм бу хакта Аллаһыга дога кылам.
2 Мин шаһитлек итә алам: алар үзләрен ихлас күңелдән
Аллаһыга багышлаганнар, әмма бу хак белемгә нигезләнмәгән.
3 Аллаһының кешеләрне ни рәвешле хак итүен белмичә, алар
үзләренчә хак булуны урнаштырырга тырышып, Аллаһының
хаклык юлына буйсынмадылар. 4 Ә Мәсих канунга чик куйды,
һәм Аллаһы һәр иман итүчене хак дип игълан итә.

*Котылу бөтен кешеләр өчен*

5 Канунны үтәү аркылы Аллаһы алдында хак булу турында
Муса болай дип яза: «Канун таләпләрен үтәүче кеше алар бе-
лән яшәячәк». 6 Ә иман аркылы Аллаһы алдында хак булу ту-
рында Изге язмада болай диелә: «Күңелеңнән: Күккә кем
менәр (ягъни Мәсихне төшерергә)? 7 Яки: Упкынга кем төшәр
(ягъни Мәсихне үлеләрдән алып чыгу өчен)? – димә». 8 Изге
язмада нәрсә диелә соң? «Аллаһы сүзе синең яныңда, авызыңда
һәм күңелеңдә тора». Менә бу сүз – без игълан итә торган
иман турындагы хәбәр. 9 Гайсәне Раббы дип икърар итсәң һәм

Аллаһының Аны үледән терелтүенә чын күңелдән инансаң, ко-
тылачаксың. [10] Чөнки йөрәк белән иман итү Аллаһы биргән
хаклыкка* алып килә, ә иманны икърар итү – котылу бирә.
[11] Изге язмада болай диелә: «Аңа иман итүче беркем оятка кал-
мас». [12] Яһүдләр белән яһүд булмаганнар арасында аерма юк,
чөнки бер Раббы – барысының да Раббысы. Аңа мөрәҗәгать
итүчеләрнең һәммәсе өчен дә Ул юмарт. [13] Изге язмада болай
дип язылган: «Ялварып Раббыга мөрәҗәгать иткән һәркем ко-
тылачак».

[14] Әмма Раббыга иман итмәгән килеш, Аңа ничек ялварып
мөрәҗәгать итә алырлар? Аның хакында ишетмәгән килеш,
Аңа ничек иман китерә алырлар? Аның турында игълан итүче
булмагач, алар ничек ишетә алырлар? [15] Әгәр игълан итәргә
җибәрелмәгән булса, ничек итеп кем дә булса игълан итә алыр?
Изге язмада болай дип язылган: «Яхшы хәбәр китерүчеләр-
нең килүе ничек куанычлы!» [16] Әмма Яхшы хәбәрне барысы
да кабул итмәде. Ишагыйя болай ди бит: «Йа Раббым! Без
сөйләгән хәбәргә кем ышанды икән соң?» [17] Шулай итеп, ке-
шеләргә иман Яхшы хәбәрне ишетүдән килә, ә ишетү – Мәсих
турындагы Яхшы хәбәрдән туа. [18] Әмма болай дип сорыйм:
әллә Исраил халкы шул хәбәрне ишетмәде микән? Әлбәттә,
ишеттеләр:

«Аларның тавышы бөтен дөнья буйлап үтте,
һәм аларның сүзләре җир йөзенең барлык читләренә
барып җитте».

[19] Һәм яңадан сорыйм: әллә Исраил халкы аңламады микән?
Беренче булып Муса җавап бирә:

«Мин сездә халык дип атап булмаган халык аркылы
көнчелек уятачакмын,
аңсыз халык аркылы сездә ачу кузгатачакмын».

[20] Ә Ишагыйя тагын да кыюрак итеп әйтә:

«Мине эзләмәгән кешеләр Мине тапты,
Мине сорамаганнарга Үземне күрсәттем».

[21] Исраил халкы турында исә: «Мин тыңлаусыз һәм үзсүзле ха-
лыкка көне буе кулларымны сузып тордым», – ди.

*Аллаһы Үз халкын кире какмады*

**11** [1] Шулай итеп, сездән сорыйм: әллә Аллаһы Үз халкын
кире кактымы? Һич тә алай түгел! Мин үзем Ибраһим
нәселеннән, Биньямин кабиләсеннән булган исраилле-
мен. [2] Аллаһы Үз халкын кире какмады, чөнки Ул аны алдан ук

* 10:10 *Хаклыкка* – ягъни «аклауга».

сайлап алды. Әллә сез Изге язмада Ильяс хакында нәрсә әйтелгәнне белмисезме? Исраил халкы турында Аллаһыга зарланып, ул менә нәрсә дигән: [3] «Йа Раббым! Синең пәйгамбәрләреңне үтерделәр, корбан китерү урыннарыңны җимерделәр; бер мин генә калдым, минем җанымны да эзлиләр». [4] Аңа Аллаһының җавабы нинди булды соң? «Ялган илаһ Багал каршында тезләнеп, аңа табынмаган җиде мең кешене Мин Үзем өчен саклап калдым». [5] Хәзерге вакытта да Аллаһы Үзенең мәрхәмәте буенча сайлап алган кешеләр бар, әмма алар күп түгел. [6] Әмма Аллаһының сайлавы Үзенең мәрхәмәте буенча икән, димәк, кешеләрнең хәерле эшләренә карап түгел; югыйсә мәрхәмәт чын мәрхәмәт булмас иде.

[7] Алайса нәрсә соң? Исраил эзләгәненә ирешмәде, ә сайланганнар аны алдылар, башкалар исә туң күңеллегә әйләнделәр. [8] Изге язмада язылганча:

«Бүгенге көнгә кадәр Аллаһы аларны сизмәүчән итте,
аларга күрми торган күзләр
һәм ишетми торган колаклар бирде».

[9] Давыт та әйтә:

«Үзләренең аш табыны алар өчен тозак һәм ятьмә,
абындыручы нәрсә һәм җәза булсын.
[10] Аларның күзләре күрмәс өчен томалансын,
аркалары гомер буе бөкрәйгән хәлдә калсын».

### *Башка халыклар коткарылачак*

[11] Шулай булгач, сорыйм: әллә исраиллеләр, абынганда, бөтенләй егылдылармы? Һич юк! Аларның абынулары аркасында башка халыкларга котылу килде һәм бу исраиллеләрдә көнчелек уятты. [12] Әгәр аларның абынулары дөньяга, уңышсызлыклары башка халыкларга мул фатихалар бирсә, исраиллеләрнең Аллаһыны тулысынча итагать итүе* шулкадәр күбрәк фатиха китерер!

[13] Сезгә — яһүд булмаганнарга әйтәм: яһүд булмаганнарның рәсүле буларак, үз хезмәтемне ихтирам итәм. [14] Үз халкымнан булганнарда, шул рәвешчә көнчелек уятып, аларның кайберләрен коткара алуыма өметләнәм. [15] Әгәр аларның кире кагылуы дөньяны Аллаһы белән дуслаштыра икән, Аның тарафыннан кабул ителүләре нәрсә булыр соң? Бу — үлеләр өчен тереклек булыр! [16] Әгәр Аллаһыга бүләк ителгән беренче икмәк изге икән, шул камырдан пешерелгән башка икмәкләр дә изге; әгәр тамыр изге икән, ботаклар да изге була.

---

* **11:12** *Исраиллеләрнең тулысынча итагать итүе* — Бу сүзләрне «исраиллеләрнең тулы санлы булуы» дип тә аңларга мөмкин.

17 Әгәр зәйтүн агачының кайбер ботаклары сындырылып,
калган зәйтүн ботаклары арасына син – кыргый зәйтүн агачы-
ның ботагы – ялганып, зәйтүн агачының юан тамырыннан
шулай ук туенасың икән, 18 сындырылган ботаклар алдында тә-
кәбберләнмә. Тәкәбберләнсәң, хәтереңә төшер: син тамырны
түгел, бәлки сине тамыр тотып тора. 19 Син исә болай әйтерсең:
«Алар урынына мине ялгау өчен ботакларны сындырдылар».
20 Дөрес. Алар иман итмәгәнгә сындырылдылар, ә син иман
итүең белән урыныңда торасың; борыныңны күтәрмә, кире-
сенчә, сак бул! 21 Чөнки, Аллаһы табигый ботакларны кызган-
маган икән, сине дә кызганмас. 22 Шуның өчен, күр: Аллаһы
игелекле дә, кырыс та. Ул юлдан язганнарга карата кырыс, ә
инде Аның игелегенә өмет багласаң, сиңа игелек була, югыйсә
син дә кисеп ташланырсың. 23 Әмма юлдан язганнар да, иман-
сыз булып калмасалар, кире ялганырлар, чөнки Аллаһы аларны
яңадан ялгый ала. 24 Әгәр син, кыргый зәйтүн агачыннан кисе-
леп, табигатькә каршы, бакчада үскән зәйтүн агачына ялганган-
сың икән, сындырылган табигый ботаклар яңадан үз агачына
бигрәк тә тиз ялганачаклар!

*Исраил халкының коткарылуы*

25 Имандашларым, сез үзегезне акыллыга санамасын өчен, бу
сернең сездән яшерен булып калуын теләмим: башка халык-
ларның кирәк кадәр тулы саны Аллаһы Патшалыгына кергәнгә
кадәр Исраил өлешчә тискәрелегендә дәвам итәчәк. 26 Һәм бө-
тен Исраил шул рәвешчә котылачак, Изге язмада язылганча:
«Сионнан Коткаручы киләчәк
һәм имансызлыкны Ягъкуб токымыннан алып
ташлаячак.
27 Мин аларның гөнаһларын алып ташлаганда,
алар белән килешүем менә шул булыр».
28 Яхшы хәбәргә килгәндә, исраиллеләр Аллаһыга сезнең хакка
дошманнар; ә Аллаһының сайлавына килгәндә, алар ата-бабала-
ры хакына Аллаһының сөеклеләре булып калалар. 29 Чөнки Алла-
һының бүләкләре һәм чакыруы кире алынмас. 30 Кайчандыр сез
Аллаһыга итагатьсез булдыгыз, ә хәзер аларның итагатьсезлеге
нәтиҗәсендә шәфкать алдыгыз. 31 Шулай ук, сезгә күрсәтелгән
шәфкать өчен, хәзер исраиллеләр Аллаһыга итагатьсез булды-
лар. Бу хәзер аларга да шәфкать күрсәтелсен өчен эшләнде.
32 Аллаһы, барысына да шәфкать күрсәтү өчен, бар кешеләр-
не итагатьсезлек тоткыны итте.
33 Әй, Аллаһының байлыгы ничек зур!
Аның зирәклеге һәм белеме ничек тирән!

Аның хөкемнәре акыл ирешмәслек,
Аның юллары эзләп тапмаслык!
34 Раббының уй-фикерләренә кем төшенде?
Яки Аңа кем киңәш бирә ала?
35 Яки, Аллаһы кире кайтарырдай,
кем Аңа нәрсә дә булса биргән?
36 Һәммәсе Аннан, Аның аша һәм Аның өчен бит.
Аңа мәңгегә дан! Амин.

*Гайсә Мәсихтә яңа тормыш*

12 [1] Шулай итеп, имандашлар, Аллаһының рәхим-шәфкате
белән сезгә ялварам: үзегезне тере, изге, Аллаһыга ярак-
лы корбан итеп тәкъдим итегез. Бу Аллаһыга сезнең
чын гыйбадәтегез була. [2] Бу дөньяның гадәтләренә буйсынып,
алар буенча гамәл кылмагыз, моның урынына, зиһенегезнең
яңаруы аша, Аллаһыга үзегезне үзгәртергә юл куегыз. Шуның
белән Аллаһының ихтыярын – нәрсәнең яхшы, Аңа яраклы
һәм камил икәнен – аныклый алырсыз.
[3] Аллаһы биргән мәрхәмәт ярдәмендә сезнең һәрберегезгә
әйтәм: үзегез хакында тиешлесеннән артык уйламагыз; бәлки
һәрберегез, Аллаһы биргән иман микъдарынча, аек фикерле
булыгыз. [4] Безнең бердәнбер тәнебездә әгъзалар күп, аларның
эшләре төрле-төрле. [5] Шулай ук без күп булсак та, Мәсихтә бер
тәнне тәшкил итәбез, аерым-аерым исә һәрберебез икенче-
безнең әгъзасы була. [6] Безгә Аллаһы биргән мәрхәмәт буенча,
һәрберебезнең Аллаһы тарафыннан бирелгән рухи сәләтләре
төрле: кемгә пәйгамбәрлек итү сәләте бирелсә, шул, иманы
нисбәтенчә, әлеге сәләтне куллансын. [7] Кемгә хезмәт итү сәлә-
те бирелсә, ул хезмәт итсен; кемгә өйрәтү сәләте бирелсә, өй-
рәтсен. [8] Кемгә башкаларның күңелен күтәрү сәләте бирелсә,
ул аларның күңелен күтәрсен. Кем үзенекен башкалар белән
уртаклашса, юмартлык белән уртаклашсын; кем җитәкче бул-
са, ул тырышып җитәкчелек итсен; кем шәфкать күрсәтүче
булса, шатланып шәфкать күрсәтсен.
[9] Мәхәббәтегез саф булсын; яманлыкны нәфрәт итегез, ях-
шылыкка ихлас күңелдән бирелгән булыгыз. [10] Бер-берегезгә
туганнарча, эчкерсез мәхәббәт күрсәтегез, бер-берегездән уз-
дырырга тырышып ихтирамлы булыгыз. [11] Тырышлыгыгызны
какшатмагыз, Рух белән янып торыгыз, Раббыга хезмәт итегез.
[12] Өмет итеп сөенегез, михнәт чигүдә түземле булыгыз, ар-
мый-талмый дога кылыгыз. [13] Мохтаҗ булган имандашларыгыз
белән үзегезнекен уртаклашыгыз; кунакчыл булыгыз. [14] Сезне
эзәрлекләүчеләргә Аллаһыдан фатиха сорагыз; аларга кар-
гыш түгел, бәлки фатиха сорагыз. [15] Куанучылыр белән бергә

куанычыгыз, елаучылар белән бергә елагыз. [16] Бер-берегез белән
килешеп яшәгез; тәкәббер булмагыз, бәлки гади кешеләр бе-
лән аралашыгыз; үзегезне акыллыга санамагыз.

[17] Беркемгә дә яманлыкка каршы яманлык кылмагыз, кире-
сенчә, барлык кешеләр алдында игелекле булган эшләр эшләргә
тырышыгыз. [18] Әгәр мөмкин булса, кулыгыздан килгәнчә, бар-
лык кешеләр белән дә тату яшәгез. [19] Әй, сөеклеләрем, үзегез
үч алмагыз, бәлки Аллаһы ачуына урын калдырыгыз. Чөнки
Изге язмада болай язылган: «Үч алу – Минем эш, Үзем кайта-
рып бирәчәкмен, – ди Раббы». [20] Киресенчә, Изге язмада языл-
ганча, «Дошманың ач булса, аны ашат; әгәр сусаган булса, эчер.
Бу игелегеңне эшләп, син аның башына утлы күмер өясең*».

[21] Яманлыкка үзеңне җиңәргә юл куйма, бәлки яманлыкны
яхшылык белән җиң.

*Хакимияткә буйсыну*

**13** [1] Һәр кеше хакимлек итүче җитәкчеләргә буйсынсын;
чөнки Аллаһы урнаштырган хакимлектән башка хаким-
лек юк, гамәлдәге хакимлек исә Аллаһы тарафыннан
куелган. [2] Шуңа күрә, хакимлеккә каршы килүче кеше Аллаһы
билгеләгәнгә каршы килә; ә каршы килүчеләр үз-үзләрен хө-
кемгә дучар итәрләр. [3] Чөнки идарә итүчеләр яхшылык эшләүче
өчен түгел, бәлки яманлык кылучы өчен куркыныч. Хакимлек
итүчедән курыкмаска телисеңме? Яхшылык эшлә, һәм ул сине
мактар. [4] Чөнки хакимлек итүче – синең мәнфәгатең өчен Алла-
һыга хезмәт итә. Әмма яманлык кыласың икән, курык! Чөнки
ул тикмәгә генә кылыч тагып йөрми: ул, Аллаһы хезмәтчесе бу-
ларак, явызлык кылучыларны Аллаһының ачуына дучар итеп,
җәза башкара. [5] Шуның өчен, җәза алудан куркып кына түгел,
бәлки вөҗдан кушуы буенча да башлыкларга буйсынырга кирәк.

[6] Менә шуның өчен сез салым түлисез дә; чөнки алар, үз хез-
мәтләрен башкару белән, Аллаһыга хезмәт итәләр. [7] Шулай
булгач, һәркемгә тиешлесен бирегез: кемгә салым булса – са-
лым; кемгә имана булса – имана түләгез; кемнән куркырга тиеш
булсагыз – шуннан куркыгыз; кем хөрмәткә лаек булса – шуны
хөрмәт итегез.

*Бер-берегезгә мәхәббәт күрсәтегез*

[8] Үзара мәхәббәттән башка, беркемгә дә һичнәрсә белән дә
бурычлы калмагыз; чөнки якынын яратучы Муса канунындагы

---

* **12:20** *Син аның башына утлы күмер өясең* – Бу сүзләр «Син аны оял-
тырсың» дигән мәгънәгә ия.

таләпләрне үтәгән була. [9] «Зина кылма», «кеше үтермә», «урлама», «хирыслык кылма», «башка берәүнекенә нәфесеңне сузма» дигән һәм барлык башка әмерләр, кыскача бер сүз белән әйткәндә, «якыныңны үзеңне яраткан кебек ярат» дигән сүзләр белән аңлатыла. [10] Мәхәббәт башка кешегә явызлык китерми; шуңа күрә бөтен канун мәхәббәт белән үтәлгән була.

[11] Боларның барысын да эшләгез, чөнки сез нинди заманда яшәвегезне беләсез. Хәзер безгә йокыдан уяну сәгате килеп җитте. Чөнки иман китергән вакытка караганда, хәзер котылуыбыз якынрак. [12] Төн үтеп бара, көн туа. Инде караңгылык эшләрен читкә куеп, яктылык коралларын алыйк. [13] Сыйлану вә эчкечелек, фәхешлек һәм азгынлык, ызгыш-талаш вә көнчелек белән түгел, бәлки, көндездәге кебек, әдәп белән гомер итик. [14] Тормышыгыз белән Раббы Гайсә Мәсих идарә итсен*, һәм кешелек табигатегезнең азгын нәфесләрен канәгатьләндерү турында уйлаудан туктагыз.

*Имандашыңны хөкем итмә*

**14** [1] Иманы зәгыйфь булганны, фикерләр турында бәхәсләшмичә, хуплап кабул итегез. [2] Кайберәүләрнең иманы аңа һәртөрле ризыкны ашарга рөхсәт итә, ә башка берәү, иманда зәгыйфь булганга, фәкать яшелчәләр генә ашый. [3] Һәрнәрсәне ашаучы ашамаучыны кимсетмәсен; ашамаучы исә ашаучыны хөкем итмәсен; чөнки Аллаһы аны Үзенә кабул иткән. [4] Башканың хезмәтчесен хөкем итәргә син кем? Ул үз Хуҗасы алдында басып тора яки егыла; һәм басып торачак, чөнки Раббы аны бастырып тотарга кодрәтле.

[5] Берәүләр ниндидер бер көнне башка көннән мөһимрәк дип исәпли, ә башка берәү һәр көнне бертөрле дип саный. Һәркем үз фикерендә нык торсын. [6] Кем бер көнне икенчесеннән мөһимрәк саный икән, ул аны Раббы хөрмәтенә мөһим дип исәпли. Кем ашый икән, ул Раббы хөрмәтенә ашый, чөнки Аллаһыга шөкер итә. Кем ашамый икән, ул Раббы хакы өчен ашамый һәм Аллаһыга шөкер итә. [7] Чөнки безнең беребез дә үзе өчен яшәми һәм беребез дә үзе өчен үлми. [8] Әгәр яшибез икән – Раббы өчен яшибез, үләбез икән – Раббы өчен үләбез. Шуңа күрә, яшибезме яки үләбезме – без һәрвакыт Раббыныкы. [9] Чөнки Мәсих нәкъ шуның өчен – үлеләр һәм тереләр өстеннән Раббы булып хакимлек итү өчен үлде дә, терелде дә.

---

* 13:14 *Тормышыгыз белән Раббы Гайсә Мәсих идарә итсен* – Бу сүзләр төп нөсхәдә сүзгә-сүз: «Кигән киемегез Раббы Гайсә Мәсих булсын».

[10] Шулай булгач, син ни өчен имандашыңны хөкем итәсең? Ә
син ни өчен имандашыңны кимсетәсең? Без барыбыз да Ал-
лаһының хөкем итү урыны алдына басачакбыз. [11] Чөнки Изге
язмада болай дип язылган:

«Минем тере булуым хак булган кебек, –
Минем алда һәрбер кеше тез чүгәчәк,
һәр тел Минем Аллаһы икәнемне икърар итәчәк, –
ди Раббы».

[12] Шулай итеп, безнең һәркайсыбыз үзе хакында Аллаһыга
хисап бирергә тиеш.

*Имандашыгызны вәсвәсәгә салмагыз*

[13] Шуңа күрә, бер-беребезне хөкем итүдән туктыйк, моның
урынына имандашыгызның юлына киртә куймаска яки вәсвә-
сәгә бирелү өчен сәбәп тудырмаска карар кылыгыз. [14] Мин
Раббы Гайсәгә иман иткәнгә, һичнәрсә дә үзеннән-үзе хәрәм
түгел, дип инанам. Ә кем берәр нәрсәне хәрәм дип уйласа, шул
нәрсә аның өчен хәрәм була. [15] Әгәр ашаган ризыгың иманда-
шыңа кайгы китерә икән, димәк, син яратып эш итмисең; аңа
ризыгың белән һәлакәт китермә, Мәсих аның өчен дә үлде
бит. [16] Үзегез яхшы дип исәпләгән нәрсәне мәсхәрәләргә юл
куймагыз. [17] Аллаһы Патшалыгы ризык һәм эчемлектән тор-
мый, бәлки Изге Рух биреп торучы тәкъвалыктан, татулыктан
һәм шатлыктан тора. [18] Кем Мәсихкә болай хезмәт итә, ул
Аллаһыга яраклы була һәм кешеләр тарафыннан хупланыла.

[19] Шулай булгач, үзара тыныч-тату яшик һәм бер-беребез-
не рухи яктан ныгытуга хезмәт итүче нәрсәләргә омтылыйк.
[20] Ризык аркасында Аллаһының эшен җимермә: һәр ризык саф,
әмма кеше ашаган ризык башка берәүне вәсвәсәгә төшерсә, бу
яхшы түгел. [21] Ит ашамау, шәраб эчмәү һәм имандашыңны рән-
җетерлек яки вәсвәсәгә төшерерлек яисә аның хәлсезләнүенә
сәбәп булырлык һичнәрсә эшләмәү яхшы.

[22] Үз карашларыңны үзең белән Аллаһы арасында гына сак-
лап тот. Үзе дөрес дип санаган нәрсә өчен үзен хөкем итәрлек
сәбәп тапмаучы бәхетле. [23] Кайсы да булса ризыкны ашарга
ярыймы яки юкмы дип шикләнеп тә кеше аны ашаса, ул хөкем
ителер, чөнки ашавы иман буенча түгел; ә иман буенча булма-
ган һәрнәрсә – гөнаһ.

**15** [1] Без, көчлеләр, көчсезләрнең йөкләрен күтәреп йөрергә
тиеш, һәм без үз-үзебезгә ярарга тиеш түгел. [2] Безнең
һәрберебез, якыныбызның иманын ныгыту өчен, аңа ях-
шы булсын дип, аңа ярарга тырышырга тиеш. [3] Чөнки Мәсих
тә Үзенә ярарга тырышмады, бәлки Изге язмада язылганча:

«Сине яманлаучыларның хурлаулары Минем өстемә төште».
4 Элек Изге язмада язылганнарның барысы да, алар биргән са-
бырлык һәм илһам аша бездә өмет булсын дип, безгә нәсыйхәт
бирү өчен язылган. 5 Сабырлык һәм илһам чыганагы булган
Аллаһы, Мәсих Гайсә үрнәгенә ияреп, үз арагызда бер фикер-
дә булуны бүләк итсен. 6 Шулай итеп, сез бердәм рәвештә,
бер авыздан Раббыбыз Гайсә Мәсихнең Аллаһысын һәм Ата-
сын данларсыз.

*Яхшы хәбәр башка халыкларга игълан ителә*

7 Шуңа күрә, Аллаһыга дан булсын өчен, Мәсих сезне кабул
иткән кебек, бер-берегезне шулай кабул итегез. 8 Шуны әйтәм:
ата-бабаларга бирелгән вәгъдә үтәлсен дип, Аллаһының тугры-
лыклы икәнен күрсәтү өчен, Мәсих яһүдләргә хезмәт итәргә
килде. 9 Ул, шулай ук, Аллаһының башка халыкларга күрсәткән
шәфкате өчен, алар Аны данласын дип тә килде. Чөнки Изге
язмада:

«Шул сәбәпле, Сине халыклар арасында данлармын,
Синең исемеңне мактап җырлармын», —

дип язылган. 10 Аннары тагын:

«Әй, бар халыклар, Аллаһы халкы белән бергә
шатланыгыз!» —

диелгән. 11 Һәм тагын:

«Бар халыклар, Раббыны мактагыз,
әй, бар милләт кешеләре, Аны данлагыз!» —

дип язылган. 12 Ишагыйя да болай ди:

«Ишай нәселеннән Берәү килер
һәм халыклар өстеннән хакимлек итү өчен күтәрелер;
алар Аңа өмет баглаячаклар».

13 Изге Рухның кодрәте аша өметегез арткannан-арта барсын
өчен, өмет бирүче Аллаһы сезне, Аңа иман итүчеләрне, бар
шатлык һәм иминлек белән сугарсын.

*Паул — башка милләтләр арасында хезмәт итүче*

14 Имандашларым, мин ышанам, сез игелек белән тулы, бар
белем белән сугарылгансыз һәм бер-берегезгә үгет-нәсыйхәт
бирә беләсез. 15 Шуңа да карамастан, миңа Аллаһы тарафыннан
бирелгән мәрхәмәт буенча, имандашларым, сезнең исегезгә
төшереп, кайбер мәсьәләләр турында шактый кыю рәвештә
яздым, чөнки Аллаһы Үзенең мәрхәмәте белән 16 мине яһүд
булмаганнарга Мәсих Гайсәнең хезмәтчесе итте. Аның хез-
мәтчесе буларак, яһүд булмаганнар Аллаһыга яраклы, Изге
Рух тарафыннан изгеләндерелгән корбан булсын өчен, мин,

Аллаһының Яхшы хәбәрен игълан итеп, рухани хезмәтен
башкарам.
17 Шулай итеп, Мәсих Гайсәнеке булганлыктан, Аллаһыга
хезмәт итүем белән горурлана алам. 18-19 Чөнки яһүд булмаган-
нарны Аллаһыга буйсынучан итү өчен, Мәсих минем аша га-
мәл кылганнардан башка нәрсәләр хакында һичнәрсә сөйләргә
батырчылык итмәм. Ул боларны сүз һәм эш белән, галәмәтләр
һәм могҗизалар көче ярдәмендә, Аллаһы Рухының кодрәте бе-
лән башкарды. Мин Иерусалимнан Иллүрикүн өлкәсенә кадәр
йөреп, Мәсих хакындагы Яхшы хәбәрне тулысынча җиткердем.
20 Ә башка берәү салган нигезгә кормас өчен, мин һәрвакыт
Яхшы хәбәрне Мәсихнең исеме билгеле булмаган урыннарда
белдерергә тырыша идем. 21 Изге язмада язылганча:

«Аның хакында ишетмәгән кешеләр күрәчәкләр
һәм ишетмәгәннәр аңлаячаклар», –

дип эшләдем.

*Паулның Римга бару нияте*

22 Моның өчен, мин күп тапкырлар янызга барырга телә-
сәм дә, әлегәчә тоткарлыкларга очрадым. 23 Хәзер исә, бу тө-
бәкләрдә эшләү мөмкинлеге булмаганга һәм күп еллардан
бирле сезгә барырга бик теләгәнлектән, 24 Испаниягә юл то-
тып, яныгызга барырмын. Анда барышлый, сезне күрермен
һәм, сезнең белән аралашудан берникадәр ләззәт алганнан
соң, сез мине юлга озатырсыз дип өмет итәм. 25 Ә хәзер изге-
ләргә хезмәт итү өчен, Иерусалимга барам. 26 Чөнки Македу-
ния белән Ахаядәге иман итүчеләр бердәмлекләре Иерусалим-
дагы изгеләр арасындагы ярлыларга акчалата ярдәм итәргә
риза булдылар. 27 Алар шулай эшләргә карар кылдылар; һәм,
дөрестән дә, яһүд булмаганнар яһүдләр алдында бурычлы.
Чөнки, яһүд булмаганнар яһүдләрнең рухи фатихаларын ур-
таклашканга, яһүд булмаганнар матди нәрсәләр белән ярдәм
күрсәтергә тиешләр. 28 Моны башкарып чыккач һәм җыелган
акчаны исән-имин аларга тапшырганнан соң, мин Испаниягә
китәрмен һәм юл уңаенда сезнең янга тукталып үтәрмен.
29 Яныгызга килгәндә исә, Мәсихнең тулы фатихасы белән ки-
ләчәгемне беләм.
30 Имандашларым, Раббыбыз Гайсә Мәсих һәм Рух мәхәб-
бәте белән сезгә ялварам: минем белән бергә тырышлык күр-
сәтеп, минем өчен Аллаһыга дога кылыгыз. 31 Яһүдиядәге
иман итмәүчеләр миңа зыян китермәсен, һәм Иерусалимдагы
изгеләр мин алып килгән акчалата ярдәмне кабул итсен өчен,
дога кылыгыз. 32 Шулай итеп, Аллаһы насыйп итсә, мин шат

хәлдә яныгызга килермен һәм, сезнең белән аралашып, көч
җыя алырмын. 33 Иминлек бирүче Аллаһы сезнең һәммәгез бе-
лән булсын! Амин.

*Шәхси сәламнәр*

16 1 Сезгә Кенхерәйдәге иман итүчеләр бердәмлегенең яр-
дәмчесе, имандаш кыз кардәшебез Фойбәне тәкъдим
итәм: 2 Ул Раббыныкы булганга, аны изгеләргә лаек бул-
ганча кабул итегез һәм аңа үзегездән тиешле ярдәм күрсәтегез;
чөнки ул күпләргә һәм минем үземә дә игелек эшләде.

3 Минем белән бергә Мәсих Гайсәгә хезмәт итүче Прискиллә
һәм Әкүлгә сәлам әйтегез. 4 Алар минем җаным хакына тор-
мышларын куркыныч астына куйдылар, аларга мин генә түгел,
бәлки яһүд булмаганнарның барлык бердәмлекләре дә рәхмәт
белдерәләр. 5 Аларның өендә җыелучы иман итүчеләр бердәм-
легенә дә сәлам әйтегез.

Асия өлкәсендә Мәсихкә беренче булып иман иткән сөекле
дустым Эпайнетка сәлам тапшырыгыз. 6 Сезнең өчен күп ты-
рышлыклар куйган Мәрьямгә сәлам әйтегез. 7 Минем белән бер-
гә төрмәдә булган кардәш-ыруларым Андроник вә Юниягә сә-
лам әйтегез. Рәсүлләр арасында алар киң танылган һәм Мәсихкә
миннән алда иман китергән. 8 Раббыныкы булган кадерле дус-
тым Амплиәткә сәлам әйтегез. 9 Минем белән Мәсихкә хезмәт
итүче Урбанга һәм сөекле дустым Стахуска сәлам белдерегез.

10 Мәсихкә хезмәттә сыналып, яхшы дип табылган Апеллескә
сәлам әйтегез. Аристобул гаиләсендәгеләргә сәлам җиткерегез.
11 Кардәш-ыруым Һирудиунга сәлам әйтегез. Нәркис өеннән
булганнарның Раббыга иман итүчеләренә сәлам диегез. 12 Раббы
өчен бик тырышып хезмәт итүче Труфайна белән Труфусага сә-
лам әйтегез. Раббы өчен күп тырышлыклар куйган кадерле дус-
тым Персисәгә сәлам әйтегез. 13 Раббы тарафыннан сайланган
Руфуска һәм шулай ук аның анасына да сәлам. Ул минем өчен
дә ана. 14 Асункриткә, Флегүнгә, Һермискә, Патрубка, Һермас-
ка һәм алар белән булган башка имандашларга сәлам әйтегез.
15 Филолүгкә һәм Юлиягә, Нирегә һәм аның сеңлесенә, Олум-
пас һәм алар белән булган барлык изгеләргә сәлам әйтегез.

16 Бер-берегезне изге үбү белән сәламләгез. Мәсихнең барлык
бердәмлекләре сезгә сәлам тапшыралар.

17 Имандашлар, сездән ялварып сорыйм: үзегез өйрәнгән
тәгълиматка карата бүленеш китереп чыгаручылардан һәм дө-
рес юлдан яздыруга сәбәп тудыручылардан сакланыгыз һәм
алардан читләшегез. 18 Чөнки андый кешеләр Раббыбыз Мә-
сихкә түгел, бәлки үзләренең карыннарына хезмәт итәләр,

ышандырырлык сүзләр сөйләп һәм ялагайланып, ихлас күңеллеләрне алдыйлар. 19 Сезнең иманга итагатегез һәркемгә мәгълүм, шуңа күрә мин сезнең өчен шатланам. Әмма ләкин яхшылыкка карата зирәк, яманлыкка карата керсез күңелле булуыгызны телим. 20 Иминлек бирүче Аллаһы шайтанны тиздән аякларыгыз астында изәчәк. Раббыбыз Гайсәнең мәрхәмәте сезнең белән булсын!

21 Хезмәттәшем Тимуте һәм кардәш-ыруларым Луки, Ясун һәм Сосипатыр сезгә сәлам җибәрәләр.

22 Бу хатны язып торучы мин, Терти дә, имандашыгыз буларак сәламлим.

23 Мине һәм бөтен иман итүчеләр бердәмлеген өенә кабул иткән Гәй сезгә сәлам җибәрә. Шәһәр милкен саклаучы Эрасты һәм имандашыбыз Кварт сезгә сәлам әйтәләр. [ 24 ]*

25-26 Аллаһыга дан! Гайсә Мәсих турында мин сөйләгән Яхшы хәбәр буенча, Ул сезне ныгытырга кодрәтле. Бу Яхшы хәбәр – борынгы заманнардан бирле яшереп тотылган, әмма хәзер ачылган сер. Мәңгелек Аллаһының әмере белән пәйгамбәрләрнең язмалары аркылы кешеләр Аңа иман китерсен һәм итагать итсен өчен, бу сер бар халыкларга игълан ителде. 27 Бердәнбер зирәк Аллаһыга Гайсә Мәсих аша мәңге дан булсын. Амин.**

---

* 16:24 Кайбер кулъязмаларда 24 нче аять тә бар: «Раббыбыз Гайсә Мәсихнең мәрхәмәте сезнең һәммәгез белән булсын! Амин».

** 16:25-27 Кайбер кулъязмаларда 25-27 нче аятьләр юк.

# ПАУЛДАН КӨРИНТЛЕЛӘРГӘ БЕРЕНЧЕ ХАТ

*Сәламнәр һәм рәхмәт белдерү*

**1** 1 Аллаһы ихтыяры белән Мәсих Гайсәнең рәсүле булырга
чакырылган Паулдан, Состенис имандаштан 2 Мәсих Гайсә
аша Аллаһыга багышланган һәм Аның изгеләре булырга ча-
кырылган Көринттәге иман итүчеләр бердәмлегенә һәм һәр
урында Раббы Гайсә Мәсихкә мөрәҗәгать итүчеләрнең һәммә-
сенә сәлам. Мәсих аларның һәм безнең Раббыбыз бит. 3 Атабыз
Аллаһы вә Раббы Гайсә Мәсихтән сезгә мәрхәмәт һәм имин-
лек булсын.
4 Сезнең өчен Аллаһыма һәрвакыт рәхмәт укыйм: Ул Мәсих
Гайсә аша сезгә мәрхәмәт бүләк итте. 5 Чөнки Мәсих Гайсәдә
сез һәрнәрсәдә: сүздә һәм белемдә баедыгыз, 6 шуның белән
Мәсих хакындагы безнең шаһитлек сездә расланды. 7 Шуңа
күрә Раббыбыз Гайсә Мәсихнең килүен көткәндә сезнең һич-
нинди рухи сәләткә мохтаҗлыгыгыз калмады; 8 Раббыбыз Гайсә
Мәсих килгән көндә сез гаепсез булсын өчен Аллаһы сезне
ахырга кадәр нык тотачак. 9 Сезне Үзенең Улы Раббыбыз Гай-
сә Мәсих белән аралашу өчен чакырган Аллаһы Үз вәгъдәсенә
турылыклы.

*Бердәмлектәге бүленешләр*

10 Имандашлар, Раббыбыз Гайсә Мәсих исеме белән һәм-
мәгездән ялварып сорыйм: сез барыгыз да бер сүзле булыгыз,
арагызда төрле бүленешләр булмасын, киресенчә, уй-фикерлә-
регез бердәм булсын. 11 Имандашларым, сездә ызгыш-талашлар
булгалавы турында миңа Хлоя өендәгеләрдән билгеле булды.
12 Мин шуны күздә тотам: сездә «Мин – Паулныкы», «Мин –
Апуллусныкы», «Мин – Кифасныкы*», «ә Мин – Мәсихнеке»
дип сөйләүчеләр бар. 13 Әллә Мәсих бүленгәнме? Паул сезнең

---

* 1:12 *Кифас* – Шимун Петернең икенче исеме.

өчен хачка кадакландымы әллә? Әллә сез Паул исеме белән
суга чумдырылу йоласын үтәдегезме? 14 Аллаһыга шөкер, мин
Криспи һәм Гәйдән башка сезнең берегезне дә чумдырмадым.
15 Шуңа күрә беркем дә беркайчан да минем турыда: «Паул үз
исеме белән чумдырды», – дип әйтә алмас. 16 Мин шулай ук
Эстефәнәс өендәгеләрне чумдырдым; ә тагын кемне дә булса
чумдыруымны хәтерләмим. 17 Чөнки Мәсих мине чумдыру
өчен түгел, бәлки, Мәсих хачының әһәмияте юкка чыкмасын
дип, Яхшы хәбәрне зирәк сүзләр кулланмыйча игълан итәргә
җибәрде.

*Мәсих – Аллаһының кодрәте һәм зирәклеге*

18 Чөнки хач турындагы сүз – һәлакәткә дучар ителгәннәр
өчен акылсызлык, ә безнең өчен – Гайсәгә иман итеп коты-
лучылар өчен Аллаһы кодрәте. 19 Изге язмада: «Хикмәт ияләре-
нең зирәклеген юкка чыгарырмын, акыллыларның акылын
кире кагармын», – дип язылган. 20 Хикмәт иясе кайда да канун-
чы кайда? Бу заманның фәлсәфәчеләре кайда? Аллаһы бу
дөньяның зирәклеген акылсыз итмәдеме? 21 Чөнки дөнья әле
үз зирәклеге аша Аллаһының тирән акылын танып белмәгән
вакытта, Аллаһы иман итүчеләрне акылсыз дип саналган Яхшы
хәбәр аркылы коткаруны мәгъкуль күрде. 22 Яһүдләр могҗиза
таләп итәләр, ә греклар зирәклек эзлиләр; 23 без исә хачка ка-
дакланган Мәсих турында игълан итәбез, ә бу – яһүдләр өчен
абыну ташы, греклар өчен – акылсызлык. 24 Ә инде Аллаһы
чакырып алганнар өчен, алар яһүдме, яисә грек булсынмы,
Мәсих – Аллаһының кодрәте һәм зирәклеге. 25 Чөнки Аллаһы-
ның «акылсызлыгы» кешеләрнең зирәклегеннән күпкә зирәг-
рәк һәм Аллаһының «көчсезлеге» кешеләрнең кодрәтеннән күп
өлеш кодрәтлерәк.

26 Имандашлар, исегезгә төшерегез әле, Аллаһы сезне чакыр-
ган вакытта сез кем идегез? Сезнең кайберләрегез генә кеше-
ләрнең үз үлчәме буенча акыллы, кодрәтле, беразыгыз гына
затлы нәселдән иде. 27 Әмма Аллаһы, акыл ияләренә һәм көч-
леләргә оят булсын өчен, дөнья акылсыз һәм көчсез дип исәп-
ләгәннәрне сайлап алды. 28-29 Һичбер кеше Аллаһы алдында
мактанмасын дип, дөньяның мөһим саналганнарын юкка чы-
гару өчен, Ул дөньяның әһәмиятсез дип исәпләнгәннәрен һәм
кимсетелгәннәрен сайлап алды. 30 Әмма хәзер Аллаһының га-
мәле аркылы сез Мәсих Гайсәдә торасыз. Ул – безнең өчен
Аллаһыдан килгән зирәклек булды. Гайсә аша без хаклык, из-
гелек һәм азатлык алабыз. 31 Шулай итеп, Изге язмада язылган-
ча: «Мактанучы кеше Раббы белән мактансын».

2 [1] Имандашлар, янгызга Аллаһының серен игълан итәргә
килгәндә, мин купшы сүзләр сөйләргә яки зирәклегемне
күрсәтергә килмәдем. [2] Чөнки сезнең янда булганда мин
Гайсә Мәсихтән һәм шуның өстенә Аның хачка кадаклану-
ыннан башка һичнәрсә белмәскә карар кылдым. [3] Мин яны-
гызга көчсез, бик курыккан һәм калтыранган хәлдә килдем.
[4-5] Иманыгыз кешеләр акылына түгел, бәлки Аллаһы кодрәтенә
нигезләнсен өчен, сүзем һәм вәгазем кеше акылының ышан-
дырырлык сүзләренә түгел, бәлки Аллаһы Рухының кодрәтен
исбатлауга нигезләнгән иде.

*Аллаһының зирәклеге*

[6] Ә без инде зирәклек турында җитлеккән иман итүчеләр ара-
сында сөйлибез. Әмма ул – хәзерге заман акылы һәм бу дөнья
хакимнәренең акылы түгел, алар бетүгә таба бара бит. [7] Ә без
Аллаһының дөнья яратылганчы ук данybыз өчен билгеләнгән,
яшерен серле зирәклеге турында сөйлибез. [8] Шул зирәклекне бу
дөньядагы бер генә хаким дә танымады. Әгәр танысалар, дан-
лыклы Раббыны хачка кадакламаган булырлар иде. [9] Әмма Изге
язмада болай дип язылган: «Аллаһы Үзен яратучыларга нәрсә
әзерләгәнен һичбер күз күрмәгән, һичбер колак ишетмәгән һәм
һичбер кешенең йөрәге бу турыда уйлап карамаган». [10] Ә моны
Аллаһы безгә Үзенең Рухы аша ачты, чөнки Рух һәрнәрсәне, хәт-
та Аллаһының тирәнлекләрен дә тикшерә. [11] Кешенең уйларын
үзендәге рухтан башка тагын кем белә? Шуның кебек үк, Алла-
һының ниятләрен дә Аллаһы Рухыннан башка һичкем белми.
[12] Без исә, Аллаһы тарафыннан нәрсә бүләк ителгәнен белү
өчен, бу дөньяның рухын түгел, бәлки Аллаһыдан килгән Рухны
кабул иттек. [13] Һәм болар турында кеше зирәклеге өйрәткән сүз-
ләр белән түгел, бәлки Рух өйрәткән сүзләр белән сөйләшәбез.
Без рухи хакыйкатьне Аллаһы Рухына ия булган кешеләргә аңла-
табыз. [14] Үзендә Аллаһы Рухы булмаган кеше Аллаһы Рухы күр-
сәткәннәрне кабул итми, чөнки аларны акылсызлык дип саный;
ул аларны аңлый алмый, чөнки болар турында Изге Рух ярдәме
белән генә фикер йөртергә мөмкин. [15] Аллаһы Рухына ия булу-
чы исә һәрнәрсә турында фикер йөртә ала, ә аның үзен һичкем
тулысынча аңлый алмый. [16] Чөнки Изге язмада язылганча:
«Раббыга киңәш бирергә
Аның уй-фикерләренә кем төшенгән?»
Ә без Мәсихнең уй-ниятләрен аңлыйбыз, чөнки аларны безгә
Изге Рух ача.*

---

* 2:16 Соңгы җөмлә грек телендә сүзгә-сүз: «Ә без Мәсихнең аңы-
на ия».

*Аллаһының хезмәттәшләре*

3 1 Имандашлар, мин Аллаһы Рухына ия булучыларга сөй-
ләгән кебек сөйли алмадым, бәлки дөньяви кешеләргә,
Мәсих юлында әле дә имчәк баласы кебек булганнарга
сөйләгән кебек сөйләдем сезгә. 2 Мин сезгә каты ризык түгел,
бәлки сөт ашаттым, чөнки сез ул ризык белән тукланырлык
дәрәҗәдә түгел идегез һәм хәзер дә әзер түгелсез. 3 Чөнки сез
һаман да дөньяви яшисез. Әгәр бер-берегездән көнләшәсез
һәм ызгышып-талашып яшисез икән, бу хәлдә сез дөньяви
кешеләр түгелме һәм гади кешеләр кебек эш итмисезме?
4 Чөнки берегез: «Мин – Паулныкы», ә икенчегез: «Мин –
Апуллусныкы», – ди икән, ул чакта сез гади кешеләр буласыз
түгелме соң?

5 Кем ул Паул? Апуллус кем ул? Алар – хезмәтчеләр генә,
һәм Раббы аларның һәрберсенә нинди вазифа бирүенә карап,
сез алар аркылы иман китердегез. 6 Мин утырттым, Апуллус су
сипте, әмма үстерүен Аллаһы үстерде. 7 Шуңа күрә утыртучы
да, су сибүче дә түгел, бәлки үстерүче Аллаһы гына мөһим.
8 Утыртучы белән су сибүче – асылда бер; әмма һәркайсы сава-
бын үзенең хезмәтенә карап алачак. 9 Чөнки без – Аллаһының
хезмәттәшләре, ә сез – Аллаһының иген кыры, Аллаһының
корылмасы.

10 Зирәк төзүче кебек, Аллаһы мәрхәмәте белән, мин нигез
салдым, ә башка берәү шуның өстенә төзи. Әмма һәркем үзе-
нең төзү рәвешенә игътибар итсен. 11 Чөнки булган нигездән
башка бүтән нигезне һичкем сала алмый, ә ул нигез – Гайсә
Мәсих. 12 Кем дә булса бу нигез өстенә алтыннан, көмештән,
асылташлардан, агачтан, печәннән, саламнан төзесә, 13 һәрбе-
ренең эше ачык күренәчәк; ул эшне исә хөкем көне белдерәчәк.
Ул көн ут белән ачылачак, һәм ут һәркемнең эшен сынаячак.
14 Кемнең корылмасы исән калса, шул савап алачак. 15 Эшләгән
эше янса, ул зыян күрәчәк. Хәер, ул үзе котылып калачак,
әмма ут эченнән чыккан кебек котылачак.

16 Әллә Аллаһы йорты булуыгызны һәм сездә Аллаһы Рухы
яшәвен белмисезме? 17 Кем Аллаһының йортын җимерсә, Алла-
һы аны җәзалаячак. Чөнки Аллаһы йорты изге; ә ул йорт – сез.

18 Берегез дә үзен-үзе алдамасын. Кайберегез бу заманда үзен
акыл иясе дип санаса, акыл иясе булу өчен, ул акылсыз булсын.
19 Бу заманның акыллылыгы – Аллаһы каршында акылсызлык
бит. Чөнки Изге язмада: «Аллаһы акыл ияләрен мәкерләрендә
эләктереп ала», – дип язылган бит. 20 Һәм тагын: «Раббы акыл
ияләренең уйларын белә: алар файдасыз». 21 Шулай булгач,

һичкем кешеләр белән мактанмасын, чөнки һәрнәрсә – сезнеке. 22 Паулмы, Апуллусмы, Кифасмы, дөньямы, тормышмы, үлемме, хәзергеме яки киләчәкме – һәммәсе сезнеке; 23 сез исә – Мәсихнеке, ә Мәсих – Аллаһыныкы.

*Рәсүлләрнең хезмәте*

4 1 Шулай итеп, безне һәркем Мәсихнең хезмәтчеләре һәм Аллаһы серләре ышанып тапшырылган идарә итүчеләр дип санасын. 2 Моннан тыш ышанып тапшырылганнарның һәрберсенең тугры булуы таләп ителә. 3 Сезнең яки башкаларның минем хакта хөкем йөртү рәвеше әһәмиятле түгел; мин үзем дә үзем турында хөкем йөртмим. 4 Ләкин, үземдә бернинди гаеп күрмәсәм дә, моның белән үземне акламыйм. Мине бер Раббы гына хөкем итә. 5 Шуңа күрә, Раббы килгәнче берничек тә хөкем итмәгез. Ул караңгылыкта яшерелгәннәрне яктыртачак һәм эчкерсез ниятләрне күрсәтәчәк, һәм шул чакта һәркемгә Аллаһыдан мактау булачак.

6 Имандашлар, сезнең хакка мин боларны үземә һәм Апуллуска карата кулландым. Изге язмада язылганнан тыш акыл сатмаска өйрәнүегезне телим, һәм һичкем берәүне башка берәү алдында мактап өстен куймасын. 7 Сине кем өстен итеп куя? Син кабул итмәгән берәр нәрсә бармы? Ә инде кабул иткәнсең икән, ни өчен кабул итмәгән кебек мактанасың?

8 Сез инде тукландыгыз, сез инде баедыгыз, сез инде боздән башка патшалар булдыгыз! Мин, чыннан да, патшалар булуыгызны теләр идем, шул вакытта без дә сезнең белән бергә патшалар булыр идек! 9 Ә миңа Аллаһы безне, рәсүлләрне, үлемгә хөкем ителгән кешеләр кебек, иң артка куйган сыман тоела. Чөнки Аллаһы безне дөнья, фәрештәләр һәм кешеләр өчен тамаша итте. 10 Без – Мәсих хакына тилеләр, сез исә – Мәсих белән берләшүдә акыллылар! Без – хәлсезләр, ә сез – көчлеләр! Сезне хөрмәтлиләр, ә безне хурлыйлар. 11 Хәтта, әлегә кадәр ачлыкка һәм сусауга дучарбыз, ярым ялангач һәм кыйналган хәлдә, бер урыннан икенче урынга күченеп йөрибез, чөнки йорт-җиребез юк. 12 Һәм үз кулларыбыз белән авыр хезмәт башкарып көн күрәбез. Безгә ләгънәт укыйлар – без фатиха бирәбез; безне эзәрлеклиләр – без түзәбез. 13 Безгә яла ягалар – без яхшылык белән җавап бирәбез. Дөнья өчен әлегә кадәр барысы тарафыннан санга саналмаган чүп-чар кебек булдык без.

14 Мин боларны сезне оялту өчен язмыйм, әмма яраткан балаларымны кисәткән сыман кисәтәм. 15 Гәрчә Мәсих юлында меңләгән нәсыйхәтчеләрегез булса да, аталарыгыз күп түгел.

Яхшы хәбәр белдереп, Мәсих Гайсә аша мин сезнең рухи атагыз
булдым. 16 Шуңа күрә ялварып сорыйм: миннән үрнәк алыгыз.
17 Шуның өчен мин сезгә үземнең сөекле һәм Раббыга туры-
лыклы улым Тимутене җибәрдем. Ул Мәсих Гайсәгә ияреп тор-
мыш итүем һәм һәр җирдә һәрбер иман итүчеләр бердәмлеген-
дәге өйрәтүләрем турында сезнең исегезгә төшерер.

18 Мин яныгызга килмәс дип, сезнең кайберләрегез масайган.
19 Әмма, Аллаһы насыйп итсә, мин тиздән сезгә килермен һәм
әлеге масаючыларның сүзен түгел, бәлки көчен сынап белер-
мен. 20 Чөнки Аллаһы Патшалыгы сүздә түгел, бәлки көчтә.
21 Нәрсә телисез сез? Сезгә таяк беләнме яисә мәхәббәт һәм ба-
сынкылык рухы белән килимме?

*Иман итүчеләр арасындагы фәхешлек*

5 1 Дөрестән дә, арагызда фәхешлек, хәтта мәҗүсиләрдә дә
булмаган фәхешлек урын алуы турында хәбәрләр бар. Кем-
дер үги анасын үзенә хатын иткән икән. 2 Ә сез, елыйсы
урында, тагын да тәкәбберләнгәнсез! Андый эш кылучыны
арагыздан сөрергә кирәк иде. 3 Ә мин тәнем белән түгел, күңе-
лем белән яныгызда булганда, андый эш эшләүчене арагызда
булган кебек хөкем иттем: 4 сез Раббыбыз Гайсә исеме белән
җыелганда һәм күңелем сезнең белән булганда, Раббыбыз Гай-
сә кодрәте белән бергә, 5 Раббыбыз көнендә аның рухы котыл-
сын дип, тәнен юкка чыгару өчен бу кешене шайтан кулына
тапшырырга кирәк.

6 Сезнең өчен мактанырлык һичнәрсә юк. Кечкенә генә ачыт-
кының да бөтен камырны ачытуын белмисезме әллә? 7 Шулай
булгач, яңа төче камыр буласыгыз килсә, иске ачыткыны таш-
лагыз. Чынлыкта сездә инде ачыткы юк, чөнки Коткарылу
бәйрәме бәрәнебез булган Мәсих безнең өчен корбан ителде.
8 Шуңа күрә иске ачыткы белән – усаллык һәм мәкерлек
ачыткысы белән түгел, бәлки ачыткысыз сафлык һәм хакый-
кать икмәге белән бәйрәм итик.

9 Мин сезгә хатымда, фәхеш кешеләр белән аралашмагыз,
дип язган идем. 10 Хәер, дөньядагы фәхеш кешеләр яки ком-
сызлар, талаучылар, потка табынучылар белән аралашмагыз
дияргә уйламадым, юкса бу дөньядан китәргә тиеш булыр иде-
гез. 11 Үзен имандаш дип атап та, фәхеш яки комсыз, потка та-
бынучы яки яман телле, эчкече яки талаучы булып кала бирүче
белән аралашмагыз, хәтта андый кеше белән бергә ашамагыз
да, дип яздым мин сезгә.

12 Ник миңа иман итүчеләрдән читтә булганнарны хөкем
итәргә? Арагыздагыларны сез үзегез хөкем итәргә тиеш түгелме

соң? [13] Читтә булганнарны исә Аллаһы хөкем итә. Шулай
итеп, Изге язмада язылганча: «Үз арагыздан яманлык кылу-
чыны сөрегез!»

*Иман итүчеләр арасындагы дәгъвалар*

6 [1] Арагыздагы башка берәүгә дәгъвасы булган кеше, изгеләр
алдында түгел, бәлки имансызлар алдында хөкем ителергә
ничек батырчылык итәр икән? [2] Дөньяны изгеләр хөкем
итәчәген белмисезме әллә? Әгәр дөньяны сез хөкем итәсез
икән, ул вакытта сез әһәмиятсез эшләрне хөкем итә алмас-
сызмы? [3] Фәрештәләрне хөкем итәчәгебезне белмисезме әллә?
Көндәлек дәгъваларны хөкем итәргә сәләтебез җитмәсме? [4] Ә
көндәлек дәгъваларны хәл итәргә кирәк булганда сез имансыз-
ларны хакимнәр итеп куясызмы? [5] Сезгә оят булсын дип әйтәм:
әллә имандашлары арасындагы бәхәсләрне хәл итәрлек бер
генә акыллы кешегез дә юкмы? [6] Имандаш белән имандаш
дәгъвалаша, өстәвенә, бу – имансызлар алдында эшләнелә!
[7] Бер-берегез арасында дәгъвалар булуы инде үзе үк сезнең ту-
лысынча җиңелүегезне күрсәтә. Сезгә ни өчен рәнҗетелгәннәр
һәм алданганнар булып калмаска? [8] Әмма сез үзегез рәнҗетәсез
һәм имандашларыгызны алдыйсыз. [9] Явызлык кылучыларның
Аллаһы Патшалыгына ия була алмаячакларын белмисезме әл-
лә? Алданмагыз: азгыннар, потка табынучылар, зиначылар,
җенси бозыклыкка бирелгәннәр, бер-берсе белән җенси мө-
нәсәбәткә керүче ирләр, [10] караклар, комсызлар, эчкечеләр,
яман теллеләр, талаучылар – берсе дә Аллаһы Патшалыгына
ия була алмаячаклар. [11] Кайберләрегез менә шундый иде. Әмма
Раббыбыз Гайсә Мәсих исеме һәм Аллаһыбыз Рухы белән
юылып чистарындыгыз, изге ителдегез һәм Аллаһы тарафын-
нан акландыгыз.

*Тәнегез белән Аллаһыны данлагыз*

[12] Миңа бар нәрсә рөхсәт ителә, әмма һәммә нәрсә дә фай-
далы түгел. Һәммә нәрсә миңа рөхсәт ителә, әмма минем өс-
тән бернәрсә дә хакимлек итмәскә тиеш. [13] Ризык – карын өчен,
карын – ризык өчен, әмма Аллаһы анысын да, монысын да юк
итәчәк. Тән исә фәхешлек өчен түгел, бәлки Раббы өчен, һәм
Раббы тән өчен була. [14] Аллаһы Раббы Гайсәне үледән терелтте
һәм Үзенең кодрәте белән безне дә терелтәчәк. [15] Әллә сез бел-
мисезме, тәннәрегез – Мәсихнең әгъзалары бит? Шулай бул-
гач, әллә миңа, Мәсихнең әгъзаларын алып, аларны фахишә
әгъзалары итәргәме? Һич тә булмас! [16] Әллә фахишә белән ку-
шылучының аның белән бер тән булуын да белмисезме? Чөнки

Изге язмада: «Икесе дә бер тән булыр», – дип язылган. 17 Ә инде
Раббы белән кушылучы Аның белән рухи яктан бер була.
18 Фәхешлектән качыгыз! Кеше эшләгән һәр гөнаһ тәннән
читтә була, ә фәхешлек итүче үз тәненә каршы гөнаһ кыла.
19 Сезнең тәнегез – Изге Рухның йорты. Изге Рух сезгә Алла-
һы тарафыннан бирелде һәм сездә яши. Әллә сез моны бел-
мисезме? Һәм сез дә үзегезнеке түгел. 20 Чөнки сез кыйбат
хакка сатып алындыгыз. Шуңа күрә тәнегез белән Аллаһыны
данлагыз.

*Никах турында*

7 1 Инде миңа язганнарыгызга килгәндә, ир кешенең ха-
тын-кыз белән җенси мөнәсәбәткә кермәве яхшы, 2 әмма,
фәхешлек булмасын өчен, һәр ирнең үз хатыны һәм һәр
хатынның үз ире булсын. 3 Ир – хатынына, ә хатын иренә ка-
рата үз бурычын үтәсен. 4 Хатын үз тәненә үзе хуҗа түгел, ире
хуҗа; шуның кебек, ир дә үз тәненә үзе хуҗа түгел, бәлки хаты-
ны хуҗа. 5 Дога кылу өчен билгеләнгән вакытка читләшүне
исәпкә алмаганда, ике якның да ризалыгыннан башка бер-бе-
регездән читләшмәгез. Аннан соң тагын бергә кушылыгыз.
Шулай итеп, шайтан, тотнаксызлыгыгыздан файдаланып, сезне
аздыра алмас. 6 Хәер, моны әмер итеп түгел, бәлки ташлама
ясап әйтәм. 7 Чөнки бар кешеләрнең дә минем кебек булула-
рын телим. Әмма һәркемнең Аллаһыдан бирелгән сәләте бар:
берәүнең мондый, ә икенче берәүнең башка төрле.
8 Никахта тормаганнарга һәм тол хатыннарга әйтәм: аларга
минем кебек калу яхшырак булыр. 9 Әмма инде түзә алмасалар,
өйләнсеннәр яки кияүгә чыксыннар. Чөнки җенси дәрт белән
януга караганда, өйләнү яки кияүгә чыгу яхшырак.
10 Ә инде өйләнгәннәргә һәм кияүдәгеләргә мин түгел, Раббы
әмер итә: хатын иреннән аерылмасын. 11 Әгәр аерыла икән, ул
чакта ирсез торсын яки үз ире белән яңадан килешсен. Ир дә
үз хатынын ташламасын.
12 Ә башкаларга, Раббы түгел, мин әйтәм: әгәр берәр иманда-
шыңның иман итмәүче хатыны булса һәм хатын аның белән
яшәргә риза икән, ир аны ташламаска тиеш. 13 Берәр хатынның
ире иман итми икән һәм ир аның белән яшәргә риза булса, ха-
тын аны ташламаска тиеш. 14 Чөнки иман итмәүче ир иманлы
хатын аша һәм иман итмәүче хатын иманлы ир аша изге ите-
лә. Югыйсә сезнең балаларыгыз саф булмас иде; ә болай изге
булалар.
15 Иман итмәүче аерылырга теләсә, аерылсын. Мондый хәл-
дә иман итүче ир яки хатын-кыз бер-беренә бәйләнмәгәннәр.

Аллаһы безне имин яшәргә чакырды. [16] Әй син, хатын, иреңне
коткара алмаячагыңны каян беләсең? Яки, әй син, ир, хаты-
ныңны коткара алмаячагыңны каян беләсең?

*Аллаһы чакырганча яшә*

[17] Һәркем Раббы билгеләгәнчә һәм Аллаһы чакырганча яшә-
сен. Барлык иман итүчеләр бердәмлекләренә минем күрсәтмәм
шундый. [18] Сөннәтле берәү Аллаһыга чакырылган икән, сөн-
нәтле булуын юк итмәсен. Аллаһыга сөннәтсез чакырылган
икән, сөннәтсез булып кала бирсен. [19] Сөннәт тә, сөннәтле
булмау да бернәрсә түгел, бәлки Аллаһы әмерләрен үтәү генә
мөһим. [20] Һәркем Аллаһыга чакырылганда нинди хәлдә булса,
шулай кала бирсен. [21] Аллаһыга чакырылганда син кол идеңме?
Бу сине борчымасын, әмма азат була алсаң, бу мөмкинлектән
файдалануың яхшырак.* [22] Чөнки Раббы тарафыннан чакырыл-
ган кол – Аның ирекле кешесе. Ә хөр хәлдә чакырылган кеше –
Мәсихнең колы. [23] Сез кыйбат хакка сатып алындыгыз, шуңа
күрә кешеләрнең коллары булмагыз. [24] Имандашлар, Аллаһыга
нинди хәлдә чакырылган булсагыз, шул хәлдә калыгыз.

*Кияүгә чыкмаган кызларга киңәш*

[25] Никахка кермәгәннәргә карата Раббыдан әмерем юк, фә-
кать, Раббының мәрхәмәте белән Аңа турылыклы буларак, ки-
ңәш бирәм. [26] Хәзерге заманның авыр шартларын истә тотып,
кеше нинди хәлдә булса, аңа шул хәлдә калу яхшырак дип
исәплим. [27] Син хатын белән кушылдыңмы? Аерылу турында
уйлама. Хатынсыз калдыңмы? Хатын эзләмә. [28] Хәер, өйләнсәң
дә, гөнаһ кылмассың. Кыз кеше дә, кияүгә чыга икән, гөнаһ
кылмас. Әмма андыйларның бу тормышта мәшәкатьләре күп бу-
лачак. Ә мин сезне бу мәшәкатьләрдән саклап калырга телим.
[29] Имандашлар, сезгә шуны әйтәм: вакыт инде аз, моннан
ары хатынлылар хатынсыз кебек, [30] елаучылар еламаучылар
кебек, шатланучылар шатланмаучылар кебек, сатып алучылар
сатып алмаучылар кебек, [31] бу дөнья белән файдаланучылар
файдаланмаучылар кебек булсыннар. Чөнки бу дөньяның хә-
зерге рәвеше үтеп бара.
[32] Ә мин сезнең мәшәкатьсез яшәвегезне телим. Өйләнмәгән
кеше, Раббыга ярарга дип, Аның эшләре хакында мәшәкатьлә-
нә, [33] ә өйләнгән кеше хатынына ярарга тырыша, дөньяви эш-
ләр турында кайгырта һәм аның игътибары төрле якка юнәлә.

---

* **7:21** Бу өлешне болай да аңларга мөмкин: «Хәтта мондый мөм-
кинлегең булса да, кол хәлендә калуың яхшырак».

34 Кияүгә чыкмаган кыз яки гыйффәтле кыз, тәнем һәм рухым
белән изге булыйм дип, Раббы турында борчыла, ә инде кияүгә
чыккан хатын иренә ярарга тырыша, дөньяви эшләр турында
кайгырта. 35 Мин моны богау салу өчен түгел, бәлки Раббы өчен
әдәпле рәвештә, чын күңелдән бирелеп, игътибарыгызны читкә
юнәлтмичә яшәвегезне теләп, сезнең файдага сөйлим.

36 Әгәр берәү үз кызының инде яше җитеп тә кияүгә чыкмый
калуын килешсез дип исәпләсә, теләгәнен кылсын – гөнаһ
булмас. Алар өйләнешсеннәр. 37 Күңеле белән какшамыйча
нык торып, һичнинди кысынкылык сизмичә, үз ихтыярын ку-
лында тотып тора алган кеше кызын кияүгә бирмичә үз янында
тотарга күңеленнән карар итә икән, ул яхшы эшли. 38 Шунлык-
тан, кызын кияүгә бирүче яхшы эшли, ә инде кияүгә бирмәүче
тагын да яхшырак эшли.*

39 Ире исән чакта хатын аңа бәйле. Ире үлгәч, кемгә теләсә,
шуңа кияүгә чыгарга иркле, әмма Раббыга иман итүчегә генә.
40 Әмма кияүгә чыкмаса, хатын бәхетлерәк була. Мин шулай
уйлыйм, Изге Рух та миңа киңәш бирә дип саныйм.

*Потларга корбан ителгән ризык турында*

**8** 1 Потларга корбан ителгән ризык турында һәммәбез беләбез, чөнки белемебез бар. Ләкин белем тәкәбберләндерә,
ә мәхәббәт көч бирә. 2 Кем дә кем нәрсәдер беләм дип уй-
лый икән, ул әле тиешенчә белми. 3 Аллаһыны яратучы исә
Аның тарафыннан таныла.

4 Шулай итеп, потларга корбан ителгән ризыкларны ашауга
килгәндә, без шуны беләбез: потлар дөньяда бернәрсә түгел, һәм
Аллаһыдан башка илаһ юк. 5 Чөнки җирдә яисә күктә илаһ-
лар дип аталганнар булса да (чыннан да, күп «илаһлар» һәм күп
«хуҗалар» бар), 6 безнең бер генә Аллаһы Атабыз бар. Бөтен
нәрсә – Аңардан, һәм без Аның өчен яшибез. Бер Раббы –
Гайсә Мәсих бар, һәрнәрсә Аның аркылы булды һәм без Аның
аша яшибез.

* 7:36-38 Бу аятьләрне болай да аңларга мөмкин: «36 Әгәр берәү үз кәләшенә карата килешмәгәнне эшлим дип саный икән һәм үзенең
көчле җенси теләген тыеп тора алмыйча, өйләнергә тиеш дип
исәпләсә, теләгәнен эшләсен. Андыйлар өйләнешсеннәр, гөнаһлы
булмаслар. 37 Күңеле белән какшамыйча нык торып, һичнинди кы-
сынкылык сизмичә, үз ихтыярын кулында тотып тора алган кеше
кәләшенең сафлыгын сакларга күңеленнән карар итә икән, ул ях-
шы эшли. 38 Шунлыктан, кәләше белән никахланучы яхшы эшли,
ә өйләнмәүче тагын да яхшырак эшли».

7 Әмма барлык кешеләрдә дә андый белем юк. Потларны
таныганлыктан, корбан ителгән ризыкны потка табыну дип са-
нап ашаганга, кайберәүләрнең зәгыйфь вөжданнары пычрана.
8 Ризык безне Аллаһыга якынайтмый, чөнки ашап без һичнәрсә
казанмыйбыз, ашамыйча да һичнәрсә югалтмыйбыз.
9 Әмма сак булыгыз: бу хөрлегегез иманы зәгыйфь булган-
нарны вәсвәсәгә төшерергә сәбәп булмасын. 10 Чөнки иманы
зәгыйфь булган берәү сине, белемлене, потханәдә өстәл артын-
да утырганда күрсә, потларга корбан ителгән ризыкны ашар-
га ярый икән, дип уйламасмы? 11 Синең белемең бу зәгыйфь
имандашыңны һәлак итәр. Мәсих шундый кеше өчен дә үлде
бит. 12 Имандашларга карата шул рәвешчә гөнаһ кылуыгыз һәм
аларның зәгыйфь вөжданын яралавыгыз белән сез Мәсихкә
карата да гөнаһ кыласыз. 13 Менә шуңа күрә мин ашаган ризык
имандашымны вәсвәсәгә төшерергә сәбәпче булса, аны вәсвә-
сәләндермәү өчен һичкайчан ит ашамам.

*Рәсүлнең хокуклары*

9 1 Мин хөр түгелмени? Мин әллә рәсүл түгелме? Мин Раббы-
быз Гайсәне күрмәдемме әллә? Сез – Раббы миңа тапшыр-
ган хезмәтемнең җимеше түгелмени? 2 Әгәр башкаларга рә-
сүл түгелмен икән, сезнең өчен – рәсүл, чөнки Раббы белән
берләшкән булуыгыз – минем рәсүллегемә дәлил.
3 Мине гаепләүчеләргә каршы шулай җавап бирәм. 4 Әллә
безнең ашарга һәм эчәргә хакыбыз юкмы? 5 Яки башка рәсүл-
ләр, Раббының энеләре һәм Кифас кебек, иманлы хатыныбыз-
ны үзебез белән сәяхәткә алырга хакыбыз юкмы? 6 Яисә бары
Барнабның һәм минем генә гомер итү өчен эшләмәскә хакы-
быз юкмы?
7 Кайчан да булса кем үз хисабына гаскәри булып хезмәт итә?
Йөзем бакчасы утырткан кеше аның җимешләрен ашамас
микән? Кемдер көтү көтеп тә үзе көткән көтүнең сөтен эчмәс
микән? 8 Мин боларны кеше уйлаганча гына сөйлимме? Канун
да шул хакта сөйли түгелме соң? 9 Муса канунында: «Ашлык
сугучы үгезнең авызын томалама», – дип язылган бит. Әллә
Аллаһы үгезләр хакында кайгыртамы? 10 Муса кануны безнең
өчен сөйләмимени? Әйе, бу безнең өчен язылган, чөнки сөрү-
че, уңыштан үз өлешемне алырмын, дигән өмет белән сөрергә
тиеш, ашлык сугучы да шундый ук өмет белән сугарга тиеш.
11 Арагызда рухи орлык чәчкәнбез икән, сездән матди уңыш
алырга хакыбыз юкмы? Әллә бу бик күпме? 12 Әгәр башкалар-
ның сездән ярдәм алырга хокукы бар икән, безнең хокукыбыз
тагын да күбрәк түгелме соң?

Әмма без бу хокуктан файдаланмадык, бәлки, Мәсих турын-
дагы Яхшы хәбәргә комачауламас өчен, бар нәрсәгә түзәбез.
13 Аллаһы Йортында эшләүчеләрнең Аллаһы Йортыннан тук-
лануларын белмисезме әллә? Яки корбан китерү урынында
хезмәт итүчеләрнең шунда китерелгән корбаннардан өлеш алу-
ларын белмисезме? 14 Шуның кебек үк Раббы да Яхшы хәбәр-
не игълан итүчеләргә әлеге хезмәт хисабына көн күрергә әмер
бирде.
15 Әмма мин үзем бу хокукларның берсеннән дә файдалан-
мадым. Һәм бу сүзләрне сездән ярдәм көтеп язмыйм. Чөнки
мактанычымны кемнең дә булса юкка чыгаруына караганда,
минем өчен үлем яхшырак. 16 Мин Яхшы хәбәр игълан итәм
икән, мактанырлык бернәрсә юк, чөнки бу – минем тиешле
вазифам. Әгәр Яхшы хәбәр таратудан туктасам, башкаема кай-
гы-хәсрәт килсен! 17 Моны үз теләгем белән эшләсәм, савабы
булачак; әгәр үз ихтыярым белән эшләмәсәм, мин бары үземә
ышанып тапшырылган хезмәтне башкарам. 18 Минем өчен са-
вап нинди булачак? Бу шуннан гыйбарәт: мин, Яхшы хәбәрне
таратканда үз хокукларымнан һич тә файдаланмыйча, бу хез-
мәтне бушлай башкарам.
19 Чөнки, барсыннан хөр булсам да, тагын да күбрәк кешене
Аллаһыга китерү өчен, мин һәммәсенә кол булдым. 20 Яһүдләр-
не Аллаһыга китерү өчен, аларга яһүд кебек булдым; Муса ка-
нунын тотучыларны Аллаһыга китерү өчен, үзем канун астын-
да булмасам да, алар алдында канун астындагы кебек булдым.
21 Муса канунын белмәгәннәрне Аллаһыга китерү өчен, алар
алдында канунны белмәүче кебек булдым. Әлбәттә, бу – мин
Аллаһы канунын тотмыйм дигән сүз түгел, киресенчә, мин
Мәсих канунына буйсынам. 22 Зәгыйфьләрне Аллаһыга ките-
рим дип, зәгыйфьләргә зәгыйфь кебек булдым. Ничек кенә
булмасын, кайберләрен генә булса да коткарыйм дип, мин ба-
рысына үзләре кебек булдым. 23 Яхшы хәбәрнең фатихаларын
уртаклашу өчен, мин боларның һәммәсен Яхшы хәбәр бәрабә-
ренә эшлим.
24 Ярыш мәйданында йөгерүчеләрнең һәммәсенең йөгерүен,
әмма бүләкне берсенең генә алуын белмисезме әллә? Шулай
булгач, бүләк алу өчен йөгерегез! 25 Ярышучыларның барысы да
ярышка бик нык әзерләнәләр. Алар моны фани таҗ алу өчен
эшлиләр, ә без фани булмаган таҗ алу өчен эшлибез. 26 Шуның
өчен дә мин максатсыз йөгергән кеше кебек йөгермәм, буш һа-
вага сугучы кебек көрәшмәм. 27 Әмма башкаларга игълан итеп,
үзем савап алу хокукыннан мәхрүм калмас өчен, тәнемне чы-
ныктырам һәм аны үз ихтыярыма буйсындырам.

*Потлар турында кисәтү*

10 [1] Имандашлар, ата-бабаларыгыз белән булган хәлләрне
белми калуыгызны теләмим. Болыт астында торганда
аларның барысын да Аллаһы саклады, алар һәммәсе дә
Кызыл диңгез аша коры җир буйлап чыктылар. [2] Һәммәсенең
болыт астында торулары һәм диңгез аша чыгулары алар өчен
Муса өммәтенә чумдырылу булды. [3] Һәммәсе дә күктән җибә-
релгән бер үк ризыкны ашады. [4] Һәммәсе дә үзләре белән йөр-
гән рухи кыя таштан күктән җибәрелгән бертөрле эчемлекне
эчте; бу кыя таш исә – Мәсих Үзе. [5] Хәер, аларның күпчелеге
Аллаһыга яраклы булмады һәм чүлдә һәлакәткә дучар булды.

[6] Алар яман теләкләргә бирелде. Шундый яман теләкләрдән
саклап, алар белән булган хәлләр безнең өчен сабак булды.
[7] Шулай ук, кайберләре кебек, потка табынучылар булмагыз.
Изге язмада алар хакында: «Халык ашарга һәм эчәргә утырды, ә
аннан соң торып бастылар һәм күңел ачтылар», – дип язылган.
[8] Кайберәүләр фәхешлек иткән кебек, фәхешлек итмик – бер
көн эчендә аларның егерме өч меңе һәлак булды. [9] Кайберәүләр
Мәсихне сынап караган кебек, без Аны сынамыйк – алар елан
чагуыннан үлделәр. [10] Аларның кайберләре сукранган кебек, сез
сукранмагыз – аларны һәлак итүче фәрештә үтерде.

[11] Бу хәлләр башкаларга сабак булсын өчен эшләнелде, ә
безгә, заманнарның ахыры якынлашкан вакытта яшәүчеләргә,
кисәтү ясап язылды. [12] Менә шуңа күрә кем дә кем нык торам
дип уйлый икән, егылмас өчен сак булсын. [13] Сез барлык ке-
шеләргә хас булган сынауга гына дучар буласыз. Аллаһы Үз
вәгъдәсенә турылыклы һәм Ул сез чыдый алмаслык сынауны
рөхсәт итмәячәк. Сыналган вакытыгызда түзеп тору өчен, сезгә
котылу юлын да күрсәтәчәк.

[14] Шуңа күрә, сөеклеләрем, потларга табынудан качыгыз.
[15] Мин сезгә акыллыларга сөйләгән кебек сөйлим. Сөйләгән-
нәрем турында үзегез уйлап карагыз. [16] Без рәхмәт белдергән
шөкрана касәсе Мәсих канына катнашу түгелме? Без сынды-
рып алган икмәк Мәсих тәненә катнашу түгелме? [17] Икмәк бер,
һәм без, күп булсак та, бер тәнне тәшкил итәбез, чөнки бер ик-
мәкне уртаклашабыз.

[18] Исраил халкына карагыз: алар корбан итен ашаучылар,
корбан китерү урынындагы гыйбадәттә катнашучылар түгелме?
[19] Инде сезгә нәрсә әйтим? Пот та, потка китерелгән корбан да
нинди дә булса әһәмияткә ияме? [20] Һич юк. Әмма мәҗүсиләр
корбанны Аллаһыга түгел, бәлки җеннәргә китерәләр. Ә мин
җеннәр белән аралашуыгызны теләмим. [21] Раббы касәсеннән дә,

женнәр касәсеннән дә эчә алмассыз. Бер үк вакытта Раббының
да, женнәрнең дә аш табынында катнашучылар була алмассыз.
22 Әллә без Раббының ачуын чыгарырга телибезме? Әллә без
Аңардан да кодрәтлерәкме?

*Һәммәсен дә Аллаһы даны өчен эшләгез*

23 Һәрнәрсә рөхсәт ителә, әмма һәрнәрсә дә файдалы түгел.
Һәрнәрсә рөхсәт ителә, әмма һәрнәрсә дә гыйбрәтле түгел.
24 Һичкем үзенә файдалыны түгел, бәлки башкаларга файдалы-
ны эзләсен.

25 Ит базарында сатыла торганнарның барысын да ашагыз
һәм, вөжданыгыз тыныч булсын өчен, төпченеп тормагыз.
26 Чөнки Изге язмада язылганча: «Җир һәм җирдәге һәрнәрсә –
Раббыныкы».

27 Әгәр иман итмәүче берәү сезне ашка чакыра һәм сез ба-
рырга телисез икән, вөжданыгыз тыныч булсын өчен тәкъдим
ителгән һәрнәрсәне төпченмичә ашагыз. 28 Ләкин берәү сезгә:
«Бу – потка китерелгән корбан», – дисә, шул берәү һәм вөж-
дан хакына ашамагыз. 29 Вөждан дигәннән, сезнекен түгел, бәл-
ки шул кешенең вөжданын күз алдында тотам. «Ни өчен әле
азатлыгым башка вөждан белән чикләнергә тиеш?» 30 Әгәр мин
ризыкны Аллаһыга рәхмәт әйтеп кабул итәм икән, бу ризык
өчен нигә мине шелтәләргә?

31 Шулай итеп, ашыйсызмы, эчәсезме, яки башка берәр нәр-
сә эшлисезме – һәммәсен дә Аллаһы даны өчен эшләгез.
32 Яһүдләргә дә, грекларга да яисә Аллаһы бердәмлегенә дә
абыну ташы булмагыз. 33 Мин дә үз файдама түгел, бәлки, күп-
ләр котылсын өчен, алар файдасына һәркемгә һәрнәрсәдә
ярарга тырышам бит.

**11** 1 Мин Мәсихтән үрнәк алган кебек, сез дә миннән үрнәк
алыгыз.

*Гыйбадәт кылу тәртибе*

2 Имандашлар, һәрнәрсәдә мине истә тотуыгыз һәм күрсәт-
мәләремне ничек биргән булсам, аларны шулай тотуыгыз өчен
сезне мактыйм.

3 Моны белүегезне телим: һәр ирнең Башы – Мәсих, хатын-
ның башы – ир, ә Мәсихнең Башы – Аллаһы. 4 Баш киеме ки-
еп дога кылучы яки пәйгамбәрлек итүче һәр ир үзенең башын
оятлы итә. 5 Баш киеме кимичә дога кылучы яки пәйгамбәрлек
итүче һәр хатын үзенең башын оятлы итә, чөнки бу – хатын-
ның чәче алдырылган булу белән бер дәрәҗәдә. 6 Чөнки ха-
тын башына кияргә теләми икән, чәче кырылсын, ә инде чәче

алынган яки кырылган булу аның өчен оятлы икән, ул чакта
башына кисен. [7] Шулай итеп, ир кеше, Аллаһының чагылышы
һәм даны булганга күрә, башына кияргә тиеш түгел; ә хатын –
ирнең даны. [8] Чөнки ир – хатыннан түгел, бәлки хатын – ирдән,
[9] һәм ир хатын өчен түгел, бәлки хатын ир өчен яратылган.
[10] Шуңа күрә хатын башында үз өстеннән хакимлекне күрсәт-
кән билге булырга тиеш. Бу – фәрештәләргә дә шуны күрсәтә.
[11] Хәер, Раббы алдында ир хатыннан, хатын ирдән бәйсез тү-
гел. [12] Чөнки хатын ирдән булган кебек, ир дә хатыннан туа. Ә
һәрнәрсә – Аллаһыдан. [13] Үзегез фикер йөртегез: хатын кешегә
башына кимичә Аллаһыга дога кылу килешерме? [14] Безне сәла-
мәт акыл үзе үк өйрәтә: ир кешенең чәче озын икән, бу – аның
өчен хурлык. [15] Әмма хатынның чәче озын икән, бу – аның өчен
дан, чөнки чәч аңа каплавыч итеп бирелгән. [16] Әгәр кем дә булса
бу хакта бәхәсләшергә тели икән, бездә дә, Аллаһы бердәмлек-
ләрендә дә хатын-кызның башына кимәү гадәте юк.

*Раббыны искә алу*

[17] Бирәчәк күрсәтмәләремдә сезне мактамыйм, чөнки сезнең
җыелышларыгыз файдага караганда күбрәк зыян китерә. [18] Бе-
ренчедән, иман итүчеләр бердәмлеге җыелышларыгызда аерым
бер төркемнәргә бүленүегез турында ишетәм һәм мин моңа
берникадәр ышанам да. [19] Чөнки Аллаһы тарафыннан хуплан-
ган кешеләр билгеле булсын өчен фикерләрнең төрле булуы да
кирәк. [20] Сез бергә җыелган вакыт, чыннан да, әле Раббының
кичке ашын ашау дигән сүз түгел. [21] Чөнки һәркем үз ризыгын
башкалардан элегрәк ашарга ашыга, шулай итеп, кайберәүләр
ач кала, кайберәүләр исерә. [22] Ашарга һәм эчәргә сезнең өегез
юкмы әллә? Әллә сез Аллаһы бердәмлеген санга сукмыйсызмы
һәм мохтаҗларны кимсетәсезме? Нәрсә әйтергә сезгә? Моның
өчен сезне мактаргамы? Юк, мактамыйм.
[23] Чөнки сезгә биргән күрсәтмәләрне мин Раббының Үзен-
нән алдым. Раббы Гайсә хыянәткә дучар төнне кулына икмәк
алды [24] һәм, шөкрана иткәннән соң, икмәкне сындырып болай
диде: «Бу – сезнең өчен бирелгән тәнем; Мине искә алу өчен
шулай эшләгез». [25] Шул рәвешчә, кичке аштан соң кулына касә
алып әйтте: «Менә бу касә – Минем каным белән расланган
яңа килешү. Моны эчкән саен, Мине искә алу өчен эчегез».
[26] Чөнки бу икмәкне ашаган һәм бу касәдән эчкән саен, сез
Раббы килгәнгә кадәр Аның үлемен игълан итәсез.
[27] Шулай итеп, кем дә кем, бу йолага хөрмәт күрсәтмичә,
икмәкне ашаса һәм Раббының касәсеннән эчсә, Аның тәне
вә канына каршы гөнаһ кылуда гаепле булыр. [28] Кеше башта

үзен-үзе сынарга тиеш, аннан соң гына бу икмәкне ашый һәм
бу касәдән эчә ала. [29] Чөнки, кемдер Раббы тәненә әһәмият
бирмичә ашый һәм эчә икән, ул шуның белән үзен-үзе хөкемгә
дучар итә. [30] Менә шуңа күрә күбегез зәгыйфь һәм авыру, вафат
булганнар да аз түгел. [31] Ә без үз-үзебезне тикшерсәк, ул чакта
хөкем ителмәс идек. [32] Хөкем ителгәндә исә, дөнья белән бергә
хөкем ителмәс өчен, Раббы безгә Үзе тәрбия бирә.

[33] Шуңа күрә, имандашларым, кичке ашка җыелганда бер-бе-
регезне көтегез. [34] Җыелуыгыз Аллаһы тарафыннан хөкем
ителерлек булмасын өчен, ач кеше өендә ашасын. Ә башка
нәрсәләр хакында яныгызга килгәч күрсәтмә бирермен.

*Изге Рухтан килгән сәләтләр*

**12** [1] Имандашлар, Изге Рухтан килгән сәләтләр хакында да
белми калуыгызны теләмим. [2] Сез беләсез, мәҗүси ва-
кытыгызда, үзегезне кемдер җитәкләп йөрткән сыман,
телсез потларга табынырга йөрдегез. [3] Менә шуның өчен сезгә
әйтәм: Аллаһы Рухы белән сөйләүче беркем дә: «Гайсәгә ләгъ-
нәт», – димәс, һәм бары Изге Рух аша гына: «Гайсә – Раббы», –
дип әйтә алыр.

[4] Изге Рух биргән сәләтләр төрле, әмма Рух бер үк. [5] Хезмәт
итүнең күп төрләре бар, әмма Раббы бер үк. [6] Гамәлләр дә төр-
ле, әмма һәммәсендә һәммә нәрсәне эш итүче – шул ук бер
Аллаһы.

[7] Ә һәрберебездә Рухның уртак файдага эш итүе күренә. [8] Бе-
рәүгә Рух аша хикмәт белән сөйләү осталыгы, икенчесенә шул
ук Рух аркылы белем бирү осталыгы бирелә. [9] Башка берәүгә
шул ук Рух тарафыннан иман бирелә, ә икенче берәүгә шул ук
Рух тарафыннан дәвалау сәләте бирелә. [10] Берәүгә могҗиза күр-
сәтү, берәүгә пәйгамбәрлек итү*, башка берәүгә төрле рухлар-
ны аера белү, кайберәүгә таныш булмаган төрле телләрдә**
сөйләү, башкасына телләрне аңлата белү бирелә. [11] Боларның
һәммәсен дә бер үк Рух эшли һәм һәркемгә сәләтне Үзе телә-
гәнчә бүлеп бирә.

*Тән бер, ә әгъзалар күп*

[12] Мәсих – күп әгъзаларга ия булган тән кебек; тән күп әгъза-
лардан торса да, бер бөтен тәнне тәшкил итә. [13] Без һәммәбез

---

* **12:10** *Пәйгамбәрлек итү* – Аллаһы сүзләрен турыдан-туры кабул итеп, аларны кешеләргә җиткерү.

** **12:10** *Таныш булмаган телләр* – күктән җибәрелгән телләр. Таныш булмаган телдә сөйләүчене Изге Рух рухландыра.

дә: яһүдләр яки греклар, коллар яки иреклеләр, бер Рух белән чумдырылып, Мәсих тәненә кушылдык, һәм һәммәбезгә эчү өчен шул ук Рух бирелде.

[14] Тән исә бер әгъзадан түгел, бәлки күп әгъзалардан тора.
[15] Әгәр аяк: «Мин, кул булмаганга, тәннеке түгел», – дисә, чынлап та ул шуңа күрә генә тәннеке булмасмы? [16] Һәм колак: «Мин, күз булмаганга, тәннеке түгел», – дисә, чынлап та, шуңа күрә генә тәннең бер әгъзасы булмасмы? [17] Әгәр бөтен тән күздән генә торса, ничек ишетә алыр иде? Бөтен тән колактан гына торса, ис сизү тойгысы кайда булыр иде? [18] Әмма ләкин Аллаһы тәндә әгъзаларның һәрберсен Үзе теләгәнчә урнаштырган. [19] Әгәр инде барысы бер әгъза булса, тән кайда булыр иде?
[20] Хәзер исә әгъзалар күп, әмма тән бер генә.

[21] Күз кулга: «Миңа кирәгең юк», – дип, яки баш аякларга: «Сез миңа кирәк түгел», – дип әйтә алмас. [22] Киресенчә, тәннең зәгыйфьрәк күренгән әгъзалары бигрәк тә кирәк. [23] Тәннең аз хөрмәткә ия булып күренгән өлешләрен күбрәк хөрмәт итәбез. Килешсез саналган әгъзаларыбызны без аеруча тырышып каплыйбыз, [24-25] ә инде килешле әгъзаларыбызның моңа ихтыяҗы юк. Әмма тәндә аерымлык булмасын, бәлки барлык әгъзалар бер-берсе турында бер дәрәҗәдә кайгыртсыннар өчен, килешсез әгъзаларга күбрәк хөрмәт күрсәтеп, Аллаһы тәндә әгъзаларны үзара шулай тоташтырды. [26] Шуңа күрә бер әгъза җәфаланса, барлык әгъзалар да аның белән бергә җәфа чигә, бер әгъза хөрмәтләнсә, әгъзаларның һәммәсе дә аның белән бергә шатлана.

[27] Сез – Мәсихнең тәне, ә аерым-аерым – шул ук тәннең әгъзалары. [28] Аллаһы Үз бердәмлегендә берәүләрне рәсүлләр, икенчеләрне пәйгамбәрләр, өченчеләрне өйрәтүчеләр итеп куйды. Аннары кайберәүләргә могҗизалар тудыру кодрәте, дәвалау, башкаларга ярдәм итү, идарә итү һәм таныш булмаган телләрдә сөйләү сәләте бирде. [29] Барысы да рәсүлләрме? Барысы да пәйгамбәрләрме? Барысы да өйрәтүчеләрме? Барысы да могҗиза тудыручылармы? [30] Һәммәсенең дә дәвалау сәләте бармы? Барысы да таныш булмаган телләрдә сөйлиме? Барысы да бу телләрне аңлата аламы? [31] Зуррак сәләтләргә ашкыныгыз. Мин сезгә иң яхшы юлны күрсәтермен.

*Чын мәхәббәт*

**13** [1] Кешеләр һәм фәрештәләр теле белән сөйләшсәм дә, әгәр миндә мәхәббәт юк икән, ул чакта мин яңгыравык бакыр яки чыңлавык тәлинкә кебек кенә булыр идем.
[2] Пәйгамбәрлек итү сәләтем булса да, барлык серләрне һәм һәртөрле гыйлемне белсәм дә, таулар күчерерлек иманым булса да,

әгәр миндә мәхәббәт юк икән, мин берни булмас идем. 3 Бөтен
мөлкәтемне өләшеп, тәнемне яндырырга тапшырсам да*, әгәр
мәхәббәт юк икән, миңа моннан бернинди дә файда булмас иде.
4 Мәхәббәт түземле, шәфкатьле, көнләшми, мактанмый, тә-
кәбберләнми, 5 дорфа түгел, үз файдасын эзләми, ярсымый,
яман эшләрне истә тотмый. 6 Мәхәббәт ялганга сөенми, бәлки
хакыйкатькә шатлана. 7 Ул барысына да түзә, бар нәрсәгә
ышана, һәрнәрсәгә өметләнә һәм сабыр итә. 8 Пәйгамбәрлек
итүләр тукталыр, телләр тынар һәм белем юкка чыгар, әмма
мәхәббәт беркайчан да бетмәс. 9 Безнең белемебез дә, пәйгам-
бәрлек итүебез дә өлешчә генә бит. 10 Ә камил нәрсә килгәч,
өлешчә генә булган нәрсә югалачак. 11 Мин бала чагында бала-
ларча сөйләдем, балаларча уйладым, балаларча фикер йөрттем,
ә инде үсеп җиткәч, бала вакыттагы эшләрне ташладым. 12 Хәзер
без, тонык көзге аркылы карагандай, чагылыш кына күрәбез, ә
инде ул вакытта, турыдан-туры йөзгә-йөз күрәчәкбез. Минем
белемем хәзер өлешчә, ә инде ул вакытта, Аллаһы мине ничек
тулы белә, мин дә тулысынча беләчәкмен.
13 Менә һәрвакыт булачак өч нәрсә: иман, өмет һәм мәхәб-
бәт. Ә мәхәббәт аларның иң бөеге.

### *Таныш булмаган телләр һәм пәйгамбәрлек итү*

**14** 1 Мәхәббәтне максат итеп, Изге Рухтан килгән сәләт-
ләргә, бигрәк тә пәйгамбәрлек итү сәләтенә ашкыны-
гыз. 2 Күктән бирелгән таныш булмаган телдә сөйләү-
че кешеләргә түгел, бәлки Аллаһыга сөйли. Чөнки аны һичкем
аңламый, ул Изге Рух ярдәмендә серләр сөйли. 3 Пәйгамбәрлек
итүче исә кешеләрне ныгыту, аларның рухларын күтәрү һәм
алар юаныч тапсын өчен сөйли. 4 Таныш булмаган телдә сөй-
ләүче үзен ныгыта, ә пәйгамбәрлек итүче – иман итүчеләр бер-
дәмлеген ныгыта. 5 Мин шуны телим: сез барыгыз да таныш
булмаган телләрдә сөйләгез, әмма тагын да яхшысы – пәйгам-
бәрлек итегез. Пәйгамбәрлек итүче таныш булмаган телләрдә
сөйләүчедән өстенрәк, әгәр таныш булмаган телләрдә сөйләүче
үз сүзләрен кешеләргә иман итүчеләр бердәмлеген нәсыйхәт
итү өчен аңлата алмаса.
6 Имандашлар, хәзер яныгызга килеп, таныш булмаган тел-
ләрдә сөйлим, һәм сезгә Аллаһыдан ачылыш яки пәйгамбәр-
лек сүзе, яисә тәгълимат бирмим икән, ни файда китерермен

---

* 13:3 *Тәнемне яндырырга тапшырсам да* – Кайбер кулъязмаларда бу мәгънә урынына «мактану өчен тәнемне үлемгә тапшырсам да» дигән мәгънә бар.

сезгә? 7 Шуның кебек үк, сыбызгы яки курай кебек тавыш чы-
гаручы җансыз әйберләр бер-берсенә охшамаган көй чыгарма-
салар, сез аларның көен танырсызмы? 8 Әгәр быргы аңлаешсыз
аваз чыгарса, сугышка кем әзерләнер? 9 Менә шулай сез дә те-
легез белән кеше төшенмәслек сүзләр әйтәсез икән, ничек
сөйләгәнегезне аңларлармы? Сез җилгә генә сөйләгән булыр-
сыз. 10 Дөньяда күп төрле телләр бар, һәм аларның һәрберсенең
үз мәгънәсе бар. 11 Әгәр әйтелгән сүзнең мәгънәсен аңламасам,
ул чакта мин сөйләүче өчен чит ил кешесе булган кебек, сөйләү-
че дә минем өчен чит ил кешесе кебек була. 12 Сезнең белән дә
шулай ук: рухи сәләтләргә омтылып, иман итүчеләр бердәмле-
ген нәсыйхәт итәчәк сәләтләрне мул кулланырга тырышыгыз.

13 Шуңа күрә, таныш булмаган телдә сөйләүче аңлата белү
өчен дога кылсын. 14 Чөнки мин таныш булмаган телдә дога
кылсам, рухым дога кыла, ә акылым анда катнашмый кала.
15 Нәрсә эшләргә соң? Рухым белән дога кылырмын, һәм акы-
лым белән дә дога кылырмын, рухым белән данлап җырлар-
мын, һәм акылым белән дә данлап җырлармын. 16 Югыйсә, ру-
хың белән генә Аллаһыга шөкер иткәндә, синең әйткәнеңне
аңламаучы гади кеше рәхмәт укуыңа ничек «амин» дип риза-
лыгын белдерер? 17 Син һичшиксез яхшы шөкер итәсең, әмма
башка берәү моннан нәсыйхәт алмый. 18 Барыгызга караганда
күбрәк телләрдә сөйләгәнем өчен Аллаһыма шөкер итәм. 19 Әм-
ма иман итүчеләр бердәмлегендә таныш булмаган телдә ун мең
сүз әйтүгә караганда, башкаларга да нәсыйхәт булсын өчен,
акыл белән биш сүз әйтүне яхшырак дип саныйм.

20 Имандашлар! Уйларыгыз балаларныкы кебек булмасын.
Яманлыкка карата балалар кебек, ә фикер йөртү рәвешегез бе-
лән балигъ булган кешеләр сыман булыгыз. 21 Канунда болай дип
язылган: «Бу халыкка сәер телләрдә сөйләүче кешеләр аша, чит
кешеләрнең авызлары белән сөйләрмен, – ди Раббы, – әмма ул
чакта да мине тыңламаслар». 22 Димәк, таныш булмаган телләр –
иманлылар өчен түгел, бәлки иман итмәүчеләр өчен билге. Пәй-
гамбәрлек итү исә иман итмәүчеләр өчен түгел, бәлки иманлылар
өчен. 23 Шулай итеп, бөтен иман итүчеләр бердәмлеге бергә җые-
лып, һәммәсе таныш булмаган телләрдә сөйләгәндә сез сөйлә-
гәнне аңламаучы гади кешеләр яки иман итмәүчеләр кереп,
алар: «Сез тилерәсез», – димәсләрме? 24 Әмма барысы да пәйгам-
бәрлек иткәндә аңламаучы бер гади кеше яки иман итмәүче ки-
леп керсә, ул, гаепләре өчен, барысы тарафыннан да фаш ителер,
барысы тарафыннан да хөкем ителер; 25 шулай итеп, аның йөрәк
серләре барысына ачылыр, һәм ул: «Чынлап та, Аллаһы сезнең
белән», – дияр һәм сәҗдә кылып Аллаһыга табыныр.

*Һәрнәрсә тәртипле һәм килешле булсын*

[26] Димәк, имандашлар, инде хәзер нәрсә? Сез бергә җыелган
вакытта һәрберегезнең мәдхиясе, тәгълиматы, таныш булмаган
телдә хәбәре, Аллаһыдан ачылышы, аңлатмасы бар. Болар исә
һәммәсе дә бердәмлекне рухи яктан ныгыту өчен булсын.
[27] Кем дә булса таныш булмаган телдә сөйли икән, берәү аңла-
тып торсын. Ә ике яки иң күбе өч кеше бер-бер артлы сөйли
ала. [28] Аңлатучы булмаса, ул чакта бердәмлектә сөйләүче дәш-
мәсен, үзенә һәм Аллаһыга гына сөйләсен.

[29] Пәйгамбәрләр дә икәү яки өчәү сөйләсеннәр, ә башкалар
сөйләнелгән буенча фикер йөртеп, аларга бәя бирсен. [30] Җые-
лышта утыручылар арасыннан берәүгә Аллаһыдан ачылыш
килсә, беренче сөйләүче аңа сүз әйтергә мөмкинлек бирсен.
[31] Чөнки һәммәгез дә өйрәнсен, һәммәгез дә файда алсын өчен,
бер-бер артлы пәйгамбәрлек итә аласыз. [32] Пәйгамбәрләрнең
рухлары да пәйгамбәрләргә буйсына, [33] чөнки Аллаһы – тәр-
типсезлек Аллаһысы түгел, бәлки тынычлык Аллаһысы.

Изгеләрнең барлык бердәмлекләрендәге кебек, [34] хатынна-
рыгыз бердәмлек җыелышларында дәшмәсеннәр, чөнки аларга
анда сөйләргә рөхсәт ителми. Муса канунында әйтелгәнчә, алар
буйсынучан булырга тиеш. [35] Алар нәрсә турында булса да бе-
лергә тели икән, өйләрендә ирләреннән сорасыннар. Чөнки
хатыннар өчен бердәмлек җыелышында сөйләү хурлык санала.

[36] Аллаһы сүзе сездән чыктымы әллә? Әллә сезгә генә ireш-
теме? [37] Үзен пәйгамбәр яки рухи яктан бик сәләтле дип исәплә-
гән кеше сезгә язганнарымның Раббы әмере икәнен танысын.
[38] Әгәр танымаса, ул да танылмасын*. [39] Шулай итеп, имандаш-
лар, пәйгамбәрлек итәргә ашкынығыз, әмма таныш булмаган
телдә сөйләүне дә тыймагыз. [40] Тик һәрнәрсә тәртипле һәм ки-
лешле булырга тиеш.

*Гайсәнең үледән терелүе*

**15** [1] Имандашлар, үзем сөйләгән Яхшы хәбәрне исегезгә тө-
шереп китәм. Сез аны кабул иттегез һәм анда нык тора-
сыз. [2] Мин игълан иткән Яхшы хәбәр сүзләрен тотсагыз,
котыласыз. Югыйсә, юкка гына иман китергән булып чыгасыз.

[3] Чөнки һәрнәрсәдән элек мин үзем кабул иткәнне сезгә тап-
шырдым, ә иң мөһиме: Мәсих, Изге язмада язылганча, безнең
гөнаһларыбыз өчен үлде, [4] күмелде һәм, Изге язмада әйтелгәнчә,

---

* **14:38** Бу аятьне болай да аңларга мөмкин: «Томана икән, томана булсын».

өченче көндә үледән терелтелде, [5] элек Кифаска, аннан соң унике рәсүлгә күренде. [6] Шуннан бер үк вакытта биш йөздән артык имандашка күренде. Аларның күбесе әлегә кадәр исән-сау, ә кайберләре инде үлде. [7] Шуннан соң Ул Ягъкубка, шулай ук барлык рәсүлләргә күренде. [8] Ә инде һәммәсеннән соң, мин «җитлекми туган бала» сыман булуга карамастан, миңа да күренде. [9] Чөнки мин – рәсүлләрнең иң әһәмиятсезе, һәм рәсүл дип аталырга лаеклы да түгелмен, чөнки Аллаһы бердәмлеген эзәрлекләдем. [10] Әмма хәзер мин кем булсам, Аллаһы мәрхәмәте белән булдым. Ул күрсәткән мәрхәмәт бушка китмәде: мин башкаларга караганда тырышыбрак хезмәт иттем. Хәер, мин түгел, бәлки минем белән булган Аллаһы мәрхәмәте хезмәт итте.
[11] Шулай итеп, минме, алармы, без шуны игълан итәбез, һәм сез шуңа иман иттегез.

*Үледән терелү*

[12] Мәсих үледән терелтелгән дип игълан ителгәч, ничек сезнең кайберләрегез, үлгәч терелү юк, дип сөйли ала соң? [13] Үледән терелү юк икән, Мәсих тә үледән терелтелмәгән булып чыга.
[14] Әгәр Мәсих терелеп тормаган икән, безнең хәбәребез дә, сезнең иманыгыз да буш була. [15] Моннан тыш без Аллаһы хакында да ялган шаһитләр булыр идек, чөнки, Ул Мәсихне үледән терелтеп торгызды, дип шаһитлек иттек. Хәлбуки, үлеләрнең терелүе булмагач, Аллаһы Мәсихне дә терелтеп торгызмаган булып чыга. [16] Чөнки, үлеләр терелтелми икән, Мәсих тә үледән терелтелмәгән була. [17] Әгәр Мәсих терелеп тормаган икән, иманыгыз – буш, сез әле дә үз гөнаһларыгыз белән бергә. [18] Бу инде – Мәсихкә иман итеп үлгәннәр дә һәлак булдылар дигән сүз. [19] Мәсихкә бу тормышта гына өмет багласак, без барлык кешеләргә караганда да кызганычрак.

[20] Әмма ләкин чыннан да Мәсих үлеләр арасыннан беренче булып терелеп торды. [21] Чөнки, үлем кеше аша килгән кебек, үледән терелеп тору да бер Кеше аша килде. [22] Адәм аркасында һәммәсе үлгән кебек, Мәсих бәрабәренә һәммәсе яңадан терeләчәк. [23] Һәркем үз чиратында: беренче булып Мәсих, соңыннан, Ул килгәндә, Аныкылар терeләчәк. [24] Шуннан соң ахыры килер, Ул, һәртөрле җитәкчелекне, хакимиятне, кодрәтне юкка чыгарып, Патшалыкны Ата-Аллаһыга тапшырачак. [25] Чөнки барлык дошманнарын Үз аягы астына салганга кадәр Мәсих патшалык итәргә тиеш. [26] Һәм соңгы дошман – үлем юкка чыгарылачак. [27] Чөнки Изге язмада әйтелгәнчә, «Аллаһы һәрнәрсәне Аның аягы астына салып буйсындырды». Һәрнәрсә Мәсихкә буйсындырылды диелгән икән, аңлашыла ки, һәрнәрсәне

Аңа Буйсындыручы Аллаһыдан башка буйсындырылды. [28] Ә инде
һәрнәрсәне Мәсихкә буйсындыргач, Угыл Үзе дә һәрнәрсәне
Аңа Буйсындыручыга буйсыначак, шулай итеп, Аллаһы һәммә
нәрсәдә бар нәрсә булачак.

[29] Югыйсә, ник үлеләр өчен суга чумдырылу йоласын үти-
ләр? Үлеләр бөтенләй терелеп тормагач, ник үлеләр өчен моны
эшлиләр? [30] Ни өчен без үзебез һәрвакыт куркыныч астында
торабыз? [31] Мин һәр көн үлем белән йөзгә-йөз очрашам. Иман-
дашлар, бу турыда сезнең өчен кичергән горурлыгым белән
Раббыбыз Мәсих Гайсә алдында ант итәм. [32] Гади кешеләр ке-
бек уйлаганда, үлеләр терелтелмәсә, Эфестә ерткычлар белән
көрәшүемнән миңа ни файда? Үлеләр терелтелмәсә, «ашыйк,
эчик, чөнки иртәгә үләчәкбез!»

[33] Алданмагыз: «азгын кешеләр белән аралашу яхшы әхлакны
боза». [34] Кирәгенчә айныгыз һәм гөнаһ кылмагыз. Чөнки сезгә
оят булсын өчен әйтәм: кайберләрегез Аллаһыны белми.

*Җир һәм күк тәннәре*

[35] Кем дә булса: «Үлеләр ничек терелеп торачаклар? Һәм алар-
ның тәне нинди булыр?» – дип сорый ала. [36] Әй акылсыз! Син
чәчкән нәрсә, башта үлмәсә, терелмәячәк. [37] Син, чәчкәндә, бу-
лачак үсемлекнең үзен түгел, бәлки бер орлыкны – бодай яки
нинди дә булса башка орлыкны чәчәсең. [38] Әмма Аллаһы аңа ни-
чек теләсә, шундый тән бирә, һәр орлыкка үз тәнен бирә. [39] Һәр
тән бертөрле түгел. Кешеләрнең тәне башка, хайваннарныкы
башка, балыкларның, кошларның да тәне башка. [40] Күктәге җи-
семнәр дә, җирдәге җисемнәр дә бар, әмма күктәге җисемнәр-
нең гүзәллеге җирдәге җисемнәрнекеннән аерыла. [41] Кояшның
да, айның да, йолдызларның да җемелдәүләре башка. Йолдыз-
лар да үзара җемелдәүләре ягыннан бер-берсеннән аерыла.

[42] Үлеләр терелеп торганда да шулай булачак. Тән чери тор-
ган булып күмелә, ә мәңге үлми торган булып терелтелә.
[43] Кимсетелеп күмелә, данланып терелеп тора. Зәгыйфь килеш
күмелә, көчле булып терелеп тора. [44] Канлы тән күмелә, рухи
тән* терелеп тора. Канлы тән бар икән, рухи тән дә бар. [45] Изге
язмада болай дип язылган: «Беренче кеше – Адәм – тере җан
иясе булды»; ә соңгы Адәм – тормыш бирүче Рух. [46] Әмма бе-
ренче булып рухи түгел, бәлки канлы тәннән торган килде,
аннан соң гына рухи килде. [47] Беренче кеше туфрак белән яра-
тылды, ул – җирдән. Икенче Кеше – күктән. [48] Җирнекеләр
туфрак белән яратылган кеше кебек, күкнекеләр күктән булган

---

* **15:44** *Рухи тән* – ягъни Изге Рух тарафыннан тормыш бирелгән тән.

Кеше кебек. 49 Без хәзер туфрак белән яратылган кешенең кы-
яфәтен йөрткән кебек, киләчәктә күктән булган Кешенең
кыяфәтен йөртәчәкбез.
50 Имандашлар, шуны да әйтим: тән һәм каннан торганнар
Аллаһы Патшалыгына ия була алмас, һәм фани да мәңгелеккә
ия була алмас. 51-52 Серне әйтәм сезгә: без барыбыз да үлмәя-
чәкбез, әмма быргының соңгы тавышы яңгыраганда кинәт, күз
ачып йомганчы, һәммәбез үзгәртеләчәкбез. Чөнки быргы кыч-
кырганда үлеләр мәңге үлми торган булып терелеп торачаклар,
һәм без үзгәртеләчәкбез. 53 Димәк, фани булган – мәңгелек
булганга, һәм үләчәк нәрсә үлемсез нәрсәгә үзгәрергә тиеш.
54 Фани булган мәңгелек булганга үзгәргәч, һәм үләчәк нәрсә
үлемсез нәрсәгә үзгәргәч: «Үлем җиңү белән йотылачак»;
55 «Үлем! Синең җиңүең кайда? Үлем! Синең угың кайда?» – дип,
Изге язмада язылган сүзләр тормышка ашар. 56 Үлемнең угы
исә – гөнаһ; ә инде гөнаһның көче – канун. 57 Раббыбыз Гайсә
Мәсих аша безгә җиңү биргән Аллаһыга рәхмәт яусын!
58 Сөекле имандашларым, менә шуның өчен нык торыгыз һәм
какшамас булыгыз. Күрсәткән хезмәтегезнең Раббы алдында
бушка булмаячагын белеп, һәрвакыт Аның эшен бар көчегезне
куеп башкарыгыз.

*Яһүдиядәге иман итүчеләр өчен җыелган иганә*

**16** 1 Изгеләр өчен җыела торган иганәгә килгәндә, мин Гә-
ләтиядәге иман итүчеләр бердәмлекләренә нинди күр-
сәтмә биргән булсам, сез дә шул рәвешчә эшләгез.
2 Мин яныгызга килгәч, сез иганә җыеп йөрмәс өчен, сезнең
һәрберегез атнаның беренче көнендә, хәленә күрә, табышының
бер өлешен аерып куйсын һәм сакласын. 3 Яныгызга килгәч,
иганәгезне тапшыру өчен сез сайлаячак кешеләрне хатлар бе-
лән Иерусалимга җибәрермен. 4 Миңа бару килешле булса, алар
минем белән барырлар.
5 Македуния аша йөргәч, мин яныгызга килермен; чөнки
мин Македуния аша барырмын. 6 Бәлки, беркадәр сезнең янда
яшәрмен, яки, хәтта, кышны да үткәрермен, һәм шулай итеп,
кая барсам да, мине озатып йөри алырсыз. 7 Чөнки хәзер сез-
нең белән аз гына вакытка күрешергә теләмим, бәлки, Раббы
насыйп итсә, беркадәр вакыт яныгызда булырга өмет итәм.
8 Эфестә исә Илленче көн бәйрәменә кадәр калырмын, 9 чөнки
анда, дошманнар күп булуга да карамастан, нәтиҗәле хезмәт
итү өчен ишекләр киң ачылды миңа.
10 Тимуте яныгызга килсә, карагыз аны, бернәрсәгә борчыл-
масын, чөнки ул да минем кебек Раббы эшләрен башкара.

[11] Шуның өчен һичкем аңа илтифатсыз булмасын, бәлки аны минем яныма иминлек белән озатыгыз. Мин аны имандашлар белән бергә көтәм.

[12] Апуллус туганга килгәндә исә, мин аннан имандашлар белән бергә яныгызга баруын бик нык үтендем. Әмма хәзергә ул сезнең янга барырга теләми, ләкин уңай вакыт табуга барыр.

*Соңгы үгетләр һәм сәламнәр*

[13] Иманда торыгыз, уяу, кыю һәм нык булыгыз. [14] Һәрнәрсәне
яратып башкарыгыз.

[15] Имандашлар, минем сезгә бер үтенечем бар. Сез Эстефәнәс гаиләсен беләсез, ул Ахаядә беренчеләрдән булып Мәсихкә иман китерде, һәм алар үзләрен изгеләргә хезмәт итүгә багыш-
ладылар; [16] үзегезне шундыйларга, безнең белән бергә хезмәт күрсәтүчеләргә һәм авыр хезмәт башкаручыларга буйсындыры-
гыз. [17] Мин Эстефәнәснең, Фөртүнәтнең һәм Әхәйкнең килеп житүенә шатмын: алар, сез юк чакта, житешмәгән нәрсәләр
белән мине тәэмин иттеләр. [18] Чөнки алар минем һәм сезнең рухыгызны тынычландырдылар. Мондыйлар хөрмәт ителүгә лаек.

[19] Асия өлкәсендәге иман итүчеләр бердәмлекләре сезне сәламли. Өйләрендәге иман итүчеләр бердәмлекләре белән бергә Әкүл һәм Прискиллә сезгә Раббы исеме белән кайнар сәлам
тапшыра. [20] Мондагы барлык имандашлар сезгә сәлам җибәрәләр. Бер-берегезне изге үбү белән сәламләгез.

[21] Мин, Паул, үз кулым белән язып сезгә сәлам җибәрәм.
[22] Кем Раббыны яратмый, аңа каһәр төшсен. «Марана та* – Раббы, кил инде!»

[23] Раббы Гайсәнең мәрхәмәте сезнең белән булсын. [24] Сез
барыгыз да Мәсих Гайсәнеке. Минем мәхәббәтем сезнең барыгыз белән бергә булсын.

---

* **16:22** *Марана та* – «Раббы, кил инде!» дигән мәгънәгә ия булган арамей телендәге бу сүзләрне шушы чордагы иман итүчеләр дога кылганда еш кулланганнар.

# ПАУЛДАН КӨРИНТЛЕЛӘРГӘ ИКЕНЧЕ ХАТ

**1** 1 Аллаһы ихтыяры белән Мәсих Гайсәнең рәсүле Паулдан
һәм Тимуте имандаштан бөтен Ахаядәге барлык изгеләргә
һәм Көринттәге Аллаһы бердәмлегенә сәлам. 2 Сезгә Атабыз
Аллаһыдан вә Раббы Гайсә Мәсихтән мәрхәмәт һәм иминлек
булсын!

*Паул Аллаһыга шөкер итә*

3 Һәрьяктан ярдәм итүче Аллаһыга һәм шәфкать Атасына,
Раббыбыз Гайсә Мәсихнең Аллаһысы һәм Атасына дан! 4 Алла-
һы безгә бөтен кайгыларыбызда булыша, шуңа күрә Аннан
кабул иткән ярдәм белән без дә һәртөрле кайгылары булган-
нарга булыша алабыз. 5 Чөнки безгә карата Мәсихнең газап-
лары арткан саен, Мәсих аша безнең юанычларыбыз да арткан-
нан-арта бара. 6 Кайгырабыз икән, сез юансын һәм котылсын
өчен кайгырабыз; юанабыз икән, сез дә юанасыз. Без кичергән
шул ук газапларга сез чыдый алсын өчен, сезгә көч бирелә.
7 Һәм сезнең хакта безнең өметебез нык. Чөнки беләбез: газап-
ларыбызны уртаклашасыз икән, Аллаһы биргән ярдәмне дә
уртаклашасыз.
8 Имандашлар, Асия өлкәсендә кичергән михнәтләребез
турында белми калуыгызны теләмибез, без чиктән тыш һәм
көч җитмәслек каты итеп изелдек, хәтта исән калуыбызга да
өметебезне югалткан идек. 9 Үзебезгә-үзебез таяну өчен түгел,
бәлки үлеләрне терелтүче Аллаһыга таяну өчен, без үзебезне
үлемгә хөкем ителгәннәр кебек хис иттек. 10-11 Аллаһы безне
дәһшәтле үлемнән коткарды һәм коткарачак, безнең өчен
кылган догаларыгыз белән безгә сез дә ярдәм иткәнгә күрә,
Аның киләчәктә дә коткарачагына өмет баглыйбыз. Шулай
итеп, күпләрнең ялваруларына җавап итеп безгә бирелгән
мәрхәмәт бүләге хакына күпләр безнең өчен Аллаһыга рәхмәт
укыйлар.

### *Паул ниятен үзгәртә*

[12] Бу – безнең мактанычыбыз: безнең вөжданыбыз: «Без
дөньяда, бигрәк тә сезнең арада, кеше зирәклеге белән түгел,
бәлки Аллаһыдан килүче изгелек һәм Аллаһы мәрхәмәте бе-
лән ихлас күңелдән яшибез», – дип шаһитлек итә. [13] Без бит
сез укый һәм аңлый торганнарны гына язабыз. Сез безне
инде өлешчә аңлыйсыз, ә мин тулысынча аңларсыз дип өмет
итәм. [14] Шулай итеп, Раббыбыз Гайсә көнендә без сезнең
мактанычыгыз булган кебек, сез дә безнең мактанычыбыз бу-
лырсыз.

[15] Менә шундый ышаныч белән икеләтә мәрхәмәт алуыгыз-
ны теләп, башта яныгызга барырга, [16] ягъни сезнең аша Маке-
дуниягә, Македуниядән соң тагын сезгә килергә һәм сезнең
ярдәм белән Яһүдиягә барырга дип ниятләнгән идем. [17] Әллә
болай ниятләнеп, мин уйламыйча эш иттемме? Әллә мин,
имансыз кеше кебек, бер үк вакытта «әйе, әйе» һәм «юк, юк»
дип әйтә-әйтә ният итәмме? [18] Әмма, Аллаһының тугрылыгы
хак булган кебек, без сезгә бер үк вакытта «әйе» һәм «юк» дип
әйтмибез. [19] Чөнки мин, Силас һәм Тимуте сезгә игълан иткән
Аллаһы Улы Гайсә Мәсих бер үк вакытта «әйе» һәм «юк» бул-
мады. Киресенчә, Аңарда һәрвакыт «әйе» генә була. [20] Чөнки
Аллаһының бөтен вәгъдәләре Гайсә Мәсихтә «әйе» дип расла-
на, һәм без Аллаһыны данлау өчен әйтә торган «амин» да
Аның аша әйтелә. [21] Аллаһы безне дә, сезне дә, Мәсих белән
берләштереп, Үзе ныгыта. Безне билгеләүче Аллаһы, [22] мөһере
белән тамгалап, безгә биреләчәк нәрсәләр өчен йөрәкләре-
безгә ышанычлы дәлил буларак Рух бирде. [23] Аллаһыны үземә
каршы шаһит итеп чакырам: әлегә кадәр мин, бары тик сезне
кызганганга күрә, Көринткә килмәдем. [24] Бу – иманыгыз өс-
теннән без хакимлек итәбез дигән сүз түгел. Киресенчә, куану-
ыгызны теләп, без сезнең белән бергә хезмәт итәбез, чөнки сез
иманыгыз белән нык торасыз.

**2** [1] Шулай итеп, мин тагын яныгызга көенеч белән килмәскә
булдым. [2] Чөнки сезне көендерсәм, мин көендергән кеше-
ләрдән башка мине кем сөендерер? [3] Менә сезгә шул туры-
да яздым да: килгәч, мине куандырырга тиешлеләрдән миңа
көенеч булмасын. Мин сезнең һәммәгезгә ышанам, куанычым
сезнең һәммәгез өчен дә куаныч булыр. [4] Сезне көендерү өчен
түгел, бәлки сезгә булган чиксез мәхәббәтемне белдерү өчен,
олы хәсрәт һәм йөрәк ачысы белән күз яшьләремне түгеп яз-
дым мин ул хатны.

*Гөнаһ кылган кешене кичерү*

[5] Берәү көендергән икән, мине түгел, ә сезнең барыгызны
да – һәрхәлдә ниндидер дәрәҗәдә (моны күпертеп күрсәтмәс
өчен язам) – көендергән. [6] Мондый берәүгә күпләр тарафын-
нан бирелгән җәза инде җитәрлек. [7] Шуңа күрә, мондый берәү
чиктән тыш көенмәсен өчен, сез аны гафу итегез һәм рухлан-
дырыгыз. [8] Шуның өчен аңа мәхәббәтегезне кабат күрсәтүе-
гезне үтенәм. [9] Сезгә ул хатны сынауны үти алдыгызмы һәм
сез һәрнәрсәдә тыңлаучанмы икәнлегегезне белү өчен яздым.
[10] Сез кемнедер гафу итәсез икән, мин дә аны гафу итәм. Гафу
иткәнемне, әгәр гафу итәрлек берәр нәрсә булган булса, мин
Мәсих алдында сезнең хакка гафу иттем. [11] Шулай итеп, шайтан,
зыян китереп, бездән файдалана алмас. Шайтанның ниятләре
безгә билгеле бит.

*Паулның тынычсызлыгы һәм юанычы*

[12] Мәсих турындагы Яхшы хәбәрне белдерергә дип Троаска
килгәч, Раббы миңа ишекләрне ачкан булса да, [13] анда иманда-
шым Титусны таба алмаганлыктан, йөрәгем үз урынында түгел
иде. Шунлыктан, андагылар белән хушлашып, мин Македуния-
гә киттем.
[14] Әмма безне һәрвакыт Мәсихнең җиңү тантанасында йөртүче
һәм безнең аша һәр җирдә Үзе хакында белем хушбуе таратучы
Аллаһыга рәхмәт яусын. [15] Чөнки Гайсәгә иман итеп котылучы-
лар арасында да, һәлак булучылар арасында да без – Аллаһыга
Мәсих аша бирелгән хуш ис. [16] Берәүләр өчен без – һәлакәткә
илтүче үлем исе, ә башкалар өчен – тереклек бирүче тормыш-
ның хуш исе. Кем мондый эшкә сәләтле соң? [17] Без, күпләр
кебек, үз файдалары өчен Аллаһы сүзе белән сәүдә итмибез,
бәлки Аллаһыныкы буларак, Аллаһы каршында Мәсих исе-
меннән ихлас күңелдән сөйлибез.

*Яңа килешүнең хезмәтчеләре*

**3** [1] Безгә үзебезне сезнең алдыгызда яңадан мактаргамы?
Яисә, кайберәүләр өчен кирәк булган кебек, сезгә яки
сездән безгә хуплау хатлары кирәкме? [2] Сез үзегез – күңел-
ләребезгә язылган, бөтен кеше белгән һәм укыган хатыбыз.
[3] Мәсих хаты булуыгызны үзегез күрсәтәсез. Бу хат язу карасы
белән түгел, тере Аллаһының Рухы белән, таш тakталарга түгел,
бәлки кеше йөрәгенең такталарына хезмәтебез аша язылган.
[4] Мәсих аша Аллаһы каршында безнең менә шундый ыша-
нычыбыз бар. [5] Безгә сәләт үзеннән-үзе килә дип дәгъва итә

алмыйбыз: безнең сәләт Аллаһыдан килә. [6] Ул безне яңа килешү хезмәтчеләре булырга сәләтле итте. Яңа килешү, язылган канунга түгел, Рухка нигезләнгән, чөнки язылган канун үтерә, ә Рух тормыш бүләк итә.

[7] Әгәр ташларга чокып язылган, үлем китерүче хезмәт шундый дан белән килгән ки, исраиллеләр Мусаның йөзенә, хәтта аның даны югалып барса да, карый алмаганнар икән, [8] ул чакта Рух хезмәте тагын да данлырак түгелме? [9] Чөнки кешене хөкемгә китерүче хезмәт данлы икән, хаклыкка китерүче хезмәтнең даны тагын да артыграк. [10] Кайчандыр данлы булган берәр нәрсәнең инде хәзер даны булмый, чөнки аның урынына тагын да данлырак башка нәрсә бар. [11] Чөнки югала барган нәрсә данлы булган икән, мәңге дәвам итүче нәрсә тагын да данлырак.

[12] Менә шундый өметебез булганга, без зур кыюлык белән эш итәбез. [13] Исраиллеләр югала барган данга карамасыннар өчен йөзенә бөркәнчек япкан Муса кебек түгел без. [14] Әмма аларның башлары миңгерәүләнгән, чөнки иске килешүне укыганда шундый ук бөркәнчек бүгенгә кадәр аларның күңелләрендә кала. Ул бөркәнчекне Мәсих кенә алып ташлый. [15] Бүгенге көнгә кадәр, Муса кануны укылган саен, аларның күңелләрендә бөркәнчек ята. [16] Әмма Раббыга мөрәҗәгать иткән чакта, бу бөркәнчек алына. [17] Раббы ул – Рух, ә Раббы Рухы булган җирдә – азатлык. [18] Һәммәбезнең йөзеннән бөркәнчек алып ташланганга, Раббының данын көзгедәй чагылдырабыз*. Без данда бер дәрәҗәдән икенче дәрәҗәгә үзгәртеләбез һәм Аллаһыга охшаганнан-охшый барабыз, андый үзгәртү Раббыдан килә, ә Раббы ул – Рух.

### *Балчык савытлардагы хәзинә*

**4** [1] Аллаһының мәрхәмәте аша безгә Рух хезмәте тапшырылганга күрә, без күңел төшенкелегенә бирелмибез. [2] Ләкин хурлыклы яшерен эшләрдән баш тартып, хәйләгә керешмичә һәм Аллаһының сүзен бозмыйча, бәлки хакыйкатьне ачыктан-ачык белдереп, Аллаһы каршында үзебезне һәр кешенең намус хөкеменә тәкъдим итәбез. [3] Ә без белдергән Яхшы хәбәр яшерелгән булса, ул бары тик һәлак булучылар өчен генә яшерелгән. [4] Бу гасырның илаһы имансызларның акылын томалады, һәм алар күзгә күренмәс Аллаһының чагылышы булган Мәсих даны турындагы Яхшы хәбәрнең яктылыгын күрмиләр. [5] Без бит үзебезне түгел, бәлки Гайсә Мәсихне Раббы итеп игълан итәбез, ә Гайсә өчен без – сезнең хезмәтчеләрегез генә. [6] Чөнки

---

* 3:18 *Көзгедәй чагылдырабыз* – яки «тамаша итәбез».

Аллаһы: «Караңгылыктан яктылык балкысын», – диде, һәм, Гай-
сә Мәсих йөзендә балкыган Аллаһы даны турындагы белемне
безгә күрсәтү өчен, Аның яктылыгы күңелләребезне яктыртты.
7 Әмма бу гаять зур кодрәтнең безнеке түгел, бәлки Аллаһы-
ныкы икәнен күрсәтү өчен, без бу хәзинәне балчык савытларда,
ягъни фани тәннәребездә йөртәбез. 8 Безне һәр яктан кысрык-
лыйлар, әмма бирешмибез; без аптырашта калдык, әмма өмет-
сезлеккә бирелмибез. 9 Безне эзәрлеклиләр, әмма Аллаһы безне
ташламый; безне бәреп төшерделәр, әмма һәлак булмыйбыз.
10 Гайсәнең тормышы да тәнебездә күренсен өчен, Аның үлемен
һәрвакыт тәнебездә йөртәбез. 11 Фани тәнебездә Аның тормышы
да күренсен өчен, без, яшәүчеләр, Гайсә хакына бертуктаусыз
үлемгә дучар ителәбез. 12 Шулай итеп, үлем – бездә, ә тормыш
сездә эш итә.
13 Изге язмада: «Мин иман иттем, шуңа күрә сөйләдем», – дип
язылган. Шул ук инану рухына ия буларак, без дә иман итәбез
һәм шуңа күрә сөйлибез. 14 Чөнки Раббы Гайсәне үледән терелт-
кән Аллаһының безне дә Аның белән бергә үледән терелтәчәген
һәм сезнең белән бергә Үз алдына китереп бастырачагын белә-
без. 15 Боларның һәммәсе дә сезнең өчен. Шулай итеп, Аллаһы-
ның мәрхәмәте тагын да күбрәк кешеләргә таралыр һәм шуның
белән Аллаһы данына тагын да күбрәк шөкер итү китерер.

### *Иман аша яшәү*

16 Менә шуның өчен без күңел төшенкелегенә бирелмибез.
Киресенчә, тәнебез череп таркала барса да, асылыбыз исә көн-
нән-көн яңара бара. 17 Чөнки кыска вакытлы җиңелчә газап чи-
гүебез безнең өчен чиктән тыш зур мәңгелек дан китерә. 18 Без
күренгәнне түгел, бәлки күренмәгәнне карыйбыз, чөнки күрен-
гән нәрсә вакытлыча, ә күренмәгәне – мәңгелек.

5 1 Без беләбез: үлгәч, безнең канлы тәннәребез* җимерелә-
чәк. Күкләрдә исә Аллаһы биргән, кул белән эшләнмәгән
безнең мәңгелек тәннәребез** бар. 2 Без күктән җибәрел-
гән тәннәрне кабул итәргә теләп сыкранабыз, 3 чөнки бу яңа
тәннәрне кабул иткәч, без тәнсез хәлдә калмабыз. 4 Без фани
тәннәребездә сыкранабыз, чөнки тәнсез калырга теләмибез,
бәлки, фанилык тормыш тарафыннан йотылсын өчен, күктән
җибәрелгән тәннәрне кабул итәргә телибез. 5 Нәкъ менә шуның
өчен Аллаһы безне тудырды һәм безгә ышанычлы дәлил итеп
Рухны бирде.

---

* 5:1 *Канлы тәннәребез* – грекча сүзгә-сүз «дөньядагы чатырыбыз».
** 5:1 *Мәңгелек тәннәребез* – грекча сүзгә-сүз «мәңгелек йортыбыз».

6 Шулай итеп, канлы тәнебездә вакытта Раббыдан ерак булу-
ыбызны белсәк тә, һәрвакыт ышаныч белән яшибез, 7 чөнки
без күзгә күренгән нәрсәләр белән түгел, иман белән йөрибез.
8 Ышаныч белән яшибез, тәннән чыгуны һәм Раббы янына
урнашуны яхшырак дип табабыз. 9 Шуңа күрә, тәндә булсак та,
тәннән чыккан булсак та, ихлас күңелдән Аңа яраклы булыр-
га омтылабыз. 10 Чөнки тәндә вакытта яхшылык эшләсәк тә,
яманлык эшләсәк тә, эшенә күрә әҗерен алу өчен, без барыбыз
да Мәсихнең хөкем итү урыны алдына килергә тиеш.

*Татулаштыру хезмәте*

11 Шулай итеп, Раббыдан куркуның нәрсә икәнен белеп, без
кешеләрне күндерергә тырышабыз. Аллаһыга исә безнең кемле-
гебез билгеле. Сезнең вөҗданыгызга да кем булуыбыз билгеле-
дер дип өмет итәм. 12 Алдыгызда мактап, үзебезне янә тәкъдим
итәргә җыенмыйбыз, фәкать, күңелдә булган нәрсә белән тү-
гел, бәлки тыштан күренүче нәрсә белән генә мактанучыларга
җавап бирә алуыгыз өчен, сезгә безнең белән мактанырга мөм-
кинлек бирәбез. 13 Без акылдан шашканбыз икән, бу – Аллаһы
өчен; акылыбызда булсак, бу – сезнең өчен. 14 Чөнки Мәсих-
нең яратуы безне, бер Кеше һәммәсе өчен үлгән икән, димәк,
һәммәсе дә үлде, дип ышанырга мәҗбүр итә. 15 Исәннәр инде
үзләре өчен түгел, бәлки үзләре өчен Үлгән һәм үледән Терел-
телгән өчен яшәсеннәр дип, Мәсих барысы өчен дә үлде.
16 Шуңа күрә хәзер без беркемгә дә кеше үлчәме белән кара-
мыйбыз; Мәсихкә элек кеше үлчәме белән карасак та, хәзер
инде алай карамыйбыз. 17 Шулай итеп, кем Мәсих белән бер-
ләшкән, ул – яңа зат итеп яратылган; борынгысы үтте – яңасы
килде. 18 Боларның һәммәсе – Аллаһыдан, Ул безне Гайсә Мә-
сих аша Үзе белән татулаштырды һәм татулаштыру хезмәтен
безгә ышанып тапшырды. 19 Кешеләрнең кылган яман эшләрен
гаепкә санамыйча, Аллаһы дөньяны Мәсих аша Үзе белән та-
тулаштырды һәм татулашу турындагы хәбәрне безгә ышанып
таратырга тапшырды. 20 Шулай итеп, без – Мәсихнең вәкилләре,
һәм Аллаһы Үзе безнең аша ничек үгетләсә, без шулай Мәсих
исеменнән ялварабыз: Аллаһы белән татуланыгыз. 21 Без Мәсих
белән берләшүдә Аллаһының хаклыгын уртаклашсын өчен, Ул
безнең хакка Гөнаһсыз өстенә гөнаһларыбызны салды.

6 1 Без исә, Аллаһы белән хезмәттәшләр буларак, ялварып
сорыйбыз: сезгә бүләк ителгән Аллаһы мәрхәмәте юкка
гына булмасын! 2 Чөнки:
«Уңайлы вакытта Мин сине ишеттем
Һәм котылу көнендә сиңа ярдәм иттем», –

дип әйтә Аллаһы. Менә хәзер уңай вакыт, менә хәзер котылу көне!

3 Хезмәтебезне гаепләмәсеннәр өчен, без беркемгә дә бернинди киртә куймыйбыз. 4 Киресенчә, һәрнәрсәдә: олы түземлелектә, бәла-казаларда, мохтаҗлыкта, газапланууда, 5 кыйнаулар астында, зинданнарда, җәбер-золымнарда, авыр хезмәттә, йокысыз төннәрдә, ачлыкта, 6 сафлыкта, гыйлемдә, чыдамлыкта, игелек күрсәтүдә, Изге Рухның кодрәтендә, эчкерсез мәхәббәттә, 7 хакыйкать сүзендә, Аллаһы кодрәтендә уң һәм сул кулларыбыздагы тәкъвалык коралы белән 8 намуслык вә намуссызлык, гайбәт һәм абруй аркылы үзебезне Аллаһы хезмәтчеләре итеп тәкъдим итәбез. Безне алдакчылар дип исәплиләр, әмма без тугрылыклы. 9 Безне билгесезләр дип исәплиләр, әмма таныйлар; безне үлеп баручылар дип саныйлар, әмма менә яшибез бит; безне җәзаланган дип уйлыйлар, әмма без үлмибез; 10 безне көендерәләр, ә без һәрвакыт сөенәбез; без ярлы, әмма күпләрне баетабыз; безнең бернәрсәбез юк, әмма без һәрнәрсәгә ия.

11 Көринтлеләр! Сезнең белән ачыктан-ачык сөйләштек, йөрәкләребез сезнең өчен киң итеп ачылган. 12 Сезне чын күңелдән яратабыз, әмма сез безгә карата мәхәббәтегезне кызганасыз. 13 Балаларыма сөйләгән кебек сөйлим: тиң итеп кайтарып бирү өчен, сез дә күңелләрегезне киңәйтегез.

*Тере Аллаһы йорты*

14 Үзегезне имансызлар белән бәйләмәгез. Тәкъвалык белән канунсызлыкның ни уртаклыгы бар? Яктылык белән караңгылыкның нинди уртаклыгы бар? 15 Мәсих белән иблис арасында нинди ризалык булсын? Яки иман итүче белән имансыз арасында нинди уртаклык бар? 16 Аллаһы йорты* белән потлар арасында нинди уртаклык бар? Ә бит без – тере Аллаһы йорты; ә Аллаһы болай дигән:

«Араларында торачакмын һәм йөриячәкмен
Һәм аларның Аллаһысы булачакмын,
Ә алар Минем халкым булачак».
17 «Шуңа күрә алар арасыннан чыгыгыз һәм аерылыгыз, –
ди Раббы, –
Пакьсезгә кагылмагыз,
Һәм Мин сезне Үземә кабул итәчәкмен».
18 «Һәм сезгә Ата булачакмын,
Ә сез улларым һәм кызларым булачаксыз, –
ди Чиксез кодрәт Иясе Раббы».

* 6:16 *Аллаһы йорты* – Аллаһы иман итүчеләрнең һәрберсенең эчендә тора, шуңа күрә алар Аллаһының йорты кебек.

7 [1] Сөеклеләрем, безгә шундый вәгъдәләр бирелде! Шуңа күрә, әйдәгез, тәннең, рухның һәртөрле бозыклыкларыннан үзебезне сафландырыйк һәм Аллаһыдан курыккан хәлдә изгелекне камилләштерик.

*Паулның шатлыгы*

[2] Күңелләрегездә безгә урын бирегез; без һичкемне рәнҗетмәдек, һичкемгә зыян китермәдек, һичкемнән файда эзләмәдек.
[3] Моны сезне хөкем итеп әйтмим: элек әйткәнемчә, бергә үлү
һәм бергә яшәү өчен сез безнең күңелләребездә. [4] Мин сезгә
бик ышанам, сезнең белән чиксез горурланам. Күңелем юаныч белән тулы, һәртөрле кайгы-хәсрәтләребезгә карамастан, чиктән тыш куанам.

[5] Чөнки, Македуниягә килгәч, без берниндиҗан тынычлыгы тапмадык. Киресенчә, безне һәр тарафтан – әйләнә-тирәдән
ызгыш-талашлар, күңелдән куркулар кысты. [6] Әмма Титусның
килүе сәбәпле рухлары төшкәннәргә ярдәм итүче Аллаһы безнең
дә күңелләребезне күтәрде. [7] Аның килүе сәбәпле генә түгел, бәлки Титуска күрсәткән ярдәмегез белән юатты. Мине сагынуыгыз, минем өчен тырышуыгыз һәм көенүегез турында сөйләп, ул
мине тагын да күбрәк куандырды. [8] Хатым белән сезне көендергәнгә, башта үкенсәм дә, инде хәзер үкенмим. Чөнки күрәм: ха-
тым сезне вакытлыча гына көендергән. [9] Хәзер мин куанам – сез
көенгәнгә түгел, бәлки көенүегез сезне тәүбәгә китереп җиткергәнгә куанам. Аллаһы ихтыяры белән көендегез, шулай итеп бездән берниндизыян күрмәдегез. [10] Чөнки Аллаһы ихтыяры белән
көенү котылуга илтүче тәүбәгә китерә; моңа үкенергә кирәкми, ә
инде бу дөнья китергән көенү үлемгә китерә. [11] Карагыз: Аллаһы ихтыяры белән сез кичергән көенеч сездә нинди ихласлык,
гаепсез булуыгызны исбатлау теләге, гаеплегә карата нәфрәт,
курку, сагыну, тырышлык, гөнаһлыны җәзалау теләге тудырды!
Бу эштә саф булуыгызны сез һәрьяктан күрсәттегез. [12] Шулай
итеп, мин сезгә рәнҗетүче хакына да түгел, рәнҗетелгән өчен дә
түгел, бәлки безнең өчен тырышуыгызны Аллаһы алдында сезгә ачык итеп күрсәтү өчен яздым. [13] Без шуның өчен юандык.

Ә инде Титус шатланганга тагын да күбрәк куандык, сез барыгыз да аның күңелен күтәргәнсез бит. [14] Шулай итеп, сезнең
хакта аның алдында мактанган булсам, мин оятка калмадым,
киресенчә, без сезнең хакта һәрвакыт дөрес сөйләгәнбез икән.
Титус алдында мактануыбыз да шулай ук дөрес булып чыкты.
[15] Куркып һәм дулкынланып аны кабул итүегезне, барыгызның
итагатен хәтерләп, аның йөрәге сезгә тагын да ныграк омтыла.
[16] Һәрнәрсәдә сезгә таяна алуым өчен куанам.

*Яһүдиядәге иман итүчеләр өчен җыелган иганә*

**8** [1] Имандашлар, сезгә Македониядәге иман итүчеләр бердәм-
лекләренә бирелгән Аллаһы мәрхәмәте хакында сөйләргә
телибез. [2] Чөнки авыр сынау җибәрелгән булуга карамастан,
аларның куанычы чиктән ашты, бик нык фәкыйрьлектә булса-
лар да, чиктән тыш юмартлык күрсәттеләр. [3] Һәм хәлләреннән
килгәнчә һәм хәтта хәлләреннән тыш та алар үз теләкләре бе-
лән ярдәм иттеләр – моңа мин шаһит. [4] Изгеләргә хезмәт итүдә
катнаштыруны бик үтенеп сорадылар. [5] Без өметләнгәнне генә
эшләп калмадылар, бәлки үз-үзләрен, иң элек, Раббыга, аннан
соң, Аллаһы ихтыяры белән, безгә тапшырдылар. [6] Шуңа күрә
без Титустан, бу игелекле эшне ничек башлаган булса, арагызда
шулай ук тәмамлавын үтендек. [7] Ә сез һәрнәрсәдә: иманда һәм
сүздә, белемдә һәм һәртөрле тырышлыкта, безгә булган мәхәб-
бәтегездә өстен булган кебек, бу иганә өчен игелек күрсәтүдә
дә өстен булыгыз.

[8] Мин сезгә әмер итеп түгел, ә мәхәббәтегезнең ихласлыгын
башкалар тырышлыгы белән сынау өчен әйтәм. [9] Чөнки сез
Раббыбыз Гайсә Мәсихнең мәрхәмәтен беләсез: фәкыйрьлеге
аша сез бай булсын өчен, бай булган хәлдә Ул сезнең хакка
фәкыйрь булды.

[10] Мин бу мәсьәләгә карата файдалы киңәш бирәм: Сез үткән
ел ук игелекле эш эшләп кенә калмадыгыз, хәтта үз теләгегез
белән иганә дә бирдегез. [11] Бу эшне хәзер башкарып чыгыгыз!
Эшегезгә бик теләп тотынган кебек, хәлегезгә күрә шундый ук
тырышлык белән башкарып чыгыгыз. [12] Чөнки тырышлык бул-
ганда, кемнең нәрсәсе булмауга карап түгел, бәлки нәрсәсе бу-
луга карап бүләге кабул ителә. [13] Башкаларга җиңеллек, ә сезгә
авырлык килү таләп ителми, һәр якка да тигез булсын. [14] Мул-
лыгыгыз хәзерге вакытта аларның ихтыяҗларын тәэмин итсен,
ә аннан соң аларның муллыгы сезнекен тәэмин итәр. Шулай
итеп, барысы да тигезләнер. [15] Изге язмада язылганча:

«Күп җыйганның артыгы булмады,
Ә аз җыйганның ихтыяҗы булмады».

*Титус Көринткә җибәрелә*

[16] Сезнең өчен дип Титус күңеленә шул ук тырышлыкны сал-
ган Аллаһыга рәхмәт яусын! [17] Чөнки ул үтенечемне хуплап кына
калмады, бәлки бик ашкынып яныгызга үз ихтыяры белән ба-
рырга карар кылды. [18] Аның белән тагын бер имандашыбызны
да җибәрәбез. Ул исә барлык иман итүчеләр бердәмлекләрендә
Яхшы хәбәр таратуы белән макталган. [19] Өстәвенә, Раббының

даны хакына һәм тырышлыгыбызны күрсәтү өчен башкара
торган игелекле эшебездә иман итүчеләр бердәмлекләре тара-
фыннан безгә юлдаш итеп тә билгеләнгән ул.
20 Шундый зур акчалар белән нәрсә эшләвебез хакында, беркем
дә тел тидерә алмасын өчен, сак булырга тырышабыз. 21 Чөнки
без Раббы каршында игелекле булган гамәлләрне генә түгел,
кешеләр алдында игелекле булганны да кылырга тырышабыз.
22 Безнең тарафтан тырышлыгы шактый эшләрдә һәм нәрсә-
ләрдә күп тапкырлар сыналган һәм хәзерге вакытта сезгә ка-
рата ышанычы булып, тагын да зуррак тырышлык күрсәткән
имандашыбызны алар белән бергә җибәрдек.
23 Титуска килгәндә, ул – минем иптәшем һәм сезнең өчен
хезмәттәш. Ә инде башка имандашларыбызга килгәндә, алар –
иман итүчеләр бердәмлекләренең вәкилләре, Мәсихнең даны.
24 Шулай итеп, мәхәббәтегезнең һәм сезнең белән мактануыбыз-
ның гадел икәнлеген аларга бердәмлекләр алдында исбат итегез.

*Юмартлык турында*

9 1 Изгеләргә ярдәм итү хакында сезгә язып торуның кирә-
ге дә юктыр, 2 чөнки мин тырышлыгыгызны беләм һәм,
Ахаядә ярдәм инде үткән елдан бирле үк әзерләнгән дип,
македуниялеләр алдында сезнең белән мактанам. Сезнең ты-
рышлыгыгыз аларны дәртләндерде. 3 Ә мактавым бу очракта
буш булмасын, бәлки, әйткәнемчә, инде әзер булырсыз дип,
имандашларны яныгызга җибәрдем. 4 Югыйсә, македуниялеләр
минем белән килгәндә сезне әзерлексез хәлдә тапсалар, без
сезгә шундый нык ышаныч белдергәнгә күрә, без дә оятка ка-
лырбыз, һәм сез дә – миңа моны әйтеп торырга да кирәкми.
5 Шуңа күрә, имандашлардан алдан ук баруларын һәм сез вәгъ-
дә иткән юмарт бүләгегезне әзерләүләрен үтенүне зарури дип
таптым. Чөнки бүләкнең теләр-теләмәс түгел, бәлки юмарт рә-
вештә әзер булуын телим.
6 Моңа игътибар итегез: кем аз чәчә, шул аз уңыш алыр; ә
кем күп чәчә, шул мул уңыш алыр. 7 Һәркем теләр-теләмәс яки
мәҗбүриләп түгел, бәлки йөрәге кушканча бирсен, чөнки Ал-
лаһы шатланып бирүчене ярата. 8 Аллаһы һәртөрле мәрхәмәтне
сезгә бик мул итеп бирә ала. Шулай итеп, сез һәрвакыт һәм
һәрнәрсәдә мул тормышлы булып, һәртөрле игелекле эштә
юмарт булырсыз. 9 Изге язмада язылганча:
«Ул Үз бүләкләрен ярлыларга юмарт өләште.
Аның игелеклелеге мәңгелек».
10 Чәчүчегә орлык, ашаучыга икмәк бирүче Аллаһы сезне
орлык белән тәэмин итәр һәм чәчкән орлыгыгызны мул итеп

үстерер, тәкъвалык җимешләрегезне арттырыр [11] һәм, сез һәр
очракта юмарт булсын өчен, сезне һәрнәрсәгә баетыр. Ә без-
нең аркылы күрсәткән юмартлыгыгыз Аллаһыга рәхмәтләр
яудырыр. [12] Чөнки сез башкарган бу хезмәт, изгеләрнең их-
тыяҗларын канәгатьләндереп кенә калмыйча, бик күпләрнең
Аллаһыга рәхмәтләрен дә мул иттерер. [13] Чөнки юмартлыгы-
гызны исбат иткән бу хезмәтне күреп, сез икърар итә торган
Мәсих турындагы Яхшы хәбәргә итагать итүегез, үзләре һәм
башкалар белән юмарт уртаклашуыгыз өчен кешеләр Аллаһы-
ны данлыйлар. [14] Сезнең өчен дога кылганда, Аллаһының сезгә
мул итеп яудырган мәрхәмәте аркасында, алар күңелләре белән
яныгызга ашкынырлар. [15] Әйтеп бетергесез зур бүләге өчен,
Аллаһыга рәхмәт яусын!

*Паул үз хезмәтен яклый*

10 [1] Арагызда тыйнак, ә инде читтә сезнең өчен кыю бул-
ган мин, Паул, Мәсих басынкылыгы һәм эчкерсезлеге
белән сезгә мөрәҗәгать итәм. [2] Яныгызга килгәч, безне,
имансыз кешеләр кебек үз файдалары өчен яшәүчеләр, дип са-
научы кайберләрегезгә кыюлыгымны күрсәтүем кирәк булма-
сын иде дип ялварам. [3] Чөнки бу дөньяда яшәсәк тә, бу дөнья
кешеләре кебек сугышмыйбыз. [4] Безнең коралларыбыз дөньяви
түгел, киресенчә, алар ярдәмендә Аллаһы кодрәте белән теләсә
нинди ныгытмаларны да җимерә алабыз. Бу кораллар белән без
ялган дәлилләрне, [5] Аллаһыны танып белүгә каршы тәкәббер
рәвештә калыккан һәртөрле комачаулыкларны җимерәбез һәм
Мәсихкә итагатьле итү өчен һәр фикерне үзебезгә буйсындыра-
быз. [6] Сез тулысынча итагать иткәннән соң, һәр итагатьсезне
җәзага тартырга әзербез.
[7] Сез тышкы ягын гына карыйсыз. Әгәр кемдер, мин Мәсих-
неке, дип ышанса, тагын уйласын: ул Мәсихнеке булган кебек,
без дә шулай Мәсихнеке. [8] Җимерү өчен түгел, бәлки сезне ны-
гыту өчен Раббының безгә биргән вәкаләте белән аз гына мак-
тансам да, оятка калмаячакмын. [9] Хәер, минем турыда, хатлары
белән генә куркытырга тырыша икән, дип уйламагыз. [10] Чөнки
кемдер: «Ул үзенең хатларында кырыс һәм көчле, ә үзе кеше
алдында көчсез һәм аның сүзләре әһәмиятсез», – ди. [11] Андый
кеше белсен: читтән язган хатларыбыздагы сүзләрдә ничек бул-
сак, сезнең арада да без шундый.
[12] Чөнки үзебезне үзләре белән мактанучыларга тиңләргә яки
чагыштырырга батырчылык итмибез. Алар, акылсызланып, үз-
ләрен үз үлчәмнәре белән үлчиләр һәм үзләрен үзләре белән
чагыштыралар. [13] Без исә Аллаһы билгеләгән чикләрдән тыш

мактанмыйбыз. Арагыздагы хезмәтләребез дә шул чикләргә
керә. 14 Без шул чикләрдән тыш мактанмыйбыз, чөнки Мәсих
турындагы Яхшы хәбәр белән сезгә килеп ирештек инде һәм
хәзер сез дә шул чикләрдә. 15 Без башкалар хезмәте белән ча-
мадан тыш мактанмыйбыз. Әмма иманыгыз арта барган саен,
Раббы тарафыннан билгеләнгән эшчәнлегебез чикләре тагын
да ныграк артыр дип өметләнәбез. 16 Шулай итеп, сездән читтә-
ге илләрдә дә Яхшы хәбәрне тарата алырбыз. Без бит башкалар
эшләгән эш белән мактанырга теләмибез. 17 Изге язмада языл-
ганча: «Мактанучы кеше Раббы белән мактансын». 18 Чөнки
үзен-үзе мактаучы түгел, бәлки Раббы мактый торган кеше генә
Аның тарафыннан хуплана.

*Паул һәм ялган рәсүлләр*

11 1 Минем бераз акылсызлануыма түземлерәк булсагыз иде!
Хәер, сез миңа түземлелек күрсәтәсез инде. 2 Мин сезнең
хакта Аллаһы кайгыртуы белән бик нык кайгыртам бит.
Чөнки мин сезне бер генә иргә – Мәсихкә ярәштем, һәм сезне
Аның алдына гыйффәтле кыз кебек китереп бастырырга телим.
3 Әмма шуннан куркам: елан Хауваны үзенең хәйләсе белән ал-
даган кебек, Мәсихкә карата ихлас күңелдән булган сафлыктан
читкә тайпылып, фикерләрегез чуалып китмәсен иде. 4 Чөнки
кем дә булса килеп, без игълан итмәгән башка бер Гайсәне
игълан итсә, яки сезгә бирелгән Рухтан башка рухны, яисә үзе-
гез кабул иткән Яхшы хәбәрдән башка бер «Яхшы хәбәрне» өн-
дәсә, сез андый кешегә бик тиз колак салыр идегез. 5 Әмма
мондый «гадәттән тыш бөек рәсүлләрдән» һич тә түбән түгел-
мен, дип уйлыйм. 6 Гәрчә сөйләргә оста булмасам да, минем
белемем бар. Хәер, без моны сезгә һәрьяктан ачык күрсәттек.
7 Аллаһының Яхшы хәбәрен бушлай игълан итүем белән мин
сезне күтәрдем һәм үземне түбәнсеттем. Шуның белән мин
гөнаһ кылдыммы әллә? 8 Сезгә хезмәт итәр өчен, башка бердәм-
лекләрне «талап», алар хисабына яшәдем. 9 Яныгызда вакытта
да, мохтаҗлыкта булсам да, һичкемгә йөк булмадым. Мине бар
кирәк-яраклар белән Македуниядән килгән имандашларым
тәэмин итте. Һичнәрсәдә сезгә йөк булмаска тырыштым һәм
тырышачакмын. 10 Миндә Мәсих хакыйкате булуы ышанычлы
булган кебек, Ахая якларында һичкем миннән бу мактанычым-
ны тартып ала алмас дип ышанам. 11 Мин ни өчен болай эшлим
соң? Әллә сезне яратмыйммы? Сезне яратуым Аллаһыга билгеле!
12 Әмма үзләрен безгә тиңләп мактанырга теләүчеләргә мөм-
кинлек бирмәс өчен, моңарчы ничек эшләгән булсам, моннан
соң да шулай эшләячәкмен. 13 Чөнки андый кешеләр – ялган

рәсүлләр, алдакчы эшчеләр, Мәсихнең рәсүлләре булып күре-
нергә тырышалар. 14 Һәм бу гаҗәп түгел: шайтан да яктылык
фәрештәсе кыяфәтенә керә бит. 15 Шунлыктан аның хезмәтчелә-
ре дә хаклык хезмәтчеләре булып кылана икән, бу гаҗәп түгел.
Әмма ахыр чиктә алар кылган гамәлләренә карап җәза алачак.

*Паулның михнәтләре*

16 Тагын әйтәм: һичкем мине акылсыз дип санамасын. Әгәр
акылсыз дип уйлыйсыз икән, мине акылсыз кебек кабул итегез
һәм аз гына мактанырга рөхсәт бирегез. 17 Болай кыю рәвештә
мактанып сөйләгәннәрем, әлбәттә, Раббыдан түгел, акылсыз
кебек мактаначакмын. 18 Күпләр дөнья кешеләре кебек макта-
налар, шуңа күрә мин дә мактанам. 19 Чөнки сез, акыллы ке-
шеләр, акылсызларга карата бик теләп түземлелек күрсәтәсез!
20 Берәү сезне коллыкка төшергәндә, сезне изгәндә, сезнең бе-
лән файданланганда, үзен күкләргә күтәргәндә, битегезгә сук-
канда сез түземлелек күрсәтәсез! 21 Оят булса да әйтим: боларга
көчебез җитмәде! Ә инде берәрсе нәрсә белән булса да мак-
танырга батырчылык итә икән, ул чакта, акылсыз кеше сы-
ман әйтәм: мин дә батырчылык итәм. 22 Алар еврейләрме? Мин
дә. Исраиллеләрме? Мин дә. Ибраһим нәселеннәнме? Мин дә.
23 Алар Мәсих хезмәтчеләреме? Акылсыз сыман сөйлим: мин
тагын да күбрәк. Мин тагын да күбрәк хезмәт иттем, зиндан-
нарга аларга караганда күбрәк ябылдым, күп тапкырлар кый-
налдым һәм күп мәртәбәләр үлем хәлендә булдым. 24 Яһүдләр
мине биш тапкыр, һәрберсендә утыз тугызар мәртәбә камчы
белән суктырдылар. 25 Мине өч мәртәбә таяк белән кыйнады-
лар, бер тапкыр ташлар атып үтерергә теләделәр, мин өч мәр-
тәбә кораб һәлакәтенә очрадым, бер төн һәм бер көнне ачык
диңгездә үткәрдем.

26 Күп мәртәбәләр ерак җирләрдә сәяхәт иттем, хәтәр елгалар-
да сәяхәт кылдым, юлбасарлар һөҗүменә дучар булдым, кабилә-
дәшләрдән һәм мәҗүсиләрдән куркыныч янады, шәһәрләрдә,
чүлләрдә, диңгезләрдә хәвеф-хәтәрләргә очрадым, ялган иман-
дашлар арасында куркынычта яшәдем. 27 Хәлдән тайганчы һәм
йончыганчы эшләдем, төннәремне еш кына йокысызлыкта үт-
кәрдем, ачлыктан һәм сусаудан җәфа чиктем, еш кына ашарга
җитәрлек ризыгым булмады, чатлама суыкта һәм ялангач яшә-
дем. 28 Читтә булган маҗаралардан тыш, мин һәркөн барлык
иман итүчеләр бердәмлекләре хакында хәсрәт чигәм. 29 Һәр
зәгыйфь янында мин дә зәгыйфьләнмимме? Кемдер берәүне
вәсвәсәгә төшерсә, аның өчен ачу белән янмыйммы? 30 Макта-
нырга тиеш булсам, зәгыйфьлегемне күрсәтүче нәрсәләр белән

мактаначакмын мин. 31 Раббы Гайсә Мәсихнең мәңге мөбарәк
Аллаһысы һәм Атасы белә: мин ялган сөйләмим. 32-33 Дәмәшекъ-
тә Һарета патшаның өлкә башлыгы мине тотып алу өчен шәһәр
капкаларына сак куйды, ә мине кәрзингә салып, дивар буйлап
тәрәзәдән төшерделәр, һәм мин аның кулына эләкмәдем.

*Раббыдан килгән илаһи күренешләр*

12 1 Мактануның файдасы булмаса да, мин мактанырга
тиеш; хәзер мин Раббы җибәргән илаһи күренешләр
һәм ачылышлар турында сөйлим. 2 Мин Мәсихкә иман
итүче бер кешене беләм, моннан ундүрт ел элек ул, – тәне бе-
ләнме, әллә рухы беләнме, белмим, бер Аллаһы гына белә, –
өченче күккә кадәр күтәрелеп алынды. 3 Һәм шул кеше хакында
беләм – тик ул тәне беләнме яки рухы беләнме икәнен бел-
мим, Аллаһы белә, – 4 ул җәннәткә алынган һәм тел белән
аңлатып бирә алмаслык сүзләр ишеткән. Ә бу сүзләрне кешегә
сөйләргә ярамаган. 5 Андый кеше белән мактана алам, үзем ха-
кында исә зәгыйфьлекләремнән башка бернәрсә белән дә мак-
тана алмыйм. 6 Хәер, мактанырга теләсәм, акылсыз булмам,
чөнки дөреслекне сөйләячәкмен. Әмма, кем дә булса минем
хакта миндә күргәненнән яки ишеткәненнән артыграк уйлама-
сын дип, мактанудан тыелып торам.
7 Аллаһыдан шундый гадәттән тыш ачылышлар алганга, бо-
рыным күтәрелмәсен өчен, минем тәнемә чәнечке бирелде.
Бу чәнечке исә, мин артык мактанмасын өчен, мине шайтан
фәрештәсе сыман интектерә. 8 Аны тәнемнән чыгарсын өчен
Раббыга өч мәртәбә ялвардым. 9 Әмма Ул әйтте: «Сиңа Минем
мәрхәмәтем җитәр, чөнки Минем кодрәтем зәгыйфьлектә иң
камил була». Шуңа күрә, миндә Мәсих кодрәте торсын өчен,
үз зәгыйфьлекләрем белән бик теләп мактаначакмын. 10 Шу-
ның өчен мин Мәсих хакына зәгыйфьлекләргә, хурлауларга,
мәшәкатьләргә, эзәрлекләүләргә, кысуларга түзәм, чөнки мин
зәгыйфь вакытта көчле.

*Паулның көринтлеләр турында кайгыртуы*

11 Мин акылдан шаштым, моңа сез мәҗбүр иттегез. Сез мине
мактарга тиеш идегез, чөнки, гәрчә мин әһәмиятсез булсам да,
«гадәттән тыш бөек рәсүлләрдән» һич ким җирем юк. 12 Минем
рәсүллек дәлилләре – галәмәтләр, могҗизалар һәм кодрәтле
эшләр – сездә зур сабырлык белән күрсәтелде. 13 Сезгә авыр
йөк булмавым белән, башка бердәмлекләргә караганда, сезнең
белән начаррак мөгамәлә иттемме әллә? Мондый гаебем өчен
мине гафу итегез!

[14] Менә, мин яныгызга өченче тапкыр барырга әзерләнәм, әмма сезгә йөк булмаячакмын, чөнки мин сезнеке булганны түгел, бәлки үзегезне эзлим. Балалар ата-аналарына түгел, бәлки ата-аналар балаларына байлык җыярга тиеш бит. [15] Җаннарыгыз өчен мин үземдә булганның һәммәсен, хәтта үземне дә бик теләп сарыф итәрмен. Әгәр сезне бик яратам икән, сез мине азрак яратасызмы?

[16] Ярый, мин үзем сезгә йөк булмадым, ди. Ләкин, сезнең әйтүегезчә, хәйләкәр буларак, сезне мәкерлек белән үз кулыма алганмын. [17] Сезгә җибәрелгәннәрнең берәрсе аркылы сездән файдаландыммы? [18] Мин Титустан яныгызга баруын үтендем һәм аның белән бер имандашымны җибәрдем. Титус сездән файдаландымы? Без соң бер үк рух белән эш иттек түгелме? Бер үк юлдан йөрмәдекме? [19] Сез, мөгаен, алдыгызда акланабыз дип уйлыйсыздыр. Юк! Без, Мәсихнеке буларак, Аллаһы алдында сөйлибез, болар һәммәсе, сөеклеләрем, сезне рухи яктан ныгыту өчен. [20] Чөнки мин, килгәч, сезне үзем теләмәгән хәлдә тапмасам иде, һәм сез дә мине үзегез теләмәгән хәлдә тапмасагыз иде. Арагызда гаугалар, көнчелек, ачу, ызгыш-талаш, яла ягу, гайбәт сату, тәкәбберлек, тәртипсезлек табырмын дип куркам. [21] Килгәч, Аллаһым сезнең алда мине тагын кимсетер дип куркам, һәм, элек гөнаһ кылып та, кылган шакшылык, фәхешлек һәм азгынлыклары өчен тәүбә итмәгән күпләр өчен, миңа күз яше агызырга туры килмәсен иде.

*Соңгы үгетләр һәм сәламнәр*

**13** [1] Сезгә инде өченче мәртәбә киләчәкмен. Изге язмада: «Һәр очрак ике яки өч шаһит белән расланырга тиеш», — диелгән. [2] Мин яныгызда икенче мәртәбә булганда сезгә кисәтү ясаган идем инде. Хәзер исә сезне тагын читтән торып кисәтәм: янә яныгызга килгәч, әүвәл гөнаһ кылганнарны һәм башкаларның һәммәсен дә кызганмам, [3] чөнки сез минем аша Мәсих сөйләвенә дәлил эзлисез. Ул сезнең өчен эш иткәндә зәгыйфь түгел, Ул сезнең арада көчле. [4] Чөнки Ул зәгыйфьлектә хачка кадакланган булса да, Аллаһы кодрәте белән яши. Шулай ук без дә Аның белән берләшүдә көчсез булсак та, Аллаһы кодрәте ярдәмендә, сезнең файдагыз өчен, Аның белән бергә яшәячәкбез.

[5] Иман белән яшибез микән? — дип үзегезне үзегез сынагыз, үзегезне үзегез тикшерегез. Гайсә Мәсихнең сездә булуын белмисезме әллә? Бәлки сез сынауда уңышсызлыкка очрагансыздыр. [6] Безгә килгәндә, сынауны уңышлы үтүебезне белерсез, дип өмет итәм. [7] Сезнең берниндиями яман эш кылмавыгыз өчен

Аллаһыга ялварабыз. Сынауны уңышлы үткәнебезне күрсәтү өчен түгел, бәлки, без сезгә сынауларны үтә алмаган кебек күренсәк тә, сезнең игелекле эш эшләвегез өчен ялварабыз.
8 Чөнки без хакыйкатькә каршы бернәрсә дә эшли алмыйбыз, әмма аның үзе өчен генә эшли алабыз. 9 Без көчсез, ә сез
көчле булганда без сөенәбез һәм сезнең камилләшүегез хакына
дога кылабыз. 10 Шунлыктан мин боларны сездән читтә вакытта
язам. Яныгызга баргач, Раббының җимерү өчен түгел, бәлки ныгыту өчен миңа биргән вәкаләтен каты рәвештә кулланмаска өметләнәм.
11 Ниһаять, имандашлар, сау булыгыз. Камиллеккә омтылыгыз, бер-берегезне рухландырыгыз, бер фикердә булыгыз, тату яшәгез: мәхәббәт һәм иминлек Аллаһысы сезнең белән булыр.
12 Изге үбү белән бер-берегезне сәламләгез. Сезгә барлык изгеләр сәлам юллый.
13 Раббы Гайсә Мәсихнең мәрхәмәте һәм Аллаһының мәхәббәте сезнең барыгыз белән булсын. Изге Рух сезнең һәммәгезнең йөрәкләрен берләштерсен*.

* 13:13 Соңгы җөмлә төп нөсхәдә сүзгә-сүз: «Изге Рухның аралашуы сезнең барыгыз белән булсын».

# ПАУЛДАН ГӘЛӘТИЯЛЕЛӘРГӘ ХАТ

*Паулның сәламе*

1 [1] Кешеләр тарафыннан да, кеше аша да түгел, бәлки Гайсә
Мәсих һәм Аны үледән терелткән Ата Аллаһы тарафыннан
рәсүл итеп сайланган Паулдан [2] һәм минем белән бергә
булган барлык имандашлардан Гәләтиядәге иман итүчеләр бер-
дәмлекләренә сәлам. [3] Сезгә Атабыз Аллаһыдан вә Раббы Гайсә
Мәсихтән мәрхәмәт һәм иминлек булсын. [4] Безне хәзерге начар
заманнан коткарам дип, Атабыз Аллаһы ихтыяры буенча безнең
гөнаһларыбыз өчен Мәсих Үзен корбан итте. [5] Аллаһыга мәң-
ге-мәңгегә дан! Амин.

*Башка Яхшы хәбәр юк*

[6] Мәсихнең мәрхәмәте белән сезне Чакыручыны ташлап,
шулай бик тиз чит «Яхшы хәбәргә» күчүегезгә хәйран калам.
[7] Хәер, башка Яхшы хәбәр юк, бәлки кайбер кешеләр сезгә
борчу тудырып, Мәсихнең Яхшы хәбәрен бозарга гына тели-
ләр. [8] Әмма, хәтта без яки күктән фәрештә килеп, үзебез сезгә
игълан иткән Яхшы хәбәргә каршыны игълан итсәк, аңа ләгъ-
нәт төшсен! [9] Без моны элек тә әйткән идек, хәзер мин яңадан
әйтәм: кемдер сез кабул иткән Яхшы хәбәрдән үзгәне игълан
итсә, аңа ләгънәт төшсен.
[10] Әллә хәзер мин илтифатны кешеләрдән эзлимме яки Ал-
лаһыданмы? Яки кешеләргә ярарга тырышаммы? Мин әле дә
кешеләргә ярарга тырышсам, Мәсих колы булмас идем.

*Паулның рәсүллеге*

[11] Имандашлар, сезнең шуны белүегезне телим: мин сөйләгән
Яхшы хәбәр кеше уйдырмасы түгел, [12] чөнки мин аны кешеләр-
дән кабул да итмәдем һәм алардан өйрәнмәдем дә, миңа аны
Гайсә Мәсих ачып бирде.
[13] Сез минем яһүд динендәге элекке яшәү рәвешем хакын-
да ишеттегез инде. Ул чакта мин Аллаһы бердәмлеген аяу-
сыз эзәрлекләдем һәм җимереп бетерергә тырыштым [14] һәм,

ата-бабаларыбыздан килгән тәгълиматларга чиксез бирелгән
булып, яһүд динендә үз халкым арасында күп кенә яшьтәшлә-
ремнән алга чыктым.
[15-16] Мине анам карынында чакта ук сайлап алган һәм Үзенең
мәрхәмәте белән чакырган Аллаһы исә, яһүд булмаганнар ара-
сында Үзенең Улы турындагы Яхшы хәбәрне вәгазьләү өчен,
Улын миңа күрсәтергә яхшы дип тапкач, мин шунда ук, бер ке-
ше белән дә киңәш итмичә [17] һәм Иерусалимга, үземнән элек
булган рәсүлләр янына да бармыйча, Гарәбстанга киттем һәм
яңадан Дәмәшекъкә кайттым.
[18] Аннары, өч ел үткәч, мин Кифас* белән танышу өчен Иеру-
салимга бардым һәм унбиш көнләп аның янында булдым.
[19] Әмма Раббының энесе Ягъкубтан башка һичбер рәсүлне күр-
мәдем. [20] Ә сезгә язганнарымны Аллаһы каршында язам, ялган-
ламыйм. [21] Шуннан соң Сурия һәм Киликия җирләренә киттем.
[22] Яһүдиядәге Мәсих бердәмлекләре исә мине күреп белмиләр
иде. [23] Алар, кайчандыр үзләрен эзәрлекләгән кеше хәзер элек
үзе юк итәргә тырышкан иманны ук вәгазьли икән, дип кенә
ишеткәннәр [24] һәм минем хакка Аллаһыны данлаганнар.

*Рәсүлләрнең Паулны кабул итүе*

**2** [1] Аннан соң, ундүрт ел үткәч, Титусны да үзебез белән
алып, мин Барнаб белән бергә тагын Иерусалимга киттем.
[2] Анда Аллаһы кушуы буенча бардым һәм, мин юкка гына
тырышмыйммы яки тырышмадыммы икән дип борчылып, үзем
яһүд булмаганнар арасында тараткан Яхшы хәбәрне шәхси әң-
гәмә вакытында андагы бик мөхтәрәм кешеләргә тәкъдим ит-
тем. [3] Әмма алар минем белән бергә булган Титусны да, гәрчә
ул грек булса да, сөннәтләнергә мәҗбүр итмәделәр. [4] Без бу
турыда сөйләшергә тиеш идек, чөнки Мәсих Гайсәдә булган
азатлыгыбызны күзәтергә һәм безне коллыкка төшерергә дип,
яныбызга яшерен рәвештә ялган «туганнар» килгән иде. [5] Әмма
Яхшы хәбәрнең хакыйкате сезнең белән калсын өчен, без алар-
га бер генә мизгелгә дә буйсынмадык.
[6] Мөхтәрәм дип исәпләнгәннәр исә, алар кайчандыр кем ге-
нә булсалар да, минем өчен мөһим түгел, чөнки Аллаһы кеше-
нең йөзенә карамый. Ул мөхтәрәм кешеләр мин игълан иткән
Яхшы хәбәргә берни өстәмәделәр. [7] Киресенчә, Яхшы хәбәр-
не яһүдләргә белдерү эше Петергә тапшырылган кебек, аны
башка халыкларга белдерү эше миңа ышанып тапшырылганын
күрделәр. [8] Чөнки яһүдләр арасында рәсүллек итүдә Петергә

---

* [1:18] *Кифас* – Шимун Петернең икенче исеме.

көч бирүче Аллаһы яһүд булмаганнар арасында рәсүл булып
эшләүдә миңа да көч бирде. [9] Миңа Аллаһы тарафыннан би-
релгән үзенчәлекле хезмәтне икърар иткәч, иман итүчеләр
бердәмлегенең терәкләре дип исәпләнгән Ягъкуб, Кифас һәм
Яхъя, уртак хезмәтебез билгесе итеп, минем һәм Барнабның
кулларын кыстылар. Без яһүд булмаганнар янына, ә алар яһүд-
ләр янына барырга дип килештек. [10] Тик фәкыйрьләргә ярдәм
итү турында һәрвакыт истә тотуыбызны гына теләделәр, һәм
мин нәкъ шуны зур теләк белән башкарырга тырыша идем.

*Паул Кифаска каршы чыга*

[11] Әмма Кифас Антиухеягә килгәч, мин аңа ачыктан-ачык
каршы чыктым, чөнки ул хаклы түгел иде. [12] Ягъкуб яныннан
кайберәүләр килгәнгә кадәр, Кифас яһүд булмаган мәсихчеләр
белән бергә ашады; ә инде тегеләр килгәч, сөннәтләүне таләп
итүчеләрдән куркып, яһүд булмаганнардан кача һәм читләшә
башлады. [13] Аның белән бергә башка мәсихче яһүдләр дә ике-
йөзлеләнделәр, хәтта Барнаб та аларның икейөзлелегенә бире-
леп китте.

[14] Ә аларның Яхшы хәбәр хакыйкате буенча туры юлдан
бармауларын күргәч, мин һәммәсе алдында Кифаска: «Син,
яһүд була торып, яһүдичә түгел, бәлки мәҗүсиләрчә яшисең
икән, ни өчен мәҗүсиләрне яһүдләр кебек яшәргә мәҗбүр итә-
сең?» – дидем.

*Бары иман аша аклану*

[15] Без – тумышыбыз буенча яһүдләр, гөнаһлы мәҗүсиләр тү-
гел. [16] Әмма ләкин кешенең канун таләпләрен үтәве белән түгел,
бәлки Гайсә Мәсихкә иман итүе аша Аллаһы тарафыннан акла-
ну алуын белгәнгә күрә, без дә канун таләпләрен үтәү белән тү-
гел, бәлки Мәсихкә иман итү аша Аллаһы тарафыннан аклану
өчен Мәсих Гайсәгә иман китердек; чөнки канун таләпләрен
үтәү белән беркем дә Аллаһы тарафыннан аклана алмас.

[17] Әгәр дә инде Мәсих аша бирелгән аклануга омтылып та,
без үзебез үк гөнаһлылар булып чыксак, бу очракта Мәсих –
гөнаһ хезмәтчесемени? Һич тә алай түгел! [18] Чөнки үзем җимер-
гән нәрсәләрне яңадан торгызам икән, мин үз-үземне канун
бозучы итеп күрсәтәм. [19] Чөнки мин, Аллаһы өчен яшәргә дип,
канун аркылы канун вәкаләтеннән азат ителдем. Мин Мәсих
белән хачка кадакландым [20] һәм инде үзем яшәмим, бәлки
миндә Мәсих яши. Ә мин хәзер фани тәндә яшим икән, мине
яраткан һәм минем өчен Үз гомерен биргән Аллаһы Улына
иман белән яшим. [21] Аллаһының мәрхәмәтен кире какмыйм.

Әгәр кеше канун аркылы хак санала икән*, ул чакта Мәсих
юкка гына үлгән булып чыга.

*Канун яки иман*

3 1 Их, акылсыз гәләтиялеләр! Сезнең зиһенегезне кем чуалт-
ты икән? Ә бит Гайсә Мәсих сезнең күз алдында ук хачка
кадаклангандай ачык сурәтләнде. 2 Сездән шуны гына бе-
лергә телим: сез Рухны канун таләпләрен үтәү беләнме, әллә
ишеткәнегезгә ышану белән алдыгызмы? 3 Сез шулкадәр акыл-
сызмыни? Сез Изге Рух белән башладыгыз, ә хәзер максатыгызга
үз көчегез белән генә ирешергә телисезме? 4 Сезнең баштан
кичкән нәрсәләрнең барысы да файдасызга булдымыни? Мин
аларның файдасызга булмавына өмет итәм! 5 Канунны үтәвегез
аркасындамы яки ишеткәнегезгә ышангангамы Аллаһы сезгә
Рух бирә һәм сезнең арагызда могҗизалар тудыра?
6 Ибраһимны исегезгә төшерегез. Изге язмада аның турында:
«Ул Аллаһыга ышанды, һәм моның белән Аллаһы тарафыннан
хак саналды», – диелгән. 7 Моннан сез шуны аңлагыз: иманга
таянучылар – Ибраһимның чын балалары. 8 Һәм Изге язма, Ал-
лаһының яһүд булмаганнарны иман аркылы аклаячагын алдан
күреп, Ибраһимга: «Бар халыклар синең аша фатиха алачак», –
дигән Яхшы хәбәр белдерде. 9 Димәк, иманга таянучылар иманлы
Ибраһим белән бергә фатиха алалар. 10 Ә инде канун таләпләрен
үтәүләренә ышанучыларның барысына да каргыш төште. Чөн-
ки Изге язмада: «Канун китабында язылганнарның бөтенесен
даими үтәмәүче һәркем ләгънәтләнә», – дип язылган. 11 Билгеле
ки, Аллаһы алдында канун аркылы һичкем aклана алмый, чөн-
ки, язылганча, «Аллаһы тарафыннан иман аша акланган кеше
яшәячәк». 12 Канун исә иманга нигезләнмәгән, киресенчә, «ка-
нун таләпләрен үтәүче алар белән яшәячәк». 13 Мәсих безнең
урынга ләгънәт булып, безне канун ләгънәтеннән йолып алды,
чөнки Изге язмада: «Агачка асылган һәркем ләгънәтле», – дип
язылган. 14 Ибраһимга бирелгән фатиха Мәсих Гайсә аша яһүд
булмаганнарга да ирешсен, һәм вәгъдә ителгән Рухны иман ар-
кылы без алсын өчен, Мәсих безне йолып алды.

*Канун һәм вәгъдә*

15 Имандашлар! Мин сезгә көндәлек тормыштан бер мисал
китерәм: хәтта кешенең гамәлгә куелган васыятен дә һичкем
юкка чыгара яки аңа һичбер нәрсә өсти алмаган кебек, бу очрак-
та да шулай. 16 Ибраһимга һәм аның токымына вәгъдәләр би-
релгән булган. Күпләр турында әйтелгән кебек, «токымнарына»

---

* 2:21 *Хак санала икән* – ягъни «аклана икән».

диелмәгән, бәлки берәүгә генә әйтелгән кебек, «синең токы-
мыңа» диелгән, ә ул – Мәсих. [17] Мин менә нәрсәне күздә тотам:
элек Аллаһы тарафыннан расланган килешүне дүрт йөз утыз
елдан соң чыккан канун гамәлдән чыгара алмый һәм, шул рә-
вешчә, вәгъдәнең көчен бетерә алмый. [18] Чөнки Аллаһының
бүләге канунны үтәвебезгә бәйле булса, ул инде вәгъдә белән
бәйле булмый. Әмма ләкин Аллаһы Ибраһимга фатихаларын
нәкъ вәгъдә аркылы биргән.

[19] Канун ни өчен соң? Канун Үзенә вәгъдә бирелгән Токым
килгәнгә кадәр булган явызлыклар аркасында бирелгән бул-
ган һәм фәрештәләр тарафыннан арадашчы аша тапшырыл-
ган. [20] Шәхес үзе генә эш иткәндә, аңа арадашчы кирәк түгел; ә
Аллаһы бер.

*Канунның максаты*

[21] Шулай итеп, канун Аллаһының вәгъдәләренә каршы чыга-
мыни? Һич тә юк! Әгәр дә тормыш бирә алырлык канун бирел-
гән булса, кеше чыннан да канунны үтәү аркылы акланыр иде*.
[22] Әмма Изге язма бөтен дөньяны гөнаһ әсире дип игълан итә,
шуңа күрә вәгъдә ителгән фатиха иман итүчеләргә Гайсә Мә-
сихкә инану аша бирелә.

[23] Ә инде бу иман килгәнче, бу иман ачылырга тиеш вакытка
кадәр, без канун сагы астында кала бирдек. [24] Шулай итеп, без
иман аркылы Аллаһы тарафыннан аклансын дип, Мәсих кил-
гәнгә кадәр канун безгә тәрбияче булды. [25] Ә иман килгәннән
соң без инде тәрбияче кул астында түгел. [26] Гайсә Мәсихкә
иман аша сез барыгыз да – Аллаһы балалары. [27] Чөнки суга
чумдырылу йоласын** үтәп, сез Мәсих белән берләшкәнсез
икән, димәк, Мәсихне «кигәнсез». [28] Шуңа күрә, яһүд белән
грек, кол белән ирекле, ир-ат белән хатын-кыз арасында аерма
юк, чөнки сез барыгыз да Мәсих Гайсәдә бер. [29] Мәсихнеке
булсагыз, сез – Ибраһимның токымнары һәм Аллаһы вәгъдә
иткәнне мирас итеп алырсыз.

*Мәсих кануннан йолып ала*

**4** [1] Мин моны күздә тотам: варис әле бала вакытта, һәрнәрсә-
нең иясе булса да, колдан бернәрсә белән дә аерылмый.
[2] Атасы билгеләгән вакытка кадәр ул тәрбияләүчеләренә
һәм йорт идарәчеләренә буйсына. [3] Без дә бала вакытта бу
дөнья белән идарә итүче көчләр коллыгында идек. [4-5] Әмма

---

* 3:21 *Акланыр иде* – ягъни «хак саналыр иде».

** 3:27 *Суга чумдырылу йоласы* – гөнаһлардан тәүбә итүне, үзеңне
Аллаһы Тәгаләгә багышлауны күрсәтә торган йола.

Аллаһы, билгеләнгән вакыт җиткәч, хатын-кыздан туган, яһүд-
ләр кануныйа буйсына торган Улын җибәрде. Аллаһының Улы,
канун астында булганнарны йолып, аларны Аллаһы балалары
итү өчен килде. 6 Ә сез Аның балалары булганга, Аллаһы Үз Улы-
ның: «Абба, Әти!» – дип чакыручы Рухын сезнең йөрәкләрегезгә
җибәрде. 7 Шуңа күрә син – инде кол түгел, бәлки Аның бала-
сы. Әгәр бала икәнсең, димәк, син – Аллаһы аша варис та.

*Паулның гәләтиялеләр хакында кайгыртуы*

8 Әмма элек, сез Аллаһыны белмәгәндә, чынлыкта илаһ булма-
ганнарга кол булып хезмәт иттегез. 9 Хәзер исә, Аллаһыны танып
белгәч, дөресрәге, Аллаһы тарафыннан танылганнан соң, ни өчен
дөнья белән идарә итүче теге зәгыйфь һәм файдасыз көчләргә
кабат борыласыз һәм яңадан үзегезне аларның колы итәргә тели-
сез? 10 Сез билгеле бер көннәргә, айларга, елларга һәм башка
бәйрәмнәргә аерым игътибар бирәсез. 11 Сезгә куйган авыр хез-
мәтем юкка гына булмадымы икән дип, сезнең өчен куркам.

12 Имандашлар, үтенеп сорыйм, минем кебек булыгыз, чөнки
мин дә сезнең кебек булдым. Сез мине бернәрсә белән дә рән-
җетмәдегез. 13 Мин, авыру булганга күрә, сезгә беренче тапкыр
Яхшы хәбәрне игълан иттем. Сез бу турыда беләсез. 14 Ләкин
минем авыруым сезнең өчен сынау булса да, миңа чирканып
карамадыгыз һәм мине кире какмадыгыз, бәлки Аллаһы фә-
рештәсен, Мәсих Гайсәнең Үзен кабул иткән кебек кабул итте-
гез. 15 Сезнең куанычыгыз кая китте соң? Сезнең хакта үзем үк
әйтеп бирә алам: әгәр мөмкин булса, сез үз күзләрегезне чокып
алып, миңа биргән булыр идегез. 16 Сезгә хакыйкать сөйләвем
аркасында дошманыгызга әйләндемме әллә?

17 Канун астында булуыгызны теләүчеләр сезнең белән бик
нык кызыксыналар, әмма яхшы ният белән түгел. Үзләре ту-
рында кайгыртуыгызны теләп, алар сезне миннән аерып алыр-
га ниятлиләр. 18 Кызыксыну яхшы ният белән булганда гына
әйбәт. Мин яныгызда чакта гына түгел, бәлки һәрвакыт шу-
лай эшләү яхшы. 19 Балаларым, Мәсих сезнең тормышыгызның
аерылгысыз өлешенә әверелгәнгә кадәр, сезнең өчен мин бала
тудыру газабын яңадан кичерәм! 20 Хәзер мин сезнең яныгызда
булырга һәм бөтенләй башкача сөйләшергә теләр идем, чөнки
мин сезнең хакта ишетеп аптырашта калдым.

*Киная: Һаҗәр һәм Сара*

21 Канунга буйсынырга теләүчеләр, әйтегез әле миңа: сез әл-
лә канунны ишетмисезме? 22 Чөнки анда: «Ибраһимның ике
улы булган, аларның берсе колдан, ә икенчесе ирекле хатыннан

туган», – дип язылган. 23 Әмма колдан туганы, гадәттә, балалар
ничек дөньяга килсәләр, шул рәвешчә туган, ә ирекле хатын-
нан булганы Аллаһының вәгъдәсе буенча туган.
24 Бу читләтеп әйтү. Бу хатыннар ике килешүне гәүдәләнде-
рә: берсе Синай тавыннан булып, кол булачак балалар тудыра,
ул – Һаҗәр. 25 Һаҗәр Гарәбстандагы Синай тавына һәм хәзерге
Иерусалимга туры килә, чөнки хәзерге Иерусалим үзенең ба-
лалары белән коллыкта. 26 Ә күктәге Иерусалим ирекле, безгә
ул – ана. 27 Чөнки Изге язмада болай дип язылган:

«Балага узмаучы,
бала тудырмаучы хатын, сөен.
Бала тудыру газабын белмәүче хатын,
кычкырып шатлыгыңны белдер.
Чөнки ялгызак хатынның балалары
ире булганныкыннан күбрәк».

28 Сез исә, имандашлар – Исхак кебек, вәгъдә балалары.
29 Әмма теге вакыттагы кебек, Рух аркасында туганны гадәти
рәвештә туган ничек эзәрлекләгән булса, хәзер дә шулай. 30 Әм-
ма Изге язма нәрсә ди соң? «Кол хатынны һәм аның улын
куып чыгар, чөнки кол хатынның улы ирекле хатын улы бе-
лән беркайчан да бергә варис булмаячак». 31 Шуңа күрә, иман-
дашлар, без – кол хатын балалары түгел, бәлки ирекле хатын
балалары.

*Иреккә чакыру*

5 1 Мәсих безне ирекле булу өчен азат итте. Шуңа күрә нык
торыгыз һәм яңадан коллык золымына төшмәгез. 2 Тың-
лагыз! Мин, Паул, сезгә әйтәм: әгәр сез сөннәткә утыр-
тыласыз икән, сезгә Мәсихтән һичнинди файда булмас. 3 Ә
сөннәтләнүче һәр кешенең бөтен канунны үтәргә тиешлеген
кабат раслыйм. 4 Канун тоту белән Аллаһы тарафыннан аклан-
ган булырга тырышучылар, сез Мәсихтән аерылып киттегез
һәм Аллаһы мәрхәмәтеннән төшеп калдыгыз. 5 Без исә Аллаһы
тарафыннан акланырбыз* дип өмет итәбез. Һәм иман иткәнгә
күрә, аның тормышка ашуын Рух ярдәме белән ашкынып кө-
тәбез. 6 Чөнки Мәсих Гайсәдә сөннәт тә, сөннәтсез булу да
бернинди әһәмияткә ия түгел, бәлки мәхәббәт белән эш итүче
иман гына әһәмиятле.
7 Сез иманда яхшы яши идегез; сезгә хакыйкатькә буйсы-
нырга кем комачаулады икән? 8 Мондый инану сезне Чакыру-
чыдан түгел. 9 Аз гына чүпрә бөтен камырны ачыта. 10 Раббыга

---

* 5:5 *Акланырбыз* – ягъни «хак саналырбыз».

таянып, мин сезнең башкача фикер йөртмәячәгегезгә ышанам;
ә сезне котыртучы кем булуына карамастан, хөкемгә дучар ителәчәк. [11] Имандашлар, мин әле дә, сөннәткә утырту кирәк, дип
өйрәтәм икән, мине тагын ни өчен эзәрлеклиләр соң? Ул чагында хач турындагы тәгълиматым киртә булмас иде. [12] Сезне борчучылар сөннәткә утырту белән үз-үзләрен харап итсеннәр иде!

[13] Имандашлар, сез ирекккә чакырылдыгыз, әмма ләкин сезнең ирегегез кешелек табигатен канәгатьләндерү өчен сәбәп булмасын, бәлки бер-берегезгә мәхәббәт белән хезмәт итегез.
[14] Чөнки бөтен канун бер әмердән гыйбарәт: «Якыныңны үзеңне яраткан кебек ярат». [15] Әгәр сез бер-берегезгә ерткыч җанварлар кебек һөҗүм итәсез икән, сак булыгыз: бер-берегезне кырып бетерә күрмәгез.

*Рух буенча яшәү*

[16] Сезгә әйтәм: Рух буенча яшәгез, шул чакта кешелек табигатенең азгын теләкләрен үтәмәссез. [17] Чөнки кешелек табигате Рухка каршы булганны тели, ә Рух – кешелек табигатенә каршы булганны: алар бер-беренә каршы торалар, шуңа күрә сез теләгәнегезне эшли алмыйсыз. [18] Әгәр сезнең белән Изге Рух җитәкчелек итә икән, ул чакта сезнең өстән канунның бернинди хокукы юк.

[19] Кешелек табигатенең эшләре билгеле: алар – фәхешлек, пычраклык, азгынлык, [20] потка табыну, сихерчелек, дошманлык, ызгыш-талаш, хөсетлек, бик нык ярсу, тәкәбберлек, низаглар, үзара каршылыклар, [21] көнчелек, эчкечелек, котырынкы эчү мәҗлесләре һәм шуларга охшаган башкалар. Инде элек әйткәнемчә, сезне яңадан кисәтәм: болай эшләүчеләр Аллаһы Патшалыгына ия булмаслар.

[22-23] Изге Рух исә мәхәббәт, шатлык, иминлек, сабырлык, игелек, яхшылык, ышаныч, басынкылык, үз-үзеңне тота белүне тудыра. Мондыйларга каршы бернинди канун юк. [24] Ә
Мәсих Гайсәнекеләр кешелек табигатьләрен дәрте һәм теләкләре белән бергә хачка кадакладылар. [25] Рух белән яшибез
икән, Рух буенча эш итәргә дә тиешбез. [26] Бер-беребезне ярсытып, бер-беребездән көнләшеп, дан сөюче булмыйк.

*Үзара ярдәмләшүгә чакыру*

**6** [1] Имандашлар, кем дә булса берәү нindидер гөнаһ кылганда тотыла икән, сез, рухлы кешеләр, аны басынкылык белән төзәтегез; тик вәсвәсәгә бирелмәс өчен һәрберегез үз-үзен дә күзәтсен. [2] Бер-берегезнең авыр йөкләрен күтәрешегез һәм шулай итеп Мәсих канунын үтәрсез. [3] Чынлыкта исә,

һичкем булмыйча, үзен зурга санаучы кеше үз-үзен алдый.
4 Һәркем үзен сынасын, шул чакта ул үзен башка берәү белән
чагыштырмыйча горурлана алыр. 5 Чөнки һәркем үз йөген үзе
йөртергә тиеш.

6 Аллаһы тәгълиматы белән нәсыйхәтләнүче үзенең барлык
игелекләрен үз нәсыйхәтчесе белән уртаклашсын.

7 Алданмагыз: Аллаһыны алдарга мөмкин түгел. Кеше ни
чәчсә, шуны урыр. 8 Үзенең кешелек табигатенә чәчүче кешелек
табигатеннән һәлакәт урыр, ә Рухка чәчүче Рухтан мәңгелек
тормыш алыр. 9 Игелек эшләргә арымагыз, чөнки игелек эшләү-
дән тукталмасак, вакытында уңышны урып алырбыз. 10 Димәк,
җае чыкканда, һәркемгә, бигрәк тә имандашларга игелек эшлик.

*Мәсих хачын данлау*

11 Карагыз, үз кулым белән сезгә нинди зур хәрефләр белән
язам. 12 Әйләнә-тирәдәгеләргә яхшы тәэсир калдырырга теләү-
челәр, үзләре Мәсих хачы хакына эзәрлекләнмәсеннәр өчен ге-
нә, сезне сөннәтле булырга мәҗбүр итәргә тырышалар. 13 Хәтта
сөннәткә утыртылганнар үзләре дә канунны тотмыйлар, ләкин
сезне бу тән йоласына дучар итеп, сезнең белән мактану өчен,
сөннәтле булуыгызны телиләр. 14 Ә мин Раббыбыз Гайсә Мә-
сих хачыннан башка һичнәрсә белән мактанырга теләмим, ми-
нем өчен бу дөнья шул хачка кадакланды, ә мин – дөнья өчен.
15 Чөнки сөннәтнең дә, сөннәтсез булуның да һич әһәмияте юк,
фәкать Аллаһы тарафыннан яңа зат итеп яратылуыгыз гына
әһәмиятле. 16 Шушы кагыйдә буенча эш итүчеләргә һәм Алла-
һының чын халкына* да иминлек һәм шәфкать булсын.

17 Миңа һичкем авырлык тудырмасын, чөнки тәнемдә Гайсә-
нең яра эзләрен йөртәм. 18 Имандашлар, Раббыбыз Гайсә Мә-
сихнең мәрхәмәте сезнең рухыгыз белән булсын. Амин.

* 6:16 *Аллаһының чын халкы* – Бу сүзләр грек телендә сүзгә-сүз «Ал-
лаһының Исраиле».

# ПАУЛДАН ЭФЕСЛЕЛӘРГӘ ХАТ

**1** 1 Аллаһы ихтыяры белән Мәсих Гайсә рәсүле Паулдан Эфес
шәһәрендәге Мәсих Гайсәгә тугры изгеләргә 2 Атабыз Ал-
лаһыдан вә Раббы Гайсә Мәсихтән мәрхәмәт һәм иминлек
булсын!

*Мәсих Гайсә фатихалары*

3 Раббыбыз Гайсә Мәсихнең Аллаһысы һәм Атасы данлансын.
Ул безне Мәсих аркылы күктәге бөтен рухи байлыклар белән
фатихалады. 4 Без Аллаһы каршында изге һәм кимчелексез бул-
сын өчен, дөнья яратылганга кадәр үк Ул безне Мәсих аркылы
сайлап алды һәм безгә булган мәхәббәте бәрабәренә 5 Гайсә
Мәсих аркылы безне Үз балалары итәргә алдан ук билгеләп
куйды. Бу – Аның максаты һәм изге нияте иде! 6 Ул моны Үзе-
нең сөекле Улы аша безгә бүләк иткән бөек мәрхәмәте мактал-
сын өчен эшләде.
7 Без Мәсихтә, Аның каны аша йолып алынабыз, димәк, гө-
наһларыбыз кичерелә. Менә шундый чиксез Аллаһының мәр-
хәмәте. 8 Аллаһы бу мәрхәмәтен барлык зирәклек һәм белем
белән, мул итеп, өстебезгә яудырды. 9 Ул, Мәсихтә тормышка
ашырырга карар кылган нияте буенча, безгә Үз ихтыярының
яшерен максатын белдерде. 10 Аның бу нияте исә моннан гый-
барәт: билгеләнгән вакыт җиткәч, күк һәм җирдә булганнар-
ның барысын да Мәсихтә бер итеп берләштерү.
11 Һәммәсен Үз нияте һәм ихтыяры белән булдыручы Аллаһы
Үзенең максаты буенча алдан билгеләп, безне Мәсих аша сай-
лап алды да. 12 Безнең, Мәсихкә өмет баглаучыларның беренче-
ләре аркылы Аллаһының даны мактылсын дип эшләде Ул моны.
13 Мәсих аша сез дә хакыйкать сүзен, үзегезгә котылу китерүче
Яхшы хәбәрне ишетеп, Аңа иман иткәч, вәгъдә ителгән Изге
Рух белән Аллаһы тарафыннан мөһерләндегез. 14 Ә Аллаһы без-
не, Аныкы булганнарны, тулысынча азат иткәнче, Аллаһы
вәгъдә иткәнне алачагыбыз өчен Изге Рух ышанычлы дәлил бу-
лыр. Һәм шуның аркылы Аллаһының данына мактау булыр.

*Паулның догасы*

15 Боларның һәммәсе өчен мин дә, Раббы Гайсәгә иманыгыз
һәм бар изгеләргә карата мәхәббәтегез турында ишетеп, 16 дога-
ларымда искә алып, сезнең өчен Аллаһыга бертуктаусыз рәх-
мәт укыйм 17 һәм Раббыбыз Гайсә Мәсихнең Аллаһысы, данлы
Ата Үзен танып белү өчен сезгә зирәклек һәм ачылыш Рухы
бирсен дип дога кылам. 18 Шулай ук, Аның чакыруы сезгә нин-
ди өмет биргәнен, изгеләргә Үзе вәгъдә иткәннәрнең нинди
мул һәм данлы икәнен 19-20 һәм бездә, иман итүчеләрдә, хәрә-
кәт итүче куәтенең чагыштыргысыз бөек икәнен белүегезне те-
ләп, Ул күңел күзләрегезне яктыртсын дип дога кылам. Бу куәт
һәм Аллаһы Мәсихне үледән терелтеп, күкләрдә Үзенең уң
ягына утыртканда кулланган кодрәтле көч – бер үк. 21 Мәсих
анда күкләрдәге барлык башлыклар, хакимлекләр, куәтләр һәм
һәртөрле югары көчләр өстеннән бу дөньяда гына түгел, бәлки
киләчәк дөньяда да һәртөрле атаклы исемнәр белән аталган-
нардан югарырак булып хакимлек итә. 22 Аллаһы һәрнәрсәне
Мәсихкә буйсындырды һәм иман итүчеләр бердәмлеге өчен
Аны бар нәрсә өстеннән Баш итеп куйды. 23 Иман итүчеләр
бердәмлеге исә – Мәсихнең тәне, бар нәрсәдә бар нәрсәне ту-
тырып торучы Мәсихнең тулылыгы.

2 1 Сез яман эшләрегез һәм гөнаһларыгыз аркасында үле
идегез. 2 Шул вакытта сез бу дөньядагы явыз гадәтләргә,
һавадагы рухи көчләр белән идарә итүчегә, Аллаһыга ита-
гать итмәүче кешеләрдә хәзер гамәл кылучы рухка буйсынып
яшәдегез. 3 Кайчандыр барыбыз да алар кебек тәнебез һәм фи-
керләребезнең теләкләре буенча табигатебезнең теләкләрен
үтәп яшәдек. Без дә, калган башкалар кебек үк, табигый хәле-
без буенча Аллаһының каһәрен алырга тиеш идек. 4 Әмма чик-
сез шәфкатьле Аллаһы безгә Үзенең бөек мәхәббәтен күрсәтте:
5 безне, яман эшләребез аркасында үлеләрне дә, Мәсих белән
бергә терелтте. Сез Аның мәрхәмәте белән котылдыгыз. 6 Әйе,
Ул безне дә Мәсих Гайсә белән бергә үледән терелтте һәм
күкләрдә Аның белән янәшә утыртты. 7 Ул моны Мәсих Гайсә
аша безгә карата булган игелеге белән Үз мәрхәмәтенең чиксез
байлыгын киләчәк гасырларда күрсәтү өчен эшләде. 8 Чөнки
сез Аллаһы мәрхәмәте белән иман аша котылдыгыз. Бу сезнең
үзегездән түгел, бәлки Аллаһы бүләге. 9 Бу – кылган эшләре-
гезнең нәтиҗәсе түгел, шуңа күрә беркем дә мактанмасын.
10 Чөнки безне Аллаһы бар итте, Аның алдан әзерләнгән иге-
лекле эшләрен башкару өчен без Мәсих Гайсә аркылы барлык-
ка китерелдек.

*Мәсихтә бер булу*

11 Шулай итеп, элекке тормышыгызны исегезгә төшерегез.
Сезне, тумышыгыз белән яһүд милләтеннән булмаганнарны,
үзләре тән йоласын үтәп, «сөннәткә утыртылганнар» дип ата-
лучы кешеләр сезне «сөннәтсезләр» дип атыйлар иде. 12 Ул
чакта сез Мәсихсез, Исраил җәмгыятеннән читтә, Аллаһы Үз
халкына биргән вәгъдәгә нигезләнгән килешүләрдән ерак, бу
дөньяда өметсез һәм Аллаһысыз идегез. 13 Ул вакытта сез Алла-
һыдан ерак идегез, ә хәзер Мәсих Гайсәдә, Аның каны аркы-
лы, Аллаһыга якынлаштыгыз. 14 Чөнки Мәсих безгә татулык
алып килде, Ул яһүдләрне һәм яһүд булмаганнарны да бер
итте, Үз тәне белән аларны аерып торучы дошманлык киртәсен
җимерде. 15 Ул канунны әмерләре һәм кагыйдәләре белән бергә
гамәлдән чыгарды. Аның максаты болай иде: Үзендә бу ике
төркемнән яңа бер халык* булдыру һәм шуның белән татулык
урнаштыру, 16 Үзенең хачтагы үлеме белән араларындагы дош-
манлыкны юкка чыгарып, хач аша икесен бер тәндә Аллаһы
белән татулаштыру. 17 Шулай итеп, сезгә, Аллаһыдан ерактагы-
ларга, шулай ук Аллаһыга якын булганнарга да Мәсих килеп,
татулык турында Яхшы хәбәр игълан итте. 18 Чөнки Аның аша
безнең икебезнең дә, ягъни яһүд һәм яһүд булмаганнарның,
бер Рух белән Ата каршына бару юлыбыз бар. 19 Шулай итеп,
сез инде – читләр һәм килмешәкләр түгел, бәлки Аллаһы
халкының милләттәшләре һәм Аның гаиләсендәгеләр. 20 Сез
рәсүлләр һәм пәйгамбәрләр салган нигезгә** бина итеп тө-
зелгәнсез. Мәсих Гайсә исә – бу нигезнең иң мөһим почмак
ташы. 21 Ул бөтен бинаны бергә кушып тота, һәм бина өскә кү-
тәрелә-күтәрелә, Раббыга багышланган Изге йорт булып үсеп
җитә. 22 Мәсихтә сез дә, башкалар белән бергә, Аллаһы Үзенең
Рухы аркылы яши торган урын булып төзеләсез.

*Паулның башка халыклар арасында хезмәте*

**3** 1 Менә шуның өчен мин, Паул, сезнең хакка, ягъни яһүд
булмаганнар хакына, Мәсих Гайсәнең тоткыны буларак,
Аллаһыга дога кылам. 2 Аллаһы мәрхәмәте белән миңа сез-
нең өчен бирелгән вазифам турында ишеткәнсездер. 3 Инде

---

* 2:15 *Ике төркемнән яңа бер халык* – грекча сүзгә-сүз «икедән бер яңа кеше».

** 2:20 *Сез рәсүлләр һәм пәйгамбәрләр салган нигезгә* – Бу сүзләрне «Сез нигезе рәсүлләр һәм пәйгамбәрләр үзләре булган» дип тә аңларга мөмкин.

кыскача язып киткәнемчә, Аллаһы миңа серен ачып, Үзенең
ниятен белдерде. [4] Сез, язганнарымны укып, Мәсихнең серен
ни рәвешле аңлавымны күз алдына китерә алырсыз. [5] Әүвәлге
заманнарда бу сер кешеләргә мәгълүм ителмәде. Хәзер исә Ал-
лаһы аны Рух аркылы изге рәсүлләренә һәм пәйгамбәрләренә
ачып бирде. [6] Бу сер шуннан гыйбарәт: Мәсих Гайсә бәрабәре-
нә, Яхшы хәбәр аркылы яһүдләр белән бергә яһүд булмаганнар
да – варисташлар, бер тәннең әгъзалары һәм Аллаһы биргән
вәгъдәне уртаклашучылар.

[7] Аллаһы куәтенең хәрәкәте белән Ул биргән мәрхәмәт аркы-
лы мин Яхшы хәбәр тарату эшендә хезмәтче булдым. [8] Миңа,
барлык изгеләр арасында иң әһәмиятсезенә, мондый бүләк –
Мәсихнең чиксез байлыгын башка халыкларга белдерү [9] һәм
Аллаһы серенең ничек тормышка ашуын һәммәсенә ачыклау
хөрмәте бирелде. Һәрнәрсәне бар иткән Аллаһы бу серне иң
баштан ук яшереп тоткан иде. [10] Аллаһының максаты: иман
итүчеләр бердәмлеге аркылы Үзенең күпкырлы зирәклеген күк-
ләрдәге башлык һәм хакимлекләргә хәзер мәгълүм итү иде.
[11] Аллаһы моны иң баштан ук булган нияте буенча башкарды.
Бу ниятне Ул Раббыбыз Мәсих Гайсә аша тормышка ашыр-
ган иде. [12] Шулай булгач, Мәсих белән тыгыз бәйләнештә то-
рып, Аңа иман итү аша, без кыю рәвештә һәм һич икеләнүсез
Аллаһыга якынлаша алабыз. [13] Шуңа күрә, үтенәм сездән: сез-
нең хакка газап чигүемә күңелегезне төшермәгез; бу газаплар –
сезнең даныгыз өчен хезмәт итә.

*Мәсихнең мәхәббәте*

[14] Боларның һәммәсе өчен мин Ата алдында тез чүгеп ялва-
рам. [15] Аннан күкләрдә һәм җирдә булган һәр ыруг үзенә исем
ала. [16] Үз данының байлыгы белән, Үзенең Рухы аркылы эчке
яктан сезгә ныгырга куәт бирсен, [17] иман итүегез аша күңел-
ләрегездә Мәсих яшәсен, дип дога кылам. Сез мәхәббәттә та-
мыр җәеп һәм ныгып урнашкан хәлдә [18-19] бар изгеләр белән
берлектә Мәсих мәхәббәтенең киңлегенә вә озынлыгына,
биеклегенә вә тирәнлегенә тулысынча төшенә алсын һәм ке-
ше акылы сыйдыра алмаслык бу мәхәббәтне белсен, дип дога
кылам. Шулай итеп, сезне Аллаһының бөтен тулылыгы чол-
гап алыр. [20] Ә бездә хәрәкәт итүче куәт белән, сораганыбыз-
дан яки уйлаганыбыздан чагыштырмаслык дәрәҗәдә күбрәк
эшли Алучыга [21] – Аңа иман итүчеләр бердәмлегендә һәм
Мәсих Гайсәдә буыннан-буынга мәңге-мәңгегә дан булсын!
Амин.

### *Мәсих тәнендә бердәмлек*

**4** [1] Шулай итеп мин, Раббы хакына тоткын буларак, сез-
дән үтенәм: Аллаһыдан алган чакыруыгызга лаеклы итеп
яшәгез. [2] Һәрвакыт тыйнак, басынкы һәм сабыр булыгыз.
Бер-берегезгә мәхәббәт күрсәтеп, түземле булыгыз. [3] Рух бир-
гән бердәмлекне татулык бәйләнешләре белән ныгытып, бар
көчегезне куеп сакларга тырышыгыз. [4] Аллаһы сезне чакыр-
ган өмет тик бер генә булган кебек, сез барыгыз – бер тән,
һәм Рух та – бер. [5] Раббы – бер, иман – бер, суга чумдырылу
йоласы – бер, [6] Аллаһы – бер, Ул – барысының да Атасы. Ул
барысыннан да өстен, барысы аркылы эш итә һәм һәркемдә
дә бар.
[7] Мәсих Үзе кирәк санаганча һәрберебезгә Үзенең бүләклә-
реннән өлеш чыгарган. [8] Шуның өчен Изге язмада:
«Югарыга күтәрелгәч,
әсирләр төркемен
Үзе белән алып барды
һәм кешеләргә бүләкләр өләште», – дип язылган.
[9] Ә «югарыга күтәрелгәч» дигән сүзләр нәрсәне аңлата? Бу –
Мәсих түбән урыннарга, җиргә дә төшкән иде, дигәнне аңлата.
[10] Түбәнгә төшкән Зат, Үзе белән бөтен галәмне тутыру өчен,
бар күкләрдән югарырак күтәрелде дә. [11] Ул Үзе берәүләрне
рәсүлләр, икенчеләрне пәйгамбәрләр, кайберәүләрне Яхшы
хәбәрне игълан итүчеләр, ә кайберәүләрне иман итүчеләр бер-
дәмлеге өчен башлыклар* һәм өйрәтүчеләр итеп куйды. [12] Ул
моны изгеләрне хезмәт итүгә, Үзенең тәнен ныгытуга әзерләү
өчен эшләде. [13] Һәммәбез иманда һәм Аллаһы Улын танып бе-
лүдә бердәм булганга кадәр бу шулай дәвам итәр. Шулай итеп,
без иманда җитлеккән һәм Мәсихнең камиллеге дәрәҗәсенә
ирешкән кешеләр булырбыз.
[14] Ул чакта инде без, мәкерле кешеләрнең хәйләсенә алда-
нып, дулкыннар көймәне бер яктан икенче якка ыргыткандай
һәм җил аны үзе белән алып киткәндәй, төрле ялган тәгъли-
матларга иярүче сабыйлар булмабыз. [15] Киресенчә, хакыйкатьне
мәхәббәт белән сөйләп, Аңарга, тәннең Башы булган Мәсих-
кә, ярашлы рәвештә һәрьяклап үсик. [16] Аннан, тәннең һәр әгъ-
засы үзенә тиешле эш башкарганда, бер-берсен беркетүче һәр
сеңер ярдәмендә берләшеп, бөтен тән үсә һәм үз-үзен мәхәббәт
ярдәмендә ныгыта.

---

* **4:11** *Башлыклар* – грек телендә сүзгә-сүз «көтүчеләр».

*Гайсәдәге яңа тормыш*

[17-18] Шуңа күрә, Раббы исеменнән катгый рәвештә кисәтәм:
тормышыгызны буш уйлы мәҗүсиләр кебек дәвам итмәгез.
Үзсүзле булганга күрә, алар белергә дә теләмиләр, шунлыктан
акыллары чуалган һәм алар Аллаһы бирә торган тормыштан
аерылганнар. [19] Алар, оятларын югалтып, азгынлыкка бирел-
гәннәр һәм һәртөрле бозыклыкларны комсызлык белән эш-
лиләр. [20] Ә сез Мәсих хакында болай өйрәнмәдегез. [21] Сез,
әлбәттә, Аның турында ишеткәнсездер һәм, хакыйкать Гайсәдә
ачыла, дип өйрәткәнсездер. [22] Шулай итеп, алдавыч нәфесләр
белән азынган элекке кешенең алдагы яшәү рәвешеннән баш
тартыгыз. [23] Фикерләү рәвешегез исә яңарырга тиеш, [24] һәм сез
Аллаһыга охшаш итеп яратылган яңа кеше булып киенергә ти-
ешсез. Кешенең яңа булуы исә аның хакыйкатьтән килгән
тәкъва һәм изге тормышында күренә.

[25] Шуның өчен, ялганны кире кагып, бер-берегезгә хакый-
катьне сөйләгез, без барыбыз да бер тәннең әгъзалары бит.
[26] Хәтта ачуыгыз килсә дә, гөнаһ кылмагыз: кояш батканчы
ачуыгыз басылсын. [27] Һәм иблискә урын бирмәгез. [28] Элек ур-
лашкан, моннан соң урлашмасын, бәлки мохтаҗларга бирер-
леге булсын өчен, үз куллары белән файдалы эш эшләсен.
[29] Бернинди кирәксез сүз сөйләмәгез, киресенчә, тыңлаучылар-
га файда китерү өчен кирәк вакытта телегездә үгет-нәсыйхәт
бирерлек игелекле сүзләр генә булсын. [30] Аллаһының Изге Рухын
кайгыга салмагыз, чөнки сезне йолып алу көне өчен сугылган
мөһер – нәкъ Ул. [31] Бар ачыну, ярсу, ачу, кычкыру, яман телле-
лек һәм һәртөрле явызлыклардан баш тартыгыз. [32] Бер-берегезгә
карата игелекле, шәфкатьле булыгыз. Аллаһы сезне Мәсих аша
кичергән кебек, бер-берегезне кичерегез.

5 [1] Шулай итеп, Аллаһының сөекле балалары буларак, Аңа
ошарга тырышыгыз. [2] Мәсих безне яраткан кебек, сезнең
тормышыгыз белән дә мәхәббәт җитәкчелек итсен. Алла-
һыга хуш исле бүләк һәм корбан булып, Мәсих безнең өчен Үз
тормышын бирде.

[3] Әмма фәхешлек, һичнинди бозыклык һәм комсызлык ту-
рында сезнең арада сүз дә булырга тиеш түгел. Аллаһы кешелә-
ре изге булганга күрә, аларга болар килешми бит. [4] Шулай ук
оятсыз сүзләр, сафсата һәм кинаяле мәзәкләр сөйләү дә сезгә
килешми, киресенчә, вакытыгызны Аллаһыга шөкер итүгә
багышлагыз. [5] Сез беләсез бит: һичбер фәхеш, бозык, шулай
ук комсыз кеше (аның потка табынучыдан бернинди аермасы
да юк) Мәсих һәм Аллаһы Патшалыгыннан өлеш ала алмый.

*Яктылык кешеләре булып яшәгез*

6 Һичкем сезне буш сүзләр белән алдамасын, чөнки шулар
аркасында итагатьсезләргә Аллаһының ачуы килә. 7 Шуңа күрә
алар белән эш итмәгез. 8 Кайчандыр сез караңгылык идегез,
ә хәзер – Раббыныкы булганга – яктылык, димәк, яктылык
кешеләре булып яшәгез. 9 Чөнки яктылыкның җимеше – һәр-
төрле игелек, тәкъвалык һәм хакыйкать. 10 Аллаһыга мәгъкуль
булганны белергә тырышыгыз. 11 Караңгылыкның файдасыз
эшләрендә катнашмагыз, аларны фаш итегез. 12 Чөнки аларның
яшертен рәвештә эшләнгән эшләре турында хәтта сөйләргә дә
оят. 13 Әмма яктылык фаш иткән һәммә нәрсә ачык күренә-
чәк, чөнки яктылык ачык күрсәткән һәммә нәрсә үзе якты-
лык була. Шуңа күрә:
14 «Йоклаучы, уян!
Үледән терел!
Һәм Мәсих сине балкытыр», – дип әйтелгән.
15 Шуның өчен тормышта сак булыгыз, акылсызлар кебек тү-
гел, бәлки акыл ияләре кебек гомер итегез. 16 Һәрбер очрактан
дөрес файдаланыгыз, чөнки хәзер әшәке заман. 17 Шуңа күрә,
акылсыз булмагыз, бәлки Раббы ихтыярының нәрсә икәнлеге-
нә төшенегез. 18 Шәраб эчеп исермәгез, чөнки ул азгынлыкка
китерә, киресенчә, Изге Рух белән сугарылыгыз. 19 Бер-берегез
белән мәдхияләр, мактаулы шигырьләр һәм рухи җырлар аша
сөйләшегез, күңелегездән Раббыны данлап җырлагыз. 20 Һәр-
нәрсә өчен Раббыбыз Гайсә исеме аша Аллаһы Атага даими
рәвештә рәхмәт укыгыз.

*Хатыннар һәм ирләр*

21 Мәсихкә ихтирам йөзеннән бер-берегезгә буйсыныгыз.
22 Хатыннар, ирләрегезгә Раббыга буйсынган кебек буйсыны-
гыз. 23 Чөнки Мәсих иман итүчеләр бердәмлегенең Башы бул-
ган кебек, ир дә хатынның башы. Мәсих исә бердәмлекнең –
Үз тәненең Коткаручысы. 24 Бердәмлек Мәсихкә буйсынган ке-
бек, хатыннар да һәрнәрсәдә ирләренә буйсынсыннар.
25 Иман итүчеләр бердәмлеген яраткан һәм Үз тормышын
корбан иткән Мәсих кебек, ирләр, сез дә хатыннарыгызны
яратыгыз. 26 Ул бердәмлекне изгеләндерү өчен Үзен корбан
итте һәм сүз* аша су белән пакьләндерде. 27 Ул моны бердәм-
лекне бик гүзәл, һичнинди тапсыз, җыерчыксыз һәм башка

---

* 5:26 *Сүз* – яисә Раббының сүзе, яисә суга чумдырылу йоласы ва-
кытында әйтелгән сүзләр дип аңларга мөмкин.

җитешсезлекләрсез, ягъни изге һәм керсез итеп Үз алдына
китерү өчен эшләде. 28 Шулай ук ирләр үз тәннәрен ничек
яратсалар, хатыннарын да шулай яратырга тиеш. Хатынын ярату-
тучы – үзен ярата. 29 Беркем дә беркайчан да үз тәненә нәфрәт
итми бит. Киресенчә, һәркем аны тукландыра һәм аның ха-
кында кайгырта. Раббы да бердәмлек турында шулай кайгыр-
тучанлык күрсәтә. 30 Чөнки без – Аның тәненең әгъзалары.
31 Изге язмада язылганча: «Шуңа күрә адәм үз ата-анасын кал-
дырып, хатыны белән кушылыр, һәм икесе дә бер тән булыр».
32 Моның сере бөек: мин болай аңлыйм, бу сүзләр Мәсихкә һәм
бердәмлеккә кагыла. 33 Һәрхәлдә, һәрберегез үз хатынын үз-үзен
яраткан кебек яратсын, хатын исә ирен хөрмәт итсен.

*Балалар һәм ата-аналар*

6 1 Балалар, ата-аналарыгызны Раббы теләгәнчә итагать ите-
гез, чөнки бу шулай булырга тиеш. 2-3 «Үз атаңны һәм
анаңны хөрмәт ит» – бу Аллаһының вәгъдә өстәп бирел-
гән беренче әмере. Аңа өстәлгән вәгъдә моннан гыйбарәт:
«Шулай эшләсәң, синең өчен яхшы булыр һәм җирдә озын
гомерле булырсың».
4 Ә сез, аталар, балаларыгызның ачуын чыгармагыз, киресен-
чә, аларны, Раббының үгет-нәсыйхәтләрен истә тотып, тәр-
типкә өйрәтегез һәм тәрбияләгез.

*Коллар һәм хуҗалар*

5 Коллар, Мәсихкә итагать иткән кебек, җирдәге хуҗалары-
гызны да, курку катыш тирән хөрмәт белән, ихлас күңелдән
итагать итегез. 6 Сез моны хуҗаларыгыз күзәтеп торганда, алар-
га ярау өчен түгел, бәлки Аллаһының ихтыярын Мәсихнең
коллары буларак саф күңелегездән үтәгез. 7 Кешеләргә түгел,
бәлки Раббыга хезмәт иткән кебек, тырышып хезмәт итегез.
8 Раббының һәркемгә – ул кол булса да, ирекле булса да – эш-
ләгән игелеге өчен әҗер түләячәген беләсез.
9 Сез дә, хуҗалар, шулай мөгамәлә итегез. Янаулар кулланудан
туктагыз. Сезнең дә, аларның да Хуҗалары күкләрдә булуын
беләсез бит. Ул исә беркемне дә өстен күрми.

*Рухи кораллар*

10 Ниһаять, Раббы белән тыгыз бәйләнештә булуыгыз аркылы
һәм Аның кодрәтенең көче белән ныгыгыз. 11 Иблиснең мәкерле
ниятләренә каршы тора алу өчен, Аллаһы биргән махсус хәрби
киемнәр белән коралланыгыз. 12 Чөнки без кешеләргә каршы
түгел, бәлки күкләрдәге явыз рухи көчләргә, башлыкларга һәм

хакимлекләргә, бу караңгы дөнья белән идарә итүчеләргә каршы көрәшәбез. [13] Шуның өчен, начар көннәрдә дошманга каршылык күрсәтеп, ахыр чиккә кадәр көрәшкәч тә, бирешмичә нык тора алу өчен Аллаһы биргән махсус хәрби киемнәр белән коралланыгыз. [14] Шулай итеп, билегезне хакыйкать билбавы белән буып һәм тәкъвалык көбәсе киеп нык торыгыз, [15] иминлек турында Яхшы хәбәр белдерергә әзерлекне аяк киемнәре итеп киегез, [16] һәрчак иман калканын кулларыгызга алыгыз, аның ярдәмендә явыз иблиснең утлы укларын сүндерә алырсыз. [17] Коткаруны тимер башлык итеп киегез һәм Рух кылычын – Аллаһы сүзен кабул итегез. [18] Һәртөрле дога вә үтенеч белән Изге Рухның көче аркылы һәрвакыт дога кылыгыз.

Бу максат өчен, уяу булып, бар изгеләр өчен армый-талмый догада булыгыз. [19] Яхшы хәбәр серен кыюлык белән белдерүемне теләп, сөйли башлаганда миңа кирәкле сүзләр бирелсен өчен, минем өчен дә дога кылыгыз. [20] Бу Яхшы хәбәр хакына мин рәсүллек вазифасын башкарам һәм хәзер төрмәдә утырам. Минем Яхшы хәбәр турында тиешенчә кыюлык белән сөйли алуым өчен дога кылыгыз.

*Сәламнәр һәм изге теләкләр*

[21] Сез дә минем хәлләремне һәмниләр эшләвемне белсен өчен, сөекле имандашыбыз һәм Раббы хезмәтендә тугры ярдәмче Тухик барысын да сөйләп бирер. [22] Нәкъ менә шуның өчен, сез безнең хакта белеп торсын һәм Тухик күңелләрегезне юатсын дип, мин аны янныгызга җибәрәм.

[23] Аллаһы Атадан вә Раббы Гайсә Мәсихтән имандашларга иминлек һәм иман белән мәхәббәт булсын. [24] Раббыбыз Гайсә Мәсихне үлемсез сөю белән яратучыларның барысына да Аллаһының мәрхәмәте булсын.

# ПАУЛДАН ФИЛИППУЙЛЫЛАРГА ХАТ

1 [1] Филиппуйдагы иман итүчеләр бердәмлегенең җитәкчеләре
һәм ярдәмчеләре белән Мәсих Гайсәнеке булган бар изге-
ләргә Мәсих Гайсә коллары Паул һәм Тимутедән сәлам.
[2] Атабыз Аллаһы вә Раббы Гайсә Мәсихтән сезгә мәрхәмәт һәм
иминлек булсын.

*Паулның догасы*

[3] Сезне искә төшергән саен, мин Аллаһыма рәхмәт укыйм.
[4-5] Сез иң беренче көннән алып, хәзергә кадәр Яхшы хәбәр та-
ратуда катнашканга, мин һәр гыйбадәтемдә сезнең барыгыз
өчен шатланып дога кылам. [6] Сездә игелекле эш башлаган Ал-
лаһы аны Мәсих Гайсә килер көнгә чаклы дәвам итәр һәм
ахырына җиткерер дип инанам.
[7] Минем барыгыз турында да шулай уйлавым дөрес, чөнки
сез минем йөрәгемдә. Мин зинданда вакытта гына түгел, бәлки
Яхшы хәбәрне яклаган һәм аның дөреслеген раслаган чагында
да, сез барыгыз да минем белән Аллаһының мәрхәмәтен бүле-
шәсез. [8] Сезнең һәммәгезне дә Мәсих Гайсә мәхәббәте белән
сагынуыма Аллаһы шаһит. [9] Мәхәббәтегез белемдә дә, һәртөрле
зирәклектә дә артканнан арта барсын, [10] сез иң яхшыларны
сайлап ала белсен, шуның белән Мәсих килер көнгә саф һәм
кимчелексез калсын, [11] Гайсә Мәсих аша тәкъвалык җимешләре
белән тутырылсын, дип дога кылам. Шул очракта Аллаһыга дан
һәм мактау булыр.

*Тоткынлык һәм үлемгә әзер булу*

[12] Имандашлар, минем белән булган хәлләрнең Яхшы хәбәр
таралуда зур файда китергәнен белүегезне телим. [13] Нәтиҗәдә,
сарайда яшәүчеләрнең барысына һәм калган башкаларга да тер-
мәдә Мәсих хакына утыруым мәгълүм булды. [14] Өстәвенә, иман-
дашларымның күбесе, төрмәдә утыруымны белеп, Мәсихтән

ышаныч алдылар һәм Аллаһы сүзен курыкмыйча, тагын да кыюрак сөйли башладылар.
[15] Дөрес, аларның кайберләре Мәсих турында көнчелек аркасында һәм бер-берсен уздырырга тырышып, башкалар исә яхшылык кылу нияте белән игълан итәләр. [16] Бу кешеләр моны мәхәббәткә таянып эшли, чөнки Яхшы хәбәрне якларга Аллаһы тарафыннан куелганымны беләләр. [17] Теге кешеләр исә Мәсих турында чын күңелдән түгел, бары үзләренә файда эзләгәнлектән һәм зиндандагы хәлемне авырайту йөзеннән вәгазьлиләр.
[18] Әмма моның бернинди дә әһәмияте юк. Мәсих турында ничек кенә вәгазьләмәсеннәр – риялы яки изге ниятләр беләнме – мин барыбер моңа бик куанам һәм киләчәктә дә шатланып туя алмаячакмын, [19] чөнки беләм: бу, сезнең догаларыгыз һәм Гайсә Мәсих Рухының ярдәме белән, миңа ирекккә чыгарга булышыр.
[20] Мин бернәрсәдә дә оятка калмам, хәзер дә һәрвакыттагыча батыр булырмын һәм яшәгән яки үлгән очракта да Мәсихне данлармын дип ашкынам һәм өметләнәм. [21] Чөнки минем өчен тормыш – Мәсих, һәм үлем – табыш кына. [22] Әгәр яшәвем белән күбрәк файдалы эшләр кыла алам икән, бу очракта кайсын сайларга да белмим. [23] Миңа ике мөмкинлекнең берсен сайларга туры килә. Бу дөньяны калдырып, Мәсих белән бергә булырга дигән көчле теләгем бар, бу чагыштыргысыз яхшырак. [24] Әмма сезнең өчен минем исән булуым, ягъни монда яшәвем әһәмиятлерәк. [25] Моңа инанганлыктан, шуны беләм: мин калачакмын һәм, сезнең имандагы уңышыгыз һәм куанычыгыз өчен, барыгыз белән бергә булачакмын. [26] Шулай итеп, яныгызга кабат килүем белән минем аркада Мәсих Гайсәдә куанычыгыз тулып ташыр.

*Иман өчен бердәм көрәш*

[27] Нәрсә генә булмасын, Мәсих турындагы Яхшы хәбәргә лаеклы булып яшәгез. Шулай итсәгез, сезгә киләмме яки сезнең турыда ишетәмме, сезнең, бер тында нык торып, Яхшы хәбәргә иман хакына кулга-кул тотынып көрәшүегезне белермен. [28] Дошманнардан һичнәрсәдә курыкмагыз: курыкмавыгыз – алар өчен һәлакәт, ә сезнең өчен котылу билгесе һәм бу – Аллаһыдан. [29] Чөнки сезгә Мәсих хакына иман итү генә түгел, бәлки Аның өчен газап чигү өстенлеге дә бирелде. [30] Шулай булгач, сез дә мин кичергән һәм, ишеткәнегез кебек, хәзер дә кичерә торган шул ук көрәшкә керәсез.

*Бер-берегез турында уйлагыз*

2 [1] Шулай итеп, әгәр Мәсихтә күңелегезне күтәрәсез икән,
әгәр Аның мәхәббәте сезгә юаныч бирә икән, әгәр сез Рух
аша аралашасыз икән, әгәр сездә ягымлылык белән шәф-
кать бар икән, [2] минем шатлыгымны тулыландырыгыз: бер үк
фикергә ия булып, бер мәхәббәтне уртаклашып, бер максат һәм
бердәм нияттә булыгыз. [3] Үзегезгә файда эзләп яки масаеп һич-
нәрсә эшләмәгез, киресенчә, кундәм булыгыз һәм башкаларны
үзегезгә караганда өстен күрегез. [4] Һәркем үзе турында гына тү-
гел, бәлки башкалар хакында да кайгыртсын.

*Мәсихнең кундәмлеге*

[5] Мөгамәләләрегез Мәсих Гайсәнеке кебек булсын.
6 Табигате буенча Аллаһы булып та,
Ул Аллаһыга тиң булуын күрсәтергә тырышмады.
7 Бәлки, кол кыяфәте алып,
Үз теләге белән бар нәрсәдән баш тартты.
Ул кеше булды
Һәм кешеләр арасында яшәде.
8 Ул Үзен түбәнсетте
Һәм үлеменә кадәр,
хәтта хачтагы үлеменә кадәр,
Аллаһыга кундәм булды.
9-11 Шуңа күрә күктәгеләрнең, җирдәгеләрнең
һәм җир астындагыларның барысы да
Гайсә исеме алдында тез чүксен,
Һәм Ата Аллаһының даны өчен
һәрбер тел Гайсә Мәсихне Раббы дип икърар итсен
дип,
Аллаһы Аны барысыннан да югары күтәрде
һәм Аңа бөтен исемнән бөегрәк исем бирде.

*Аллаһыга яраклы булыгыз*

[12] Сөеклеләрем, сез мине һәрчак тыңладыгыз. Шулай итеп,
мин сезнең арагызда булганда гына түгел, бәлки, бигрәк тә хә-
зер, сезнең янда булмаганда да, үзегезнең котылуыгыз хакына
хезмәтегезне курку һәм тирән хөрмәт белән ахыргача дәвам
итегез. [13] Чөнки Аллаһы Үзенең игелекле ихтыяры белән, эш
итү өчен, сездә теләк һәм сәләт тудыра. [14] Һәр эшне зарлан-
мыйча һәм бәхәсләшмичә эшләгез; [15] шул чагында гына азгын
һәм бозык кешеләр арасында гаепсез, саф һәм Аллаһының
кимчелексез балалары булып калырсыз. [16] Мәсих килер көндә

минем тырышлыгым һәм хезмәтем юкка булмаган дип горур-
лана алсын өчен, бу кешеләргә тормыш сүзен тәкъдим итеп,
алар арасында күктәге йолдызлар кебек җемелдәгез. 17 Әгәр, кор-
бан буларак Аллаһыга тәкъдим ителгән иманыгызга һәм хезмә-
тегезгә өстәп, хәтта үз җанымны фида кылсам да, мин куанам
һәм сезнең барыгыз белән дә шатлыгымны уртаклашам. 18 Сез
шулай ук куаныгыз һәм минем белән бергә шатланыгыз.

*Тимуте һәм Эпафрудит турындагы хәбәрләр*

19 Раббы Гайсә ярдәме белән тиздән Тимутене сезгә җибәрер-
мен дип ышанам. Ул сезнең хәлегезне белеп, минем дә күңе-
лемне күтәрер иде. 20 Сезнең хакта аның кебек ихлас күңелдән
кайгыртучы башка беркемем дә юк. 21 Чөнки барысы да, Гайсә
Мәсихкә мәгъкуль булганны түгел, бәлки үзләре турында гына
кайгырталар. 22 Үзенең ышанычлылыгын күрсәткәнлеге сезгә
билгеле, чөнки ул Яхшы хәбәр таратуда, үз атасы белән хезмәт
итүче угыл кебек, минем белән бик тырышып хезмәт итте.
23 Шуңа күрә, эшләремнең ни хәлдә торуын күргәч тә аны сез-
нең янга җибәрермен дип өметләнәм. 24 Үземнең дә тиздән
сезгә барачагыма Раббыга ышанычым бар.
25 Сезнең тарафтан миңа ярдәмгә җибәрелгән илче туганым,
хезмәттәшем һәм көрәштәшем Эпафрудитны кире кайтаруны
кирәк санымйм. 26 Чөнки ул барыгызны да бик сагына һәм, сезгә
аның авырганлыгы турында ишетелгәч, бик күңелсезләнде.
27 Ул чыннан да бик нык авырый, хәтта үлем хәлендә иде, әмма
Аллаһы аңа гына түгел, бәлки, кайгы өстенә кайгы булмасын
дип, миңа да мәрхәмәт күрсәтте. 28 Шуңа күрә, аны яңадан
күреп куанырсыз һәм, минем дә кайгым бетәр дип, аны сезгә
тагын да теләбрәк җибәрәм. 29 Сез барыгыз да Раббыныкы бул-
ганга, аны зур шатлык белән сәламләгез һәм аның кебекләргә
хөрмәт күрсәтегез. 30 Чөнки хезмәтегезнең җитешмәгән җирлә-
рен җиткерү өчен, үз гомерен куркыныч астына куеп, Мәсих
эше өчен ул аздан гына үлми калды.

*Мәсих барысыннан да бөегрәк*

**3** 1 Имандашларым, йомгаклап әйтәм, Раббыныкы булганга
күрә куаныгыз. Сезгә бер үк нәрсә турында язу миңа һич
тә мәшәкать тудырмый, һәм бу сезнең өчен дә саклану ча-
расы булыр.
2 «Этләрдән» сакланыгыз! Яманлык кылучылардан сакланыгыз!
Дөрес булмаган сөннәтләүне таләп итүчеләрдән сакланыгыз!
3 Чөнки чын сөннәтлеләр – без, тән йолаларына ышанучылар
түгел, бәлки Аллаһыга Рухы белән гыйбадәт кылучылар һәм

Мәсих Гайсә белән горурланучылар. 4 Хәер, мин андый йолаларга да ышана алам. Әгәр башка берәү тән йолаларына ышанырга уйласа, мин тагын да күбрәк инана алам: 5 мин – туып, җиде көн үткәч, сөннәткә утыртылган, Исраил халкыннан, Биньямин кабиләсеннән, еврей ата-анадан туган еврей, яһүдләр кануныңа мөнәсәбәтем буенча фарисей. 6 Бар гайрәтем Мәсих бердәмлеген эзәрлекләүгә юнәлгән иде. Ә инде канун таләпләрен үтәү аша булган тәкъвалыкка килгәндә, миңа бәйләнер урын юк иде.
7 Әмма хәзер исә минем өчен табышлы булганнарны Мәсих хакына югалту дип саныйм. 8-9 Алай гына да түгел, Раббым Мәсих Гайсәне танып белү өстенлеге белән чагыштырганда, бар нәрсәне дә мәгънәсез дип уйлыйм. Аның өчен мин һәрнәрсәдән баш тарттым һәм Мәсихкә ия булу хакына һәм Аныкы булуым ачык күренсен өчен, калган бар нәрсәне чүп-чар дип исәплим. Минем хаклыгым канунны үтәү аша түгел, минем хаклык – Мәсихкә иман аша, ул Аллаһыдан һәм иманга нигезләнгән. 10 Мин Мәсихне һәм Аның үледән терелүе кодрәтен белергә, Аның газапларын уртаклашырга, Аның үлемендә Аңа охшашлы булырга
11 һәм ничек булса да үледән терелтелүгә ирешергә өметләнәм.

*Максатыгызга ирешергә омтылыгыз*

12 Мин инде барысына ирештем яки камилләштем, димим, әмма Гайсә Мәсих мине нәрсә өчен сайлап алган булса, шуңа ирешергә тырышам. 13 Имандашлар, мин үземне теләгемә ирештем дип санамыйм, бәлки, үткәнемне онытып һәм алга омтылып, 14 максатыма ашкынам, Аллаһы мине Мәсих Гайсә аша алырга чакырган бүләккә – күкләрдәге тормышка ирешергә ашыгам. 15 Шулай итеп, безнең арада кем дә булса рухи яктан җитлеккән икән, шулай ук фикер йөртергә тиеш; әгәр сез берәр нәрсә хакында башкача фикер йөртәсез икән, Аллаһы моны да сезгә ачачак. 16 Әмма ләкин тормышыбызны үзебез ирешкәннәр буенча дәвам итик.

17 Туганнар, барыгыз да миннән үрнәк алыгыз һәм без күрсәткән үрнәк буенча яшәүчеләргә күз салыгыз. 18 Чөнки күпләр Мәсих хачына дошман булып яшиләр, алар турында мин сезгә еш сөйләдем, ә хәзер хәтта күз яшьләремне түгеп әйтәм.
19 Аларның язмышы – һәлакәт, аларның илаһы – карын, аларның даны – оялырга тиешле нәрсәләр белән горурлану. Алар бары дөньяви гамәлләр турында уйлыйлар. 20 Безнең Ватаныбыз исә күкләрдә. Коткаручыны, Раббыбыз Гайсә Мәсихне без шуннан ашкынып көтәбез. 21 Ул безнең гаҗиз тәнебезне үзгәртер һәм, һәрнәрсәне Үзенә буйсындыра алучы көче ярдәмендә, Үзенең данлы тәненә охшашлы итәр.

*Үгет-нәсыйхәт*

**4** 1 Шулай итеп, сөекле һәм зарыгып көткән имандашларым,
минем бәхетем һәм дан таҗым, Раббы белән берләшүдә
нык торыгыз, кадерлеләрем.

*Сәламнәр*

2 Әүдия белән Сүнтүхиянең икесе дә Раббыныкы булганга
күрә бер үк фикердә булуларын үтенәм. 3 Әйе, синнән дә үте-
неп сорыйм, тугрылыклы көрәштәшем, зинһар өчен бу хатын-
нарга ярдәм ит, чөнки алар да, Климис һәм исемнәре Тормыш
китабына язылган башка хезмәттәшләрем дә минем белән
Яхшы хәбәр тарату хакына көрәштеләр. 4 Һәрвакыт Раббыда
куаныгыз; кабатлап әйтәм: куаныгыз! 5 Сезнең башкаларга илти-
фатлы булуыгыз һәркемгә мәгълүм булсын. Раббы якынлаша.
6 Һичнәрсә турында борчылмагыз, әмма теләсә нинди хәлдә дә
дога кылганда, ялварып сораганда Аллаһы каршында үтенечлә-
регезне шөкер итеп белдерегез. 7 Һәм һәр акылдан өстенрәк бул-
ган Аллаһы иминлеге сезнең йөрәкләрегезне һәм фикерләре-
гезне Мәсих Гайсәдә саклаячак. 8 Ниһаять, туганнарым, әгәр
нинди дә булса яхшылык һәм мактауга лаек эшләр бар икән,
нәрсә хак, хөрмәтле, дөрес, саф, ягымлы, шөһрәткә лаеклы –
шулар турында фикер йөртегез. 9 Нәрсәгә өйрәндегез, миннән
нәрсә кабул иттегез һәм ишеттегез, миндә нәрсә күрдегез – бо-
ларның барын да тырышып башкарыгыз һәм иминлек Аллаһы-
сы сезнең белән булыр.

*Бүләкләр өчен рәхмәт белдерү*

10 Шундый озак вакыт узганнан соң, минем хакта яңадан
кайгырта башлавыгызга, мин Раббыда бик нык сөенәм. Әлбәт-
тә, сез һәрвакыт минем турыда кайгырттыгыз, әмма моны күр-
сәтергә мөмкинлегегез генә булмады. 11 Моны мохтаҗлыктан
чыгып әйтмим, чөнки мин булганы белән канәгатьләнергә өй-
рәндем. 12 Мин фәкыйрьлектә дә, муллыкта да яшәдем; тукмы
яки ачмы, муллыкта яки мохтаҗлыкта яшимме, һәрвакыт һәм
төрле хәлләрдә дә канәгать булырга өйрәндем. 13 Мин көч Би-
рүче аша һәрнәрсәгә әзер торам. 14 Шулай да, минем михнәт
чигүемне уртаклашып, сез яхшы эшләдегез. 15 Сез, филиппуй-
лылар, беләсез: Яхшы хәбәр таратыла башлаганда, мин Маке-
дониядән киткәч, миңа сездән башка һичбер иман итүчеләр
бердәмлеге дә матди ярдәм күрсәтмәде. 16 Сез исә ихтыяҗымны
канәгатьләндерү өчен берничә мәртәбә Тессалуникә шәһәренә
дә ярдәм җибәрдегез. 17 Моны бүләк өмет итеп әйтмим, әмма

табышның сезнең хисапка өстәлгән кебек булуын телим.
18 Мин бөтенесен һәм артыгын да алдым. Эпафрудит аша сез
җибәргәннәрнең барын да алдым һәм тулысынча тәэмин ител-
дем. Алар – хуш исле, Аллаһының күңеленә ятышлы, Аңа ярак-
лы корбан. 19 Һәм минем Аллаһым сезнең бар ихтыяҗлары-
гызны Мәсих Гайсәдәге данлы байлыгыннан канәгатьләндерер.
20 Атабыз һәм Аллаһыбызга мәңгелектән мәңгелеккә дан бул-
сын. Амин.

21 Һәр иман итүчене Гайсә Мәсихтә сәламләгез. Минем белән
бергә булган туганнар сезне сәламли. 22 Сезне барлык имандаш-
лар, бигрәк тә кайсар сараендагылар сәламли.

23 Раббыбыз Гайсә Мәсихнең мәрхәмәте сезнең барыгыз бе-
лән дә булсын.

# ПАУЛДАН КӨЛЕССӘЙЛЕЛӘРГӘ ХАТ

**1** 1-2 Көлессәйдә яшәүче изгеләргә һәм Мәсихкә тугры ту-
ганнарга Аллаһының ихтыяры белән Мәсих Гайсәнең рәсү-
ле Паулдан һәм Тимуте туганнан сәлам. Сезгә Атабыз Ал-
лаһыдан мәрхәмәт һәм иминлек булсын.

*Аллаһыга рәхмәт белдерү*

3 Сезнең өчен дога кылганда, Аллаһыга, Раббыбыз Гайсә
Мәсихнең Атасына, һәрвакыт рәхмәт укыйбыз, 4 чөнки Мәсих
Гайсәгә иманыгыз һәм барлык изгеләргә булган мәхәббәтегез
турында ишеттек. 5 Иманыбызның һәм мәхәббәтегезнең сәбә-
бе – сезнең өчен күкләрдә саклап тотыла торган өмет. Бу өмет
турында сез элек Яхшы хәбәрнең хак сүзендә ишеткән идегез.
6 Сезгә килеп җиткән бу Яхшы хәбәр, сез Аллаһы мәрхәмәте-
нең чынлыкта ничек булуын аңлаган көннән бирле арагызда
ничек булса, бөтен дөньяда да шулай зур уңыш китерә һәм та-
рала. 7 Сез Аллаһы мәрхәмәте турында безнең хакка Мәсихкә
турылыклы хезмәтче, сөекле хезмәттәшебез Эпафрастан өй-
рәндегез; 8 ул безгә Рухтан килгән мәхәббәтегез турында да
хәбәр итте.
9 Шуңа күрә, бу турыда ишеткән көннән бирле, сез Изге Рух
тарафыннан бирелгән бар зирәклек һәм аң белән Аллаһының
ихтыярын тулысынча танып белсен дип, сезнең өчен дога кы-
лудан һәм ялварып сораудан туктамыйбыз. 10 Һәр игелекле эше-
гез җимеш китереп, сез Аллаһыны танып белүдә үскәннән-үсә
барып, Раббыга лаеклы булып яшәрсез һәм һәрнәрсәдә Аңа
яраклы булырсыз, дип дога кылабыз. 11 Сез чыдам һәм сабыр
булсын өчен Аның искиткеч бөек кодрәте сезне һәртөрле куәт-
тә ныгытсын. 12 Сезне яктылык патшалыгында Үз халкы өчен
саклаган бүләктән өлеш алырга яраклы иткән Атага сез сөенеп
рәхмәт әйтегез. 13 Ул караңгылык хакимлегеннән коткарып, без-
не Үзенең сөекле Улы Патшалыгына алып керде, 14 һәм Аның
Улы аша без йолып алынабыз, димәк, гөнаһларыбыз кичерелә.

*Мәсих һәм Аның хезмәте*

15 Мәсих – күзгә күренмәс Аллаһының чагылышы, Ул – Бе-
ренче Угыл, яратылганнарның барысыннан да өстенрәк,
16 чөнки күктә һәм җирдә булган, күренгән һәм күренмәгән-
нәрнең һәммәсе Аның аркылы яратылган: җитәкче көчләрме,
өстен көчләрме, башлыкލармы, хакимлекләрме – барысы
Аның аша һәм Аның өчен яратылган. 17 Аллаһы Улы һәрнәр-
сәдән элек булган, һәм Аның аркасында бар нәрсә үз уры-
нында тора. 18 Ул – тәннең Башы, ә тән – Аңа иман итүчеләр
бердәмлеге; һәрнәрсәдә беренче булсын өчен Ул – Башлан-
гыч, үледән тереләселәр арасыннан иң беренче булып торган,
19 чөнки Аллаһы бөтен тулылыкның Улында яшәвен мәгъкуль
күрде. 20 Шулай итеп, Аның аркылы, Аның хачта түгелгән ка-
ны белән тынычлык урнаштырып, җирдә һәм күктә булган
һәр нәрсәне Аның аша Үзе белән татуландыруны мәгъкуль
күрде.
21 Һәм сезне, фикерегез һәм яман эшләрегез аркасында элег-
рәк Аллаһыга чит һәм дошман булганнарны, 22 хәзер Үз алдын-
да изге, кимчелексез һәм гаепсез итеп күрсәтү өчен, Улының
тәне аркылы, Аның үлеме аша Үзе белән татулаштырды. 23 Әм-
ма сез, иманыгызда нык һәм тайпылмыйча торып, үзегез ишет-
кән Яхшы хәбәр биргән өметтән читләшмәскә тиеш. Бу Яхшы
хәбәр дөньядагы һәр җан иясенә игълан ителгән һәм мин,
Паул, аның хезмәтчесе булдым.

*Паулның бердәмлеккә хезмәт итүе*

24 Хәзер сезнең өчен кичергән михнәтләремә сөенәм һәм
Үзенең тәне булган иман итүчеләр бердәмлеге өчен Мәсихнең
газап чигүләренең җитмәгән кадәрен үземнең тән газапларым
белән тулыландырам. 25 Мин, Аллаһы кушуы буенча, бердәм-
лек хезмәтчесе булдым. Ул, сезгә яхшылык эшләү йөзеннән,
миңа Үз сүзен бөтен тулылыгы белән игълан итәргә тапшырды.
26 Бу сүз – гасырлардан һәм нәселләрдән бирле яшерен сер,
хәзер исә ул Аның изгеләренә ачылды. 27 Халыклар арасында
Аллаһы бу сернең бай һәм данлы булуын белдерергә теләде.
Бу сер: Мәсих – сездә, Ул – Аллаһы данын уртаклашу өчен
өметегез!
28 Без һәр кешегә Мәсих турында игълан итәбез. Һәр кешене
камил мәсихче итеп Аллаһыга тәкъдим итү өчен аңа нәсыйхәт
бирәбез һәм бар зирәклеккә өйрәтәбез. 29 Бу максатка ирешү
өчен, Мәсихнең миндә куәтле хәрәкәт итүче көче белән, үзем-
не кызганмыйча, мин бу авыр хезмәтне башкарам.

2 [1] Сезнең хакка, Лаудикеядә яшәүчеләр хакына һәм мине
күрмәгән барлык кешеләр хакына минем нинди тырыш-
лык куюымны белүегезне телим; [2] мин моны, алар мәхәб-
бәттә берләшеп, күңелләре күтәрелсен һәм төшенү алып килә
торган ышануның тулы байлыгына ия булсыннар өчен эшлим.
Шул рәвешчә алар Аллаһының серен – Мәсихне белерләр.
[3] Аңарда зирәклекнең һәм белемнең бөтен хәзинәләре яшерен-
гән. [4] Мин моны, ялагай сүзләр белән сезне һичкем алдамасын
өчен сөйлим, [5] чөнки тәнем белән сезнең янда булмасам да,
рухым белән – яныгызда һәм сездәге тәртипне, Мәсихкә има-
ныгызның ныклыгын күреп куанам.

*Мәсихтәге яңа тормыш*

[6] Мәсих Гайсәне Раббы* итеп кабул иткәнсез икән, Аның бе-
лән берлектә яшәгез**. [7] Аңарда тамыр җәегез һәм төпләнегез,
үзегезгә өйрәтелгән иман буенча ныгыгыз һәм бервакытта да
рәхмәт укырга онытмагыз.
[8] Сак булыгыз, Мәсих тәгълиматына түгел, бәлки дөньяның
идарә итүче көчләренә нигезләнеп, буш һәм алдавыч фәлсәфә
белән сезне һичкем кол итмәсен, [9] чөнки Аллаһы бөтен тулы-
лыгы белән Мәсихтә гәүдәләнеп яши. [10] Мәсих – һәммә баш-
лык һәм хакимлек өстеннән Баш, сезгә Аның аркылы тулы
тормыш бирелгән. [11] Сез Аңарда, кеше кулы белән башкарыл-
ган сөннәт белән түгел, бәлки гөнаһлы табигать хакимлегеннән
нән азат ителү белән, димәк, Мәсих сөннәте белән сөннәтлән-
дегез дә. [12] Сез суга чумдырылу йоласын үтәгәндә Аның белән
бергә күмелдегез һәм, Аны үледән терелткән Аллаһының код-
рәтенә ышану аркасында, Аның белән бергә терелдегез дә.
[13] Сез гөнаһларыгыз аркасында һәм яһүд булмаган өчен үлек
булганда, Аллаһы сезне Аның белән бергә терелтте һәм барлык
гөнаһларыбызны кичерде. [14] Ул, безгә каршы булган, Муса ка-
нунын тотмаганлыктан, безне гаепләгән бурычларыбыз исем-
леген кагыйдәләре белән юкка чыгарды һәм, хачка кадаклап,
аны бөтенләй алып ташлады; [15] өстен көчләр һәм хакимлекләр-
не бирелергә мәҗбүр итте һәм Мәсих аркасында җиңүне тантa-
на итеп***, аларны бар халык алдында фаш итте.

---

* 2:6 *Раббы* – Бу сүз Аның кешелек өстеннән, бөтен матди һәм рухи дөнья өстеннән Хуҗа икәнен күрсәтә.

** 2:6 *Аның белән берлектә яшәгез* – грекча сүзгә сүз: «Аның Үзендә (эчендә) йөрегез».

*** 2:15 *Мәсих аркасында җиңүне тантана итеп* – Бу сүзләрне грек теленнән болай да аңларга мөмкин: «хачта алар өстеннән тантана итеп».

[16] Шулай итеп, ризык һәм эчемлек өчен яисә нинди дә булса
бәйрәм яки яңа ай яисә шимбә көннәренә кагылышлы сораулар өчен сезне һичкем хөкем итмәсен. [17] Болар – киләчәкнең
күләгәсе генә, ә чынбарлык – Мәсихтә. [18] Ясалма тыйнаклыктан һәм фәрештәләргә табынудан ләззәт табучы һичкем сезне
савап алу хокукыннан мәхрүм итмәсен. Андый кеше үзе күргәннәр белән горурлана, кешелек акылының буш уйлары аны
масаючан итә. [19] Ул Мәсихне, димәк, тәннең Башын тотмый.
Ә бөтен тән бары тик Башка таянып кына, буыннары һәм
сеңерләре белән үзара беркетелеп һәм ныгытылып, Аллаһы
кушуы буенча үсә бит.

*Мәсихтәге яңа тормыш*

[20] Сез Мәсих белән бергә үлдегез һәм бу дөньяның хакимлек итүче көчләреннән котылдыгыз. Ни өчен соң үзегезне, бу
дөньяда яшәүчеләр кебек: [21] «кагылма», «татыма», «тимә» кебек
карарларга буйсындырасыз? [22] Болар бары тик кеше уйлап чыгырган кагыйдәләргә һәм тәгълиматларына гына кагыла һәм
аларның барысы да кулланганнан соң юкка чыгачак. [23] Боларның фәкать тышкы яктан, үзләре сайлаган табынуда, ясалма
тыйнаклыкта һәм тәнгә карата катгый чаралар куллануда гына
зирәклеге бар, әмма җенси нәфесне тыюда аларның бернинди
файдасы юк.

*Иске һәм яңа тормыш*

**3** [1] Сез Мәсих белән бергә терелеп тордыгыз, шуңа күрә
күктәге нәрсәләргә ашкыныгыз, Мәсих анда Аллаһының
уң ягында утыра; [2] җирдәге нәрсәләр турында түгел, һәрвакыт күктәгеләр турында уйлагыз. [3] Чөнки сез иске тормыш
өчен үлдегез, ә сезнең яңа тормышыгыз Мәсих белән бергә
Аллаһыда яшеренгән. [4] Сезнең тормышыгыз – Мәсих, һәм Ул
килгәндә сез дә Аның данын уртаклашып, Аның белән бергә
килерсез.

[5] Шулай итеп, үзегездәге дөньяви теләкләрне: фәхешлек,
пычраклык, нәфес, хайвани теләкне һәм потка табынуга тиң
булган комсызлыкны үтерегез. [6] Менә шулар өчен Аллаһының
ачуы килә*. [7] Кайчандыр сез дә боларны эшләгәндә шул юлларда йөрдегез. [8] Ә хәзер сез боларның һәммәсеннән: ачу, ярсу,
усаллык, яман теллелек һәм әдәпсез сүзләрдән сакланып калыгыз; [9] бер-берегезгә ялган сөйләмәгез, чөнки сез бөтен кылган

---

* 3:6 Кайбер кулъязмаларда болай язылган: «Менә шулар өчен Үзенә итагатьле булмаганнарга Аллаһының ачуы килә».

гамәлләрегез белән элекке яшәү рәвешегезне киемне салгандай
салып ташладыгыз [10] һәм яңа кеше булып киендегез. Бу яңа ке-
шене Булдыручы Аллаһы, Үзе турында тулы белемгә илтү өчен,
сезне һәрвакыт Үзенә охшашлы итеп яңартып тора. [11] Шуңа
күрә яһүд булмаганнар һәм яһүдләр, сөннәтле һәм сөннәтле
булмаганнар, вәхшиләр, кыргыйлар*, коллар һәм ирекleләр
арасында бернинди аерма юк, әмма Мәсих – һәммәсе һәм
барысында. [12] Шулай итеп, сез, сөекле изгеләр, Аның сайла-
ганнары буларак, шәфкатьле, яхшы күңелле, күндәм, басынкы,
түземле булыгыз. [13] Бер-берегезгә сабырлык күрсәтегез һәм,
бер-берегезгә карата шикаятегез булса, бер-берегезне кичере-
гез; Мәсих сезне кичергән кебек, сез дә бер-берегезне киче-
регез. [14] Бу сыйфатларның барысына тагын мәхәббәтне өстәгез,
ул, һәммәсен берләштереп, камиллеккә илтә. [15] Йөрәкләрегез-
дә Аллаһының иминлеге хакимлек итсен. Сез, бер тәннең әгъ-
залары булып, нәкъ менә шушы иминлеккә чакырылдыгыз һәм
рәхмәтле булыгыз. [16] Мәсих сүзе сездә муллык белән урнаш-
сын; бер-берегезне бөтен зирәклек белән өйрәтегез һәм нә-
сыйхәт итегез; мәдхияләр, мактаулы шигырьләр һәм рухи җыр-
лар җырлап, күңелләрегездән Аллаһыга рәхмәт укыгыз. [17] Сез
нәрсә генә эшләсәгез яки ни генә сөйләсәгез – барын да
Раббы Гайсә Мәсихкә таянып һәм Аның аша Ата Аллаһыга
шөкер итеп эшләгез.

*Яңа тормыштагы мөнәсәбәтләр*

[18] Хатыннар, Раббыга иман итүчеләр үзләрен ничек тотарга
тиеш булса, ирләрегезгә шулай буйсыныгыз. [19] Ирләр, хатын-
нарыгызны яратыгыз һәм аларга кырыс булмагыз. [20] Балалар,
һәрнәрсәдә ата-аналарыгызның сүзен тыңлагыз, чөнки бу –
Раббыга мәгъкуль. [21] Аталар, балаларыгыз өметсезлеккә би-
релмәсен өчен, аларны ярсытмагыз. [22] Коллар, дөньядагы
хуҗаларыгызга һәрнәрсәдә буйсыныгыз, кешеләргә ярарга
тырышучылар кебек булмагыз, хезмәт итүегез күз буяу өчен
булмасын, бәлки, тирән хөрмәт белән, Аллаһыдан куркып, саф
күңелдән эшләгез.
[23-24] Раббыдан савап алачагыгызны белеп, нәрсә генә эшлә-
сәгез дә, һәммәсен кешеләр өчен түгел, бәлки Раббы өчен

---

* 3:11 *Вәхшиләр* – грекча «барбарос», ягъни милләте буенча греклар түгел һәм грек телен белмәүче, җәмгатьнең иң түбән катлавыннан булган кыргый кешеләр. *Кыргыйлар* – русча «скиф» дигәнне аңлата. Греклар аларны вәхшиләргә караганда да кыргыйрак дип исәпләгәннәр.

эшләгән кебек ихлас күңелдән эшләгез, чөнки сез Раббы
Мәсихкә хезмәт итәсез. 25 Ә хаксызлык кылучы үзенең кыл-
ган хаксызлыгын кайтарып алачак; Аллаһы каршында барысы
да тигез.

**4** [1] Хуҗалар, күктә сезнең дә Хуҗагыз барлыгын истә то-
тып, колларыгызга намуслы һәм гадел мөнәсәбәт күрсә-
тегез.

### *Төрле үгет-нәсыйхәтләр*

2 Армый-талмый догада булыгыз, шөкер итеп уяу торыгыз.
3 Бер үк вакытта, Мәсих сере турында игълан итү өчен Аллаһы
безгә ишек ачсын дип, безнең өчен дә дога кылыгыз – мин ме-
нә шуның өчен тоткынлыкта бит. 4 Мин кешеләргә ул серне
тиешенчә ачык һәм аңлаешлы итеп сөйли алсын өчен дога кы-
лыгыз. 5 Чит кешеләр белән, һәрбер уңайлы очрактан файдала-
нып, төпле акыл белән мөгамәлә кылыгыз. 6 Һәркемгә ничек
җавап бирергә кирәклеген белегез, сүзегез һәрвакыт ягымлы,
мавыктыргыч һәм төпле булсын.

### *Соңгы сәламнәр*

7 Минем турыда сезгә ышанычлы хезмәтче һәм Раббы эшендә
хезмәттәшебез, сөекле Тухик туган барысын да хәбәр итәр.
8-9 Хәлебез турында белдерү һәм күңелләрегезне күтәрү өчен,
мин аны сездән килгән ышанычлы һәм сөекле туганыбыз
Онисим белән бергә яныгызга җибәрәм: алар мондагы барлык
хәлләр турында сезгә сөйләп бирерләр. 10-11 Минем белән бергә
зинданга ябылган Аристарх сезгә сәлам тапшыра һәм Барнаб-
ның туганнан-туган кардәшенең улы Марк (аның турында,
янызга килсә, аны кабул итегез, дигән әмер алдыгыз) һәм
шулай ук Юсты дип тә аталган Гайсә сезгә сәлам тапшыра.
Алар – Аллаһы Патшалыгы өчен минем белән бергә хезмәт
итүчеләр арасында Мәсихкә иман итүче яһүдләрнең бердән-
берләре; алар миңа зур юаныч булдылар. 12 Сездән килгән
Эпафрас, Мәсих Гайсә колы, сәлам тапшыра. Аллаһының бар
ихтыярында җитлеккән булуыгыз һәм иманда торуыгыз өчен
ул һәрвакыт сезнең өчен бик тырышып дога кыла. 13 Аның ту-
рында шаһитлек бирәм: ул сезнең хакка, Лаудикея һәм Һиера-
полис шәһәрендәгеләр хакына бик авыр хезмәт башкара. 14 Без
яраткан табиб Лүк һәм Димас сезне сәламли. 15 Лаудикеядәге
имандашларга, Нумфага һәм аның өендә җыела торган иман
итүчеләр бердәмлегенә сәлам әйтегез.
16 Бу хатны укыгач, аны Лаудикеядәге иман итүчеләр бер-
дәмлегендә дә укысыннар өчен, шунда җибәрегез, ә Лаудикея

бердәмлегенә язылган хатны сез дә укыгыз. 17 Архипка: «Ка-
ра, Раббыдан кабул иткән хезмәтне ахырына җиткерү өчен
игътибарлы бул», – диегез. 18 Бу сәламне мин, Паул, үз кулым
белән язам. Минем төрмәдә утыруымны онытмагыз. Мәрхәмәт
сезнең белән булсын.

# ПАУЛДАН ТЕССАЛУНИКӘЛЕЛӘРГӘ БЕРЕНЧЕ ХАТ

**1** [1] Паулдан, Силастан һәм Тимутедән Тессалуникәдәге иман
итүчеләр бердәмлегенә, Ата Аллаһы һәм Раббы Гайсә Мә-
сих өммәтенә* мәрхәмәт һәм иминлек булсын.

*Тессалуникәлеләрнең иманы*

[2] Без һәрвакыт, догаларыбызда сезне искә алып, барыгыз
өчен дә Аллаһыга рәхмәтләр укыйбыз. [3] Сез иман аркылы
башкарган эшләрне, мәхәббәт белән илһамландырылган авыр
хезмәтегезне һәм Раббыбыз Гайсә Мәсихкә өмет баглап нык
торуыгызны Аллаһыбыз һәм Атабыз алдында без һәрвакыт
исебездә тотабыз.
[4] Имандаш туганнар, без беләбез: Аллаһы сезне ярата, Ул
сезне сайлап алды. [5] Чөнки без сөйләгән Яхшы хәбәр сүзләрдә
генә түгел, ә кодрәт, Изге Рух һәм тирән ышану белән сезгә
барып иреште. Сезнең белән бергә вакытта сезнең өчен ничек
яшәгәнебезне беләсез. [6] Сез, ул хәбәрне күп газаплар эчендә
Изге Рухтан килгән шатлык белән кабул итеп, безне һәм шулай
ук Раббыны кабатлаучылар булдыгыз. [7] Шулай итеп, сез Маке-
дуния һәм Ахая өлкәләрендә яшәүче барлык иман итүчеләргә
үрнәк булдыгыз. [8] Раббының сүзе сезнең аркылы Македуния
һәм Ахая өлкәләрендә генә ишетелеп калмаган, сезнең Алла-
һыга иман итүегезне һәркайда беләләр. Шуңа күрә безгә тагын
нәрсәдер сөйләргә кирәк тә түгел. [9-10] Безне ничек кабул итүегез
турында кешеләр безгә үзләре сөйлиләр. Шулай ук, хак һәм те-
ре Аллаһыга хезмәт итү өчен, Аллаһы Углының – Гайсәнең –
күкләрдән килүен көтү өчен потларны калдырып Аллаһыга
таба борылуыгыз хакында әйтәләр. Аллаһы Аны үледән те-
релтте, Ул безне Аллаһының якынлашып килүче ачуыннан
коткарачак.

---

* [1:1] *Гайсә Мәсих өммәте* – Гайсә Мәсихкә иман итүче кешеләр.

*Паулның Тессалуникәдәге хезмәте*

2 [1] Имандаш туганнар, белгәнегезчә, сезнең янга килеп китүебез файдасыз булмады. [2] Үзегез беләсез, элегрәк без Филиппуйда газаплар кичердек, безне хурладылар. Ләкин, көчле каршылыкларга карамастан, Аллаһыдан килгән Яхшы хәбәрне сезгә сөйләргә Аллаһыбыз безгә кыюлык бирде. [3] Безнең өйрәтүебез ялгыш та түгел, начар уйлар белән дә түгел. Без берәүне дә алдарга теләмибез. [4] Киресенчә, Яхшы хәбәрне тарату эшен ышанып тапшырырга Аллаһы безне лаеклы дип тапкан, шуңа күрә без Аның ихтыяры буенча сөйлибез. Сөйләгәндә, кешеләргә түгел, ә йөрәкләребезне сынаучы Аллаһыга ярарга тырышабыз.

[5] Белгәнегезчә, без беркайчан да ялагайланып сөйләмәдек. Безнең сүзләр комсызлыкны каплау өчен әйтелмәде. Аллаһы – безгә шаһит! [6] Без кешеләрдән – сездән дә, башкалардан да – дан көтмәдек. [7] Мәсихнең рәсүлләре буларак, сездән таләп итә алыр идек, ләкин без сезнең белән булганда, ана кеше үзенең сабыйлары турында кайгырткандай, сезгә карата ягымлы булдык. [8] Сезне шулай нык яратканга күрә Аллаһының Яхшы хәбәрен җиткерү генә түгел, сезнең өчен җаннарыбызны бирергә әзер идек. Чөнки безнең өчен шундый кадерле булдыгыз. [9] Имандаш туганнар, эшебезне һәм авыр хезмәтебезне хәтерлисез бит. Сезгә Аллаһының Яхшы хәбәрен сөйләгәндә, берегезгә дә йөк булмас өчен, көне-төне эшләдек. [10] Сезнең алда, иман итүчеләр алдында, изге, тәкъва һәм кимчелексез булганлыгыбызга сез һәм шулай ук Аллаһы шаһит. [11] Ата кеше үз балаларына карата ничек булса, без дә һәрберегезгә карата шулай булдык, һәм сез бу турыда беләсез. [12] Без шулай итеп сезне дәртләндердек, юаттык, Үз Патшалыгына һәм данына чакыручы Аллаһының ихтыяры буенча яшәргә өндәдек.

*Аллаһы сүзе үз эшен эшли*

[13] Тагын шуның өчен Аллаһыга һәрвакыт рәхмәтләр әйтәбез: без җиткергән Аллаһы сүзен сез кешедән булган хәбәр итеп түгел, ә чынында ничек булса, шулай итеп, Аллаһы сүзе итеп кабул иттегез; һәм шул сүз сездә, иман итүчеләрдә, үз эшен эшли. [14] Имандаш туганнар, сез Мәсих Гайсәнең Яһүдиядә урнашкан Аллаһы бердәмлекләре кебек булдыгыз: алар яһүдләрдән җәфа чиккән кебек, сез дә үз милләттәшләрегездән җәфа чиктегез. [15] Яһүдләр Раббы Гайсәне һәм пәйгамбәрләрне үтерделәр, безне куып җибәрделәр. Алар Аллаһыга да мәгъкуль түгел, бар кешеләргә дә каршы. [16] Без, башка халыклар котыла

алсын өчен, аларга сөйләргә телибез, ә яһүдләр безгә комачаулаpга тырыша. Һәрвакыт шундый эшләр кылып, алар үз гөнаһларын күбәйткәннәр һәм, ниһаять, Аллаһының ачуы алар өстенә төшкән.

*Паулның тессалуникәлеләрне күрергә теләве*

[17] Ә без, туганнар, сезнең белән кыска вакытка аерылыштык (күңелләребез түгел, ә тәннәребез генә аерылышты) һәм сезне шундый сагындык, үзегезне бик нык күрәсебез килде. [18] Сезнең яныгызга барырга теләдек. Мин, Паул, берничә тапкыр. Ләкин шайтан безгә комачаулады. [19] Раббыбыз Гайсә килгәндә, сез – Аның алдында безнең өчен өмет, шатлык һәм мактау таҗы бит.
[20] Әйе, сез – безнең даныбыз һәм шатлыгыбыз!

**3** [1] Шуңа күрә, без бүтән көтеп тора алмадык, Афинада үзебез генә калырга булдык [2-3] һәм, эзәрлекләүләргә карап берегез дә борчылмасын өчен, сезне ныгытырга, иманыгызны дәртләндерергә дигән максат белән Мәсихнең Яхшы хәбәрен вәгазьләүдә Аллаһының хезмәттәше булган Тимуте туганыбызны сезнең янга җибәрдек. Безгә эзәрлекләүләр билгеләнгән. Бу турыда сез үзегез дә беләсез. [4] Безнең белән шундый эзәрлекләүләр булачагы хакында алдан, без бергә булган вакытта әйткән идек һәм, белгәнегезчә, шулай булды да. [5] Шуңа күрә, мин бүтән көтеп тора алмадым, иманыгызның ныклыгы хакында белергә теләп, Тимутене сезнең янга җибәрдем. Чөнки, аздыручы* сезне коткыга керткән һәм хезмәтебез бушка киткән, дип хәвефләндем.

*Тимутенең куанычлы хәбәре*

[6] Ә хәзер Тимуте Тессалуникәдән кайтты һәм безгә иманыгыз һәм мәхәббәтегез хакындагы куанычлы хәбәрне җиткерде. Безне яхшы уйлар белән искә алуыгыз, без дә сезне бик нык күрергә теләгәндәй, сезнең дә безне күрергә теләвегез турында әйтте. [7] Шуңа күрә, туганнар, сезнең иманыгыз турында ишеткәч, барлык газаплар һәм эзәрлекләүләр эчендә күңелебез юанды. [8] Сез Раббыда нык торасыз икән, димәк без дә яшибез.
[9] Сезне уйлап, Аллаһыбыз алдында кичергән шатлык өчен Аңа нинди рәхмәтләр әйтик? [10] Сезнең белән күрешергә һәм иманыгызга җитешмәгән нәрсәләрне бирергә теләп, көне-төне тырышлык белән дога кылабыз.

[11] Аллаһы Атабыз Үзе һәм Раббыбыз Гайсә сезнең янга барыр юлыбызны турайтсын. [12] Безнең сезгә булган мәхәббәтебез кебек

---

* 3:5 *Аздыручы* – шайтан дигән мәгънәдә.

Раббыбыз сезнең дә бер-берегезгә һәм барлык кешеләргә карата булган мәхәббәтегезне арттырсын, мул итсен: 13 Раббыбыз Гайсә Үзенең изгеләре белән килгәндә, Аллаһы Атабыз алдында сез керсез, изге булсын өчен, Рабби шулай итеп йөрәкләрегезне ныгытсын.

*Аллаһының теләге: изге булыгыз*

4 1 Аллаһыны канәгатьләндерү өчен ничек яшәргә кирәклеге турында өйрәткән идек, һәм сез шул өйрәтүләр буенча яшисез. Ә хәзер, имандашлар, без һәммәбез Раббы Гайсәнеке булганга күрә, сездән үтенеп сорыйбыз: тагын да зуррак тырышлыклар куегыз. 2 Гайсә Мәсихнең вәкаләте белән сезне нәрсәләргә өйрәткәнебез турында беләсез. 3 Аллаһының теләге: сезнең изге булуыгыз. Ул җенси азгынлыкны читкә этәрүегезне тели. 4 Һәрберегез үз тәнен изгелектә һәм кадерләп сакларга өйрәнсен иде. 5 Аллаһыны белмәгән мәҗүсиләр кебек дәрт һәм шәһвәт* кушканга иярмәгез. 6 Бу яктан берегез дә үз туганыгызга явызлык эшләмәгез, үзегезгә файда эзләп, аны кулланмагыз, чөнки андый эшләр кылган һәр кеше Раббы тарафыннан җәзага тартылачак. Без сезгә бу турыда кисәтү ясап әйткән идек инде. 7 Аллаһы безне шакшы булырга түгел, ә изге булып яшәү өчен чакырды. 8 Шуңа күрә бу өйрәтүләрне кире кагучы зат кешеләрне түгел, ә сезгә Үзенең Изге Рухын җибәрүче Аллаһыны кире кага.

9 Имандашларыгызны яратуга килгәндә, бу турыда язуның кирәге юктыр. Чөнки Аллаһы сезнең үзегезне бер-берегезне яратырга өйрәтте 10 һәм, чынлап та, сез бөтен Македуния өлкәсендәге барлык имандашларны яратасыз. Сездән үтенеп сорыйбыз, имандаш туганнар: тагын да ныграк тырышыгыз.

11 Без кушканча, тыныч яшәргә, үз эшегез белән генә шөгыльләнергә һәм ризыгыгызны үз кулларыгыз белән эшләп табарга тырышыгыз. 12 Шулай эшләсәгез, чит кешеләр алдында әдәпле булырсыз, үзегезнең ихтыяҗларыгызда беркемгә дә бәйле булмассыз.

*Раббының килүе*

13 Имандаш туганнар, сез өметсез кешеләр кебек кайгырмасын өчен, үлем йокысына киткәннәр турында белүегезне телибез. 14 Без Гайсәнең үлгәненә һәм үледән терелгәненә ышанабыз. Шуңа күрә, Гайсәгә иман итеп үлем йокысына киткәннәрне Аллаһы Аның белән кире кайтарачак. 15 Без сезгә

---

* 4:5 *Шәһвәт* — җенси дәрт.

хәзер әйтәчәк сүзләр – Раббы сүзләре. Без, исәннәр – Раббы
килгәнче яшәячәк кешеләр – үлем йокысына киткәннәрдән
алдарак булмабыз. 16 Боерык ишетелгәндә, җитәкче фәрештә-
нең һәм Аллаһы быргысының тавышы астында күкләрдән
Раббы Үзе төшәчәк һәм Мәсихкә ышанып үлгәннәр беренче
булып тереләчәкләр. 17 Шуннан соң без, исәннәр – монда кал-
ганнар – һавада Раббыны каршы алу өчен, алар белән бергә
болытларда һавага алыначакбыз һәм мәңгегә Раббы белән
бергә булачакбыз. 18 Шулай итеп, бер-берегезне шушы сүзләр
белән дәртләндерегез.

5 1 Бу хәлләрнең кайчан булачагы турында язуыбызның ки-
рәге юк, туганнар. 2 Чөнки сез үзегез бик яхшы беләсез:
Раббы көне, төнлә белән карак кергәндәге кебек, көтмә-
гәндә килеп җитәчәк. 3 Кешеләр: «Бар да тыныч, куркыныч тү-
гел», – диярләр. Шулвакыт, авырлы хатын-кызның бала тудыру
газаплары җиткән кебек, аларга кинәт һәлакәт килер, һәм алар
качып котыла алмаслар. 4 Әгәр сез караңгылыкта булсагыз, ул
көн сезнең өчен карак кебек көтмәгәндә килер иде, ә сез, туган-
нар, караңгылыкта түгел. 5 Чөнки сез барыгыз да яктылыкныкы
һәм көннеке. Без төннеке һәм караңгылыкныкы түгел. 6 Шулай
итеп, башкалар кебек йоклап ятмыйк, бәлки уяу һәм аек бу-
лыйк. 7 Йокыдагылар төнлә йоклыйлар, эчеп исерүчеләр төнлә
эчеп исерәләр. 8 Ә без, яктылыкныкылар булганга күрә, иманны
һәм мәхәббәтне көбә кием итеп, котылуга булган өметне тимер
башлык итеп киеп аек булыйк. 9 Чөнки Аллаһы безне ачуга дучар
булу өчен түгел, ә Раббыбыз Гайсә Мәсих аркылы котылу кабул
итүебез өчен билгеләде. 10 Раббыбыз Гайсә Мәсих, үлем йокы-
сында булсак та, исән булсак та, без Аның белән бергә яши ал-
сын дип, безнең өчен үлде. 11 Шуңа күрә хәзер ничек эшлисез,
бер-берегезне шулай дәртләндерегез һәм рухи яктан ныгытыгыз.

*Паулның үгет-нәсыйхәте*

12 Имандаш туганнар, арагызда авыр хезмәт куючы, сезгә
үгет-нәсыйхәт кылучы, Раббыны уйлап сезгә юнәлеш бирүче
кешеләрне хөрмәт итегез. 13 Хезмәтләре өчен аларга карата бик
ихтирамлы булыгыз һәм аларны яратыгыз. Бер-берегез белән
тыныч яшәгез.

14 Без сездән, туганнар, үтенеп сорыйбыз: эшсез утыручылар-
ны үгетләгез, курка торганнарны дәртләндерегез, хәлсезләргә
ярдәм итегез. Бар кешеләргә карата түземле булыгыз. 15 Кара-
гыз аны, берәү дә явызлыкка явызлык белән җавап бирмәсен.
Һәрвакыт бер-берегезгә һәм бар кешеләргә яхшылык эшләргә
тырышыгыз.

16 Һәрвакыт шатланыгыз. 17 Бертуктаусыз дога кылыгыз.
18 Нинди генә шартларда калсагыз да Аллаһыга рәхмәтләр әй-
тегез, чөнки сездән, Гайсә Мәсихнеке булган кешеләрдән, Алла-
һы шуны тели.

19 Изге Рухны сүндермәгез. 20 Пәйгамбәрлек итүгә кимсетеп
карау булмасын. 21 Аллаһыданмы, түгелме икәнен белү өчен бар
нәрсәне сынап карагыз, яхшылыкка нык тотыныгыз, 22 һәртөр-
ле явызлыктан читкә китегез.

23 Аллаһы Үзе, тынычлык чыганагы, сезне бөтен килеш изге
итсен. Раббыбыз Гайсә Мәсих килгәндә Ул бөтен барлыгыгыз-
ны: рухыгызны да, күңелегезне дә, тәнегезне дә саф килеш сак-
ласын. 24 Сезне Чакыручы моны эшләячәк, чөнки Ул тугры.

25 Имандашлар, безнең өчен дә дога кылыгыз. 26 Бар имандаш
туганнарны изге үбү белән сәламләгез. 27 Раббының абруе бе-
лән таләп итәм: бу хатны барлык имандаш туганнарга укыгыз.
28 Раббыбыз Гайсә Мәсихнең мәрхәмәте сезнең белән булсын.

# ПАУЛДАН ТЕССАЛУНИКӘЛЕЛӘРГӘ ИКЕНЧЕ ХАТ

1 [1] Паулдан, Силастан һәм Тимутедән Тессалуникәдәге иман
итүчеләр бердәмлегенә, Атабыз Аллаһы һәм Раббы Гайсә
Мәсих өммәтенә сәлам. [2] Сезгә Атабыз Аллаһыдан һәм
Раббы Гайсә Мәсихтән мәрхәмәт һәм иминлек булсын.

*Паулның дәртләндерү сүзләре*

[3] Без һәрвакыт сезнең өчен Аллаһыга рәхмәтләр әйтергә тиеш,
имандаш туганнар. Һәм шулай эшләү – дөрес, чөнки сезнең
иманыгыз нык үсә, һәркайсыгызның бер-берегезгә карата булган
мәхәббәте арта бара. [4] Шуңа күрә, без сез кичерә торган барлык
эзәрлекләүләр һәм газаплар эчендә булган түземлелегегез һәм
иманыгыз белән Аллаһының бердәмлекләре алдында мактана-
быз. [5] Боларның барысы да Аллаһы хөкеменең гадел икәнен күр-
сәтә. Нәтиҗәдә, сез Аллаһы Патшалыгына керергә лаеклы дип
саналырсыз: сез Аллаһы Патшалыгы өчен инде газап чигәсез.
[6] Сезнең газап чигүегезгә гаепле кешеләргә кайгы-хәсрәт бирү,
ә сезгә, җәфа чигүчеләргә, һәм безгә тынычлык бүләк итү – Ал-
лаһы алдында гадел. [7-8] Ул моны Раббы Гайсә күкләрдән Үзенең
куәтле фәрештәләре белән ялкынланып янып торган утта кил-
гәндә эшләр. Раббы Гайсә Аллаһыны белмәүчеләрне һәм Раббы-
быз Гайсә турындагы Яхшы хәбәрне тыңламаучыларны җәзага
тартыр. [9] Аларга җәза мәңгелек һәлакәт булыр, алар Раббы янын-
нан һәм Аның кодрәтле шөһрәтеннән аерып алынырлар. [10] Ул
көнне Раббы Үзенең изгеләреннән дан, Үзенә иман китергәннәр-
нең барысыннан да мактау кабул итү өчен киләчәк. Сез дә алар
арасында булырсыз, чөнки без сөйләгән хәбәргә ышандыгыз.
[11] Шуңа күрә, без һәрвакыт сезнең өчен дога кылабыз, Ал-
лаһыбыз сезне Үзе чакырган тормыш юлына лаеклы итсен, һәр
яхшы ниятне һәм иман эшен Үзенең көче белән төгәлләсен,
дип сорыйбыз. [12] Аллаһының һәм Раббыбыз Гайсә Мәсихнең
мәрхәмәте буенча Раббыбыз Гайсә Мәсих сездә шулай итеп
данланыр һәм үзегез дә Аңарда данлыклы булырсыз.

*Канунсызлык кешесе турында*

2 [1] Раббыбыз Гайсә Мәсихнең килүе һәм Аның янына җыела-
чагыбыз турында язып китәбез. Имандаш туганнар, сездән
үтенеп сорыйбыз: [2] ашыгыч фикер йөртеп, акылыгызны
югалтмагыз. Раббының көне җитте, дип рух игълан иткән пәй-
гамбәрлек сүзе дә, яки кемдер әйткән сүз дә, яки янәсе бездән
килгән хат та сезне борчымасын. [3] Карагыз аны, сезне беркем
дә алдамасын. Чөнки зур чуалыш булмыйча һәм һәлакәткә хө-
кем ителгән канунсызлык кешесе ачылмыйча торып, Раббының
килү көне җитмәячәк. [4] Ул кеше алла дип аталган һәм кешеләр
табына торган һәр нәрсәгә каршы чыгып, үзен югары күтәрә-
чәк, Аллаһы Йортына кереп утырачак һәм үзен Аллаһы дип
игълан итәчәк. [5] Мин сезнең яныгызда булганда шул турыда
сөйләгәнемне хәтерләмисезме әллә?
[6] Канунсызлык кешесе билгеләнгән вакытта ачылсын өчен,
аны нәрсә тоткарлап торуын сез хәзер беләсез. [7] Канунсыз-
лыкның яшерен көче инде хәрәкәттә, ләкин тоткарлаучы үзе
алынганчы тоткарлавын дәвам иттерәчәк. [8] Канунсыз ачылгач,
Раббы Гайсә аны Үзенең тыны белән үтерәчәк, килүенең бал-
кышы аны юк итәчәк. [9] Шайтан йогынтысы астында канунсыз
зур көч, ялган галәмәтләр, ялган могҗизалар күрсәтеп килер.
[10] Һәртөрле явыз ялганнарны һәлакәткә баручыларга каршы
кулланыр. Алар һәлакәткә баралар, чөнки алар үзләрен котка-
ра алырдай хакыйкатьне яратудан баш тарттылар. [11] Шуңа күрә,
Аллаһы аларга зур ялгышу җибәрер, һәм алар ялганга ышаныр-
лар. [12] Нәтиҗәдә, хакыйкатькә ышанмыйча явызлыктан тәм та-
бучылар хөкем ителерләр.

*Аллаһы сезне сайлады: нык торыгыз*

[13] Сезнең өчен, имандаш туганнар, Раббының сөеклеләре, без
һәрвакыт Аллаһыга рәхмәтләр әйтергә тиешбез, чөнки Рух-
ның сезне изге итүе аркылы, хакыйкатькә ышануыгыз аркылы
Аллаһы сезне беренче булып котылу өчен сайлады. [14] Сез Раб-
быбыз Гайсә Мәсихнең шөһрәтенә ирешсен өчен, без сөйләгән
Яхшы хәбәр аркылы Аллаһы сезне сайлады һәм шушы котылу-
га чакырды. [15] Шуңа күрә, туганнар, нык торыгыз, без сөйләгән
яки хатлар аша сезгә җиткергән өйрәтүләргә тотыныгыз.
[16] Раббыбыз Гайсә Мәсих Үзе һәм безгә Үзенең мәхәббәтен
күрсәткән, Үзенең мәрхәмәтлелегендә мәңгелек юану, как-
шамас өмет биргән Атабыз Аллаһы [17] сезнең дә күңелләрегезне
юатсын, һәртөрле яхшы эшләрне башкарырга һәм яхшы сүзләр
сөйләргә сезне ныгытсын.

*Безнең өчен дога кылыгыз*

**3** [1] Әйтелгәннәргә өстәп, сездән сорыйбыз, туганнар, безнең өчен дога кылыгыз: сездәге кебек, башка җирләрдә дә Раббының сүзе тиз таралсын һәм ихтирам ителсен. [2] Шулай ук бозык һәм явыз кешеләрдән арынсак иде, чөнки бар кешеләр дә иман итмиләр бит.

[3] Ә Раббы Ул – тугры. Ул сезне ныгытыр һәм явыздан саклар. [4] Раббыдан килгән ышануыбыз аркылы, без кушканнарны башкаруыгызга һәм киләчәктә дә башкарачагыгызга иманыбыз камил*. [5] Раббы сезнең йөрәкләрегезне Аллаһының мәхәббәтенә һәм Мәсих бирә торган түземлелеккә юнәлтсен.

*Ялкаулык турында кисәтү*

[6] Имандаш туганнар! Раббыбыз Гайсә Мәсих исеменнән сезгә әмер итәбез: бездән кабул иткән өйрәтүләр буенча яшәмичә ялкаулыкта гомер кичерә торган имандашлар белән аралашмагыз. [7] Безнең үрнәк буенча ничек яшәргә тиеш икәнегезне үзегез беләсез. Без сезнең арагызда яшәгәндә ялкауланмадык. [8] Беркемнең дә ипиен бушлай ашамадык, берегезгә дә йөк булмас өчен, көне-төне тырышып эшләдек. [9] Сорарга хакыбыз булмаган өчен түгел, ә сез ияреп эшләсен өчен, сезгә шулай үрнәк күрсәттек. [10] Янызда булганда без сезгә: «Кем эшләми, шул ашамый», – дигән сүзләрне кагыйдә итеп әйткән идек. [11] Без сезгә бу турыда язабыз, чөнки кайберләрегезнең ялкаулыкка салышулары, бернәрсә эшләмичә башка кешеләрнең хезмәтләренә керүләре турында ишеттек. [12] Андый кешеләргә Раббы Гайсә Мәсихнең исеме белән әмер итәбез һәм өндибез: үз ризыкларын, үзләре хезмәт куеп, тыныч кына эшләп тапсыннар. [13] Ә сез, имандаш туганнар, яхшылык эшләргә арымагыз.

[14] Әгәр дә берәрсе бу хатта язылган сүзләрне тыңламаса, ул кешегә игътибарыгызны юнәлтегез һәм, аның ояты килсен өчен, аның белән аралашмагыз. [15] Ләкин ул кешене дошман дип исәпләмәгез, ә туганга караган кебек итеп үгетләгез.

[16] Тынычлык чыганагы Раббы Үзе сезгә һәрвакыт һәм һәр эштә иминлек бирсен. Раббы барыгыз белән дә булсын.

[17] Мин, Паул, үз кулым белән сәламләү сүзләрен язам. Бу сүзләр һәр хатымның миннән икәнен күрсәтә. Мин шулай язам. [18] Барыгыз белән дә Раббыбыз Гайсә Мәсихнең мәрхәмәте булсын!

---

* 3:4 *Раббыдан килгән ышануыбыз аркылы иманыбыз камил* – Бу сүзләр грек телендә: «Раббыда иманыбыз камил».

# ПАУЛДАН ТИМУТЕГӘ БЕРЕНЧЕ ХАТ

1 [1] Коткаручыбыз Аллаһы һәм өметебез Мәсих Гайсәнең әмере буенча Мәсих Гайсә рәсүле Паулдан [2] имандагы үз улым Тимутегә: Ата Аллаһы вә Раббыбыз Мәсих Гайсәдән мәрхәмәт, шәфкать, иминлек булсын.

*Ялган тәгълиматлар турында кисәтү*

[3] Македуния өлкәсенә китеп барышлый ук, мин синнән
Эфестә калуыңны үтенгән күк, синең хәзер дә анда булуыңны
телим. Анда кайберәүләр чит тәгълиматка өйрәтәләр, ә син
аларны туктатырга тиеш. [4] Аларга риваятьләргә һәм очсыз-кы-
рыйсыз шәҗәрәләргә игътибар итмәскә куш. Чөнки болар бә-
хәсләр генә тудыра һәм Аллаһы ниятенең алга китүенә ярдәм
итми, ә Аллаһы нияте иман аркылы эш итә. [5] Бу әмернең мак-
саты исә – саф йөрәктән һәм саф вөҗданнан, риясыз иманнан
килгән мәхәббәт. [6-7] Кайберәүләр, болардан читләшеп, ни сөй-
ләүләрен һәм нәрсә раслауларын аңламаган хәлдә, канун укы-
тучылары буласы килеп, буш сүзләр сөйләүгә борылдылар. [8] Ә
без беләбез: әгәр канун дөрес кулланылса, ул яхшы. [9] Шуны да
беләбез: канун тәкъва кешеләр өчен түгел, бәлки канунсызлар
һәм буйсынмаучылар, имансызлар һәм гөнаһлылар, Аллаһыны
да, изге нәрсәләрне дә ихтирам итмәүчеләр, атасын яки ана-
сын үтерүчеләр һәм кеше үтерүчеләр өчен, [10] фәхешләр, ирләр
белән җенси мөнәсәбәткә керүче ирләр, кеше урлаучылар,
ялганчылар, ялган шаһитләр һәм аек тәгълиматка каршы кил-
гән башка барлык нәрсәләр өчен чыгарылган. [11] Миңа ышанып
тапшырылган мөбарәк Аллаһының даны турындагы Яхшы хә-
бәрдә шулай өйрәтелә.

*Аллаһының Паулга мәрхәмәте*

[12] Миңа көч биргән Раббыбыз Мәсих Гайсәгә рәхмәт: Ул ми-
не ышанычлы санап, Үзенең хезмәтенә билгеләде; [13] элек кө-
фер сөйләүче, эзәрлекләүче һәм дорфа булсам да, Аллаһы миңа

шәфкать күрсәтте. Чөнки Мәсихкә иман итмәгәнгә, ни эшлә-
гәнемне белми идем. [14] Раббыбызның мәрхәмәте исә миңа,
артыгы белән, Мәсих Гайсәгә иман итү һәм Аның мәхәббәте
белән бергә бирелде.

[15] Мәсих Гайсә дөньяга гөнаһлыларны коткару өчен килде
дигән сүз хак һәм тулысынча кабул итүгә лаеклы. Гөнаһлылар
арасында иң начары — мин. [16] Ләкин Мәсихкә иман итеп, мәң-
гелек тормышка ирешәселәргә мине үрнәк итү өчен, Мәсих
Гайсә бар сабырлыкны миндә — гөнаһлыларның иң начарында
күрсәтсен дип, Аллаһы миңа рәхим-шәфкать белдерде. [17] Мәң-
гелек Патшага, үлемсез, күзгә күренмәс бердәнбер Аллаһыга
мәңге-мәңгегә хөрмәт һәм дан! Амин.

[18] Тимуте улым, синең хакта элек сөйләнгән пәйгамбәрлек
сүзләре буенча, бу әмерне сиңа ышанып тапшырам: син, аларга
таянып, яхшы сугышчы кебек көрәш. [19] Иман һәм саф вөжда-
ныңны сакла. Кайберәүләр исә, аны кире кагып, иманнарын
һәлакәткә дучар иттеләр: [20] Һүменәй белән Искәндәр алар ара-
сында иде, мин аларны, көфер сүзләр сөйләмәскә өйрәнсеннәр
дип, шайтан кулына тапшырдым.

*Гыйбадәт кылу*

**2** [1-2] Шулай итеп, иң элек шуны үтенәм: тулысынча диндар-
лык һәм сафлык белән гаугасыз вә тыныч гомер кичерик
дип, бар кешеләр, патшалар һәм дәүләт башлыклары өчен
соргагыз, дога кылыгыз, ялварыгыз, шөкер итегез. [3] Бу — Котка-
ручыбыз Аллаһы алдында яхшы һәм мәгъкуль. [4] Ул барлык ке-
шеләрнең котылуын һәм хакыйкатьне тануга ирешүләрен тели.
[5-6] Чөнки Аллаһы бер, һәм Аллаһы белән кешеләр арасында
арадашчы бер, Ул — бар кешеләр котылсын өчен Үз тормышын
биргән Кеше Мәсих Гайсә: моңа үз вакытында шаһитлек бирел-
де. [7] Мәсих Гайсә турындагы бу хәбәрне тарату өчен мин вә-
газьче һәм рәсүл итеп, яһүд булмаганнарга иман һәм хакыйкать
өйрәтүче итеп куелдым. Мин дөресен сөйлим, ялганламыйм.

[8] Инде шуны телим: ир-атлар һәр җирдә рухи яктан саф бу-
лып, ярсымыйча вә бәхәсләшмичә, кулларын күтәреп дога
кылсыннар.

[9] Шулай ук хатын-кызлар да чәчләрен үрү, алтын яки энҗе-
ләр яисә кыйммәтле киемнәр белән түгел, бәлки тыйнак киемдә
оялчанлык һәм әхлаклылык белән, [10] үзләрен Аллаһыга табыну-
чы хатын-кызларга хас булган игелекле эшләр белән бизәсеннәр.
[11] Хатын-кыз күндәмлек белән тавыш-тынсыз гына өйрәнсен.
[12] Хатын-кызга исә ир-атны өйрәтергә, аның өстеннән баш бу-
лырга рөхсәт итмим, ул тавыш-тынсыз булсын. [13] Чөнки башта

Адәм, аннан соң Хаува яратылган; [14] һәм Адәм алданмаган,
бәлки хатын-кыз, алданып, гөнаһка төшкән. [15] Әмма әхлакый
сафлык белән иман, мәхәббәт һәм әүлиялектә торса, ул ана
булу вазифасын үтәп* котылачак.

*Бердәмлектәге җитәкчеләр*

3 [1] Әгәр кем дә булса иман итүчеләр бердәмлегенең җитәк-
чесе булырга омтылса, ул бик нык игелекле эш тели, дигән
сүзләр хак. [2] Ул җитәкче исә бер гаепсез, бер генә хатын-
ның ире, тотнаклы, төпле, әдәпле, кунакчыл, өйрәтергә сә-
ләтле булырга, [3] эчкече, сугыш чукмары түгел, бәлки йомшак
күңелле, татулык сөюче, байлык җыярга яратмаучы булырга,
[4] үз гаиләсе белән оста идарә итүче, балаларын бөтен хөрмәт
белән, күндәм итеп тәрбияләүче булырга тиеш. [5] Әгәр үз йорты
белән идарә итә белмәсә, ул Аллаһы бердәмлеге турында ни-
чек кайгырта алыр соң? [6] Тәкәбберләнеп, иблис төшкән хөкем-
гә төшмәс өчен, әле генә иман китергән булырга тиеш түгел.
[7] Шелтәгә һәм иблис тозагына төшмәс өчен, чит кешеләр ара-
сында да ул абруйлы булырга тиеш.

*Бердәмлек ярдәмчеләре*

[8] Шулай ук бердәмлек ярдәмчеләре дә икейөзле, эчәргә яра-
тучы, хурлыклы табышка омтылучан булмаска, [9] иманыбызның
серен саф вөҗдан белән саклаучы, ихтирамга лаек булырга ти-
еш. [10] Шулай итеп, аларны да башта сынап карасыннар, әгәр
кимчелексез булсалар, алар ярдәмчеләр булып хезмәт итсен-
нәр. [11] Шулай ук хатын-кызлар** да, гайбәтче булмыйча, аек,
һәрнәрсәдә тугрылыклы, ихтирамга лаек булырга тиеш.

[12] Бердәмлек ярдәмчесенең бер генә хатыны булырга тиеш,
ул үз балаларын тәрбияли һәм гаилә эшләре белән яхшы ида-
рә итә белүче булырга тиеш. [13] Үз хезмәтләрен яхшы үтәүче-
ләр башка иман итүчеләр тарафыннан ихтирам казаналар һәм
Мәсих Гайсәгә иманда үтә кыюлыкка ирешәләр. [14] Мин моны
тиздән синең янга килеремә өметләнеп язам. [15] Әгәр мин
токкарлансам, хакыйкатьнең терәге һәм нигезе булган тере
Аллаһы бердәмлегендә, димәк, Аллаһы йортында син нәрсә
эшләргә кирәклеген белергә тиеш. [16] Иман серенең бөек булуы
бәхәссез:

---

* 2:15 *Ана булу вазифасын үтәп* — Бу сүзләрне «бала тудыручы булып» дип тә аңларга мөмкин.

** 3:11 *Хатын-кызлар* — Бу сүзне болай да аңларга мөмкин: «хатын-кыз-ярдәмчеләр» яисә «ярдәмчеләрнең хатыннары».

Ул тәндә пәйда булды,
Изге Рух тарафыннан хак дип күрсәтелде,
Аны фәрештәләр күрде,
Ул халыклар арасында вәгазьләнде,
Дөньяда иман белән кабул ителде,
Дан белән күккә ашты.

*Тимутегә киңәшләр*

**4** 1 Рух исә ачык әйтә: соңгы вакытларда кайберәүләр, ал-
дакчы рухларга һәм җен өйрәтүләренә колак салып,
иманнан кире чигенерләр. 2 Шундый өйрәтүләр вөҗ-
даннары тою сәләтен югалткан ялган сөйләүчеләрнең ике-
йөзлелеге аша килер. 3 Бу ялганчылар никахлашуны тыялар,
һәм Аллаһы ризыкларны иман итүчеләр вә хакыйкатьне белү-
челәр шөкер итеп кабул итсеннәр өчен булдырса да, кайбер
ризыкларны ашамаска кушалар. 4 Әмма Аллаһы булдырган
һәрнәрсә яхшы һәм шөкер итеп кабул ителсә, һичнәрсә кире
кагылмаска тиеш, 5 чөнки ул Аллаһы сүзе һәм дога белән из-
ге ителә.

6 Иман сүзләре һәм һәрвакыт үзең ияргән яхшы тәгълимат
белән рухи яктан баеп, боларны имандашларга өйрәтсәң,
Мәсих Гайсәнең яхшы хезмәтчесе булырсың. 7 Имансыз һәм
юк-бар риваятьләрне исә кире как, ә үзеңне диндарлыкка
күнектер. 8 Чөнки тән күнекмәсенең файдасы аз, ә инде дин-
дарлык һәрнәрсәгә файдалы, чөнки ул хәзерге һәм киләчәк
тормышны вәгъдә итә. 9 Бу сүзләр хак һәм тулысынча кабул
итүгә лаеклы. 10 Бу тормышка ирешү өчен без авыр хезмәт
башкарабыз һәм ашкынабыз, чөнки барлык кешеләрне, биг-
рәк тә иман итүчеләрне Коткаручы тере Аллаһыга өмет баг-
лыйбыз.

11 Бу әмерләрне башкаларга тапшыр һәм өйрәт. 12 Синең
яшьлегеңә һичкем түбәнсетеп карамасын, ләкин сөйләмдә,
үз-үзеңне тотышында, мәхәббәттә, иманда, сафлыкта иман
итүчеләргә үрнәк бул. 13 Мин килгәнгә кадәр Изге язманы
бердәмлек алдында уку, вәгазь сөйләү һәм өйрәтү белән мәш-
гуль бул. 14 Өлкәннәр сиңа кулларын куйганда, пәйгамбәр сүзе
аша бирелгән рухи бүләкне игътибарсыз калдырма.

15 Алга китешең һәркемгә ачык күренсен өчен, шулар белән
шөгыльлән, үзеңне шуларга багышла. 16 Үз-үзеңне һәм өйрәт-
кән тәгълиматыңны күзәтеп тор һәм, нык торып, моны башка-
руыңны дәвам ит. Чөнки шулай эшләсәң, үзеңне дә, тыңлау-
чыларыңны да коткарырсың.

*Тол хатыннар, өлкәннәр, коллар турында киңәш*

5 1 Өлкән яшьтәге ир-атларны шелтәләмә, бәлки атаңны
үгетләгән кебек үгетлә, яшь ир-атларны, кардәшләреңне
үгетләгән кебек, 2 өлкән хатыннарны, анаңны үгетләгән
кебек, яшь хатыннарны, бар сафлык белән кыз кардәшләреңне
үгетләгән кебек үгетлә.
3 Чыннан да ялгыз булган тол хатыннарга хөрмәт күрсәт. 4 Ә
тол хатынның балалары яки оныклары булса, алар башта,
ата-аналары һәм әби-бабалары хакында кайгыртып, иманнарын эштә күрсәтергә өйрәнсеннәр, чөнки Аллаһы шуны тели.
5 Ә чыннан да тол һәм ялгыз хатын Аллаһыга өмет баглый һәм,
Аллаһыга ялварып, көне-төне дога кыла. 6 Ә кәеф-сафага бирелгән тол хатын, яшәсә дә, ул инде үле. 7 Кимчелексез булсыннар өчен, бу турыда кешеләрнең күңеленә сеңдер. 8 Әгәр дә
берәү кардәш-ырулары, бигрәк тә якыннары хакында кайгыртмый икән, ул иманыннан ваз кичкән һәм имансыздан да яманрак була.
9-10 Бер ирнең генә хатыны булып, алтмыш яшьтән ким булмаган тол хатын, үзенең игелекле эшләре буенча танылган булса: балалар тәрбияләп үстергән, кунакчыллык күрсәткән, имандашларының аякларын юган*, авырлык килгәннәргә ярдәм иткән һәм үзен һәртөрле игелекле эшкә багышлаган булса гына, толларның бердәмлектәге исемлегенә** кертелсен.
11 Яшь тол хатыннарны исә исемлеккә кертмә, чөнки алар,
женси теләккә бирелеп, тагын никахка керергә телиләр 12 һәм,
шулай итеп, үзләрен Мәсихкә багышлаудан туктыйлар һәм үзләрен хөкемгә дучар итәләр. 13 Шуның өстенә алар, өйдән-өйгә
йөреп, эшлексез булырга күнегәләр һәм эшсез йөреп кенә калмыйлар, тиешсез нәрсәләр сөйләп, гайбәт саталар һәм кеше
эшенә тыкшыналар. 14 Шуңа күрә, мин шуны телим: яманатын сатар өчен дошманнарга һичнинди сәбәп бирмәс өчен, яшь тол хатыннар никахка керсеннәр, балалар тудырсыннар, йорт-җирне карасыннар. 15 Инде кайберәүләр, дөрес юлдан читкә борылып, шайтан юлына бастылар бит.
16 Әгәр ниндидер иман итүче хатынның гаиләсендә толлар булса, бердәмлек алар өчен мәшәкатьләнмәсен һәм чыннан

* 5:9-10 *Аякларны юу* – кунакчыллык билгесе. Бу эшне гадәттә коллар башкарган.

** 5:9-10 *Исемлек* – Иман итүчеләр бердәмлегендә чын тол хатыннарның рәсми исемлеге төзелгән һәм бердәмлек тарафыннан аларга матди ярдәм күрсәтелергә тиеш булган.

да тол булган хатыннарга ярдәм итә алсын өчен, ул аларга
үзе ярдәм итәргә тиеш.

*Бердәмлек өлкәннәре*

17 Яхшы җитәкчелек итүче өлкәннәр, бигрәк тә Аллаһы сү-
зен белдерүдә һәм өйрәтүдә авыр хезмәт башкаручылар, ике
тапкыр артык алырга лаеклы булып саналсыннар. 18 Чөнки
Изге язма болай ди: «ашлык сугучы үгезнең авызын томалама»
һәм «эшче хезмәт хакына лаек». 19 Өлкәнгә каршы шикаятьне*
ике яки өч шаһит белән булганда гына кабул ит. 20 Башкалар-
да да курку тусын өчен, гөнаһ кылучыларны барысы алдында
фаш ит.
21 Аллаһы, Мәсих Гайсә һәм сайланган фәрештәләр алдында
мин сиңа кушам: бу кагыйдәләрне алдан ук тискәре караштa
торып һәм берьяклылык күрсәтеп кулланма. 22 Хезмәткә сайлау
билгесе итеп, һичкем өстенә ашыгычлык белән кулларыңны
куйма һәм башкаларның гөнаһларына катнашма; үзеңне саф
тот. 23 Бүтән коры су гына эчмә, карының өчен, еш авырмас
өчен бераз шәраб та эч.
24 Инде кайбер кешеләрнең гөнаһлары билгеле һәм туры-
дан-туры хөкемгә илтәләр, ә кайберләренең гөнаһлары исә
соңрак ачылыр. 25 Шул ук рәвештә игелекле эшләр дә билге-
ле, әгәр кайберләре билгесез икән, яшеренеп калу мөмкин
түгел.

*Коллар турында*

6 1 Аллаһы исемен һәм тәгълиматны һичкем хурламасын
өчен, коллык богавындагылар үз хуҗаларын барлык ихти-
рамга лаеклы дип санарга тиеш. 2 Хуҗалары иманлы бул-
ганнар, бер-берсе белән имандаш булганлыктан, алар белән
илтифатсыз мөгамәлә итәргә тиеш түгел, бәлки тагын да күб-
рәк хезмәт күрсәтергә тиеш, чөнки хезмәттән файда казанучы
хуҗалар – иман итүчеләр һәм сөеклеләр. Боларны өйрәт һәм
нәсыйхәт ит.

*Ялган тәгълимат һәм чын байлык*

3 Әгәр кем дә кем башка тәгълимат өйрәтә һәм Раббыбыз
Гайсә Мәсихнең хак сүзләре һәм иман турындагы өйрәтү бе-
лән килешми икән, 4 ул тәкәббер, һичнәрсә белми, әмма бә-
хәсләшергә һәм сүз көрәштерергә һәвәслек белән агуланган
була, һәм болардан көнчелек, низаг, хурлау, мәкерле шикләнү

---

* 5:19 *Шикаять* – кешенең гаебен күрсәткән сүз яки әләк.

килеп чыга, [5] акылларына зыян килгән һәм хакыйкатьтән мәх-
рүм калган кешеләр арасында фикер каршылыклары туа. Шул
кешеләр, диндарлык табыш казануга хезмәт итә, дип уйлыйлар.
Андыйлардан ерак йөр.
[6] Кеше үзендә булганнар белән канәгать икән, Аллаһыга
иман итү аның тормышын бик нык баета, [7] чөнки без дөньяга
һичнәрсә алып килмәдек, аннан һичнәрсә алып та китә алма-
быз. [8] Ризыгыбыз һәм кием-салымыбыз булса, шуның белән
канәгать булыйк. [9] Ә инде баерга теләүчеләр коткыга һәм то-
закка төшә, аларда бик күп акылсыз һәм зарарлы теләкләр туа.
Бу инде кешеләрне афәткә һәм һәлакәткә китерә; [10] чөнки бар
явызлыкларның башлангычы – акчага хирыслык. Кайберәү-
ләр, моңа бирелеп, иманнан читләшкәннәр һәм үз-үзләрен күп
кайгыларга дучар иткәннәр.
[11] Ә син, Аллаһы кешесе, болардан кач һәм тәкъвалыкка,
диндарлыкка, иманга, мәхәббәткә, түземлелеккә һәм басынкы-
лыкка омтыл. [12] Иман көрәшен каһарманнарча алып бар, мәң-
гелек тормышка ия бул, чөнки син шул мәңгелек тормышка
чакырылдың һәм күп шаһитләр алдында үз иманыңны икъ-
рар иттең. [13] Һәрнәрсәгә тереклек бирүче Аллаһы алдында һәм
Понти Пилатка шаһитлек биреп, хакыйкатьне икърар иткән Мә-
сих Гайсә алдында сиңа боерык бирәм: [14] Раббыбыз Гайсә Мәсих
килгәнгә кадәр әмерне тел тидермәслек һәм шелтәсез итеп баш-
кар. [15-16] Мөбарәк һәм бердәнбер Хаким, патшаларның Патшасы
һәм хуҗаларның Хуҗасы, бердәнбер үлмәс, якын бара алмаслык
яктылыкта торучы, кешеләрдән һичкем күрмәгән һәм күрүе дә
мөмкин булмаган Аллаһы Мәсихне үз вакытында күрсәтәчәк.
Аллаһыга хөрмәт һәм мәңгелек хакимлек булсын! Амин.
[17] Бу дөньядагы байларны кисәт: алар тәкәбберләнмәсеннәр
һәм ышанычсыз байлыкка түгел, бәлки хозурлану өчен безгә
һәрнәрсәне мул итеп бирүче Аллаһыга өмет багласыннар.
[18] Аларга яхшылык кылырга, игелекле эшләре аркылы бай һәм
юмарт булырга, байлыкларын башкалар белән бүлешергә әзер
торырга боерык бир. [19] Шул рәвешчә, чын тормышка ирешү
өчен, киләчәккә нигез булырлык хәзинә тупларлар.
[20] Әй, Тимуте! Үзеңә ышанып тапшырылганны сакла. Дөнья-
ви буш сүзләр, урынсызга гыйлем дип аталган һәм дөреслеккә
туры килмәгән нәрсәләрдән читтә тор. [21] Кайберәүләр, шуларга
бирелеп, иманнан читләштеләр.
Мәрхәмәт сезнең белән булсын.

# ПАУЛДАН ТИМУТЕГӘ ИКЕНЧЕ ХАТ

1 1 Мәсих Гайсәдә булган тормыш турындагы вәгъдәне игъ-
лан итәргә җибәрелгән, Аллаһы ихтыяры буенча Мәсих
Гайсәнең рәсүле Паулдан 2 сөекле улым Тимутегә сәлам.
Ата Аллаһыдан вә Раббыбыз Мәсих Гайсәдән сиңа мәрхәмәт,
шәфкать һәм иминлек булсын.

*Тугрылыклы булырга өндәү*

3 Көндез һәм төнлә даими рәвештә догаларымда сине искә
төшергәндә, мин дә, әби-бабаларым кебек, саф вөҗдан белән
үзем хезмәт итә торган Аллаһыга рәхмәт белдерәм. 4 Синең күз
яшьләреңне истә тотып, күңелемне шатлыкка тутырыр өчен,
сине бик күрәсем килә. 5 Башта Лоис әбиеңдә, аннары әниең
Әүникәдә яшәгән эчкерсез иманың турында искә төшерәм.
Һәм ул синдә дә бар дип инанам. 6 Шул сәбәптән хәтереңә
төшерәм: кулларымны өстеңә куеп алу аша сиңа Аллаһы та-
рафыннан бирелгән рухи бүләкне үстер. 7 Чөнки Аллаһы безгә
курку рухын түгел, бәлки көч, мәхәббәт һәм аек фикер йөртү
рухын биргән.
8 Шулай итеп, Раббыбыз турында шаһитлек бирүдән, Аның
хакына тоткын булган миннән дә оялма, әмма, Аллаһы көче
белән ныгытылып, Яхшы хәбәр өчен минем белән бергә газап
чик. 9 Аллаһы кылган эшләребез аркасында түгел, бәлки Үзенең
нияте һәм мәрхәмәте нигезендә коткарып, безне изге тормыш-
ка чакырган. Ул безгә бу мәрхәмәтне вакыт башланганчы ук
Мәсих Гайсә аркылы биргән, 10 хәзер исә аны Коткаручыбыз
Мәсих Гайсәнең килүе аша күрсәткән. Ә Мәсих Гайсә үлемне
юкка чыгарган һәм, Яхшы хәбәр аркылы, тормыш вә үлемсез-
лекне ирешә алырлык иткән. 11 Мин шул Яхшы хәбәрне игълан
итүче, рәсүл һәм өйрәтүче итеп билгеләп куелган. 12 Мин шу-
ның өчен газап чигәм дә, әмма оялмыйм, чөнки Кемгә ышану-
ымны беләм, һәм миңа ышанып тапшырылганны Аның соңгы
көнгә кадәр саклый алачагына инанам.

13 Мәсих Гайсәгә иман итеп һәм Аның мәхәббәтендә торып,
миннән ишеткән дөрес сүзләрне үрнәк итеп тот. 14 Сиңа ыша-
нып тапшырылган чын тәгълиматны бездә яшәүче Изге Рух
ярдәме белән сакла.
15 Син беләсең, Асия өлкәсендәгеләрнең барысы да мине
ташлап киттеләр: Фүгел һәм Һермогенис та алар арасында.
16 Раббы Онисифор гаиләсенә шәфкать бирсен, чөнки ул күп
тапкырлар минем күңелемне күтәрде һәм төрмәдә утыруымнан
оялмады. 17 Киресенчә, Римга килгәч, мине бик тырышып эз-
ләгән һәм эзләп тапкан. 18 Соңгы көндә ул Раббы ярдәме белән
Ходай шәфкатен алсын. Эфестә чакта аның миңа тырышып
хезмәт итүен бик яхшы беләсең.

*Мәсих Гайсәнең яхшы сугышчысы*

2 1 Улым, син Мәсих Гайсәнең мәрхәмәте белән нык тор
2 һәм күп шаһитләр алдында, миннән ишеткән нәрсәләрне
башкаларны да өйрәтергә сәләтле булачак ышанычлы ке-
шеләргә тапшыр. 3 Мәсих Гайсәнең яхшы сугышчысы кебек,
барлык иман итүчеләр белән газап чик. 4 Бернинди хәрби хез-
мәткәр дә, гаскәр башлыгына ярарга тырышып, үзен көндәлек
эшләр белән бәйләми. 5 Шул рәвешчә, әгәр кемдер йөгерү
ярышында катнашып, кагыйдәләр буенча йөгерми икән, ул
җиңүчегә дигән бүләккә лаек була алмас. 6 Авыр хезмәт башка-
ручы игенче, җыеп алынган уңыштан үз өлешен беренче алырга
тиеш. 7 Мин әйткәннәр турында уйла һәм Раббы сиңа бар нәр-
сәне дә аңларга ярдәм итәр.
8 Гайсә Мәсихне исеңдә тот. Ул, Давыт нәселеннән булып,
үледән терелтеп торгызылды. Бу турыда мин игълан иткән Яхшы
хәбәрдә әйтелә. 9 Яхшы хәбәрне тарату хезмәтен башкарып,
хәтта җинаятьче кебек богауланып, мин газапларга түзәм, әмма
Аллаһы сүзе богауларда түгел. 10 Шуңа күрә, Аллаһы сайлап ал-
ганнар хакына, алар да Мәсих Гайсә биргән котылуны һәм шу-
ның белән бергә мәңгелек дан алсын өчен, мин барына да түзәм.
11 Түбәндәге сүзләр хак:
Аның белән үлгәнбез икән,
Аның белән бергә яшәрбез дә.
12 Әгәр түзәбез икән,
Аның белән патшалык та итәрбез;
Әгәр Аннан баш тартсак,
Ул да бездән баш тартыр.
13 Без тугры булмасак та,
Ул һәрчак тугры булып кала,
чөнки Ул Үз-Үзенә каршы килә алмый.

*Аллаһының мактаулы эшчесе*

[14] Боларны бөтен кешеләрнең исләренә төшер һәм, сүзләр
турында бәхәсләшмәсеннәр өчен, Аллаһы каршында аларны
ныгытып кисәт. Моның бернинди дә файдасы юк, ә тыңлаучы-
ларны һәлакәткә илтә. [15] Хакыйкать сүзенә дөрес өйрәтүче һәм
эшен оятка калмаслык итеп башкаручы эшче кебек, Аллаһының
хуплавына ирешү өчен, мөмкин булганнарның барысын да эшлә.
[16] Имансыз буш сүзләрдән исә ерак тор; чөнки алар кешеләрне
Аллаһыдан тагын да ныграк читләштерә. [17] Андый сүзләр – та-
ралучы яман шеш кебек; Һүменәй белән Филит тә шуларны та-
ратучылар арасында. [18] Безнең өчен үледән терелү инде булды
дип, алар хакыйкатьтән читкә тайпылдылар һәм кайберәүләр-
нең иманнарын какшаттылар. [19] Әмма Аллаһы корган нигез
нык тора, аңарга мондый сүзләр язылган: «Раббы Үзенекеләрен
белә», һәм: «Раббыга табынучы явызлыктан читләшсен».
[20] Зур йортта алтын һәм көмештән ясалган савыт кына түгел,
бәлки агач һәм балчык савытлар да бар, һәм аларның кайбер-
ләре махсус тотыла торган, икенчеләре гадәти кулланышта.
[21] Шулай итеп, кем үзен явызлык кылудан чистартыр, ул – үзен
Аллаһыга багышлаган, Йорт Хуҗасына яраклы, һәрбер игелек-
ле эшкә әзер булган махсус кулланылыштагы савыт булыр.
[22] Яшьлекнең әдәпсез теләкләреннән кач. Һәм Раббыны чын
йөрәктән ярдәмгә чакыручылар белән бергә тәкъвалыкка,
иманга, мәхәббәткә, иминлеккә омтыл. [23] Акылсыз һәм томана
бәхәсләргә катышма, аларның ызгыш-талашлар гына китереп
чыгаруын беләсең. [24] Раббы колы исә бәхәсләшергә тиеш түгел,
әмма һәммәсенә дә ягымлы булырга, оста итеп өйрәтүче һәм
сабыр булырга, [25] өйрәтүләргә карышучыларга басынкылык бе-
лән үгет-нәсыйхәт бирергә тиеш. Бәлки Аллаһы аларга хакый-
катьне танып белүгә алып килә торган тәүбә бирер, [26] бәлки
алар акылга утырырлар һәм иблис үзенең ихтыярын үтәсеннәр
өчен эләктергән тозактан котылып калырлар.

*Соңгы вакытлар алласызлыгы*

**3** [1] Белеп тор, соңгы көннәрдә авыр вакытлар булачак.
[2] Чөнки кешеләр үзләрен генә сөючән, байлык яратучан,
мактанчык, һавалы һәм хурлаучан булырлар; алар ата-ана-
ларына буйсынмаслар, яхшылыкны белмәсләр, изге нәрсә-
ләрне ихтирам итмәсләр. [3] Алар мәхәббәтсез, килешмәүчән,
яла ягучан, тотнаксыз, шәфкатьсез булырлар һәм яхшылыкны
дошман күрерләр; [4] алар хыянәтче, оятсыз, тәкәббер булыр
һәм, Аллаһыны яратуга караганда, ләззәтне күбрәк яратырлар.

5 Тышкы яктан иман тотучы булып күренерләр, ә иман тотуның
көчен инкяр итәрләр. Андыйлардан ерак тор.
6 Андыйлар сиздермичә генә йортларга керәләр һәм гөнаһка
баткан вә төрле азгын теләкләрнең кубызына биюче бәхетсез
хатын-кызларның күңелләрен биләп алалар. 7 Бу хатыннар исә
һәрвакыт өйрәнәләр, әмма беркайчан да хакыйкатьне аңлауга
ирешә алмыйлар. 8 Янис һәм Ямбрис Мусага каршы килгән ке-
бек, бозык акыллы һәм иманда файдасыз булган бу кешеләр
шулай ук хакыйкатькә каршы киләләр. 9 Әмма ерак китә ал-
маслар, чөнки тегеләрнең акылсызлыгы мәгълүм булган күк,
аларныкы да һәммәсенә ачык күренер.

*Тимутегә киңәшләр*

10-11 Син исә тәгълиматыма, яшәү рәвешемә, ниятләремә,
иманыма, сабырлыгыма, мәхәббәтемә, түземлегемә иярдең.
Мине ничек эзәрлекләүләрен һәм ничек газап чигүләремне
беләсең. Антиухея, Икүниун һәм Лустра шәһәрләрендә нин-
ди эзәрлекләүләргә дучар булуымны да беләсең. Мине барын-
нан да Раббы коткарды! 12 Чынлап та Мәсих Гайсәгә хезмәт
итеп, хак дин буенча яшәргә теләүчеләрнең барысы да эзәр-
лекләнер. 13 Әмма мәкерле кешеләр һәм алдакчылар исә, адаш-
тырып һәм үзләре дә адашып, явызлыкларында тагын да алга
китәрләр.

*Иман һәм Изге язма*

14 Син исә нәрсәгә өйрәндең һәм нәрсәгә инандың, шулар-
ны дәвам ит, чөнки кемнән өйрәнгәнеңне беләсең. 15 Шуның
өстенә син Изге язмаларны балачактан ук беләсең. Алар сиңа,
Мәсих Гайсәгә иман итү аша, сине котылуга китерүче зирәклек
бирә ала. 16-17 Аллаһы кешесе сәләтле һәм барлык яхшы эшкә
әзер булсын өчен, бөтен Язма Аллаһы тарафыннан рухланды-
рылган һәм өйрәтү, шелтәләү, төзәтү һәм Аллаһыга яраклы бу-
лып яшәү турында үгет-нәсыйхәт бирү өчен файдалы.

**4** 1 Тереләрне һәм үлеләрне хөкем итәчәк Мәсих Гайсә Пат-
ша булып киләчәк, шуңа күрә Аллаһы һәм Мәсих Гайсә
алдында сиңа җитди рәвештә кушам: 2 Аллаһы сүзен игъ-
лан ит, моны уңайлы һәм уңайсыз вакытта да эшләргә әзер
тор, төзәт, шелтәлә, өйрәткәндә һәрвакыт сабырлык белән
үгетлә. 3 Чөнки шундый вакыт килер, дөрес тәгълиматны тың-
ларга теләмәсләр, бәлки үзләренә ошаган, колакларына ятыш-
лы итеп өйрәтүче укытучыларны гына үзләре янына күп итеп
җыярлар, 4 һәм, хакыйкатьне тыңламыйча, кешеләр уйлап чы-
гарган риваятьләргә колак салырлар. 5 Син исә беркайчан да

югалып калма, кайгыларга түз, Яхшы хәбәр тарату эшен кыл,
үз хезмәтеңне башкарып чык.
6 Чөнки миңа бу дөньядан китәр вакыт җитте. Минем тор-
мышым корбан китерү урынына салынган корбан кебек. 7 Мин
яхшы ярыштым, ахырга тикле йөгердем, иманны саклап кал-
дым. 8 Хәзер мине җиңүче бүләге – хаклык таҗы көтә. Раббы,
гадел Хөкем кылучы, миңа аны соңгы көндә бирәчәк. Һәм
миңа гына түгел, бәлки Аның килүен сагынып көтүчеләрнең
барсына да бирәчәк.

*Шәхси киңәшләр һәм үтенечләр*

9 Тиздән минем янга килергә тырыш, 10 чөнки бу дөньяны
яратып, Димас мине ташлап, Тессалуникә шәһәренә, Крискис –
Гәләтия, Титус – Далматия өлкәләренә киттеләр. 11 Монда ми-
нем белән бер Лүк кенә. Маркны үзең белән алып кил, чөнки
хезмәтемдә ул миңа ярдәм итә ала. 12 Тухикны исә мин Эфес
шәһәренә җибәрдем. 13 Килгәндә Троас шәһәрендә Карпларда
калдырган җиләнемне һәм минем язма төргәкләрен, бигрәк тә
күннән ясалганнарын алып кил.
14 Тимерче Искәндәр миңа күп явызлыклар эшләде. Раббы
аңа эшләренә карап түләр. 15 Син үзең дә аннан саклан, чөнки
ул безнең сүзләргә бик нык каршы килде.
16 Үземне беренче тапкыр яклаган вакытта минем белән бер-
кем дә юк иде, барысы да мине калдырып китте. Бу аларга гаеп
булып саналмасын! 17 Раббы исә минем янда булды һәм, Алла-
һының хәбәре минем аркылы тулысынча игълан ителсен һәм
бар халыкларга ишетелсен өчен көч бирде һәм мин арыслан
авызыннан коткарылдым. 18 Раббы мине һәрбер явыз эшләр-
дән йолып алыр һәм, коткарып, Үзенең Күктәге Патшалыгына
алып китәр. Аңа мәңгедән мәңгегә дан. Амин.
19 Прискиллә белән Әкүл һәм Онисифорлар гаиләсен сәлам-
лә. 20 Эрасты Көринт шәһәрендә калды. Трофимны исә Милит
шәһәрендә авыру килеш калдырдым. 21 Кышка хәтле килеп җи-
тәргә тырыш. Сине Әүбул һәм Пудис, Лин белән Кләудия һәм
барлык имандашлар сәламли.
22 Раббы синең рухың белән. Мәрхәмәт сезнең белән.

# ПАУЛДАН ТИТУСКА ХАТ

**1** 1 Аллаһы колы һәм Гайсә Мәсихнең рәсүле Паулдан сәлам.
Аллаһы тарафыннан сайлап алынганнарны иманга һәм дин-
дарлыкка илтүче хакыйкатьне танып белүгә китерү өчен
җибәрелдем мин. 2 Безгә бу иман һәм хакыйкатьне танып белү –
Аллаһы вакыт башланганчы ук вәгъдә иткән мәңгелек тормыш-
ка өмет бирә, ә Ул беркайчан да ялганламый. 3 Билгеләнгән
вакыт җиткәч, Коткаручыбыз Аллаһы боерыгы буенча миңа
ышанып тапшырылган вәгазь аша, Ул Үзенең бу хәбәрен игъ-
лан итте. 4 Минем белән бер үк иманны уртаклашучы чын улым
Титуска Ата Аллаһы вә Коткаручыбыз Мәсих Гайсәдән мәрхә-
мәт һәм иминлек булсын.

*Титусның Крит утравындагы вазифалары*

5 Төгәлләнмәгән эшләрне тәртипкә китерү һәм барлык шә-
һәрләрдә мин боерганча иман итүчеләр бердәмлекләренең өл-
кәннәрен билгеләү өчен, мин сине Критта калдырдым. 6 Өлкән
бер гаепсез, бер генә хатынның ире булырга тиеш. Аның балала-
ры шулай ук иман итүчеләр, акылсызлыкта яки буйсынмаучан-
лыкта гаепләнмәүчеләр булырга тиеш. 7 Чөнки бердәмлектәге
җитәкче, Аллаһы эшләре белән идарә итүче буларак, бер гаеп-
сез булырга тиеш. Ул тәкәббер, ачулы, эчкече, сугыш чукмары,
хурлыклы табышка омтылучан түгел, 8 бәлки кунакчыл, яхшы-
лык сөючән, төпле, гадел, изге, үз-үзен тота белүче булырга
тиеш. 9 Башкаларны дөрес тәгълиматта нәсыйхәтләү һәм аңа
каршы кешеләрне фаш та итә алу өчен, шул тәгълиматка туры
килгән тугры сүзне тотарга тиеш.

*Ялган укытучыларны фаш итү*

10 Чөнки буйсынмаучан, такылдык һәм ялганчылар бигрәк тә
мәсихче-яһүдләр арасында күп. 11 Аларны авызларын ябарга
мәҗбүр итәргә кирәк, чөнки алар хурлыклы табыш хакына, ти-
еш булмаганнарны өйрәтеп, бер бөтен гаиләләрне җимерәләр.

12 Алар арасыннан берәү, бер акыл иясе: «Критлылар – һәрва-
кыт алдакчы, явыз ерткычлар, ялкау һәм гуҗлар», – дигән.
13-14 Бу шаһитлек хак.
Шуңа күрә алар хак иманны тотсыннар һәм яһүдләрнең
риваятьләренә һәм хакыйкатьне кире кагучыларның кагый-
дәләренә таянмасыннар өчен, аларны бик нык тәнкыйтьлә.
15 Сафлар өчен барысы да саф, әмма бозык һәм имансыз кеше-
ләр өчен берниндиcафнәрсәюк, чөнки аларның акыллары
һәм вөҗданнары бозык. 16 Алар, Аллаһыны беләбез, дип ышан-
дыралар, әмма эшләре белән Аннан ваз кичәләр. Алар әшәке,
тыңлаусыз һәм һәрбер игелекле эш өчен файдасыз.

*Иман итүчеләр бердәмлеге өчен кагыйдәләр*

2 1 Әмма син аек тәгълиматка туры килгәннәрне өйрәт. 2 Өл-
кән яшьтәге ир-атларга әйт: алар тотнаклы, ихтирамга лаек,
төпле булырга һәм иман, мәхәббәт, түземлектә нык то-
рырга тиеш. 3 Шулай ук өлкән яшьтәге хатын-кызларга да әйт:
алар үзләрен чын иман итүчеләр кебек тотарга, гайбәт сөйләш-
мәскә, эчкечелеккә бирелмәскә һәм башкаларны яхшылыкка
өйрәтергә тиеш. 4 Аллаһы сүзенә карата хурлык килмәсен өчен,
алар яшь хатыннарны үз ирләрен һәм балаларын яратырга,
5 төпле, саф, яхшы хуҗабикә булырга һәм ирләренә күндәм бу-
лырга өйрәтергә тиеш. 6 Шул рәвешчә, яшь ир-атларга да төпле
булырга нәсыйхәт бир. 7 Аларга барлык яхшы гамәлләрдә үрнәк
күрсәт. Өйрәтүләреңдә намуслы һәм җитди бул; 8 каршы тору-
чылар безнең турыда һичнинди начар сүз әйтә алмыйча оятка
калсын өчен, сөйләмең тәнкыйть итә алмаслык дәрәҗәдә дө-
рес булсын. 9 Колларга нәсыйхәт бир: алар бар нәрсәдә хуҗала-
рына буйсынсыннар, ярарга тырышсыннар, бәхәсләшмәсеннәр,
10 урлашмасыннар, бәлки үзләренең һәрнәрсәдә чыннан да тугры
булуларын күрсәтсеннәр. Коткаручыбыз Аллаһының тәгълиматы
кешеләрнең игътибарын бар нәрсәдә үзенә җәлеп итә торган
булсын өчен, аларга боларны эшләү кирәк.

*Аллаһының мәрхәмәте*

11 Чөнки Аллаһының һәр кешегә котылу бирүче мәрхәмәте
килде. 12 Бу мәрхәмәт, алласызлыкны һәм дөньяви нәфесләрне
кире кагып, безне бу дөньяда төпле, гадел һәм Аллаһыны хөр-
мәт итеп яшәргә өйрәтә. 13 Шул ук вакытта бөек Аллаһы һәм
Коткаручыбыз Гайсә Мәсихнең шөһрәте килүенә куанычлы
өметебез бар. 14 Мәсих безне һәртөрле гөнаһтан йолып алу өчен
һәм яхшылык кылырга ашкынып торучы үзенчәлекле халкын
Үзе өчен чистартырга дип, Үзен корбан итте.

[15] Моның барысын һәртөрле хакимлек белән сөйлә, нәсый-
хәт ит һәм фаш ит. Сиңа беркем дә түбәнсетеп карамасын.

*Мәсихченең яхшы гамәлләре*

**3** [1] Башлыкларга, хакимлеккә буйсынырга һәм аларны тың-
ларга, һәртөрле яхшы эшләргә һәрвакыт әзер торырга
кирәклеген иман итүчеләрнең исләренә төшер. [2] Аларны
шулай ук беркемне дә яманламаска, бәлки бар кешеләргә кара-
та һәрнәрсәдә басынкылык күрсәтеп, тыныч һәм игътибарлы
булырга өйрәт. [3] Чөнки кайчандыр без дә тинтәк, тыңлаусыз,
алданган, төрле нәфес һәм ләззәтләр коллыгында идек; без тор-
мышыбызны явызлыкта һәм көнчелектә үткәрдек; безгә нәф-
рәтләнделәр, һәм без дә бер-беребезгә нәфрәтләндек. [4] Әмма
Коткаручыбыз Аллаһы Үзенең игелеклелеген һәм кешеләргә
карата мәхәббәтен күрсәткәндә, [5] безне кылган тәкъва эшләре-
без аркасында түгел, бәлки Үзенең шәфкате буенча, Изге Рух
белән яңадан тудыру вә яңарту аркылы, Үзенең юып чистарту
гамәле аша коткарды. [6-7] Без Аның мәрхәмәте аркылы акланып,
үзебез өмет иткән мәңгелек тормышка ия булу өчен, Ул бу Рух-
ны Коткаручыбыз Гайсә Мәсих аша безгә мул итеп яудырды.
[8] Бу сүзләр хак. Синең бу нәрсәләр турында басым ясап әйтү-
еңне телим, Аллаһыга иман итүчеләр үзләрен яхшы эшләргә
багышласын, чөнки болар әйбәт һәм кешеләргә файдалы. [9] Ә
тинтәк бәхәс, шәҗәрәләр һәм канун турындагы ызгыш-талаш
һәм кычкырышулардан читләш, чөнки алар файдасыз һәм
мәгънәсез. [10] Бер яки ике тапкыр кисәткәннән соң, бүленешләр
китереп чыгара торган кеше белән бернинди уртак эшең бул-
масын! [11] Син беләсең, андый кеше бозык һәм ул гөнаһ кыла,
шуның белән үз-үзен хөкемгә дучар итте.

*Шәхси киңәшләр һәм үтенечләр*

[12] Мин синең янга Әртимәс яки Тухикны җибәрәм. Алар ки-
леп җиткәч, үзең минем янга Никәполискә килү өчен бөтен
көчеңне куй, чөнки мин кышны анда чыгарга уйлыйм. [13] Канун-
чы Зинәс һәм Апуллусны, алар бернәрсәгә мохтаҗ булмаслык
итеп, бик тырышлык белән юлга әзерлә. [14] Безнең иман итүче-
ләр, башкаларның ихтыяҗларын канәгатьләндерә алсын өчен,
үзләрен игелекле эшләргә багышларга өйрәнсеннәр. Аларның
тормышлары файдасыз булмасын.

[15] Минем белән булганнарның барысы да сине сәламли.
Безне яратучы иман итүчеләрнең барысына да сәлам тапшыр.
Мәрхәмәт сезнең барыгыз белән дә булсын.

# ПАУЛДАН ФИЛИМУНГА ХАТ

*Коллык һәм туганлык*

1-2 Кадерле дустыбыз һәм хезмәттәшебез Филимунга, шулай
ук синең йортыңа җыелучы иман итүчеләр бердәмлегенә, туга-
ныбыз Апфия ханым һәм көрәштәшебез Архипка Мәсих Гайсә
хакына төрмәдә утыручы Паул һәм имандашыгыз Тимутедән
сәлам. 3 Атабыз Аллаһы вә Раббы Гайсә Мәсихтән сезгә мәрхә-
мәт һәм иминлек булсын.

4 Туганым Филимун, догаларымда сине искә төшергәндә,
һәрвакыт Аллаһыма рәхмәт укыйм, 5 чөнки Раббы Гайсәгә
иманың һәм изгеләргә карата мәхәббәтең турында еш ишетәм.
6 Иманыңны башкалар белән дә нәтиҗәле итеп бүлеш һәм, без
Мәсихтә ия булган бар игелекне алар тулысынча аңласын дип,
дога кылам. 7 Туганым, мәхәббәтең миңа олы шатлык һәм зур
юаныч булды, чөнки синең аша иман итүчеләрнең күңелләре
сафланды.

8 Мәсихтә рухи кардәшең буларак бурычыңны үтәүне таләп
итәргә хакым булса да, 9 башка һичкем түгел, мин, Паул –
Мәсих Гайсәнең илчесе һәм дә Аңа иман итүем* өчен хәзер
төрмәдә утыручы тоткын – сиңа мәхәббәткә таянып мөрәҗә-
гать итүне кулайрак күрәм. 10 Үземнең улым Онисим** хакына
сиңа мөрәҗәгать итәм, чөнки зинданда мин аның рухи атасы
булдым. 11 Элек ул сиңа файдасыз иде, хәзер исә синең өчен дә,
минем өчен дә файдалы.

12 Аны, йөрәгемнән өзеп, кире синең янга җибәрәм. 13 Мин
аны үз янымда калдырырга теләр идем: ул сине алыштырып,
Яхшы хәбәр хакына зинданда вакытта миңа ярдәм итәр иде.
14 Әмма бернәрсәне дә синең ризалыктан башка эшлисем кил-
мәде. Ул вакытта игелекле эшең үз теләгең буенча түгел, бәлки

---

* 1:9 *Мәсих Гайсәнең илчесе һәм дә Аңа иман итүем* – Бу сүзләрне грек теленнән болай да аңларга мөмкин: «инде карт кеше һәм дә Мәсих Гайсәгә иман итүем».

** 1:10 *Онисим* – Бу грек исеме «файдалы» дигәнне аңлата.

ирексезләп кушканга булыр иде. 15 Ул синең янда бөтенләйгә
калсын өчен, синнән вакытлыча аерылып торган булуы да их-
тимал. 16 Аны хәзер кол кебек түгел, бәлки колга караганда
яхшырак итеп, якын туганың кебек каршы ал. Мин аны бик
яратам, әмма, синең өчен, кеше буларак та, мәсихче буларак та
ул тагын да кадерлерәк булыр.

17 Шулай булгач, әгәр мине имандаш күрсәң, аңа да, мине
кабул иткәндәй, ачык чырай күрсәт. 18 Ул сиңа ниндидер зыян
китергән икән яки бирәчәге булса, боларны минем бурычым
итеп сана. 19 Мин, Паул, моны үз кулым белән язам: сиңа үзем
түләрмен; инде үзеңнең дә тормышың белән миңа бурычлы бу-
луыңны әйтеп тормыйм. 20 Әйе, туганым, Раббы хакына миңа
яхшылык кыл; Мәсихтә имандаш буларак, күңелемне күтәр.
21 Бу үтенечемне кире какмасыңа ышанып язам һәм, сорагany-
ма караганда, синең күбрәк тә эшләячәгеңне беләм.

22 Шулай ук минем өчен дә бер бүлмә хәстәрләп куйчы, чөн-
ки догаларыгызга җавап булып сезгә кире әйләнеп кайтырмын
дип өметләнәм.

23-24 Мәсих Гайсә хакына кулга алынган Эпафрас һәм хез-
мәттәшләрем Марк, Аристарх, Димас һәм Лүк шулай ук сине
сәламли.

25 Раббы Гайсә Мәсихнең мәрхәмәте сезнең рухыгыз белән
булсын.

# ЕВРЕЙЛӘРГӘ ХАТ

*Аллаһы Улы – фәрештәләрдән өлкәнрәк*

1 [1] Аллаһы борынгы заманда пәйгамбәрләр аша ата-бабала-
рыбызга күп мәртәбәләр һәм күп төрле сөйләде. [2] Шушы
соңгы көннәрдә Ул безгә бөтен нәрсәнең варисы итеп
куйган Улы аша сөйләде. Аллаһы галәмне Улы аша барлыкка
китерде. [3] Аның Улы – Аллаһының даны чәчкән яктылык вә
Аллаһының төп-төгәл чагылышы. Ул һәммә нәрсәне Үзенең
кодрәтле сүзе белән тотып тора. Кешеләрне гөнаһларыннан
чистарткач, Ул күктә Мәһабәт Аллаһының уң ягына утырды.
[4] Ул фәрештәләрдән никадәр өлкәнрәк булса, Аның исеме алар
исеменнән шулкадәр югарырак тора.

[5] Чөнки фәрештәләрнең берәрсенә кайчан да булса:

«Син – Минем Улым,
бүген Мин Сине тудырдым», –

дип әйткәнме Аллаһы? Һәм тагын фәрештәләрнең кайсы ту-
рында да булса:

«Мин – Аның Атасы булачакмын,
ә Ул Минем Улым булачак», –

дип әйткәнме Аллаһы? [6] Дөньяга Үзенең беренче туган Улын
китергәндә, Аллаһы:

«Барлык Аллаһы фәрештәләре Аңарга
табынсын», –

ди. [7] Фәрештәләр турында Аллаһы:

«Аллаһы Үзенең фәрештәләрен җилләр итә,
хезмәтчеләрен янып торган ялкын итә», –

ди. [8] Улы турында исә:

«Йа Аллаһым, Патшалыгың мәңгелек;
Синең хакимлегең гадел, –

ди.

[9] – Син хаклыкны сөйдең, канунсызлыкны
күралмадың.
Шуңа күрә Аллаһы, Синең Аллаһың,
Сиңа иптәшләреңә караганда

зуррак шатлык бүләк итте*».
10 Аллаһы тагын болай ди:
«Йа Раббым, башта Син җирнең нигезләрен,
кулларың белән күкләрне бар иттең.
11 Алар бетәр, ә Син исә мәңге калырсың.
Алар һәммәсе дә кием кебек тузып бетәчәк.
12 Син аларны өс киеме кебек итеп төреп алачаксың,
алар кием кебек алыштырылачак,
Син исә гел бер төрле калачаксың,
Синең гомерең мәңге бетмәячәк».
13 Фәрештәләрнең берәрсенә Аллаһы кайчан да булса:
«Дошманнарыңны Синең аяк астыңа баскыч итеп
салганчы,
утыр Минем уң ягымда», —
дигәнмени? 14 Фәрештәләр — котылуны мирас итеп алачак зат-
ларга хезмәт итү өчен җибәрелгән рухлар түгелмени?

*Бөек коткарылу*

2 1 Шуңа күрә, туры юлдан чыкмас өчен, ишеткәннәребезгә
аеруча игътибарлы булырга тиешбез. 2 Чөнки фәрештәләр
аша җиткерелгән сүз дөрес булып, һәртөрле җинаять вә
тыңлаусызлык тиешле җәзасын алган икән, 3 шундый бөек
коткарылу белән исәпләшмәсәк, җәзадан без ничек котылып
калырбыз соң? Раббы Үзе кешеләргә бу хакта беренче булып
хәбәр җиткерде. Һәм Раббы әйткәнне ишеткән кешеләр бу кот-
карылуның чын булуын безгә исбат иттеләр. 4 Аллаһы Үзе дә
моны безгә галәмәтләр, могҗизалар вә төрле кодрәтле гамәлләр
кылып, Изге Рухтан килгән бүләкләрне Үз ихтыяры буенча бү-
леп бирү юлы белән исбат итте.

*Гайсә кешеләрне коткарылуга алып бара*

5 Аллаһы без хәзер сөйли торган киләчәк дөньяны фәрештә-
ләр кулына тапшырмады. 6 Әмма кемдер кайдадыр Изге язмада
әйткән:
«Син ни өчен кеше турында кайгыртасың?
Син нигә адәм улы турында уйлыйсың?
7 Син аны беркадәр вакытка фәрештәләрдән түбәнрәк
куйдың;
Син аның башына дан вә кадер-хөрмәт таҗын кидердең,
8 һәммәсен дә аның кулына тапшырдың».

---

* 1:9 *Сиңа иптәшләреңә караганда зуррак шатлык бүләк итте* — грек телендә сүзгә-сүз: «Шатлык мае белән майлап, Сине иптәшләреңә караганда өстенрәк куйды».

Бар нәрсәне аңа буйсындыргач, һәммәсе дә аның ихтыярына
буйсына торган булды. Ләкин әле без һәммә нәрсәнең аңарга
буйсынганын күрмибез. 9 Әмма без, Аллаһы мәрхәмәте аркасын-
да, һәр кеше өчен үлсен дип, беркадәр вакытка фәрештәләрдән
түбәнрәк куелган Гайсәне күрәбез. Хәзер без Аны газап чиккәне
һәм үлгәне аркасында дан вә кадер-хөрмәт тажы кигән хәлдә
күрәбез.
10 Аллаһы һәммә нәрсәне бар итә һәм саклый. Үзенә иярүче
күпләгән кешене данга илткән чагында Аның Гайсәне газаплар
аша камиллеккә ирештерүе урынлы булды. Чөнки коткарылуга
аларны Гайсә илтә. 11 Кешеләрне изге итүче Гайсә һәм Ул изге
иткән кешеләр – икесе дә бер үк Атадан. Менә ни өчен Гайсә
аларны туганнарым дип атаудан тартынмый. 12 Гайсә:

«Синең исемеңне туганнарыма игълан итәрмен,
гыйбадәт кылырга җыелган халык алдында
Сиңа дан җырлармын», –

ди. 13 Ул тагын:

«Мин Аллаһыга ышаныч баглыйм», –

ди. Ул шулай ук:

«Менә Мин Үзем
һәм Миңа Аллаһы биргән балаларым», –

ди.
14 Бу балаларның каны вә тәне бар. Гайсә, Үз үлеме аша,
үлемгә баш булган иблиснең хакимлеген юк итәр өчен, 15 гомере
буена үлемнән куркып, кол булып яшәгән кешеләрне азат итәр
өчен, Үзе дә кешеләр кебек булды. 16 Чөнки Ул, әлбәттә, фәреш-
тәләргә түгел, ә Ибраһим токымына ярдәм итә. 17 Шуңа күрә,
Үзен корбан итеп, халыкның гөнаһларын йолар өчен, Аллаһы-
га хезмәт итүдә рәхим-шәфкатьле вә тугрылыклы Баш Рухани
булыр өчен, Гайсә бар нәрсәдә Үзенең туганнарына охшарга
тиеш булды. 18 Чөнки Ул Үзе дә, вәсвәсәләндерелеп, газап чик-
кәнгә күрә, вәсвәсәгә дучар булганнарга ярдәм итә ала.

### *Гайсә Мусадан өлкән*

**3** 1 Изге туганнар, сезне дә Аллаһы чакырып алган. Шуңа
күрә уйларыгызда Гайсәне – без тоткан иманның Алла-
һы җибәргән Баш Руханиен* саклагыз. 2 Ул, Муса Аллаһы
йортындагы эшләрдә тугры булган кебек үк, Үзен билгеләгән
Аллаһыга тугры булды. 3 Йортны төзүчегә йортның үзенә кара-
ганда күбрәк хөрмәт күрсәтелгән кебек, Гайсә Мусага караганда

---

* 3:1 *Аллаһы җибәргән Баш Руханиен* – Бу сүзләрне грек теленнән «Рәсүлен һәм Баш Руханиен» дип тә аңларга мөмкин.

олырак хөрмәткә лаек дип саналды. 4 Әлбәттә, һәрбер йортны
кем дә булса берәү сала, ә һәммә нәрсәне Аллаһы бар кылган.
5 Муса Аллаһы йортында тугры хезмәтче иде һәм Мусаның эш-
ләре Аллаһы киләчәктә әйтәчәк нәрсәләргә шаһитлек булды.
6 Ә Мәсих Аллаһы йорты өчен җаваплы Угыл буларак тугры-
лыклы; Аның йорты исә – без, әгәр дә инде кыюлыкны вә
өметкә ышанычыбызны ахырга кадәр сакласак.

*Ышанмаучы булуга каршы кисәтү*

7 Шулай итеп, Изге Рух әйткәнчә,
«Бүген Аллаһының тавышын ишетәсез икән,
8 чүлдәге сынау көнендә Аллаһыга каршы чыккандагы кебек,
үҗәтләнмәгез,
9 анда сезнең ата-бабаларыгыз Мине сынадылар
вә Минем кырык ел буена нәрсә эшләгәнемне күрделәр.
10 Шуның өчен Минем бу кешеләргә ачуым чыкты
һәм Мин: „Аларның күңелләре һәрвакыт ялгыш уйлый,
алар Мин күрсәткән юлларны белмәделәр“, – дидем.
11 Шуның өчен Мин, ачуым чыгып:
„Алар беркайчан да
Минем тынычлыгыма кермәячәкләр“, – дип ант иттем».

12 Сак булыгыз, имандашлар, берегездә дә тере Аллаһыдан
баш тарткан, явыз, ышанмый торган йөрәк булмасын. 13 Кире-
сенчә, «бүген» дигән сүз әле гамәлдә булганда, сезнең берегез
дә, гөнаһ алдауларына бирелеп, киреләнмәсен өчен, бер-бере-
гезне һәр көнне дәртләндереп торыгыз. 14 Чөнки без барыбыз
да, әгәр дә ахырга кадәр баштагы ышанычыбызга нык тотын-
сак, Гайсә белән бер үк юлдан барачакбыз. 15 Изге язмада әй-
телгәнчә:

«Әгәр дә сез бүген Аллаһының тавышын ишетәсез икән,
Аллаһыга каршы чыккандагы кебек үҗәтләнмәгез».

16 Аллаһы тавышын ишетеп, Аңа каршы баш күтәргән кеше-
ләр кемнәр иде соң? Муса Мисырдан алып чыккан кешеләр
түгел идемени алар? 17 Аллаһы кырык ел буена кемгә ачулы
булды соң? Гөнаһ кылып, чүлдә үлеп калган кешеләргә түгел-
ме? 18 Алар Минем тынычлыгыма беркайчан да кермәячәк, дип
кем турында ант итте соң Аллаһы? Сүз тыңламаучылар хакында
түгелмени? 19 Шулай итеп, ышанмаулары өчен, аларның Алла-
һының ял итү урынына керә алмаганын күрәбез.

*Аллаһы халкы өчен тынычлык*

4 [1] Шулай итеп, Аллаһының безгә тынычлык, ял бирү ха-
кындагы вәгъдәсе әле үз көчендә калганга күрә, берәребез
аны алудан мәхрүм ителә дип табылмасын өчен, сак бу-
лыйк. [2] Исраиллеләргә җиткерелгән кебек, Яхшы хәбәр безгә
дә җиткерелде, ләкин алар ул хәбәрне ишетсәләр дә, файдасы
булмады, чөнки алар хәбәрне тыңлаучыларның ышануын ур-
таклашмадылар. [3] Без исә, ышануыбыз аркасында, Аллаһының
тынычлыгын кабул итәбез.

Аллаһы:

«Ачуым чыгып, Мин ант иттем:
алар беркайчан да Минем тынычлыгымны кабул
итмәячәк», –

диде. Гәрчә, дөньяны бар иткәннән соң, Аның эшләре инде
тәмамланган булса да, Ул шулай дип әйтте. [4] Бер урында атна-
ның җиденче көне турында болай дип язылган бит: «Җиденче
көнне Аллаһы Үзенең барлык эшләреннән ял итте». [5] Шунда
ук тагын: «Бу кешеләр беркайчан да Минем тынычлыгымны
кабул итмәячәк», – дип язылган.

[6] Яхшы хәбәрне элегрәк ишеткән кешеләр, тыңлаусызлык-
лары өчен, Аллаһының тынычлыгын кабул итмәделәр. Ләкин
кайберәүләрнең аны кабул итәчәкләре дөрес булганлыктан,
[7] Аллаһы тагын билгеле бер көнне – «бүгенге көн»не билгеләде.
Күп еллар узганнан соң бу хакта Ул Давыт аша белдерде, инде
әйтелгәнчә:

«Сез бүген Аллаһының тавышын ишетәсез икән,
үҗәтләнмәгез».

[8] Чөнки халыкка тынычлыкны Ешуа китергән булса, Аллаһы
бүтән көн хакында әйтмәс иде. [9] Алай булгач, Аллаһы халкы
өчен шимбә көн ял булачак. [10] Чөнки Аллаһының тынычлыгын
кабул иткән кеше, Аллаһы Үзенең эшләреннән ял иткән кебек,
үз эшләреннән соң ял итәчәк. [11] Шуңа күрә, Аның тынычлыгын
алу өчен бар көчебезне куйыйк, тыңлаусызлар үрнәгенә ияргән
өчен беркем дә аннан мәхрүм калмасын.

[12] Чөнки Аллаһының сүзе тере вә куәтле; ул ике ягы да үткен
теләсә нинди кылычтан да үткенрәк. Ул безнең эчебезгә шул-
кадәр тирән үтеп керә ки, җанны рухтан, буыннарны сөяк
җелегеннән аера. Ул безнең йөрәгебездәге уй-фикерләребезне
хөкем итә. [13] Аллаһының күзеннән кача алырлык берни дә юк,
Аның алдында бар нәрсә ачык вә ничек булса шулай күренә.
Без Аңа хисап бирәчәкбез.

*Гайсә – бөек Баш Рухани*

14 Безнең күкләр аша узган бөек Баш Руханиебыз – Аллаһы
Улы Гайсәбез бар, шуңа күрә, үзебез тоткан иманга тугрылык-
лы булып калыйк. 15 Безнең Баш Руханиебыз безнең җитешмә-
гән якларыбызны аңламаучы, безгә теләктәшлек итә белмәүче
Зат түгел. Ул безнең кебек үк сыналды, ләкин һич кенә дә
гөнаһ кылмады. 16 Шулай итеп, ярдәм кирәк булганда шәфкать
алу һәм мәрхәмәт табу өчен, ышаныч белән мәрхәмәт тәхете
янына барыйк.

5 1 Һәр баш рухани, кешеләр арасыннан сайланып, Аллаһыга
хезмәт итү өчен кешеләрнең вәкиле итеп куела; һәм ул, ке-
шеләрнең гөнаһлары өчен, Аллаһыга бүләк вә корбаннар
бирә. 2 Андый баш рухани белмәүчеләрне дә, туры юлдан тай-
пылучыларны да аңлый ала, чөнки ул үзе дә көчсез бер бәндә
генәдер. 3 Шуңа күрә ул үз гөнаһлары өчен дә, халыкның гө-
наһлары өчен дә корбан китерергә тиеш.

4 Мондый хөрмәтле бурычны кеше үз өстенә үзе йөкли ал-
мый, аны, үз вакытында Һарунны сайлаган кебек, Аллаһы Үзе
билгеләп куя. 5 Шулай итеп, Баш Рухани булу хөрмәтен Гайсә
Үз өстенә Үзе алмады, киресенчә, Аллаһы Аңарга:

«Син – Минем Улым,
бүген Мин Сине тудырдым», –

диде. 6 Аннары тагын Изге язмадагы икенче бер урында Аллаһы:

«Мәлик-Садыйк ничек рухани булса,
Син дә мәңгегә Рухани буласың», –

диде.

7 Җирдә яшәгән чагында Гайсә, күз яшьләре белән кычкы-
рып елап, Үзен үлемнән коткара алачак Аллаһыга дога кылды
һәм ялварды, Аллаһы ихтыярына буйсынучы буларак, Аның ял-
варуы Аллаһыга барып иреште. 8 Аллаһы Улы булса да, Ул Үз
газаплары аша тыңлаучан булырга өйрәнде һәм, 9 камиллеккә
ирешкәннән соң, Үзенә тыңлаучан булган һәркем өчен мәңге-
лек котылу чыганагы булды. 10 Ул, Мәлик-Садыйк ничек рухани
булса, шулай Аллаһы тарафыннан Баш Рухани итеп билгеләнде.

*Дөрес юлдан читкә тайпылу турында кисәтү*

11 Бу хакта күп сөйләргә кирәк иде, ләкин сезгә аңлатуы бик
кыен, чөнки сез сөйләгәнне бик авыр аңлый башладыгыз. 12 Уз-
ган вакытка карасак, сез инде үзегез өйрәтүче булырга тиеш
идегез, ләкин әлегә сезнең үзегезне Аллаһы тәгълиматының иң
беренче дәресләренә өйрәтергә кирәк. Сезгә каты азык түгел,
сөт бирергә кирәк. 13 Сөт белән туенучы кеше хак белән ялган

арасындагы аерманы сизә алмый. [14]Каты азык исә өлкәннәр
өчен; алар тормыш итү тәҗрибәсе аша яхшылык белән яман-
лыкны аерырга өйрәнәләр.
6 [1-2]Шуңа күрә, Мәсих тәгълиматының иң башлангыч
өлешен калдырып, камилрәгенә күчик. Үлемгә китерүче
эшләрдән тәүбә итүгә, Аллаһыга инануга, шулай ук суга
чумдырылу йолалары, кулларны кую*, үлгәннәрнең терелүе вә
мәңгелек хөкем турындагы тәгълиматка янә нигез сала башла-
мыйк инде. [3]Аллаһы Үзе рөхсәт итсә, без алга таба китик.
[4]Инде бер мәртәбә Аллаһы хәбәрен хак дип таныган, күк
бүләгенең тәмен татыган, Изге Рухта катнашкан, [5]Аллаһының
яхшы сүзен вә киләчәк дөнья көчләренең тәэсирен татыган, [6]ә
аннары дөрес юлдан читкә тайпылган кешеләрне яңадан тәү-
бәгә китерергә мөмкин түгел, чөнки Аллаһы Улын алар үзләре
яңадан хачка кадаклыйлар, Аны бөтен халык алдында мәсхә-
рәлиләр.
[7]Яңгыр мул итеп сугарган җир, дымны үзенә сеңдереп, җир
кем өчен эшкәртелсә, шул кешегә файдалы уңыш бирсә, Алла-
һының фатихасын ала. [8]Ләкин әгәр бу җирдә шайтан таягы вә
чәнечкеле куаклар үсә торган булса, аның бернинди дә файда-
сы юк. Аны каргыш көтә, ахыр килеп, ул җирне яндырырлар.
[9]Ләкин, сөеклеләрем минем, шулай дип әйтсәк тә, сезнең
хәлегез әйбәтрәк вә ул сезне коткарылуга илтә дип ышанабыз.
[10]Аллаһы гаделсез түгел. Ул сезнең хезмәтләрегезне дә, иман-
дашларыгызга ярдәм кылганыгыз вә ярдәм кылуны дәвам
итүегез аша Аңа булган мәхәббәтегезне күрсәткәнегезне дә
онытмаячак.
[11]Без сезнең һәрберегезнең ахырга кадәр, өметегезнең ту-
лысынча тормышка ашуына кадәр, тырышлык куюын телибез.
[12]Ялкау булмагыз, бәлки, иманлы вә түземле булулары белән
үзләренә вәгъдә ителгәнне алучы кешеләр үрнәгенә иярегез.

*Аллаһының ышанычлы вәгъдәсе*

[13]Ибраһимга вәгъдәсен биргәндә Аллаһы, ант итәрлек юга-
рырак һичкем булмаганлыктан, Үз-Үзе белән ант итте. [14]Ул:
«Мин сиңа фатиха өстенә фатиха бирәм. Мин синең токымың-
ны ишәйткәннән-ишәйтәчәкмен», – диде. [15]Һәм Ибраһим,
сабырлык белән көткәннән соң, вәгъдә ителгәнне алды. [16]Ке-
шеләр үзләреннән югарырак зат белән ант итәләр, ул ант әй-
телгәнне раслый вә һәртөрле бәхәсләргә чик куя. [17]Шуңа күрә

---

* 6:2 *Кулларны кую* – Аллаһы хезмәтенә билгеләнгән кешеләргә шу-
шы хәрәкәт аркылы фатиха һәм куәт бирелә.

Аллаһы Үз максатының үзгәрешсез булуын Аллаһы вәгъдә ит-
кәнне алачак кешеләр аңласын өчен, аны ант биреп раслады.
18 Ике үзгәрешсез нәрсә – вәгъдә һәм ант турында Аллаһы
һич тә ялганлый алмый. Алар безне, Аллаһыга сыенганнарны,
алдыбызда торган өметкә нык тотынырга дәртләндерә. 19 Бу
өмет безнең җаныбызның ышанычлы вә ныклы якоре сыман.
Ул пәрдә артындагы Иң изге урынга керә. 20 Гайсә анда, безнең
хакка, бездән алдарак керде. Мәлик-Садыйк ничек баш рухани
булса, Гайсә дә мәңгегә Баш Рухани булды.

*Мәлик-Садыйк рухани*

7 1 Бу Мәлик-Садыйк, Шалим патшасы, Аллаһы Тәгаләнең
рухание иде, ул, патшаларны тар-мар итеп кайтып кил-
гән Ибраһимны очратып, аңа фатихасын бирде. 2 Ибраһим
аңарга сугышта тапкан байлыгының уннан бер өлешен бирде.
Аның «Мәлик-Садыйк» дигән исеме «хаклык патшасы» дигән-
не, ә «Шалим патшасы» – «иминлек патшасы» дигәнне аңлата.
3 Мәлик-Садыйкның әти-әнисе дә, ата-бабалары да билгесез.
Аның гомеренең башы вә ахыры турында да берни мәгълүм
түгел, ул, Аллаһы Улы кебек, мәңге рухани булып кала.
4 Аның никадәр бөек икәнлеген күрдегезме инде! Хәтта ыруг
башлыгы Ибраһим да аңа сугышта тапкан байлыгының иң ях-
шысыннан уннан бер өлешен бирде. 5 Соңыннан рухани булган
Леви токымы угыллары, канун кушуы буенча, туганнарыннан,
алар да Ибраһим токымыннан булсалар да, табышының уннан
бер өлешен алырга тиеш. 6 Мәлик-Садыйк рухани исә, Леви
токымыннан булмаса да, Ибраһим табышының уннан бер өле-
шен кабул итте һәм аңа, Аллаһының вәгъдәсен кабул иткән
кешегә, фатихасын бирде. 7 Фатиханы бирүче кеше һичшик-
сез аны кабул итүчедән өстенрәк була. 8 Беренче очракта та-
бышның уннан бер өлешен үләсе руханилар җыйды, ә икенче
очракта уннан бер өлешен, Изге язма шаһитлек иткәнчә, мәңге
яшәүче кеше алды. 9 Күпмедер мәгънәдә, Леви хәтта үзе дә та-
бышының уннан бер өлешен Ибраһим аша Мәлик-Садыйкка
түләгән, дип әйтергә була. 10 Чөнки Мәлик-Садыйк Ибраһим-
ны очраткан вакытта Леви әле тумаган булса да, ул инде үзенең
ата-бабасы Ибраһимның тәнендә иде.

*Мәлик-Садыйк кебек Рухани Гайсә*

11 Әгәр дә левиле руханилар хезмәте аша камиллеккә ирешe-
лергә мөмкин булса (чөнки Муса кануны левиле руханилык
белән тыгыз бәйләнештә бирелгән булган), Һарун кебек түгел,
ә Мәлик-Садыйк кебек икенче Руханиның килүенә ихтыяҗ

тумас иде. 12 Чөнки руханилык үзгәрсә, канун да һичшиксез
үзгәрә. 13 Ә без сөйләгән Зат икенче бер ырудан иде, ул ырудан
беркем дә корбан китерү урыны янында хезмәт итмәде. 14 Без-
нең Раббыбыз бит Яһүд ыруыннан чыкты, ә Муса, руханилар
турында сөйләгәндә, бу ыру турында берни дә әйтмәгән.

15 Моның шулай икәнлеге Мәлик-Садыйк кебек яңа Рухани
килгәч тагын да ачыграк, аңлаешлырак булды. 16 Ул кешенең чы-
гышына кагылышлы канун әмере буенча түгел, ә мәңге бетми
торган яшәү көче буенча Рухани булды. 17 Аның хакында Изге
язмада: «Мәлик-Садыйк ничек рухани булса, Син дә мәңгегә
Рухани буласың», – диелгән. 18 Шуңа күрә, зәгыйфь вә файдасыз
булуы сәбәпле, элеккеге канун әмере үз көчен югалтты. 19 Муса
кануны бернине дә камилләштермәде, ә аның урынына безне
Аллаһыга ныграк якынайткан зуррак өмет барлыкка китерелде.

20 Өстәвенә, бу Затны Рухани итеп билгеләвен Аллаһы Үзенең
анты белән раслады. Калган руханилар антсыз руханилар булды,
21 ләкин Гайсә исә Аллаһының анты аркылы, ягъни Аллаһы Аңа:

«Раббы ант итте,
Ул Үзенең карарын үзгәртмәячәк:
„Син – мәңгелек Рухани!“» –

дигәндә Рухани булды. 22 Шул рәвешле, Аллаһы төзегән әйбәт-
рәк килешүнең ышанычлысы Гайсә булды.

23 Башка руханилар күп иде, ләкин алар хезмәтләрен дәвам
итә алмадылар, чөнки үлә тордылар. 24 Ә Гайсә мәңге тере,
Аның руханилыгы да үзгәрешсез. 25 Шуңа күрә дә Ул үзе аркы-
лы Аллаһыга килүче кешеләрне тулысынча коткара ала. Чөнки
Ул, алар турында Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, алар турында ял-
вару өчен һәрвакыт яши.

26 Безгә нәкъ менә шундый Баш Рухани кирәк: Ул изге, гаеп-
сез, саф, гөнаһлылардан аерып куелган вә күктән дә югары кү-
тәрелгән. 27 Ул, бүтән баш руханилар сыман, көн саен башта
Үзенең гөнаһлары, аннары халыкның гөнаһлары өчен корбан
китерүгә мохтаҗ түгел. Ул Үзен корбан итеп, бер тапкыр һәм
мәңгелек корбан китерде. 28 Муса кануны баш рухани итеп ке-
шеләрне билгели, ә кеше ул зәгыйфь. Ә инде кануннан соң би-
релгән ант буенча, Аллаһы Улы Баш Рухани итеп билгеләнде.
Ул – мәңгелек камиллеккә ирешкән Зат.

### *Яңа килешүнең Баш Рухание*

**8** 1 Без сезгә сөйләгәннәрдә иң мөһиме – күктә Мәһабәт
Аллаһының уң ягында утыручы Баш Руханиебыз бар. 2 Ул
Изге йортта – кешеләр түгел, ә Раббы Үзе корган чын
гыйбадәт кылу чатырында хезмәт итә. 3 Һәр баш рухани бүләк

вә корбаннар китерү өчен билгеләнә. Шуңа күрә безнең Баш
Руханиебызның да корбан китерү өчен нәрсәседер булырга
тиеш иде. 4 Әгәр җирдә булса, Ул рухани булмас иде, чөнки
Муса кануны буенча корбан китерүчеләр инде бар. 5 Җирдәге
руханилар күктәге йорт үрнәгенә ияреп төзелгән Изге йортта
хезмәт итәләр, ә ул күктәге Изге йортның фәкать күләгәсе генә.
Менә шуңа күрә Мусага гыйбадәт кылу чатыры корыр алдын-
нан кисәтеп куелды: «Кара аны, һәммәсен дә тауда күрсәтелгән
үрнәк буенча эшлә», – диде Аллаһы. 6 Иске килешүгә караган-
да Гайсә Арадашчы булган яңа килешү әйбәтрәк булган кебек,
Аңа тапшырылган хезмәт җирдәге руханилар хезмәтеннән әй-
бәтрәк. Яңа килешү әйбәтрәк, чөнки ул әйбәтрәк вәгъдәләргә
нигезләнгән.

7 Чөнки беренче килешү кимчелексез булган булса, икенчесе-
нә ихтыяҗ да булмас иде. 8 Ләкин Аллаһы, Үз халкыннан гаеп
табып, болай дип әйтә:

«Шундый көннәр киләчәк, ди Раббы,
Мин Исраил халкы вә Яһүд халкы белән
яңа килешү төзиячәкмен.
9 Бу килешү Мин аларның ата-бабаларын
Мисырдан җитәкләп чыгарганда төзегән килешүгә
охшамаган.
Алар Минем килешүемә тугрылыклы булмадылар,
һәм Минем алардан гайрәтем чикте, ди Раббы.
10 Исраил халкы белән Мин киләчәк көннәрдә төзиячәк
килешү шушы:
Үз кануннарымны Мин аларның зиһеннәренә
салачакмын,
күңелләренә язып куячакмын.
Мин – аларның Аллаһысы,
ә алар Минем халкым булачак.
11 Инде беркем дә икенче берәүне, үзенең туганын:
„Раббыны танып бел“, – дип өйрәтмәячәк.
Чөнки Мине кечесеннән башлап олысына кадәр
беләчәк.
12 Чөнки Мин аларның явыз эшләрен кичерәчәкмен,
кылган гөнаһларын инде беркайчан да искә
алмаячакмын».

13 Бу килешүне Ул «яңа» дип атап, искесен гамәлдән чыгарды,
ә гамәлдән чыгарылган һәм искергән һәр нәрсә тиздән юкка
чыгачак.

*Иске килешү вакытында гыйбадәт кылу*

9 1 Беренче килешүнең гыйбадәт кылу хакында күрсәтмә-
ләре һәм җирдәге Изге йорты бар иде. 2 Гыйбадәт кылу
чатыры корылды, аның алгы өлешендә шәмдәл һәм Алла-
һыга багышланган икмәкләр куелган өстәл урнаштырылды. Бу
өлешне «Изге урын» дип атадылар. 3 Икенче пәрдә артында ча-
тырның «Иң изге урын» дип аталган өлеше бар иде. 4 Анда хуш
исле сумала яндыру өчен алтыннан ясалган изге өстәл вә алтын
белән капланган килешү сандыгы бар иде. Сандыкка манна*
салынган алтын савыт, Һарунның чәчәк аткан таягы һәм Аллаһы
әмерләре язылган таш такталар урнаштырылган иде. 5 Ә сандык
өстенә, Аллаһының шунда булуын сурәтләгән, күктәге канатлы
затларның сыннары куелган иде, аларның канатларыннан төш-
кән күләгә гөнаһларны йолу урынын каплап торды. Ләкин без
хәзер һәммәсен дә җентекләп сөйләп тормыйбыз.
6 Бу әйберләр менә болай урнаштырылган иде. Чатырның ал-
гы өлешенә руханилар, Аллаһыга гыйбадәт кылганда, һәркөн
керәләр. 7 Ә икенче өлешкә баш рухани гына елга бер мәртәбә
керә. Ул үзе белән кан алырга тиеш, ул үзе өчен дә, белмичә
гөнаһ кылган халык өчен дә Аллаһыга корбан итеп кан китерә.
8 Шуның белән Изге Рух әле чатырның алгы өлеше булганда
Иң изге урынга юлның әлегә ачык булмавын күрсәтә. 9 Моның
бүгенге көн өчен дә мәгънәсе бар: бүләкләр вә корбаннар ките-
релү белән Аллаһыга гыйбадәт кылучының вөҗданы сафлана ал-
мый. 10 Бу йолалар ашау-эчү, төрле юыну йолаларын гына күздә
тотты. Болар тышкы якны гына күздә тотучы кагыйдәләр иде,
һәм алар яңа тәртип урнаштырылганчы гына үз көчендә була.

*Яңа килешү корбаны*

11 Хәзер инде Мәсих монда булган яхшы нәрсәләрнең Баш
Рухание булып килде. Ул бөегрәк вә камилрәк, кеше кулы сал-
маган һәм бу фани дөньяныкы булмаган чатыр аркылы барды.
12 Иң изге урынга Мәсих кәҗә вә бозау каны белән түгел, ә ба-
ры бер мәртәбә Үз каны белән керде, кешеләргә мәңгелек ко-
тылу тәэмин итте. 13 Чөнки әгәр дә үгез һәм кәҗә каны яисә
корбан итеп яндырылган яшь бозау көле, хәрәм булганнар өс-
тенә сибелеп, тәнне тышкы яктан чистарта икән, 14 Мәсих каны
безне чагыштырып булмаслык дәрәҗәдә күбрәк чистартачак бит!

---

* 9:4 *Манна* – борынгы Исраил халкын коллыктан азат итеп Ми-
сырдан чыгаргач, чүлдә туйдыру өчен Аллаһы күктән җибәреп
торган ризык.

Ул мәңгелек Рух аркылы Үзен Үзе кимчелексез корбан рәвешендә тапшырды, һәм, без тере Аллаһыга хезмәт итә алсын өчен, Аның каны безнең вөжданнарыбызны үлемгә китерүче гамәлләрдән чистартыр.
15 Шуңа күрә Мәсих, иске килешү вакытында кылынган гөнаһлардан кешеләрне Үз үлеме белән коткарып, Аллаһы тарафыннан чакырылганнар вәгъдә ителгән мәңгелек мирасны ала
алсыннар өчен, яңа килешүне Урнаштыручы булды. 16 Әгәр дә
васыять* бар икән, аны язган кешенең үлгәнен исбатларга
кирәк. 17 Чөнки васыять, аны язган кеше исән чагында, бернинди дә көчкә ия булмый. Васыять аны язган кеше үлгәч кенә
көченә керә. 18 Шуның өчен беренче килешү* каннан башка
гамәлгә керә алмады. 19 Муса канун күрсәтмәләренең барысын
да халык алдында укып чыккач, кызыл йон вә һүссөп** чыбыкларын алып, бар халыкка һәм канун язылган төргәкнең үзенә
бозау, кәҗә каны белән су сибеп чыкты. 20 Ул: «Бу – килешүне
раслаучы кан. Аллаһы сезгә ул килешүне үтәргә әмер бирде», –
диде. 21 Ул шулай ук чатырга һәм анда булган, Аллаһыга гыйбадәт кылганда кулланылган барлык әйберләргә кан сибеп чыкты. 22 Канун бар нәрсәнең диярлек кан белән пакьләнделүен
таләп итә, һәм кан түгелмичә ярлыкау булмый.
23 Күктәге үрнәк буенча җирдә төзелгән нәрсәләр шул рәвешле чистартылырга тиеш иде, ләкин күкнеке яхшырак корбаннар белән пакьләндерүне таләп итә. 24 Чөнки Мәсих кеше
кулы белән төзелгән вә чын Изге йортның нибары күчермәсе
генә булган Изге йортка кермәде. Ул, безнең өчен Аллаһы алдына барып басарга дип, күкнең үзенә керде. 25 Ул, баш рухани
һәр елны Иң изге урынга үз каны булмаган кан алып кергән
сыман, Үзен кабат-кабат корбан итәр өчен кермәде. 26 Әгәр дә
шулай булса, Мәсих, дөнья яратылганнан бирле, Үзен корбан итеп, кабат-кабат газап чигәргә тиеш булыр иде. Ләкин Ул Үзен корбан итү аша гөнаһны бетерер өчен, соңгы дәвердә бары тик бер мәртәбә килде. 27 Һәркем кайчан да булса бер үлеп,
аннары хөкем алдына басарга тиеш булган кебек, 28 Мәсих,
күпләгән кешенең гөнаһларын Үз өстенә алыр өчен, бер мәртәбә корбан ителде, һәм Ул әле икенче тапкыр киләчәк, ләкин инде кешеләрнең гөнаһларын йолу өчен түгел, ә Үзен көтеп торучыларны коткару өчен киләчәк.

---

* 9:16, 18 *Васыять, килешү* – грек телендәге «диатеке» сүзенең «килешү» һәм «васыять» дигән мәгънәләре бар.

** 9:19 *Һүссөп* – яһүдләрнең дини йолаларында кулланыла торган үсемлек.

10 [1] Канун – киләсе яхшы нәрсәләрнең төгәл чагылышы
түгел, ә аларның күләгәсе генә. Шуңа күрә ул, ел саен
бер үк корбаннар китереп, Аллаһы алдына килгән кеше-
ләрне беркайчан да камил итә алмый. [2] Әгәр дә канун моны
эшли алса, корбаннар китерүдән туктамаслар идемени? Чөнки,
бер тапкыр чистарынгач, гыйбадәт кылучылар үзләрен гөнаһлы
дип хис итми башларлар иде. [3] Әмма ләкин корбаннар ел саен
гөнаһ турында искә төшереп тора, [4] чөнки үгез каны белән кә-
җә каны кешенең гөнаһын юа алмый.

[5] Шуңа күрә, дөньяга килгәч, Мәсих:
«Син корбан китерүне дә, бүләк бирүне дә теләмәдең,
ләкин Син Минем өчен тән әзерләдең, – диде.
6 – Сине яндырылган хайван корбаннары да,
гөнаһлар өчен китерелгән корбаннар да сөендермәде.
7 Шунда Мин: „Йа Аллаһы, менә Мин,
Изге язма төргәгендә* Минем хакта язылганча,
Синең ихтыярыңны җиренә җиткерү өчен
килдем!“ –
дидем». [8] Шулай итеп, башта Ул: «Син корбаннар да, бүләкләр
дә, яндырылган корбаннар да, гөнаһ өчен корбаннар да ките-
рүне теләмәдең, алар Сине сөендермәде», – диде. Бу корбан-
нар канун буенча таләп ителүгә дә карамастан, Ул шулай диде.
[9] Аннары Ул: «Менә Мин, Синең ихтыярыңны җиренә җитке-
рер өчен килдем», – дип өстәде. Ул иске килешүне гамәлдән
чыгарып, икенчесен – Аллаһы ихтыярын үтәүне гамәлгә керт-
те. [10] Аллаһы ихтыяры буенча без Гайсә Мәсихнең Үз тәнен бер
мәртәбә һәм мәңгелек көчкә ия булган корбан итүе белән изге
ителдек.

[11] Һәр рухани, көн саен гыйбадәт кылып, күп тапкырлар шул
ук корбаннарны китерә, әмма алар кешене һичкайчан гөнаһ-
лардан арындыра алмый. [12] Ләкин бу Баш Рухани, гөнаһлар
өчен мәңгелек көчкә ия булган корбанны бер мәртәбә китер-
гәч, Аллаһының уң ягына утырды. [13] Шул вакыттан алып Ул
дошманнарының Үз аягы астына баскыч итеп салынуын көтә.
[14] Чөнки бер корбан белән Ул изге ителүчеләрне мәңгегә камил
кылды.

[15] Бу хакта безгә Изге Рух та шаһитлек кыла. Башта Ул бо-
лай ди:
16 «Киләчәк көннәрдә Мин алар белән төзиячәк килешү
шушы, – ди Аллаһы.

---

* 10:7 *Изге язма төргәге* – ул заманда язмалар төргәк формасында
булган (русча – свиток).

– Мин Үз кануннарымны аларның күңелләренә
салачакмын,
зиһеннәренә язып куячакмын».
17 Аннары Ул болай дип өсти: «Аларның гөнаһларын вә явыз
эшләрен Мин инде беркайчан да искә алмам». 18 Болар киче-
релгән икән, гөнаһ өчен корбан бирүнең инде кирәге юк.

*Нык торыгыз!*

19 Шулай итеп, имандаш туганнар, Гайсә каны белән без Иң
изге урынга ышаныч белән керә алабыз, 20 Ул безгә яңа вә тере
юлны ачкан. Бу юл пәрдә, ягъни Аның тәне аша бара. 21 Безнең
Аллаһы йорты башында торучы бөек Руханиебыз бар. 22 Шуңа
күрә, әйдәгез, Аллаһыга ихлас күңел вә иман ышанычлылыгы
белән, күңелләребез гөнаһлы вөжданнан чистарынган, тән-
нәребез чиста су белән юылган хәлдә Аллаһыга якынайыйк.
23 Үзебез икърар иткән өметкә нык тотыныйк, чөнки безгә
вәгъдә биргән Зат тугрылыклы. 24 Әйдәгез, бер-беребезгә игъ-
тибарлы булыйк, бер-беребезне мәхәббәт вә изге эшләргә
дәртләндерик. 25 Кайберәүләр кебек, гыйбадәт кылу өчен бергә
җыелудан баш тартмыйк, киресенчә, бер-беребезгә көч биреп,
тагын да ныграк дәртләндереп торыйк, чөнки Раббы көненең
якынлашуын күреп торасыз.
26 Әгәр дә без, хакыйкатьне танып белгәннән соң, аңлы рә-
вештә гөнаһ кылуыбызны дәвам итәбез икән, гөнаһлар өчен
инде бернинди корбан да калмый. 27 Ә ул чагында инде хөкемне
һәм Аллаһының дошманнарын яндырачак, бернине дә кызга-
нып тормаячак утны куркынып көтеп торасы гына кала. 28 Муса
кануныннан баш тарткан кеше, ике яисә өч шаһит күрсәтүе
нигезендә, һич кызганусыз үлемгә дучар ителә. 29 Алай булгач,
Аллаһы Улын аяк астына салып таптаган, Аллаһы килешүенең
аны изгеләндергән канын нәҗес дип санаучы, мәрхәмәт Рухын
кимсетүче кеше ни дәрәҗәдә каты җәзага лаек соң? 30 Без: «Үч
алу Минем эш, Үзем кайтарып бирәчәкмен», – дигән һәм: «Ал-
лаһы Үз халкын Үзе хөкем итәчәк», – дигән Затны беләбез.
31 Тере Аллаһы кулына эләгү коточкыч эш!
32 Сез Аллаһы яктылыгы сезне яңа гына яктырткannнан соң бу-
лып үткән көннәрне исегезгә төшерегез. Ул чагында сез газап-
ларга каршы көрәшүдә нык тора идегез. 33 Кайвакыт сезне бар ха-
лык алдында мәсхәрәләделәр, сезне эзәрлекләделәр, кайвакыт
сез боларны үз башыннан кичергән кешеләр янәшәсендә булды-
гыз. 34 Сез тоткынлыктагы кешеләргә теләктәшлек иттегез, мил-
кегездән мәхрүм иткәндә сез сөендегез дә, чөнки үзегезнең әй-
бәтрәк, мәңгелек байлыгыгыз барын белә идегез. 35 Кыю булудан

туктамагыз, моның әҗере зур булачак. 36 Ләкин Аллаһы ихтыя-
рын үтәр өчен сезгә сабырлык кирәк, аны үтәгәннән соң Алла-
һы вәгъдә иткәнне алырсыз. 37 Чөнки, Изге язмада язылганча,
«Инде күп калмады,
һәм килергә тиешле Зат озак көттерми киләчәк.
38 Минем тәкъва кешем үзенең инануы белән яшәячәк,
ләкин әгәр чигенсә,
ул Миңа яраклы булмаячак».
39 Ләкин без иманнан баш тартып һәлак булучылардан түгел,
юк, без иманда торабыз һәм коткарылачакбыз.

*Иман*

**11** 1 Иман ул – без өметләнеп көткәннәрнең тормышка
ашуына ышану, күренмәгән нәрсәләргә инанган булу.
2 Безнең борынгы ата-бабаларыбыз шундый иман арка-
сында Аллаһыдан хуплау алган.

3 Галәмнең Аллаһы сүзе белән булдырылганын һәм күзгә кү-
ренүче нәрсәнең күзгә күренми торган нәрсәдән барлыкка
килгәнен без иман аркылы аңлыйбыз. 4 Һабил Аллаһыга, иман
белән, Кабилныкына караганда әйбәтрәк корбан китергән.
Иманы өчен Аллаһы аның корбаннарын хуплады һәм аны хак
кеше дип раслады. Иманы аркылы Һабил, үзе исән булмаса да,
безгә әле һаман сөйли. 5 Иман аркасында Ханух, үлемне кичер-
мичә, бу дөньядан алынган. Аны бер җирдән дә таба алмады-
лар, чөнки Аллаһы аны Үз янына алган иде. Аның турында, ул
дөньядан алынганчы Аллаһыга ярый алган, дип әйтелә Изге
язмада. 6 Иман китерми торып Аллаһыга ярап булмый, чөнки
Аңа килүче һәркем Аллаһының барлыгына вә Аны ихластан эз-
ләгән кешеләргә әҗерен бирми калмаячагына инанырга тиеш.
7 Иман аркасында Нух, нәрсәләр буласы турында Аллаһыдан
кисәтү алгач, ләкин әле аны күрмәс борын, Аңа буйсынып,
гаиләсен коткару өчен көймә төзегән. Аның иманы дөньяны
хөкем иткән, һәм иманы аркасында Аллаһы аны хак дип игъ-
лан иткән.

8 Иман аркылы Ибраһим, Аллаһы чакыргач, буйсынып, ки-
ләчәктә үзенә мирас дип вәгъдә ителгән җиргә киткән, гәрчә
кая барганын белмәсә дә. 9 Иман белән ул вәгъдә ителгән илдә
килмешәк булып яшәгән. Исхак вә Ягъкуб кебек үк, ул да ча-
тырларда яшәгән, алар да аның белән бергә, Аллаһы вәгъдә ит-
кәнне алырга тиеш булган. 10 Чөнки ул рәссамы вә төзүчесе
Аллаһы булган, мәңгелек нигезле шәһәрне көткән.

11 Иманы аркасында Ибраһимның хатыны Сара үзе дә, инде
карт булса да, балага уза алган, чөнки ул үзенә вәгъдә биргән

Аллаһыны ышанычлы дип исәпләгән*. [12] Шулай итеп, тәне
инде картайган Ибраһим күктәге йолдызлар кадәр күп санлы
вә диңгез ярындагы исәпсез-хисапсыз ком бөртекләре кадәр
токым бирде.
[13] Барлык бу кешеләр иманнарын саклап үлгәннәр. Алар үз-
ләренә вәгъдә ителгәннәрне, кабул итмичә, ерактан гына
күргәннәр һәм сәламләгәннәр. Алар бу дөньяда үзләренең
килмешәк вә юлчылар гына икәнлекләрен таныганнар. [14] Бо-
лай дип әйтүче кешеләр үзләренең чын ватаннарын эзләүләрен
күрсәтәләр. [15] Әгәр дә алар үзләре калдырып киткән ил турын-
да хәтерләренә төшереп уйлаган булсалар, анда кире кайту
мөмкинлеге дә булган булыр иде. [16] Юк, алар әйбәтрәк илгә –
күк иленә омтылганнар. Шуңа күрә аларның Аллаһыны үз
Аллаһысы дип тануы Аллаһыга оят түгел; чөнки Ул алар өчен
шәһәр әзерләп куйган.
[17-18] Ибраһим, Аллаһы тарафыннан сыналганда, иманы ар-
касында Исхакны корбанга тәкъдим итте. Ул Аллаһының
вәгъдәсен алган булса да һәм аңа: «Синең нәселең Исхак аша
килә», – дип әйтелгән булса да, ул үзенең бердәнбер улын кор-
бан итәргә әзер торды. [19] Ибраһим Аллаһының үледән терелтә
алуына исәп тотты, һәм Исхак, үледән терелтелүне алдан күр-
сәтүче билге буларак, әтисенә кире кайтарылды.
[20] Киләчәккә иман белән карауччы Исхак Ягъкуб белән Эсау-
га фатихасын бирде. [21] Иман аркылы Ягъкуб үләр алдыннан
Йосыфның ике улына да фатиха бирде һәм, таягына таянган
килеш, Аллаһыга табынып баш иде. [22] Иман аркылы Йосыф го-
меренең ахырында Исраил халкының Мисырдан чыгачагы ту-
рында сөйләде һәм үз сөякләрен нәрсә эшләтергә икәнен әйтте.
[23] Иман аркылы Мусаның ата-анасы Муса туганнан соң өч
ай буена аны яшереп сакладылар, чөнки аның гадәттән тыш
матур бала булуын күрделәр, аларны патша фәрманы куркыт-
мады. [24] Иман аркылы Муса, олы кеше булгач, фиргавен кызы-
ның угылы дип йөртелүдән ваз кичте. [25] Гөнаһтан кыска вакыт-
лы ләззәт алуга караганда Аллаһы халкы белән бергә газаплар
кичерүне мәгъкульрәк күрде. [26] Ул булачак әҗерне карап торды
һәм, шуңа күрә, Мәсих хакына хурлык кичерүне Мисыр бай-
лыкларыннан кадерлерәк исәпләде. [27] Иман аркылы Муса, пат-
шаның ачуыннан курыкмыйча, Мисырдан чыкты. Үз алдында

---

* **11:11** Грек теленнән бу аятьне: «Иманы аркасында Ибраһим, инде үзе карт, хатыны Сара бала тудыруга сәләтсез булса да, әти кеше була алган, чөнки ул үзенә вәгъдә биргән Затны ышанычлы дип исәпләгән» дип тә аңларга мөмкин.

күзгә күренми торган Аллаһыны күргән кебек булганлыктан, ул
түзде. 28 Иман аркылы ул, беренче булып туганнарны һәлак
итүче фәрештә Исраил халкының балаларына кагылмасын
өчен, ишекләргә кан сибү һәм Коткарылу бәйрәме үткәрде.
29 Иман аркылы Исраил халкы Кызыл диңгезне коры җирдән
баргандай атлап чыкты, ә мисырлылар шуны ук эшләп карагач,
һәммәсе дә батып үлде.

30 Иман аркылы Исраил кешеләре шәһәрне тышкы яктан җиде
көн рәттән әйләнеп чыккач, Әрихәне әйләндереп алган таш
диварлар ишелеп төште. 31 Иман аркылы бозык хатын Рәхәб,
Исраил шымчыларын дус дип кабул иткәнгә күрә, Аллаһыны
тыңламаучылар белән бергә һәлак ителмичә, котылып калды.

32 Шуннан да артыгын сөйләп торырга кирәкме икән? Гиде-
он, Барак, Шимшон, Ифтах, Давыт, Шамуил вә пәйгамбәрләр
турында сөйләп торырга вакытым җитмәс иде. 33 Алар иман
белән патшалыкларны буйсындырдылар, гаделлек урнаштыр-
дылар, вәгъдә ителгәнгә ирештеләр. Арысланнарның авызла-
рын яптылар, 34 ярсулы утны сүндерделәр, кылычтан котылып
калдылар. Аларның көчсезлеге көчкә әйләнде, сугышта алар
куәтле булдылар һәм чит ил гаскәрләрен качарга мәҗбүр итте-
ләр. 35 Кайбер хатыннар үлгән якыннарын тере килеш кире ал-
дылар. Бүтәннәре, үледән әйбәтрәк терелүгә ирешү өчен, азат
ителүдән баш тартып, җәзаландылар. 36 Кайберәүләрне мыскыл
иттеләр, аларны камчы белән кыйнадылар, кайберләренә хәтта
богау кигезелде, алар төрмәләргә ябылды. 37 Аларны ташлар
атып үтерделәр, гәүдәләрен пычкы белән урталай кистеләр,
кылычтан үткәрделәр. Алар сарык вә кәҗә тиреләренә төренеп
йөрделәр, башлары мохтаҗлыктан чыкмады, аларны эзәрлек-
ләделәр, кыйнадылар. 38 Дөнья бу затларга лаек түгел иде. Алар
чүлләрдә, тауларда, мәгарәләрдә, упкыннарда каңгырып йөрде.

39 Алар һәммәсе дә иманнары өчен Изге язмада әйбәт бәя
алдылар, ләкин берсе дә, җирдә яшәгән чагында, үзләренә
вәгъдә ителгәнне алмады. 40 Бу кешеләр бары тик безнең белән
генә камиллеккә ирешсен өчен, Аллаһы безнең өчен әйбәтрәк
бер нәрсә ниятләде.

*Гайсәдән күзебезне алмыйк*

**12** 1 Безнең тирә-ягыбызда шаһитләр шулкадәр күп! Шуңа
күрә, әйдәгез, юлыбызда торган бар киртәне алып
ташлыйк, безне җиңел генә алдап йөртүче гөнаһларны
калдырыйк һәм үзебезгә билгеләнгән ярыш юлын сабырлык
вә ныклык белән йөгереп үтик. 2 Гайсәдән – иманны Барлык-
ка китерүче вә Камилләштерүчедән күзебезне һәрдаим алмый

торыйк. Үзен киләчәктә көткән шатлык хакына хачка кадаклану хурлыгына игътибар итмичә, Ул хачта үлүне кичерде, хәзер
менә Аллаһы тәхетенең уң ягында утыра. [3] Гөнаһлылар тарафын-
нан шундый каршылыкны кичергән Гайсә турында уйлагыз; бу күңелегезне төшермәскә һәм Аллаһыга ышанудан туктамаска ярдәм итәр.

[4] Сезнең әле гөнаһка каршы сугышта кан түккәнче карш-
ылык күрсәткәнегез булмады. [5] Ата кеше үз балаларына эндәшкән
сыман, Аллаһы сезгә:

«Улым Минем, Раббың шулай тәрбияләгәнгә гамьсез карама,
гаебеңне күрсәткәндә күңелеңне төшермә.
6 Раббы Үзе яраткан кешеләрне үгетләп төзәтә
вә улы дип кабул иткән һәр кешене тәрбияли», —
дигән дәртләндерү сүзләрен оныткансыз. [7] Сезнең газап чигүе-
гез тәрбияләнүгә алып килә. Бу — Аллаһы сезгә Үз балалары итеп карый дигән сүз. Атасы тәрбия бирмәгән бала бармыни?
[8] Әгәр дә сез һәркем үтәргә тиешле тәрбияне үтмисез икән, ди-
мәк, сез чын угыллар түгел, ә җилдән туган балалар. [9] Моннан
тыш, безнең һәммәбезнең дә җирдә безне тәрбияләгән аталары булды һәм без аларны ихтирам итә идек. Ә рухларыбызның Атасына без тагын да ныграк буйсынырга тиеш түгелмени? Аңа
колак салу безгә яшәү бирә бит! [10] Безнең аталарыбыз безне
беркадәр вакыт буена, үзләре иң яхшы дип тапкан, ләкин бик үк камил булмаган чаралар белән тәрбияләлиләр, ләкин Аллаһы безне, Аның изгелегенә катнаша алсыннар дип, үз иминлегебез
хакына тәрбияли. [11] Безне тәрбияләгәндә бу гамәл шатлык түгел,
ә авырту китерүче чара булып күренә. Ләкин соңрак тәрбия узган кешеләргә ул уңыш китерә: имин вә Аллаһыга мәгъкуль тормыш бирә.

[12] Шуңа күрә хәлсез кулларыгызны, калтыранган көчсез тез-
ләрегезне ныгытыгыз. [13] Аксаучы аяк тәмам имгәнмәсен, кире-
сенчә, сәламәт булсын өчен, туры юлдан йөрегез.

### *Какшамас патшалык*

[14] Барлык кеше белән тынычлыкта яшәргә һәм изге булырга омтылыгыз, чөнки изге булып яшәмәсә, беркем дә Аллаһыны
күрмәячәк. [15] Карагыз аны, беркем дә Аллаһының мәрхәмәтен-
нән мәхрүм калмасын; ачы тамырлы үлән үсеп чыгып, беркемгә дә бәла-каза китерерлек булмасын һәм күпләрне нәҗесләмәсен.
[16] Карагыз аны, беркем дә женси йөгәнсезлеккә бирелмәсен,
бер ашарлык аш өчен, олы угыл буларак бирелергә тиешле хокукларны саткан Эсау кебек, әхлаксыз тормыш белән яшәмәсен.

17 Белгәнегезчә, соңыннан ул фатиха алырга теләгән, ләкин кире кагылган. Бу хакта күз яшьләре белән сораса да, булган хәлне берничек тә үзгәртә алмаган.

18 Сез кагылырга мөмкин булган, дөрләп янган Синай тавына – караңгыга да, давылга да килмәдегез. 19 Сез быргы тавышына да, тыңлаучылар бүтән ишетергә теләмәгән сүзләр сөйләүче тавышка да килмәдегез. Ул сүзләрне ишеткән кешеләр боларны бүтән сөйләмәүне үтенгәннәр, 20 чөнки алар: «Хәтта бу тауга хайван кагылса да, аны ташлар атып үтерергә тиешле», – дигән боеру сүзләренә түзә алмаганнар. 21 Бу күренеш шундый куркыныч булган, хәтта Муса да: «Мин куркуымнан тетрәнәм», – дигән. 22 Юк! Сез Сион тавына, күктәге Иерусалимга – тере Аллаһы шәһәренә килдегез! Сез шатлыклы тантанага җыелган меңләгән фәрештәләр янына килдегез. 23 Сез исемнәре күккә язып куелган беренче туган балалар җыенына килдегез. Сез Аллаһыга, бар кешене Хөкем кылучы янына, камилләштерелгән тәкъва кешеләрнең рухлары янына килдегез. 24 Сез яңа килешүне Урнаштыручы булган Гайсә янына вә Аның Һабил канынннан әйбәтрәк сөйләүче сибелгән каны* янына килдегез.

25 Карагыз аны, үзегезгә сөйләүче Аллаһыны кире какмагыз. Җирдә сөйләгән чагында кешеләр Аны тыңламаган өчен җәзасыз калмаган икән, күктән торып кисәткәндә Аңардан баш тартсак, без тагын да зуррак җәзага дучар булачакбыз. 26 Ул чагында Аның тавышы җирне дер селкетте, ләкин Ул хәзер: «Мин җирне тагын бер тапкыр тетрәтәм, һәм җирне генә түгел, күкне дә», – дип вәгъдә итә. 27 «Тагын бер тапкыр» дигән сүзләр шуны белдерә: тотрыклы нәрсәләр генә калсын өчен, һәр тотрыксыз, ягъни, бар ителгән нәрсә юкка чыгарылачак. 28 Безгә какшамас патшалык бирелә, шуңа күрә, әйдәгез, рәхмәтле булыйк һәм Аллаһыга мәгъкуль рәвештә тирән ихтирам белән, куркынып Аңарга табыныйк, 29 чөнки безнең Аллаһыбыз – йота торган ут.

*Аллаһыга ошаган тормыш*

**13** 1 Бер-берегезне туганнар кебек яратудан туктамагыз. 2 Кунакчыллык күрсәтергә онытмагыз; болай эшләп, кайберәүләр, үзләре дә белмичә, фәрештәләрне кунак иткәннәр. 3 Төрмәдәге кешеләрне, алар белән үзегез дә тоткынлыкта булган кебек, исегездә тотыгыз. Газап чигүче кешеләрне, үзегез дә алар белән газап чиккән сыман, исегездә тотыгыз.

---

* 12:24 *Сибелгән кан* – Тәүраттан билгеле булганча, рухани, пакьләндерү өчен, кешеләрнең гөнаһлары өчен чалынган корбанның канын килешү сандыгы өстенә сипкән.

4 Никахны һәрьяклап югары бәяләгез, никахыгыз чиста булырга тиеш, чөнки иренә яисә хатынына хыянәт иткән вә бозык тормыш белән яшәгән кешене Аллаһы хөкем итәчәк. 5 Байлык яратмагыз, булганына канәгать булып яшәгез, чөнки Аллаһы: «Сезне беркайчан да калдырмам вә беркайчан да ташламам», – дигән. 6 Шуңа күрә кыю булыйк, чөнки без:

«Аллаһы – минем Ярдәмчем,
мин курыкмам.
Кеше миңа нәрсә эшли алсын?» –

дип әйтә алабыз.

*Аллаһыга яраклы корбаннар*

7 Сезгә Аллаһы сүзен җиткергән җитәкчеләрегезне исегездә тотыгыз, аларның гомер нәтиҗәләре турында уйлап, иманнарын үрнәк итеп, аларга иярегез. 8 Гайсә Мәсих кичә дә, бүген дә һәм мәңгегә шундый ук.

9 Һәртөрле чит-ят тәгълиматлар сезне туры юлдан читкә алып китмәсен. Йөрәкләрегезне ризык ашау турындагы кагыйдәләрне тоту белән түгел, ә Аллаһының мәрхәмәте белән ныгытырга кирәк. Мондый кагыйдәләр аларны үтәүчеләргә файда китермәгән. 10 Безнең корбан китерү урыныбыз бар, чатырдагы хезмәтчеләрнең андагы корбанны ашарга хакы юк. 11 Баш рухани хайван канын Иң изге урынга гөнаһлар бәрабәренә корбан китерергә алып керә, ә хайван түшкәләре исраиллеләрнең вакытлы торак урынының тышында яндырыла. 12 Шуның аркасында Гайсә дә, халыкны Үзенең каны белән изгеләндерер өчен, шәһәр капкасы тышында газап чикте. 13 Шуңа күрә, әйдәгез, без, Ул кичергән хурлыкны кичереп, вакытлы торак урынының тышкы ягына Аның янына чыгыйк. 14 Чөнки бирдә, җирдә, безнең даими тора торган урыныбыз юк, ләкин без килергә тиешле шәһәрне көтәбез. 15 Шуңа күрә Гайсә аркылы Аллаһыга даими рәвештә данлау корбаны китерик, Аның исемен телебез белән мактыйк. 16 Кешеләргә игелек эшләүне, үзегездә булганны бер-берегез белән бүлешүне онытмагыз – бу Аллаһы ярата торган корбан.

17 Җитәкчеләрегезне тыңлагыз вә аларга буйсыныгыз. Алар, хисап бирергә тиешле кешеләр буларак, сезнең җаннарыгыз турында кайгырталар. Әгәр аларны тыңлыйсыз икән, алар шатланып эшләрләр, тыңламасагыз, кайгырып эшләрләр, һәм бу сезнең өчен файдалы булмас.

18 Безнең өчен дога кылыгыз. Без намусыбызның чиста булуына ышанабыз, чөнки бар нәрсәдә дөрес гамәл кылырга телибез. 19 Мин сездән, Аллаһы сине безнең янга тизрәк кайтарсын иде, дип дога кылуыгызны аеруча үтенәм.

*Дога вә сәламләү сүзләре*

20 Мәңгелек килешүне раслаучы кан аркасында Раббыбыз
Гайсәне, сарыкларның бөек Көтүчесен, тынычлык Аллаһысы
үледән терелтте. 21 Үзенең ихтыярын үтәр өчен Аллаһы сезне
һәр яхшы нәрсә белән тәэмин итсен, һәм Гайсә Мәсих аша
безгә Үзенә мәгъкуль булганны эшләсен. Мәңгелек дан Мә-
сихкә. Амин.

22 Имандашларым, сездән бу хатымда биргән киңәшләремә
түземлелек белән колак салуыгызны үтенеп сорыйм, чөнки мин
бит кыска гына итеп яздым. 23 Безнең туганыбыз Тимутенең
азат ителгәнен сезгә белдерергә телим. Әгәр дә ул тиздән ми-
нем янга килсә, мин аны үзем белән бергә алып, сезне күрергә
килермен.

24 Барлык башлыкларыгызга вә Аллаһының барлык изгелә-
ренә сәлам. Италиядән булган имандашларыбыз сезгә сәлам
юллый. 25 Барыгызга да Аллаһының мәрхәмәте булсын.

# ЯГЪКУБТАН ХАТ

1 [1]Дөнья буйлап таралган унике кабиләгә* Аллаһы һәм Раббы
Гайсә Мәсих колы Ягъкубтан сәлам!

*Сынаулар һәм иман*

[2-3]Имандашларым, иманыгыз сыналуының сабырлык тудыруын белгәнгә күрә, төрле сынауларга эләгүне үзегезгә зур шатлык дип санагыз.
[4]Сез камил, бөтен булсын өчен, сездә кимчелек булмасын өчен сабырлык үз эшен эшләп бетерергә тиеш.
[5]Әгәр кайсыгызның да булса зирәклеге булмаса, ул вакытта аны Аллаһыдан сорасын, һәм ул аңа биреләчәк, чөнки Аллаһы юмарт һәм, берсен дә шелтәләмичә, барысына да бирә.
[6]Ләкин сез иман белән, инанып, һич тә шикләнмичә сорарга тиеш, чөнки шикләнүчеләр, җил куып йөрткән, бер яктан икенче якка бәрелә торган диңгез дулкынына охшаганнар.
[7]Андый кеше Раббыдан нәрсәдер алырмын дип уйламасын.
[8]Мондый кеше – икеләнүчән, үзенең кылган гамәлләрендә нык тормаучан.

[9]Мохтаҗ мәсихче үзенең күтәрелүе белән горурлансын.
[10]Бай исә үзенең түбән төшерелүе белән горурлансын, чөнки ул кыргый чәчәк шикелле юкка чыгачак.
[11]Кояш чыга, көйдергеч эсселек башлана, эсседән үлән сула, аның чәчәге коела һәм матурлыгы югала. Байлар да шулай ук үзләренең эшләрен эшләгәндә юкка чыгачак.
[12]Сынауларга түзгән кеше бәхетле: алар аша узып, ул Аллаһы Үзен сөючеләргә вәгъдә иткән тормыш таҗын алачак.
[13]Коткыга бирелгәннәрнең берсе дә: «Бу коткы Аллаһы тарафыннан җибәрелгән», – дип әйтергә тиеш түгел, чөнки явызлык Аллаһыны вәсвәсәләндерә алмый һәм Аллаһы Үзе беркемне дә вәсвәсәләндерми.
[14]Ләкин һәркемне дә үзенең үк кызыктырып алып кереп китүче һәм аны тозакка эләктерүче

---

* [1:1] *Унике кабилә* – дөнья буйлап таралган яһүд мәсихчеләре, яисә дөньядагы барлык мәсихчеләр.

хайвани теләкләре вәсвәсәгә кертә. 15 Шуннан соң, хайвани теләк, яралып, гөнаһны, ә гөнаһ, ныгыгач, үлемне тудыра. 16 Үзегезгә алданырга ирек бирмәгез, сөекле имандашларым. 17 Һәртөрле игелекле һәм камил бүләк югарыдан, яктылыклар Атасыннан килә. Ул һәрвакыт үзгәрешсез һәм һичкайчан, борылып, караңгылык тудырмый*. 18 Яратканнары арасында без беренче җимеш булсын өчен, Ул безне, хакыйкать сүзе аша, Үз ихтыяры белән барлыкка китерде.

*Тыңлагыз һәм үтәгез*

19 Сөекле имандашларым, шуңа игътибар итегез: һәркем тыңларга өлгер булырга, ә сөйләргә һәм ачуланырга ашыкмаска тиеш, 20 чөнки кеше ачуы Аллаһы теләгән тәкъва тормышка алып килми. 21 Шулай итеп, бөтен әхлакый шакшылыктан һәм башка төрле яманлыктан ваз кичегез, йөрәкләрегез туфрагына утыртылган Аллаһы сүзен тыйнаклык белән кабул итегез, ул сүз сезнең җаннарыгызны коткара ала. 22 Сүз тыңлап кына үз-үзегезне алдамагыз, ә аны үтәгез. 23 Кем дә булса Аллаһы сүзенә колак сала, ләкин аны үтәми икән, ул үзенә табигать тарафыннан бирелгән йөзен көзгедән караучыга охшап кала: 24 үзенә җентекләп карый да, читкәрәк китү белән, йөзенең нинди икәнен шундук оныта. 25 Кем дә кем Аллаһының камил булган ирекле лек канунын игътибар белән тикшерә һәм, шулай дәвам итеп, ишеткәнен онытмыйча, аны башкара икән, ул үзенең эшләрендә бәхетле булачак. 26 Әгәр кем дә булса үзен Аллаһыга табынучы дип саный, ләкин телен тыймый икән, бу вакытта ул үзен алдый гына, һәм аның диндарлыгы бернигә тормый. 27 Аллаһы Ата Үз каршында саф, тапсыз санаган табыну – ятимнәрнең, тол хатыннарның кайгылары белән уртаклашып, алар турында кайгырту һәм үзеңне, нәҗесләмичә**, фани дөньядан саклау.

*Һәркемгә тигез карагыз*

**2** 1 Имандашларым минем, иң бөек Раббыбыз Гайсә Мәсихкә иман итүчеләр буларак, һәркемгә тигез карагыз. 2 Әйтик, җыелышыгызга бай киенгән, алтын балдаклы кеше һәм шулай ук тузган кием кигән ярлы кеше дә килә, ди. 3 Бай киенгән кешегә аерым игътибар биреп: «Менә монда, бу яхшы

* 1:17 *Борылып, караңгылык тудырмый* – Монда Аллаһы Тәгаләнең үзгәрешсез булуы, күк җисемнәренең торышларын үзгәртеп, караңгылык булдырулары һәм башка күренешкә керүләре белән капма-каршы куела.

** 1:27 *Нәҗесләү* – дини мәгънәдә пычрату дигән сүз.

урынга утырыгыз», – дип әйтсәгез, ярлыга исә: «Әнә тегендә
бас» яисә «Аягым очына утыр», – дисәгез, [4]үз арагызда бер-бере-
гезне аерып карыйсыз һәм, начар фикерләргә таянып, хөкем
итүче хаким кебек буласыз түгелме? [5]Тыңлагыз, сөекле иман-
дашларым! Аллаһы иманга бай булырга һәм Үзен яратучыларга
Үзе вәгъдә иткән Патшалыкны кабул итәргә дөнья күзлегеннән
караганда ярлы булып күренгәннәрне сайлады түгелме? [6]Ә сез
исә ярлыларны мәсхәрәлисез! Сезне җәберләүчеләр һәм хаким-
нәр алдына сөйрәүчеләр – байлар түгелмени инде? [7]Мәсихнең
яхшы исемен яманлыйлар түгелме алар? Ә Аллаһы сезне бу
исем белән атады. [8]Әгәр сез чыннан да Изге язмада әйтелгән:
«Якыныңны үзеңне яраткан кебек ярат» дигән Аллаһы Патша-
лыгы канунын үтисез икән, дөрес эшлисез. [9]Ләкин әгәр һәр-
кемгә дә тигез карамыйсыз икән, сез гөнаһ кыласыз һәм канун
сезне канун бозучылар дип атап хөкем итә. [10]Канунны бөтен
килеш тотучы аның бер генә таләбен үтәмәсә дә, тулысынча
канунны бозуда гаепле. [11]Чөнки «Зина кылма» дип әйткән
Аллаһы шулай ук «Үтермә» дип тә әйткән. Һәм шуңа күрә дә,
әгәр зина кылмасаң, ләкин үтерсәң, син канунны бозучы була-
сың. [12]Ирекле лек кануны буенча хөкем ителәсе кеше буларак
сөйлә һәм гамәл кыл. [13]Чөнки рәхимлелек күрсәтмәгәннәргә
хөкем рәхимсез булачак. Рәхимлелек исә хөкемнән өстен тора!

*Иман һәм эшләр*

[14]Әгәр кем дә булса: «Мин иман итәм», – дип әйтә, ә эштә
күрсәтми икән, имандашларым, моннан ни файда? Андый иман
аны коткара аламы? [15]Әгәр имандаш ир-ат яки хатын-кыз ки-
емгә яки ризыкка мохтаҗ булып, сезнең берәрегез: [16]«Иминлек
белән китегез. Җылыныгыз һәм яхшы итеп тукланыгыз!» – дип
әйтсә, әмма аларга тормышта кирәк булган нәрсәләрне бирмә-
сә, бу сүзләрдән ни файда? [17]Иман белән дә шулай ук. Әгәр дә
иман, үзенә лаеклы гамәлләр белән бергә булмыйча, үзе генә
булса, ул үле. [18]Ләкин кемдер: «Синең иман, ә минем эшләр
бар!» – дип әйтер. Син миңа үзеңнең иманыңны гамәлләрдән
башка күрсәт. Ә мин сиңа үз иманымны кылган гамәлләрем бе-
лән күрсәтермен! [19]Син Аллаһының бер булуына ышанасың.
Яхшы! Хәтта җеннәр дә моңа ышана һәм калтырап тора. [20]Әй,
син, төпсез кеше! Гамәлсез иманның файдасыз булуына дәлил-
ләр телисеңме? [21]Әллә атабыз Ибраһим үзенең улы Исхакны,
корбан китерү урынына корбан рәвешендә тәкъдим итеп,
эш-гамәлләре белән Аллаһы тарафыннан акланмаганмы? [22]Кү-
рәсең ки, аның иманы кылган гамәлләре белән бергә барган
һәм шул гамәлләре аркылы иманы камил булган. [23]Изге язмада

язылган: «Ибраһим Аллаһыга ышанды, һәм моның белән Аллаһы тарафыннан хак саналды», – дигән сүзләр тормышка ашты. Шулай итеп, ул «Аллаһы дусты» дип аталды. 24 Кешенең Аллаһы тарафыннан иман белән генә түгел, бәлки кылган гамәлләре белән аклануын күрәсез. 25 Хәбәрчеләрне сыендырып һәм аларга башка юлдан качарга ярдәм итеп, уйнашчы хатын Рәхәб шулай ук кылган гамәленә карап Аллаһы тарафыннан акланды. 26 Шулай итеп, җансыз тән үле булган кебек, кылган гамәлдән башка иман да үле.

*Игътибар белән сөйләгез*

**3** 1 Имандашларым, арагыздан бары кайберләрегез генә укытучы булсын. Сез беләсез: укытучы буларак, башкаларга караганда без ныграк хөкем ителербез. 2 Чөнки без барыбыз да төрлечә абынабыз. Сүздә гөнаһ кылмый торган кеше – камил, үзенең бөтен тәнен тыя белә торган кеше. 3 Тыңласыннар өчен, без атларның авызына авызлык кидерәбез һәм, шулай итеп, аларның гәүдәләре белән идарә итә алабыз. 4 Әйдәгез, корабларны мисал итеп китерик. Зур булсалар да һәм аларны көчле җилләр куып йөртсә дә, алар бик кечкенә кораб койрыгы ярдәмендә койрыкчы теләгән якка идарә ителәләр. 5 Тел дә шулай ук, гәүдәнең кечкенә генә әгъзасы булса да, бөек нәрсәләр белән мактана ала. Уйла: нинди кечкенә очкын зур урманны яндырып җибәрергә мөмкин. 6 Тел дә – ут. Тәнебезнең әгъзалары арасында ул – яманлык дөньясы. Ул бөтен тәнебезне нәҗесли һәм тормышыбыз агышында янгын чыгара. Телне исә җәһәннәм уты кабызып җибәрә. 7 Һәртөрле хайваннарны, кошларны, сөйрәлүчеләрне һәм диңгез хайваннарын кеше үзенә буйсындыра ала һәм буйсындырды да. 8 Ләкин беркем дә телне буйсындыра алмый: ул тыелгысыз, усал һәм үтергеч агулар белән тулы. 9 Телебез белән Раббы Атабызны данлыйбыз, шул ук тел белән Аллаһыга охшашлы итеп барлыкка китерелгән кешеләрне каргыйбыз. 10 Бер үк авыздан данлаулар да, каргышлар да чыга. Имандашларым, алай булырга тиеш түгел. 11 Бер чишмәдән төче һәм тозлы су ага аламы әллә? 12 Имандашларым, инҗир агачы зәйтүн, ә йөзем чыбыгы инҗир җимеше бирә аламыни? Тозлы чишмә дә төче су бирә алмый.

*Чын зирәклек*

13 Сезнең арагызда кайсыгыз зирәк һәм акыллы, ул үзенең шундый икәнлеген игелекле тормышы белән, зирәк тыйнаклык тудырган гамәлләре белән күрсәтсен. 14 Ләкин йөрәкләрегездә ачы көнчелек һәм үз-үзеңне генә ярату яшәсә, мактанмагыз,

һәм сез хакыйкатькә каршы ялганламассыз. [15] Андый зирәклек
югарыдан түгел, ул дөньяныкы; рухи түгел, ул җеннәрдән килә.
[16] Чөнки көнчелек һәм үз-үзеңне генә ярату булган урында тәр-
типсезлек тә, һәртөрле явыз эшләр дә була. [17] Ә югарыдан ки-
лүче зирәклек, беренчедән, саф, шулай ук тыныч, башкаларга
игътибарлы, аек акыл белән тыңлаучан, шәфкатьлелек һәм иге-
лекле җимешләр белән тулы, кешеләрне аермый торган һәм
эчкерсез. [18] Тәкъвалык орлыкларын тынычлыкта чәчәләр һәм ул
орлыклар тынычлык булдыручыларга уңыш китерә.

*Дөнья белән дус кеше – Аллаһы дошманы*

**4** [1] Арагыздагы низаг һәм талашлар кайдан килә? Һәрвакыт
сездә көрәшеп яшәүче көчле теләкләрдән килеп чыкмый-
мыни алар? [2] Сез нәрсәдер телисез, ләкин ала алмыйсыз,
үтерәсез, бик каты телисез, ләкин теләгәнегезгә ирешә алмый-
сыз. Сез талашасыз һәм көрәшәсез. Аллаһыдан сорамаганга
күрә, теләгәнегезне ала алмыйсыз. [3] Сорап та ала алмыйсыз,
чөнки, алган нәрсәләрне, хозурлану өчен кулланырга теләп,
дөрес булмаган ниятләр белән сорыйсыз. [4] Хыянәтчеләр, сез
дөньяны яратуның Аллаһы белән дошман булуга бәрабәр икә-
нен белмисезме әллә? Дөнья белән дус булырга теләүче кеше
Аллаһыга дошман була. [5] Яки Изге язмада: «Аллаһы безгә сал-
ган рухны көнләп, бик нык ашкынып тели*», – дип юкка гына
әйтелгәнме әллә? [6] Ләкин Аллаһының бирә торган мәрхәмәте
тагын да зуррак. Менә шуңа күрә Изге язмада:
«Аллаһы тәкәбберләргә каршы тора,
Ә басынкыларга мәрхәмәтен бирә», –
дип әйтелгән. [7] Шуңа күрә үзегезне Аллаһыга буйсындырыгыз.
Иблискә каршылык күрсәтегез, һәм ул сездән качар. [8] Аллаһыга
якын килегез, һәм Ул да сезгә якынаер. Гөнаһлылар, куллары-
гызны чистартыгыз, икеләнүчеләр, йөрәкләрегезне сафланды-
рыгыз! [9] Хәсрәтләнегез, ачыныгыз һәм ыңгырашыгыз! Сезнең
көлүегез кайгыга, ә шатлыгыгыз хәсрәткә әйләнсен. [10] Раббы
алдында баш иегез, һәм Ул сезне югары күтәрер. [11] Туганнар,
бер-берегезне яманламагыз. Үзенең имандашын яманлаучы
һәм хөкем итүче канунны да яманлый һәм хөкем итә. Әгәр син
канунны хөкем итәсең икән, димәк, син – канунны үтәүче
түгел, ә аны хөкем итүче хаким. [12] Бары тик бер генә канун Чы-
гаручы һәм Хаким бар. Ул гына коткара һәм һәлак итә ала.
Шулай булгач, башкаларны хөкем итәргә кем соң син?

---

* 4:5 *Аллаһы безгә салган рухны көнләп, бик нык ашкынып тели* – Бу сүзләрне «Аллаһы безгә салган рухта көчле теләкләр бар» дип тә аңларга мөмкин.

*Масаючанлыкны кисәтү*

13 «Бүген яки иртәгә без шундый-шундый шәһәргә китәрбез
һәм анда ел буе торырбыз, сату итәрбез һәм зур табыш алыр-
быз», – дип сөйләүчеләр, хәзер сез тыңлагыз. 14 Сез хәтта ир-
тәгә тормышыгызда нәрсә буласын да белмисез. Сез аз гына
күренеп алучы, ә соңыннан юкка чыгучы томан кебек. 15 Аның
урынына сез: «Әгәр Раббы теләсә, без исән булырбыз һәм мо-
ны яки тегене эшләрбез», – дип әйтергә тиеш. 16 Ләкин сез,
чынлыкта, тәкәбберләнәсез һәм масаясыз гына. Һәр масаю-
чанлык – начар! 17 Шулай итеп, кем дә кем дөресен эшләргә
кирәклекне белеп тә, алай эшләми икән, бу вакытта гөнаһ
кылган була.

*Байларга кисәтү*

5 1 Байлар, сез тыңлагыз! Сезгә якынлашучы бәхетсезлекләр
өчен ыңгырашып елагыз. 2 Сезнең байлыгыгыз череп бетте,
киемнәрегезне көя ашап бетерде. 3 Алтын-көмешләрегез
тутыкты! Бу тутык сезгә каршы дәлил булачак һәм тәнегезне ут
шикелле ашаячак. Байлыкны шушы соңгы көннәрдә туплады-
гыз. 4 Кырларыгызда эшләүчеләр сезнең өчен уңыш җыйды, сез
исә аларга түләмәдегез. Тыңлагыз – хакы түләнмәгән хезмәт
сезгә каршы кычкыра. Уракчыларның ачы тавышлары Чиксез
Кодрәтле Раббының колакларына барып ишетелде. 5 Җирдә
яшәгәндә сез күңелегезне күрдегез. Сезне чалу өчен билгеләнгән
көндә үзегезне симерттегез. 6 Гаепсезне хөкем иттегез һәм
үтердегез; ул сезгә каршы килми.

*Сабырлык һәм дога кылу*

7 Имандашлар, Раббының килүенә кадәр сабыр булыгыз.
Игенченең үз җиреннән кыйммәтле уңыш күтеп алуын исегез-
дә тотыгыз. Ул сабырлык белән көзге һәм язгы яңгырлар көтә.
8 Сез дә шулай ук сабыр булыгыз. Күңелегезне ныгытыгыз,
чөнки Раббы киләчәк көн якын. 9 Имандашлар, бер-берегезгә
каршы әләкләмәгез, алай эшләсәгез, хөкем ителерсез. Хаким
инде ишек янында тора. 10 Имандашлар, Раббы исеменнән сөй-
ләгән пәйгамбәрләрнең газаплануларыннан һәм түземлелекләреннән
үрнәк алыгыз. 11 Түзеп нык торганнарны без бәхетле
дип атыйбыз. Сез Әюбнең сабырлыгы турында ишеттегез һәм
Раббының ахырда аның белән нәрсә эшләгәнлеген күрдегез;
Раббы шәфкатьлелек белән тулы һәм рәхимле бит. 12 Иң элек,
имандашларым, ант итмәгез; күк-җир белән дә, я башка нәрсә
белән дә ант итмәгез. Аллаһы хөкеменә дучар булмас өчен,

сезнең «Әйе» – «Әйе» булсын, «Юк» – «Юк» булсын. 13 Сезнең
берәрегез газапка дучар була икән, дога кылсын. Кайсыгыз
бәхетле, мактау җырлары җырласын. 14 Кайсыгыз авыру булса,
шул иман итүчеләр бердәмлеге өлкәннәрен чакырсын һәм
алар, Раббы исеме белән, аңа зәйтүн мае сөртеп, аның өчен
дога кылсыннар. 15 Иман белән кылынган дога авыруны сә-
ламәтләндерер, Раббы аны савыктырыр. Әгәр ул гөнаһлар
кылган булса, Аллаһы аны гафу итәр. 16 Шулай итеп, савыгу
өчен, бер-берегез алдында гөнаһларыгызны икърар итегез һәм
бер-берегез өчен дога кылыгыз. Тәкъва кеше догасы зур куәткә
һәм көчле тәэсиргә ия. 17 Ильяс безнең кебек үк кеше булган.
Яңгыр яумасын өчен, ул тырышлык белән дога кылган һәм ул
җирдә өч ел ярым яңгыр яумаган. 18 Соңыннан ул тагын дога
кылган, һәм күк яңгыр җибәргән, җир уңыш китергән.

19 Имандашларым, әгәр сезнең берәрегез хакыйкатьтән чит-
ләшеп, икенчегез аны хакыйкать кочагына кире кайтарса, 20 ул
вакытта белегез: гөнаһлыны ялган юлыннан кире кайтаручы
кеше бу гөнаһлының җанын үлемнән коткарыр һәм күп гөнаһ-
ларның кичерелүен тәэмин итәр.

# ПЕТЕРДӘН БЕРЕНЧЕ ХАТ

1 [1] Гайсә Мәсихнең рәсүле Петердән Понтта, Гәләтиядә,
Кәппәдүкиядә, Асия өлкәсендә һәм Битуниядә килмешәк
булып таралып яшәүче сайланганнарга сәлам! [2] Аллаһы Ата-
ның алдан белеп торуы буенча, Аның Рухының сезне изге итүе
аша Гайсә Мәсихкә итагатьле булу өчен һәм өстегезгә Аның
каны сибелү юлы белән чистарыну өчен сайландыгыз сез.

Сезгә мәрхәмәт яусын һәм иминлегегез артсын!

*Яңа өмет*

[3] Раббыбыз Гайсә Мәсихнең Аллаһысына һәм Атасына дан!
Ул Үзенең бөек мәрхәмәте белән Гайсә Мәсихне үледән терел-
тү аша безне яңадан тудырды һәм безгә тере өмет бирде. [4] Ул
моны күкләрдә сезнең өчен сакланган черемәс, пакь, шиңмәс
мирасыгыз булсын өчен эшләде. [5] Соңгы вакытта ачылырга
әзер торучы котылу өчен Аллаһы сезне иман итүегез аша Үзе-
нең кодрәте белән саклап тора. [6] Шуңа күрә хәзер кыска ва-
кытлы төрле сынаулардан газап чигәргә тиеш булсагыз да, ко-
тылачагыгызга куаныгыз. [7] Шулай сыналган иманыгыз, Гайсә
Мәсих килгәндә, сезгә мактау, хөрмәт һәм дан китерер. Алтын
ут белән сынала, ләкин барыбер юкка чыга. Ә сезнең иманы-
гыз алтыннан да кадерлерәк бит. [8-9] Гайсә Мәсихне күрмәгән
килеш яратасыз, хәзер күрмәсәгез дә, Аңа иман итәсез һәм
иманыгызның максатына, җаныгызның котылуына ирешеп,
әйтеп бетергесез һәм ифрат зур куаныч белән шатланасыз.
[10] Сезгә биреләчәк мәрхәмәт турында алдан күреп әйткән
пәйгамбәрләр бу котылу хакында уйландылар һәм җентекләп
тикшерделәр. [11] Пәйгамбәрләр, алардагы Мәсих Рухы, алдан
күреп, Мәсихнең газап чигәчәге һәм соңыннан киләчәк дан
турында әйткән сүзләренең нинди хәлләргә һәм кайсы вакытка
күрсәтүен тикшерделәр. [12] Күктән җибәрелгән Изге Рух аша
Яхшы хәбәр таратучылар, хәзер сезгә игълан иткәннәрне
пәйгамбәрләр сөйләгәндә, аларның хезмәте үз файдалары өчен

түгел, бәлки сезнең файдага була, дип Аллаһы аларга ачыклап бирде. Хәтта фәрештәләр дә игълан ителгәннәр турында аңларга телиләр.

*Изге булыгыз*

[13] Шуңа күрә, акылыгызны җигеп хәрәкәт итәргә әзер торыгыз, аек акыллы булыгыз, Гайсә Мәсих килгәндә сезгә биреләчәк мәрхәмәткә тулысынча өмет баглагыз. [14] Сүз тыңлаучан
балалар сыман булыгыз, Яхшы хәбәр турында белмәгән вакытыгыздагы элекке тән нәфесләренә иярмәгез. [15] Киресенчә,
сезне чакырган Аллаһы изге булган кебек, сез дә бар гамәлләрегездә изге булыгыз. [16] Изге язмада: «Изге булыгыз, чөнки
Мин изге», — дип язылган бит. [17] Һәркемне эшенә карап, тигез
хөкем Итүчене Ата дип атыйсыз икән, бу дөньяда гомерегезне
курку катыш тирән хөрмәт белән үткәрегез. [18] Чөнки сез беләсез:
ата-бабаларыгыздан бирелгән мәгънәсез тормыштан алтын-көмеш кебек фани нәрсәләр белән түгел, [19] бәлки гаепсез һәм пакь
бәрән кебек булган Мәсихнең кадерле каны белән йолындыгыз.
[20] Мәсих дөнья яратылганга кадәр үк алдан сайланган иде, әмма сезнең өчен соңгы вакытта гына ачылды. [21] Мәсихне үледән
терелтеп, Аңа дан биргән Аллаһыга сез Мәсих аша иман итәсез. Шулай итеп, иманыгыз һәм өметегез Аллаһыда була. [22] Хакыйкатькә итагать итеп, җаннарыгызны пакьләдегез һәм хәзер
имандашларыгызга риясыз мәхәббәт күрсәтәсез. Шулай булгач,
бер-берегезне ихлас күңелдән яратыгыз! [23] Фани орлыктан түгел,
бәлки фани булмаган орлыктан, Аллаһының тере һәм мәңгелек
сүзе аша, яңадан тудыгыз бит. [24] Изге язмада язылганча:

«Һәр адәм үлән кебек,
Кешенең һәртөрле даны — үлән чәчәге кебек;
Үлән кибә,
Аның чәчәге дә шиңә;
[25] Әмма Раббы сүзе мәңге тора».

Ул — сезгә игълан ителгән сүз.

*Тере таш һәм изге халык*

**2** [1] Шулай итеп, һәртөрле явызлыкны һәм мәкерлекне,
икейөзлелекне һәм көнчелекне, гайбәтне читкә ташлап,
[2] яңа туган сабыйлар кебек, пакь рухи сөт* эчәргә омтылыгыз, шуның белән үсеп, котылуга ирешерсез; [3] чөнки сез
Раббының игелеген татыдыгыз. [4] Аңа — кешеләр тарафыннан

---

* 2:2 *Пакь рухи сөт* — иман итүчеләрнең иманын үстерү өчен нәсыйхәт, ягъни Раббы сүзе.

кире кагылган, әмма Аллаһы тарафыннан сайланган кыйммәт-
ле тере Ташка килегез, 5 һәм үзегез дә тере ташлар кебек рухи
йорт булып төзелегез. Шулай итеп, Гайсә Мәсих аша Аллаһыга
мәгъкуль дөньяви булмаган корбаннар китерүче изге руханилар
булырсыз. 6 Чөнки Изге язмада болай дип әйтелгән:

«Менә, Мин кыйммәтле таш сайладым,
Аны, иң мөһим почмак ташы итеп, Сионда* куйдым.
Аңа иман итүче һич оятка калмаячак».

7 Шулай итеп, Ул сезнең өчен, иман итүчеләр өчен, кыйм-
мәтле Таш, ә ышанмаучылар өчен

«Төзүчеләр яраксыз дип кире каккан таш
Иң мөһим почмак ташы булды».

8 «Ул – кешеләрне абындырачак таш,
Алар абынып егылачак кыя».

Аллаһы сүзенә итагать итмәгәнгә, ышанмаучылар ташка абы-
налар, бу алар өчен билгеләнгән дә бит. 9 Әмма сез – караңгы-
лыктан Үзенең гаҗәеп яктылыгына Чакыручының шөһрәтле
эшләрен игълан итү өчен сайланган нәсел, патша-руханилар**,
изге халык, Аллаһының Үз халкы. 10 Кайчандыр сез хәтта халык
та түгел идегез, ә хәзер Аллаһы халкы булдыгыз. Кайчандыр
сезгә шәфкать күрсәтелмәгән иде, хәзер исә шәфкатьне кабул
иттегез.

*Аллаһының коллары кебек яшәгез*

11 Сөеклеләрем! Сездән, килмешәкләрдән һәм мосафирлардан
үтенәм: җанга каршы көрәшүче гөнаһлы теләкләрдән читлә-
шегез; 12 мәҗүсиләр сезне явызлык кылучылар дип яманласа-
лар да, игелекле эшләрегезне күреп, Аллаһы яныбызга киләчәк
көндә Аны данласыннар өчен, алар арасында үзегезне әдәпле
тотыгыз. 13 Раббы хакы өчен кешеләрдә урнаштырылган тәр-
типкә, яисә барсыннан өстен булган патшага, 14 яисә җинаять-
челәрне җәзаларга, игелек кылучыларга әҗерен бирергә аның
тарафыннан куелган идарәчеләргә күндәм булыгыз. 15 Чөнки
Аллаһының ихтыяры шундый: игелек кылуыгыз белән акылсыз
һәм надан кешеләрнең авызын томалагыз. 16 Ирекле кешеләр
кебек яшәгез, әмма ирегегезне явызлыкны яшерү өчен фай-
даланмагыз; Аллаһының коллары кебек яшәгез. 17 Һәммә ке-
шеләрне хөрмәт итегез, имандашларны яратыгыз, Аллаһыдан
куркыгыз, патшаны хөрмәт итегез.

---

* 2:6 *Сион* – Иерусалим шәһәренең шигъри исеме.
** 2:9 *Патша-руханилар* – бер үк вакытта патшалар да булган руха-
нилар.

*Мәсихнең михнәт чигүе — безнең өчен үрнәк*

18 Хезмәтчеләр, яхшы һәм миһербанлы хуҗаларыгызга гына
түгел, бәлки кырысларына да курку катыш тирән хөрмәт белән
буйсыныгыз. 19 Чөнки берәрсе, нахакка михнәт чиккәндә, Ал-
лаһы хакында уйлап түземле булса, Аллаһы моны хуш күрә.
20 Гаеп эш эшләгәндә кыйналган вакытта түземлек күрсәтәсез
икән, моның ни мактанычы бар? Әмма инде игелек эшләп тә,
михнәт чигәсез һәм шул чакта түземлек күрсәтәсез икән, менә
моны Аллаһы хуш күрә. 21 Сез моның өчен чакырылдыгыз. Сез
Мәсих эзләре буенча барсын өчен, Ул сезгә үрнәк калдырып,
сезнең өчен газап чикте. Шуңа күрә Аннан үрнәк алыгыз. Изге
язмада:

22 «Ул һичнинди гөнаһ кылмады,
Һәм Аның телендә мәкерлек булмады», —

дип язылган.

23 Мыскыл ителгән вакытта Ул Үзе мыскыл итмәде; газап
чиккәндә янап куркытмады, бәлки Үзен гадел Хөкем итүчегә
тапшырды. 24 Гөнаһлардан арындырып, дөреслек өчен яшәсен-
нәр дип, Ул безнең гөнаһларыбызны Үз тәнендә хачка күтәрде.
Сез Аның яралары белән савыктырылдыгыз. 25 Адашып йөрүче
сарыклар сыман идегез сез, әмма хәзер Көтүчегез һәм җанна-
рыгызны Саклаучы янына әйләнеп кайттыгыз.

*Хатыннар һәм ирләр*

**3** 1-2 Хатыннар, сез дә ирләрегезгә күндәм булыгыз. Шуның
белән, ирләрегез арасында Аллаһы сүзенә итагать итмәү-
челәр сезнең пакь һәм тәкъва яшәвегезне күргәнгә, алар-
ны берсүзсез Аллаһы янына алып килерсез. 3 Сезнең матурлы-
гыгыз үрелгән чәч, алтын бизәкләр, купшы киемнәр кию кебек
тышкы матурлык түгел, 4 ә чын йөрәктән чыккан, басынкы һәм
тыныч рухның мәңге сулмас эчке матурлыгы булсын. Аллаһы
каршында менә шул бик кыйммәтле. 5 Элекке заманда Алла-
һыга өмет баглаган изге хатыннар да үзләрен шулай бизәгән-
нәр, ирләренә буйсынучан булганнар. 6 Мәсәлән, Сара да, Иб-
раһимны әфәндем дип атап, аңа күндәм булган; сез дә, игелек
кылсагыз һәм һичнәрсәдән курыкмасагыз, Сара кызлары бу-
лырсыз.

7 Ирләр, сезнең дә хатыннарыгыз белән тормыш итү турында
белемегез булырга тиеш. Алар сездән көчсезрәк. Аларны хөр-
мәт итегез, алар да сезнең кебек үк Аллаһыдан тормыш бүләген
кабул итеп алалар бит. Шул рәвешчә догаларыгызга тоткарлык
булмас.

*Гаделлек өчен михнәт чигү*

[8] Ниһаять, һәммәгез дә бер фикердә, миһербанлы, туган жан-
лы, шәфкатьле, тыйнак булыгыз. [9] Яманлыкка яманлык белән
яки ачулы сүзләргә ачулану белән җавап кайтармагыз. Кире-
сенчә, фатиха бирегез, чөнки сез фатиха кабул итәргә чакы-
рылдыгыз. [10] Изге язмада язылганча:
«Тормышны яратучы,
Ямьле көннәр күрергә теләүче
Телен яманлыктан,
Авызын мәкерле сүзләрдән тыйсын.
[11] Яманнан читкә китсен, яхшылык кылсын,
Тынычлык эзләсен һәм шуңа омтылсын.
[12] Чөнки Раббының күзләре тәкъва кешеләргә,
Аның колаклары аларның ялваруына юнәлгән;
Әмма Ул яманлык кылучыларга каршы тора».
[13] Игелек эшләргә омтылсагыз, сезгә кем явызлык кылыр?
[14] Ә гаделлек өчен газап чигәсез икән, сез бәхетле. Ә кешеләр-
нең янауларыннан курыкмагыз һәм борчылмагыз. [15] Әмма йө-
рәкләрегездә Мәсихне Раббы итеп олылагыз. Уртак өметегез
хакында сездән хисап таләп итүче һәркемгә һәрвакыт басын-
кылык һәм ихтирам белән җавап бирергә әзер булыгыз, [16] вөж-
даныгыз саф булсын. Шул вакытта, Мәсихнеке булуыгызны
һәм игелекле эшегезне күреп, сезне яманлаган гаепләүчеләр
оятка калырлар. [17] Әгәр бу Аллаһы ихтыяры булса, игелекле эш
өчен газаплану яманлык өчен газапланугa караганда яхшырак.
[18] Чөнки Мәсих, безне Аллаһы янына алып бару өчен, гөнаһлы
кешеләр урынына гадел Кеше буларак, гөнаһларыбыз өчен бер
тапкыр үлде. Аның тәне үлемгә тапшырылды, әмма Аллаһы
Аны Үзенең Рухы белән терелтте. [19] Әнә шул Рух ярдәмендә Ул
тоткындагы рухлар янына барып, аларга вәгазь итте. [20] Бу рух-
лар борынгы заманнарда – Нух көннәрендә – Аллаһыга ита-
гатьсез булганнар. Әмма Аллаһы, сабырлык күрсәтеп, көймә-
нең төзелеп бетүен көткән; ул көймәдә бик аз, ягъни сигез җан
гына, су ярдәмендә котылып калган. [21] Бу су хәзер сезне кот-
кара торган суга чумдырылу йоласын гәүдәләндерә. Суга чум-
дырылу – тәннең керен юып төшерү түгел, бәлки саф вөждан
белән Аллаһыга мөрәҗәгать итү буларак, Гайсә Мәсихнең
үледән терелеп торуы аша сезне коткара. [22] Ул күккә ашты
һәм Аллаһы янында иң мөһим урында тора. Фәрештәләр бе-
лән бергә күктәге барлык хакимлекләр һәм кодрәтләр Аңа
буйсынган.

### *Тормыштагы үзгәрешләр*

4 [1] Шулай итеп, Мәсих тән газабы кичергән кебек, сез дә
шундый ук фикерләү рәвеше белән коралланыгыз, чөнки
тән газабы кичерүче гөнаһтан читкә борылды, [2] нәтиҗәдә
бу дөньяда калган вакытын инде кеше нәфесе буенча түгел,
бәлки Аллаһы ихтыяры буенча яши. [3] Гомерегезнең шактый
өлешен мәҗүсиләр кебек азгынлыкка, гөнаһлы теләккә, эч-
кечелеккә, кирәгеннән артык күп ашау-эчүгә бирүегез һәм
җирәнгеч потларга табынуыгыз инде җитәр. [4] Шуңа күрә мәҗү-
силәр хәзер сезнең үзләре белән бергә шул ук азгынлыкларда
катнашмавыгызга гаҗәпләнәләр һәм шуның өчен сезне яман-
лыйлар. [5] Алар үлеләрне һәм тереләрне хөкем итәргә әзер
булган Аллаһыга җавап бирергә тиеш. [6] Шуңа күрә Яхшы хәбәр
инде үле булганнарга да игълан ителде. Чөнки, барлык кеше-
ләрнеке кебек, тәннәре үлемгә тапшырылса да, алар рухлары
белән Аллаһы кебек яшиләр.

[7] Һәр нәрсәнең ахыры якынлаша. Шуңа күрә, дога кыла алу
өчен аек һәм тотнаклы булыгыз. [8] Барыннан да бигрәк бер-бе-
регезне эчкерсез яратыгыз, чөнки мәхәббәт күп гөнаһларны
юкка чыгара, [9] бер-берегезгә зарланусыз кунакчыл булыгыз.
[10] Аллаһыдан нинди сәләт алган булсагыз, һәрберегез шул сә-
ләт белән бер-берегезгә хезмәт итегез. Яхшы идарәчеләр кебек,
Аллаһы тарафыннан бирелгән төрле сәләтләрне кулланыгыз.
[11] Берәү сөйли икән, Аллаһы сүзләрен әйткән кебек сөйләсен,
берәү хезмәт күрсәтә икән, Аллаһы биргән көч белән хезмәт
итсен, шулар белән Гайсә Мәсих аша һәрнәрсәдә Аллаһы дан-
ланыр. Мәсихкә мәңге-мәңгегә дан һәм кодрәт. Амин.

### *Мәсих исеме өчен газап чигү*

[12] Сөеклеләрем! Сезне сынау өчен җибәрелгән куркыныч
вәсвәсәне үзегез белән булган ниндидер сәер хәл кебек күреп
гаҗәпләнмәгез. [13] Киресенчә, Мәсихнең даны ачылганга да
тантана итеп куану өчен, Аның газапларында катнашучы була-
рак шатланыгыз. [14] Сезне Мәсих исеме өчен мыскыл итәләр
икән, сез бәхетле, чөнки сездә дан Рухы, Аллаһы Рухы яши.
[15] Әгәр берегез газап чиксә, кеше үтерүче яки карак, явызлык
кылучы яки башкалар эшенә тыкшынучы буларак газап чигәр-
гә тиеш түгел. [16] Ә мәсихче* буларак газап чигәсез икән, оялма-
гыз, бәлки мәсихче исемен йөртүегез өчен Аллаһыны данлагыз.
[17] Чөнки Аллаһының хөкем итә башлау вакыты җитте. Иң элек

---

* **4:16** *Мәсихче* – Гайсә Мәсихкә иман итүче.

Ул үзенекеләрен хөкем итәчәк. Бу бездән башланса, Аллаһының Яхшы хәбәренә итагать итмәгәннәрнең ахыры ничек булыр? Изге язмада язылганча:

18 «Әгәр тәкъва кеше көчкә котыла икән,
Имансыз һәм гөнаһлы кая барыр?»

19 Шулай итеп, Аллаһы ихтыяры буенча газап чигүчеләр үз җаннарын тугры Тудыручыга тапшырсыннар һәм игелек кылуларын дәвам итсеннәр.

### *Өлкәннәргә һәм кечеләргә нәсыйхәт*

5 1 Үзем дә өлкән, Мәсих газапларының шаһите һәм киләчәктә ачылачак данны уртаклашучы буларак, арагыздагы өлкәннәргә ялварам: 2 үзегездәге Аллаһы ышанып тап-
шырган иман итүчеләр көтүен мәҗбүриләп түгел, бәлки үзегез теләп һәм Аллаһы ихтыяры буенча; акчага комсызланып түгел, бәлки күңел кушканча тырышлык белән көтегез. 3 Сезгә тап-
шырылганнар өстеннән хакимлек итмәгез, бәлки көтүгә үрнәк булыгыз. 4 Һәм Баш Көтүче килгәч, сулмый торган дан таҗын алырсыз. 5 Яшьләр, сез шулай ук өлкәннәргә буйсыныгыз. Шу-
лай ук һәрберегез бер-берегезгә карата басынкылык күрсәтегез, чөнки Изге язмада язылганча:

«Аллаһы тәкәбберләргә каршы тора,
Ә басынкыларга мәрхәмәтен бирә».

6 Шулай итеп, Аллаһының кодрәтенә буйсыныгыз, һәм Ул үз вакытында сезне югары күтәрер. 7 Үзегезнең барлык мәшәкать-
ләрегезне Аллаһыга йөкләгез, чөнки Ул сезнең хакта кайгырта. 8 Аек һәм уяу булыгыз, сезнең дошманыгыз иблис, үкерүче арыслан кебек, кемне йотарга дип эзләнеп йөри. 9 Имандашла-
рыгызның дөньяда шундый ук газапларга дучар ителүен белеп, иманда нык торыгыз һәм иблискә каршы торыгыз. 10 Мә-
сих аша безне Үзенең мәңгелек данына чакырып алган, һәр мәрхәмәтнең чыганагы булган Аллаһы, сез беркадәр газап чиккәннән соң, көчегезне кайтарачак, куәт бирәчәк вә ныгытачак һәм үзегезне какшамас итәчәк. 11 Аңа мәңге-мәңгегә кодрәт булсын. Амин.

12 Мин бу кыска хатны үзем ышанычлы дип санаган имандашыбыз Силас аркылы яздым. Сезнең күңелегезне күтәреп, моның Аллаһының чын мәрхәмәте булуын раслыйм. Шул мәр-
хәмәт белән нык торыгыз сез! 13 Бабылдагы сезнең кебек үк сайланган иман итүчеләр бердәмлеге һәм рухи улым Марк сез-
гә сәлам юллый. 14 Бер-берегезне ярату белән үбеп сәламләгез. Мәсихнеке булган һәммәгезгә иминлек булсын.

# ПЕТЕРДӘН ИКЕНЧЕ ХАТ

**1** 1 Гайсә Мәсихнең колы вә рәсүле Шимун Петердән – Алла-
һыбыз һәм Коткаручыбыз Гайсә Мәсихнең хаклыгы аша
кыйммәтле иманны безнең белән бер дәрәҗәдә кабул иткән
туганнарга: 2 Аллаһыны вә Раббыбыз Гайсәне танып белү аша
сезгә мәрхәмәт һәм иминлек мул итеп бирелсен.

*Иман итүченең чакырылуы һәм сайлануы*

3 Үзенең даны һәм камиллеге белән безне Чакырган Затны
танып белүебез аша Аның илаһи кодрәте безгә Аллаһыга ярак-
лы итеп яшәргә кирәк булган һәммә нәрсәне бүләк иткән.
4 Болар аркылы Ул безгә иң бөек һәм кыйммәтле вәгъдәләр
биргән. Алар гамәлгә ашкач, сез явыз нәфесләр аркасында бо-
зылган дөньядан котылып, илаһи табигатьтә катнаша алырсыз.
5 Шул сәбәпле, иманыгызга игелек өстәү өчен, хәлегездән кил-
гән бар нәрсәне эшләгез. Игелеккә белемне өстәгез; 6 белемгә
тотнаклыкны; тотнаклыкка сабырлыкны; сабырлыкка Алла-
һыга бирелүне; 7 Аллаһыга бирелүгә имандаш туганнарыгызны
яратуны; имандаш туганнарыгызны яратуга мәхәббәт өстәгез.
8 Әгәр сездә бу хасиятләр булса, һәм алар арта барса, сезнең
Раббыбыз Гайсә Мәсихне белүегез файдасыз һәм уңышсыз
калмас. 9 Ә инде кемдә алар юк, ул – сукырларча начар күрүче
һәм элекке эшләгән гөнаһларыннан чистартылганын оныткан
кеше. 10 Шуңа күрә, имандаш туганнар, Аллаһы тарафыннан
чакырылган һәм сайланган булуыгызны тагын да ышанычлы-
рак итәргә тырышыгыз. Шулай эшләсәгез, һичкайчан иманы-
гыздан тайпылмассыз 11 һәм Раббыбыз вә Коткаручыбыз Гайсә
Мәсихнең мәңгелек Патшалыгына зур теләк белән кабул ите-
лерсез.
12 Шул сәбәптән, сез боларны белсәгез дә һәм, сезгә бирел-
гән хакыйкатькә нык тотынып торсагыз да, мин болар хакын-
да һәрвакыт хәтерегезгә төшерәчәкмен. 13 Үзем әле исән һәм,
шушы тәнемдә вакытта, болар хакында хәтерегезгә төшерүне

үземнең бурычым итеп исәплим. [14] Мин беләм: тиздән бу тә-
немнән китәчәкмен: миңа моны Раббыбыз Гайсә Мәсих ачкан
иде. [15] Шуңа күрә, арагыздан киткәч, боларны һәрвакыт истә
тотыгыз дип, хәлемнән килгән бар нәрсәне эшлим.

### *Мәсихнең яңадан килүе*

[16] Без сезгә Раббыбыз Гайсә Мәсихнең кодрәте һәм Аның
килүе хакында сөйләгәндә, хәйләле риваятьләргә ияреп түгел,
бәлки Аның мәһабәтлеген үз күзләребез белән күреп сөйләдек.
[17] Бөек данлы Аллаһыдан: «Бу Минем сөекле Улым, Ул Минем
куанычым», – дигән аваз килгәндә, Аллаһы Ата тарафыннан
Гайсәгә кадерләү һәм дан балкышы бирелде. [18] Гайсә белән
изге тауда булган чакта, күкләрдән килгән бу авазны үзебез
ишеттек. [19] Шуның өчен без пәйгамбәрләр сөйләгән Аллаһы
хәбәренә тагын да ныграк ышана алабыз. Сез дә, караңгы
урында балкып торган яктылыкка игътибар иткән кебек, бу
хәбәргә әһәмият биреп, дөрес эшлисез. Сез, көн җитеп, йөрәк-
ләрегезне таң йолдызы балкытканга кадәр, аңа әһәмият бирүе-
гезне дәвам итәргә тиешсез. [20] Иң элек шуны аңлагыз: Изге
язмадагы бер генә пәйгамбәрлек сүзен дә һичкем үз сәләтенә
таянып аңлата алмый. [21] Чөнки пәйгамбәрлек сүзе беркайчан да
кеше ихтыярыннан бирелмәде, бәлки кешеләр Аллаһыдан кил-
гән хәбәрне Изге Рухтан рухландырылып сөйләделәр.

### *Ялган өйрәтүчеләр турында*

**2** [1] Әмма ләкин Исраил халкы арасында ялган пәйгамбәрләр
дә булганнар. Шулай ук, сезнең арагызда да ялган өйрәтү-
челәр булыр. Алар яшерен рәвештә һәлакәткә китерүче
ялган тәгълиматны арагызда тарата башларлар, хәтта үзләрен
йолып алган Хөкемдарны да инкяр итеп, үз өсләренә кötел-
мәгән һәлакәт китерерләр. [2] Күпләр аларның азгын яшәешенә
иярер, һәм аларның эшләре аркасында хакыйкать юлы хур-
ланыр. [3] Бу ялган өйрәтүчеләр, комсызланып, үзләре уйлап
чыгарган риваятьләре ярдәмендә сездән файдаланырлар. Алар
өстеннән инде күптәннән хөкем тора, аларның һәлакәте ко-
тылгысыз.

[4] Аллаһы гөнаһ кылган фәрештәләрне дә аямаган бит, бәлки,
чылбырлар белән бәйләп, җәһәннәм караңгылыгына ташлаган:
алар анда хөкем көнен көтәләр. [5] Аллаһы, тәкъва тормышны
вәгазьләүче Нух белән җиде кешедән кала, борынгы җиһанны
да аямаган: дәһриләр өстенә туфан китерткән. [6] Ул, дәһриләр
белән киләчәктә ни буласын кисәтүче сабак итеп, Сәдүм һәм
Гамура шәһәрләрен ут белән көлгә әйләндереп хөкем иткән.

[7] Анда яшәгән азгыннарның әхлаксыз гамәлләреннән интеккән
әхлаклы Лутны коткарган. [8] Бу әхлакый кеше азгыннар ара-
сында яшәгәндә, аларның әхлаксыз эшләрен күреп һәм ише-
теп, чын күңеленнән көннән-көн газап чиккән. [9] Шулай итеп,
Раббы Үзенә бирелгәннәрне сынаулардан ничек коткарырга, ә
явызларны, җәза астында тотып, хөкем көненә ничек сакларга
икәнен белә.

[10] Бу бигрәк тә үзләренең бәдәни азгын теләкләренә ияреп,
Раббы хакимлеген нәфрәт итүчеләргә кагыла. Алар – тәкәббер
һәм тупас кешеләр. Алар күкләрдәге шөһрәтле затларга яла
ягудан да курыкмыйлар. [11] Хәер, бу шөһрәтле затлардан күпкә
көчлерәк һәм куәтлерәк фәрештәләр дә Раббы алдында аларны
хурлап гаепләмиләр. [12] Бу ялган өйрәтүчеләр үзләре аңламаган
нәрсәне яла ягып гаеплиләр. Алар табигый теләкләренә буй-
сынып яшәгән һәм фәкать аулау һәм үтерелү өчен генә туган
аңсыз хайваннар сыман. Хайваннар ничек үтерелсә, шулай бу
ялган өйрәтүчеләр дә һәлак ителәчәкләр. [13] Алар үзләре ки-
тергән явызлыкларына явызлык әҗере алачаклар. Алар өчен
хозурлык – көн яктылыгында мәҗлесләрдә комсызланып
ашап-эчү. Сезнең мәҗлесләрегездә булганда, алар – пычрак
һәм хурлыклы таплар, чөнки алар үзләрен алдаучы ләззәтләргә
биреләләр. [14] Кем белән зина кылырга икән дип кенә ха-
тын-кызларга күңел бирәләр һәм гөнаһтан һич туймыйлар;
тотрыксыз кешеләрне юлдан яздыралар; аларның күңелләре
комсызлыкта шомарган; алар – ләгънәт уллары. [15] Алар, туры
юлдан тайпылып, адаштылар. Алар үзенең явыз гамәлләре өчен
табыш алуны яраткан Бегор улы пәйгамбәр Бильям эзләреннән
бара башладылар. [16] Ә Бильям явыз эше өчен шелтәләнгән.
Ишәк аңа кеше тавышы белән эндәшеп, пәйгамбәрне ахмак-
лыгыннан туктаткан.

[17] Бу кешеләр – сусыз чишмәләр, көчле җил куып тараткан
томан сыман. Алар өчен тирән караңгылыкта урын саклана.
[18] Чөнки алар, күпертелгән буш сүзләр сөйләп, азгын бәдәни
теләкләрен кулланып, ялгыш юлдан баручылар арасыннан әле
генә арына башлаганнарны ятьмәгә эләктерергә тырышалар.
[19] Алар теге кешеләргә азатлык вәгъдә итәләр, ә үзләре – бо-
зыклык коллары; чөнки кеше нәрсәгә җиңелсә, шуның колы
була. [20] Әгәр бу кешеләр Раббыбыз һәм Коткаручыбыз Гайсә
Мәсихне танып белү аша бу дөньяның азгынлыгыннан арын-
ганнан соң янә буталалар һәм аңа җиңеләләр икән, димәк
аларның соңгы халәте элеккегедән яманрак була. [21] Чөнки хак-
лык юлын танып белгәннән соң үзләренә бирелгән изге әмер-
дән кире чигенүгә караганда, ул юлны бөтенләй белмәүләре

алар өчен яхшырак булган булыр иде. 22 Андый кешеләр белән
ни булганы хакында мәкальләрдә дөрес әйтелгән: «Эт үзенең
косыгына әйләнеп кайта», һәм «Юындырылган дуңгыз пычрак
сазда аунарга бара».

*Раббы көне якынлаша!*

3 1 Сөекле имандаш туганнарым! Мин сезгә инде икенче
хатымны язам. Бу хатларда белгәннәрегез хакында хәте-
регезгә төшереп, мин сезне дөрес фикер йөртүгә дәртлән-
дерәм. 2 Элгәре вакытларда изге пәйгамбәрләр тарафыннан
әйтелгән сүзләрне һәм Раббыбыз вә Коткаручыбыз рәсүлләре-
гез аша биргән әмерне искә төшерүегезне телим.
3 Иң элек шуны аңлавыгыз кирәк: соңгы көннәрдә үзләренең
нәфес теләкләре буенча гамәл кылучы, мыскыллаучы кешеләр
чыгачак. 4 Алар: «Гайсә яңадан килергә вәгъдә итмәдемени?
Кая соң Ул? Безнең ата-бабаларыбыз үлем йокысына талдылар,
ә һәммә нәрсә дөнья яратылганнан бирле ничек булса, шул
килеш кала бирә», – диячәкләр. 5 Әмма алар күк вә җир бо-
рынгыдан булуын, аларның Аллаһы сүзе аркылы судан һәм су
белән яратылганын юри онытталар. 6 Борынгы дөнья сүз аркы-
лы туфан суы белән юк ителгән. 7 Ә Аллаһының шул ук сүзе
белән хәзерге күк һәм җир ут белән юк ителү өчен хөкем көне-
нә сакланып тора. Шул көндә алар яндырылып бетереләчәкләр
һәм дәһриләр һәлак ителәчәкләр.
8 Сез, сөеклеләрем, бер нәрсәне онытмагыз: Раббы өчен бер
көн мең ел сыман, һәм мең ел бер көн сыман. 9 Кайберәүләр
озакка суза дип исәпләүләренә карамастан, Раббы Үзенең
вәгъдәсен үтәүне озаклатмый. Киресенчә, Ул сезгә зур сабыр-
лык күрсәтә, чөнки Ул беркемнең дә һәлак булуын теләми,
бәлки барысының да тәүбәгә килүен тели.
10 Әмма Раббы көне якынлаша! Карак көтмәгәндә кергән
кебек, Раббы да шулай киләчәк. Күкләр көчле дөмбердәгән
тавыш астында юкка чыгачак; күк җисемнәре утта янып тар-
калачак; җир өстендәге һәммә нәрсә фаш ителәчәк. 11-12 Әгәр
һәммә нәрсә шулай таркалачак икән, ул чакта сез нинди кеше
булырга тиеш соң? Сез Аллаһының көнен көткәндә һәм ул
көннең тизрәк килүе өчен тырышканда, тормышыгыз изге һәм
Аллаһыга багланган булуы кирәк. Ул көнне күк янып таркала-
чак һәм кызулыктан күк җисемнәре эреп бетәчәк. 13 Әмма без,
Аллаһының вәгъдәсенә иманып, гаделлек хакимлек итә торган
яңа күкне һәм яңа җирне көтәбез.
14 Шуңа күрә, сөеклеләрем, моның һәммәсен дә көтеп, Ал-
лаһы каршында иминлектә яшәп, һичбер тапсыз, кимчелексез

табылуыгыз өчен хәлдән килгән бөтен нәрсәне эшләгез.
15 Раббының сабырлыгын сез котылу мөмкинлеге дип аңлагыз.
Үзенә Аллаһы тарафыннан бирелгән зирәклеге белән безнең
сөекле имандаш туганыбыз Паул да сезгә шулай дип язган иде.
16 Бу хакта ул бөтен хатларында да яза. Ул хатларда авыр аңла-
шыла торган кайбер нәрсәләр бар. Белемсез, тотрыксыз кеше-
ләр, башка Изге язмаларны бозган кебек, бу урыннарны да
бозып аңлаталар. Моның белән алар үзләрен һәлакәткә дучар
итәләр. 17 Ә сез исә, сөеклеләрем, бу хакта инде белгәнлектән,
әхлаксыз кешеләр ялгышлыклары сезне тайпылдырмасын һәм
сез, ышанычлы нигездән егылып төшмәс өчен, сак булыгыз.
18 Раббыбыз һәм Коткаручыбыз Гайсә Мәсих мәрхәмәтендә
һәм Аны танып белүдә даими үсегез. Аңа бүген дә һәм мәңге
дан булсын! Амин.

# ЯХЪЯДАН БЕРЕНЧЕ ХАТ

*Тормыш Сүзе*

**1** 1 Баштан ук булган, без ишеткән, үз күзләребез белән күргән,
күзәткән һәм кулларыбыз белән кагылган нәрсә – тормыш
Сүзе хакында язабыз. 2 Тормыш ачылды: без аны күрдек һәм
Атабыз кулында булган, безгә ачылган мәңгелек тормышны
сезгә шаһитлек итәбез һәм игълан итәбез. 3 Безнең белән арала-
шуыгыз булсын өчен, үзебез күргән һәм ишеткән нәрсәне сезгә
дә игълан итәбез. Ә без исә Ата һәм Аның Улы Гайсә Мәсих
белән аралашып яшибез; 4 һәм, куанычыбыз тулы булсын дип,
боларны сезгә язабыз.

*Аллаһы – яктылык*

5 Без Аннан ишеткән һәм сезгә игълан итә торган хәбәр шун-
нан гыйбарәт: Аллаһы – яктылык, һәм Аңарда һичнинди караң-
гылык юк. 6 Әгәр без: «Аллаһы белән аралашып яшибез», – дип
әйтсәк, әмма караңгылыкта йөрсәк – без ялганлыйбыз һәм
хакыйкать буенча яшәмибез. 7 Әгәр инде Аллаһы яктылыкта
булган кебек, без дә яктылыкта йөрсәк, димәк, бер-беребез
белән аралашып яшибез һәм Аның Улы Гайсәнең каны безне
һәр гөнаһтан чистарындыра.
8 Әгәр: «Гөнаһыбыз юк», – дисәк, без үз-үзебезне алдыйбыз
һәм бездә хакыйкать юк. 9 Әмма гөнаһларыбызны икърар ит-
сәк, безнең гөнаһларыбызны Аллаһы ярлыкар һәм, һәртөрле
хаксызлыктан арындырып, безне чистартыр, чөнки Ул тугры
һәм гадел. 10 «Без гөнаһ кылмадык», – дисәк, Аллаһыны ялган-
чы итәбез һәм Аның сүзе бездә юк.

*Мәсих – безнең Яклаучыбыз*

**2** 1 Балаларым! Боларны сезгә, гөнаһ кылмагыз, дип язам.
Ә инде берәү гөнаһ кылса, Ата алдында Яклаучы-Юату-
чыбыз – һәрвакыт дөрес гамәл итүче Гайсә Мәсих бар.
2 Мәсих гөнаһларыбызның, безнең генә түгел, бәлки бөтен
дөньяның да гөнаһлары кичерелүен алып килүче һәм Аллаһы

белән татулаштыручы корбан булды. [3] Ә Аллаһының әмерләрен
үтәсәк, Аны танып белүебездә ышанычлы була алабыз. [4] Кем дә
кем: «Мин Аллаһыны таныйм», – ди, әмма Аның әмерләрен
үтәми, ул – ялганчы һәм аңарда хакыйкать юк. [5] Ә Аның сүз-
ләрен үтәүче кешедә Аллаһы мәхәббәте чыннан да камилләш-
кән була: шуның аша без Аңарда булуыбызны беләбез. [6] Кем
дә кем: «Аллаһыда торам», – ди икән, ул Гайсә сыман гамәл
итәргә тиеш.

*Яңа әмер*

[7] Сөеклеләрем! Яңа әмер язмыйм, бәлки сездә баштан ук
булган иске әмерне язам: иске әмер исә – сез ишеткән хәбәр
ул. [8] Әмма шуның белән бергә бу әмер яңа да: аның хакыйкате
Мәсихтә ачылды һәм сез аны танып беләсез, чөнки караңгы-
лык кире чигенә, хакыйкый яктылык инде балкый.
[9] Кем дә кем үзен яктылыкта дисә, әмма имандаш туганына
нәфрәтләнсә, ул һаман караңгылыкта була. [10] Кем дә кем үзе-
нең туганын ярата икән, ул яктылыкта була, һәм аңарда башка-
ларны вәсвәсәгә китерүгә урын юк. [11] Ә кем үзенең имандаш
туганына нәфрәтләнсә, ул караңгылыкта була, караңгылыкта
йөри һәм кая баруын белми, чөнки караңгылык аның күзләрен
сукырайткан.

[12] Балаларым, сезгә язам,
чөнки сезнең гөнаһларыгыз Гайсә аркасында
кичерелде.
[13] Аталар, сезгә язам,
чөнки баштан ук Булучыны сез танып беләсез.
Егетләр, сезгә язам,
чөнки сез явыз иблисне җиңдегез.
[14] Балаларым, мин сезгә язам,
чөнки сез Атаны танып беләсез.
Аталар, мин сезгә язам,
чөнки сез баштан ук Булучыны танып беләсез.
Егетләр, мин сезгә язам,
чөнки сез көчле,
Аллаһы сүзе сездә тора,
һәм сез явыз иблисне җиңдегез.

[15] Фани дөньяны һәм анда булган нәрсәләрне яратмагыз.
Дөньяны яратучыда Атаны ярату юк. [16] Чөнки бу дөньяда бул-
ган һәммә нәрсә – тән нәфесләре, күзләр нәфесе һәм тормышта
тәкәбберлеккә китерүче нәрсәләр – Атадан түгел, фәкать дөнь-
ядандыр. [17] Дөнья һәм аның нәфесләре үтеп китә, әмма Аллаһы
ихтыярын үтәүче мәңге яши.

*Мәсих дошманнары турында кисәтү*

[18] Балаларым! Хәзер соңгы вакытлар. Мәсихнең дошманы*
киләчәге хакында сез ишеткән идегез инде. Хәзер Мәсихнең
күп дошманнары чыктылар. Ахыргы вакыт җиткәнен шуннан
беләбез дә инде. [19] Алар безнең арабыздан чыктылар, әмма без-
неке булмадылар. Әгәр безнеке булган булсалар, алар безнең
белән калган булырлар иде. Әмма һәммәсе дә безнеке булмавы
күренсен өчен, алар чыктылар.
[20] Сезгә исә Изге Аллаһы Үзенең Рухын биргән**, һәм сез
хакыйкатьне беләсез. [21] Мин сезгә хакыйкатьне белмәгәнегез
өчен түгел, әмма аны белгәнегез өчен һәм хакыйкатьтән һич-
нинди ялган килмәгәнгә күрә яздым. [22] Кем ялганчы? Ялганчы –
Гайсәнең Мәсих икәнен инкяр итүче. Ул кеше – Мәсихнең
дошманы. Ул Атаны да, Улы Гайсәне дә инкяр итә. [23] Аллаһы-
ның Улын инкяр итүче һичкемнең Аллаһы Ата белән мөгамә-
ләсе юк. Аллаһының Улын икърар итүченең исә Ата белән дә
мөгамәләсе бар.
[24] Сез исә баштан ишеткән нәрсәне күңелләрегездә саклагыз.
Әгәр баштан ишеткән нәрсә күңелләрегездә торса, ул чакта
сез дә Аллаһының Улында һәм Улының Атасында торачаксыз.
[25] Моны, мәңгелек тормышны, безгә Мәсих Үзе вәгъдә иткән.
[26] Боларны мин сезне юлдан яздырырга тырышучылар ха-
кында язам. [27] Ә сезгә Мәсихтән бирелгән Изге Рух сезнең
үзегездә тора һәм сез һичкемнең өйрәтүенә мохтаҗ түгелсез.
Мәсихнең Рухы сезгә барын да өйрәтә, һәм ул Рух хакыйкый,
ялган түгел. Рух сезгә өйрәткән кебек, Мәсихтә торыгыз.

*Аллаһы балалары*

[28] Балаларым, Мәсих килгәндә, Аның алдында ышаныч бе-
лән һәм оялусыз тора алуыбыз өчен, Мәсихтә яшәгез. [29] Аның
һәрвакыт хак булуын беләсез икән, димәк, хаклык эшләүче
һәркемнең Аллаһыдан туган булуын да беләсез.

**3** [1] Карагыз – Ата безне ничек нык яраткан! Шуңа күрә
безне «Аллаһы балалары» дип атыйлар. Дөнья кешеләре,
Аллаһыны танымаганга күрә, безне белмиләр. [2] Сөеклелә-
рем, без хәзер Аллаһы балалары, әмма безнең нәрсә булачагы-
быз әле ачылмады. Беләбез: Гайсә килгәндә без Аңа охшаулы

---

* 2:18 *Мәсих дошманы* – дәҗҗал; Мәсихкә каршы торучы алдакчы затны аңлата. (Русча – антихрист.)

** 2:20 *Сезгә Рухын биргән* – Бу урында грек телендә: «сезне майлаган/сезгә май сөрткән» дигән сүзләр бар.

булырбыз, чөнки чынлыкта Ул ничек булса, без Аны шулай
итеп күрербез. [3] Һәм шушы өметен Аңа баглаган һәркем, Мәсих
пакь булган кебек, үзен даими рәвештә пакьләндерә.

[4] Гөнаһ кылучы һәркем Аллаһы канунын боза; ә бу исә үзе
гөнаһ. [5] Һәм сез беләсез: Мәсих гөнаһларны Үз өстенә алыр
өчен килде. Һәм Аңарда гөнаһ юк. [6] Аңарда торучы һәркем
гөнаһ кылмый. Гөнаһ кылучы һәркем Мәсихне күрмәгән һәм
Аны танымаган.

[7] Балаларым, сезне һичкем алдамасын. Хаклык булдыручы
кеше Мәсих кебек үк хак була. [8] Гөнаһ кылучы исә иблистән-
дер, чөнки иблис баштан ук гөнаһ кыла. Аллаһы Улы нәкъ ме-
нә иблис эшләрен җимерергә дип килде. [9] Аллаһыдан туган
гөнаһ кылмый, чөнки аңарда Аллаһыдан бирелгән орлык кала.
Һәм ул кеше гөнаһ кыла алмый, чөнки ул Аллаһыдан туган.
[10] Аллаһы балалары һәм иблис балалары болай таныла: хаклык
кылмаучы, шулай ук үзенең туганын яратмаучы һәркем Алла-
һыдан түгел.

*Бер-берегезне яратыгыз*

[11] Электән үк сез ишеткән хәбәр: без бер-беребезне яратырга
тиешбез. [12] Безгә явыз иблистән булган һәм үзенең энесен үтер-
гән Кабил* кебек булырга ярамый. Ул ни өчен энесен үтергән?
Чөнки Кабилнең эшләре явыз, ә энесенең эшләре тәкъва бул-
ган. [13] Туганнарым, сезгә дөнья кешеләре нәфрәтләнә икән,
моңа гаҗәпләнмәгез. [14] Без үлемнән тормышка күчкәнебезне
беләбез, чөнки имандаш туганнарыбызны яратабыз. Яратмаучы
үлем эчендә тора. [15] Үзенең туганына нәфрәтләнүче һәркем ке-
ше үтерүче була. Кеше үтерүченең мәңгелек тормышы булмага-
нын сез беләсез.

[16] Без мәхәббәтне шулай танып белдек: Мәсих Үзенең җанын
безнең өчен бирде. Без дә туганнарыбыз өчен үзебезнең җаны-
бызны бирергә тиешбез. [17] Кем дә кем, һәммә нәрсәсе булып,
һәм туганының мохтаҗлыгын күрә торып, аңа шәфкать күрсәт-
мәсә, аңарда Аллаһы мәхәббәте ничек торыр икән? [18] Балала-
рым, сүз һәм тел белән түгел, бәлки эшләребез һәм хакыйкать
белән яратыйк. [19-20] Шуның белән без үзебезнең хакыйкатьтән
булуыбызны белербез һәм йөрәгебез безне кайчан булса да
гаепләсә, аны Аллаһы каршында тынычландырырбыз. Чөнки
Аллаһы безнең йөрәгебездән бөек һәм Ул һәммә нәрсәне белә.

---

* 3:12 *Кабил* – Адәм һәм Хауваның беренче улы булган. Ул үзенең
Һабил исемле энесен үтергән. (Тәүрат, «Яратылыш» китабы, 4 нче
бүлек.)

[21] Сөеклеләрем! Әгәр йөрәгебез безне гаепләми икән, димәк,
Аллаһыда ышанычыбыз бар, [22] һәм ни генә сорасак та, Аннан
алабыз, чөнки Аның әмерләрен үтибез һәм Аңа яраклы эшләр
эшлибез. [23] Аның әмере шуннан гыйбарәт: без Аның Улы Гайсә
Мәсихнең исеменә иман итәргә һәм Ул биргән әмер буенча
бер-беребезне яратырга тиешбез. [24] Аллаһының әмерләрен үтәү-
че Аңарда тора һәм Аллаһы әмерләрне үтәүчедә тора. Һәм
Аллаһының бездә торуын Аның безгә биргән Рухы аркасында
белербез.

*Хакыйкый һәм ялган рух*

**4** [1] Сөеклеләрем! Һәр рухка инанмагыз, ул рухларның Алла-
һыданмы икәнлеген сынагыз. Чөнки дөньяга күп ялган
пәйгамбәрләр чыктылар. [2] Аллаһы Рухын сез болай та-
нырсыз: Гайсә Мәсихнең кеше булып килгәнлеген икърар итү-
че һәр рух Аллаһыдан була. [3] Ә Гайсәне икърар итмәүче бер рух
та Аллаһыдан түгел, ул – сез аның киләчәге хакында ишеткән
һәм хәзер инде дөньяда булган Мәсих дошманының рухы була.
[4] Сез исә Аллаһыдан, балаларым. Һәм ялган пәйгамбәрләр-
не җиңдегез, чөнки сездә順Торучы Аллаһы Рухы дөньяда булган
рухтан бөек. [5] Алар – бу дөньядан, шуңа күрә алар дөньяви
сөйлиләр һәм дөнья кешеләре аларны тыңлый. [6] Без – Аллаһы-
дан. Аллаһыны танып белүче безне тыңлый. Аллаһыдан булмау-
чы исә безне тыңламый. Без шуның аша хакыйкать рухын һәм
ялганлык рухын таныйбыз.

*Аллаһы – мәхәббәт*

[7] Сөеклеләрем! Бер-беребезне яратыйк, чөнки мәхәббәт Ал-
лаһыдан килә. Һәр яратучы Аллаһыдан туган һәм Аллаһыны
танып белә. [8] Яратмаучы Аллаһыны танып белми, чөнки Алла-
һы – мәхәббәт ул. [9] Аллаһы безгә мәхәббәтен күрсәтте: Үзенең
Улы аша безгә яшәү булсын өчен, Аллаһы бердәнбер Улын
дөньяга җибәрде. [10] Мәхәббәт менә шуннан гыйбарәт: без Ал-
лаһыны яратканнан түгел, бәлки Ул безне яратты һәм безнең
гөнаһларыбызның кичерелүен алып килүче һәм безне Аллаһы
белән татулаштыручы корбан рәвешендә Үзенең Улын җи-
бәрде. [11] Сөеклеләрем, Аллаһы безне шулай яраткан икән, без
дә бер-беребезне яратырга тиешбез. [12] Аллаһыны һичкем һич-
кайчан күрмәгән. Әгәр бер-беребезне яратабыз икән, Аллаһы
бездә яши һәм Аның мәхәббәте бездә камилләшкән була.
[13] Аллаһы безгә Үзенең Рухыннан биргән. Шунлыктан без
Аллаһыда торуыбызны һәм Аның бездә торуын беләбез. [14] Ата
Үзенең Улын дөньяны Коткаручы итеп җибәргәнен без күрдек

һәм аңа шаһитлек бирәбез. [15] Кем дә кем Гайсәнең Аллаһы Улы
булуын икърар итсә, аңарда Аллаһы тора һәм ул Аллаһыда то-
ра. [16] Шулай итеп, Аллаһының безгә карата булган мәхәббәтен
без таныдык һәм аңа инандык.

Аллаһы – мәхәббәт. Мәхәббәттә торучы Аллаһыда торыр
һәм Аллаһы аңарда торыр. [17] Шулай итеп, хөкем көнендә без
ышаныч белән тора алсын өчен, мәхәббәтебез камилләште.
Чөнки Гайсә ничек булса, без дә бу дөньяда шундый булабыз.
[18] Мәхәббәттә курку юк, бәлки камил мәхәббәт куркуны куа.
Җәза хакында уйланулар куркыта, куркучы кеше исә мәхәббәт-
тә камилләшмәгән була.

[19] Без яратабыз, чөнки беренче булып Аллаһы безне яратты.
[20] Әгәр берәү: «Мин Аллаһыны яратам», – дип әйтсә, ә үзенең
имандаш туганына нәфрәтләнсә, ул – ялганчы. Чөнки үзе күр-
гән туганын яратмаучы кеше күрмәгән Аллаһыны ярата алмый.
[21] Аллаһы безгә: «Аллаһыны яратучы кеше үзенең туганын да
яратсын», – дигән әмерне бирде.

### *Мәңгелек тормыш – Аллаһы Улында*

5 [1] Гайсәнең Мәсих булуына иман итүче һәркем Аллаһыдан
туган. Һәм атаны яратучы һәркем аның баласын да ярата.
[2] Без Аллаһы балаларын яратуыбызны Аллаһыны яратуыбыз
һәм Аның әмерләрен үтәвебез аркылы беләбез. [3] Һәм Аллаһы-
ны яратуыбызны Аның әмерләрен үтәвебез белән күрсәтәбез.
Ә Аның әмерләре авыр түгел, [4] чөнки Аллаһыдан туган һәммә
кеше явыз дөньяны җиңә. Дөньяны җиңгән җиңү – безнең
иманыбыз ул. [5] Гайсәнең Аллаһы Улы булуына инанучы дөнья-
ны җиңүче булмый кем булсын?

[6] Ул, Гайсә Мәсих, Үзенең чумдырылуының суы һәм үлеме-
нең каны белән килгән. Су белән генә түгел, бәлки су һәм кан
белән килгән. Бу хакта Рух шаһитлек бирә, чөнки Рух – ха-
кыйкать ул. [7] Шаһитлек бирүче өчәү бар: [8] Рух, су һәм кан. Һәм
өчесе дә бер үк шаһитлек бирәләр. [9] Без кешеләр шаһитлеген
кабул итәбез, ә Аллаһының шаһитлеге бөегрәк. Чөнки бу –
Аллаһы шаһитлеге: Ул Үзенең Улы хакында шаһитлек бирде.
[10] Аллаһы Улына иман итүченең үзендә шушы шаһитлек бар.
Аллаһыга иман итмәүче Аны ялганчы иткән була, чөнки Алла-
һының Үз Улы хакында биргән шаһитлегенә ышанмады. [11] Ул
шаһитлек исә шуннан гыйбарәт: Аллаһы безгә мәңгелек тор-
мыш бирде һәм ул тормыш – Аның Улында. [12] Аллаһы Улы
барның тормышы бар, Аллаһы Улы булмаганның тормышы юк.

[13] Мин моны сезгә, Аллаһы Улы исеменә иман итүчеләргә,
үзегезнең мәңгелек тормышыгыз барлыгын белегез, дип яздым.

5

14 Безнең Аның каршында булган ышанычыбыз бар – без Ал-
лаһының ихтыяры буенча нәрсәне генә сорасак та, Ул безне
тыңлый. 15 Аның тыңлаганын без беләбез икән, нәрсә генә со-
расак та, сораганыбызны алуыбызны беләбез.

16 Әгәр берәү имандаш туганының үлемгә китермәүче гөнаһ
кылуын күрә икән, ул кеше дога кылсын һәм Аллаһы аның ту-
ганына тормыш бирәчәк. Моны үлемгә китермәүче гөнаһ кы-
лучылар хакында әйтәм. Үлемгә китерүче гөнаһ бар: бу гөнаһ
хакында дога кылсыннар дип әйтмим. 17 Һәр явызлык – гөнаһ,
әмма бөтен гөнаһ та үлемгә китерми.

18 Аллаһыдан туганнарның гөнаһ кылмавын без беләбез, Ал-
лаһыдан туган Угыл аларны саклый һәм явыз иблис аларга ка-
гыла алмый. 19 Без үзебезнең Аллаһыдан булуыбызны, ә бөтен
дөньяның исә явыз иблиснең хакимлеге астында булуын белә-
без. 20 Без Аллаһы Улының килгәнен һәм, хакыйкый Аллаһыны
таныр өчен, безгә аң биргәнен беләбез. Һәм без Хакыйкыйда,
Аның Улы Гайсә Мәсихтә. Ул – хакыйкый Аллаһы һәм мәңге-
лек тормыш.

21 Балаларым, үзегезне потлардан саклагыз.

# ЯХЪЯДАН ИКЕНЧЕ ХАТ

[1]Аксакалдан – Аллаһы тарафыннан сайланган ханымга һәм
аның балаларына. Мин һәммәгезне ихлас күңелдән яратам.
Һәм мин генә түгел, бәлки хакыйкатьне танучы һәммә кеше
сезне ярата. [2]Без сезне яратабыз, чөнки хакыйкать бездә тора
һәм безнең белән мәңге булачак.
[3]Аллаһы Атадан һәм Атаның Улыннан – Гайсә Мәсихтән
бирелгән мәрхәмәт, шәфкать һәм иминлек безнең белән ха-
кыйкатьтә һәм мәхәббәттә булсын.

*Хакыйкать һәм мәхәббәт*

[4]Синең балаларың арасында без Атадан кабул иткән әмер
буенча хакыйкатьтә йөрүчеләрне тапканыма бик сөендем. [5]Хә-
зер, ханым, сиңа яңа әмер түгел, бәлки баштан ук без кабул
иткән әмерне язам һәм үтенәм: бер-беребезне яратыйк. [6]Мә-
хәббәт исә шуннан гыйбарәт: без Аллаһының әмерләре буенча
йөрергә тиешбез. Сез баштан ук ишеткәнегезчә, Аның әмере
шуннан гыйбарәт: сез мәхәббәттә яшәргә тиешсез.
[7]Гайсә Мәсихнең тәндә килүен инкяр итүче күп ялганчы-
лар дөньяга чыктылар. Андый кешеләр – ялганчылар һәм Мә-
сих дошманнары. [8]Сез нәрсә хакына эшләгәнебезне югалтмас
өчен, бәлки тулы әҗер алыр өчен, сак булыгыз. [9]Мәсих тәгъ-
лиматын сакламаган һәм аның чигеннән узган һәркемдә Алла-
һы юктыр. Тәгълиматны саклаучыда исә Ата да, Аның Улы да
бар. [10]Әгәр сезгә берәү килсә һәм бу тәгълиматка өйрәтмәсә, ул
кешене өегездә кабул итмәгез һәм аны сәламләмәгез. [11]Чөнки
сәламләгән кеше аның явыз эшләренә кушыла.
[12]Сезгә яза торган сүзләрем күп, әмма кәгазьгә кара белән
язарга теләмим, бәлки куанычыбыз тулы булсын өчен, яныгыз-
га килеп, сезнең белән сөйләшергә өметләнәм.
[13]Аллаһы тарафыннан сайланган имандаш кыз туганыңның
балалары сине сәламлиләр.

# ЯХЪЯДАН ӨЧЕНЧЕ ХАТ

1 Аксакалдан – чын күңелдән сөйгән Гәйгә.
2 Сөекле дустым, җаның уңышка ирешкән кебек, һәрьяктан
да имин һәм сәламәт бул, дип дога кылам. 3 Синең хакый-
катькә тугры булуың хакында имандаш туганнарның килеп
шаһитлек бирүләренә мин бик шатландым. Синең хакыйкать-
тә йөрүең хак. 4 Балаларымның хакыйкатьтә йөрүләре хакында
ишетүдән дә зуррак шатлык минем өчен юктыр.

*Хакыйкать өчен бергәләп эшләү*

5 Сөекле дустым, иман итүче туганнар хакында, хәтта алар
синең өчен ят булсалар да, кайгыртуың бик яхшы. 6 Алар
синең мәхәббәтең хакында иман итүчеләр бердәмлеге ал-
дында шаһитлек бирделәр. Зинһар өчен, Аллаһыга яраклы
итеп, аларга юлларын дәвам итәргә ярдәм итче. 7 Чөнки алар
Мәсих исеме хакына, Аңа иман итмәүчеләрдән һичнәрсә
кабул итмичә, юлга чыктылар. 8 Димәк, бергә хакыйкать
өчен эшли алуыбыз өчен, без алар кебекләргә ярдәм итәргә
тиешбез.
9 Мин иман итүчеләр бердәмлегенә кыска итеп яздым, әмма
араларында беренчелекне тотарга яратучы Диотрефис безне игъ-
тибарга алмый. 10 Шуңа күрә, мин яныгызга килсәм, аның эш-
ләгән эшләрен күтәрәчәкмен. Ул безнең хакта яман сүзләр
таратып кына калмый, хәтта имандаш туганнарны кабул итми,
кабул итәргә теләүчеләргә комачаулый һәм бердәмлектән куып
җибәрә.
11 Сөекле дустым! Явызлыкка иярмә, бәлки яхшылыкка ияр.
Яхшылык эшләүчеләр Аллаһыдандыр, явызлык эшләүче исә
Аллаһыны күрмәгән. 12 Димитер хакында барысы да яхшы итеп
сөйли, хәтта хакыйкать үзе дә аның ягында. Шулай ук без дә
шаһитлек итәбез. Һәм безнең шаһитлегебезнең хакыйкый булу-
ын син беләсең.

13 Мин сиңа күпне язар идем, әмма кара һәм каләм белән
язарга теләмим. 14 Тиздән синең белән күрешергә өметләнәм.
Шунда бергәләп сөйләшербез.
15 Иминлек сиңа. Сине дуслар сәламлиләр. Дусларыбызның
һәркайсына сәлам әйт.

# ЯҺҮДТӘН ХАТ

1 Гайсә Мәсихнең колы, Ягъкубның туганы Яһүдтән Алла-
һы-Ата тарафыннан чакырылганнарга, сөелгәннәргә һәм Гайсә
Мәсих өчен сакланганнарга: 2 сезгә шәфкать, иминлек һәм мә-
хәббәт мул итеп бирелсен.

*Барлык ялган пәйгамбәрләрне хөкем көтә*

3 Сөеклеләрем! Безнең уртак котылуыбыз хакында сезгә
язарга дип бик дәртләнсәм дә, мин изгеләргә бер тапкыр һәм
гомергә бирелгән иман өчен тырышып эшләгез, дип өндәп
язуны тиешле таптым. 4 Чөнки кайбер имансыз кешеләр ара-
гызга яшеренеп керделәр. Алар Аллаһыбызның мәрхәмәтен
азгынлыкка бирелү сәбәбенә әйләндерәләр һәм бердәнбер
булган Хөкемдарыбыз һәм Раббыбыз Гайсә Мәсихне инкяр
итәләр. Алар алачак хөкем турында Изге язмада инде күптән
әйтелгән.
5 Ләкин мин сезгә, инде барын да белсәгез дә, хәтерегезгә
төшерергә телим: Раббы бервакыт халыкны Мисырдан коткар-
ган булса да, икенче очракта араларындагы ышанмаучы кеше-
ләрне һәлак иткән. 6 Тиешле халәтләрен сакламый торып, әмма
үзләренең торакларын ташлап киткән фәрештәләрне онытма-
гыз: Раббы аларны тирән караңгылыкта, бөек көндә хөкем итү
өчен мәңгелек чылбырларда бәйләп тота. 7 Шул фәрештәләр
кебек фәхешлеккә һәм бәдәни бозыклыкка бирелгән Сәдүм
белән Гамура шәһәрләре* һәм алар тирәли урнашкан шәһәр-
ләр дә, барысына да кисәтүче гыйбрәт булып, мәңгелек ут җә-
засын кичерәләр.

---

* 1:7 *Сәдүм, Гамура* – Үле диңгез буендагы тигезлектә урнашкан биш шәһәрнең икесе Сәдүм һәм Гамура шәһәрләре булган. Анда яшәүче кешеләрнең гөнаһлары өчен, күктән ут яудырып, Аллаһы бу шәһәрләрне юкка чыгарган. (Тәүрат, «Яратылыш» китабы, 19 нчы бүлек.)

[8] Шулай бу кешеләр дә, хыялга бирелеп, тәннәрен нәҗесли-
ләр, Раббы хакимлеген инкяр итәләр, хәтта күкләрдәге шөһ-
рәтле затларга яла ягалар. [9] Җитәкче Микаил фәрештә дә,
Мусаның гәүдәсе хакында иблис белән бәхәсләшкәндә, хурлау
сүзе әйтергә батырчылык итмәгән, бәлки: «Сине Раббы шелтә-
ләсен», – дигән. [10] Алар исә үзләре аңламаган һәммә нәрсәне
яманлыйлар, аңсыз хайваннар сыман, табигый теләкләренә
бирелеп яшиләр һәм нәкъ шул аларны һәлак итә дә.

[11] Аларга кайгы, чөнки алар Кабил юлыннан бардылар.
Бильям кебек, акча хакына бөтенләй ялгышлыкка бирелделәр,
Корах* кебек, фетнә чыгарган өчен һәлак булдылар.

[12] Сезнең мәхәббәт мәҗлесләрегездә алар – пычрак таплар:
вөҗдансызланып сыйланалар. Алар – үзләре хакында гына
кайгыртучы көтүчеләр. Алар – җил куып йөрткән яңгырсыз
болытлар. Алар – бөтенләй үлгән, тамыры белән кубарылган,
көзен җимеш бирми торган агачлар. [13] Алар – үзләренең хур-
лыклы эшләренең күбеге белән капланган давыллы диңгез
дулкыннары. Алар – адашкан йолдызлар. Мәңгелек дөм ка-
раңгылыкта алар өчен урын саклана.

[14-15] Ханух, Адәм буыныннан җиденчесе, алар хакында пәй-
гамбәрлек итеп болай дигән: «Менә Раббы барысы өстеннән
хөкем итү өчен, аларның кылган барча имансыз гамәлләре һәм
бөтен гөнаһлы имансызларның Раббыга каршы сөйләгән бар-
лык оятсыз сүзләре өчен җәзаларга дип, Үзенең меңнәрчә из-
геләре белән килә». [16] Бу кешеләр – язмышларыннан канәгать
булмаган сукранучылар. Алар үзләренең нәфес теләкләре буен-
ча гамәл итәләр, тәкәббер сүзләр әйтәләр, үз файдалары хакы-
на ялагайланып йөриләр.

*Кисәтүләр һәм киңәшләр*

[17] Сез исә, сөеклеләрем, Раббыбыз Гайсә Мәсихнең рәсүллә-
ре тарафыннан алдан әйтелгән сүзләрне истә тотыгыз. [18] Алар
сезгә: «Соңгы вакытта үзләренең бозык теләкләре буенча га-
мәл кылучы мыскыллаучылар чыгачак», – диделәр. [19] Ул кеше-
ләр таркалыш чыгаралар, нәфес теләкләренә буйсыналар, һәм
аларда Изге Рух юк.

[20] Сез исә, сөеклеләрем, үз тормышыгызны иң изге иманы-
гыз нигезендә корып яшәгез, Изге Рух белән дәртләнеп дога
кылыгыз. [21] Раббыбыз Гайсә Мәсих Үзенең шәфкатендә сезгә

---

* **1:11** *Корах* – Аллаһы тарафыннан сайланган юлбашчылар Муса һәм Харунга каршы күтәрелгән фетнәчеләр башлыгы. (Тәүрат, «Саннар» китабы, 19 нчы бүлек.)

мәңгелек тормыш бирәчәген көтеп, Аллаһыга карата булган мәхәббәтегездә калыгыз.

22 Кайбер кешеләр икеләнүдә булсалар, аларга шәфкать күрсәтегез. 23 Башкаларын уттан тартып алгандай коткарыгыз. Өченчеләренә исә шәфкать күрсәткәндә, күңелләрегездә курку хисе булсын: шакшы эшләре белән тапланган киемнәреннән дә җирәнегез.

*Данлау догасы*

24 Сезне гөнаһка төшүдән саклый алучы, сезне кимчелексез рәвештә шатлык белән Үзенең даны алдына китерә алучы
25 Раббыбыз Гайсә Мәсих аша безне Коткаручы бердәнбер Аллаһыга бар вакытлардан элек, хәзер һәм мәңгегә дан, мәһабәтлек, кодрәт һәм хакимлек булсын. Амин.

# АЧЫЛЫШ

1 [1] Бу китапта, тиздән нәрсә булырга тиешлеген Үзенең кол-
ларына күрсәтер өчен, Аллаһы тарафыннан Гайсә Мәсихкә
бирелгән ачылыш. Ул аны Үзенең фәрештәсе аркылы җи-
бәреп, колы Яхъяга ачып күрсәтте. [2] Яхъя Аллаһы сүзе һәм Гайсә
Мәсих күрсәтеп сөйләгәннәр хакында, үзе күргән һәммә нәрсә
турында шаһитлек бирә. [3] Бу пәйгамбәрлек сүзләрен укучылар
һәм тыңлаучылар һәм анда язылганнарны үтәүчеләр бәхетле,
чөнки ул сүзләрнең гамәлгә ашу вакыты якын.

*Иман итүчеләрнең җиде бердәмлеген сәламләү*

[4] Яхъядан Асия өлкәсендәге иман итүчеләрнең җиде бердәм-
легенә: Хәзер Булучы, Булган һәм Киләчәк Зат – Аллаһыдан
һәм Аның тәхете каршында торучы җиде рухтан, [5] һәм Гайсә
Мәсихтән сезгә мәрхәмәт һәм иминлек булсын. Бу тугры Ша-
һит, Мәсих, үлгәннәрдән беренче терелеп торган, Ул – җир-
дәге патшаларның Башлыгы. Аңа, безне сөючегә һәм безне
гөнаһларыбыздан Үзенең түгелгән каны аша азат иткән [6] һәм
Үзенең Атасы Аллаһыга хезмәт итү өчен безне руханилар
патшалыгы итеп куйган Гайсәгә мәңге дан һәм кодрәт бул-
сын. Амин.

[7] Менә, Ул болытлар өстендә килә,
Һәм Аны һәркем күрер.
Аны чәнчегән кешеләр дә
Аны күрәчәкләр.
Җирдәге барлык халыклар
Аның өчен үкереп елаячаклар.
Әйе, амин.

[8] Мин – Альфа һәм Омега*, – дип әйтә Раббы Аллаһы, – Бар
булучы, Булган һәм Киләчәк Зат, Чиксез кодрәт Иясе.

---

* 1:8 *Альфа һәм Омега* – грек әлифбасының беренче һәм соңгы хә-
рефләре.

*Адәм Улы Яхъяга күренә*

[9] Мин, сезнең белән бергә Гайсә өчен газап чигүләрне, Патшалыкны һәм сабырлыкны уртаклашучы имандашыгыз Яхъя, Аллаһы сүзе һәм Гайсә хакында шаһитлек иткәнем өчен, Патмос дип аталган утрауда булдым.
[10] Раббының көнендә* мине Рух биләп алды һәм артымда быргыдан чыккандай көчле тавыш ишеттем.
[11] Ул әйтте: «Күргәннәреңнең барын да китап итеп язып, җиде бердәмлеккә җибәр: Эфескә, Смурнага, Пергәмгә, Түәтәйрәгә, Сәрдәйскә, Филаделфеягә, Лаудикеягә».

[12] Әйтүчене күрергә дип борылып карагач, мин җиде алтын
яктырткыч күрдем.
[13] Ә яктырткычлар арасында озын кием кигән һәм күкрәген алтын пута белән буган, адәм улына охшаган
Берәүне күреп алдым.
[14] Аның башындагы чәчләре ак йон кебек, кар кебек ак иде. Күзләре исә ут ялкыны,
[15] ә аяклары мичтә кыздырган бронза кебек һәм тавышы шарлавык тавышы
кебек иде.
[16] Ул Үзенең уң кулына җиде йолдыз тоткан, авызыннан ике ягы да үткен кылыч чыккан иде. Аның тышкы кыяфәте бар кодрәтендә балкып торган кояштай иде!

[17] Мин Аны күргәч, үле кешедәй, Аның аяклары алдына егылдым. Ул исә Үзенең уң кулын миңа тидереп, әйтте:

– Курыкма! Мин – Беренче һәм Соңгы,
[18] һәм Теремен; Мин үлгән идем, һәм менә, мәңге яшим. Үлем һәм үлем патшалыгы ачкычлары Минем кулда.
[19] Шулай итеп, нәрсә күргәнеңне, хәзер нәрсә бар һәм моннан соң нәрсә булырга тиешлеге
хакында яз.
[20] Минем уң кулымда күргән җиде йолдызның һәм җиде алтын яктырткычның сере шунда: җиде йолдыз – җиде бердәмлекнең фәрештәләре һәм җиде яктырткыч – җиде бердәмлек ул.

*Эфестәге иман итүчеләр бердәмлегенә хат*

**2** [1] Эфес бердәмлегенең фәрештәсенә яз:

«Үзенең уң кулында җиде йолдыз тотучы һәм җиде яктырткыч арасында Йөрүче болай әйтә:
[2] Синең эшләреңне, авыр хезмәтеңне, сабырлыгыңны һәм явызларга чыдап тора алмаганыңны беләм. Үзләрен рәсүл дип (ә алар рәсүл түгел) атаучыларны сынаганыңны һәм аларны ялганчылар дип тапканыңны
беләм.
[3] Синең сабырлыгың барлыгын, Минем исемем өчен күп нәрсәләр кичереп тә арымаганыңны беләм.
[4] Әмма сиңа каршы шелтәм бар: син беренче мәхәббәтеңне калдырдың!
[5] Шулай

---

* **1:10** *Раббының көне* – атнаның беренче көне, ягъни якшәмбе турында сүз бара дип аңларга мөмкин.

итеп, кайдан егылганыңны исеңә төшер һәм, тәүбә итеп, элек-
кеге эшләреңне эшлә. Югыйсә, әгәр тәүбә итмәсәң, яныңа ки-
лермен һәм синең яктырткычыңны урыныннан кузгатырмын.
6 Ләкин яхшы ягың бар: Никүләй тарафдарларының эшләрен
нәфрәт итәсең. Аларны Мин дә нәфрәт итәм. 7 Рухның бердәм-
лекләргә әйткәнен колагы булган ишетсен. Җиңүчегә Мин Алла-
һы оҗмахында булган тереклек агачыннан ашарга бирәчәкмен».

*Смурнадагы иман итүчеләр бердәмлегенә хат*

8 Смурна бердәмлегенең фәрештәсенә яз:
«Беренче һәм Соңгы, үлгән һәм терелеп Торган болай дип
әйтә: 9 Синең хәсрәт чигүеңне һәм фәкыйрьлегеңне беләм, әм-
ма син бай. Үзләрен яһүдләр дип атаучыларның сине хурлаула-
рын күтәргәнеңне беләм. Алар яһүдләр түгел, бәлки шайтан
җыены. 10 Алда сине көткән һичнәрсәдән курыкма. Синең ке-
шеләреңне сынар өчен, арагыздан кайберләрегезне иблис төр-
мәгә утыртачак һәм ун көн буе алар хәсрәт кичерәчәк. Үлгәнгә
тикле тугры бул, һәм сиңа тормыш таҗы бирәчәкмен. 11 Рух-
ның бердәмлекләргә әйткәнен колагы булган ишетсен. Җиңүче
икенче үлемнән һичнинди зыян күрмәс».

*Пергәмдәге иман итүчеләр бердәмлегенә хат*

12 Пергәм бердәмлегенең фәрештәсенә яз:
«Ике ягы да үткен кылычы булган Зат болай дип әйтә: 13 Си-
нең кайда яшәвеңне беләм: анда шайтан тәхете тора. Син Ми-
ңа булган иманыңны саклап тотасың. Сездә, шайтан яшәгән
җирдә, тугры шаһитем Антипас үтерелгән вакытта да син Миңа
булган иманыңнан ваз кичмәдең. 14 Әмма сиңа каршы берничә
шелтәм бар: синдә Бильям тәгълиматын тотучылар бар. Ә ул,
потка бүләк итеп китергән корбаннарны ашасыннар һәм фә-
хешлеккә бирелсеннәр дип, Исраил улларын гөнаһка кертергә
Балакны өйрәткән бит*. 15 Шулай ук синдә Никүләй тарафдар-
ларының тәгълиматын тотучылар бар. 16 Шуңа күрә, тәүбә ит.
Югыйсә, тиздән яныңа килермен һәм авызымнан чыккан кылыч
белән аларга каршы көрәшермен. 17 Рухның бердәмлекләргә
әйткәнен колагы булган ишетсен. Җиңүчегә серле манна** һәм
ак таш бирәчәкмен. Ул ташта исә, аны алучыдан башка һичкем
белмәгән яңа исем язылган булыр».

---

* 2:14 Бу хәл турында Тәүратның «Саннар» китабының 31:16 дан укырга мөмкин.

** 2:17 *Манна* – Аллаһы борынгы Исраил халкын Мисыр коллыгыннан чыгаргач, чүлдә туйдыру өчен күктән җибәргән ризык.

*Түәтәйрәдәге иман итүчеләр бердәмлегенә хат*

18 Түәтәйрә бердәмлегенең фәрештәсенә яз:
«Күзләре ут ялкыны кебек һәм аяклары ялтырап торган
бронза сыман булган Аллаһы Улы болай дип әйтә: 19 Синең эш-
ләреңне, мәхәббәтеңне, иманыңны, хезмәтеңне, сабырлыгың-
ны, һәм синең соңгы гамәлләрең беренчеләреннән яхшырак
булуын беләм. 20 Әмма сиңа каршы шелтәм бар: үзен пәйгамбәр
дип атаган Изебел исемле хатынга фәхешлеккә һәм потларга
корбан ителгән ризыкны ашарга өйрәтеп, Минем колларымны
юлдан яздырырга юл куясың. 21 Мин аңа, тәүбә кылсын дип,
вакыт бирдем, әмма ул үзенең фәхешлегеннән тәүбә итәргә те-
ләми. 22 Менә, Мин аны каты авыру түшәгенә салачакмын.
Һәм, аның гамәлләреннән баш тартмасалар, ул хатын белән
бергә зина кылучыларны зур кайгыга дучар итәчәкмен. 23 Аның
иярченнәрен үлемгә дучар итәчәкмен, һәм эчке уйларны, те-
ләкләрне тикшереп Белүче булуымны барча бердәмлекләр дә
беләчәкләр. Барыгызга да эшегезгә карата тиешлесен бирермен.
24 Аның тәгълиматын тотмаган һәм шайтанның тирән серләрен
белмәгән, Түәтәйрәдә яшәгән калган туганнарга исә моны әй-
тәм: сезгә башка йөк салмаячакмын. 25 Тик Мин килгәнгә ка-
дәр үзегездә булганны тотып торыгыз. 26 Җиңүчегә һәм Минем
эшләремне ахырга тикле үтәүчегә халыклар өстеннән хакимлек
итәргә бирәчәкмен.
27 Һәм ул алар өстеннән тимер таяк белән хакимлек
итәчәк*;
Алар балчык чүлмәк сыман ватылачаклар.
28 Ул Мин Атамнан алган шул ук хакимлекне алачак, һәм Мин
җиңүчегә таң йолдызы бирәчәкмен. 29 Рухның бердәмлекләргә
әйткәнен колагы булган ишетсен».

*Сәрдәйстәге иман итүчеләр бердәмлегенә хат*

3 1 Сәрдәйс бердәмлегенең фәрештәсенә яз:
«Аллаһының җиде рухы һәм җиде йолдызы булган Зат бо-
лай дип әйтә: Синең эшләреңне беләм; син тере исемен
йөртәсең, әмма син үле. 2 Уяу тор һәм үзеңдә калган, үләр дә-
рәҗәгә җиткән нәрсәләрне ныгыт, чөнки эшләреңнең Алла-
һым каршында тәмамланган булуын күрмим. 3 Шуңа күрә, нәр-
сә кабул кылганыңны, нәрсә ишеткәнеңне исеңә төшер, аны
үтә һәм тәүбә ит. Әгәр инде уяу тормасаң, Мин, карак кебек,

---

* 2:27 *Алар өстеннән хакимлек итәчәк* – грекча сүзгә-сүз «аларны көтәчәк», ягъни «аларга көтүче булачак». Шулай ук 12:5, 19:15 тә.

көтмәгәндә килермен һәм кайсы сәгатьтә килүемне син белмәс-
сең. [4] Ләкин, Сәрдәйстә киемнәрен пычратмаган берничә кешең
бар. Алар Минем белән ак киемдә йөриячәкләр, чөнки моңа
лаеклылар. [5] Шулай, җиңүче кеше ак кием киячәк һәм Мин
аның исемен Тормыш китабыннан сызып ташламаячакмын.
Атам һәм Аның фәрештәләре каршында җиңүченең исемен
икърар итәчәкмен. [6] Рухның бердәмлекләргә әйткәнен колагы
булган ишетсен».

*Филаделфеядәге иман итүчеләр бердәмлегенә хат*

[7] Филаделфея бердәмлегенең фәрештәсенә яз:
«Изге, Хакыйкый, кулында Давыт ачкычы* булган Зат – Ул
ачса, һичкем яба алмаячак; япса, һичкем ача алмаячак – болай
дип әйтә: [8] Синең эшләреңне беләм, менә Мин синең каршың-
да ишек ачтым, һәм аны һичкем яба алмаячак. Беләм, синең
көчең аз, әмма син Минем сүземне үтәдең, Минем исемемнән
ваз кичмәдең. [9] Шайтан гыйбадәтханәсеннән булган, үзләрен
яһүд дип атаучылар белән (ә алар яһүдләр түгел, бәлки ялган-
чылар) Мин болай эшләрмен – алар синең аякларыңа егыла-
чаклар һәм Минем сине сөйгәнемне беләчәкләр. [10] Син Минем
сабыр булу кирәклеге хакында әйткән сүземне саклап тотканга
күрә, җирдә яшәүчеләрне сынар өчен, бөтен җиһанга киләчәк
сынау вакытыннан Мин дә сине саклап калачакмын. [11] Тиздән
киләм: таҗыңны** һичкем тартып алмасын өчен, үзеңдә бул-
ганны нык тот. [12] Җиңүчене Мин Аллаһым Йортының баганасы
итеп куячакмын, һәм ул инде аннан чыкмаячак. Аның өстенә
Аллаһымның исемен һәм күктән, Аллаһымнан иңәчәк шәһәр-
нең – яңа Иерусалимның исемен һәм Үземнең яңа исемемне
язачакмын. [13] Рухның бердәмлекләргә әйткәнен колагы булган
ишетсен».

*Лаудикеядәге иман итүчеләр бердәмлегенә хат*

[14] Лаудикея бердәмлегенең фәрештәсенә яз:
«Амин дип аталган тугры һәм хакыйкый Шаһит, Аллаһы
булдырган нәрсәләрнең Чыганагы*** булган Зат болай дип
әйтә: [15] Синең эшләреңне беләм: син салкын да, кайнар да тү-
гелсең. Их, син салкын яисә кайнар булсаңчы! [16] Әмма син сал-
кын да, кайнар да түгел, җылымса гына булганга күрә, сине

* 3:7 *Давыт ачкычы* – Мәсихкә вәгъдә ителгән хакимлек итүнең символы.
** 3:11 *Таҗыңны* – ягъни «Аллаһы бирәчәк әҗереңне».
*** 3:14 *Чыганагы* – грек сүзенең икенче мәгънәсе: «Хаким».

авызымнан төкереп чыгарачакмын! 17 Син: „Мин бай һәм бае-
дым, һичбер нәрсәгә мохтаҗлыгым юк“, – дисең. Әмма син
үзеңнең барысыннан да бәхетсез, мескен, фәкыйрь, сукыр һәм
ялангач булуыңны аңламыйсың. 18 Шуңа күрә, үзеңә, баер
өчен, Миннән утта чистартылган алтын, ялангачлыгыңның
мәсхәрәлеге ачылмасын өчен, киенергә ак кием, һәм, күзләрең
күрсен өчен, сөртергә күз мае сатып алырга киңәш итәм.
19 Мин Үзем яраткан һәркемнең гаебен фаш итәм һәм аны тәр-
типкә өйрәтәм. Шулай итеп, тырышлык күрсәт һәм тәүбә ит.
20 Менә, Мин ишек төбендә шакып торам. Кем тавышымны
ишетеп һәм ишеген ачса, Мин аның янына керәчәкмен һәм
аның белән ашаячакмын, ә ул Минем белән ашаячак. 21 Мин
җиңеп чыктым һәм, Атам белән бергә, Аның тәхетенә утыр-
дым. Шулай ук, җиңүчегә Үзем белән бергә тәхетемә утыру хо-
кукы бирәчәкмен. 22 Рухның бердәмлекләргә әйткәнен колагы
булган ишетсен».

*Күктәге тәхет*

**4** 1 Шуннан соң күрәм: менә, күктә ачык ишек, һәм моңар-
чы миңа сөйләгән быргыдай тавыш әйтте: «Монда мен.
Мин сиңа моннан ары булырга тиешле нәрсәләрне күр-
сәтермен». 2 Шул мизгелдә үк мине Рух биләп алды. Һәм менә,
күктә тәхетне һәм тәхеттә Утыручыны күрдем. 3 Утыручы кыя-
фәте белән яшма һәм сердолик ташы сыман иде, тәхетне зө-
бәрҗәт төсендәге яктылык боҗрасы әйләндереп алган иде. 4 Бу
тәхет әйләнәсендә егерме дүрт тәхет тора иде, ул тәхетләрдә ак
киемнән, башларына алтын таҗ кигән егерме дүрт аксакал уты-
ра иде. 5 Тәхет ягыннан яшен яшьни, авазлар һәм күк күкрәгән
тавышлар чыга иде. Ә тәхет алдында Аллаһының җиде рухы
булган җиде ут яктырткычы янып тора иде. 6 Тәхет каршында
кристаллга охшаулы пыяла диңгез сыман нәрсә бар; һәм тә-
хетнең дүрт ягында дүрт җан иясе тора иде. Ул җан ияләренең
аллары һәм артлары күп күзләр белән тулы иде. 7 Беренче җан
иясе арысланга, икенчесе үгез бозауга охшаган, өченчесенең
йөзе кешенеке кебек, дүртенчесе исә очып баручы бөркет сы-
ман иде. 8 Һәрберсе алты канатлы, канатларының тышы һәм
эче күзләр белән тулы бу дүрт җан иясе:

«Изге, изге, изге,
Булган, Бар булучы һәм Киләчәк
Чиксез кодрәт Иясе Раббы Аллаһ!» –

дип бертуктаусыз көне-төне кабатлыйлар. 9 Җан ияләре тәхет-
тә Утыручы мәңге Яшәүчегә дан, хөрмәт һәм рәхмәт белдер-
гән вакытта, 10 егерме дүрт аксакал, тәхеттә Утыручы каршында

йөзтүбән капланып, мәңге Яшәүчегә сәҗдә кылалар һәм тажларын тәхет алдына салып куялар һәм болай диләр:

11 «Раббы Аллаһыбыз!
Син дан, хөрмәт һәм кодрәт кабул итәргә лаеклы.
Чөнки һәммә нәрсәне Син яраттың,
Һәм барысы да Синең ихтыярың белән булдырылды
һәм гамәлдә тора!»

*Җиде мөһер сугылган язма төргәге һәм Бәрән*

5 [1] Шуннан соң мин тәхеттә Утыручының уң кулында эчке
һәм тышкы ягына язылган һәм җиде мөһер белән мөһер-
ләнгән язма төргәген* күрдем. [2] Һәм көчле тавыш белән:
«Мөһерләрен кубарып, язма төргәген ачарга кем лаеклы?» — дип
игълан итүче көчле фәрештәне күрдем. [3] Әмма күктә дә, җирдә
дә, җир астында да язма төргәген ачарга һәм аңа карарга лаек-
лы һичкем булмады. [4] Язма төргәген ачарга һәм аңа карарга
лаеклы кеше табылмаганлыктан, мин бик нык еладым. [5] Шунда
аксакалларның берсе миңа әйтте: «Елама. Менә, Яһүд нәселен-
нән, Давыт токымыннан булган Арыслан җиңеп чыкты. Язма
төргәгенең җиде мөһерен кубарып, Ул аны ача ала».
[6] Шуннан соң күрдем: менә, тәхет белән дүрт җан иясе
арасында һәм аксакаллар арасында Бәрән тора. Ул суелган
кебек иде. Аның җиде мөгезе һәм җиде күзе бар иде. Болар —
бөтен җиргә җибәрелгән Аллаһы рухлары. [7] Ул, килеп, тә-
хеттә Утыручының уң кулыннан язма төргәген алды. [8] Бәрән
язма төргәген алгач, дүрт җан иясе һәм егерме дүрт аксакал
Аның алдында йөзтүбән капландылар. Аларның һәрберсендә
арфа һәм хуш исле сумала (ягъни Аллаһы изгеләренең дога-
лары) белән тулы алтын касәләр бар иде. [9] Алар яңа җыр
җырладылар:

«Син язма төргәген алырга,
аның мөһерләрен кубарырга лаеклы.
Чөнки Син корбан итеп суелдың
һәм Үзеңнең каның белән
Һәр кабиләдән һәм телдән,
халыктан һәм милләттән
Аллаһы өчен кешеләрне йолып алдың.

10 Аларны Аллаһыбызга хезмәт итү өчен патшалар һәм
руханилар иттең;
алар җирдә патшалык итәчәкләр».

---

* 5:1 *Язма төргәге* — ул заманда язмалар төргәк формасында булган (русча — свиток).

[11] Тәхет, җан ияләре һәм аксакаллар әйләнәсендә күп фә-
рештәләрне күрдем һәм аларның тавышын ишеттем. Аларның
саны йөзләрчә миллион һәм дистәләрчә меңнәр иде. [12] Алар:

«Суелган Бәрән кодрәт,
байлык, тирән гакыл,
куәт, хөрмәт, дан
Һәм мактау алырга лаеклы», —

дип көчле тавыш белән әйтә иделәр.
[13] Күктә һәм җирдә, җир астында һәм диңгездә һәммә яра-
тылган затның һәм анда булган һәммә нәрсәнең:

«Тәхеттә Утыручыга
һәм Бәрәнгә мәңге-мәңге мактау,
хөрмәт, дан һәм кодрәт булсын», —

дип әйтүләрен ишеттем. [14] Дүрт җан иясе: «Амин», — дип әй-
тә иделәр, һәм аксакаллар йөзтүбән капланып сәҗдә кыла
иделәр.

*Бәрән алты мөһерне кубара*

6 [1] Аннары мин Бәрәннең мөһерләрнең берсен кубаруын
күрдем, һәм җан ияләренең берсенең күк күкрәгәндәй та-
выш белән: «Кил!» — дип әйтүен ишеттем. [2] Менә, мин ак
ат күрдем; һәм кулына җәя тоткан җайдагына таҗ бирелде. Ул
җайдак җиңүче булып, җиңү өчен чыкты.
[3] Бәрән икенче мөһерне кубаргач, мин икенче җан иясенең:
«Кил!» — дигәнен ишеттем. [4] Шуннан соң уттай җирән ат чык-
ты. Аның җайдагына, берсен-берсе үтерсеннәр өчен, барлык
җиһанның тынычлыгын алырга вәкаләт бирелде. Һәм аңа зур
кылыч бирелде.
[5] Бәрән өченче мөһерне кубаргач, мин өченче җан иясенең:
«Кил!» — дигән тавышын ишеттем. Һәм кара ат күрдем, ә аның
өстендәге җайдак үз кулына үлчәү тоткан иде. [6] Җан ияләре
арасыннан тавыш сыман чыккан авазны ишеттем: «Бер ди-
нарга бер савыт* бодай, бер динарга өч савыт арпа. Әмма
зәйтүн агачларына һәм йөзем бакчаларына зыян китермә!»
[7] Бәрән дүртенче мөһерне кубаргач, дүртенче җан иясенең:
«Кил!» — дигән тавышын ишеттем. [8] Һәм аксыл төстәге атны
күрдем. Аның өстендәге җайдакның исеме «Үлем», ә аның ар-
тыннан бөтен үлем патшалыгы килә иде. Аларга җиһанның

---

* 6:6 *Савыт* — сүзгә-сүз «хойникс», бер кешегә бер көн туклану өчен җитә торган күләм. Бу пәйгамбәрлектә кешенең бер көнлек хезмәт хакын тәшкил иткән бер динарга бары тик бер савыт бодай алып булачагы турында язылган.

дүрттән бер өлешендәге кешеләрне кылыч, ачлык, үләт һәм
кыргый хайваннар белән үтерергә хакимлек бирелде.
[9] Бәрән бишенче мөһерне кубаргач, корбан китерү урыны
астында Аллаһы сүзе өчен һәм шаһитлек биргәннәре өчен үте-
релгәннәрнең җаннарын күрдем. [10] Алар көчле тавыш белән:
«Кайчанга кадәр Син, изге һәм хакыйкый Хөкемдар, җирдә
яшәүчеләрне хөкем итмәссең һәм безнең каныбыз өчен үч ал-
массың?» – дип кычкырдылар. [11] Аларның һәрберсенә ак кием
бирелде. Һәм алар кебек үк үтереләчәк хезмәттәшләренең һәм
имандашларының саны тулганга тикле тагын бераз тынычла-
нып торырга кушылды.
[12] Мин, Бәрән алтынчы мөһерне кубаргач, көчле итеп җир
тетрәвен, кояшның матәм кием кебек каралуын, айның кан
кебек кызыл төскә керүен күрдем. [13] Инҗир агачының өлгермә-
гән җимешләре көчле җилдән коелган кебек, җиргә күк йол-
дызлары атылдылар. [14] Күк, кульязма төргәге кебек бөтерелеп,
юкка чыкты. Барлык таулар һәм утраулар үз урыннарыннан
кузгатылдылар.
[15] Җирнең патшалары, түрәләре, гаскәриләр башлыклары, бай-
лары, куәтлеләре – барысы да: һәр кол, һәр ирекле кеше таулар-
дагы мәгарәләрдә һәм таш кыялар арасында яшеренделәр. [16] Һәм
алар әйттеләр: «Өстебезгә авып төшегез һәм безне тәхеттә Уты-
ручының йөзеннән һәм Бәрәннең ачуыннан яшерегез! [17] Чөнки
Аларның бөек ачу көне килде. Моңа каршы кем тора алсын?»

### *Мөһер сугылган 144 мең кеше*

**7** [1] Шуннан соң мин җирнең дүрт почмагында торучы дүрт
фәрештәне күрдем. Алар җиргә, диңгезгә һәм бер генә
агачка да исмәсен дип, җирнең дүрт җилен тотып торалар
иде. [2-3] Мин үзендә тере Аллаһының мөһере булган көнчыгыш-
тан күтәрелүче башка фәрештәне күрдем. Ул җиргә һәм диңгезгә
зыян китерергә вәкаләт бирелгән дүрт фәрештәгә көчле тавыш
белән: «Без Аллаһыбызның хезмәтчеләренең маңгайларына мө-
һер сукканыбызга тикле җиргә, диңгезгә һәм агачларга зыян
китермәгез», – дип кычкырып эндәште. [4] Һәм мин мөһер сугыл-
ган кешеләрнең санын ишеттем. Бөтен Исраил кабиләләреннән
мөһерләнгән кешеләрнең саны бер йөз кырык дүрт мең иде:

[5] Яһүд кабиләсеннән мөһерләнгән унике мең кеше,
Рубин кабиләсеннән унике мең кеше,
Гәд кабиләсеннән унике мең кеше,
[6] Ашер кабиләсеннән унике мең кеше,
Нафтали кабиләсеннән унике мең кеше,
Менаше кабиләсеннән унике мең кеше,

7 Шимун кабиләсеннән унике мең кеше,
Леви кабиләсеннән унике мең кеше,
Исәскәр кабиләсеннән унике мең кеше,
8 Зебулун кабиләсеннән унике мең кеше,
Йосыф кабиләсеннән унике мең кеше,
Биньямин кабиләсеннән унике мең кеше мөһерләнде.

*Ак киемгә киенгән зур халык төркеме*

9 Шуннан соң, бихисап күп кеше басып торганын күрдем;
аларны һичкем санап чыга алмас иде! Алар һәр милләттән, ка-
биләдән, халыктан һәм телдән иделәр. Ул кешеләр ак кием-
нәргә киенгәннәр, кулларына хөрмә ботаклары тотып, тәхет
һәм Бәрән алдында басып торалар иде. 10 Алар:
«Котылу тәхеттә утыручы Аллаһыбыздан
һәм Бәрәннән килә!» –
дип кычкырып әйттеләр. 11 Тәхет тирәли, аксакаллар һәм дүрт
җан иясе тирәли баскан фәрештәләр тәхет алдында йөзтүбән
капландылар һәм Аллаһыга сәҗдә кылып әйттеләр:
12 «Амин! Аллаһыбызга мактау һәм дан,
тирән гакыл һәм рәхмәт,
хөрмәт, кодрәт һәм куәт мәңге булсын! Амин».
13 Шунда аксакалларның берсе миннән: «Бу ак киемгә киен-
гән кешеләр кемнәр алар һәм каян килгәннәр?» – дип сорады.
14 Мин аңа: «Әфәндем, син беләсең», – дидем. Ул миңа әйтте:
«Алар зур газап кичереп килгәннәр һәм киемнәрен Бәрәннең
каны белән юып агарткannar. 15 Шуңа күрә
Алар Аллаһы тәхете алдында торалар,
Аның Йортында Аңа көне-төне хезмәт итәләр.
Тәхеттә Утыручы алар өстендә Үзенең чатырын корачак.
16 Алар һичкайчан ачыкмаслар, һичкайчан сусамаслар.
Аларны кояш та, эсселек тә көйдермәс.
17 Чөнки тәхет уртасындагы Бәрән аларга Көтүче булачак,
Аларны тереклек суы чишмәләренә алып барачак.
Аллаһы аларның һәр күз яшен сөртәчәк».

*Җиденче мөһер һәм алтын төтәсләү савыты*

8 1 Бәрән җиденче мөһерне кубаргач, ярты сәгать чамасы
булыр, күктә тынлык урнашты. 2 Мин Аллаһы алдында
басып торган җиде фәрештәне күрдем, аларга җиде быр-
гы бирелде.
3 Һәм алтын төтәсләү савыты тоткан бүтән фәрештә изге өс-
тәл каршына килеп басты. Аңа тәхет алдындагы алтыннан
ясалган изге өстәлгә Аллаһының барлык изгеләренең догалары

белән бергә куярга дип, күп хуш исле сумала бирелде. [4] Менә
Аллаһы каршында фәрештә кулыннан ул изгеләрнең догалары
белән бергә хуш исле сумала төтене күтәрелде. [5] Фәрештә тө-
тәсләү савытын алды һәм аны, корбан китерү урынындагы ут
белән тутырып, җиргә ташлады. Шуннан соң, күк күкрәүләр,
дөмбердәгән тавышлар ишетелде, яшен яшьнәде, җир тетрәде.

*Җиде фәрештәнең җиде быргысы*

[6] Җиде быргысы булган җиде фәрештә быргы кычкыртырга
әзерләнде. [7] Беренчесе быргысын кычкыртты: кан катнаш боз
һәм ут хасил булды, һәм алар җиргә ыргытылды. Җирнең өчтән
бер өлеше, агачларның өчтән бер өлеше һәм бөтен яшел үлән
янып бетте.

[8] Менә икенче фәрештә быргысын кычкыртты: ут чорнаган
гаять зур тауга охшаулы нәрсәдер диңгезгә ыргытылды; диңгез-
нең өчтән бер өлеше канга әверелде. [9] Диңгездә яшәүче җан-
варларның өчтән бер өлеше һәлак булды. Корабларның да өчтән
бер өлеше һәлак ителде.

[10] Менә өченче фәрештә быргысын кычкыртты: елгаларның
өчтән бер өлешенә һәм чишмәләргә, яктырткыч кебек янып,
күктән зур йолдыз төште. [11] Ул йолдызның исеме – Әрем. Су-
ларның өчтән бер өлеше әрем сыман әче булды. Бу әче судан
кешеләрнең күбесе үлде.

[12] Менә дүртенче фәрештә быргысын кычкыртты: кояшның,
айның, йолдызларның өчтән бер өлешенә зарар килде, шун-
лыктан аларның яктылыкларының өчтән бер өлеше караңгы-
ланды. Шулай итеп, көн үзенең яктылыгының өчтән бер өлешен
югалтты, шулай ук төн дә.

[13] Шунда мин күктә, югарыда очып барган бөркетне күрдем.
Аның: «Калган өч фәрештә кычкыртачак быргы тавышы арка-
сында җирдә яшәүчеләргә кайгы, кайгы, кайгы!» – дип көчле
итеп кычкырганын ишеттем.

**9** [1] Менә бишенче фәрештә быргысын кычкыртты. Һәм мин
күктән җиргә төшкән йолдызны күрдем. Аңа упкын* кое-
сының ачкычы бирелде. [2] Йолдыз упкын коесын ачып җи-
бәрде. Гаять зур мичтән чыккан төтен кебек коедан күтәрел-
гән төтеннән кояш белән һава караңгыланды. [3] Төтеннән җир-
гә саранчалар чыкты. Аларга, җирдәге чаяннарда булган кебек,
чагу сәләте бирелде. [4] Аларга җирдәге үләнгә, төрле яшеллеккә
һәм төрле агачка зыян китермәскә, фәкать маңгайлары Аллаһы

---

* **9:1** *Упкын* – шул чорда яшәүчеләр аңлавынча, явыз рухларны хө-
кем көненә кадәр ябып тоту урыны.

мөһере белән мөһерләнмәгән кешеләргә генә зарар китерергә
боерылды. [5] Аңа кешеләрне үтермәскә, бары тик биш ай буе
аларны газапларга хокук бирелде. Кешенең ул газаплары чаян
чаккандагы кебек. [6] Ул көннәрдә кешеләр үлем эзләрләр, ләкин
аны тапмаслар; үләргә теләрләр, әмма үлем алардан качар.

[7] Саранчалар исә кыяфәте белән сугышка әзерләнгән атлар
кебек иде. Аларның башларында алтын таҗ сыман нәрсә бар, ә
йөзләре кешенеке сыман иде. [8] Чәчләре хатын-кызныкы сы-
ман, ә тешләре арысланныкы кебек иде. [9] Аларның өсләрендә
тимер көбә сыман күкрәкчәләре бар иде, ә канатларының та-
вышы сугышка ыргып чапкан атлы сугыш арбаларыннан чык-
кан тавыш кебек иде. [10] Аларның чаянныкы кебек койрыклары
һәм чаккычлары бар иде, һәм аларга шушы койрыклары белән
биш ай буе кешеләрне газапларга хак бирелде. [11] Саранчалар-
ның патшасы исә – упкын фәрештәсе; аның исеме яһүд телен-
дә «Абаддун», грек телендә «Аполлуон»*.

[12] Беренче кайгы үтте, менә аның артыннан тагын икесе килә!

[13] Менә алтынчы фәрештә быргысын кычкыртты, һәм мин
Аллаһы алдында торучы, хуш исле сумала яндыру өчен алтын-
нан ясалган изге өстәлнең дүрт мөгезеннән килгән тавышны
ишеттем. [14] Ул тавыш исә быргысы булган алтынчы фәрештәгә:
«Бөек Фөрат елгасы янында бәйләнгән дүрт фәрештәне азат
ит», – диде. [15] Һәм, кешеләрнең өчтән бер өлешен үтерер өчен,
бу сәгатькә, көнгә, айга һәм елга әзерләп торган фәрештәләр
азат ителделәр. [16] Атлы гаскәрнең саны ике йөз миллион иде.
Мин аларның санын ишеттем. [17] Күренештә атларны һәм җай-
дакларны мин болай итеп күрдем: җайдакларның күкрәкчәләре
уттай кызыл, куе зәңгәр һәм күкерт кебек саргылт төстә иде-
ләр. Атларның башлары арыслан башы сыман, авызларыннан
исә ут, төтен һәм күкерт бөркелеп тора иде. [18] Кешеләрнең өч-
тән бер өлеше шушы өч бәла-казадан: атларның авызыннан
чыккан уттан, төтеннән һәм күкерттән үтерелде. [19] Чөнки ат-
ларның көче авызларында һәм койрыкларында; аларның кой-
рыклары елан сыман һәм башлы иде. Шул башлары белән алар
кешеләрне чагалар иде.

[20] Бу бәла-казадан үлми калган кешеләр исә кылган гамәл-
ләреннән тәүбә итмәделәр. Алар җеннәргә һәм күрә, ишетә,
йөри алмаган алтын, көмеш, бронза, таш һәм агач потларга
табынуларыннан ваз кичмәделәр. [21] Бу кешеләр үзләренең үте-
рүләреннән, сихерләүләреннән, фәхешлекләреннән, урлашула-
рыннан тәүбә итмәделәр.

---

* 9:11 *Абаддун, Аполлуон* – «Җимерүче» мәгънәсендә.

### *Язма төргәге тоткан фәрештә*

10 [1] Шуннан соң мин күктән төшүче икенче бер кодрәтле
фәрештәне күрдем. Ул болытка төренгән, ә баш өстен-
дә яктылык бәжрасы бар иде. Аның йөзе кояш кебек,
аяклары утлы багана сыман иде. [2] Кулында ачылган кечкенә
язма төргәге бар иде. Ул уң аягы белән диңгезгә, сул аягы бе-
лән җиргә басты [3] һәм арысландай көчле тавыш белән кыч-
кырып җибәрде. Ул кычкыргач, җиде күк күкрәү тавыш би-
реп, нәрсәдер әйттеләр. [4] Җиде күк күкрәү әйткәч, мин аны
язарга ниятләдем. Әмма күктән килгән авазның: «Җиде күк
күкрәүнең сөйләгәннәрен сер итеп сакла һәм язма», – дигәнен
ишеттем.
[5] Ә диңгездә һәм җирдә басып торучы мин күргән фәрештә
уң кулын күккә күтәрде [6] һәм күкне, шулай ук анда булган һәр-
нәрсәне, җирне һәм анда булган һәрнәрсәне, диңгезне һәм ан-
да булган һәрнәрсәне Булдырган мәңге Яшәүче белән ант итте:
«Тоткарлау бүтән булмаячак, [7] җиденче фәрештә үзенең быргы-
сын кычкыртачак көнне, Аллаһы Үзенең колларына – пәйгам-
бәрләренә игълан иткәнчә, Аның сере гамәлгә ашкан булыр».
[8] Аннан соң, инде моңарчы ишеткән, күктән килгән аваз та-
гын миңа әйтте: «Бар, диңгездә һәм җирдә торучы фәрештәнең
кулыннан ачылган язма төргәген ал». [9] Мин фәрештә янына
килеп, аның миңа шул кечкенә язма төргәген бирүен үтендем.
Ул миңа әйтте: «Аны алып аша. Ашказаныңда аннан әче булыр,
әмма авызыңда бал кебек татлы булыр». [10] Мин фәрештәнең
кулыннан кечкенә язма төргәген алып ашадым. Авызымда ул
бал кебек татлы булды, ләкин, ашап бетерүемә, ашказанымда
аннан әче булды. [11] Аннары миңа әйттеләр: «Син күп халыклар,
милләтләр, телләр һәм патшалар хакында тагын пәйгамбәрлек
итәргә тиешсең».

### *Ике шаһит*

11 [1] Миңа үлчәү таягы сыман камыш сабагы бирелде һәм
әйтелде: «Бар, Аллаһы Йортын һәм корбан китерү уры-
нын үлчә, андагы табынучыларны санап чык. [2] Әмма
Аллаһы Йортының тышкы ишегалдын хисапка кертмә һәм үл-
чәмә, чөнки ул мәҗүсиләргә бирелгән. Алар изге Иерусалим
шәһәренең урамнарын кырык ике ай буе таптап йөриячәкләр.
[3] Мин Үземнең ике шаһитемә вәкаләт бирәчәкмен һәм алар,
матәм киемнәре киеп, бер мең ике йөз алтмыш көн буе пәй-
гамбәрлек итәчәкләр». [4] Бу шаһитләр – ике зәйтүн агачы һәм
бөтен җир Раббысы алдында торучы ике яктырткыч. [5] Әгәр

берәрсе аларга зыян китерергә ниятләсә, ул чакта аларның
авызларыннан ут чыгачак, һәм аларның дошманнарын йота-
чак. Аларга зыян китерергә ниятләгән кеше шулай үтерелергә
тиеш. 6 Пәйгамбәрлек иткән вакытта яңгыр яумасын дип, алар-
ның күкне капларга вәкаләтләре бар. Канга әйләндерү өчен
аларның сулар өстеннән вәкаләтләре бар. Һәм үзләре кайчан
теләсә, шул чакта җиргә һәртөрле бәла-казалар белән зыян
китерергә вәкаләтләре бар.

7 Шаһитлек бирүләрен тәмамлагач, упкыннан җанвар күтәре-
леп чыгачак, аларга каршы сугышачак, аларны җиңәчәк һәм
үтерәчәк. 8 Бу ике шаһитнең гәүдәсе аларның Раббысы хачка
кадакланган бөек шәһәр урамында ятачак. Ул шәһәрнең исеме
кинаяләп „Сәдүм“ һәм „Мисыр“ дип атала. 9 Бу мәетләргә өч
көн ярым буе төрле халыклардан, кабиләләрдән, телләрдән
һәм милләтләрдән булган кешеләр караячаклар. Ул мәетләрне
кабергә салырга рөхсәт итмәячәкләр. 10 Җирдә яшәүчеләр моңа
шатланачаклар һәм күңел ачачаклар, бер-беренә бүләкләр җибә-
рәчәкләр, чөнки бу ике пәйгамбәр җирдә яшәүчеләрне күп га-
заплаган иделәр.

11 Әмма өч көн ярым үткәч, аларга Аллаһыдан яшәү тыны
керде һәм алар аякларына торып бастылар. Аларны күрүче-
ләрне бөек курку басты. 12 Шуннан соң шаһитләр күктән көчле
тавышның: «Монда күтәрелегез», – дип әйтүен ишеттеләр. Алар
күккә болытта күтәрелделәр, ә дошманнары аларга карап торды.

13 Шул вакытта ук көчле итеп җир тетрәде һәм шәһәрнең ун-
нан бер өлеше җимерелде. Җир тетрәүдән җиде мең кеше үлде,
ә калганнары бик нык куркыштылар һәм күкләр Аллаһысын
данладылар.

14 Икенче кайгы үтте, менә аның артыннан өченчесе килә!

*Җиденче быргы*

15 Җиденче фәрештә быргысын кычкыртты. Һәм күктә:
«Дөнья патшалыгы инде Раббыбызның
һәм Аның Мәсихенең Патшалыгы булды.
Раббы мәңге патшалык итәчәк!» –
дип әйтүче көчле тавышлар яңгырады. 16 Аннары, Аллаһы ал-
дында үз тәхетләрендә утыручы егерме дүрт аксакал, йөзтүбән
капланып, Аллаһыга сәҗдә кылдылар һәм 17 әйттеләр:
«Бар булучы, Булган, Чиксез кодрәт Иясе Раббы
Аллаһы,
Сиңа шөкрана итәбез!
Чөнки Син Үзеңнең бөек кодрәтеңне гамәлгә керттең
һәм патшалык итә башладың.

18 Халыклар ярсыдылар.
Синең ачу көнең килде
һәм үлеләрне хөкем итү вакыты җитте.
Синең хезмәтче пәйгамбәрләреңә, изге кешеләреңә,
Исемеңнән куркучы кечкенәләргә һәм зурларга
әҗер бирү вакыты,
Җирне һәлак итүчеләрне
һәлак итү вакыты җитте!»

19 Шуннан соң күктә Аллаһы Йорты ачылды һәм анда Аның
килешү сандыгы* күренде. Шунда яшен яшьнәде, дөмбердәгән
тавышлар ишетелде, күк күкрәүләр, җир тетрәү булды һәм бик
көчле итеп боз яуды.

*Хатын һәм аждаһа*

12 1 Күктә бөек галәмәт күренде: менә кояшка төренгән
хатын; аның аяклары астында ай, башында унике йол-
дызлы таҗ иде. 2 Хатын йөкле булып, бала тудыру газап-
ларыннан һәм авыртудан кычкыра иде. 3 Күктә бүтән галәмәт
күренде: менә җиде башлы һәм ун мөгезле кызыл төстәге гаять
зур аждаһа; аның һәр башында кечкенә таҗ иде. 4 Койрыгы күк
йолдызларының өчтән бер өлешен себереп, аларны җиргә ат-
ты. Хатын баласын тудыру белән, аның баласын ашар өчен,
аждаһа бала тудыру халәтендә булган хатын алдына басты.
5 Менә хатын, барлык халыклар өстеннән тимер таяк белән ха-
кимлек итәргә тиешле ир бала тудырды. Хатынның баласы
Аллаһыга һәм Аның тәхете алдына тотып китерелде. 6 Ә хатын
чүлгә качты. Анда аңа мең ике йөз алтмыш көн буе кайгырту
астында булу өчен Аллаһы әзерләп куйган урын бар иде.

7 Шуннан соң күктә сугыш башланды: Микаил үзенең фә-
рештәләре белән аждаһага каршы сугышты. Аждаһа да үзенең
явыз фәрештәләре белән аларга каршы сугышты. 8 Әмма аж-
даһа җиңелде һәм үзенең явыз фәрештәләре белән моннан
ары күктә кала алмады. 9 Бу зур аждаһа, бөтен дөньяны ал-
даучы, иблис һәм шайтан дип аталган борынгы елан, җиргә
бәреп төшерелде; аның белән бергә явыз фәрештәләре дә бә-
реп төшерелделәр. 10 Шуннан соң, мин күктә көчле тавыш
ишеттем:
«Менә Аллаһыбызның коткаруы, кодрәте, патшалыгы
һәм Аның Мәсихенең хакимлеге урнашты!
Чөнки Аллаһыбыз алдында көне-төне имандашларыбызны
гаепләүче бәреп төшерелде.

---

* 11:19 *Килешү сандыгы* – сүзлекне карагыз.

11 Туганнарыбыз аны Бәрән каны белән
һәм Гайсә хакындагы шаһитлек сүзләре белән
җиңделәр,
Хәтта, үлемнән курыкмыйча,
үзләренең җаннарын аямадылар.
12 Шуңа күрә, күкләр
һәм анда яшәүчеләр, куанычгыз!
Әмма җиргә һәм диңгезгә кайгы,
чөнки иблис, вакыты аз калганын белеп,
Көчле ярсу белән сезгә төште!»

13 Үзенең җиргә бәреп төшерелүен күргәч, аждаһа ир бала ту-
дырган хатынны куа башлады. 14 Хатынга исә, бу еланнан качып,
аның өчен чүлдә әзерләгән урынга очсын дип, зур бөркетнең
ике канаты бирелде. Ул анда вакыт*, вакытлар һәм ярты вакыт
буе кайгырту астында булачак. 15 Хатынны елга агызып китсен
дип, хатын артыннан елан үзенең авызыннан елга кебек су
агызды. 16 Әмма җир, авызын ачып, аждаһа авызыннан аккан
елганы йотып, хатынга ярдәм итте. 17 Аждаһа хатынга нык яр-
сыды, һәм хатынның Аллаһы әмерләрен үтәүче, Гайсә хакында
шаһитлек бирүче калган балаларына каршы сугышыр өчен кит-
те. 18 Шуннан соң аждаһа диңгез ярына басты.

*Диңгездән чыккан җанвар*

**13** 1 Шуннан соң мин диңгездән чыгучы, ун мөгезле һәм
җиде башлы җанварны күрдем. Аның мөгезләрендә ун
кечкенә таҗ, һәм башларында көфер исемнәр иде. 2 Мин
күргән җанвар капланга охшаган. Аның аяклары аюныкы сы-
ман, авызы исә арысланныкы кебек иде. Аждаһа аңа үзенең
көчен, тәхетен һәм зур вәкаләтен бирде. 3 Аның башларының
берсе үле дәрәҗәсендә яраланган иде, аннан соң, ул ярасы тө-
зәтелде. Бөтен җиһан гаҗәпкә калып, җанвар артыннан китте
4 һәм аждаһага сәҗдә кылды, чөнки җанварга ул вәкаләт биргән
иде. Кешеләр: «Кем җанвар кебек була алсын һәм аның белән
кем сугыша алсын?» — дип, җанварга да сәҗдә кылдылар.

5 Бу җанварга тәкәбберләнергә һәм көфер сүз сөйләргә ирек
куелды. Аңа кырык ике ай буе хакимлек итәргә бирелде. 6 Ул
Аллаһыга каршы көфер сүзләр әйтә башлады; Аның исемен,
Аның яшәгән урынын һәм күктә яшәүчеләрне көферли башла-
ды. 7 Җанварга Аллаһының изге кешеләренә каршы сугышырга
һәм аларны җиңәргә рөхсәт ителде. Аңа һәр кабилә, һәр ха-
лык, һәр тел һәм һәр милләт өстеннән хакимлек итәргә рөхсәт

* 12:14 *Вакыт* — бу урында, белгечләр фикеренчә, «ел» мәгънәсендә.

ителде. [8] Җирдә яшәүчеләрнең дөнья яратылганга кадәр исемнәре чалынган Бәрәннең Тормыш китабына язылмаган һәммәсе шушы җанварга табыначаклар.

[9] Колагы булган ишетсен:

10 Кем әсирлеккә төшәргә тиешле икән,
шул кеше әсирлеккә төшәчәк.
Кем кылыч белән үтерелергә тиешле икән,
шул кеше кылычтан үләчәк.

Монда Аллаһының изге кешеләренең сабырлыгы һәм иманы күренергә тиешле.

*Җирдән чыккан җанвар*

[11] Аннан соң җирдән чыгучы башка җанварны күрдем. Аның ике мөгезе бәрәннекенә охшаш һәм ул аждаһа кебек сөйли иде. [12] Ул беренче җанварның бөтен вәкаләте белән аның алдында гамәл кыла иде, җирне һәм анда яшәүчеләрне үлем дәрәҗәсендәге ярасы төзәлгән беренче җанварга табындырды. [13] Ул зур галәмәтләр эшли иде, хәтта кешеләр алдында күктән җиргә ут яудыра иде. [14] Ул беренче җанвар алдында эшләргә бирелгән галәмәтләре белән җирдә яшәүчеләрне алдый иде. Аларга кылычтан яраланган һәм терелгән җанвар сынын ясарга кушты. [15] Беренче җанварның сыны сөйләсен һәм аңа табынмаган һәркем үлемгә бирелсен өчен, икенче җанварга ул сынга җан кертергә рөхсәт ителде. [16] Һәм икенче җанвар кечеләрнең һәм бөекләрнең, байларның һәм фәкыйрьләрнең, иреклеләрнең һәм колларның уң кулларына яисә маңгайларына тамга салдырды. [17] Шушы тамгасы, ягъни җанвар исеменең тамгасы яки аның исеменең саны булмаган һәркем сатып та ала алмады һәм сата да алмады.

[18] Монда зирәклек кирәк. Акылы булган кеше җанварның санын хисаплап чыгарсын. Чөнки ул – кеше саны. Аның саны – алты йөз алтмыш алты.

*Бәрән һәм 144 мең кеше*

**14** [1] Шунда мин күрдем: менә Сион тавында Бәрән тора. Аның белән бергә маңгайларында Бәрәннең исеме һәм Аның Атасының исеме язылган йөз кырык дүрт мең кеше бар иде. [2] Шуннан соң мин күктән зур шарлавык тавышы сыман һәм көчле күк күкрәгән сыман тавыш килүен ишеттем. Мин ишеткән тавыш арфачылар уйнаган тавышка охшаган иде. [3] Алар тәхет алдында, дүрт җан иясе һәм аксакаллар алдында яңа җыр җырлыйлар иде. Ул җырны җирдә яшәгәннәр арасыннан йолып алынган йөз кырык дүрт мең кешедән башка һичкем

өйрәнә алмады. [4] Болар – хатын-кызлар белән нәҗесләнмәгән-
нәр; алар гыйффәтлеләр. Болар – Бәрән кайда гына барса, Аның
артыннан баралар. Алар кешеләр арасыннан йолып алынганнар,
Аллаһыга һәм Бәрәнгә багышланган беренче уңышлар иделәр.
[5] Аларның телләрендә ялган булмады, алар әхлаклы иделәр.

*Өч фәрештә*

[6] Җирдә яшәүче һәр милләткә, кабиләгә, телгә һәм халыкка
игълан итү өчен мәңгелек Яхшы хәбәре булган, югары күктә
очып барган башка фәрештәне күрдем. [7] Ул көчле тавыш бе-
лән: «Аллаһыдан куркыгыз һәм Аны данлагыз! Чөнки Аның
хөкем сәгате килде. Күкне, җирне, диңгезне һәм су чишмәлә-
рен Булдыручыга табыныгыз!» – диде.
[8] Икенче фәрештә дә: «Бөек Бабыл җимерелде, җимерелде!
Ул барча халыкларны үзенең тыелгысыз фәхешлек шәрабыннан
эчерткән», – дип, аңа иярде.
[9] Тагы бер фәрештә, өченчесе, аларга ияреп: «Кем җанварга
һәм аның сынына табына, үзенең маңгаена яки кулына җанвар
тамгасын кабул итә, [10] шул Аллаһының ачу касәсенә салынган
ярсу шәрабын, су кушылмаган шәрабын эчәчәк. Ул кеше изге
фәрештәләр һәм Бәрән алдында утлы күкерт эчендә газаплан-
дырылачак. [11] Аларның газаплану төтене мәңге күтәреләчәк.
Җанварга һәм аның сынына табынучы, аның исем тамгасын
кабул итүче һәркем көндез дә, төнлә дә газаптан тынгы күрмә-
ячәк». [12] Бу вакытларда Аллаһының әмерләрен үтәүче һәм Гай-
сәгә иман итүче изге кешеләрнең түземле булулары кирәк.
[13] Мин күктән килгән тавыш ишеттем: «Яз: „Шушы вакыттан
башлап үлүчеләр – Раббыга иман итеп үлүчеләр бәхетле“».
«Әйе, алар үзләренең михнәтләреннән ял итсеннәр, чөнки
аларның эшләре үзләре артыннан бара», – ди Рух.

*Җир уңышы*

[14] Шуннан соң мин ак болыт һәм болыт өстендә утыручы адәм
улына охшаган Затны күрдем. Аның башында алтын таҗы һәм
кулында үткен урагы бар иде. [15] Аллаһы Йортыннан тагын бер
фәрештә чыгып, болыт өстендә Утыручыга көчле тавыш белән:
«Үзеңнең урагыңны алып ур: урак өсте җитте, чөнки җир уңы-
шы өлгерде», – дип кычкырды. [16] Шуннан соң, болытта Утыру-
чы Үзенең урагын җир өстенә җибәрде һәм уңыш урылды.
[17] Аннары күктәге Аллаһы Йортыннан башка фәрештә чык-
ты. Аның да үткен урагы бар иде. [18] Корбан китерү урыныннан,
ут өстеннән хакимлеге булган башка фәрештә чыкты. Ул көчле
тавыш белән үткен урагы булган фәрештәгә: «Үзеңнең үткен

урагыңны җибәр һәм җир өстендәге йөзем тәлгәшләрен җый,
чөнки аның җимешләре өлгерде!» — диде. 19 Фәрештә үзенең
үткен урагын җиргә җибәрде һәм җирдәге йөземне җыеп, Ал-
лаһының гаять зур ачу изгеченә ташлады. 20 Ул йөзем шәһәр ар-
тында изгечтә тапталды. Изгечтән атларның йөгәненә кадәр
җиткән, бер мең алты йөз стадия* озынлыкта кан акты.

### *Җиде бәла-казалы җиде фәрештә*

**15** 1 Шуннан соң мин күктә бөек һәм искиткеч башка галә-
мәт билгесен — соңгы җиде бәла-казаны тотып торган
җиде фәрештәне күрдем. Ул бәла-казалар соңгылары иде,
чөнки Аллаһының ачуы шулар белән тәмамлана. 2 Һәм мин ут
белән пыяла катнашкан диңгез сыман нәрсәне күрдем. Пыяла
диңгез өстендә җанварны, аның сынын һәм аның исем санын
җиңеп чыкканнар кулларына Аллаһының арфаларын тотып то-
ралар иде. 3 Алар Аллаһы колы Мусаның җырын һәм Бәрәннең
җырын җырлыйлар иде:

«Чиксез кодрәт Иясе Раббы Аллаһы!
Синең эшләрең бөек һәм искиткеч.
Халыкларның Патшасы,
Синең юлларың гадел һәм хакыйкый.
4 Раббы! Синнән кем курыкмас,
Исемеңне кем данламас?
Чөнки тик бер Син генә изге.
Бөтен халыклар килеп,
Синең алдыңда сәҗдә кылачаклар,
Чөнки Синең гадел эшләрең ачылды».

5 Моннан соң мин күрдем: менә күктә шаһитлек чатырында-
гы изге урын ачылды. 6 Изге урыннан җиде бәла-казасы булган
җиде фәрештә чыкты. Алар чиста һәм ялтырап торган житен
кием кигәннәр һәм күкрәкләрен алтын пута белән буганнар
иде. 7 Дүрт җан иясенең берсе җиде фәрештәгә мәңге яшәүче
Аллаһының ачуы белән тулы җиде алтын касә бирде. 8 Изге
урын Аллаһы даныннан һәм кодрәтеннән төтен белән тулды,
һәм җиде фәрештәнең җиде бәла-казасы тәмамланмыйча, анда
һичкем керә алмады.

### *Аллаһы ярсуы тулы җиде касә*

**16** 1 Шуннан соң мин: «Барыгыз һәм җиргә Аллаһының
җиде ярсу касәсен түгегез», — дип, Аллаһы Йортыннан
җиде фәрештәгә сөйләүче көчле тавыш ишеттем.

---

* 14:20 *Бер мең алты йөз стадия* — өч йөз чакрым чамасы.

[2] Беренче фәрештә китте һәм үзенең касәсен җир өстенә
түкте. Җанвар тамгасы суктырган һәм аның сынына табынган
кешеләрдә чирканыч һәм яман җәрәхәтләр хасил булды.
[3] Икенче фәрештә үзенең касәсен диңгезгә түкте. Аның суы
үләт каны кебек булды, һәм диңгездәге барлык җан ияләре
үлделәр.
[4] Өченче фәрештә үзенең касәсен елгаларга, су чишмәләренә
түкте, һәм аларның суы канга әверелде. [5] Аннан соң, мин сулар
фәрештәсенең әйтүен ишеттем:

«Бар булучы, Булган һәм Изге!
Син шулай хөкем итеп, гадел эшләдең.
[6] Чөнки бу явыз кешеләр изгеләрнең, пәйгамбәрләрнең
канын койдылар,
һәм Син аларга кан эчәргә бирдең.
Алар моңа лаеклылар!»

[7] Мин корбан китерү урыны ягыннан килгән тавыш ишеттем:

«Әйе, Чиксез кодрәт Иясе Раббы Аллаһы!
Синең хөкемнәрең хакыйкый һәм гадел!»

[8] Дүртенче фәрештә үзенең касәсен кояш өстенә түкте һәм
кояшка кешеләрне ут белән көйдерергә бирелде. [9] Һәм кеше-
ләрне көчле эсселек көйдерде. Бу бәла-казалар өстеннән ха-
кимлеге булган Аллаһының исемен кешеләр хурладылар, әмма
тәүбә итмәделәр һәм Аны данламадылар.
[10] Бишенче фәрештә үзенең касәсен җанвар тәхете өстенә
түкте һәм аның патшалыгы караңгылыкка чумды. Кешеләр
авыртудан үзләренең телләрен тешләделәр, [11] сызлануларыннан
һәм җәрәхәтләреннән күк Аллаһысын хурладылар, әмма кыл-
ган эшләреннән тәүбә итмәделәр.
[12] Алтынчы фәрештә үзенең касәсен бөек Фөрат елгасына
түкте. Көнчыгыштан килүче патшаларга юл әзер булсын өчен
аның суы кипте. [13] Һәм мин аждаһаның, җанварның һәм ялган
пәйгамбәрнең авызларыннан чыккан гөберле бака сыман өч
шакшы рухны күрдем. [14] Алар – галәмәтләр күрсәтүче явыз рух-
лар. Алар бөтен җир патшаларын Чиксез кодрәт Иясе Аллаһы-
ның бөек көнендә сугышка җыяр өчен чыгалар.
[15] «Менә карак кебек көтмәгәндә киләм: ялангач йөрмәс
өчен һәм хурлыгын кешеләр күрмәсен өчен уяу торучы һәм
киемнәрен саклаучы кеше бәхетле!»
[16] Явыз рухлар патшаларны яһүд телендә «Һармагедун» дип
аталган урынга җыйдылар.
[17] Җиденче фәрештә үзенең касәсен һавага түкте, һәм Алла-
һы Йортыннан, тәхеттән: «Тәмамланды!» – дигән көчле тавыш
ишетелде. [18] Яшен яшьнәде, тавышлар, күк күкрәүләр булды.

Көчле итеп җир тетри башлады: җирдә кеше яши башлаганнан
бирле булмаган шундый көчле, шундый нык тетрәү булды!
19 Бөек шәһәр өч өлешкә бүленде һәм халыкларның шәһәрләре
җимерелде. Аллаһы бөек Бабылны искә төшерде һәм Үзенең
ярсулы ачу касәсеннән шәраб эчәргә бирде. 20 Һәр утрау юкка
чыкты, таулар җимерелделәр. 21 Күктән кешеләр өстенә зур-зур
боз кантарлары* ява башлады. Кешеләр бу бәла-каза өчен Ал-
лаһыны хурлый иделәр, чөнки ул ифрат та авыр иде.

*Фахишә һәм җанвар*

17 1 Колларында җиде касә булган фәрештәләрнең берсе
килде дә миңа әйтте: «Кил монда. Мин сиңа күп суларда
утыручы бөек фахишәгә булачак хөкем җәзасын күрсә-
термен. 2 Аның белән җир патшалары фәхешлек иттеләр, аның
фәхешлек шәрабыннан җирдә яшәүчеләр исергәнче эчтеләр».

3 Мине Рух биләп алды, һәм фәрештә мине чүлгә күчерде.
Мин җиде башлы һәм ун мөгезле, көфер исемнәр белән тулы
булган кызыл җанвар өстендә утыручы хатынны күрдем. 4 Ха-
тын шәмәхә һәм кызыл төстәге киемнәргә киенгән, алтын,
асылташлар һәм энҗе белән бизәлеп матурланган, кулына үзе-
нең фәхешлегенең чирканычлыгы һәм шакшылыгы тулы алтын
касә тоткан иде. 5 Аның маңгаена серле исем язылган: «Бөек
Бабыл – җир фахишәләренең һәм чирканыч нәрсәләрнең ана-
сы». 6 Мин хатынның изгеләр канынннан һәм Гайсә шаһитләре-
нең канынннан исергәнлеген күрдем. Аны күргәннән мин бик
нык гаҗәпләндем. 7 Фәрештә миңа әйтте: «Син нигә гаҗәплән-
деӊ? Мин сиңа хатынның һәм аны йөртүче җиде башлы һәм ун
мөгезле җанварның серен аңлатып бирәм. 8 Син күргән җанвар
бар иде, инде ул юк; ул упкыннан күтәрелеп чыгачак һәм һәлак
ителәчәк. Дөнья яратылганнан бирле исемнәре Тормыш кита-
бына язылмаган кешеләр җанварны күреп, гаҗәпләнәчәкләр,
чөнки ул бар иде, хәзер юк һәм янә булачак.

9 Монда зирәк акыл кирәк. Җиде баш – хатын утырган җиде
тау, шулай ук – җиде патша ул. 10 Ул патшаларның бишесе
һәлак булды, берсе бар, башкасы әле килмәгән. Килгәч, ул
озак булырга тиеш түгел. 11 Ә булган һәм хәзер булмаган җан-
вар – ул сигезенче патша. Ул – җиде патшаның берсе, һәм ул
һәлакәткә бара.

12 Син күргән ун мөгез – ун патша ул. Алар патшалыкларын
әле алмадылар. Әмма җанвар белән бергә, бер сәгатькә, патшалар

---

* 16:21 *Зур-зур боз кантарлары* – сүзгә-сүз «талант авырлыгындагы бозлар», бер талант – 40 кг чамасы.

дәрәҗәсендә хакимлек алачаклар. [13] Аларның ниятләре бер,
алар җанварга үзләренең көчләрен һәм хакимлекләрен тапшы-
рачаклар. [14] Алар Бәрән белән сугышачаклар һәм Бәрән аларны
җиңәчәк, чөнки Ул – хакимнәрнең Хуҗасы һәм патшаларның
Патшасы. Аның белән бергә булганнар исә чакырылганнар,
сайланганнар һәм тугрылар».

[15] Шуннан соң, фәрештә миңа әйтте: «Син күргән фахишә
утырган сулар исә – алар халыклар, төркемнәр, милләтләр һәм
телләр. [16] Син күргән ун мөгез һәм җанвар фахишәне нәфрәт
итәчәк һәм аны бөлгенлеккә төшерәчәк, ялангач калдырачак,
аның тәнен ашаячак һәм аны утта яндырачак. [17] Чөнки Аллаһы
аларның ниятләре бер булырга һәм үз патшалыкларын җанвар-
га тапшырырга, моның белән Үзенең ихтыярын үтәргә алар-
ның йөрәкләренә салган. Болар барысы Аллаһының сүзләре
тормышка ашканга кадәр булачак. [18] Ә син күргән хатын – җир
патшалары өстеннән патшалык итүче бөек шәһәр ул».

*Бабылның җимерелүе*

**18** [1] Болардан соң, мин күктән төшүче бөек вәкаләте бул-
ган башка фәрештәне күрдем. Аның даны белән җир
яктыртылды. [2] Фәрештә көчле тавыш белән кычкырды:

«Бөек Бабыл җимерелде, җимерелде!
Ул җеннәр торагына һәм төрле пакьсез рухлар,
пакьсез кошлар, төрле пакьсез һәм нәфрәт тудыргыч хайваннарга
сыену оясы булды.
3 Чөнки ул үзенең ярсулы фәхешлек шәрабыннан
барлык халыкларны эчертте,
һәм җир патшалары аның белән зина кылдылар.
Сәүдәгәрләр аның көчле нәфес теләгеннән баедылар».

[4] Мин күктән килгән башка тавышны ишеттем:

«Минем халкым, аның гөнаһларында катнашмас өчен
һәм аның бәла-казаларына дучар булмас өчен аннан чык.
5 Чөнки аның гөнаһлары күккә кадәр барып җитте
һәм Аллаһы аның җинаятьле эшләрен искә алды.
6 Ул ничек биргән булса,
сез дә аңа шулай кайтарыгыз,
эшләренә карата икеләтә бирегез.
Үзе әзерләгән касәдә аның үзенә икеләтә әзерләгез.
7 Ул үзен күпме данлаган булса,
җенси ләззәтлектә яшәгән булса,
шулкадәр аңа газап һәм кайгы бирегез!

Чөнки ул үзенең күңеленнән:
„Патша булып утырам, мин тол хатын түгел,
кайгыны да күрмәм!“ – дип әйтә.
8 Шуңа күрә аңа бер көндә бәла-казалар –
үлем, хәсрәт, ачлык киләчәк.
Һәм ул утта яндырылачак,
чөнки аны хөкем итүче Раббы кодрәтле!»
9 Аның белән зина кылган һәм женси теләкләрен канәгать-
ләндергән жир патшалары, аның януыннан чыккан төтенгә ка-
рап, аның хакында үкереп елаячаклар. 10 Аның газапларыннан
куркып, читтәрәк басып торачаклар һәм:
«Кайгы, кайгы сиңа, бөек һәм куәтле Бабыл шәһәре!
Чөнки сиңа бер сәгать эчендә хөкем килде», –
дип әйтәчәкләр.
11 Җир сәүдәгәрләре дә аның хакында елаячаклар һәм кайгы-
рачаклар, чөнки бүтән алардан беркем бернәрсә сатып алмый:
12 алтын һәм көмеш әйберләрен, асылташларын һәм энҗеләрен,
нәфис җитен, ефәк, куе кызыл һәм алсу төстәге тукымаларын,
һәртөрле кыйммәтле төрдәге агачларын һәм фил сөягеннән
ясалган әйберләрен, иң кыйммәтле агачтан, бронзадан, тимер-
дән һәм мәрмәрдән ясалган һәртөрле әйберләрен 13 һәм дарчин-
нарын, аш тәмләткечләрен, хуш исле майларын, ладаннарын,
шәрабларын, зәйтүн майларын, иң яхшы оннарын һәм иген-
нәрен, мал-туарларын, сарыкларын һәм атларын, арбаларын,
кеше гәүдәләрен һәм кеше җаннарын да алмый.
14 «Җаның теләгән яхшы әйберләр синнән киттеләр.
Синең барлык зиннәтлелегең һәм купшылыгың юк
булды;
Син аларны һичкайчан тапмаячаксың!»
15 Болар белән сәүдә итүчеләр һәм аннан баючылар, аның га-
запларыннан куркып, елап һәм инрәп читтәрәк торачаклар.
16 Алар: «Нәфис җитен, куе кызыл һәм алсу төстәге тукымалар-
га киенгән, алтын, асылташларга һәм энҗегә бизәлгән бөек
шәһәргә кайгы, кайгы! 17 Чөнки шундый күп байлык бер сәгать
эчендә юк булды», – диячәкләр.

Диңгездәге һәрбер кораб йөртүче һәм һәрбер йөзүче, диңгез-
челәр һәм диңгез кәсебеннән файда күрүчеләр еракта басып
тордылар. 18 Аның януыннан чыккан төтенгә карап: «Бу бөек
шәһәргә кайсы шәһәр тиң булсын!» – дип кычкырдылар.
19 Алар башларына тузан сиптеләр һәм елап:
«Кайгы, кайгы сиңа,
байлыгыңнан диңгездә кораблары булган
һәммә кеше баеган бөек шәһәр!

Чөнки син бер сәгать эчендә юкка чыктың», —
дип кайгырып кычкырдылар.
[20] Әй, күк һәм изгеләр, рәсүлләр һәм пәйгамбәрләр! Аның ха-
кында шатланыгыз, чөнки сезгә каршы кылган гамәлләре өчен
Аллаһы аны хөкем итте.
[21] Аннары бер көчле фәрештә тегермән ташы кебек зур таш
алып, аны диңгезгә ташлады һәм әйтте:
«Бөек шәһәр Бабыл шундый көч белән җимереләчәк
һәм мәңгегә юк булачак.
22 Арфада уйнаучылар һәм җырлаучылар,
сыбызгычылар һәм быргычылар тавышын синдә инде ишетмәсләр.
Бер генә һөнәр буенча да бер генә һөнәрчене табып булмас
һәм тегермән ташларының тавышы синдә ишетелмәс.
23 Яктырткыч уты синдә моннан ары яктыртмас,
кияү белән кәләш тавышлары моннан ары синдә ишетелмәс.
Чөнки синең сәүдәгәрләрең җирдә бөек булдылар,
синең сихереңә бөтен халыклар да алдандылар.
24 Ул шәһәрдә барлык пәйгамбәрләрнең, изгеләрнең
һәм җирдә үтерелгән барлык кешеләрнең каны табылды».

*Раббыны мактагыз!*

**19** [1] Аннан соң мин күктә зур халык төркеменнән чыккан
кебек көчле тавыш ишеттем. Алар әйттеләр:
«Раббыны мактагыз*!
Котылу, дан һәм кодрәт безнең Аллаһыбызныкы!
2 Чөнки Аның хөкемнәре хакыйкый һәм гадел:
җирне үзенең фәхешлеге белән бозыклыкка китергән
Бөек фахишәне Ул хөкем итте,
һәм Үзенең бәндәләренең каны өчен аннан үч алды».
[3] Һәм:
«Раббыны мактагыз!» —
дип кабатлап әйттеләр.
Аның газапларының төтене мәңге күтәрелә.
[4] Аннары, егерме дүрт аксакал һәм дүрт җан иясе йөзтүбән
капланып, тәхеттә утыручы Аллаһыга:
«Амин! Раббыны мактагыз!» —
дип, сәҗдә кылдылар.

---

* **19:1** *Раббыны мактагыз* — яһүд телендә: «Һалелуя».

[5] Тәхеттән тавыш килде:
«Аның барлык бәндәләре,
Аннан куркучылар, кечеләр һәм зурлар,
Безнең Аллаһыбызны мактагыз!»
[6] Аннан соң, мин, зур халык төркеменнән чыккандай, шар-
лавык аккандай һәм көчле күк күкрәгәндәй тавыш белән әй-
телгәнне ишеттем:
«Раббыны мактагыз!
Чөнки Чиксез кодрәт Иясе Раббы Аллаһыбыз
патшалык итә башлады!
[7] Куаныйк һәм нык шатланыйк, Аны данлыйк!
Чөнки Бәрәннең туе килде, һәм Аның кәләше үзен
әзерләде».
[8] Кәләшкә, кияр өчен, ялтырап торган нәфис
ак җитен тукымадан чиста кием бирелде,
чөнки ак җитен – изге кешеләрнең тәкъва
эшләре ул.
[9] Фәрештә миңа: «Бәрәннең туй мәҗлесенә чакырылганнар
бәхетле, – дип язарга кушты. – Бу сүзләр – Аллаһының хакый-
кый сүзләре», – диде ул. [10] Шуннан соң мин, сәҗдә кылырга
дип, аның аякларына егылдым, әмма ул миңа әйтте: «Кара аны,
болай эшләмә! Мин синең һәм Гайсәнең шаһитлеге булган
имандашларыңның хезмәттәше. Аллаһыга сәҗдә кыл. Чөнки
Гайсәнең шаһитлеге пәйгамбәрләрне рухландыра».

*Ак ат өстендәге җайдак*

[11] Мин ачылган күкне күрдем. Менә ак ат; аның Җайдагы
Тугры һәм Хакыйкый дип атала. Ул гадел хөкем итә һәм сугыш
алып бара. [12] Аның күзләре ут ялкыны кебек һәм башында
күп таҗлар иде. Аңа Үзеннән башка һичкем белми торган исем
язылган иде. [13] Ул канга баткан кием кигән һәм Аның исеме –
Аллаһы Сүзе. [14] Аның артыннан ак атларга атланган ак, чиста,
нәфис җитеннән кием кигән күк гаскәрләре ияргән. [15] Аның
авызыннан, халыкларга сугар өчен, үткен кылыч чыгып тора,
һәм Ул Үзе алар өстеннән тимер таяк белән хакимлек итәчәк.
Ул Чиксез кодрәт Иясе Аллаһының ярсу һәм ачу шәрабын
изгечтә изә. [16] Аның киемендә һәм ботында «Патшаларның
Патшасы һәм хакимнәрнең Хуҗасы» дигән исем язылган.
[17] Аннан соң, мин кояшта торучы бер фәрештәне күрдем. Ул,
бик югарыда очучы бөтен кошларга мөрәҗәгать итеп, көчле та-
выш белән кычкырды: «Килегез, Аллаһының бөек кичке мәҗле-
сенә җыелыгыз! [18] Патшаларның һәм гаскәр башлыкларының,
көчлеләрнең, атларның һәм аларның җайдакларының итен,

бөтен ирекмеләрнең һәм колларның, кечеләрнең һәм зурларның итен ашагыз».
[19] Мин теге җанварны, җир патшалары һәм аларның гаскәрләрен атта Утыручыга һәм Аның гаскәренә каршы сугышырга дип
җыелганнарын күрдем. [20] Аннары, җанвар һәм аның каршында
галәмәтләр күрсәткән ялган пәйгамбәр кулга алындылар. Бу ялган пәйгамбәр җанвар тамгасын кабул иткәннәрне, аның сынына табынучыларны шул галәмәтләр ярдәмендә алдаган иде. Алар
икесе дә янып торган күкертле күлгә тере килеш ыргытылды. [21] Ә
калганнары атта Утыручының авызыннан чыккан кылыч белән үтерелделәр, һәм барлык кошлар аларның итен ашап туйдылар.

*Мең ел буе патшалык итү*

**20** [1] Шуннан соң, мин үзендә упкын ачкычы һәм кулында зур чылбыр булган күктән төшүче фәрештәне күрдем.
[2] Ул борынгы елан аждаһаны, ягъни иблис-шайтанны
тотып алды һәм аны мең елга чылбырлады. [3] Мең ел үткәнгә кадәр халыкларны алдамасын өчен, аны упкынга ташлады, бикләп куйды һәм упкынга мөһер сукты. Мең елдан соң, ул аз гына вакытка азат ителергә тиеш.
[4] Аннан соң, мин тәхетләрне һәм анда утыручыларны күрдем. Аларга хөкем итәргә хокук бирелгән иде. Гайсә хакында шаһитлек иткәннәре өчен һәм Аллаһы сүзе өчен башлары киселгән, җанварга һәм аның сынына табынмаган, маңгайларына һәм кулларына тамга салдырмаган кешеләрнең җаннарын күрдем. Алар үледән терелеп тордылар һәм Мәсих белән мең ел
буе патшалык иттеләр. [5] (Үлгәннәрнең калганнары исә мең ел
үтмичә терелмәделәр.) Бу – беренче терелү. [6] Беренче терелүдә
катнашучылар бәхетлеләр һәм изгеләр. Икенче үлем алар өстеннән хакимлек итми инде, ләкин алар Аллаһының һәм Мәсихнең руханилары булачаклар. Алар Мәсих белән бергә мең ел буе патшалык итәчәкләр.

*Шайтанны хөкем итү*

[7] Мең ел үткәч, шайтан үзенең төрмәсеннән азат ителәчәк
[8] һәм җирнең дүрт почмагындагы Гог һәм Магог халыкларын алдап, сугышка җыяр өчен чыгачак. Аларның саны диңгез комы
кебек күп булыр. [9] Алар җир киңлегенә чыктылар һәм Аллаһының изге кешеләре яшәгән станны һәм яраткан шәһәрне камап алдылар. Әмма күктән ут төшеп, аларны яндырып бетерде.
[10] Җанвар белән ялган пәйгамбәр ташланылган утлы һәм күкертле күлгә аларны алдаучы иблис тә ыргытылды. Алар анда көне-төне һәм мәңге газапланачаклар!

*Үлеләрнең хөкем ителүе*

[11] Аннан соң, мин зур ак тәхет һәм анда Утыручыны күрдем.
Аның йөзеннән җир белән күк качты һәм, аларга урын табыл-
мады. [12] Тәхет каршында торучы үлгәннәрне – зурларны һәм
кечеләрне күрдем. Китаплар ачылып куелганнар иде. Тормыш
китабы дип аталган башка китап та ачылган иде. Китапларда
язылган буенча, үлгәннәр үз эшләренә карата хөкем ителде-
ләр. [13] Диңгез үзендә булган үлгәннәрне бирде. Үлем һәм үлем
патшалыгы да үзендә булган үлгәннәрне бирделәр. Бу үлгән
кешеләр һәркайсысы үз эшләренә карата хөкем ителделәр.
[14] Үлем һәм үлем патшалыгы да утлы күлгә ыргытылдылар. Бу
утлы күл – икенче үлем. [15] Исеме Тормыш китабында табылма-
ган һәркем шул утлы күлгә ыргытылды.

*Яңа күк һәм яңа җир*

**21** [1] Шуннан соң, мин яңа күкне һәм яңа җирне күрдем.
Чөнки әүвәлге күк һәм әүвәлге җир юкка чыктылар,
диңгез дә инде юк. [2] Мин, үзенең кияве өчен әзерлән-
гән, бизәнгән кәләш кебек, Аллаһыдан, күктән төшүче яңа
изге Иерусалим шәһәрен күрдем. [3] Һәм тәхеттән килгән көчле
тавышны ишеттем: «Менә Аллаһының кешеләр белән яшәү
урыны. Ул кешеләр белән бергә яшәячәк. Алар Аның халкы
булачак һәм Аллаһы Үзе алар белән булачак, Ул аларның Ал-
лаһысы булачак. [4] Ул аларның һәр күз яшен сөртәчәк һәм үлем,
кайгы, ачы тавыш, авырту башка булмаячак. Чөнки әүвәлге
үтеп китте».

[5] Тәхеттә Утыручы әйтте: «Менә, Мин һәммә нәрсәне яңа
итеп ясыйм. Яз, чөнки бу сүзләр ышанычлы һәм хакыйкый».
[6] Ул миңа әйтте: «Гамәлгә ашты! Мин – Альфа һәм Омега,
Башы һәм Ахыры. Сусаучыга Мин тереклек суы чишмәсен-
нән эчәргә бушлай бирәм. [7] Җиңүче моның барысына ия була-
чак һәм аның Аллаһысы Мин булачакмын, ә ул Минем улым
булачак. [8] Әмма куркакларның, тугры булмаганнарның, әшә-
келәрнең, кеше үтерүчеләрнең, фәхешлек кылучыларның, си-
херчеләрнең, потка табынучыларның, барлык ялганчыларның
өлеше ут һәм күкерт белән ялкынланып торган күлдә. Бу –
икенче үлем».

*Яңа Иерусалим*

[9] Минем янга соңгы җиде бәла-каза белән тулы җиде касә
тоткан җиде фәрештәнең берсе килде һәм: «Кил, мин сиңа
кәләшне, Бәрәннең хатынын күрсәтәм», – диде. [10] Мине Рух

биләп алды һәм фәрештә мине гаять зур һәм биек тауга күчерде. Ул миңа Аллаһыдан, күктән төшүче изге Иерусалим шәһәрен күрсәтте. [11] Ул шәһәр Аллаһы данынннан балкып тора иде. Аның яктылыгы асылташ балкышына һәм чиста яшма кристаллы балкышына охшашлы иде. [12] Аның коймасы бик зур һәм биек, унике капкасы бар һәм капкалары янында унике фәрештә иде. Капкаларында Исраил халкының унике кабиләсенең исемнәре язылган. [13] Көнчыгыштан өч капка, төньяктан өч капка, көньяктан өч капка һәм көнбатыштан өч капка бар иде. [14] Һәм шәһәр коймасының унике нигезе бар. Ул нигезләрдә Бәрәннең унике рәсүленең исемнәре язылган иде.

[15] Миңа сөйләүче фәрештәнең шәһәрне һәм аның капкаларын, коймасын үлчәр өчен алтын үлчәү таягы бар иде. [16] Шәһәр тигезьяклы дүртпочмак булып урнашкан: аның озынлыгы киңлегенә тигез иде. Фәрештә шәһәрне таяк белән үлчәде, ул унике мең стадия* булды; аның озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге бертигез иде. [17] Фәрештә аның коймасын үлчәп чыкты. Койма фәрештә кулланган кеше үлчәме буенча йөз кырык дүрт аршын** булды. [18] Аның коймасы асылташтан иде, шәһәр исә үтә күренмәле пыяла сыман саф алтыннан иде. [19] Шәһәр коймасының нигезләре төрле асылташлар белән бизәлгән иде: беренче нигезе – яспис, икенчесе – зәңгәр якут, өченчесе – халцедон, дүртенчесе – зөбәрҗәт, [20] бишенчесе – оникс, алтынчысы – сердолик, җиденчесе – хризолит, сигезенчесе – берилл, тугызынчысы – топаз, унынчысы – хризопраз, унберенчесе – гиацинт, уникенчесе – аметист. [21] Унике капка – унике энҗе, капкаларның һәрберсе бер энҗедән иде. Шәһәрнең урамы – үтә күренмәле пыяла сыман, саф алтыннан иде.

[22] Мин шәһәрдә Аллаһы Йортын күрмәдем, чөнки бу шәһәрнең Аллаһы Йорты – Чиксез кодрәт Иясе Раббы Аллаһы Үзе һәм Бәрән. [23] Шәһәр кояшның һәм айның яктыртуына мохтаҗ түгел, чөнки Аллаһының даны аны яктырта һәм аның яктырткычы – Бәрән Үзе. [24] Халыклар бу шәһәрнең яктылыгы астында йөриячәкләр, җир патшалары аңа үзләренең даннарын китерәчәкләр. [25] Көндез аның капкалары һичкайчан ябылмаячак, чөнки анда төн булмаячак. [26] Бу шәһәргә халыкларның данын һәм хөрмәтен китерәчәкләр. [27] Шәһәргә һичбер шакшы әйбер, әшәкелек эшләүче һәм ялганчы кермәячәк, фәкать исемнәре Бәрәннең Тормыш китабында язылганнар гына керәчәк.

---

* 21:16 *Унике мең стадия* – ике мең өч йөз чакрым чамасы.
** 21:17 *Аршын* – монда якынча 0,5 метр.

*Тереклек суы елгасы*

**22** [1]Шуннан соң, фәрештә миңа Аллаһының һәм Бәрәннең тәхетеннән чыккан, кристалл сыман ялтырап торган тереклек суы елгасын күрсәтте. [2]Ул елга урамның уртасыннан ага. Елганың бу һәм теге як ярында унике тапкыр җимеш бирүче, һәр айны үз җимешен бирүче тереклек агачы бар. Агачның яфраклары халыкларны савыктыру өчен. [3]Шәһәрдә ләгънәт ителгән бер нәрсә дә булмаячак, фәкать Аллаһының һәм Бәрәннең тәхете торачак, һәм Аның бәндәләре Аңа хезмәт итәчәкләр. [4]Алар Аның йөзен күрәчәкләр, һәм Аның исеме аларның маңгайларында булачак. [5]Анда инде төн булмаячак, һәм аларның яктырткыч белән кояш яктылыгына мохтаҗлыклары булмаячак. Чөнки аларны Раббы Аллаһы яктыртачак, һәм алар мәңге патшалык итәчәкләр.

[6]Аннары, фәрештә миңа әйтте: «Бу сүзләр ышанычлы һәм хакыйкый. Пәйгамбәрләр рухының Раббы Аллаһысы Үзенең бәндәләренә, тиздән нәрсә булырга тиешлеген күрсәтергә дип, Үзенең фәрештәсен җибәрде».

*Гайсәнең килүе*

[7]«Менә, тиздән киләчәкмен! Бу китапның пәйгамбәрлек сүзләрен үтәүче бәхетле».

[8]Мин, Яхъя, боларны ишеттем һәм күрдем. Мин ишеткәч һәм күргәч, сәҗдә кылырга дип, боларны күрсәтүче фәрештәнең аякларына егылдым. [9]Әмма ул миңа әйтте: «Кара аны, моны эшләмә! Мин синең, пәйгамбәр имандашларыңның һәм бу китап сүзләрен үтәүчеләрнең хезмәттәше. Аллаһыга сәҗдә кыл».

[10]Ул миңа әйтте: «Бу китапның пәйгамбәрлек сүзләрен яшермә, чөнки вакыт якын. [11]Яманлык кылучы яманлык кылуын дәвам итсен, бозык кеше үзен тагын да бозыклатсын, тәкъва кеше тагын да тәкъвалык тудырсын һәм изге кеше изге яшәү рәвешен дәвам иттерсен».

[12]«Менә, тиздән киләм! Һәркемгә үз эшләренә карата бирер өчен, әҗерне Үзем белән алып киләм. [13]Мин – Альфа һәм Омега, Беренче һәм Соңгы, Башы һәм Ахыры. [14]Тереклек агачына һәм капка аша шәһәргә керергә хокуклы булыр өчен киемнәрен юып пакьләндерүчеләр бәхетле. [15]Әтләр, сихерчеләр, фәхешлек кылучылар, кеше үтерүчеләр, потка табынучылар, ялганны ятратучы һәм эшләүче һәркем тышта калачак. [16]Мин, Гайсә, Үземнең фәрештәмне сезгә болар хакында бердәмлекләрдә шаһитлек итәргә дип җибәрдем. Мин – Давыт токымыннан, иртәнге якты йолдыз».

17 Рух та, кәләш тә: «Кил!» – диләр. Һәм ишетүче дә: «Кил!» –
дип әйтсен. Сусаучы килсен, теләгән кеше тереклек суын
бушлай алсын.
18 Бу пәйгамбәрлек китабының сүзләрен ишетүчене мин кисә-
тәм: әгәр берәрсе боларга өстәсә, Аллаһы ул кешегә бу китапта
язылган бәла-казаларны өстәр. 19 Әгәр берәрсе бу пәйгамбәр-
лек китабының сүзләрен төшереп калдырса, бу китапта языл-
ган тереклек агачыннан һәм изге шәһәрдән Аллаһы ул кешенең
өлешен төшереп калдырыр.
20 Бу сүзләр хакында шаһитлек Бирүче әйтә: «Әйе, тиздән
киләм!» Амин, Раббы Гайсә, кил!
21 Раббы Гайсәнең мәрхәмәте барлык иман итүчеләр белән
булсын! Амин.